2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

# Шушы яктан, шушы туфрактан без

**IV Республикакүләм укуларның**

**«Түгәрәк өстәл» юнәлеше материаллары**

**февраль, 2021 нче ел**

**ББК 84 (2Рос=Тат)6**

**УДК 821.512.145**

**М62**

**Төзүчеләр:**

Шәйдуллина Л.К., «Шушы яктан, шушы туфрактан без» проекты авторы

Афзалова Л.А., математика укытучысы;

Галиәхмәтова Г.И., математика укытучысы.

**Конференциянең юнәлеше өчен җаваплы укытучылар:** Закирова Ә.Р., Мусина Г.Ф., Юнысова Р.Ф., Нуретдинова А.Г., Фәрхетдинова Т.Ф., Шәйхелисламова Л.Ф.

**Техник редактор:** Гатин Р.И., директорның информатизация буенча урынбасары.

**Проектның фәнни консультанты:** Миннегулов Х.Й., филология фәннәре докторы, академик, Татарстанның Язучылар берлеге әгъзасы

**Шушы яктан, шушы туфрактан без.** Якташларыбыз – укытучы, шагыйрь, фронтовик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әзһәр Габидинең тууына – 95, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Хәниф Хәйруллинның тууына – 90, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе шагыйрә Клара Булатованың – 85, прозаик, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Фәрит Яхинның 60 яшьлек юбилейларына багышланган республикакүләм укуларның методик эшкәртмәләр юнәлеше материаллары. – Җәлил бистәсе, 2021 ел.

**Шушы яктан, шушы туфрактан без**. Материалы IV Республиканских чтений, посвященных юбилеям писателей Сармановского района: 95-летию со дня рождения поэта, заслуженного работника культуры ТАССР Азгара Габиди, 90-летию со дня рождения писателя, журналиста, заслуженного деятеля культуры ТАССР Ханифа Хайруллина, 85-летию поэтессы, лауреата премии имени Г.Тукая Клары Булатовой, 60-летию поэта, прозаика, доктора филологических наук, заслуженного работника культуры Татарстана и России Фарита Яхина. – пгт. Джалиль, 2021 год.

**В сборнике собраны материалы конкурса конспектов (сценарий, технологических карт) уроков и внеурочных занятий, нацеленных на пропаганду творчества писателей и поэтов-юбиляров, составленных учителями и воспитателями, библиотекарями, музейными работниками.**

**Члены жюри:**
Шамсетдинова Расима Равиловна, зав.кафедрой татарского языка ИРО РТ
Фаттахова Рузиля Фирдавесовна, кандидат филологических наук, доцент
Хадиева Гульнара Василовна, старший преподаватель кафедры татарского языка ИРО РТ
Гыйлязева Лилия Гыйльметдиновна, старший преподаватель кафедры татарского языка ИРО РТ
Вагапова Адиля Рустамовна, старший преподаватель кафедрой татарского языка ИРО РТ

**Шушы яктан, шушы туфрактан без**
(Дәрестән тыш чара эшкәртмәсе)

Нуртдинова Раушания Равил кызы, татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Кәлимуллина Әлфия Нәҗиб кызы китапханәче, А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш мәктәбе, Сарман районы

**1 нче алып баручы.** Сарман халкы – ачык, киң күңелле, талантлы, җырга-моңга оста, ярдәмчел һәм эшчән халык. Һәр районның үзенә генә хас, кабатланмас, истәлекле урыннары, горурланырлык күренекле шәхесләре бар. Татар дәүләт академия театры артисткасы Фәридә Мирхафизан кызы Сафина; Татарстанның халык артисткасы Зөһрә Шәрифуллина; Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Илһам Гыйльметдин улы Шакиров; язучы, журналист, һәвәскәр археограф Дамир Хәйрулла улы Гарифуллин; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева һәм башка тагын бик күп күренекле шәхесләр чыккан туган төбәгебездән.

**2 нче алып баручы.** Бүгенге чарабызны якташларыбыз – укытучы, шагыйрь, фронтовик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әзһәр Габиди, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Хәниф Хәйруллин, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Клара Булатова, прозаик, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Фәрит Яхинга багышларбыз. Быел Әзһәр Габидинең тууына 95, Хәниф Хәйруллинның тууына 90 яшь булган булыр иде, ә Клара Булатовага – 85 яшь, Фәрит Яхинга 60 яшь тула. Клара Булатова әйткәндәй, шушы яктан, шушы туфрактан алар.

**Җыр: «Шушы яктан, шушы туфрактан без» (Клара Булатова сүзләре, Рәис Нәгыймов көе)**

**Китапханәче, презентация кулланып, Әзһәр Габидинең биографиясе белән таныштырып үтә, әсәрләреннән, аның турында язылган чыганаклардан төзелгән күргәзмә белән таныштыра**

**1 нче алып баручы.** Әзһәр Сәмигулла улы Габиди – балалар әдәбиятының танылган өлкән шагыйре. Сарманыбызның йөзек кашы Әзһәр Габиди башлыча балалар шигъриятенә хезмәт итте. Аның балалар өчен «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Калган эшкә кар ява», «Таң сәгате», «Без – яз дуслары», «Югалган кояш» китаплары дөнья күрде. Әзһәр Габидинең балалар өчен язган шигырьләре туган як, андагы вакыйгалар, күренешләр турында. Аларның һәркайсына шагыйрь балалар күзлегеннән карап бәя бирә. Туган ил, туган җир темасы Ә. Габидинең балалар өчен язган шигырьләрендә кызыл җеп булып сузылган. Төрле образлар аша ул туган як җиренең уңдырышлылыгы, муллыгы турында сөйли.

**Ә. Габидинең «Нарат» шигырен бер укучы сөйли**

**2 нче алып баручы.** Әзһәр Габидинең шигырьләре композиторлар өчен илһам чыганагы булып тора. Аның дистәләгән шигыренә Илгиз Закиров, Зөфәр Сәхәбиев, Равил Курамшин, Мәгъфур Йөзлебаев, Хәмит Җаббаров, Эмиль Хуҗиәхмәт һәм Валерий Әхмәтшиннар көйләр дә язганнар. «Бар ул ярату», «Эзеңдә яшел чирәм», «Онытмасаң бер кайтырсың әле», «Зәңгәр тау кызларына», «Ник гармун уйный икән?», «Эх, кайтса егет чагым», «Аланнарда балан», «Җәлил», «Болыннарым», «Сине генә уйлап», «Түгәрәк күл».

**Җыр «Аланнарда балан» (Ә.Габиди сүзләре, З.Мөхәммәтдин көе)**

**1 нче алып баручы.** Әзһәр Габиди әниләр турында да бик күп шигырьләр язган.

«...Аналарның җылы канаты –
Бала өчен җылы каралты», – дип яза ул гади генә итеп. Шушы ике юлга нинди тирән мәгънә салынган. Шагыйрьнең әниләр турында шигырьләре: «Шифа күчтәнәче», «Ярлыкама», «Рәхмәт, әнкәй!», «Әнкәй миннән сәлам көткәндер», «Ник әйтмәде икән?», «Ана көтә улын», «Ана сагышы», «Минем әни киң күңелле иде», «Әнкәй киңәше», «Аналарга хатлар юллагыз», «Әнкәй», «Җирне сөйгән кеше бирешмәс».

**Ә.Габидинең «Әнкәй» шигырен бер укучы сөйли.**

**2 нче алып баручы.** Әзһәр Габиди иҗатын кыска вакыт аралыгында гына бәяләп, шигырьләренә анализ ясап бетереп булмый. Ул мәсәлләр, балладалар авторы да, шагыйрь дә, очерклар, тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр язучы да. Әзһәр ага милләтне, телне, табигатьне сакларга чакырды, тарихны онытмаска өндәде, мәхәббәткә дан җырлады. Ул гомере буе дөньяны акларга теләде.

**1 нче алып баручы.** Шагыйрь үзе «Ничек болай булды әле?» шигырендә менә нәрсә ди:

Китте, диеп, мәңгелеккә, онытмагыз,
Каберемә эзегезне суытмагыз.
Аның өстен капламасын ачы әрем,
Җитте инде, күп татыдым аның тәмен.
Каберемә чәчәкләр дә куйгалагыз,
Мин бит сезгә чит-ят түгел – үз балагыз.

**2 нче алып баручы.** Укытучы, шагыйрь, фронтовик, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия иясе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Әзһәр абый Габиди күбрәк игътибарга лаек. Без аны онытырга тиеш түгел.

Китапханәче, презентация кулланып, Хәниф Хәйруллинның биографиясе белән таныштырып үтә, әсәрләреннән, аның турында язылган чыганаклардан төзелгән күргәзмә белән таныштыра

**1 нче алып баручы.** Хәниф Гыйздулла улы Хәйруллин – язучы, журналист. Иҗатының үзәгендә – авылда барган үзгәрешләр, туган төбәгенең үткәне турында язылган роман, повестьлар, очерклар. Балалар өчен язылган беренче әсәре «Бакыр базының серләре» «Ялкын» журналында басылып чыга. Балалар өчен «Тылсымлы таяк табышы» исемле маҗаралы повесть язды. Әсәрләре авыл тормышы һәм авыл кешеләре язмышы турында. Унлап китабы басылып чыккан.

**2 нче алып баручы.** 2019 елда Сарманда Хәниф Хәйруллин исемендәге беренче премия ияләре ачыкланды, җиңүчеләргә бүләкләр тапшырдылар. Премияләргә хәбәрчеләр – Сарман авылыннан Клара Вәлишина, Җәлилдән татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ландыш Шәйдуллина, мәгариф бүлеге белгече Илназ Дәүләтбаев лаек булдылар. Бүләкләрне Сарман мәгълүмат-мөхәррият үзәге җитәкчесе Альбина Сабирова һәм иганәче Хәниф абыйның улы Ленар Хәйруллин тапшырды.

**1 нче алып баручы.** Безнең район – сандугачлы зәңгәр таулар иле. Бакыр Тау (Сармандагы бакыр руднигы) – тау токымнарын эшкәртү сәнәгате тарихи истәлеге, Сарман районы үзәге янәшәсендә урнашкан туристлык объекты. 2013 елда 13 000 турист килгән. XVIII гасырдан калган, тикшерелгән һәм әле дә сакланган иң иске рудниклардан санала. Мәгарә озынлыгы 2 000 метрга җитә. Эчендә бозылмый торган, саф сулы күл бар. Һава температурасы $+7^0$ С. Менә шушы Бакыр Тау турында Хәниф Хәйруллин «Бакыр базының серләре» әсәрендә яза да инде.

Х. Хәйруллинның «Бакыр базының серләре» әсәреннән өзек уку.

Х. Хәйруллинның «Тылсымлы таяк табышы» исемле маҗаралы повестеннан өзек уку.

**2 нче алып баручы.** Сарман гимназиясендә Хәниф Хәйруллинга багышланган музей бар. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Хәниф Хәйруллин Сарманда иҗат иткән. 1998 елның 18 июнендә вафат була. 1974 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы булган. 1981елда аңа татар әдәбиятын үстерүдәге казанышлары өчен «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирелгән. Аның иҗаты ихтирамга лаек.

Китапханәче, презентация кулланып, Клара Булатованың биографиясе белән таныштырып үтә, әсәрләреннән, аның турында язылган чыганаклардан төзелгән күргәзмә белән таныштыра

**1 нче алып баручы.** Клара Булатова иҗаты барлык яшьтәге кешеләргә: әби-бабайлар, әти-әниләр, яшьләр, үсмерләр өчен дә аңлаешлы. Менә аның кечкенә балалар өчен язган «Марс китабы», «Әллә кайсын тыңласы», «Курка димәгез әле», «Камилә – тәти кыз» дигән китаплары чыкты. Бай сурәтләү чаралары аша бу китаплар балаларны яхшылыкка өнди, дөньяны ныграк танып белергә өйрәтә.

**2 нче алып баручы.** Мәктәпне бетергәч, ул Казан дәүләт /университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Университетны тәмамлаганнан соң, Клара Булатова Әлмәт районының Яңа Кәшер урта мәктәбенә тел-әдәбият укытучысы булып китә. Шуннан соң ул башы-аягы белән мәктәпкә чума һәм үзенә яңа бер дөнья ача – балалар дөньясы. Балалар күңеле аның җанына яктылык биреп, шигырьләренә нур өсти. Балалар өчен матур-матур китаплар чыгара. Бик күп шигырьләрендә ул мәктәпкә, балаларга булган олы мәхәббәтен сурәтли:

Миңа сорау бирсәләр,
– Шатлыгың ни? – дисәләр,
Шушы мәктәп сукмаклары
Шатлыгыма илтәләр.

**1 нче алып баручы.** К. Булатова шигриятенең төп темасы – мәктәп, балалар язмышы. Тумыштан ук шагыйрә булган кебек, тумыштан ук укытучы да. Мәктәптә изелгән, мәктәптә басылган һәм мәктәптә әвәләнгән бер җан иясе ул. Бик якын кешесенә ул болай җавап биргән:

…Тотасың да миңа «ташла» дисең,
Шулмы булды дуслар әйткән сүз?
Минсез дә ул мәктәп мәктәп инде,
Мин кем булыр идем мәктәпсез?

**2 нче алып баручы.** Клара Булатова – чын мәгънәсендә милләтебезнең күренекле шәхесе, атаклы укытучысы. Сарман җирлегендә туып, безне искиткеч шигъри әсәрләре белән сөендерә алуы – безнең өчен чиксез горурлык бит! Укытучы, укучы, мәктәп темаларын яктыртып, яшь буынга уйланырлык җирлек тудыра белә ул.

**1 нче алып баручы.** Яңа көнгә яңа хужа булып яңа буын килә, дип куана шагыйрә. Оныгы Марат тугач, инде әби булгач, балалар өчен яңа җыр текстлары языла башлый. Үз оныгы өчен генә түгел, күпләрнең оныклары өчен изге дога булырдай юллар бар аларда.

Күкләргә кара, улым,
Йолдызлар сана, улым.
Йолдызларны таныган бала
Үз юлын таба, улым.

Җыр – шигырьнең соңгы юлларында:

…Йолдызың күрсәткән юлдан
Тайпылмасана, улым, – дип, меңләгән әниләрнең, әбиләрнең гозер-теләкләрен җиткерә.

**2 нче алып баручы.** Клара Булатованың оныгы Гайшә Марс кызы Булатованың да шигырьләр язуы тагын да куандыра безне. Ул язган шигырьләрдән дөнья күргән «Әбиләрдә кунакта» китапчыгыннан шигырьләр сөйләп китәсебез килә.

**Гайшә Булатованың «Үзем болай кечкенә», «Әбиләргә бүләк», «Икенче Клара» шигырьләрен укучылар сөйли**

**1 нче алып баручы.** Гомумән алганда, Клара апаның иҗаты сокландыру тудыра. 2021 елның 18 мартында Клара Булатовага 85 яшь тулачак. Озак еллар яшәп, сәламәт булып, тагын бик күп әсәрләр иҗат итәргә язсын аңа. Шагыйрәнең шигъри тойгылары бик заманча, күңелгә хуш килә торган, теле бик ачык, авылча, саф татарча. Клара Булатова – шагыйрь булып туган кеше, шигырь җанлы, фанатик шагыйрә, талантлы, бик популяр шагыйрә ул.

**2 нче алып баручы.** Аның иҗаты елдан-ел киңәя, алга атлый барганлыгы, бер урында таптанмавы күренеп тора. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Рафаил Төхфәтуллин, Саҗидә Сөләйманова премияләре иясе, Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы Клара Булатова хәзерге көндә дә – дистәләгән шигырь китаплары һәм күпсанлы җырлар авторы. Клара Булатова сүзләренә язылган җырлар: «Асылмалы күпер», «Бәлки син үзедер», «Кырга чыктым, юлга чыктым», «Кыңгырау чәчәкләре», «Онытма», «Су буенда кыяк үлән», «Тамчы җыры», «Туган як сагышлары», «Язлары еракта гомеремнең».

**«Кызара инде миләшләр» җыры (Р. Андреев көе, К. Булатова сүзләре)**

Кызара инде миләшләр,
Ни көтә тиле күңел?..

Әйтерсең, әле гел яшьләр,
Әйтерсең, илле түгел.
Әйтерсең, әле күзем дә
Күрә гел көннең алын.
Әйтерсең, әле синең дә
Артымнан йөргән чагың.
Әйтерсең, әле телең дә
Гел матур сүзләр сибә.
Үзгәрдең юкса, үзгәрдең,
Үзгәрдең… Күзләр килә.
Сүзгә дә саран димәсләр,
Сайламый гөлен генә.
Кызара инде миләшләр,
Күз дими күңел генә.

Китапханәче, презентация кулланып, Фәрит Яхинның биографиясе белән таныштырып үтә, әсәрләреннән, аның турында язылган чыганаклардан төзелгән күргәзмә белән таныштыра

**1 нче алып баручы.** 2021 елның 2 гыйнварында прозаик, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, чыгышы белән безнең ут күршебез Дүсем авылыннан булган Фәрит Зәкиҗан улы Яхинга 60 яшь тулды.

**2 нче алып баручы.** Фәрит Яхин иҗатының татар әдәбиятында үз урыны бар. Шагыйрь, язучы, әдәбият галиме Фәрит Яхинның иҗаты, әдәбиятка килеп керешкә, бәхетле язмышка очрады. «Прозада беркемне дә кабатламый торган үз стиле, үз язу осталыгы белән Ф.Яхин Гомәр Бәширов, Фатих Хөснидән килә торган әдәби осталыкны, Аяз Гыйләҗев һәм Мөхәммәт Мәһдиевнең ялкынлы, милли якты хисләргә үрелеп бара торган мәгънәле прозаны сәнгатьчә камиллеккә күтәрешкән, аны яңа сыйфатлар белән баеткан каләм остасы», – дип язды Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, тәнкыйтьче Алсу Шәмсутова «Шәһри Казан» газетасында Фәрит Яхин турында.

**1 нче алып баручы.** Ф.Яхин – лирик тезмәләре тупланган өч шигъри җыентык («Гүргә кадәр саклнган сөю», «Таңга кайту», «Хис керфегемдә күз яшең») һәм балалар өчен «Могҗизалы ел фасыллары» дигән әкият-поэма (1994) авторы. Аның «Мөхәммәдьяр» исемле драматик поэмасы 1997 елда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә спектакль итеп куела.

**2 нче алып баручы.** Ул проза жанрында да актив иҗат итә, укучыларга көндәлек матбугатта басылган дистәләрчә хикәя, повестьлары һәм ике кисәктән торган «Август ае» дигән романы белән билгеле. Болардан тыш Ф.Яхинның борынгы төрки-татар әдәбияты ядкәрләрен текстологик яктан басмага әзерләү юнәлешендә алып барган нәтиҗәле фәнни-мөхәррирлек эшчәнлеген дә аерым әйтеп үтәргә кирәк.

**1 нче алып баручы.** Соңгы елларда басмада дөнья күргән Әхмәд Ясәви хикмәтләре, Сәйядинең «Дастаны Бабахан»ы, Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин»е («Гаҗизләргә терәк»), Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» кыйссасы, «Бакырган китабы» – болар барысы да Ф.Яхинның турыдан-туры катнашы белән әзерләнгәннәр.

Ф.Яхинның «Могҗизалы ел фасыллары, яки Күбәләк кыз турында әкият» дигән әкият-поэмасыннан бер укучы өзек сөйли.

**2 нче алып баручы.** Туган ягыбызның гүзәл табигате, Сарман төбәгенең җырга-моңга бай халкы аны әдип буларак формалаштырган. Бу турыда Ф.Яхин «Сөембикә» журналында «Тәгәрәпләр китте йөрәгем» исеме астында бастырылып чыккан Р.Мулланурова белән әңгәмәсендә үзе әйтә.

**1 нче алып баручы.** Ф.Яхин мәктәптә укыган чакларында, унөч яшеннән шигырьләр яза башлый. Аның шул чорда тормышка үзенчәлекле карашлары формалаша. «Сарман таңнары» дип аталган, район үзәгендә «Ленинчы» район газетасы каршысында оешкан әдипләрнең утырышларына йөри, районлаш шагыйрьләр белән хатлар алыша.

**Ф. Яхинның «Шигырь туу» шигырен бер укучы укый.**

Тишелми орлык вакыты җитмичә,
Тумый шигырь йөрәктә пешмичә,
Балкып чәчәктәй аңкытмый моңын
Һәм дә тибрәтми бәндәләр җанын.
Чү!..
Тишелде орлык — бодай бөртеге,
Сынды күземнең сыңар керфеге!

2 **нче алып баручы.** Мәктәпне тәмамлагач, Фәрит Яхин университетка укырга керә, анда да шигырьләр, проза әсәрләрен язуын дәвам итә.

**Ф. Яхинның «Мин авылдан киттем» шигырен бер укучы укый.**

Мин ул көнне үзем чыгып киттем,
Калды авыл җиргә сыенып,
Юлым якын кебек иде дә шул,
Эзем барды арттан уелып.
Зар елапмы яшем тамды анда?
Яңгырлармы басты тузанны?
Куылганнар хисабыннан түгел –
Кире кайта алмыйм узганны.
Мин һаман да атлый бардым алга,
Максат арбасында җан елый!
Туган илдән киткән бәндәләрне
Чит-ят җирләр якын күралмый.
Бәхетемне эзләп бардыммы соң?
Шатлыгыммы көтте юлларда?
Башымнымы югалтырга барам –
Юлым калса әгәр елларда?
Ни чыдамлык белән түзәр җаным?
Ничек кояш чыгар, көн кичәр?
Кайтырмын дип чыгып киткән идем,
Кайталмадым,
Әнекәем нишләр?

**1 нче алып баручы.** Әдипләр арасында беренчеләрдән булып Ф.Яхин дини темаларны күтәреп чыга, Ислам дине фәлсәфәсенә корылган әсәрләрен бастыра. Бигрәк тә «Пәйгамбәрләр тарихы», «Иман», «Ислам дине нигезләре», «Пәйгамбәребез Мөхәммәд» китаплары рухларыбызны яңартуда төп рольне уйныйлар. Алар бүгенге көндә дә Ислам дине һәм Ислам фәлсәфәсе хакындагы әсәрләрдән халык арасында зур кызыксыну белән укылалар, һаман да әһәмиятләрен югалтмыйлар.

**2 нче алып баручы.** Ф.Яхин әсәрләрендә халкыбызның гореф-гадәтләре, тәрбия, гаилә, мәхәббәт күренешләре, аерым образлар, геройларның үзара мөнәсәбәтләре аша ачылалар. Бу әсәрләрне укыгач, безнең күңелләрдә матур, нәфис хисләр уяна, әхлакый кыйммәтләрне аңлыйбыз, уйлана башлыйбыз, матурлыкка омтылабыз, милләтнең киләчәге өчен борчылабыз.

**Ф. Яхинның «Татарым» шигырен бер укучы укый..**

Курыкканның җаны чыкмый калса,
Куа килә арттан коткысы,
Бу милләтнең, менә күреп торам,
Нидән качкан икән йокысы!
Бар тинтәкләр йоклаган дип йөри
Йокы күрәлмәгән мескене –
Йөрәгенә аның курку төшкән,
Яңартмакчы була искене!
Үзгәрерлек, дәртләнерлек чакта
Яраргамы кемгә маташа?
Аллага дип, Шайтанга да шунда

Хезмәт итмәк – сырхау алаша!
Искегә һәм артка юллар ябык,
Ташла шикләнүне, татарым,
Куркып торсаң, хәлең дә үзгәрмәс,
Мин дип йөрсәң иде, батырым!

**1 нче алып баручы.** Кайсы гына өлкәгә күз ташлама – Ф.Яхинның эшләгән эшләре ифрат та күп. Мул сәләте аны фәндә дә, әдәбиятта да бердәй уңышка китерә. Әлбәттә, аның характерына хас булган сыйфаты – алдына куйган ниятенә ирешүдәге ныклык, тырышлык кебек сыйфатларының да талантының күпьяклы булып ачылуында әһәмиятле роль уйнавын әйтергә кирәк. Максатка омтылудагы ныклыгы, тырыш эшчәнлеге аны фән юлына алып чыга һәм чагыштырмача тиз арада фәннең югары биеклекләренә күтәрә. Бүгенге татар әдәбиятында язучы-галим Фәрит Яхинның һичкем алыштыргысыз какшамас үз урыны бар.

**2 нче алып баручы.** Безнең як кешеләренең киң күңелле, сабыр холыклы булуларына һәркем таң кала. Әйе, күпме авырлыклар килсә дә сынмаган, сыгылмаган районадаш язучыларыбыз, шагыйрьләребез. Пандемия башлангач та, Клара Булатова өлкән яшьтә булуына карамастан, Иске Минзәләбаш авылы халкы, укучылары белән очрашуга килде. Бу бик зур батырлык диясебез килә. Шушы яктан, шушы туфрактан шул ул.

**1 нче алып баручы.**

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Читтә йөрсәк, шуңа күрәдер,
Чишмә чыңлап, өянкеләр елап,
Таллар җырлап төшкә керәдер.
Шушы якта безнең хезмәт калсын,
Мирас булып килер яшьләргә.
Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Шул туфракта язсын яшәргә!

2 нче алып баручы. Шагыйрьләргә илһам бирерлек гүзәл табигате, җырларда мактап җырларлык уңган халкы, бишек җырыдай моңлы челтерәгән чишмәләре, шаулап утырган алтын башаклы басулары, артистлары, җырчылары, язучылары, шагыйрьләре белән дан тота районым минем. Сарман ягы үзенең матур табигате белән дә, якты йөзле, эшчән кешеләре белән дә шигъри юлларга кереп, җырларда җырлана.

**1 нче алып баручы.** Хөрмәтле Клара Булатова, Фәрит Яхин! Сезнең иҗат чишмәгез сулмасын, саекмасын, тылсымлы шигырьләрегез, хикәяләрегез язылып торсын. Сез бик кирәкле кешеләр – балалар күңеленә игелеклелек орлыклары салучы, дөньяның матурлыгын аңларга, чын кеше булып үсәргә өйрәтүче, гамьле, моңлы шагыйрьләребез!

**2 нче алып баручы.** Ә Әзһәр Габиди һәм Хәниф Хәйруллиннарны бүген искә алуыбыз мәрхүмнәребезгә дога булып ирешсен иде! Һәркайсыгызга, һәркайсыбызга «Шушы яктан, шушы туфрактан без», – дип, горурланып яшәргә язсын!

## Ә тормыш, тормыш матур ул

(Клара Булатова иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Дәүләтова Илсөяр Гаязетдин кызы, Олы Арташ мәктәбе укытучысы,
Саба районы

Җиһаз. Шагыйрәнең портреты, иҗатына багышланган презентация, китапларыннан күргәзмә, шигырьләренә карата ясалган иллюстрацияләр тупланган стенд.
Эпиграф язып эленә:

Яшәвеңнең юкка түгеллеген
Раслап яшә вакыт алдында,
Раслап калдыр Тарих алдында.
( «Уйландыра, шушы уй уйландыра»)

Сәхнәгә алып баручылар чыга. Презентация куела.

**1нче алып баручы.**

Зәңгәр юллар сызам,
Юллар озын, ерак.
Шул юллардан узыйм,
Кайтыйм җирне урап,
Кайтыйм җирне урап.

**2 нче алып баручы.** Хөрмәтле укучылар, укытучылар! Шагыйрә Клара Булатова иҗатын сөюче дуслар! Бүгенге бәйрәм белән сезне – Шигырь бәйрәме белән.

**1нче алып баручы.**

Гомер үткән, дистә еллар үткән,
Язлар киткән язлар артыннан.
Ә тарихта безнең буын гомере
Шул алсулык белән балкыган.

**2 нче алып баручы.**Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Әлмәт районының Мактаулы гражданины, Рафаил Төхфәтуллин, Саҗидә Сөләйманова исемендәге премияләр лауреаты, танылган шагыйрә, укытучы Клара Булатова – иҗаты кыю омтылышлар, якты хисләре белән сугарылган, табигать һәм җәмгыятьтәге һәр вакыйга, күренешләрне сизгер һәм нәфис йөрәге белән тойган шәхес.

**1 нче алып баручы.** Шагыйрә 1936 елның 18 мартында Татарстанның Сарман районы Татар Карамалысы авылында укытучылар гаиләсендә туа. Әти-әнисе укытучылар булганлыктан, аңа бала чактан ук әти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенчесенә күчеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә.

**2 нче алып баручы.** 1954 елның көзеннән хезмәт юлын башлый: Түбән Ләшәү авылы мәктәбенең башлангыч сыйныфларында балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәт шәһәрендә көнкүреш комбинатында кассир, Төзүчеләр сараенда оештыручы вазифаларын башкара. 1962-1965 елларда ул янәдән мәктәптә – Әлмәт районының Колшәрип авылы балаларына тел-әдәбият, тарих фәннәре укыта.

**1 нче алып баручы.** 1965-1969 елларда Клара Булатова Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам иттерә.

**2 нче алып баручы.** 1967 елда студент кызның «Язлар алда» исемле лирик шигырьләре тупланган беренче китабы дөнья күрә. 1970 елдан – СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы. Ярты гасырдан артык гомерен балалар тәрбияләүгә багышлаган Клара ханымның иҗаты кеше күңелен җырлата да, елата да торган, иң мөһиме, уйландыра, җанны-рухны чистарта, өмет яктылыгын сакларга өйрәтә торган итагатьле тойгылар тупланган 50 китабы белән бай. Аның шигырьләрен балалар да, өлкәннәр дә бик яратып укыйлар.

Клара Булатованың «Шыксыз бала» хәтер кыйссасы буенча әзерләнгән күренеш.

**1 нче алып баручы.**

«Җырдан башка яшәп булмый», – диләр.
Әйе, шулай. Бик тә ышанам.
Күкрәгемне кысса авыр уйлар,
Мин үземә җырдан көч алам.

Клара Булатованың күп кенә шигырьләренә композиторларыбыз көй язган. Мәсәлән: «Шушы яктан, шушы туфрактан без» «Дүрт кыз», «Гармун», «Кайтыгыз», «Якын дустың барын онытма», «Кыңгырау чәчәкләре», «Су буенда кыяк үлән», «Арада тау киртә түгел» һәм башкалар. Хәзер аның сүзләренә язылган «Шушы яктан, шушы туфрактан» җырын тыңлап китәбез

**2 нче алып баручы.**

Ах, минем дә килә киң юлларның
Иң яктысын сайлап аласым.
Гел кояшка карап, гел кояшка карап,
Гел кояшка карап барасым.

«Юк, кайтмасын ул чор!» шигыре укыла.

**2 нче алып баручы.** Әйе, Клара Булатова шигъриятенең әдәби кыйммәте – шигырьләренең тәрбияви идея салынган эчтәлеккә ия булуда. Аның иҗаты – буыннан-буынга күчеп укырлык, киң планда өйрәнерлек тирән иҗат. Ул үзенең укучысына шигырьләре аша

әхлакый кануннарның асылын аңлата. Язучының фикере бүгенге көндә дә актуаль, тәрбияви эчтәлеккә ия.

**1нче алып баручы.**

Тәгәрәпләр йөгереп үтә гомер...
Әрәм итмә көнең:чикле гомерең!
Яшәвеңнең юкка түгеллеген
Раслап яшә вакыт алдында,
Раслап калдыр Тарих алында!

**2 нче алып баручы.**

Яраткан шагыйрәбез Клара Булатова иҗатына багышланган кичәбез тәмам.

**Сарман үзен җырга салган ихлас җанлы улын онытмас**

(Ә.Габидинең тууына 95 ел уңаеннан сценарий (телдән журнал)

Даутова Роза Могайяр кызы, Кәүҗияк мәктәбе укытучысы,
Сарман районы

**Максат**: укучыларга Әзһәр Габиди иҗаты аша шигырьләренә һәм китапларына мәхәббәт уяту. Әзһәр аганың тормыш юлын, иҗатын тирәнрәк өйрәнү.

**Залның бизәлеше:** Зал матур итеп җиһазландырыла, әкрен генә талгын музыка уйнап тора. Диварга «Әзһәр Габиди» дип язып эленә. Бүлмә уртасында, стеллажда Әзһәр ага Габидинең портреты һәм «Янсын гомер учагы» исемле китап күргәзмәсе, укучылар тарафыннан ясалган рәсемнәр куела.

**Укытучы**. Җырларда җырланган Сарман ягы, Сарман төбәге... Бу якның никадәр гүзәл як икәнен аңлау, ярату өчен, җәй көннәрендә аның урманнарыннан җиләк җыярга, челтерәп аккан чишмәләрнең көмештәй саф, балдай татлы суыннан авыз итәргә, кыш көннәрендә киртләч тауларыннан чаңгы шуарга, көзге урманнарына йөрергә, җыр-моңнарын тыңларга кирәк. Монда һәр тау итәге, һәр агач, болындагы һәр чәчәк, кыскасы, һәрбер нәрсә иҗатка, моңга, шигъриятькә рухландыра. Никадәр талантлы кешеләр үсеп чыккан Сарман төбәгеннән...

Бүгенге көндә Сарман якларыннан 25ләп шагыйрь һәм прозаик үсеп чыккан. Шулар арасында балалар һәм зурлар өчен дә матур-матур шигырьләр иҗат итүче язучыбыз Әзһәр ага Габиди дә бар. Бүгенге кичәне якташыбыз Әзһәр ага Габидинең тууына 95 ел булуга багышлыйбыз.

**«Сарман үзен җырга салган, ихлас җанлы улын онытмас»** дигән телдән журналыбызның беренче битен ачабыз.

**1 а.б.** Журналыбызның беренче бите «Иҗат башы кайдан башлана?»дип атала. Әзһәр абый 1925 елның 25 сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында дөньяга килә. Гаиләдә өченче бала булганга күрә, ул авыл тормышының бөтен авырлыкларын үз җилкәсендә татый. Балачактан ук шигъри җанлы булып үсә. Үзендә әдәбиятка, иҗатка сәләте барлыгын тоя. Тик хыяллары чынга ашмый кала. Сарман урта мәктәбендә 10 нчы сыйныфны тәмамларга да өлгерми, сугыш башлана. Шулай итеп, язмыш әле генә яшьлек чорына аяк баскан, тормышны танып белә башлаган Әзһәр абыйны фронтка илтеп ташлый. 1946 елда гына авылына кайта ул.

1950 елда Минзәлә педагогика училищесында белем ала, соңыннан Сарман районы Чукмарлы мәктәбендә 30 ел буена татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Шул вакытта аның «Без – яз дуслары» исемле беренче шигырь җыентыгы дөнья күрә һәм аны алга таба иҗат эше белән шөгыльләнергә илһамландыра.

1945 елда «Тревога» исемле фронт газетасы типографиясендә аның «Борылмалы юллардан» исемле китабы басыла.

*(«Борылмалы юллардан» исемле китабыннан шигырьләр сөйләнә).*

**2 а.б.** Журналыбызның икенче бите – Әзһәр ага Габиди – балалар шагыйре. Ә.Габиди 1942 елдан бирле әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Иҗатының зур өлеше балаларга багышланган. Аның төрле елларда дөнья күргән «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Калган эшкә

кар ява», «Таң сәгате», «Без – яз дуслары», «Өч киңәшче» һ.б. китаплары яшь буынны намуслы һәм тәртипле, тырыш һәм хезмәтчән итеп тәрбияләүдә зур роль уйный.

Әзһәр ага Габидинең балалар өчен язган шигырьләре туган як, андагы вакыйгалар, күренешләр турында. Аларның һәркайсына шагыйрь балалар күзлегеннән карап бәя бирә.

( *«Без – яз дуслары»,«Калган эшкә кар ява»,«Кошчыгым» китапларыннан шигырьләр сөйләү)*

**1 а.б.** Язучы хакында күбрәк беләсең килсә, аның туган ягына бар яки әсәрләрен укы, диләр. Шагыйрьнең туган ягы, чыннан да, искиткеч матур урында урнашкан. Кыр ягы дип даны чыккан Сарман төбәгендә туган Әзһәр Габидинең туган авылына урман аварга тора бит. Ә ул урмандагы гүзәллек, авыл чишмәләренең саф сулары, ипигә ягып ашарлык саф һавасы хакында ничек матурдан-матур шигырьләр язмыйсың ди. Мондый якны яратмаган җирдән яратырсың, мондый җирләрне сөймәс җирдән сөярсең. Авыл баласы кечкенәдән үк җиргә гашыйк, җирне сөя, аның хикмәтләрен белә Әзһәр абыйның шигырьләре нәкъ менә шулар турында. Туган як матурлыгы турында, сафлык, хаклык турында. Туган ил, туган җир темасы Ә. Габидинең балалар өчен язган шигырьләрендә кызыл җеп булып сузылган. Төрле образлар аша ул туган як җиренең уңдырышлылыгы, муллыгы турында сөйли. Мәсәлән, «Нарат» шигыре.

*(1 укучы «Нарат» шигырен сөйли.)*

<u>**2 а.б**</u>. Шул рәвешле шагыйрь яшь укучысына: «Туган җиреңнән аерылма, аерылсаң рәхәт күрмәссең», – дип әйтә сыман. Ә. Габиди балалар психологиясенә хас булган тискәре сыйфатлардан көлә, уңай сыйфатларга, киресенчә, дан җырлый, бу сыйфатларны яшь укучыда күрергә тели. Бу турыда шагыйрь ачыктан-ачык әйтми, ә бәлки киная белән яшь укучыга нәтиҗәләр ясарлык итеп сөйли. «**Һавалы чеби»** шигырендәге чуар тавык чебие кебек һаваланып йөрсәң, песи тырнагына эләгерсең, «аерылганны аю түгел, песи дә ашый». Карак мәче кебек булсаң, келәткә кереп май урлап йөрсәң, тычкан көләрлек хәлдә калырсың, – ди язучы

*(1 укучы «Һавалы чеби» шигырен сөйли.)*

<u>**1 а.б**</u>. Журналыбызның өченче бите – Әзһәр Габиди – укытучы.

Бер акыл иясе әйткән: «Берничә айдан уңыш алыйм дисәң – иген чәч, ун елдан җимеш ашыйм дисәң – агач утырт, гомерең буе кадер-хөрмәттә яшим, җир йөзендә якты эз калдырыйм дисәң – бала укыт!» Әйе, укытучы һөнәре – иң дәрәҗәле, иң гадел, иң хөрмәтле һөнәрләрнең берсе. Минзәлә педагогия училищесын тәмамлагач, Ләке, Морбаш, Чукмарлы сигезьеллык мәктәпләрендә укыта. Ул – татар теле һәм әдәбияты укытучысы гына түгел, ә оста куллы хезмәт дәресе укытучысы буларак та, үзе хакында җылы тәэсирләр калдырган шәхес. Аның укучылары белән бергә ясаган стендлары озак еллар буе мәктәпне бизәп торган. Ә ул җитәкләгән «Яшь бөре» әдәби түгәрәгенә йөреп күпме укучы беренче тапкыр шигырь язу серләренә төшенгән, беренче тапкыр шигырь язып караган. Ул – Клара Булатова, Ямаш Игәнәйнең беренче остазы, фатиха бирүчесе.

<u>**1 а.б**</u>. Журналыбызның дүртенче бите – ӘзҺәр ага Габидинең нәсел җебе.

*(1 укучы «Шәҗәрә» шигырен сөйли)*

Әзһәр аганың «Шәҗәрә» шигыреннән күренгәнчә ул затлы, тырыш, булган нәселдән. Ул – фронтовик-укытучы. Аның һөнәрен балалары дәвам итә. Ул һәм кызлары районыбыз мәктәпләрендә балаларга белем бирәләр. Әзһәр ага шигъриятта дә үзенә әллә нинди олы исемнәр, бетмәс-төкәнмәс дан өмет итеп яшәмәде. Ул бөтен барлыгын, бөтен күңелен шигырьләренә салган һәм үзе дә шигырьләре кебек үк гади, моңлы, кайнар булды. Аның иҗаты хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнде. Сугышчан орден-медальләре янына төрле газета-журналларның Мактау грамоталары өстәлде... Аңа «Халык мәгарифе отличнигы», «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр бирелде. Әзһәр ага Габиди – 1994 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Ул һичкайчан зур бөеклекләргә омтылмыйча, әрсезлек күрсәтмичә, бары иҗат итте, шигырьләр язды. Туган ягы Сарман төбәгенең кабатланмас гүзәл табигатен, аның хезмәт сөйгән халкын олылады, гашыйк булып язды, сагынып язды.

**2 а.б**. Үзе булмаса да, шигырьләре яши, матурлыкка өнди, уйландыра... Үзенең бер шигырендә мөхтәрәм шагыйребез:

Без ул кадәр

Олы шәхес түгел,
Тукайныкы кадәр эз калмас.
Ләкин Сарман үзен җырга салган.
Ихлас җанлы улын онытмас, – дип язган иде. Бу шигъри юлларга өстәп: «Сине Сарман гына түгел, җөмһүриятебез, бөтен татар халкы беркайчан да онытмас иде», – дип кабатлыйбыз.

**«Бәхетле очрак» уены**

(Клара Булатованың тормыш юлына багышланган класстан тыш эшчәнлек)

Хабибуллина Гөлнара Флорис кызы, Ибрагимова Альфира Наил кызы,
Зур Нөркәй урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы

**Максатлар:** Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне камилләштерү; укучыларның фикерләү сәләтләрен, сөйләм телләрен һәм җитезлекләрен үстерү; патриотизм хисе тәрбияләү.
**Шәхескә кагылышлы УУГ:** уку эшчәнлеге һәм аның мотивлары арасында элемтә урнаштыру.
**Регулятив УУГ:** укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; кагыйдәләрне истә тотып гамәлләр кылу.
**Танып белү УУГ:** логик фикерләүне үстерү гамәлләре башкару (анализ, синтез); тиешле мәгълүматны сайлап алу; төп мәгълүматны аеру;
**Коммуникатив УУГ:** үз фикерләрен төгәл, ачык, аңлаешлы итеп әйтергә өйрәтү.

**Җиһазлау:** Клара Булатованың портреты, китаплар күргәзмәсе, ноутбук, диск («Сарман» көе, К.Булатова сүзләренә иҗат ителгән җырларның аудиоязмалары), тур атамалары язылган слайдлар (презентация).

План.

1. Оештыру өлеше.
1.1. Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.
1.2. Сыйныфтан тыш уку дәресенең темасын билгеләү.
1.3. Сыйныфтан тыш уку дәресенең максаты белән таныштыру.
2. Төп өлеш.
2.1. Командаларга бүленү (исем, девиз, капитаннарны билгеләү).
2.2. Жюри әгъзаларын сайлау.
2.3. 1 тур «Кем тизрәк?»
2.4. II тур «Капитаннар – алга»
2.5. III тур «Син – миңа, мин – сиңа»
2.6. IV тур «Сүзне тап»
3. Йомгаклау.
3.1. Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты буенча нәтиҗә ясау.

Дәрес барышы.

Оештыру өлеше.

<u>Укытучы.</u> Исәнмесез, укучылар!
Хәерле көннәр сезгә.
Зиһен һәм тел ачкычлары
Телимен һәммәгезгә.

Утырыгыз. Үзебезнең чираттагы класстан тыш эшчәнлегебезне башлыйбыз. Бүгенге класстан тыш эшчәнлегенә сез якташыбыз Клара апа Булатова турында әзерләнеп килдегез. Без шагыйрәнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәребезне камилләштерербез.

**Төп өлеш.**

<u>Укытучы.</u> Бүгенге класстан тыш эшчәнлеген «Бәхетле очрак» уены рәвешендә уздырырбыз. Уенда ике команда катнаша. Хәзер командаларга бүленәбез, һәр команда үзенә исем, девиз, капитаннарны билгели. 1 нче команда – «Дуслык». Девиз: «Дуслык белән ныклы без». Капитан – Сөмбелә.

2нче команда – «Җилкәннәр». Девиз: «Җилкәннәр җилдә сынала». Капитан – Румил.

Укытучы. Димәк, безнең уенда «Дуслык» һәм «Җилкәннәр» командасы ярыша.

**I тур «Кем тизрәк?»** дип атала. Әлеге турда мин сезгә сораулар бирәм, ә сез тиз итеп дөрес җавапны бирергә тиеш буласыз. Кайсы команда җавап бирә алмый, сорау көндәш командага күчә. Бирем аңлашылдымы?

Балалар. Аңлашылды.

Укытучы. Уенны башлыйбыз.

1. К. Булатованың туган көне, ае, елын атагыз. (18 март 1936)
2. Әтисенең исеме ничек? (Гариф абзый)
3. Әнисенең исемен атагыз. (Хәнисә апа)
4. К. Булатованың туган җире кайда? (Сарман районы Карамалы авылы)
5. Әти-әнисе кем булып эшлиләр? (Мөгаллимнәр)
6. Шагыйрә 3-7 сыйныфны кайда укый? (Сарман районы Ләке авылында)
7. Анда күпчелек кемнәр яши? (Керәшен татарлары)
8. Сарман урта мәктәбен ничәнче елда тәмамлый? (1954)
9. Аттестат алгач, шагыйрә нишли? (Сарман районы Түбән Ләшәү башлангыч мәктәбендә балалар укыта)
10. Тормыш юлын кайда дәвам итә? (Әлмәттә)
11. К.Булатова анда башта кем булып эшли? (Төзүче, көнкүреш комбинатында кассир булап эшли)
12. Оештыручы вазифасын ул кайда башкара? (Төзүчеләр сараенда)
13. 1978 елда шагыйрәгә нинди исем бирелә? («Укытучы-методист» исеме)
14. Әлмәт телевидениесендә ул нинди программа алып бара? («Җомга» программасын)
15. Туган ягым, кыр ягым,
    Игеннәр уңар ягым.
    Синдәгедәй нурлы таңнар,
    Синдәгедәй сылу ярлар Кай җирләрдә бар тагын...
    Бу шигырь юллары нинди шигырьдән? («Сарманым»)
16. ...Ах, ул Питрау! Билдән күмәр иде.

Болыннарда чәчкә-үләне,

Тирә-юньнән кунак килер иде!

Кыз-кырыны, егет-җиләне...

Бу шигырь юллары нинди шигырьдән? («Ләкеләргә ел да кайтыр идем»)

17.Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә ул ничәнче елларда укый? (1965-1969)

18.1967 елда шагыйрәнең тормышында нинди вакыйга була? («Язлар алда» дигән шигырьләр җыентыгы чыга)

17. Шагыйрәгә 1986 елда нинди исем бирелә? (Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеме)

18. Татарстан Республикасының мактау грамотасы белән К.Булатова кайчан бүләкләнә? (1996)

Укытучы. Шушының белән сораулар бетте. Ә без алдагы турга күчәбез.

**II тур «Капитаннар – алга!»** дип атала.

Укытучы. Укучылар, Клара апа Булатова кем булып эшләгән?

Балалар. Укытучы.

Укытучы. Әйе. Бу һөнәр аңа кемнән күчкән?

Балалар. Бу һөнәр аңа әти-әнисеннән күчкән.

Укытучы. Дөрес. Әтисе Гариф абзый математика укыта, күп еллар мәктәп директоры була. Ә әнисе Хәнисә апа тел һәм әдәбият укытучысы булып эшли. Үзенең профессиясенә Клара апа Булатова шигырьләрендә дә тугры кала. Укытучы профессиясе турында аның бик матур шигыре бар. Ул «Укытучы бәхете» дип атала. Шагыйрә уйлавынча, сөенеч, шатлык һәм бәхет нәрсәдә? Әлеге сорауга безнең капитаннарыбыз җавап бирә. Сезгә 3-4 минут вакыт бирелә. Вакыт үткәч, эшләрегезне жюрига тапшырасыз. (Эшләрне тапшыру).

Җанатарлар чыгышы. (К. Булатова сүзләре, И.Котовский көе «Кыңгырау чәчәкләре» җыры)

Укытучы. Димәк, шагыйрә уйлавынча, сөенеч – таңнан торып, эшкә килгән иртәләр; шатлык – мәктәп сукмаклары; бәхет – укучылар кеше булып үссәләр. Сезнең җавапларыгыз шушындый булырга тиеш иде.

**III турга** күчәбез. Ул **«Син – миңа, мин – сиңа»** дип атала. Бу турда командалар бер-берсенә Клара апа Булатованың тормыш юлы һәм иҗатына караган сораулар бирәләр. Сораулар һәр командага да икешәр. Әгәр команда соруга җавап бирә алмый икән, команда үз соравына үзе җавап бирә.

Балалар.

1. К. Булатова иҗатында керәшен татарларының нинди бәйрәмнәре телгә алына? («Олы көн», «Питрау», «Торыйсун»)
2. К. Булатова Әлмәт шәһәрендә телевидениедә эшләгәндә, халык теленә ул нинди исем белән кереп кала? («Җомга апа»).
3. Шагыйрәнең шигырьләренә кайсы республика композиторлары көй яза? (Татарстан һәм Башкортстан композиторлары).
4. Шагыйрә ничәнче елдан язучылар берлеге әгъзасы? (1970 елдан).

Укытучы. Хәзер **IV турны** башлар вакыт җитте. Әлеге турда без командаларның башваткычларны чишүдә җитезлекләрен карыйбыз, һәр командага да «**Сүзне эзләп тап»** биремен бирәм. Әлеге биремне эшләгәндә өстән аска һәм сулдан уңга йөреп сүзләрне дөрес тапсагыз, Клара апа Булатованың шигыренең исеме килеп чыгарга тиеш.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| я | м | я | к | т | а | н | е | ш | Т |
| а | е | ң | ф | х | е | ф | п | р | У |
| ш | п | җ | ш | у | ш | ы | н | я | Ф |
| у | п | э | а | п | г | ш | ф | с | Р |
| ш | г | ж | җ | о | е | д | т | и | А |
| ы | л | ъ | ч | л | ш | ү | х | һ | К |
| я | ч | ю | б | в | п | л | һ | ү | Т |
| с | с | у | е | э | п | о | н | у | А |
| т | л | й | з | ш | г | ү | к | ф | Н |
| ь | г | з | р | в | и | ж | ю | н | З |

Җавап. «Шушы яктан, шушы туфрактан без».

Укытучы. Шушы тур белән безнең уеныбыз тәмамлана. (Уенга нәтиҗә ясала).

**III. Йомгаклау өлеше.**

Укытучы. Клара апа Булатова тумышы белән җырларда көйләнгән, бик күп мәшһүр затларны, шул исәптән әдәбият һәм сәнгать әһелләрен биргән атаклы Сарман ягыннан, татар теленең, халык моңының табигый төбәгеннән. Әгәр дә Клара апа Булатова теленең, сүз сәнгатенең бөтен нечкәлекләрен белеп, тел дәрьясында судагы балык кебек эш итә икән, монда, әлбәттә, Сарман ягының да роле зур. Туган төбәк, аны сагыну хисләре, җирсү әдибәнең иҗатында да калку гәүдәләнеш тапкан.

(Клара Булатованың «Шушы яктан, шушы туфрактан без» дигән җырын тыңлау).

Укытучы. Укучылар, әлеге уенда катнашканыгыз өчен бик зур рәхмәт. Сау булыгыз.

## Зоопаркка сәяхәт

(Мәктәпкә әзерлек яшьтәге балалар төркемендә физкультура шөгыле)

Жопбыева Роза Марат кызы, Җәлил бистәсенең
3 нче балалар бакчасының тәрбиячесе, Сарман районы

**Максат:** мәктәпкәчә яшьтәге балаларның хәрәкәт активлыгын төрлечә белем бирү юнәлешендә үстерү.

**Белем бирү өлкәсе бурычлары:** өйрәтү: каршылыклар аша сикерү; гимнастик скамейкада тигезлек саклап йөрү; физик сыйфатлар үстерү: тизлек, җитезлек, хайваннарның хәрәкәтләрен кабатлау;
Сәламәтлек: үзеңнең сәламәтлеген саклый белергә өйрәтү;
Аралашу: өлкәннәр һәм үз иптәшләре белән аралашырга өйрәтү;
Музыка: музыка характерына туры китереп хәрәкәт итүләренә ирешү;
**Атрибутлар:** 2 гимнастик скамейка, 2 кыршау, 2 дуга.

| Гомуми үстерү күнегүләре | Дозир | Методик күрсәтмә |
|---|---|---|
| **I өлеш:**<br>Маршка басып залга кереп тезеләләр. | 3мин | Исәнмесез балалар! Рәткә тезелдек! Тигезлән (равняйсь)! Туры бас (смирно)!<br>Балалар, сез барыгыз да шагыйрь Әзһәр Самигулла улы Габидуллинның шигырьләрен, табышмакларын беләсез. Безнен бүгенге шөгыль табышмакларга багышланган.<br>Бергә түгәрәккә басып:<br>Бергәләшеп әле басыйк,<br>Бик зур, матур түгәрәк ясыйк.<br>Куллар җылысын тойыйк,<br>Шатланып бер-беребезгә елмаеп.<br>Хәерле көннәр теләп<br>Шөгылебезне башлыйк.<br><br>1.Күлләре бар – суы юк,<br>Чүлләре бар – комы юк,<br>Таулары бар – кар ятмый,<br>Аны белгән адашмый. (Карта)<br>Әйе, бу – илнең картасы. Карта ярдәмендә нишләп була балалар? Бик дөрес әйтәсез. Аның ярдәмендә сәяхәткә барып була. Картага күз салыйк әле, балалар. Безнең юл зоопаркка илтә.<br>2. Күрсәтергә юк кулым<br>Сөйләшергә юк телем.<br>Кешеләргә юнәлешне<br>Дөрес күрсәтәм үзем. (Компас)<br>Дөньяның дүрт ягын билгеләү өчен куллана торган прибор, аның магнит угы һәрвакыт төньякка күрсәтә.<br>Ә сәяхәткә нәрсә белән барасын алдагы табышмакны чишкәч белербез. |
| Марш – бер колоннада атлау.<br>«Самолет»<br>Аяк очларында йөрү, чүгәләп йөрү. | 1 түгәрәк | 3. Пыр-пыр килеп китәр кош,<br>Күккә менеп житәр кош.<br>Ширбәт тугел, су да түгел,<br>Девон маен эчәр кош. (Самолет)<br>Әйе, дөрес, без самолетта очабыз.<br>Ә хәзер бер-беребез артыннан тезелеп басабыз<br>Кулларны җәйдек, борын белән сулыйбыз, араны саклыйбыз.<br>Балалар, матур аланга килеп төштек. |
| «Велосипед»<br>Кулларыбыз билбауда, тезләрне югарырак күтәрәбез. | 1 түгәрәк | 4.Ә хәзер нәрсә белән барасын табышмакны чишеп белегез әле:<br>Мөгеземнән тоталар да<br>Аяк белән йөртәләр.<br>Миңа утырып, кешеләр<br>Юлны житез үтәләр. (Велосипед)<br>Алга таба велосипедта барабыз. Кулларыбыз билбауда, |

| | | |
|---|---|---|
| «Аю»<br>Аю кебек әле бер якка, әле икенче якка авыша-авыша йөрибез. | 1<br>түгәрәк | тезләрне югарырак күтәрәбез.<br>Менә, балалар, зоопаркка да килеп җиттек. Балалар, карагыз әле, зоопаркта күпме җәнлекләр.<br>5. Асрамаса да умарта,<br>Балны бик тә ярата.<br>Кышын сөя йокыны,<br>Язгача тормый ята (Аю)<br>Аю кебек әле бер якка, әле икенче якка авыша-авыша йөрибез. |
| «Көнгерә»<br>Бер-беребез артынан сикерәбез, кулларыбыз билбауда | 1<br>түгәрәк | 6.Кеше дисәң, кеше түгел,<br>Сумка булыр түшендә.<br>Китап тугел, дәфтәр түгел,<br>Бала йөртер эчендә. (Көнгерә)<br>Көнгерә – дөрес. Димәк, без бер-беребез артыннан сикерәбез, кулларыбыз – билбауда. Афәрин! |
| **II өлеш**:<br>Өч шеренгага тезелү<br>*Күркәләр белән күнегүләр.* | 25мин | 7. Энәсенең күзе юк,<br>Тегәр өчен җебе юк.<br>Яшерсә башын, аягың,<br>Ул нәни генә бер туп. (Керпе)<br>Әйдәгез әле, көч җыеп алыйк. Безгә керпе чыршы күркәләре җыеп куйган. |
| 1.Б.т.: аяклар бергә, күркәләр артта.<br>1–3 кулны алга сузу, 2–4 б.т. | 6<br>тапкыр | Б.т.: аяклар бергә, күркәләр артта.<br>Арка туры |
| 2. Б.т.: аяклар иңсә киңлегендә, күркәләр күкрәк янында.<br>1–3 янга борылу, кулларны сузу.<br>2–4 б.т. | 6<br>тапкыр | Б.т.: аяклар иңсә киңлегендә, күркәләр күкрәк янында.<br>Аякларны идәннән алмыйбыз |
| 3. Б.т.: т.т.<br>1–3 чүгәләп, кулларны алга сузу.<br>2–4 б.т. | 6<br>тапкыр | Чүгәләп, кулларны алга сузу. |
| 4. Б.т.: тезләнеп, күркәләр тездә.<br>1–3 тезгә басып, кулларны өскә күтәрү.<br>2–4 б.т. | 6<br>тапкыр | Б.т.: тезләнеп, күркәләр тездә. |
| 5.Б.т.: т.т. Бер урында сикерү | 6<br>тапкыр | Бер урында сикерү<br>Борын белән сулыйбыз |
| **Төп хәрәкәт төрләре** | | 8. Янымда минем беркайчан<br>Булмаса да сәгатем,<br>Бар кайсы вакыт икәнне<br>Әйтә торган гадәтем. (Әтәч) |
| 1.Гимнастик таяклар аша | 3<br>тапкыр | Кулларны канат каккандай селкетегез. Аякларны югары күтәреп атлагыз |

| | | |
|---|---|---|
| аякларны күтәреп атлау<br><br><br>2. Дүрт аякланып дуга астыннан чыгу.<br><br><br><br><br>3.Кыршаудан кыршауга сикерү<br><br><br><br><br>Хәрәкәтле уен «Күркә белә Күке» | <br><br><br><br>3 тапкыр<br><br><br><br><br><br>3 тапкыр<br><br><br><br><br><br>3 тапкыр | 9.Мыеген ул үстермәс,<br>Ләкин сакалсыз йөрмәс.<br>Бакчада булыр күзе,<br>Урлашмый туймас үзе. (Кәҗә)<br>Дүрт аяклап дуга астыннан чыгабыз.<br>10.Үзе «Гөр-гөр», – ди,<br>Тик үзе качмый.<br>Качсаң да, сине<br>Эзләп маташмый. (Күгәрчен)<br>Кыршаудан кыршауга сикерәбез.<br>11.Кызыл бантик йөртә үзе<br>Гомер буе башында<br>Үзе кызыл төсне күрсә<br>Кабарына, ярсына. (Күркә)<br>12.Бигрәк инде иләс кош,<br>Үз оясы булмас кош,<br>Үз оясы булмаса да,<br>Кукәй салмый тормас кош.<br>Бу нинди кош?<br>Исем куш! (Күке)<br>Балалар, мин сезгә «Күркә белән Күке» уенын тәкъдим итәм. |
| **III өлеш:**<br>Куларны ачтык, борын белән сулыйбыз, араны саклыйбыз. | 4мин | Ә хәзер без сезнең белән яңадан балалар бакчасына кире кайтабыз.<br>Әйдәгез, самолетка рәхим итегез!<br>Балалар бергә:<br>Мин очам, очам, очам,<br>Бакчага очам, очам.<br>Әйе шул, әйе шул,<br>Бакчага очам, очам.<br>Балалар, без бүген кая сәяхәткә бардык? Бигрәк тә сезгә нәрсә ошады?<br>Җыр яңгырый. Балалар бер рәткә тезеләләр, атлап группага кайталар. |

## Талантлы син, Сарман ягым

(Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен әдәби-музыкаль кичә)

Җиһаншина Венера Рафис кызы, Горшенина Марина Александр кызы,
Җәлил бистәсенең 3 нче балалар бакчасы тәрбиячеләре, Сарман районы

**Максат.**
Якташ шагыйрьләребез Клара Булатова һәм Әзһәр Габидинең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү, балаларда якташ шагыйрьләребез иҗат мирасына кызыксыну уяту, туган якка карата мәхәббәт тәрбияләү.
**Бурычлар.**
1. К.Булатова һәм Ә.Габидинең иҗаты белән таныштыруны дәвам итү.
2. Балалар сөйләмен үстерү, сүзлек запасын баету; вак моторика, ирекле фикер йөртергә, фантазияләргә өйрәтү; хәтер, фикерләү, күрү сәләтен үстерүгә ярдәм итү.
3. Шәхеснең әхлакый сыйфатлары: туган як тарихына һәм кешеләргә карата хөрмәт, якташларың өчен горурлык хисе тәрбияләү.
**Мәгариф өлкәләрен интеграцияләү:** «Танып-белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Социаль-коммуникатив үсеш», «Сәнгать-эстетик үсеш», «Физик үсеш».

**Җиһазлар:** шагыйрьләр Ә.Габиди, К.Булатова фотолары, проектор, мультимедиа тактасы, аудио-язмалар.

**Күңел ачу барышы:**

*Музыка залы бәйрәмчә бизәлә. Өстәлдә чәчәкләр. К.Булатова, Ә.Габидинен портретлары. Китапларыннан күргәзмә оештырыла. Бер якта шагыйрьләрнен әсәрләре буенча балалар ясаган рәсемнәр күргәзмәсе. Проекторда – презентация «Клара Булатова, Әзһәр Габидинын иҗаты».*

*«Сарман буйларында» татар халык җыры яңгырый.*

(Балалар залга керә, урындыкларга утыралар)

**Алып баручы.** Исәнмесез, кадерле балалар! Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар! Без сезнең белән шушы бәйрәмне үткәрүебезгә бик шат! Бүген без, балалар, якташ шагыйрьләребез кичәсенә җыелдык.

Сез ничек уйлыйсыз, кемгә багышланган бу бәйрәм? Без сезнең белән кем портретлары күрәбез? (алып баручы экранга игътибар итә. Балаларның җаваплары)

**Алып баручылар**. Әйе, Әзһәр Габиди, Клара Булатова. Алар – татар шагыйрьләре, ватандашларыбыз, якташлар. Әзһәр Габиди һәм Клара Булатова безнең кебек Сарман районында туганнар һәм яшәгәннәр. Шагыйрь Әзһәр Габиди 1926 елның 25 сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында өченче бала булып туа. Ул кечкенәдән үк шигырьләр яратып үсә һәм аларны иҗат итәргә омтыла. Ләкин 10 нчы сыйныфны тәмамларга да өлгерми, Бөек Ватан сугышы башлана. Бик яшьли Әзһәр фронтка китә.

Сугыштан кайткач, ул шигырьләр яза башлый. Ә. Габиди искиткеч матур урында урнашкан туган ягы турында, урмандагы гүзәллек, авыл чишмәләренең саф сулары, ипигә ягып ашарлык саф һавасы хакында ничек матурдан-матур шигырьләр язмыйсың, ди.

***Балалар Ә. Габидинең шигырьләрен укыйлар.***

1. **«Яратам сине, кояш!»**

Кояш –минем якын дустым,
Мин аңа сөеп багам.
Аннан җылы нурлар ала
Урман, кыр, иркен далам

Ул булганда һава чиста,
Ул булганда саф һава
Ул булганда, чәчәкләргә
Хуш исле баллар ява.
Ул булганда, тугайда да
Тирбәлә зәңгәр рәшә,
Ул булганда, болында да
Тулып җиләкләр пешә.

Кояш белән көннәр матур,
Кояш белән көн якты,
Әнине яраткан кебек
Яратам мин кояшны.

2. **«Көтү кайта»**

Тау арында
Кояш батты,
Җир өстенә
Эңгер ятты,
Авылымда
Шатлык артты –
Урам тулып
Көтү кайтты.
Сөтләр ага

Чиләкләргә,
Нәниләрне
Бүләкләргә.
Әй тәмле дә
Сыер сөте,
Аннан кидә
Чәчәк исе,
Тугай исе,
Муллык исе!

Шагыйрә Булатова Клара Гариф кызы 1936 елда Сарман районы Татар Карамалы авылында туа. К.Булатованың әнисе татар әдәбияты укытучысы булган, әтисе математика укыткан. Алар икесе дә поэзиягә гашыйк булганнар, үзләре шигырьләр иҗат итү белән шөгыльләнгәннәр. Шулай итеп, укытучылар эшенә, әдәбиятка һәм шигъриятькә мәхәббәт кечкенәдән үк салына. Шагыйрәнең беренче шигырьләре туган як матурлыгына, авыл хезмәтчәннәренә, төзүчеләргә багышлана. К.Булатованың тормыш һәм хезмәт шатлыгы – тугрылык, дуслык, мәхәббәт хисләре. Клара Булатова балалар өчен дә бик күп шигырьләр язган. Аларда күңел җылысы, игелек һәм җиңел юмор сизелә. Аның әсәрләре журналларда басыла, шигырьләре белән китаплар дөнья күрде.

***Балалар К. Булатованың шигырьләрен укыйлар.***

**«Буран»**

Тышта буран котыра,
Әти өйдә утыра.
Машинасы тик тора
– Чыга алмый торам, – ди –
Тышта кара буран, – ди.
Әти белми: буран ул
Кара булмый,
ак була!

«Әниемнең кызы юк бит»

Әниемнең кызы юк бит,
Мин әнигә бер генә.
Кызы да юк, эш тә бик күп
Әнинең берүзенә.
Әниемнең кызы юк шул,
Мин булышам әнигә.
Идән юам, җыештырам,
Кер юышам әнигә.
Кибеттән сөт алып кайтам,
Ипигә дә йөгерәм.
Әниемнең кызы юк та,
Малае бар бер дигән.

**Алып баручы.** К. Булатова кечкенә чагында төрле уеннар уйнарга ярата. Без дә балалар сезнең белән уеннар уйнарга яратабыз. Әйдәгез, уйнап алыйк әле.

**«Урманда» уены (К. Булатова шигыре)**

*(почмакта Аю йоклый, балалар тыныч кына аның янына бара һәм сүзләр әйтәләр)*

Җиләк җыям, как коям
Әниемә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю, бүре юк микән?

*(Бу сүзләрдән соң аю балаларны тота башлый)*

**Алып баручы**. К. Булатова һәм Ә. Габиди табигатьне бик яраталар. Шуңа күрә аларның күп кенә әсәрләре безнең як матурлыгына багышланган.

Балалар шигырьләр укыйлар.

**«Жәйге кич» (Ә. Габиди)**

Жәйге кичтә ак болытлар
Аллана.
Куакларда сандугачлар
Моңлана.
Җир өстендә көмеш чыклар
Җемелди.
Кыекларда күгәрченнәр
Гөрелди.
Бабайлар да гәп коралар
Болдырда.
Кешнәп куя яшь колыннар
Болында.
Хезмәт җырын көйли кырда
Башаклар,
Бу җырга без барыбызда
Гашыйклар.
Күреп шушы гүзеллекне,
Ташый хис.
Нинди гамьле, нинди ямьле
Җәйге кич!

«Урамда» (К. Булатова)

Марс – газон янында,
“Яшел дөнья” сагында.
Яшел тасма беләктә,
Олылырны өйрәтә.
– Үлән таптап йөрмәгез,
Газоннарга кермәгез.
Тротуардан атлагыз,
Яшеллекне саклагыз.

Парлы татар халык биюе башкарыла (аудиоязма «Шома бас»)

**Алып баручы:**. Әзһәр абыйның табышмак шигырьләре дә күп. Әйдәгез әле, балалар, табышмак чишеп карыйк.

1.Табаным утлы булсада,
Тукымадан йөрим мин.
Җыерчыклы йөзләрне дә
Матурлап тигезлим мин. **(Үтүк)**

2.Мөгеземнән тоталар да
Аяк белән йөртәләр
Миңа утырып кешеләр
Юлны җитез үтәләр**. (Велосипед)**

3.Мыегын ул үстермәс,
Ләкин сакалсыз йөрмәс.
Бакчада булыр күзе,
Урлашмый туймас үзе**.(Кәҗә)**

4.Энәсенең күзе юк,
Тегәр өчен җебе юк,
Яшәрсә башын,аягын,
Ул нәни генә бер туп. **(Керпе)**

5.Утырабыз урманнарда
Ап-ак эшләпә киеп
Киптерә дә, кыздыра да
Кешеләр безне җыеп. **(Гөмбә)**

6.Күлмәгем алтын төсендә,
Тәнем минем бүз кебек
Торалар минем күлмәкне
Салдырганда яшь түгеп**. (Суган)**

Алып баручы: Клара Булатова балалар өчен язган шигырьләренең күбесен бик шук һәм акыллы Марс исемле малай турында яза.

**«Унга кадәр»**

Марсның бармаклары –
Санагыч таяклары.
Бер турайта, бер бөгә,
Унга кадәр сан белә.
Әти белән әни, ди,
Бабай белән әби, ди,
Үзем, абый һәм апа,
Боларга кушкан чакта
Бозау белән песи, ди,
Алай да җитешми, ди,
Этемне дә син куш, ди,
Унынчысы Актүш, ди.

Татар халык уены «Чума үрдәк, чума каз»
Чума үрдәк, чума каз,
Тирән күлне ярата ул, ярата.
Әлфия үзенә иптәш эзли,
Белмим, кемне ярата шул, ярата. Илназны ярата шул, ярата.

**Алып баручы**: Безнең балалар Клара апаның «Әллә кайсын тыңласы» дигән шигырен сәхнәләштерделәр. Рәхим итеп карагыз әле. (*Өй күренеше. Ишеккә кемдер шакый, музыкага әби белән бабай керә, Марс исемле малай да алар белән. Марс әби белән бабайга карап тора. Өстәлдә тәлинкә, уклау, куна тактасы. Бу вакытта әби камыр баса. Бабай ит кисә. Марс ярдәм итәргә тели.)*

**Алып баручы:**

Әби баса камырын
Бабай итен тапаша
Марс инде шул тирәдә
Булышам дип маташа
Бабай әйтә: «Һай рәхәт!
Яса улым, яса, – ди, –
Пилмәнебез тәмле булыр,
Үзең эшләп аша!» – ди.

(Әби камыр җәя, бабай ит сала, Марс камыр ала. Аның кулына камыр ябыша)

Әби җәя камырын,
Бабай итен салыша.
Марс та бик ясар иде –
Камыр кулга ябыша.
Әби әйтә: «Бәбкәем,
Син бәләкәй шул әле!
Камырымны бозасың бит,
Карап кына тор әле!»

(Марс аптырап тора)

Әллә эшләп ашасы,
Әллә карап торасы.
Берсе куша, берсе тыя,
Әллә кайсын тыңласы.

(Персонажлар китә)

**Алып баручы**. Күрәсезме, балалар, Марс әби белән бабайга ярдәм итәргә тели, тик әлегә аның бик килеп чыкмый. Марс үсеп җиткәч, үзе бар эшен дә үзе эшләячәк. Марс тагын да көчле, кыю булырга һәм армиягә барырга хыяллана. Аның бабасы, әтисе, абыйлары да хезмәт иткән.

***Клара Булатова сүзләренә, М.Минһаҗев көенә язылган «Солдатлар» җырын малайлар башкара.***

**Алып баручы**. Татар шагыйрьләре Әзһәр Габиди һәм Клара Булатова әсәрләре белән сез, балалар, киләчәктә, мәктәптә танышырсыз. Ә бүген без шуны әйтә алабыз – шундый шәхесләрнең безнең районашларыбыз, якташларыбыз булуы белән без, һичшиксез, горурланабыз! Кичәбез ахырына якынлашты, сау булыгыз!

## Туган як һәм әни бер генә, син аларның кадерен бел генә

(2 сыйныф укучылары өчен әдәби уку фәненнән дәрес эшкәртмәсе)

Михайлова Әлфия Мостафа кызы, Ләке төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

Максатлар: Якташ шагыйрә Клара Булатова тормыш юлы белән танышу, иҗатында чагылдырылган туган як һәм әни темаларына тукталу; сәнгатьле, аңлап уку күнекмәләрен, логик фикер йөртү сәләтләрен, сөйләм телен үстерү; гаиләнең һәркем өчен бер генә булуына төшендерү, әти-әниләргә ихтирам, хөрмәт, ярату хисе тәрбияләү, туган якның, әти-әниләренең газиз, кадерле кеше булуларын балаларга тагын бер тапкыр аңлату.

УУГ:

Шәхси: геройлар кылган гамәлләр аша тәртибеңә бәя бирергә өйрәнү, әниләргә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү,

Регулятив: максат кую, әсәрнең төп эчтәлегенә төшенү,

Коммуникатив: үз фикереңне тулы һәм төгәл итеп әйтә белү, дәлилләү,

Танып-белү: кирәкле мәгълүматны табу һәм анализлау, фикер йөртүнең логик чылбырын төзү, нәтиҗә чыгару.

Дәрес тибы: яңа материалны өйрәнү дәресе.

Җиһазлау: дәреслек, проектор, экран, презентация, китап күргәзмәсе, аудиоязма, карточкалар, кластер төзү өчен күргәзмәлелек.

**I. Оештыру моменты, мотивация**

Белем иле кайчак мина
Никтер серле урман кебек.
Ә юллары кызыктырып,
Гел чакырып торган кебек.

Белем сукмагының серле юлларыннан атлавыбызны дәвам итәбез. Алдагы дәресләрдә өйрәнгәннәр юлыбызны уңышлы үтәргә ярдәмче булыр.

**II. Белемнәрне актуальләштерү**

Өй эшләрен тикшереп алыйк.

**III. Проблемалы ситуация тудыру һәм дәреснең темасын ачыклау.**

Дәресебезне «КОНЭРС» уены белән дәвам итәбез. Уенның тәртибе сезгә яхшы таныш. Экрандагы юллар кем турында бара икән, шул авторның портреты янына барып басабыз һәм ни өчен шушы авторны сайлавыбызны аңлатабыз. Өстәмә мәгълүматыгыз бар икән, иптәшләрегезгә җиткерә аласыз. (Портретлар кабинетның 4 урынына эленгән)

1.Ул безнең якташыбыз. Авыл яныннан аккан елга исемен үзенә псевдоним итеп алган. Без аның бик күп шигырьләрен яттан беләбез. Мәктәптә аңа багышланган музей бар. (Ямаш Игәнәй)

2.Ул – герой-шагыйрь, «Моабит дәфтәре»нең авторы. Әдәби уку дәресләрендә без аның «Бакчачы», «Кечкенә дуслар», «Күке» һ.б шигырьләрен өйрәндек. «Сәгать» әсәрен хәтта җыр итеп тә башкарабыз. (Муса Җәлил)

3.Ул бик аз гына гомер эчендә бик тә эчтәлекле әсәрләр язып калдырган. «Шүрәле», «Су анасы» әкиятләре безгә кечкенәдән таныш. Ел фасыллары турында шигырь-табышмаклар язган. Урлашмаска, эш сөяргә, табигатьне яратырга, туган телдә сөйләшергә кирәклеген әйтә. (Г.Тукай)

4. 1936 елның 18 мартында Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Аның этисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа күрә аңа бала-чактан ук әти-әниләре белән бергә, бер төбәктән икенче төбәккә күчеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 елда ул Югары Чыршылы авылында беренче класска укырга керә, 3 нче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, ә урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыга. (Клара Булатова)

Бу автор сезгә танышмы? Аның турында нәрсә әйтә аласыз? Димәк, бүген кем иҗатын өйрәнәчәкбез икән?

**IV. Дәрес темасы буенча эшләү**

1. Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗатына багышланган презентация карау (яшәгән урыннары, гаиләсе, китаплары, шигырьләреннән өзекләр слайдларда бирелә)

Клара Гариф кызы Булатова 1936 елның 18 мартында Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа күрә Кларага бала-чактан ук әти-әниләре белән бергә, бер төбәктән икенче төбәккә күчеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 елда ул Югары Чыршылы авылында беренче класска укырга керә, 3 нче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, ә урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыга. Шул ук елның көзеннән хезмәт юлын башлый – Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч классларда балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәттәге төзелеш комбинатында кассир, «Төзүчеләр» клубында оештыручы була. 1962-1965 елларда ул яңадан мәктәптә – Әлмәт районының Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта. Клара Булатованың шигъри иҗаты да нәкъ шул чорда тернәкләнеп китә. Әле мәктәп елларында ук аерым шигырьләре матбугатта күренгән яшь шагыйрә актив рәвештә Әлмәттәге әдәби түгәрәккә йөри, һәм 1956 елдан башлап «Татарстан яшьләре», «Совет Татарстаны» газеталарында, «Пионер», «Азат хатын», «Совет әдәбияты» журналларында күп кенә шигырьләре дөнья күрә. Бераздан аерым шигъри цикллары «Үсү юлы», «Идел» альманахы, «Яшь үрентеләр» кебек күмәк җыентыкларда басыла.

1965-1969 елларда К.Булатова В.И.Ульянов исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам иттерә: 1965 елда аның шигъри бәйләме «**Дуслык**» исемле күмәк җыентыкта басылып чыга. Шагыйрәнең исеме тәнкыйтьтә җылы сүз белән искә алына башлый. 1967 елда «Язлар алда» исемле мөстәкыйль китабы – лирик шигырьләре җыентыгы дөнья күрә.

Университетны тәмамлаганнан соң, К.Булатова Әлмәт районының Яңа Кәшер урта мәктәбенә тел әдәбият укытучысы булып китә. Тәҗрибәле укытучы буларак, 1978 елда аңа РСФСР Мәгариф министрлыгы тарафыннан «Укытучы-методист» дигән мактаулы исем бирелә. 70 нче елларда шагыйрә тагын берничә шигырь җыентыгын чыгарды. Аның бер бәйләм шигырьләре русчага тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә «Детская литература» нәшриятында чыккан «Песня, мечта и любовь» исемле күмәк җыентыкка да кертелгән. Шагыйрәнең егерме елдан артык иҗат эшчәнлеген чагылдырган шигырьләре 1981 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Гел кояшка карап» исемле күләмле китабында урын алган.

Клара Булатова шигырьләрендә күзгә бәрелеп торган иң беренче матур сыйфат – аларда күңел кичерешләренең табигать мизгелләренә тыгыз бәйләнеп бирелүе. Ул шушы Җир кызы, шигырьләренә дә шушы яктан, шушы туфрактан килеп керә. Китап исемнәренә генә күз салыйк. «Җәйләр җитсә», «Язлар алда», «Гел кояшка карап», «Печән өсте». Күргәнебезчә, шагыйрә өчен шушы як кадерле, чөнки "мәтрүшкәләр монда хуш ислерәк, ромашкалар монда эрерәк".

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Китә калсак үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,

Өянкеләр елап озата, – кебек юлларында шагыйрә туган якның матурлыгын җырлый, аның белән горурлана.

Марат Фәйрушин башкаруында «Шушы яктан, шушы туфрактан без» җырын тыңлау (https://lightaudio.ru/mp3/шушы%20яктан%20шушы%20туфрактан%20без)

2. Мәктәп китапханәчесенең ясаган китап күргәзмәсе буенча мәгълүмат тыңлау («Марс китабы», «Әллә кайсын тыңласы», «Курка димәгез әле», «Камилә – тәти кыз» китапларына күзәтү)

3. Шигырьләр уку

3.1 Табышмаклар әйтү

1.Тәмле ашлар пешерә, матур гөлләр үстерә
Өебезнең нуры ул, барыбыздан олы ул. (Әби)
2. Ул бик күпне күргән, сугышта да булган ул,
Йөзе нурлы айдай, кем дисезме? Ул – (Бабай).
3. Ул зирәк тә, шаян да, акыллы да, әйбәт тә.
Иң матур кеше ул, минем (Әти), әлбәттә.
4. Кая барсам, күз алдымда, һәрчак күңелдә яши.
Ул безгә бик якын кеше, беләсезме, ул – (Әни)

- Бу җавапларны берләштереп, нинди сүз белән атап була? (Гаилә)
- Дәресебезне дәвам итеп нинди темага карата шигырьләр укырбыз икән?

Шагыйрә иҗатындагы калку бер сыйфат – хатын-кыз кичерешләрен һәрьяклап тулы итеп ачып күрсәтү. Күп кенә шигырьләрендә ул Ана булып та, бала булып та уйлый. Шуның белән шагыйрә буыннар бәйләнешен ныгыта, үткәнне киләчәккә тоташтыра. Бала психологиясен гади һәм тулы итеп ачып бирә. Бер яктан әниләрне гаилә иминлеге сагында торучылар итеп күрсәтсә, гаиләнең ныклыгы, тормыш хәле, йорт-җирнең төзеклеге, бөтенлеге әтиләр кулында булуын искәртә.

3.2 «Әни –егет» исемле шигыре белән таныштыру һәм фикер алышу.

Әти дә эштән кайтты,
Әни дә эштән кайтты.
Әти диванга ятты,
Әни кухняга чапты.
Әти әйтә: «Мин ач, – ди, –
Кайчан була ул аш?» – ди.
Әни әйтә: «Үзең дә
Булыш, алай булгач», – ди.
Әти әйтә: «Мин – ир, ди,
Аш пешерә белмим, – ди,
Мин хатын-кыз түгел, ди,
– Мин кухняда йөрмим», – ди.
Юкса «Житмеш һөнәр аз, –
Диләр, – егет кешегә».
Безнең өйдә әти түгел,
Әни – егет, әни белә
Чөнки бөтен эшне дә.

3.2.1 Сорауларга җавап бирү

- Шигырь сезгә ошадымы? Ни өчен? Анда сүз кемнәр турында бара? Эчтәлеге буенча нәрсә әйтә аласыз? Ни өчен автор әсәрне шулай атаган? Сез нинди исем бирер идегез?
- Сезнен өйдә мондый күренешнең булганы бармы?

3.2.2 Шигырьне хор белән уку һәм анализлау

- Әсәрнең исеме һәм авторын искә төшерү
- Әсәрнең жанрын билгеләү (рифмаларын табып дәлилләү)
- Шигырьнең эчтәлеге турында нәрсә әйтер идегез? (Әниләрнең өйдә башкарган хезмәтләре бихисап, алар эштән кайткач та ял итмичә, гаилә әгъзалары турында кайгыртучанлык күрсәтәләр)

- Клара Булатова бу шигырьдә нинди проблема күтәрә? (Әниләргә карата хөрмәт, аларның күп эш башкара белүләре, ир-атлар белән тиң була белүләре белән горурлану)
- Автор бу шигыре аша безне нәрсәгә өйрәтә? (Бер-берең не хөрмәт итәргә, бер-береңә салынып, кеше эшләгәнне көтмәскә, үзара ярдәм булдыру)
3.3 «Әниемнең кызы юк бит» шигырен тыңлау (аудиоязма)
Әниемнең кызы юк бит.
Мин әнигә бер генә.
Кызы да, эше дә күп
Әнинең берүзенә.
Әниемнең кызы юк шул,
Мин булышам әнигә.
Аш пешерәм, җыештырам,
Кер юышам әнигә.
Кибеттән сөт алып кайтам,
Ипигә дә йөгерәм.
Әниемнең кызы юк та –
Малае бар бер дигән.
3.3.1 Дәреслек буенча эш – «Әниемнең кызы юк бит» шигыре буенча эш оештыру
А) шигырьне эчтән уку һәм сорауларга җавап бирү
- Шигырь сезгә ошадымы? Ни өчен? Анда сүз кемнәр турында бара? Эчтәлеге буенча нәрсә әйтә аласыз? Ни өчен автор әсәрне шулай атаган? Сез нинди исем бирер идегез?
Б) Шигырьне берничә укучыдан укыту һәм эчтәлегенә карата телдән “рәсем ясату”
- Шигырьне укыганда яки тыңлаганда сезнең күз алдына нәрсә килә?
- Әгәр дә сез рәссам булсагыз, рәсемгә нәрсә ясар идегез?
- Шигырьдәге геройларны атап чыгыгыз.
- Вакыйга кем исеменнән сөйләнә? Аны каян белеп була?
В) Шигырьне хор белән уку һәм үз гаиләләренең әгъзалары турында фикер алышу.
- Сезнең гаиләдә кемнәр бар? Алар нинди хезмәт башкаралар?
- Сез әти-әниегезгә нинди ярдәм күрсәтәсез?

**Физкультминутка**

Бу бармак – бабай, бу бармак – әби
Бу бармак – әти, бу бармак – әни.
Бу бармак – бәби, аның исеме чәнти.
2) «Ярый-ярамый!» уены. Слайдтагы рәсемнәргә карап, гаилә әгъзаларына карата фикерләрен хәрәкәтләр белән күрсәтү. Әгәр укучылар, рәсемдә сурәтләнгән вакыйга уңай дип санасалар – кул чабалар, әгәр тискәре дип бәяләсәләр – аяклары белән тыпырдыйлар.
V. **Алган белемнәрне практик эшчәнлектә куллану**
1. Клара Булатованың гаилә турында ишеткән ике шигырен чагыштыру
- Кайсы гаиләдәге әнигә яшәү җиңелрәк? Ни өчен дип уйлыйсыз?
- Моннан үзегезгә нинди нәтиҗә ясый аласыз?
**2. «Буталган юллар» уены. Парларда эшләү**
Клара Булатованың «Әниемнең кызы юк бит» шигырен шигъри юллар язылган карточкалар ярдәмендә төзү.
**VI. Рефлексия**
Клара Булатованың «Әниемнең кызы юк бит» шигырен анализлау

| Әсәрнең исеме | Авторы | Жанры | Геройлары | Темасы | Идеясе |
|---|---|---|---|---|---|

**VII. Йомгак**
1. Дәрес турында фикер алышу.

Бүгенге дәрес ахырына якынлаша. Сез үзегезгә берәр яңалык алдыгызмы? Дәрестә иң кызыклысы нәрсә булды? Шагыйрә Клара Булатова турынданиләр истә калды?
2. Төркемнәрдә эш. «Кластер» алымы

Йомгаклау өчен схема ясыйбыз, кыскача гына әйткәндә (кояшның уртасына Клара Булатова дип язылган, парталарда төрле сүзләр язылган «нурлар», шулар арасыннан Клара Булатовага

туры килгәннәрен сайлап алып кояш ясыйбыз: язучы, **шагыйрә**, **укытучы**, тракторчы, **әни**, җырчы, **әби**, укучы, **кассир**, артист, **якташ.** һ.б.

- Кем ул Клара Булатова?

**VIII. Өй эше**

I вариант – Шигырьне яттан сөйләргә.

II вариант – (иҗади бирем) «Мин – әнинең ярдәмчесе» темасына хикәя төзү.

III вариант – (эзләнүле бирем) «Минем нәсел нинди һөнәрләргә ия».

## Әзһәр Габиди – укытучы, фронтовик, шагыйрь

(Сыйныф сәгате эшкәртмәсе)

Корбыева Гөлчәчәк Фаил кызы, Мөхәметдинова Рүзилә Гүзәл кызы,
Ләшәү-Тамак төп гомумбелем бирү мәктәбе,
Сарман районы

**Максат**:

1.Укучыларда Әзһәр Габиди иҗаты аша шигырьләренә һәм китапларына мәхәббәт уяту.

2. Әзһәр аганың тормыш юлын, иҗатын тирәнрәк өйрәнү.

**Җиһазлау**:

Талгын көй, шагыйрьнең портреты, «Җир кешеләр белән матур» исемле китап күргәзмәсе, укучылар тарафыннан ясалган рәсемнәр, проектор, презентация.

**1.а.б**. Сарман районының Чукмарлы авылында дөньяга килгән фронтовик-шагыйрь Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллинның иҗаты белән танышлар әдипне көрәшчеләр затыннан дисәләр, арттыру булмас. Ул моны фронт юлларында башланган иҗаты, соңгы сулышына кадәр көрәш бастионының алгы сызыгына калуы белән раслады. Әдип каләме белән халыкны бәхетле итү, аны яктылыкка, матурлыкка илтү идеясенә турылыклы калды, кыйбласын бутамады. Тормышта аның күзе төшмәгән, күңелен кузгатмаган өлкә булмагандыр.

**2.а.б.** Үзе дә алты бала атасы булган, гомер буе укытучы булып эшләгән, балалар белән турыдан-туры аралашып яшәгән кеше буларак, ул күбрәк балалар өчен яза, алардагы яхшы якларны күбрәк күрә, алар күңелен аңлый, дөньяга балалар күзе белән карый белә. Шундый олы гәүдәле кешенең шулай кече күңелле булуы беркадәр мәзәк тә кебек хәтта. Шулай да, шагыйрь балалардагы тискәре якларны да бик оста итеп, беркемне дә үпкәләтмәслек итеп әйтеп бирә белә.

**1.а.б.** Язучы хакында күбрәк беләсең килсә, аның туган ягына бар яки әсәрләрен укы, диләр. Шагыйрьнең туган ягы, чыннан да, искиткеч матур урында урнашкан. Кыр ягы дип даны чыккан Сарман төбәгендә туган Әзһәр Габидинең туган авылына урман аварга тора бит. Ә ул урмандагы гүзәллек, авыл чишмәләренең саф сулары, ипигә ягып ашарлык саф һавасы хакында ничек матурдан-матур шигырьләр язмыйсың, ди. Әзһәр Габидинең шигырьләрендә туган як матурлыгы, сафлык, әниләр, яшәеш, матур киләчәккә өмет чагыла. Шагыйрь иҗатында дөреслек, тормышның тискәре яклары сурәтләнә.

**2. а.б.** Туган авылында Ә.Габиди – татар теле һәм әдәбияты укытучысы гына түгел, ә оста куллы хезмәт дәресе укытучысы буларак та, үзе хакында җылы тәэсирләр калдырган шәхес. Аның укучылары белән бергә ясаган стендлары озак еллар буе мәктәпне бизәп торган. Ә ул җитәкләгән «Яшь бөре» әдәби түгәрәгенә йөреп, күпме укучы беренче тапкыр шигырь язу серләренә төшенгән?!

**1. а.б.** Шагыйрьнең күз карашына игътибар итсәң, анда ниндидер бер тирән уйга бирелү, туган халкы турында уйлану чагыла төсле. Милләтебезнең үткәне һәм киләчәге, бетеп бара торган авылларның үкенечле язмышы, көннән-көн пычрана барган табигать, сөенечле яки үкенечле мәхәббәт, сугыш чоры хатирәләре, туган ягының хезмәт сөйгән кешеләре, эшләп-эшләп тә мантый алмаган хезмәт ияләре, сагындыргыч яшьлек... Аларны санап бетереп буламыни?! Габиди кайсы гына темага алынмасын, фәкать үзе белгәнне һәм йөрәге аша кичергәнне язган.

**2 а.б**. Ә хәзер шагыйрьнең биографиясенә күз салыйк.

Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин 1926 елның 26 сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында урта хәлле крестьян семьясында туа. Җидееллык мәктәпне бетереп, Сарман урта мәктәбендә укып, унынчы классны тәмамлап, фронтка китә һәм яраланып, госпитальлләрдә ята. 1945 елда «Тревога» исемле фронт газетасы типографиясендә аның «Борылмалы юллардан» исемле китабы басыла. Әзһәр ага Габиди соңгы елларда бик актив язган, еш кына газета-журналларда шигырьләре басылып чыккан.

**1 а.б. :** Әзһәр ага Габиди башлыча балалар шигъриятенә хезмәт итте.

Язучының бүгенге көнгә балалар өчен «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Калган эшкә кар ява», «Таң сәгате», «Без – яз дуслары», «Югалган кояш», «Күлдәвектә кояш көлә» китаплары дөнья күргән.

Әзһәр ага Габидинең балалар өчен язган шигырьләре туган як, андагы вакыйгалар, күренешләр турында. Аларның һәркайсына шагыйрь балалар күзлегеннән карап бәя бирә.

Ә хәзер шарадаларын чишеп алыйк әле.

1.Тәүге иҗегем
Бай минем суга,
Соңгы иҗегем
Үсә басуда.
Минем үземне
Һәр кеше сөя,
Шуңа, яратып,
Өстенә кия.(күл-мәк)
2.Минем өч хәреф
Ява җәй көне
Чәчәк,гөлләргә
Һәм азык була
Нечкә билләргә.
Соңгы икесен
Йөртә бер елга,
Җәен-кышын да
Мин яшим шунда (бал-ык)

3.Нәни генә кош
Булсам да үзем,
Атым (исемем) эчендә
Бар ике исем.
Аның тәүгесе
Сөт каймак бирә,
Ә икенчесе
Җәй көннәрендә
Төшә чирәмгә.
Үземне бик тә
Сөя балалар.
Ясап оялар
Каршы алалар(сыер-чык)

**2 а.б**. Никадәр матур чагыштырулар, гүзәл сынландырулар! Мондый якны яратмаган җирдән яратырсың, мондый җирләрне сөймәс җирдән сөярсең. Авыл баласы кечкенәдән үк җиргә гашыйк, җирне сөя, аның хикмәтләрен белә. Җир җиләге нигә бик тәмле? «Әллә әни аңа шикәр сибәме?» шигыре.

**1 а.б**. Туган ил, туган җир темасы Ә. Габидинең балалар өчен язган шигырьләрендә кызыл җеп булып сузылган. Төрле образлар аша ул туган як җиренең уңдырышлылыгы, муллыгы турында сөйли. Мәсәлән, «Нарат» шигыре.

**2 а.б**. Шул рәвешле шагыйрь яшь укучысына: «Туган жиреңнән аерылма, аерылсаң рәхәт күрмәссең», – дип әйтә сыман.

Ә. Габидинең шигырьләрендә кеше белән табигать нык берләшкән. «**Таң гөле»** шигырен тыңлап үтик.

**1 а.б**. Тау буенда кешеләр утырткан гөл үсә. Җил аның ал керфеген сыйпый, былбыллар аңа кунып сайрый, ак болытлар яңгыр булып тама. Гөл үзе дә җавапсыз калмый шат: күңелләргә хуш исләрен бүләк итә. Бактың исә, без үзебез дә Җир-әнкәйнең гөле икән бит, шуңа күрә безгә туган якта рәхәт, иркен, күңелле.

**2 а.б**. Ә. Габиди балалар психологиясенә хас булган тискәре сыйфатлардан көлә, уңай сыйфатларга, киресенчә, дан җырлый, бу сыйфатларны яшь укучыда күрергә тели. Бу турыда шагыйрь ачыктан-ачык әйтми, ә бәлки киная белән яшь укучыга нәтиҗәләр ясарлык итеп сөйли. **«Һавалы чеби»** шигырендәге чуар тавык чебие кебек һаваланып йөрсәң, песи тырнагына эләгерсең, “аерылганны аю түгел, песи дә ашый”.

**1 а.б**. Карак мәче кебек булсаң, келәткә кереп май урлап йөрсәң, тычкан көләрлек хәлдә калырсың, – ди язучы.

Балаларның зиһенен баетуда, уйлау-фикерләү сәләтен үстерүдә дә Әзһәр аганың күп кенә табышмаклары игътибарга лаек.

Әйдәгез әле, без дә зиһеннәребезне тикшереп «Булсаң зирәк – әйт тизрәк!» дигән табышмак әйтү уенын уйнап алыйк.

1. Пыр-пыр килеп китәр кош,
Күккә менеп җитәр кош.
Ширбәт түгел, су да түгел,
Девон маен эчәр кош.(Самолет)

2.Табаным утлы булса,
Тукымадан йөрим мин.
Җыерчыклы йөзләрне дә
Матурлап тигезлим мин (Үтүк)

3. Мөгеземнән тоталар да
Аяк белән йөртәләр.
Миңа утырып, кешеләр
Юлны җитез үтәләр.(Велосипед)

4. Старты юк – йөгертә,
Гармуны юк – биетә,
Куллары юк – чеметә,
Нәрсә соң ул, кем әйтә?(Суык)

Әзһәр Габиди һичкайчан зур бөеклекләргә омтылмыйча, әрсезлек күрсәтмичә, бары иҗат итте, шигырьләр язды.

**<u>1 а.б</u>**. Туган ягы Сарман төбәгенең кабатланмас гүзәл табигатен, аның хезмәт сөйгән халкын олылады, гашыйк булып язды, сагынып язды. **«Сагындым»**

**<u>1 нче укучы:</u>**

Бу кадәрле сагынырмын диеп,
Уйламаган идем, Сарманым.
Күз алдыннан китми айлы кичең,
Истән чыкмый алсу таңнарын.
Күз йомдыммы – төшләремә керә
Чәчәкләре зәңгәр тавымның.
Һич яшермим сездән: туган якның
Әременә кадәр сагындым.

<u>2 а.б.</u> Әзһәр ага туган яктан, төбәктән бер көн генә дә аерылып китә алмый. Ул чишмәләрнең тәмен, ахак төсле офыкларын, эт өрүен, әтәч кычкырганын сагына

**<u>1 а.б</u>**. Әзһәр ага Габиди шигырьләрендә, сокландырырга тырышып, башкаларны да үз артыннан ияртергә омтылып иҗат итте. Әнә шуңа да Әзһәр ага Габиди шигырьләре үзләренең тормышчан гадилеге, эчкерсезлекләре, самимилекләре белән күңелне җәлеп итәләр.

**2 нче укучы**

Уртак итеп яши белгәнгә,
Кешеләрдә күз яшьләре күрсәм,
Гамьсез генә үтеп китмәдем.
Булмаса да кульяулыгым белән
Мин аларның яшен сөрткәнем,
Гамьсез генә үтеп китмәдем.

<u>1 а.б.</u> Аның шигырьләрендә, синең үз күңелеңдә туып та, әлегәчә сүзләргә әверелмәгән хисләр, уй тойгыларның өермәсе белән очрашкандай буласың. Әйтәсе сүзләр «Соңламыйк» шигырендә ачык күренә.

3 нче укучы

Дөнья арттан янып килми диеп,
Гамьсез генә яши бирәбез,
Дус-ишләрнең уй-хыялы белән
Кызыксынмыйбыз соң нигә без?
Нигә алар белән бергә сулап
Хыялына канат куймыйбыз?
Омтылышын аның үстерергә,
Җылы сүз әйтергә соңлыйбыз.

**<u>4 нче укучы</u> «Киңәш»**

Үз бәхетең юллап чыккан чакта
Кеше кайгысын син күрмәсәң,
Үз җаныңа уртак итеп алып
Тигез итеп аны белмәсәң.
Ялгыз шатлык шатлык буламыни –

Ялгыз шатлык бит ул гомерсез.
Кешеләргә дәрт, дәрман да бирми
Һәм ул юкка чыга бер эзсез.
Аларга да чыгар өлешне.

Һәркайсыбызга бик тә таныш, якын булган, үзенең фәлсәфи-лирик, нәфис-тәэсирле шигырьләре белән күңелләребезне яулаган мөхтәрәм Әзһәр агабыз бу якты дөньяда юк инде. Ул халкының, Ватанының, милләтнең патриоты, Сарманының газиз баласы булып калды. Алга таба да аның шигырьләре халык теленнән төшмәсен,үз укучысын тапсын иде.

**Клара Булатованың иҗаты**
(Педагогик проект)

Халитова Наилә Әмирҗан кызы, Хәкимова Гөлүсә Габдулла кызы,
Җәлил бистәсенең «Аленушка» балалар бакчасы тәрбиячеләре, Сарман районы

**Кереш**

Һәр кешенең йөрәгендә туган илгә, туган телгә мәхәббәт яши. Һәр төбәк, һәр ил, һәр шәһәр, һәр авыл үзенчә матур, үзенчә бөек, халкыбызга якын. Һәркем үзенчә туган телгә булган мәхәббәтен белдерә. Рәссамнар аның матурлыгын күрсәтә торган картиналар ясыйлар, шагыйрьләр Ватан турында шигырьләр язалар, игенчеләр басуларны тутырып ашлык үстерәләр, төзүчеләр иң матур йортларның берсен төзиләр.

Бу мәхәббәтне саклау, үстерү, ныгыту өчен балачактан ук балаларны дөрес тәрбияләргә кирәк. Тәрбия-ул катлаулы педагогик процесс. Аның нигезе булып әхлакый сыйфатлар булдыру тора. Туган илгә мәхәббәт баланың якыннарына – әти-әниләренә, әбиләренә, туган йортына якын булуыннан башлангандыр. Туган ягыбызның матурлыгын тоя, туган як чәчәк атсын өчен күп көч куйган кешеләр белән горурлана белүдә Ватанга мәхәббәт чагыла.

Татарстан Республикасының һәр кечкенә почмагының үз үзенчәлекләре бар, үз якташлары, алар белән горурланалар. Алар турындагы истәлекне без киләчәк буыннар өчен саклап кала алабыз һәм сакларга тиеш. Безнең Сарман районында да бик күп танылган кешеләр бар. Дамир Гарифуллин, Мәдинә Маликова, Әзһәр Габиди, Хәниф Хәйруллин, Фәрит Яхин. Аларның берсе-танылган татар шагыйрәсе, Г.Тукай премиясе лауреаты – Клара Булатова.

Шагыйрә Клара Булатова 1936 елда Сарман районында, Татар Карамалы авылында педагоглар гаиләсендә туа. Бу булачак шагыйрәнең рухи үсешендә зур роль уйнады. Клара Булатованың әнисе татар әдәбияты укытучысы булган, әтисе математика укыткан. Алар икесе дә поэзиягә гашыйк булганнар, үзләре шигырьләр иҗат итү белән шөгыльләнгәннәр. Шулай итеп, укытучылар эшенә, әдәбиятка һәм шигъриятькә мәхәббәт кызга кечкенәдән үк салына. Заман сулышы үзенекен итә: гаилә авылдан-авылга күчә. Булатовлар Татарстан АССРның Сарман районы берничә авылында яшиләр. Шулай итеп, Кларага еш кына күченүләр нәтиҗәсендә төрле мәктәпләрдә укырга туры килә. Аның мәктәп еллары Сарман районы Ләке авылында уза, аның иҗаты да биредә формалаша башлый.

Тиздән Клара Булатова Казан дәүләт университетына укырга керә һәм студентлар мохитенең тере легендасы була. Шунысы игътибарга лаек, бу вакытта ул әдәби түгәрәкнең төп оештыручысы булып тора.

Иҗади шәхес буларак, шагыйрә Клара Булатова кырык ел дәвамында үзен укытучылык эшчәнлегенә багышлый. Ул телнең барлык нечкәлекләрен һәм гүзәллеген, аның үзенчәлеген, байлыгын һәм кыйммәтен тирәнрәк тоя. Үзенең бер шигырендә ул яза:

Укытучы булып гомер иттем,
Укытучы идем!
Чын ихластан ул исемне йөрттем,
Шул исемне сөйдем.

Педагог һәм шагыйрә Клара Булатова инде ярты гасырга якын үзенең шигырьләрен дә киң кулланып, яңа буын тәрбияли. Ул балаларның психологиясен, аларның яшь

үзенчәлекләрен яхшы белә, шуңа күрә шигырьләрдән тыш, методик тәкъдимнәр һәм уку әсбаплары да яза. Алар, әлбәттә, шигъри формада языла.

Шул ук вакытта Клара Булатова өлкәннәр дөньясына да, балалар дөньясына да бер үк төрле кагылышлы проблемаларны да күтәрә. Еш кына бу очракта үзәк булып үсеп килүче буынны тәрбияләү һәм укыту проблемасы тора. Автор үз карашларын, уй-хисләрен көчләп такмый, – дип уртаклаша алар махсус уйлап табылган күңелле хәлләр тасвирламалары аша.

Язучыларның һәм шагыйрьләрнең күпчелеге авыл җирендә туа. Мөгаен, табигатькә якын булу аларга иҗат өчен көч бирә. Туган як, аңа мәхәббәт темасы шулай ук Клара Булатованың шигырьләрендә һәм поэмаларында чагылыш тапкан. Автор өчен Туган як табигате – ул бетмәс-төкәнмәс илһам, рухи тынычлык, уйлау өчен ризык чыганагы.

Клара Булатова иҗатында табигать тасвирламасы кешенең эчке дөньясының психологик үзенчәлекләрен тапшыру ысулы булып тора. Моннан тыш, әхлак нигезен, автор фикеренчә, туган як табигатенә, туган йортына карата яхшы мөнәсәбәт формалаштыра. Бу шигырьләрдә туган табигатьнең матурлыгына соклану, аңа катнашуы һәм аның алдында баш июе өчен горурлык хисе сизелә. Шагыйрәнең бу матурлыкны бай тел ярдәмендә тапшыра белүе сокландыра. Автор табигатьне, бигрәк тә агачлар: тал, каен, балан һәм миләш образларын кеше, аның рухи дөньясы тапшыру өчен куллана.

Безнең проектның нигезендә танып-белү һәм иҗади эшчәнлек ята. Безнең тәрбияләнүчеләребезнең бөек якташларын белүләрен, алар яшәгән урынны яратуларын һәм горурлануларын телибез.

**Проектның максаты:** шагыйрә Клара Булатованың тормыш һәм иҗатын өйрәнү, балаларда якташ шагыйрәнең иҗат мирасына кызыксыну уяту, туган якка карата мәхәббәт тәрбияләү.

**Проектның бурычлары:**

1. Тәрбияләнүчеләрнең күзаллауларын киңәйтү, кече Ватан тарихы, аның күренекле кешеләре турында белемнәрне тулыландыру.

2. Балалар сөйләмен үстерү, сүзлек запасын баету; ирекле фикер йөртергә, фантазияләргә өйрәтү; хәтер, фикерләү, вак моторика, күрү сәләтен үстерүгә ярдәм итү.

3. Шәхеснең әхлакый сыйфатлары: туган як тарихына һәм кешеләргә карата хөрмәт, якташларың өчен горурлык хисе тәрбияләү.

4. Тарихи үткән турында мәгълүматларны кабул итү өчен шартлар тудыру.

5. Проектны тормышка ашыру процессында ата-аналар белән хезмәттәшлекне оештыру.

**Проектта катнашучылар:** мәктәпкә әзерлек төркеме балалары, тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе, балаларны татар теленә өйрәтү буенча тәрбияче, тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары.

**Балаларның яше:** 6-7 яшь.

**Мәгариф өлкәләрен интеграцияләү:** «Танып-белү үсеше», «Сөйләм үсеше», «Иҗтимагый-коммуникатив үсеш»«, «Сәнгать-эстетик үсеш», «Физик үсеш»

**Проектның вакыты:** кыска вакытлы (3 атна).

**Проектның төре:** танып-белү һәм иҗади.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

Проект эшчәнлеген оештыру һәм планлаштыру 3 юнәлеш буенча алып барыла:

- балалар белән эшләү;
- тәрбиячеләр белән эшләү;
- ата-аналар белән эшләү.

**Проектның этаплары:**

**1 этап әзерлек:**

- теманы сайлау, максатлар һәм бурычлар кую; әдәбият эзләү;
- танып-белү һәм методик әдәбиятны өйрәнү; «Мәктәпкәчә белем бирү» журналларында әхлакый-патриотик тәрбия бирү буенча язмалар уку;
- музыкаль әсәрләр сайлау;
- интернет-ресурслар мәгълүматы куллану;
- күрсәтмә материал әзерләү.

**Төп этап:**

- мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә фән-үсеш тирәлеген камилләштерү (китап почмаклары, мәгълүмати стендлар);
- шагыйрә Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу буенча балалар белән белем бирү эшчәнлеге үткәрү;
- әңгәмә;
- музыкаль әсәрләрне тыңлау;
- җырлар өйрәнү;
- якташларыбызның әсәрләрен уку;
- музейда булу;
- балалар поселок китапханәсенең уку залында булу;
- рәсем һәм рәсемнәр карау;
- дидактик уеннар;
- ата-аналар белән эшләү.

**3 нче йомгаклау этабы:**

- балалар бакчасы хезмәткәрләре өчен тәҗрибә тәкъдим итү;
- проект эшчәнлеген рәсмиләштерү;
- нәтиҗәләр ясау.

**Проект эшчәнлеге планы**

| **Катнашулар** | **Эш формасы** | **Вакыты** |
|---|---|---|
| Балалар белән эш | 1. Балалар белән шагыйрә Клара Булатованың тормышы һәм иҗаты белән таныштыру.<br>2. «Якташларыбыз турында мәхәббәт белән сөйләү» әңгәмә.<br>3. Кичке укулар: «Якташларыбыз әсәрләре буенча сәяхәт» (Клара Булатов, Дамир Гарифуллин, Әзһәр Габиди).<br>4. Балалар белән бистәбезнең китапханәсендә уку залында булу.<br>5. Бистәбезнең музеенда булу.<br>6. Бистәнең урамнарына, истәлекле урыннарына багышланган «Минем бистәм тарихы» презентациясе белән танышу.<br>7. Туган як хайваннары, үсемлекләр дөньясы турында табышмаклар кичәсе үткәрү: «Табышмаклар иленә сәяхәт».<br>8. Татар халык бармак уеннарын өйрәнү.<br>9. Күңел ачу: ата-аналар һәм балалар белән «Моңлы минем туган ягым».<br>10. Рәсем: «Солдатлар», «Әниемнең кызы юк бит», «Шушы яктан, шушы туфрактан без», «Минем йортым», «Туган ягым!»; «Безнең бистәдә уңыш бәйрәме»; «Милли киемнәр».<br>12. Кисеп ябыштыру: «Безнең урамдагы йортлар».<br>13. Туган як табигате белән таныштыручы дидактик уеннар уйнау: «Кайсы агачтан», «Безнең урманда яшәүче хайваннарны тап», «Бу кайчан була».<br>14. Балаларга милли-мәдәни тәрбия бирү, аларны татар халкының милли киемнәре белән таныштыру: «Читекне бизә», «Алъяпкычны бизә», «Курчакларны киендер» дип исемләнгән уеннар уйнау.<br>15. Татар халык уеннары: «Миңлебай», «Парлашу», «Әтәчле», «Буяу сатыш», «Кем җитезрәк». | Март |

| | | |
|---|---|---|
| Тәрбиячеләр белән эш | 1. Проектның максатлары һәм бурычлары турында фикер алышу; проектны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру буенча кызыксыну формалаштыру.<br>2. Балаларны язучының иҗатына, туган як иҗатына җәлеп итү буенча методик материаллар, рекомендацияләр эшләү һәм туплау.<br>3. Якташларыбыз иҗаты буенча китаплар җыю.<br>4. Тәрбиячеләр өчен консультация: «Балаларны якташларыбызның тормышы һәм иҗаты белән ничек таныштырырга». | Март |
| Ата-аналар белән эш | 1. Ата-аналар арасында китап уку буенча анкета тутыру.<br>2. Күчмә папка: «Укырга киңәш итәбез».<br>3. Бистә урамы макеты (балалар белән бергә).<br>4. Милли курчаклар өчен кием тегү (балалар белән бергә). | Март |

**Нәтиҗә**

Әлеге проект һәм алынган белемнәр нигезендә нәтиҗәләр ясарга мөмкин: без куйган максатыбызга ирештек, без балаларның күзаллауларын киңәйттек, якташыбызның иҗаты белән таныштырдык, кече Ватаныбызны күбрәк яратырга һәм кадерен белергә кирәк икәнлеген аңлаттык.

**Алга таба эш перспективалары:**

1. Кече Ватаныбыз шагыйрьләренең иҗади мирасын өйрәнүне дәвам итәргә.
2. Якташларыбыз катнашында әдәби очрашу оештырырга.

## Клара Булатова иҗаты

(Мәктәпкә хәзерлек төркеме балалары өчен сөйләм телен үстерү буенча эшчәнлек конспекты)

Галимова Айсылу Фәнил кызы, Яр Чаллы шәһәренең 62 нче гомумүстерешле балалар бакчасы тәрбиячесе

*Белем бирү бурычлары*: балаларның туган төбәгебез язучыларының иҗаты турындагы белемнәрен баету һәм камилләштерү; телдән журнал чыгарырга өйрәнүне дәвам итү.

*Үстерү бурычлары*: әдәби әсәрләрне тыңлый һәм аңлый белү сәләтен, эчтәлеге буенча сорауларга тулы җавап бирә белү күнекмәләрен үстерү.

*Тәрбия бурычлары*: Клара Булатова иҗатына ихтирам, кызыксыну уяту. Өлкәннәрнең кадерле кешеләр булуын төшендерү, кечкенә дусларыбызга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләү.

<u>*Планлаштырылган нәтиҗәләре.*</u>

*Шәхси УУГ:* укуга карата кызыксыну хисе;

<u>*Метапредмет нәтиҗәләр.*</u>

*Регулятив УУГ:* биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү (тәрҗемәче ярдәмендә).

*Коммуникатив УУГ:* башкаларның сөйләмен тыңлау һәм аңлый белү; парларда, төркемнәрдә эшли белү.

- *Танып - белү УУГ:* тәрҗемәченең авыр булмаган сорауларга җавап бирү; рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү.

*Сүзлек:* сүзләрен татлы булсын, каты тел катма, тәмсез сүз әйтмә, яманнан якла, йолдызың ачкан юлыңнан, тайпылмасана.

**Җиһазлау**: аудиоязма, компьютер, проектор, экран, презентация, китап һәм журналлар күргәзмәсе, магнитлы такта.

*Эшчәнлек барышы.*

1. Оештыру өлеше.

*Тәрбияче.* Балалар, карагыз әле, безнең бүлмәдә нинди матур кояш чыккан. (Балаларның игътибарын экрандагы кояшка юнәлтә). Тәрәзәдән дә безгә шундый матур кояш елмая. Әйдәгез, тәрәзәгә карап, кояш белән исәнләшик әле. (Тәрәзә янына килпләр). Башта пышылдап, аннары гадәти тавыш белән, аннан кычкырып «Исәнме, кояш!» – дип (Балалар кабатлыйлар). Слайд.

Без бүген сезнең белән телдән журнал чыгарачакбыз. Шуның өчен магнитлы тактада да эшләячәкбез.

*Тәрбияче.* Иң иртә ул күренә.
Менеп китә үренә.
Сокланамын эшенә –
Нур сибә бар кешегә.

- Бу шигырь юллары нәрсә турында? (Балаларның җавабы).

2. Клара Булатова турында тәрбияче хикәясе (Слайдлар ярдәмендә)

Без бүген сезнең белән, кояш кебек балкучы, якташыбыз Клара Булатова иҗаты белән танышырбыз. Ул Сарман районы Татар Карамалысы авылында туып үскән. Бик яшьтән шигырьләр белән кызыксынган. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам иткән. Әле мәктәптә укыганда ук аерым шигырьләре газета һәм журналларда басылып чыга. Югары белем алып, Әлмәт шәһәрендә эшләгәндә ул үзенә яңа бер дөнья – балалар дөньясын ача. Балалар күңеле аның җанына кояш кебек яктылык биреп, шигырьләренә нур өсти.

Клара Булатова шигырьләре туган якка, газиз туфрагына тирән мәхәббәт белән язылган. Шагыйрә туган ягының газиз табигатенә, иксез-чиксез хәзинә байлыкларына, тырыш, хезмәт сөючән, батыр халкына дан җырлый.

Бөтен кешелек дөньясына ямь бирүче, елмаюлары белән безне иркәләүче, җылы карашлары белән назлаучы, акыллы фикерләре белән безгә ак юл күрсәтүче сөекле әбиләребезгә багышлаган шигырьләре дә бик күп. Хәзер шундый шигырьләрнең берсен укып китәбез.

*3.Шигырь уку*: Күкләргә кара, улым. (Әби җыры)

Күкләргә кара, улым,
Йолдызлар сана, улым...
Йолдызлар таныган бала
Якты юл таба, улым.
Йолдызлар якты булсын,
Юлларың яхшы булсын,
Сүзләрен татлы булсын.
Каты тел катма, улым,
әмсез сүз әйтмә, улым;
Олыны да, кечене дә
Яманнан якла, улым.
Күкләргә кара, улым,
Йолдызлар сана, улым...
Йолдызың ачкан юлыңнан
Тайпылмасана, улым!

4. Балаларга сораулар: (әңгәмә үткәрелә)

- Шигырьдә нәрсә турында язылган?
- Балалар, Клара апа бу шигырендә безгә нәрсә әйтергә теләде икән? Хәзер шуны ачыклыйбыз. (Сюжетлы рәсемнәрдән табалар)
- Сез нинди тәмле сүзләр беләсез?
- «Каты тел» дигән сүзне ничек аңлыйсыз?
- Олыларны нигә хөрмәт итәргә кирәк?
- «Туры юл» дигән сүзне ничек аңлыйсыз?
- Йолдызың ачкан юлыңнан тайпылмасана, улым! – дип нигә әйтәләр?

*Тәрбияви күнегү* «Назлы сүзләр» (Гаиләдәге кешеләргә матур сүзләр белән эндәшү; мәсәлән: әнием, әтием, әнкәем, эткәем, әбекәем, әбекәй, дәү әни, дәү әти һ.б.).

5. Дуслык – ул иң кирәкле мөнәсәбәтләрнең берсе. Минемчә, дуслары, туганнары булган кеше бәхетледер. Ә сезнеңчә ничек? Бу турыда күп шигырьләр, хикәяләр язылган.
- Әйтегез әле, кем ул дус?(Слайд) (Бергә уйнаучы, ярдәм итүче, иң якын кеше...) Дуслыкның билгеле бер кагыйдәләре бар. Нинди кагыйдәләр икән алар, уйлап карагыз әле? (Слайд)
- Гадел, сабыр, ышанычлы булу.
- Ә хәзер экранга карыйк әле. Безнең кешеләр арасында гына түгел, ә хайваннар арасында да дуслык була икән. Хәзер без сезнең белән Клара апабызның «Иптәш» шигыре белән танышып китәрбез. (Шигырь укыла).
- Ни өчен Марска күңелсез? (Аңа күңелсез булмасын өчен, песи алып кайтканнар.)
- Песи турындагы юлларны тагын бер тапкыр укып карыйк әле.
- Песисез йорт авылда бик сирәк, шәһәрдә дә күбегезнең өендә песи бардыр. Сезнеңчә ничек, песи малайга иптәш булырмы?
Әйе, песи ул йортка ямь, җанлылык өсти. Марс та песи белән дуслашыр, аның белән уйнарга өйрәнер, аны ашатыр, карар.
- Ә сезнең өйдә песи бармы? Ул нинди? Нәрсәләр эшли белә? Сез аны яратасызмы?
- Клара апабызның:
Олыны да, кечене дә
Яманнан якла, улым, – дигән юлларын тагын бер кабатлыйк әле.
- Кечене дә, – дигән сүзләре менә шундый йорт хайваннарына туры килә дә инде.




6. *Ял минутында* К.Булатованың шигыреннән өзек ятланыла. (Сүзлек эше үткәрелә).
Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Шул туфракта язсын яшәргә.

7. *Дидактик уен* «Фотоаппарат» (30 секунд йорт хайваннарына бәйле рәсем күрсәтелә, аннан соң шундый ук рәсем үзгәрешләр белән бирелә. Бала бу үзгәрешләрне сизәргә тиеш).

8. *Үстерешле уен*. «Кем күбрәк белә?» (Экранда Г. Тукай, М.Җәлил, К. Булатова, Ш.Галиев, З.Туйфалова портретлары күрсәтелә, балалар җавап бирә).

9. *Йомгаклау. Тәрбияче*. Балалар, сезгә «Күкләргә кара, улым» һәм «Иптәшләр» шигырьләре ошадымы? Аны кем язган? Клара Булатова турында нәрсәләр белдегез? Сезгә бигрәк тә нәрсә ошады? (Балаларның җаваплары) Ә миңа сезнең бүгенге эшчәнлектә бик тырыш, игътибарлы булуыгыз, сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирүегез ошады. Мин сездән бик канәгать. Рәхмәт сезгә, балалар!
- Балалар, Клара Булатованың шигырьләре сездә зур кызыксыну уятты. Ләкин аның иҗаты белән чикләнгән вакытта гына танышу мөмкин түгел. Бу шагыйрәнең иҗатын өйрәнүне дәвам итәрбез.
Клара Булатова – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Габдулла Тукай һәм Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премияләр лауреаты да әле ул. Бу турыда сез мәктәп укучылары булгач өйрәнерсез һәм шигырьләрен укырсыз.
- Сау булыгыз!
*Магнитлы тактада эшләү*

| **Шушы яктан, шушы туфрактан без. Клара Булатова иҗаты.** | | |
|---|---|---|
|   |  | Иң иртә ул күренә.<br>Менеп китә үренә.<br>Сокланамын эшенә –<br>Нур сибә бар кешегә. |

<table>
<tr>
<td>Клара Булатова Сарман районы Татар Карамалысы авылында туып үскән. Бик яшьтән шигырьләр белән кызыксынган. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам иткән. Әле мәктәптә укыганда ук аерым шигырьләре газета һәм журналларда басылып чыга.</td>
<td>Югары белем алып, Әлмәт шәһәрендә эшләгәндә ул үзенә яңа бер дөнья – балалар дөньясын ача. Балалар күңеле аның җанына кояш кебек яктылык биреп, шигырьләренә нур өсти.</td>
<td>Клара Булатова шигырьләре туган якка, газиз туфрагына тирән мәхәббәт белән язылган. Шагыйрә туган ягының газиз табигатенә, иксез-чиксез хәзинә байлыкларына, тырыш, хезмәт сөючән, батыр халкына дан җырлый.</td>
</tr>
<tr>
<td>Күкләргә кара, улым. (Әби җыры)<br>Күкләргә кара, улым,<br>Йолдызлар сана, улым...<br>Йолдызлар таныган бала<br>Якты юл таба, улым.<br><br></td>
<td><br>Йолдызлар якты булсын,<br>Юлларың яхшы булсын,</td>
<td>Олыны да, кечене дә<br>Яманнан якла, улым.<br>Күкләргә кара, улым,<br>Йолдызлар сана, улым...<br></td>
</tr>
<tr>
<td><br></td>
<td>Сүзләрен татлы булсын.<br>Йолдызың ачкан юлыңнан<br>Тайпылмасана, улым!</td>
<td><br></td>
</tr>
<tr>
<td><br><br>Каты тел катма, улым,<br>Тәмсез сүз әйтмә, улым.</td>
<td></td>
<td><br></td>
</tr>
</table>

## Могҗизалар кыры

Шамсова Резида Дәниф кызы, Әмәкәй мәктәбе, Мөслим районы

Исәнмесез, саумысез,
Һәрберегез, барчагыз.
Бездән сезгә кайнар сәлам
Кабул итеп алыгыз.

Хөрмәле укытучылар һәм укучылар! Без бүген бу залга белемнәребезне, зирәклекләребезне сынау йөзеннән җыйналдык. Өлкән яшьтәге юбиляр язучыларның

тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнү максатыннан күрше районнан шагыйрә, Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты (*2015*), Татарстанның халык язучысы (*2019*), бүгенге көндә Әлмәт районы Нәдер авылында яшәп иҗат итүче Клара Гариф кызы Булатованың шигырь җыентыкларын тәкъдим иткән идем. Сез шагыйрәнең биографиясе, иҗаты белән дә, интернет челтәрдә бирелгән материаллар белән дә танышкансыздыр дип уйлыйм. Хәзер инде чебиләрне санар вакыт җитте. Мин сезнең шагыйрә-укытучы Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты белән ни дәрәҗәдә мәгълүматлы булуыгызны тикшерү максатыннан «Могҗизалар кыры» уенына чакырам. Сез бу уенның тәртибен беләсез. Шулай да искә төшереп китик.

Могҗизалар кырында 3әр уенчыдан торган 3 төркем катнаша. Һәрбер катнашучы үзе турында кыскача гына таныштырып китә. Уенның тәртибе белән таныштырып кителә. П – приз, Б – банкрот (Барлык очколарың да юкка чыга), 3 тапкыр рәттән дөрес хәреф әйтелсә, 2 шкатулка тәкъдим ителә (Берсендә акча була). Һәр турдан соң укучыларның матур чыгышлары. Тамашачылар белән викторина сорауларына җавап биреп, укучыларга кызыксындыру призлары бирү дә каралган. Турлар арасында укучылар тарафыннан Клара Булатова сүзләренә язылган җырлар һәм матур шигырьләре башкарыла.

(һәр турга уенчылар сайлап алына. Табышмакларга җавап табу юлы белән дә, К.Булатованың иҗаты буенча гади сорауларга җавап табу юлы белән дә сайлап алынырга мөмкин. )

3 турда катнашу өчен 9 укучы сайлап алырга кирәк. Сораулар:

Сорау. Клара Булатова кайчан һәм кайда туган? (Клара Булатова 1936 елның 18 мартында Татарстан АССРның Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туган).

Сорау. Шагыйрәнең әти-әнисенең профессияләре? (Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була).

Сорау. Кызчык беренче сыйныфка ничәнче елда һәм кайда укырга керә? (1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә).

Сорау. Хезмәт юлын кем буларак башлый? (К. Булатова хезмәт юлын Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч класслар укытучысы булып башлый).

Сорау. Клара Булатова югары белемне кайда, нинди белгечлек буенча ала? (Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген (1969) тәмамлаган, укытучы һөнәрен үзләштерә)

Сорау. Клара Булатованың шигырьләре кайсы матбугат битләрендә яктыртыла? («Татарстан яшьләре», «Совет Татарстаны» («Социалистик Татарстан») газеталарында, «Пионер» («Ялкын»), «Азат хатын», «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналларында аның күп кенә шигырьләре дөнья күрә).

Сорау. Клара Булатованың бүләкләре, мактаулы исемнәре. (Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, 1994 – Рафаил Төхфәтуллин премиясе, 2007 – Саҗидә Сөләйманова премиясе – «Әрнү» китабы өчен)

Сорау. Клара Булатованың бүләкләре, мактаулы исемнәре. (2015 – Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты)

Сорау. Клара Булатованың бүләкләре, мактаулы исемнәре. (2019 – Татарстанның халык язучысы)

| Г | А | М | И | Л |
|---|---|---|---|---|

1 тур

| А | Ф | З | А | Л |
|---|---|---|---|---|

Сорау. К.Булатова иҗаты турында Татарстан Республикасының халык шагыйре, төпле фикерле, туры сүзле әдип болай дип язган: «Шагыйрәнең шигъри тойгылары бик заманча, кешелекле, күңелгә хуш килә торган, теле бик ачык, авылча, саф татарча. Аның иҗаты бик халыкчан... К. Булатова шагыйрь булып туган кеше, шигырь җанлы, шигырь җенле, фанатик шагыйрә, талантлы, бик популяр шагыйрә ул». Кем шулай дип әйтә?

2 тур

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Ү | Р | Н | Ә | К |

Тормыш – көрәш, дибез. Зур күләмле шигырен К.Булатова әтисенә багышлаган. Гариф ага катлаулы, сикәлтәле гомер юлы узган. Дөрес, ул яшәгән чор шундый булган. 1920 еллардагы ачлык, колхозлаштыру, Бөек Ватан сугышы... Ул үлемне дүрт мәртәбә күргән һәм... җиңгән. Яу кырыннан тәне теткәләнеп кайтса да, аның күңеле таза-сау, җаны олы булып калган. Шигырь барысын да сөйли: шагыйрәнең әтисе яшәү утында яна, сугыш йончыткан халкына ярдәм итәргә атлыгып тора, өр-яңадан илне күтәрү юнәлешендә җиң сызганып эшли. Авылда мәктәп салдыра, белемле, үз һөнәренә бирелгән чын кешеләр тәрбияли. Шигырь шушы турыда. Бу шигырьнең исеме?

3 тур

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Я | З | Л | А | Р |
| А | Л | Д | А | |

1967 елда мөстәкыйль дөнья күргән беренче шигырьләр җыентыгының исеме.

Финал

3 тур уенда җиңгән җиңүчеләр катнашында финал уйнала.

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| С | Ә | Я | Х | Ә | Т | Н | А | М | Ә | Л | Ә | Р |

Клара Булатовага 2015 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирелә. Анда өч шигырьләр җыентыгы турында әйтелә. Шуның берсенең исеме.

Супер уен

Супер уенны уйный башлаганчы уенчыга таблода очколарын һәм аларга бүләкләр сайлау мөмкинлеге тудырыла. Уенчының ихтыяры белән уен дәвам иттерелә. Уенчы бүләкләрне алып уеннан чыгып та китә ала.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Җ | И | Д | Е | |
| Т | У | Б | А | Л |
| Б | Ә | Х | Е | Т |

К.Булатованың шигырьләр җыентыгына Ленар Шәех мәкалә яза. «Тонықланмас иҗат» дигән баш мәкаләдә мондый юллар бар: «Клара Булатова тәрбия, әхлак, намус төшенчәләре, тырышлык, гореф-гадәтләрнең сакланышы өчен көрәшә. Халыкчанлык рухы белән укучы күңеленә үтеп керә. Шагыйрә чын мәгънәсендә популяр, аның шигърияте безнең өчен үрнәк тә, үзенә күрә бер дәрес-сабак та. Ул – тере, тормышчан, тонықланмас иҗат!» Җыентык 2014 елда чыккан. Бу җыентыкның исеме?

Супер уенда катнашучы белән йомгак ясау.

Кичәбез ахырына якынлашты.
Сау булыгыз, дуслар, шат яшәгез
Ямьләндереп бөек Ватанны.
Зур уңышлар белән каршылагыз
Туган илдә аткан һәр таңны.

## Шагыйрә Клара Булатова иҗатына бер караш

Әсәдуллина Ә.М., Мортазина А.Н., Җәлил беренче санлы мәктәбе укытучылары, Сарман районы

Әлмәт төбәгендә яшәп иҗат итүче шагыйрә Клара Булатованың шигырь һәм поэмаларын кадерле кунак кебек һәр өйдә көтеп алалар, сәхнәләрдән укыйлар, композиторлар көйгә салалар. Чөнки аның шигырьләре мавыктыргыч, укучыларга аңлаешлы тел, үтемле сурәтләү-тасвирлау чаралары белән, зәвыклы итеп язылган.

Клара Булатованың шигырьләре туган якка, газиз туфрагына тирән мәхәббәт белән сугарылган. Данлыклы Әлмәт төбәгенең гүзәл табигатенә, иксез-чиксез хәзинә байлыкларына, тырыш, хезмәт сөючән, батыр, фидакарь халкына мәдхия, дияр идек без аның әсәрләрен.

Шагыйрә үзе җырларга кергән Сарман якларында туып үссә дә, иҗаты Әлмәтнең ундырышлы туфрагында чәчәк аткан. Биредә аның тынгысыз, якты хыялларга бай яшьлеге, иң җегәрле, көч-куәте ташып торган еллары үткән. Әлмәт – шагыйрәнең рухи туган җире.

Безнең яшьлекне үзенә
Фундамент иткән шәһәр –
Улларыбызга мирас ул,
Кызларыбызга мәһәр, –

дип яза үзенең «Куларты поселогы» шигырендә. Әлеге фикерне «Безнең дә бит яшьлек бар иде» шигырендә тагын да көчәйтеп җибәрә:

Яңа яшьләр үсә Әлмәттә.
Алар өчен юллар салдык без.
Йорт төзедек, бакча үстердек,
Алар өчен җырлар яздык без,
Алар белән бергә калдык без.

Әйе, шагыйрьнең тормыш-көнкүреше, шатлык-көенечләре, иҗат җимешләре Әлмәт төбәгеннән аерылыгыз:

Синдә кердем шигырь дөньясына,
Шигъриятта яшим яшь көйдәй,
И Әлмәтем, мин бит гашыйк сиңа.
Вакытлыча түгел, бөтенләй.

Шагыйрә Әлмәт төбәгенең зәңгәр язларын, ак мамыклы кышларын, көмеш нурга коенган урманнарын, сихри айга төннәрен үзенә генә хас поэтик бизәкләргә төреп бирә һәм сиздермичә генә фәлсәфи фикер дөньясына алып керә.

Шагыйрәнең поэтик тукымасында метафора, чагыштыру, эпитетларга киң урын бирелгән. «Безнең як» шигырен генә алыйк:

Ипигә ягып ашарлык
Кара җир безнең якта.
Шәл итеп иңгә ябарлык
Яшеллек безнең якта.

Ел фасылларын тасвирлаган шигырьләре гүзәллек дөньясында алып керә, күз алдыбызда җанлы картиналар китереп баса. «Шушы яктан, шушы туфрактан без» шигырендә дә шул ук мотив.

Шушы якта безнең хезмәт калсын
Мирас булып килер яшьләргә.

Җыеп кына әйкәндә, шагыйрә табигатьтән бөтен матурлыкны җыя да матур чәчәк бәйләме итеп укучының үзеңә кайтарып бирә. «Бер җәйге көн бирегез сез!» шигырендә бу ачык чагылыш таба.

...Һәм көйләргә салган да! Клара Булатованың шигырьләре җырлап тора, композиторларны үзенә тартып, җанны актара торган көйләр язарга рухландыра. Җырларның халык ихлас күңелдән кабул итә. Аның җырлары җанны иркәли, күңелләрне канат куя.

«Кеше җанын кеше рухын яктыртырдай җыр тудырган мәңгелеккә бәхетледер», – дип шагыйрә үзе дә бик дөрес әйтә.

Клара Булатова – милли җанлы, чын татар рухлы шагыйрәбез. Аның иҗатында халкыбызның әхлакый идеаллары, милләт язмышы, гореф-гадәтләребез турында гамьнәребез чагылыш таба.

## Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты

Гайнанова Рәмилә Рамазан кызы, Яр Чаллы шәһәре, 21 нче мәктәп укытучысы

| | |
|---|---|
| Максат | 1.К.Булатованың тормыш юлын, иҗатын өйрәнү.<br>2. Өйрәнелгән материал буенча балаларны сөйләмгә чыгару.<br>3. Якташыбыз иҗатына кызыксынучанлык уяту, китап укырга омтылыш |

| | |
|---|---|
| | тәрбияләү |
| Дәрес тибы | яңа белем үзләштерү. |
| Төп ресурслар | К.Булатовнаның китаплары, презентация |
| **Дәрес барышы** | |
| I этап.<br>Оештыру, мотивация | Исәнмесез, укучылар. Дәресебезне башлыйбыз.<br>«Шушы яктан, шушы туфрактан без» (Укытучы шигырь укый)<br>Китә калсак үзгә бер якка,<br>Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,<br>Өянкеләр елап озата.<br>Шушы яктан, шушы туфрактан без.<br>Читтә йөрсәк, шуңа күрәдер<br>Чишмә чыңлап, өянкеләр елап,<br>Таллар җырлап төшкә керәдер.<br>Шушы якта безнең эзләр калсын,<br>Мирас булып килер яшьләргә.<br>Шушы яктан, шушы туфрактан без,<br>Шул туфракта язсын яшәргә.<br>Мин сезгә яңа гына «Шушы яктан, шушы туфрактан» шигырен укып киттем.<br>- Укучылар, слайдка күз салыйк әле. Бу шигырьне кем язган икән? Сезгә бу шәхес танышмы?<br>- Укучылар, бүген дәресебездә без кемнең иҗаты турында сөйләшербез икән?<br>- Сез сез аның турында ишеткәнегез бармы?<br>Димәк, укучылар бүгенге дәресебезнең темасы: К.Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты. (Дәреснең темасы укыла.)<br>- Дәресебезгә укучылар нинди максатлар куярбыз икән?<br>- Әйе, укучылар без бүген дәресебездә К.Булатованың тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнербез һәм аның нинди бүләкләргә лаек булганлыгын белеп китәрбез. |
| II этап. Уку мәсьәләсен чишү | Презентация ярдәмендә К.Булатова турында кыскача мәгълүмат бирү.<br>Бер укучының чыгыш тыңлап китү.<br>Чыгыш буенча тест эшләү.<br>1. Клара Булатова кайчан туган?<br>а) 10 май 1936<br>б) 20 март 1936<br>в) **март 1936**<br>2. К.Булатова Сарман районының нинди авылында туган?<br>а) Ак Чишмә<br>б) **Татар Карамалысы**<br>в) Карасу<br>3. Башлангыч белемне кайда ала?<br>а) **Югары Чыршылы мәктәбендә**<br>б) Ләке авылында<br>в) Татар Карамалы авылында<br>4. Ничәнче елларда к.Булатова Казан дәүләт университетында белем ала?<br>а) **1965-1969**<br>б) 1966-1970<br>в) 1964-1968<br>5. Ничәнче елда аңа «Укытучы-методист» дигән мактаулы исем бирелә?<br>а) **1978 нче елда**<br>б) 1977 нче елда<br>в) 1979 нче елда<br>70 елларда шагыйрә берничә җыентык чыгара. Аның бер бәйләм |

| | |
|---|---|
| | шигырьләре рус теленә тәрҗемә ителә. Бүгенгесе көндә ул 40 артык китап авторы. Ул укытучы буларак бик күп шигырьләре аның балаларга багышланган. Менә мин сезгә К.Булатованың 1-2 шигырен сезгә укып китәм.<br>Әзерләнгән укучылар К.Булатованың шигырьләрен укып китәләр.<br>Менә, укучылар, аның «Үзеннән үзе туа җыр» җыентыгында аның шигырьләренә язылган көйләре дә ноталар белән күрсәтелгән. Кызыксынсагыз, укып китә аласыз, җырларын өйрәнә аласыз, җырлый аласыз.<br>Укучылар, быел 18 мартта К.Булатованың 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтәбез. |
| III этап. Рефлексия | 1. Рефлексив кабатлау.<br>Укучыларга бүгенге дәрестә нинди яңа белемнәр алулары турында сораулар бирелә.<br>- Дәрескә куелган уку мәсьәләсе чишелдеме?<br>- Нәрсәләр белдегез?<br>2. Бәяләү. Укучыларга, дәрестә катнашканнарын бәяләп, билгеләр куела.<br>3. Өй эше: К.Булатова иҗаты турында сөйләргә әзерләнеп килү. |

## Укытучы, шагыйрь, фронтовик
(Сыйныф сәгате)

Яхина Алсу Халит кызы, Шәйдуллина Гөлназ Ришат кызы,
Ләшәү-Тамак төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

Максат: Фронтовик шагыйрь Ә. Габидинең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру; шигырь укуга мәхәббәт тәрбияләү, укучыларның зиһеннәрен тикшерү; туган як язучылары иҗаты белән кызыксыну хисе тәрбияләү.

Җиһазлау: ноутбук, интерактив такта (проектор), шагыйрь китапларыннан күргәзмә, шигырьләреннән китапчык, табышмаклары.

Сыйныф сәгате барышы:

Укучыларда уңай халәт тудыру. Уку мәсьәләсен кую.

**1слайд. Шигырь тексты экранда.** (Шигырьне укытучы укый)

**Илемә**

Дүрт ел буе канлы яуда йөрдем,
Күпме атакага кермәдем.
Явыз дошман көчле булса да,
Җиңүдән мин өмет өзмәдем.
Егылсам да алга егылдым мин,
Алга бару иде теләгем,
Фашист дигән канлы хәшәрәттән
Арчыдык без илнең күкрәген.
Без – җиңүче,
Триумфатор булып,
Берлин урамыннан атлыйбыз,
Яраланса безнең яралана,
Җиңелүне белми халкыбыз.
Рейхстагка әләм элмәсәм дә,
Диварына яздым атымны,
Туган илем, җиңеп үтәдем мин
Сиңа биргән изге антымны.

Сүзлек өстендә эш: триумфатор, рейхстаг, дивар сүзләренең мәгънәләрен аңлату.
Экраннан укыту.

**Төркемнәрдә тикшерү өчен сораулар:**

- Шигырь сезгә ошадымы?

- Шигырьдәге төп тема нәрсә турында?(Сугыш турында)

- Шагыйрь сугышта үлеп калганмы, туган илгә җиңеп кайтканмы? (Җиңеп кайткан)

- Сугышта катнашкан кешеләрне кемнәр диләр? (фронтовиклар)

- Шигырь кайсы фронтовик-шагыйрьнеке дип уйлыйсыз? (Укытучы тарафыннан юнәлеш бирелә: районыбызда яшәп иҗат иткән, Бөек Ватан сугышында катнашкан, тумышы белән Чукмарлы авылыннан).

Бүгенге класс сәгатебез Чукмарлы авылында туып-үскән, яшәгән һәм шунда иҗат иткән балалар шагыйре Әзһәр Габидигә багышлана.

**2 слайд. Экранда шагыйрь портреты.**

Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин (Әзһәр Габиди) 1926 елның 26 сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында туа. Җидееллык мәктәпне авылда тәмамлап, Сарман урта мәктәбендә 10 нчы классны тәмамларга да өлгерми, 18 яше дә тулмас борын сугышка китә. Фронтта каты яраланып, госпитальләрдә ята. 1947 елда туган авылына җиңүче булып кайта.

Сугыштан соң, Минзәлә педагогия училищесын тәмамлагач, Ләке, Морбаш, Чукмарлы сигезьеллык мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Мәктәптә укытканда шигырьләр яза һәм китаплар бастырып чыгара.

Аңа «Халык мәгарифе отличнигы», «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Шагыйрь башлыча балалар әдәбиятына хезмәт итә. Аңа әдәбияттагы казанышлары өчен Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия бирелә. Әзһәр Габиди – 13 китап авторы.

**3 слайд. Экранда – шагыйрь китаплары.**

Шагыйрь 74 яшендә каты авырудан вафат була, аның гәүдәсе Чукмарлы зиратына күмелә.

**Шагыйрь иҗатына күзәтү ясау.**

**Төркемнәрдә эш.** (1төркемнән 2 укучы укый)

**«Бакчада» шигыре** (Шигырьне рольләргә бүлеп уку)

Нәрсәдән син болай тәмле
Әйт әле, җир җиләге?
Мин югында әллә әни
Сиңа шикәр сибәме?
Матур бул дип, әллә абый
Сине алга манамы?
Хуш исле бул дип, апа да
Хушбуйларын ягамы?
– Син яраткан тәмле балны
Мин, дустым, җирдән алам,
Ә битемне, алсулатып,
Кояш нурына манам.

2 нче төркем укучыларына сорау:

Шигырьдә сүз нәрсә турында бара? ( Җир-анабыз биргән җиләк-җимешләр һәм кеше белән табигать бергәлеге турында)

2 нче төркем укучыларыннан 1укучы «**Һавалы чеби» шигырен** укый.

Һаваланып йөргән булды
Чуар тавык чебие,
Аны тотып алып киткән
Күршебезнең песие.
Песи тырнагына эләккәч
Үкенгәндер, бичара,
Мондый чакта ялгыз чеби
Кыла ала ни чара?!
Төркемеңнән аерылу –
Һәлакәт башы икән,
Аерылганны аю түгел

Песи дә ашый икән.

1 нче төркемгә сорау: Шагыйрь балаларга нәрсә әйтергә тели?

**Җавап:** Шигырьдәге чеби кебек һаваланып, масаеп йөрмәскә, иптәшләреңнән аерылмаска кирәк, ди.

**«Булсаң зирәк - әйт тизрәк!» уены.**

**4 слайд. Экранда “Тапкырҗан табышмаклары» «Югалган кояш» китапларының тышлыклары.**

Шагыйрьнең «Тапкырҗан табышмаклары» һәм «Югалган кояш» китапларында балаларның зиһеннәрен сынау, уйлау-фикерләү сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән байтак табышмаклары урын алган.

Музыка уйнаганда балалар бииләр, көй туктауга, парлашып басалар һәм укытучыдан уң якта торучы балалар 1 табышмакны алып укыйлар, икенче парлары җавап бирергә тиеш.

**Табышмаклар** (Җаваплары экранда күренә)

1.Анда диңгезләр җәелгән,
Тик йөзми балыклары.
Күп-күп шәһәрләр төзелгән,
Күренми халыклары. *(Карта)*
2.Сырлы минем күлмәгем,
Моңлы минем телләрем;
Моңым белән кешеләрнең
Күтәрәм күңелләрен. *(Гармун)*
3.Кырга барам сырт белән,
Баргач йөрим түш белән.
Түшем белән эшләмим,
Эшләп йөрим теш белән. *(Тырма)*
4.Мөгеземнән тоталар да
Аяк белән йөртәләр,
Миңа утырып, кешеләр
Юлны җитез үтәләр. *(Велосипед)*
5.Утырабыз урманнарда,
Ап-ак эшләпә киеп,
Киптерә дә, кыздыра да
Кешеләр безне җыеп. *(Гөмбә)*
6.Исемем «кар»лы,«боз»лы,
Тик үзем салкын түгел,
Мине ашаган чагында
Хушланып китә күңел. *(Карбыз)*

Укытучы сораулары:

- Без кайсы шагыйрь турында сөйләштек?
- Әзһәр Габиди кемнәр өчен язган?
- Ни өчен без бу шагыйрь иҗатына тукталдык?

**Йомгаклау өлеше.**

**Укытучы:** Утны, суны кичкән фронтовик-шагыйрьне, районлашыбызны искә алуыбыз юкка түгел. Быел без Әзһәр Габидинең 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтәбез. Шайгыйрьнең татар әдәбиятын үстерүгә керткән өлеше зур, шуңа күрә без аны онытырга тиеш түгел.

*Класс сәгатен Ә.Габиди сүзләренә язылган җыр белән тәмамлыйсы килә. (Җыр тыңлату. Әзһәр Габиди сүзләре, Сәит Абдуллин көе «Үпкәләп калган шикелле»).*

## Күңелле шигырьләр иртәсе

(6 -7 яшьлек балалар өчен балалар иртәсе өчен сценарий)

Дәүләтҗанова Регина Дамир кызы, Җәлил бистәсенең
6 нчы санлы балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

Максат: Балаларны Клара Булатованың шигырьләре белән таныштыру. Әлмәт шәһәрендә яшәүче якташ шагыйрә иҗатына кызыксынучанлык тәрбияләү. Иҗади сәләтне үстерү өчен мәйдан ачу, этәргеч бирү.
Җиһазлау: Клара Булатова китапларыннан күргәзмә, шигырьләре буенча ясалган рәсемнәр, җыр язмалары, презентация.
Залда өйнең эчке бизәлеше. Балалар урындыкларга кереп утыралар.
**Тәрбияче:** Кадерле дусларыбыз. Без сезнең белән «Күңелле шигырьләр» иртәсенә җыелдык.
**Тәрбияче**. «Безнең як» шигырен сөйли

Ипигә ягып ашарлык
Кара җир безне якта.
Шәл итеп иңгә ябарлык
Яшеллек безнең якта.
Алтынга алыштыргысыз
Хәзинә безнең якта.

Тәрбияче. Кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар! Без бүген шушы шигырь юллары авторы, Р.Төхфәтуллин исемендәге бүләк иясе, «Җиде тубал бәхет», «Үзеннән-үзе җыр туа», «Марс китабы», «Гел кояшка карап» китаплары авторы, Әлмәт шәһәрендә яшәп иҗат итүче шагыйрә Булатова Клара Гариф кызына багышланган «Күңелле шигырьләр иртәсе» исемле күнел ачу кичәсенә җыелдык.

*(Салмак көй астында залга әби килеп керә. Кулында кызыл төенчек).*

**Әби:** Улым, алтыным, әйдә тизрәк җыен, абыеңнарга коймаклар илтеп кайтыйк.
**Малай Нияз:** И әбекәй, әбекәем. Безгә бит кунаклар килде, без бәйрәм ясарга булдык.
**Әби:** И-и-и. Күрмичә дә торам икән. Исәнмесез, балакайларым.
**Балакайлар:** Исәнме, әбекәй.
**Малай Нияз:** Әбием, әйдә син дә безнең белән бәйрәм ит.
**Әби:** Рәхмәт, балам. Мин алайса йон эрли торырмын, сезне тыңлап утырырмын.

*(Әби йон эрләргә утыра).*

**Азалия:** «Әниемнең кызы юк бит» (Клара Булатова)
**Артур:** «Курка димәгез әле»(Клара Булатова)
**Нәфисә:** «Безнең як» (Клара Булатова)
Алып баручы: Әйдәгез, бер уйнап алыйк: «Чума үрдәк, чума каз».
**Нияз:** «Март башында» (Клара Булатова)
**Ильяс:** «Рәхәт чак» (Клара Булатова)
**Муса:** «Сөенеч» (Клара Булатова)
**Әби:** Булдырасыз, балалар.
Мин бер табышмак әйтәм,
Әткәм-әнкәмнән калган.
Әгәр җавабын тапсагыз,
Уеннар итәр дәвам.
«Кечкенә генә бер әби
Йөгерә-йөгерә йон җыяр».
**Балалар:** Орчык!
**Әби:** Бик дөрес. Һәрбер эшнең җае бар, ботканың да мае бар, диләр. Әйдәгез түгәрәк ясап утырыгыз. Бу орчыкның ике ягы бар: бер яктан – җеп эрләү, икенче яктан – күңел ачу. Орчык башы кемгә карап туктаса, шул кеше берәр һөнәр күрсәтә. Әйләндерәм орчыкны.
Ниязга карап туктады.
Нияз бер мәкаль әйтсен (бака булып сикерсен, кәҗә булып кычкырсын, әтәч булып кычкырсын, табышмакка җавап бирсен).
Булдырдыгыз, балалар
**Булат:** «Урманда» (Клара Булатова)
**Ш. Ильназ:** «Шундый көн» (Клара Булатова)
**Н. Ильназ: «**Зоопаркта» (Клара Булатова)
**Диләрә: «**Ярышу» (Клара Булатова)
**Әби:** И балакайларым, булдырдыгыз. Әйдәгез хәзер сезнең белән бер уен уйнап алыйк.

**«Наза әби» уены.**

*(Бүлмәгә елап Белмәмеш керә).*

**Белмәмеш:** Мин бернәрсә дә өйрәнә алмыйм, булдыра алмыйм, мәктәпкә бармыйм.
**Тәрбияче:** Борчылма, Белмәмеш, без сиңа булышырбыз, бездә кал, балалар белән уйнарсың, өйрәнерсең, шигырьләрен тыңларсың.
**Самат:** «Әллә кайсын тыңлыйсы?» (Клара Булатова)
**Камил:** «Эшләп ашый» (Клара Булатова)
**Зәринә:** «Иптәш» (Клара Булатова)
**Әмир:** «Унга кадәр» (Клара Булатова).
**Салават:** «Кызык инде бу бабай» (Клара Булатова)
**Белмәмеш:** Искә төште, искә төште.
Мин бит бер уен беләм.
Уеннар бит, балалар,
Витамин кебек алар.
Күңелләрне үстерә,
Йөрәкләргә көч бирә.
Әйдәгез «Зәңгәр чәчәк» уенын уйнап алыйк.
**Тәрбияче:** Белмәмеш, Клара Булатованың күңел серләре сыйган шигырьләрен безнең тәрбиячеләр дә үз иттеләр.
**Регина Дамировна:** «Сиңа кайтам» шигыреннән өзек.
**Дания Фатиховна:** «Әниемә»

**«Куш кулым» уены**

**Тәрбияче:** Булдырдылар. Белмәмеш, сиңа бездә ошадымы? Безнең балалар нинди матур шигырьләр сөйләделәр, уеннар уйнадылар.
**Белмәмеш:** Рәхмәт, балалар, сез бик акыллы, булган икәнсез.Тырышкан табар – ташка кадак кагар. Сез миңа бик булыштыгыз. Хәзер инде мәктәпкә ашыгыйм. Сау булыгыз.
**Әби:** Ә мин сезне, балакайларым, тәмле коймаклар белән сыйлыйм. Акыллы, тәртипле, тәмле телле булып үсегез, әти-әниегезгә игелекле балалар булыгыз.
**Балалар:** Рәхмәт, әбекәй, авырма, сызланма.

Күңел ачу кичәсе Клара Булатова сүзләренә язылган җырны тыңлау белән тәмамлана.

## Мин зур үскәч

(Балалар белән әңгәмә)

Талибуллина Сәбилә Әнәс кызы,
Җәлил бистәсенең 6 нчы санлы балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

**ТӘРБИЯЧЕ**:
Табигать, сиңа үпкәләп
Йөргәнмен бер дә юкка.
Мин монда үзем ышандым
Үземнең матурлыкка.
Һәр таңнан торып җыр язу
Керде көн гадәтемә.
Мин монда үзем ышандым
Үземнең сәләтемә.
Һәр көнең шатлык китерә
Иртәдән торуыма.
Мин монда үзем ышандым
Бәхетле булуыма.

Клара Булатова үзенең укучысын үзенчәлекле тавышы, матур сүз осталыгы көчле булуы белән әсир итә. Тирәндә яткан күренешләрне җиңел итеп, гади итеп әйтә белүе – бу

әдибәнең табигый халәте. Шигырь юллары аның, ташны ярып чыккан чишмә кебек, үзләреннән-үзләре туалар. Клара апа үзе дә: «Минем тормыш һәм иҗат юлым икесе бергә башлангандыр, дип беләм: шигырьләрне үзем белә башлаганнан бирле чыгарам, нәкъ шулай «чыгарам» ә «язам» түгел», – дип аңлата.

Шагыйрәнең иҗаты һәм тормыш юлы турында

1936 елның 18 мартында Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туган. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа күрә Кларага бала чактан ук әти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күчеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. Ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә, өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый.

Ләке мәктәбен ул «бик яхшы» билгеләренә генә тәмамлый. «Чыгарылыш җыелышында» мәктәпнең яңа директоры Митрофанов абый: «Отличниклар өчәр метр күлмәклекләр белән бүләкләнә», дип сөендерә. Ләкин «әллә акчасы булмый, әллә оныта...». Клара апа ул вакыйганы болай дип искә ала: «Сарманга килеп, 8 нче класста укый башлагач, мин тоттым да аңа шигъри калыпта ачык хат яздым:

...Биргән вәгъдә үтәлергә тиеш!
Без әле дә өмет итәбез.
Июль, авгус, сентябрь үтте –
Октябрьдә бүләк көтәбез!

Шуннан бирле мине «безнең шагыйрәбез» дип атадылар һәм шуннан бирле мин шигырьләр язам»,– дип яза ул.

Урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыга. Шул ук елның көзеннән К. Булатова хезмәт юлын башлый: Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч классларда балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәттәге көнкүреш комбинатында кассир, «Төзүчеләр» клубында оештыручы була. 1962-1965 елларда ул яңадан мәктәптә – Әлмәт районының Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта. Аның иҗаты укытучылык эше белән үрелеп бара: актив рәвештә Әлмәттәге әдәби түгәрәккә йөри, аның иҗат җимешләре газета-журнал битләрендә дөнья күрә. Бераздан аерым шигъри цикллары «Үсү юлы», «Идел» альманахы, «Яшь үрентеләр» кебек күмәк җыентыкларда басыла.

1965-1969 елларда К. Булатова В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам иттерә. Шагыйрәнең исеме тәнкыйтьтә җылы сүз белән телгә алына башлый. 1967 елда «Язлар алда» исемле мөстәкыйль китабы – лирик шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Клара Булатованың укытучы гаиләсендә тәрбияләнеп, ата-ана һөнәренә тугры булып, гомерен шуңа багышлавы, иҗатында укытучы шәхесен олылавы бер дә гаҗәп түгел. Укытучылык аңа кан белән бирелгән, ана сөте белән күчкән, гаилә тәрбиясе белән сеңгән.

Университетны тәмамлаганнан соң К. Булатова Әлмәт районының Яна Кәшер урта мәктәбенә тел әдәбият укытучысы булып килә. 10 ел татар гимназиясендә укыта. 8 елдан артык Әлмәт муниципаль институтында булачак татар теле һәм әдәбияты укытучыларына әдәбият дәресләре бирә. Олуг шагыйрәбезгә хөрмәт йөзеннән, бу уку йорты тарафыннан Клара Булатова исемендәге премия булдырылды.

Тәҗрибәле укытучы буларак, 1978 елда аңа РСФСР Мәгариф министрлыгы тарафыннан «Укытучы-методист» дигән мактаулы исем бирелә. Татар җанлы, тынгы белмәс Клара апабыз 10 еллап «Нур» телерадиокомпанисендә журналист булып эшли. Аның алып барган «Җомга» тапшыруын татар яшьләре зур кызыксыну белән көтеп алалар.

Укытучылык хезмәте – Клара ханым иҗатының буеннан-буена сузылган үзәк темаларның берсе. Яшьлек оптимизмы, тормышны ихлас ярату, аның киләчәгенә тирән ышану, самими кичерешләр... авторның шушы үз профессиясе-белгечлеге үзенчәлекләрен тасвирлаган шигъри юлларыннан да ташып-ургылып тора. Шагыйрә бу яраткан хезмәтенә бәхетенең югары бер чагылышы итеп карый, бәхет төшенчәсен дә үз һөнәрендә, укытучы хезмәтендә күрә. Хәтта укытучының йокы калдырып, үз дәресенә төннәр буе әзерләнеп утыруы да аның өчен олы бер бәхет.

«Укытучы апаң йокламаган» исемле шигырь укыла.

**АЛИНА**:

Абажурлы зәңгәр лампасыннан
Өстәлеңә якты сибелгән.
Дәфтәрләр дә инде тикшерелгән,
Планнар да күптән төзелгән.
Ә ул әле һаман йокламаган,
Төн йокысын нәрсә алган соң?
Сәбәбе син, Азат,
Син дә бүген
Язма эштә «5»ле алгансың.

**АЗАТ:**

Табельдәге синең «3»леләрне
Алыштырсын өчен шул билге...
Ничә төне ялсыз үтте аның,
Йөрәк көче күпме түгелде.
Күзләрендә бүген борчу түгел,
Шатлык яна синең җиңүдән.
Алда ята дәрес планнары,
Дәфтәрләре янда өелгән...
Син йоклыйсың, татлы төшләр күреп,
Әнкәң җәйгән җылы урыныңда.
Укытучы апаң, керфек какмый,
Һаман уйлый синең турында.

**-** Нишләтәсең, укытучының көндәлек тормышы һәм еллык эш режимы да турыдан-туры шушы мәктәп-балалар дөньясы белән бәйле. Мәктәпнең үз чәчү вакыты һәм үз «урак өсте» бар. Мәктәп үз әхлакый кысалары, үз фәлсәфи үлчәмнәре белән яши.

– К.Булатова турында яшьтәшләре, каләмдәшләре горурланып язалар. Атлас Гафиятов менә нәрсә дип яза: «Безнең Балачак, Яшьлек иленә мәңге тугрылык саклап калган кешеләребез бар. К.Булатова-Ана, Педагог һәм Шагыйрә». Балалар күңеленә мәрхәмәтлелек, туган телгә карата мәхәббәт орлыкларын кечкенәдән үк салып куйган ул, Клара апабыз.

Клара Булатова иҗаты барлык яшьтәге кешеләргә: әби-бабайлар, әти-әниләр, яшьләр, үсмерләр өчен дә аңлаешлы. Менә аның кечкенә балалар өчен язган «Марс китабы», «Әллә кайсын тыңласы», «Курка димәгез әле», «Камилә – тәти кыз» дигән китаплары чыкты. Бай сурәтләү чаралары аша бу китаплар балаларны яхшылыкка өнди, дөньяны ныграк танып белергә өйрәтә. Клара апаның шигъриятен мин фирүзә сулы тирән диңгез белән чагыштырыр идем. Чумган саен чумасы, киңрәк колачлыйсы килә. Шигырьләре табигый, иркен укыла ки, якын кешең белән үзара сөйләшеп, гәп корып утырган төсле тоела. Чыгышымны шагыйрәнең «Мин зур үскәч» әсәре белән тәмамлыйсы килә

**КАМИЛӘ:**

«Мин зур үскәч...», – дибез бала чакта.
Үзе генә шушы сүз безгә
Әллә ниләр инде вәгъдә итә,
Әллә ниләр килер көнебездә.
«Мин зур үскәч», – дибез, шушы сүзгә
Хыялларны теркәп сөйлибез.
Сәгать, көнне, айны, елны куып,
Зур үсүне көтеп йөрибез.
Ә зур үскәч, тик бер кайтыр өчен
Гамьсез үткән якты көннәргә,
Бу зурлыкның барын бирер идек,
Бирер идек әллә ниләр дә.

**Шушы яктан, шушы туфрактан без**

(башлангыч сыйныф укучылары өчен әдәби кичә)

Сибгатуллина Алсу Мансур кызы, Әлки төп гомуми белем мәктәбе,
Буа районы

**Максат:** Шагыйрә Клара Булатова белән таныштыру, шагыйрәнең иҗатына күзәтү ясау, укучыларда Клара Булатова иҗаты белән кызыксынучанлык, китап укырга омтылыш тәрбияләү.
**Җиһазлау**: Клара Булатова турында презентация, Клара Булатова китапларыннан күргәзмә, җыр язмалары, «Җомга» тапшыруыннан өзек видеоязмасы

**Кичә барышы**.

(«Шушы яктан, шушы туфрактан без» җыры яңгырый)

Укучылар кичәбезне бердә юкка җыр белән башламадым. Бу җырны ишеткәнегез бармы? ( Исеме, авторы әйтеп үтелә)

Бүген без Әлмәт шәһәреннән Г.Тукай, Р.Төхфәтуллин, С.Сәләйманова премияләре лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, халык шагыйрәсе Клара Булатова белән танышачакбыз. (Экранда портреты)

Шагыйрә Клара Гариф кызы Булатова 1936 елның 18 мартында Татарстанның Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. 1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче сыйныфка укырга керә, өченче сыйныфтан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, ә урта белемне 1954 елда Сарман урта мәктәбендә алып чыга. 7 сыйныфны тәмамлап, 8 нче сыйныфны башка мәктәпкә барып укыйсы чыгарылыш елында шундый бер хәл була. Мәктәпне бишкә тәмамлаган укучыларга мәктәп директоры күлмәклек ситсы бүләк итәргә вәгъдә итә. Әмма вәгъдәсен үтәми. «Бишле» билгеләренә генә тәмамлаган кыз әлеге бүләкне көтеп-көтеп тә ала алмагач, бу турыда шигырь язып, район газетасына җибәрә. Шигырьдә чыгарылыш сыйныфларның җыелышы, тәбрикләү сүзләре, мәктәп директорының вәгъдәсе, аның үтәлмәве турында бәян ителә. Бу шигырь менә шулай тәмамлана: …Ләкин юкка гына шатланганбыз,
Бүләк күлмәкләрне кимәдек.
Озын җәйләр үтте, көзләр җитте,
Бүләкнең төсен дә күрмәдек.
Биргән вәгъдә берәр үтәлер дип,
Без һаман да өмет итәбез.
Июль, август, сентябрьләр үтте,
Октябрьгә бүләк көтәбез.

«Бу шигырь басылып чыккач, миңа 7 сум 20 тиен гонорар килде. Ул вакытта бу зур акча иде. Мин аңа күлмәклек, сугыштан соңгы бала — сеңлемә ташкурчак, әле җитмәсә, карамель дә алдым», – ди.

Клара Булатова исеме шигърият яратучыларга күптәннән таныш. Үз гомерендә 20дән артык китап чыгарган, 50дән артык шигыре көйгә салынган шагыйрә ул бүген. Укучылар игътибарына К.Булатова чыгарган җыентыкларны санап китәсе килә. (Экраннарда китаплары)

«Язлар алда» 1967
«Һәрвакыт янымда» 1969
«Җәйләр җитсә» 1972
«Һәр язның үз җыры» 1978
«Гел кояшка карап» 1981
«Марс китабы» 1982
«Печән өсте» 1986
«Хәтер тәрәзәләре» 1989
«Миләш кагы» 1991
«Курка димәгез әле»
«Якты сагыш» 1995
«Хәтер көзгесе» 1995
«Әллә кайсын тыңласы» 1996
«Шушы яктан, шушы туфрактан без» 2000

«Үзеннән-үзе туа җыр» 2002
«Әрнү» 2003
«Яшел каләм» 2003

Ә хәзер шагыйрәбезнең шигырьләрен тыңлап алыйк. (Шигырьне алдан бирелгән укучылар укый: «Туган җиремә», «Сарманыма»).

Шагыйрәнең эти-әнисенә атап язган шигырьләре дә игътибарга лаек. (Экраннарда эти-әнисенен фотосурәте). Клара Булатова – укытучы шагыйрә. Аның этисе дә, әнисе дә укытучылар булганнар. Хәзер без сезгә К.Булатованың «Ана шатлыгы» дигән шигырен тәкъдим итәбез. (Алдан бирелә укучы укый. Шигырь «Ана шатлыгы»)

Укытучылык хезмәте – Клара Булатова иҗатының буеннан-буена сузылган үзәк темаларның берсе. Ул 40 елдан артык балаларга белем бирә, укучыларында матурлыкны, туган телебезгә мәхәббәт тәрбияли. Укытучы күңеле һәрчак балачакта. Шагыйрәнең шигырьләре – моның ачык мисалы. (Шигырь тыңлап китү: «Укытучы апаң йокламаган»)

Клара Булатова шигырьләре хис-кичерешләргә бик бай, алардан моң агыла. Шуның өчен дә шагыйрә матур-матур җырлар авторы буларак танылды. Җырларда туган як, мәхәббәт темасы үзәк урынны алып тора. Филология фәннәре кандидаты Рәфкать Шагиев: «Төбәгебезнең асылын ачкан «Шушы яктан, шушы туфрактан без» дигән әсәр өчен генә дә аны җырчы-шагыйрә атап булыр иде, ә аның андый әсәрләре санап бетергесез», – ди. (Җыр тәкъдим итү, тыңлау)

Нефтьчеләр башкаласында яшәүчеләр өчен Клара ханым Булатова дистә еллар дәвамында милләтебезгә генә хас иң яхшы сыйфатларны эченә сыйдырган күркәм, тыйнак, тирән эчтәлекле «Җомга» тапшыруының сценарий авторы да. (Видеоязма карап үтү).

Клара Булатова шигырьләрне тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә. 1959 елда Геннадий Паушкинның берничә шигырен татарчага тәрҗемә итә. Аны К.Табул дип куя. К.Табул – псевдоним.

Укучылар Клара Булатова эшчәнлеген, әсәрләрен санап, сөйләп бетергесез. Алар белән тагын да күбрәк өлкән сыйныфларда танышырсыз.

Кичәнең соңгы өлешен **блиц тур** итеп үткәреп төгәллибез. Һәр кеше үзенә балл җыя. Кемнең кичә барышында бик нык игътибарлы булуын тикшерәбез. Сорауларга җавапны кул күтәреп бирәбез.

- Клара Булатованың туган төбәге?
- Әти-әнисе кемнәр булганнар?
- Ничә китабы дөнья күрә?
- Ничә әсәрен беләсез?
- Беренче китабы кайчан чыккан һәм исеме ничек?
- Нинди әсәрләрен истә калдырдыгыз?
- Аның нинди җырларын атый аласыз?
- Балалар өчен язылган әсәрләрен атагыз?
- Нинди псевдоним астында шигырьләр тәрҗемә иткән?
- Нинди тапшыруның сценарий авторы?

Бик әйбәт, укучылар. (Балларны санап нәтиҗә ясала). Афәрин.

## Шушы яктан, шушы туфрактан...

(Сыйныфтан тыш чара өчен сценарий)

Шиһабиева Фирая Әхмәтхан кызы, Олы Арташ төп
гомумбелем бирү мәктәбе укытучысы, Саба районы

**Максат:** ХХ гасырның икенче яртысында татар әдәбиятында үзенчәлекле урын яулаган шагыйрәләребезнең берсе – Клара Булатованың тормышын һәм иҗатын укучыларга җиткерү, татар поэзиясенең горурлыгы икәнен укучыларга төшендереп, иҗатына карата олылау, хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре уяту, балаларда сәнгатьле сөйләм, сәхнәдә үзеңне тоту күнекмәләре үстерү

Кичә шагыйрәнең тормыш юлы һәм чагылдырган презентация белән алып барыла. Китапларыннан, шигырьләренә ясалган иллюстрацияләрдән күргәзмә куела

**Кичәнең барышы**

Әкрен генә «Шушы яктан, шушы туфрактан...» көе ишетелә. (К.Булатова шигыре, Р. Нәгыймов музыкасы)

**1 алып баручы.** Исәнмесез, кадерле укучылар, укытучылар, килгән кунаклар! «Шушы яктан, шушы туфрактан...» дип аталган кичәбезне башларга рөхсәт итегез. Буген ул татар әдәбиятында үзенчәлекле урын яулаган шагыйрәләребезнең берсе – Клара Булатованың 85 яшьлек олуг юбилеена багышлана

**2 алып баручы.** «Сезнең кайчан да булса тезелешеп очкан кошларны күзәткәнегез, алар биеклегенә күтәрелергә тырышканыгыз юкмы? Әгәр булса, сез – шигъри җанлы кеше. Зәңгәр күктән тезелешеп очкан кошлар каурыйлары белән һавада шигырь язып калдыралар. Ә инде кошлар телен аңлый белүче илаһи затлар шул шигырьләрне эләктереп алалар да дәфтәр битләренә төшерәләр. Аларны шагыйрьләр дип атыйлар», – дип язган Фәнис абый Яруллин. Мин бу сүзләрне очраклы рәвештә генә алмадым, чөнки шагыйрә Клара Булатованың шигырьләре белән танышу ирексездән нииндидер илаһи бер сихри дөньяга алып кереп китә.

**1 нче алып баручы:** Клара Булатова кебек гаҗәеп сәләткә ия тагын берәр талант иясе бармы икән? Ул үзе риваять булырлык искиткеч зат. Шагыйрьлеге тумыштан, зиһене шаккатырлык, сәгатьләр буе шигырь сөйләп, теләсә кемне авызына каратып тора ала. Авыр елларда – сугыш чорларында – 1943 елда беренче шигырьләре туа. Бу вакытта шагыйрәгә 7 яшь була. 1951 елдан бирле газета-журналларда басылып яши, 1970 елдан Язучылар союзы әгъзасы. 40тан артык китап бастырып чыгарды. Аллаһыбыз аңа соклангыч аһәң биргән, аны тыңлап сихерләнәсең, рухи ләззәт аласың.

**1 нче укучы**

Анын кебек шагыйрә
Кайчан туар бу җиргә?
Андый талантлар булса да,
Булалардыр бер... меңгә.
Иҗаты хөрмәткә лаек
Иле, халкы алдында
Акылы, зыялылыгы
Күзләрендә чагыла.
Башкаларга охшамаган.
Ул үзенә бертөрле.
Кабатланмас, бары бер Ул
Күктәге Ай шикелле.
(Ай кебек сихри, серле.)

2 алып баручы: Гүзәл Татар Карамалысы авылы. Татарстанның сихри бер почмагы. Клара апаның гомер җебе шушы җирләрдән башлана. Сарман районына кергән Татар Карамалысы авылында туа ул. Бүгенге көндә танылган шагыйрә, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы. Шулай ук шагыйрә – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Рафаил Төхфәтуллин һәм Саҗидә Сөләйманова премиясе иясе.

**1 алып баручы:** Беләсеңме, дустым? Клара апа гади шагыйрь генә түгел шул! Ул бик күп балаларга белем биргән укытучы да.

*1 нче укучы «Укытучы апаң йокламаган...» шигырен сөйли.*

Абажурлы зәңгәр лампасыннан
Өстәлеңә якты сибелгән.
Дәфтәрләр дә инде тикшерелгән,
Планнар да күптән төзелгән.
Ә ул әле һаман йокламаган,
Төн йокысын нәрсә алган соң?
Сәбәбе син, Азат,
Син дә бүген
Язма эштә «5»ле алгансың.

Табельдәге синең «3»леләрне
Алыштырсын өчен шул билге...
Ничә төне ялсыз үтте аның,
Йөрәк көче күпме түгелде.
Күзләрендә бүген борчу түгел,
Шатлык яна синең җиңүдән.
Алда ята дәрес планнары,
Дәфтәрләре янда өелгән...
Син йоклыйсың, татлы төшләр күреп,
Әнкәң җәйгән җылы урынында.
Укытучы апаң, керфек какмый,
Һаман уйлый синең турында.
2 нче алып баручы:
Мөгаллимнәр гаиләсендә туып үскән кыз әтисе Гариф һәм әнисе Халисә һөнәренә тугрылыклы калып, гомере буе Әлмәт районы авыл мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Укытучы буларак кына түгел, шагыйрә буларак та балаларда туган җиргә, хезмәт кешесенә мәхәббәт тәрбияләүче, аларның күңеленә игелек орлыклары салучы чын педагог ул

*9 нчы сыйныф укучылары* ***«Хәтерлим мин әле бүгенгедәй»*** *җырын башкаралар.*

**1 нче алып баручы:** Клара Булатова үзенең «Әнием» шигырендә, әнисенә үзенең беренче укытучысы – хәреф таныргa, язарга өйрәтүче буларак мөрәҗәгать итә. Укытучы-әни образына югары бәя бирә.

Син башлап хәреф өйрәттең,
Әлифен, яңалифен.
Тукайлы, җырлы, шигырьле
Дөньяга әйдәп керттең.
Сөйләгән әсәрләреңне
Күңелдән әле беләм.
Мавыктым гомер буена
Мин синең фәнең белән, – дип шагыйрә үзенең тормыш юлында әнисе өйрәткән әсәрләр аша туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләвен, әнисе-остаз үрнәгендә үзе дә татар теле һәм әдәбияты укытучысы һөнәрен сайлавын ассызыклый:
Тукайлы, җырлы дәрескә
Кергәндә иртән килеп.
Һәрвакыт әни остазым
Ияреп керә кебек.

**2 нче алып баручы:** Укытучылык хезмәте – Клара ханымның иҗатының буеннан-буена сузылган үзәк темаларның берсе. Яшьлек оптимизмы, тормышны ихлас ярату, аның киләчәгенә тирән ышану, самими кичерешләр... авторның шушы үз профессиясе-белгечлеге үзенчәлекләрен тасвирлаган шигъри юлларыннан да ташып-ургылып тора. Шагыйрә бу яраткан хезмәтенә бәхетенең югары бер чагылышы итеп карый, бәхет төшенчәсен дә үз һөнәрендә, укытучы хезмәтендә күрә.

**1 нче алып баручы:** «Беренче укытучыма» дигән шигырендә дә Клара Гариф кызы Укытучы образын, аның мактаулы һәм авыр хезмәтен сурәтли. Беренче укытучысының беркайчан да исеннән чыгармавын ассызыклый. Укытучысын якын итеп, үз итеп беренче апам дип атый: «*Беренче укытучым»*

Минем исемдә:
Җитәкләшеп бергә килдек
Белем көнендә.
Минем өчен Сез булдыгыз
Беренче апам.
Янәшәгездән атлыймын,
Юк, очып барам.
Мин сезнең бер укучыгыз,
Тәүге сыйныфта.

Сез – беренче укытучым
Минем тормышта.
Күпме еллар узды,
Хәзер... үзем мөгаллим,
Тик шул мизгелне һаман да
Күңелемдә саклый.

**2 нче алып баручы:** Клара Булатованың «Гел кояшка карап» дигән китабында «Укытучы көндәлеге» дип аталган аерым бүлек бар. Бу бүлеккә кергән шигырьләр авторның үз хезмәт тәҗрибәсеннән чыгып язылган. «Тагын башлана уку еллары», «Беренче сентябрь», «Төшләреңдә күреп», «Котлау сүзе», «Алтынчы класстагылар» һ.б. шундый шигырьләре укытучы һәм укучы мөнәсәбәтләренә, укытучының уй-хисләренә, үз хезмәтләрен чын күңелдән сөюләренә багышланган.

*3 нче укучы*«Алтынчы класстагылар» шигырен сөйли.

Алтынчылар...
Унөч, ундүрт яшьтә,
Киләчәктә сездән кем чыгар?
Инженерлар, врач һәм, әлбәттә,
Космонавтлар чыгар, җырчылар.
Үсеп килгән галәм хуҗалары!
Килер көнгә шулар барасы.
Ә бүгенгә менә минем алда
Орбиталар – парта арасы.
Сорау тулы күзләр сиңа карый:
Бер сораумы, йөзме, меңәүме?
«Белмим» сүзен, куй, юк, әйтә күрмә!
Кичермиләр алар белмәүне.
Син белергә тиеш, укытучы,
Ни сорыйлар – шуны белергә.
Укытучы булу – бу шундый эш, –
Белгәнеңне кирәк бирергә.
Белгәнеңне бирә белү кирәк:
Ундүрт яшьлек үсмер хыялын
Чикләмәсен парта орбитасы,
Алтынчының класс дивары.
Бу яшь буын юллар юнәлешен
Синнән ала кая барырга?!
Алар гомере, заман килере өчен
Җаваплы син тормыш алдында.
Унөч-ундүрт яшьтә...
Алтынчылар...
Тик башлана гына юлыгыз.
Киләчәктә сездән кемнәр чыгар?..
Кем булса да –
Кеше булыгыз!

Җыр: «Онытма» (З.Сафиуллин көе)

**1 нче алып баручы:** К.Булатова төрле буын кешеләре өчен шигырьләр яза. Шигырьләренең безгә багышланганы да, урта сыйныф укучылары укырлыклары да, яшьләр өчен хисләнеп укый торганнары да, өлкән буын кешеләрен кызыксындырган-нары да бар. Чөнки шагыйрә үзе дә безнең кебек мәктәптә укыган, укытучы булып эшләгән, малай үстергән, ә хәзерге көндә кадерле әби дә.

***«Кырга чыктым, юлга чыктым»*** *( Р. Нәгыймов көе) җыры башкарыла*

**2 нче алып баручы:** Шагыйрә әсәрләре безне тормышта киң күңелле, миһербан-шәфкатьле, ихтирамлы һәм игътибарлы булырга өйрәтә, ялгыш адымнардан сакланып гомер җебен

сүткәндә һәркайсыбызга камил акыл белән фикер йөртеп игелекле эшләргә чакыручы өлге булып тора.
*4 нче укучы: «Үсмер чагым» шигырен укый.*
*5 нче укучы: «Яшьлек чагым» шигырен укый.*
*6 нчы укучы: «Шәкертләремә» шигырен укый.*
*7 нче укучы: «Әби сүзе» шигырен укый.*
*8 нче укучы: «Өйрәтегез яратырга» шигырен укый.*
**1 нче алып баручы:** Халык күңелен яулап алган шагыйрьләр дә табигатьнең гүзәл, сирәк бүләкләре бит. Якты, саф чишмә кебек бәреп чыккан талант иясе ул – Клара Булатова. Заман үзгәрсә дә үзгәрми торган, күңел кылларын тибрәтерлек шигырьләр язучы, үз тавышы булган шагыйрә бит ул.

Туган көнең белән яз китердең,
Кояш нурын сиптең җир өстенә
Син үзең дә язлар кебек көләч,
Яз китергән чәчкә төсендә.

**2 нче алып баручы:**
Сез җирдәге һәрнәрсәгә гашыйк
Гашыйк таңга,зәңгәр кичләргә.
Сез яшисез шундый матурлыкка
Тагын матур бер яшь өстәргә.
Сез булганга без дә бик бәхетле,
Сезнең белән якты көнебез.
Безнең белән сез дә бәхетледер,
Сезнең белән без дә бәхетле.
«Шушы яктан, шушы туфрактан без» җыры башкарыла (К.Булатова шигыре, Р.Нәгыймов музыкасы)
Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Китә калсак үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр елап озата.
Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Читтә йөрсәк — шуңа күрәдер,
Чишмә чыңлап, өянкеләр елап,
Таллар җырлап төшкә керәдер
Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Шушы җиргә дәшеп кайтырга,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр зурлап чакыра.
Хөрмәтле, мөхтәрәм кунаклар, сөекле укытучыларыбыз, кадерле укучылар, Клара Булатованың 85 яшьлек олуг юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичәбез тәмам. Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

## Шушы яктан, шушы туфрактан без
(әдәби кичә)

Шәмсетдинова А. Ш., Җәлил бистәсенең «Әкият» балалар бакчасының тәрбиячесе, Сарман районы

**Максат:** шагыйрә Клара Булатова турында сөйләшү, шагыйрәнең иҗатына күзәтү ясау, балаларда Клара Булатова иҗаты белән кызыксынучанлык, китап укырга омтылыш тәрбияләү.
**Җиһазлау:** Клара Булатова китапларыннан күргәзмә, шагыйрә турында презентация, җыр язмалары.

**Кичә барышы.**

**Алып баручы:** Хәерле көн, кадерле балалар! Бүген без Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның халык шагыйрәсе, Габдулла Тукай, Рафаил Төхфәтуллин, Саҗидә Сөләйманова исемендәге бүләк иясе Клара апа Булатова турында сөйләшербез.

**Алып баручы:** Клара Булатова кебек гаҗәеп сәләткә ия тагын берәр талант иясе бармы икән? Ул үзе риваять булырлык искиткеч зат. Шагыйрьлеге тумыштан, зиһене шаккатырлык, сәгатьләр буе шигырь сөйләп, теләсә кемне авызына каратып тора ала. Авыр елларда – сугыш чорларында – 1943 елда беренче шигырьләре туа. Бу вакытта шагыйрәгә 7 яшь була. 1951 елдан бирле газета, журналларда басылып яши, 1970 елдан Язучылар союзы члены. 38 китап бастырып чыгарды. Ярабббыбыз аңа соклагыч аһәң биргән, аны тыңлап сихерләнәсең, рухи ләззәт аласың.

Әйдәгез хәзер Клара Булатованың шигырьләрен тыңлап үтик: ( балалар шигырь сөйли )

1нче бала: «Сабый чагым» шигырен укый.

(Ф. Вәлиәхмәтов башкаруында «Мәшәкать» җырының 1 куплеты яңгырый).

2 нче бала: «Булмый алмашып» шигырен укый.

3 нче бала: «Үсмер чагым» шигырен укый.

4 нче бала: «Яшьлек чагым» шигырен укый.

5 нче бала: «Әби сүзе» шигырен укый.

6 нчы бала: «Өйрәтегез яратырга» шигырен укый.

**Алып баручы:** Хәзер музыкаль пауза ясап алыйк әле. Вафина Р.М. башкаруында «Күз тимәсен балама» җыры яңгырый.

**Алып баручы:** Халык күңелен яулап алган шагыйрьләр дә табигатьнең гүзәл, сирәк бүләкләре бит. Якты, саф чишмә кебек бәреп чыккан талант иясе ул – Клара Булатова. Заман үзгәрсә дә үзгәрми торган, күңел кылларын тибрәтерлек шигырьләр язучы, үз тавышы булган шагыйрә бит ул. Клара Булатова безнең Колшәрип авылын якын, үз итеп, Колшәрибем дип, аның хуш исле гөлләренә гашыйк булып, үзенең иң ягымлы шигырьләрен иҗат итте. Ләкин Колшәрип авылы да җавапсыз калмады, иң тәмле, саф сулы чишмәбезгә Клара Булатова исеме бирелде.

Хәзер кичәбезне дәвам итеп, Клара Булатова иҗатын, тормыш юлын презентациядан карап үтик.

Ә хәзер зурлар төркеме **«Шушы яктан, шушы туфрактан без»** исемле җыр башкаралар (К.Булатова сүзләре, Р.Нәгыймов музыкасы).

**Алып баручы: «Шушы яктан, шушы туфрактан без»** дигән әдәби-музыкаль кичәбез тәмам, игътибарыгыз өчен бик зур рәхмәт.

## Калган эшкә кар ява

(Әдәби уку дәресенә технологик карта)

Таҗетдинова Рүзилә Илгизәр кызы, Сарман гимназиясе укытучысы,
Сарман районы

**ШУУГ:** иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру.

**ТБУУГ**: кирәкле информацияне китаптан таба белү.

**РУУГ:** эшчәнлегеңне контрольгә алу

**КУУГ**: күршең белән хезмәттәшлек итү.

**Предметара бәйләнеш:** әйләнә-тирә дөнья, сәнгать.

**Кулланылган материал**: Э.Габидинен «Күлдәвектә кояш көлә» жыентыгы; ноутбук .

**Җиһазлау:**Э.Габидинен портреты һәм презентация, китап күргәзмәсе,буяу карандашлары

**Эш төрләре**: фронталь, индивидуаль, парларда.

| | | **Укытучы** | **Һәр этапның белем бирүче үстерешле биремнәре** | |
|---|---|---|---|---|
| **1 этап. Оештыру өлеше.** | Укытучыга игътибар | Инструктаж | **1 этап.Оештыру**. | Коммуника- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| - укучыларны уку эшчәнлегенә мотивлаштыру. Көтелгән нәтиҗә:дәрескә уңай психологик халәт булдыру. | итү. Дәрестә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре формалаштыру. | үткәрү, балаларны эшкә әзерләү. | Талгын гына музыка уйный.<br>- Хәерле көн, укучылар. Кәефләрегез ничек? Карагыз әле, бүген көн нинди матур! Әйдәгез, бер-беребезгә уңышлар телик һәм дәресебезне башлап җибәрик. | тив эшчәнлек.<br><br>Шәхси эшчәнлек. |
| **2 этап. Белемнәрне актуальләштеру.**<br><br>- алдагы дәрестә алган белемнәрне искә төшерү. | Ә.Габидинен «Күлдәвектә кояш көлә» җыентыгын-нан шигырьләр уку | Фронталь эш оештыру. | **2 этап. Белемнәрне актуальләштеру**.<br>Бирелгән өй эшен тикшерик. Укучылар җыентыктагы шигырьләрне укыйлар. | Регулятив (укучылар тарафыннан белгән күнекмәләр-не үзара бәйләү). |
| **3 этап. Яңа материал өйрәнү.**<br><br>- укучыларның дәрес темасын үзләре формалаштыра алу. | Дәреснең темасын формалаштыру. Мәкальне анлату.<br><br>Сорауга җавап бирүдә катнашу.<br><br>Информация белән эшләү.<br><br>Проблемалы сорауны чишүдә катнашу, шәхси фикерен формалаштыру, аны дәлилләү.<br><br>Сорауларга җавап бирүдә катнашу.<br><br>Нәтиҗә ясыйлар. Укытучы соравына җавап бирәләр. | Укучыларны активлаштыру.<br><br>Фронталь эш оештыру.<br><br>Язучы Ә.Габидинең иҗаты белән таныштыру. Укытучы презентацияне кү рсәтеп бара. | - Укучылар, мин сезгә мәкаль әйтеп китәм. Уйлагыз, нәрсә турында булыр, аңлатып карарсыз әле?<br>«Калган эшкә кар ява"<br>(Балаларның җаваплары)<br><br>-Димәк, без бүген нәрсә турында сөйләшәбез? (Хезмәт турында)<br><br>Телефонга СМС килә. Шуның белән танышу:<br>-Укучылар, кемдер безнең белән элемтәгә керергә тели.<br>Исәнмесез, балалар! Мин Әзһәр Габиди абыегызның оныгы булам. Минем бабамның әсәрләрен яратып укуыгыз өчен рәхмәт.<br><br>- Сез язучының нинди шигырьләре белән таныш?<br>(Балаларнын җаваплары)<br>- Ничек уйлыйсыз, болар нинди шигырьләр?<br><br>- Әлбәттә, болар балалар өчен язылган шигырьләре | Танып-белү эшчәнлеге.<br><br>Коммуникатив эшчәнлек<br><br>Шәхес буларак эшчәнлек.<br><br>Коммуника-тив эшчәнлек. |
| **3 этап. Бала нинди авырлыклар белән очраша?**<br><br>- хыял, фантазия төшенчәләрнең бер-берсеннән аерырга өйрәтү. | Шәхси фикерен формалаштыру, аны дәлилләү.<br><br>Практик эзләнү эшендә катнашу.<br><br>Парларда эшләү. Үзара ярдәмләшеп эшләү.<br><br>Кара-каршы тикшеру. | Биремнең үтәлешенә контроль булдыру.<br><br>Практик эзләнү<br><br>Биремнең үтәлешенә контроль булдыру. | -Ә хәзер үзебезне әкият дөньясында дип хис итик. Күзләрегезне йомыгыз.<br><br>-Я, нишләдегез? Нинди могҗизаларга тап булдыгыз?<br><br>Нәтиҗә ясау.<br><br>Укучылар җавапларының дөреслеген тикшерәләр.<br><br>**Физминутка.** | Шәхес буларак эшчәнлек.<br><br>Коммуника-тив эшчәнлек<br><br>Танып-белү эшчәнлеге.<br><br>Коммуника-тив |

| **Физминутка** | **Физминутка** | | | эшчәнлек |
|---|---|---|---|---|
| **4 этап. Яңа материалны аңлату.**<br><br>- уку күнекмәләрен үстерү өстендә эшләүне формалаштыру,<br>таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен истә калдыру. | Текст белән танышу.<br><br>Гөжләп уку.<br>Абзацлап кычкырып уку<br><br>Сорау-җавап бирүдә катнашу. | Текстның эчтәлеген укучыларга дөрес дикция, аһәң белән җиткерү.<br><br>Сүзлек өстендә эш (Экранда) Биремнең үтәлешенә контроль булдыру<br><br>Үз фикерләрен әйтүгә ирешү, нәтиҗә ясарга өйрәтү. | Ә.Габидинен «Калган эшкә кар ява» әкиятенең беренче бүлеге белән танышу.<br><br>-Ялкавыннан ачы көлеп,<br>Салмакҗан диеп йөргэн;<br>юлларын ничек анлыйсыз?<br>-Аягы төкле булган,-<br>Аның үткән эзләрендә<br>Калыккан яшел юрган;<br>юлларын ничек аңлыйсыз?<br>(Балаларнын җаваплары)<br><br>Хикәяне укып фикер алышу. | Танып-белү эшчәнлекне<br><br>формалашты ру.<br><br>Шәхси универсаль. укыту гамәл ләрен формалашты ру. |
| **5 этап. Белемнәрне беренчел ныгыту.**<br><br>- ишетеп,күреп тану күнекмәләрен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү. | Текст белән танышу.<br><br>Текстны «гөжләп» укып чыгу.<br>Сәнгатьле уку<br><br>Сорау-җавап бирүдә катнашу. | Укучыларны активлаштыру. | Ә.Габидинен «Калган эшкә кар ява» әкиятенең икенче бүлеге белән танышу.<br><br>-Өлгер белән Салмакҗан нәрсә белән аерылганнар? Ни өчен шулай уйлыйсыз? (Жаваплар, фикер алышу)<br><br>1бүлеккә беренче рәт, 2 бүлеккә икенче рәт сораулар төзи. (Бала-лар күмәк эшлиләр, нәтиҗә ясыйлар) | Танып-белү эшчәнлекне формалашты ру<br><br>Коммуникати в эшчән-лек |
| **6 этап. Белемнәрне гомумиләштерү.**<br><br>- алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту һәм гомумиләштерү. | Шәхси фикерен формалаштыру, аны дәлилләү. | Укучыларны активлаштыру. | Магнитофоннан Ә.Габидинең «Калган эшкә кар ява» әкиятен тулысынча тыңлап, рәсем ясау. | Коммуника-тив эшчән-лек<br><br>Шәхес буларак эшчән-лек |
| **7 этап.Нәтиҗә һәм бәяләү. Рефлекция.**<br><br>- дәрестә эшләнгән эшләргә нәтиҗә ясау. | Мин нәрсә белдем?<br>Ничек бәяләдем? | Үз фикерләрен әйтүгә ирешү, нәтиҗә ясарга өйрәтү. | Бүгенге дәрестә сез нәрсәләр белдегез? (аралашу, нәтиҗә чыгару)<br>Өй эше.<br>1) Әкиятнең өченче, дуртенче бүлекләрен укырга.<br>2) Теләге булган балаларга үзләренә хезмәт турында әкият уйлап яып килергә. | Коммуникати в эшчән-лек<br><br>Шәхес буларак эшчәнлек. Регулятив эшчәнлек. |

## Туган як жырчысы

Римма Җиһангирова, Яңа Нәдер урта гомуми белем бирү мәктәбе,
Әлмәт районы

Җиһазлау: К.Булатова китапларыннан күргәзмә, экран, «К.Булатова тормышта һәм иҗатта»» дип исемләнгән слайд.

**Кичәнең барышы**

«Шушы яктан, шушы туфрактан» җыры башкарыла.

А.б. Укытучы, шагыйрә, әни, әби. Укучылар, бүген безнең бәйрәмебез шушы исемнәрне берләштерүче авылдашыбыз, Әлмәтебезнең йөзек кашы булып торучы апабыз Клара Булатовага багышлана. Клара апа үз гомерендә 20дән артык китап бастырган. «Мәйдан» журналының соңгы номерында шагыйрәнең дөнья күргән китапларының тулы исемлеген күрәсез, ә аларның кайберләре сезнең алдыгызда. Клара апагызның 50дән артык шигыре көйгә салынган, шуларның берсен әле яңа гына иптәшегез башкаруында тыңлап үттегез, тагын берничәсен кичә барышында ишетерсез.

Язучы өчен иң куанычлысы, укучылар, китапларының шушы киштәләрдә генә калмыйча, сезнең кулларга килеп керүе, аның шигырьләре белән кызыксынуыгыз. К.Булатова төрле буын кешеләре өчен шигырьләр яза. Шигырьләренең сезгә багышланганы да, урта сыйныф укучылары укырлыклары да, яшьләр өчен хисләнеп укый торганнары да, безнең буын кешеләрен кызыксындырганнары да бар. Чөнки шагыйрә үзе дә сезнең кебек мәктәптә укыган, укытучы булып эшләгән, малай үстергән, ә хәзерге көндә кадерле әби дә.

Без бүген сезнең белән бик бәхетлеләр, чөнки шагыйрә Клара Булатова бүген безнең мәктәптә кунакта.. Клара апа, рәхим итеп, Сезнең сәхнәбез түреннән урын алуыгызны сорыйбыз.

Сүзне озын-озакка сузмыйча, аның үзенә бирик әле, сезне кызыксындырган сорауларга җавапны шагыйрәнең үзеннән ишетик. Рәхим итегез, Клара апа. (К. Булатова сөйләгәннән соң, сүз укучыларга бирелә).

А.б. Чынлап та, табигате белән тыйнак, гади күңелле, җор телле шагыйрә әдәбиятыбызда җуелмаслык тирән эз калдырырлык итеп туган халкына һәм туган теленә хезмәт итә. Ә хәзер укучыларыбыз башкаруында К. Булатованың шигырьләрен һәм аның сүзләренә язылган җырларны тыңлап үтәрбез. Авылда туып үскәнгәме, аның шигырьләренең күбесе авыл табигатен, аның хезмәт сөючән халкын, булдыклы хатын-кызларын чагылдыра. Ә инде шигырьләренең көйгә салынып җырлануы шагыйрә өчен икеләтә бәхеттер. К.Булатованың шигырьләре хис-кичерешләргә бик бай, алардан гүя моң сирпелә. Шуның өчен шагыйрә матур-матур җырлар язучысы буларак танылды. Җырларда туган як, мәхәббәт темасы үзәк урыннарны алып тора. Аның 2002 елны 76 җырын туплаган «Үзеннән-үзе туа җыр» китабы дөнья күрде.

Сезнең игътибарга Марс Макаров көйгә салган «Кыңгырау чәчәкләре» җырын тәкъдим итәбез.

«Ач күзеңне, улым», «Безнең балачактан бер яңа ел», «Әни – егет» шигырьләре, «Су буенда кыяк үлән» (К.Булатова сүзләре, Р. Андреев көе) җыры башкарыла.

А.б. К. Булатованы шагыйрә буларак кына телгә алсак, аның тормышының зур бер өлешенә күз йому булыр иде. К.Булатова – мөгаллимә-шагыйрә. Бу ике образ бер-берсен тулыландыра. Ул гомере буенча үзенең укытучылык һөнәренә тугрылыклы булып калды. Клара апа бүген дә балалар белән элемтәсен өзми, туган телебезне, мәдәниятебезне саклап калуда, аны үстерүдә армый-талмый хезмәт итә. Укытучы хезмәте турындагы берничә шигырен тыңлап үтик.

«Укытучы бәхете «, «Алтынчы класстагылар» шигырьләре яңгырый.

К.Булатова сүзләре, Идрис Хисамов көе «Якын дустың барын онытма» җыры башкарыла.

А.б. Сез түземсезлек белән көткән минутлар якынлашты. Укучылар, ә хәзер Клара апагызга үзегезне кызыксындырган сорауларны бирә аласыз. (Сорауларга җавап бирелгәннән соң, укучылар үзләре ятлаган «Ак каен», «Инәйнең яраннары», «Юк, кайтмасын ул чор», «Синә кайтам» шигырьләрен сәнгатьле итеп укып күрсәтәләр.)

А.б. Үз фикерен укучыларга җиткерү өчен сүзләрнең тирән мәгънәлесен, тыгыз фикерлесен эзли. К. Булатова – тормышны чын дәрәҗәсендә аңлап, туган ягына, табигатенә мәхәббәтен эчке кичерешләре аша чагылдыручы лирик шагыйрь.

К.Булатова сүзләренә Мирсәет Хөснуллин көенә язылган «Кырга чыктым, юлга чыктым» җыры башкарыла.

А.б. Бүген безнең мәктәбебездә эшләп лаеклы ялга чыккан хөрмәтле укытучыларыбыз кунакта. Алар Клара апа белән чордашлар гына түгел, ә аларны укытучы булу да берләштерә. Бәлки аларның да безгә әйтер сүзләре бардыр. Укучылар, Клара апагызның шигырьләре сездә тагын да зур кызыксыну уяткандыр. Шундый аз вакытта гына аның иҗаты

белән танышу мөмкин түгел. Бу яраткан шагыйрәбезнең иҗатын өйрәнүне дәресләрдә дәвам итәрбез.

Клара апа! Сезнең иҗатыгыз алдында баш иябез.

Туганда ук шагыйрь булып
Туу Сезгә насыйп булгандыр.
Гомер буе мөгаллимлек кылып
Чәчегезгә кырау кунганмы?
Тик шулайда һаман яшьсез әле
Олыгаю хисе кермәгән.
Әйтерсең лә борчу-мәшәкатьләр
Сезнең кырда бер дә йөрмәгән.

Кәефсез, күңелсез чакларымда К.Булатова шигырьләрен кулыма алам. Уйландыра, моңландыра, сөендерә, көлдерә торган әсәрләр күңелдә җылы хисләр уята, күңелне күтәрә, рухландыра. Йөз яшә, Клара апа! Иҗат чишмәгез мәңге сүрелмәсен, тынмасын.

**Хәниф Хәйруллин тормыш юлы һәм иҗатына күзәтү**

(9-10 нчы сыйныф укучылары өчен сыйныфтан тыш чара – дәрес-сәяхәт)

Хәбибуллина Миләүшә Хәмит кызы, Җәлил беренче мәктәбе
китапханәчесе, Сарман районы

**Максат:** Хәниф Хәйруллинның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру; укучыларның фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү; укучыларда Хәниф Хәйруллин иҗаты белән кызыксыну уяту; укучыларда олыларга, туган җиргә хөрмәт тудыру, татулыкны күрә белергә өйрәтү.

**Җиһазлау:** Хәниф Хәйруллинның портреты, фоторәсемнәре, китаплары, сәяхәт картасы, компьютер, шагыйрьнең иҗатын, тормыш юлын чагылдырган электрон презентация.

**Китапханәче.** Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн! Туган як.Туган туфрак.Туган төбәк. Бу сүзләр өлкән яшьтәге кешеләр өчен генә түгел, һәр сабый бала өчен дә газиз һәм кадерле булырга тиеш. Туган якның табигате, аңа бәйле кызыклы фактлар, аның тарихы, халыкның көнкүреше, гореф-гадәтләре, милли йолалары балаларга белем һәм тәрбия бирүдә зур роль уйный.

Милли төбәк компоненты халык һәм милләт үзенчәлеген, мәдәниятен һәм рухи дөньясын, телен һәм тарихын, табигый-географик мохитен, традицияләрен чагылдырган укыту материалын берләштерә. Укучы үзе яши торган төбәкнең табигатен, аның үзенчәлекләрен, халкын, традицияләрен, мәдәниятен, тарихын яхшы белергә тиеш. Һәр төбәкнең үзенең күренекле шәхесләре була. Алар турында горурланып сөйләнелә, кылган гамәлләре хөрмәтләнә, яшь буынны да шулар үрнәгендә тәрбияләү максаты куела. Укучыларны туган якта туып-үскән каләм әһелләренең иҗаты белән таныштырмый торып, әдәбияттан алар үзләштерергә тиешле белемне тулысынча алалар дип әйтеп булмый. Без Сарман төбәгенең шифалы туфрагында туып-үскән якташ әдипләребез, шагыйрьләребез, галимнәребез, сәнгать кешеләре белән хаклы рәвештә горурланабыз. Без бүген шул горурлыгыбыз булган шәхесләребезнең берсе – Хәниф ага Хәйруллин белән танышырбыз. Аның тормыш юлы һәм иҗаты буенча сәяхәт итәрбез, әсәрләрендә күтәрелгән проблемаларны карарбыз. Дәрес ахырында нәтиҗәләр чыгарырбыз. Сәяхәткә кузгалдык, укучылар.

**II.Төп өлеш.** ***1нче тукталыш «Хәниф Хәйруллинның тормыш юлы һәм иҗаты»*** дип атала. Бу тукталышта без язучының тормыш юлын, иҗатын карап үтәрбез. (Алдан әзерләнеп килгән укучыга сүз бирелә, фоторәсемнәр күрсәтелә). 1нче слайд. Шагыйрьнең биографиясен чагылдырган фоторәсемнәр.

Хәниф Гыйздулла улы Хәйруллин 1931 елның 12 сентябрендә Татарстан АССРның Сарман районы Сарман авылында туган. 1950 елда туган авылындагы урта мәктәпне

тәмамлаганнан соң, бер ел шул ук районның Азалак авылында мәктәптә укыта. 1951-1956 елларда Казанда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый, аннары утыз елга якын район газеталарында (Сарманда – «Югары уңыш өчен», «Ленинчы», Буада – «Байрак») хатлар бүлеге мөдире, редактор һәм җаваплы секретарь вазифаларын башкара. Ул – 1958 елдан КПСС члены. Хәниф Хәйруллин әдәбиятка журналистикадан килгән язучы. Аның беренче очерклары, колхоз авылы тормышының төрле мәсьәләләренә багышланган публицистик мәкаләләре көндәлек матбугатта илленче елларда күренә башлый. Озак вакытлар авылда яшәү һәм газета редакциясендә эшләү аңа колхоз тормышы, хезмәт кешеләре, аларның эш-гамәлләре, борчу-шатлыклары, уй-хыяллары белән якыннан танышырга мөмкинлек бирә. Бер үк вакытта ул туган төбәгенең революцион үткәнен, гражданнар сугышы һәм колхозлашу чорында анда барган социаль үзгәрешләрне, катлаулы вакыйгаларны җентекләп өйрәнә. Шул конкрет тормыш материалы нигезендә Х. Хәйруллин алтмышынчы еллар дәвамында документаль повесть характерындагы «Бакыр базының серләре», «Алмаз ихтыяр», «Канлы еллар, авыр еллар», «Хуҗида үскән батыр» кебек очеркларын һәм балалар өчен «Тылсымлы таяк табышы» исемле маҗаралы повестен иҗат итә. Соңыннан алар аерым җыентыкларга тупланып Татарстан китап нәшриятында басылып чыга. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Сарманда яшәп иҗат итә һәм 1998 елда вафат була.

2 нче слайд. Хәниф Хәйруллинның китап җыентыкларының фоторәсемнәре. Кыскача белешмә.

***2 нче тукталыш «Китапханә» дип атала. Китапханәче:*** Укучылар, сез Хәниф Хәйруллинның нинди китаплары белән таныш? (Фикерләр тыңланыла).

- Аның бик күп әсәрләре төрле журналларда дөнья күрә. Мәсәлән, балалар өчен язылган «Бакыр базының серләре» беренче булып «Ялкын» журналында басыла. Аннары Кәүҗияк авылы укытучысы белән бергә язган «Кәүҗияк каһарманнары» әсәре вакытлы матбугатта күренә һәм соңыннан «Канатлы юллар, авыр еллар» исеме белән аерым китап булып дөнья күрә.

Шулай ук «Алмаз ихтыяр», «Канлы еллар», авыр еллар һәм балалар өчен «Тылсымлы таяк табышы» исемле маҗаралы повестен иҗат итә. Соңыннан алар, аерым җыентыкларга тупланып, Татарстан китап нәшриятында басылып чыга. Хәзерге авыл тормышын сурәтләгән, кызыклы уйланылган образлары, катлаулы конфликтлары булган «Канатлар талмасын» повестеның беренче басмасы Татарстан китап нәшриятында 1974 елда басыла. Әйтелеп бетмәгән фразасын үз эченә алган «Картлык ... кемгә шатлык» әсәре дә бик күпләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Әлеге повесть 1976 елда Казанда Татарстан китап нәшриятында басыла. Шулай ук «Хуҗида үскән батыр», «Канатлар талмасын», «Фатыйманың бәхете» исемле китаплары да халык тарафыннан яратылып кабул ителә. Ә без Хәниф Хәйруллинны язучы итеп таныткан әсәрләре – «Канатлар талмасын», «Картлык ... кемгә шатлык» повестьларын карап үтәрбез.

Алдагы ***өченче тукталышыбыз – «Хәниф Хәйруллинның иҗат җимешләре» дип аталыр.*** Әлеге тукталышта алда әйтеп үтелгән ике әсәренә тукталырбыз, нинди мәсьәләләр күтәрелгән шуларны карарбыз. Иң беренче «Канатлар талмасын» әсәреннән башларбыз. ***(Алдан әзерләнгән укучыларга сүз бирелә.)***

***Китапханәче:*** Әйе, әлеге әсәрне укучылар да, әдәби тәнкыйть тә авторның җитди уңышы итеп кабул итәләр. Әсәрдә автор алтмышынчы еллар колхоз тормышында барган үзгәрешләр, яңалыклар җирлегендә хуҗалык белән идарә итү, җитәкче кешенең (колхоз председателенең) хезмәтне яңача оештырудагы роле кебек актуаль мәсьәләләрне күтәрә, бу өлкәдәге уңышлы яклар белән бергә, кимчелекле моментларны күрсәтә һәм заман өчен характерлы булган каршылыкларны ача. Әлеге әсәр 1971 елда язылып, башта «Казан утлары»нда, соңыннан аерым китап булып басылып чыга. Әлеге әсәрдә тыңлап үткәнчә, хәзерге авыл тормышы сурәтләнелә. Автор үз алдына зур һәм катлаулы бурыч – безнең җәмгыять кешесенең тормышка мөнәсәбәтен, заман сулышын тоеп, киләчәкне ачык күреп яшәргә тиешлеген күрсәтү бурычын куйган. Повесть бүгенге көн таләпләре һәм кирәкләре белән генә яшәүче, үз тынычлыгын гына саклап, югары оешмалар алдында теләсә нинди

чаралар белән дә яхшы булып күренергә тырышучыларны фаш итә. Нинди геройлар алар, укучылар, кайсыгыз әйтә?(Укучыларга сүз бирелә.)

- Райкомның беренче секретаре Рәшит Галиевич Шәйлиев. Ул «1Май»колхозыннан, хөкүмәткә үз нормативын үтәүгә карамастан, һаман иген таләп итә. Колхоз председателе Рамай Вильданов белән каршылыкка килә һәм аңа каршы каты шелтә белдерергә тәгъдим ясый, ләкин бюро членнары риза булмыйлар. Чөнки Рамай Ибраһимович эшен җиренә җиткереп башкара. Ә Рәшит Галиевичны әсәр ахырында паралич суга һәм ул больницада үлә.

***Китапханәче:*** Әйе, автор әсәрендә колхозларны ныгыту өчен бөтен көчләрен аямыйча көрәшүче намуслы кешеләрне зур горурлык белән сурәтли. Андый геройларга безнең алдан әйтеп үткән колхоз рәисе Рамай Ибраһимович, Яхъя Курмашов, Габделхак Шакирович һәм башкаларны күрсәтергә була. Укучылар, укыганда тагын нәрсәләргә игътибар иттегез? ***Укучыларга сүз бирелә.***

- Әсәр кызыксыну белән укыла. Теле җиңел һәм образлы. Күп мәкальләр һәм әйтемнәр кулланылган. Мәсәлән: уку – инә белән кое казу; азыклы ат арымас; кунак булсаң, тыйнак бул; иске авызга яңа аш – моның ачык мисаллары. Шулай ук гади телдә язылуы әсәрне тагын да бизи, минемчә.

***Китапханәче:*** Әлеге әсәр буенча әзерләнеп килгән һәм сыйныфташларына тулысынча аңлаткан укучыларга бик зур рәхмәтемне белдерәм. Х. Хәйруллинның шулай ук авыл тормышына багышланган һәм кеше характерын әхлак нормалары күзлегеннән, фәлсәфи-психологик планда ачарга тырышкан «Картлык... кемгә шатлык?» повестена күчәбез.

***(Алдан әзерләнгән укучыларга сүз бирелә).***

Әсәрнең төп герое ике карт – Хәсән белән Асыл. Зур булмаган әлеге әсәрдә ике зур язмыш, болар өстенә колхозның бүгенге проблемалары, кешеләре дә бар. Әлеге повесть баскан, яшәгән җирләре бүгенге көн булып, үткән тормышны искә алу рәвешендә корылган. Мәсәлән, 1917 елның март аенда патша төшерелгән дигән хәбәр таралгач, Асыл карт һәм авыл ир-атларының Кәүҗияккә барып Габдрахман байның малларын юк итүләре, шуның өчен кулга алынулары моңа мисал булып тора. Асыл карт малларны юк итеп кенә калмый, Башкортстанга барып байны эзләп таба һәм авылда калдырып качкан байлыкларының кайда икәнлеген әйттерә. Байлык салынган сандыкның ачкычын алып кабат авылга кайта һәм яшьтән бергә үскән Хәсән янына бара. Дусты аңа кечкенәдән үк ярдәм итә. Асыл картның әтисе япон сугышында үлеп калгач, дустына өеннән ашарга ташый, бик каты кыйналган дустын аякка бастыруда да читтә калмый. Хәсән белән сандыкны эзләп табып хөкүмәткә тапшыралар. Анда 820 мең сум акча була. Әсәр ахырында Асыл карт үлә һәм бу вакытта да кабергә ташны Хәсән куя. Повесть төрле мәкаль-әйтемнәргә бай. Мәсәлән: тимерне кызуында сугалар; эт печән ашамас, сарыкка ирек бирмәс; бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карый мисаллары моның ачык мисалы.

***Китапханәче:*** Әлеге әсәрләрне әзерләүче укучыларга бик зур рәхмәт. Безнең алдагы тукталыш «Язучы турында башка язучыларның фикерләре» дип атала. ***4нче тукталыш – «Язучы турында башка әдипләрнең фикерләре»*** *(Укучыларга сүз бирелә).*

1 нче укучы: Х.Хәйруллин үткен сюжет линиясе төзи белә, әдәби сурәтләү чараларын оста куллана. Әсәрләрендә персонажларның эчке дөньясын, уй-хисләрен тирәнтен ачу өчен ул әдәби телнең тирән катламнарына төшә, татар теленең бай мирасын файдалана. Бу яктан алганда, ул мәшһүр әдипләр, тел осталары Ф.Хөсни, Г.Бәширов, Г. Ибраһимов, М.Мәһдиев традицияләрен дәвам итә... Әлеге юлларны Равил Гыймадиев белдергән.

2 нче укучы: Фоат Садриев түбәндәге сүзләрне язган: «Х.Хәйруллин гомере буе мактануны яратмады.Тарихи очерклары белән республиканы шаулаткан каләм иясе булуына карамастан, һич тә һаваланмады, редакциядә үзен барыбыз белән дә бертигез тотты».

3 нче укучы: «Х.Хәйруллин җитәкчелегендәге район газетасы кызыклы язылган материалларга бай, эчтәлеге һәм теле бик аңлаешлы була иде. Ул газетада басылган тәнкыйть материаллары буенча тиешле чара күрү яки эшне төзәтү буенча, аның нәтиҗәлелегенә ирешү өчен бөтен көчен, вакытын бирә иде». Әлеге истәлекле юлларны дусты Вилдан Рамазанов җиткергән.

***Китапханәче:*** сәяхәтебезне дәвам итәбез.
**5 нче тукталыш – «Мактау тактасы»** (укучылар Х.Хәйруллинга бирелгән мактаулы исемнәрне атыйлар).
***Китапханәче:*** 1981 нче елда ТАССР атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелә.
**III.Йомгаклау.**

Шулай итеп, укучылар, без бүген Сарман районы горурлыгы булган шәхесләребезнең берсе – Хәниф ага Хәйруллинның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштык, әсәрләренә күзәтү ясадык. Куандыра, уйландыра автор үзенең укучысын. Сөйкемле булырга, күбрәк белергә, үзенең уңай геройларыннан – үрнәк, тискәре геройларыннан нәфрәт алырга өнди Хәниф ага Хәйруллин. Игътибарыгыз өчен, эчтәлекле чыгышларыгыз өчен, укучылар, рәхмәтемне белдерәм.

## Сарман сандугачы якташыбыз шагыйрә Клара Булатованың иҗатына багышланган кичә

Талибуллина Гөлнара Рәис кызы, Җәлил бистәсенең
«Аленушка» балалар бакчасы тәрбияче, Сарман районы

**Максат:** К.Булатованың тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге белән таныштыруны дәвам итү. Балаларның бәйләнешле, сәнгатьле сөйләм телен, хәтер сәләтен үстерү; тапкырлык, зирәклек күнекмәләрен тикшерү. К.Булатова әсәрләре аша балаларда туган җиргә мәхәббәт, аның белән горурлану хисе; дуслык, татулык сыйфатлары тәрбияләү. Шагыйрәнең иҗатына кызыксыну, ихтирам уяту.

**Кичә барышы**

*Музыка залы бәйрәмчә бизәлә. Өстәлдә чәчәкләр. К.Булатова портреты, әсәрләреннән өзекләр эпиграф итеп стенага язып эленә. Китапларыннан күргәзмә оештырыла. Бер якта шагыйрьнең әсәрләре буенча балалар ясаган рәсемнәр күргәзмәсе. Проекторда – презентация «Клара Булатова иҗаты»*

**Алып баручы:** Хәерле көн, кадерле балалар һәм хөрмәтле кунаклар!

Сарман ягы – зәңгәр таулар,
Мәңге сайрар сандугачлар.
Яшел болын, алтын кырлар,
Җанга җылы биргән җырлар.
Сарман ягы – аяз күкләр,
Алсу таңнар, озын юллар.
Бәхет кенә, шатлык кына
Алып килсен туар еллар.

Бу кичәбезне якташыбыз, Сарман авылы шагыйре, тарихчы, академик һәм дә татар халкының атаклы улы Дамир абый Гарифуллин язган «Күкрәп яшә, Сарманым» дип аталган шигырь белән башладык.

Матур, мул, ямьле безнең Сарман яклары. Нефте, игеннәре, кырлары, эшчән халкы белән дан тота ул. Безнең районда бик күп сәләтле, талантлы кешеләр туган: язучылар, җырчылар, шагыйрьләр, композиторлар. Без алар турында күп беләбез, алар белән горурланабыз. Ә бүген мин сезне тагын бер якташыбыз – шагыйрә Клара апа Булатова иҗаты белән таныштырырга телим.

К.Булатова сүз., Р.Нәгыймов көенә **«Шушы яктан, шушы туфрактан без» җырын тыңлау** (тәрбиячеләр башкаруында)

**Алып баручы:** Клара Булатова 1936 елның 18 мартында Татарстан АССРның Сарман районы Татар Карамалысы авылында туган. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа күрә Кларага бала чактан ук эти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күчеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә, өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, ә Сарман урта мәктәпне бетерә. Шул ук елның көзеннән К. Булатова хезмәт юлын башлый: Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч класларда балалар укыта, аннан

Әлмәт шәһәрендә төзелештә эшли.  Соңрак ул яңадан мәктәптә – Колшәрип авылында татар теле һәм әдәбияты, тарих укыта. Шул ук вакытта ул шигырьләр  яза. Бигрәк тә балалар өчен язылган күңелле, кызыклы әсәрләрен без тыңлап китәрбез.

**1 нче бала:** **Иптәш**

Илдарның бар сеңлесе,
Ленарның бар энесе.
Марс кына берүзе –
Ялгыз әллә нишлисе?!
Матур песи таптылар,
Өйгә алып кайттылар.
Әмма ни хәл итәсе:
Куркак булды иптәше.
Тик утыра почмакта,
Чыгып йөрми йортка ул.
Барыннан да бигрәк
Тычканнардан курка ул.

2 нче бала: Әниемнең кызы юк бит

Әниемнең кызы юк бит,
Мин әнигә бер генә.
Кызы да юк, эше дә күп
Әнинең берүзенә.
Әниемнең кызы юк шул,
Мин булышам әнигә.
Аш пешерәм, җыештырам,
Кер юышам әнигә.
Магазиннан  сөт апкайтам,
Ипигә дә йөгерәм.
Әниемнең кызы юк та-
Малае бар бер дигән.

Алып баручы:  Клара апаның һәр яңа әсәре безнең өчен рухи азык. Аның күп шигырьләре сатира-юморның белән бәйләнешле. Бигрәк тә балалар тормышын тасвирлаган әсәрләре.

**3 нче бала** **Әни - егет**

Әти дә эштән кайтты.
Әти дә эштән кайтты.
Әти диванга ятты.
Әни кухняга чапты.
Әти әйтә: «Мин ач, – ди,
- Кайчан була ул аш?» –ди.
Әни әйтә:«Үзең дә
Булыш, алай булгач», – ди.
Әти әйтә:«Мин – ир, – ди,
- Аш пешерә белмим, – ди.
- Мин хатын-кыз түгел, – ди,
- Мин кухняда йөрмим» – ди.
Юкса «Җитмеш һөнәр аз, –
диләр, – егет кешегә».
Безнең өйдә әти түгел,
Әни – егет, әни белә
Чөнки бөтен эшне дә.

4 нче бала Әти белми.

Тышта буран котыра,
Әти өйдә утыра.
Әти өйдә утыра,

Машинасы тик тора.
Әти өйдә утыра:
- Чыга алмый торам, – ди,
- Чыга алмый торам, – ди,
- Тышта кара буран, – ди.
Тышта һаман буранлый,
Кар бураны ак кына.
Әти белми: буран ул
Кара булмый, ак була.

Алып баручы: Клара апа Булатова балалар өчен менә шундый күңелле, мавыктыргыч шигырьләр иҗат итә. Кайбер әсәрләренә композиторлар көй язганнар. Әйдәгез шундый бер җырны тыңлап үтик.

**Балалар башкаруында җыр «Солдатлар»**

(К. Булатова сүз., М. Минһаҗев көе )

**Алып баручы:** Клара апа туган ягыбызны бик ярата, татар халык мәдәниятен бик ярата һәм хөрмәт итә.

**Сүзле уен «Мәкальне дәвам ит»**

Әткәй – шикәр, әнкәй – бал.
Ипидән зур нәрсә юк.
Сәламәтлек – зур байлык.
Кем эшләми, шул ашамый.
Иң татлы тел – туган тел, әнкәм сөйләп торган тел.
Кош канаты белән, кеше дуслык белән көчле.
Китап – белем чишмәсе.
Дустың булмаса – эзлә, тапсаң – югалтма.
Күз күне бала кебек – бер күлә дә бер елый.
Туган ил була бер генә, туган илнең кадерен бел генә.

**Татар халык уены «Зәңгәр чәчәк»**

Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк ярата.
Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләреңә ипле булсын,
Мендәреңне куй әле.

Алып баручы: Клара Булатова балалар өчен язган шигырьләренең күбесен бик шук һәм акыллы Марс исемле малай турында яза.

**5 нче бала:** **Унга кадәр**

Марсның бармаклары –
Санагыч таяклары.
Бер турайта, бер бөгә,
Унга кадәр сан белә.
Әти белән әни, ди,
Бабай белән әби, ди,
Үзем, абый һәм апа,
Боларга кушкан чакта
Бозау белән песи, ди,
Алай да җитешми, ди,
Этемне дә син куш, ди,
Унынчысы Актүш, ди.

**6 нчы бала:** Бакчада

Бабайның бакчасы бар,
Бакчада алмасы бар.

Алмагачның алмаларын
Үрелеп аласы бар.
Уң кулын суза Марс,
Сул кулын суза Марс.
Ничек кенә аласы соң,
Нинди җаен табасы?
Рәхәтләнеп өзде Марс
Күтәргәчтен бабасы.

Алып баручы: Безнең балалар Клара апаның «Әләкләргә ярамый» дигән шигырен сәхнәләштерделәр. Рәхим итеп карагыз әле.

**Әләкләргә ярамый**

*Өй күренеше. Музыка астында малай белән песи уйныйлар: чабалар, сикерәләр, песи өстәлдә торган әйберләрне, гөлне аударып төшерә. Шул вакытта әни эштән кайтып керә һәм орыша башлый. Песи малайның артында качып посып тора.*

**Әни:**

- Син үзең дә тәртипсез,

Песиең дә тәртипсез!
Туздыргансыз сез өйне,
Аударгансыз бу гөлне.
Монда ята чүлмәк,
Тегендә ауный күлмәк,
Азынасыз бигерәк,
Аерырга сезне кирәк!

**Малай:**

Бүлмә үзе тузгандыр,
Без аны гел күрмәдек.
Чүлмәк үзе аугандыр,
Без аңа да тимәдек.
Һич тәртипсез түгел без,
Без бит бары уйныйбыз,
Песи наян, мин шаян,
Шуңа өйгә сыймыйбыз.
Песи чапты, мин кудым,
Алны-артны карамый.
Кайсыбыз гөл аударганны
Ул да әйтми,
Мин дә әйтмим,
Әләкләргә ярамый!

Татар халык биюе «Су буенда»

*«Каз канаты» аннары тиз бию көенә кызлар һәм малайлар башкаралар.*

**Алып баручы**: Шагыйрәнең тагын берничә күңелле шигырен тыңлап үтик.

**7 нче бала**: **Кызык инде бу бабай**

Көн кояшлы булган чакта
Марс йөри сөенеп.
Әллә нигә шундый чакта
Бабай йөри көенеп.
Бүген, әнә, яңгыр ява,
Ишек алды чылана,
Бөтен урам пычрана бит!
Бабай шуңа куана.
Яңгыр яугач, җир пычрана,
(Бабай шуны уйламый)
Җир пычрангач, өс буяла,
Әни тышка чыгармый.

**8 нче бала:** Урманда.

«Җиләк җыям, как коям
Әниемә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю, бүре юк микән».
Марс килгән урманга
Кура җиләк җыярга.
Җыйсын әле күп итеп,
Какка җитәрлек итеп.
«Җиләк җыям, как коям
Әбиемә бүләк дип.
Әби тәмләп чәй эчәр,
Улым җыйган җиләк», – дип.

Алып баручы: Клара Булатованың әсәрләре белән сез, балалар, киләчәктә, мәктәптә танышырсыз. Ә бүген без шуны әйтә алабыз – шундый шәхеснең безнең районлашыбыз, якташыбыз булуы белән без һичшиксез горурланабыз! Кичәбез тәмам, сау булыгыз!

## Туган як җырчылары

(Мәктәпкә әзерлек төркеме балалары өчен әдәби-музыкаль кичә)

Афзалова Кадрия Закар кызы, Җәлил бистәсенең 3нче
балалар бакчасының музыка җитәкчесе, Сарман районы

**Бурычлар: С**арман районы шагыйрьләре һәм композиторларының иҗаты турында белемнәрен тирәнәйтү һәм киңәйтү, аларның музыкаль һәм әдәби әсәрләре белән таныштыру. Шигырьләрне аңларга, сәнгатьле укырга өйрәтү. Нәфис сүз һәм музыкага мәхәббәт тәрбияләү.

***Кичә барышы.***

***Алып баручы (слайд: 1, 2)***

Сарман ягы – зәңгәр таулар,
Мәңге сайрар сандугачлар.
Яшел болын, алтын кырлар,
Җанга җылы биргән җырлар.
Сарман ягы – аяз күкләр,
Алсу таңнар, озын юллар.
Бәхет кенә, шатлык кына
Алып килсен туар еллар. *(Д.Гарифуллин)*

Балалар, сез ничек уйлыйсыз, бу шигырь нәрсә турында?

***Балалар:*** туган як, туган авыл, туган җир турында...

***Алып баручы (слайд 3)*** Безнең яшәгән җиребез бик матур. Аның тирә-ягында җиләкле, гөмбәле урманнар, салкын сулы чишмәләре, күлләре, киң кырлары, яшел болыннары бар. Безнең яши торган өебез, әниебез-әтиебез, без йөри торган балалар бакчасы, дусларыбыз, без уйный торган мәйданчыклар, безнең урам, ял итә торган парклар – болар барысы да туган як була инде.

*1 нче бала*

Җир-анабыз!
Без балалар –
Синең алтын бөртекләрең.
Әй, һавабыз!
Без балалар –
Синең нәни бөркетләрең.
Кояшыбыз!

Без балалар –
Синең вак-вак чаткыларың.
Чишмә суы!
Без балалар –
Синең көмеш тамчыларың. *В.Хәйруллина*

*«Хәерле көн» җыры, В.Хәйруллина сүз., Г.Якупова муз.*

***Алып баручы (слайд 4)*** Безнең Сарман якларын сандугачлы, моңлы як дип йөртәләр. Дөрес тә, ул онытылмас табигатькә генә түгел, ә безнең янәшәбездә яшәүче талантлы кешеләргә дә бай. Алар безнең арада бик күп, әмма без алар турында бик аз беләбез.

Шагыйрьләр, музыкантлар, рәссамнар – туган ягыбызның матурлыгын һәм бөеклеген иҗатлары аша күрсәтә белгән талантлы кешеләр. Без горурлык белән аларны туган як җырчылары дип атый алабыз. Бүген без туган як шагыйрьләре һәм композиторлары турында сөйләшү өчен музыкаль кунакханәгә җыелдык.

***Алып баручы (слайд 5, 6)*** 1936 елның 18 мартында Сарман районы Татар Карамалы авылында укытучылар гаиләсендә кыз бала туа. Балага Клара исеме кушалар. Аның әти-әнисе бик тә шигырь яратканнар, хәтта үзләре дә шигырьләр иҗат иткәннәр. Клара кечкенәдән әнисе белән тегәргә, бәйләргә, чигәргә өйрәнә, ә иң мөһиме – әнисе укыган шигырьләрен тыңларга һәм аңларга өйрәнә. Ул гомер буе поэзия, әдәбият ярата. Мәктәптә укыганда ук ул үзе шигырьләр яза башлый. Аның беренче шигыре сугыш чорында, икенче класста укыганда туа. ***(слайд 7)***

Клара Булатова – танылган шагыйрә, укытучы.Үзенең бер шигырендә ул болай дип яза:

Укытучы булып гомер иттем,
Укытучы идем!
Чын ихластан ул исемне йөрттем,
Шул исемне сөйдем.

***(Слайд 8)*** Клара Гариф кызы Булатова шигырьләре аша балаларда туган якка, туган телгә, ата-аналарга мәхәббәт тәрбияли, табигатьнең, тормышның матурлыгын тоярга ярдәм итә.

*2 нче бала* Урманда

«Җиләк җыям, как коям
Әниемә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю, бүре юк микән?!»
Марс килгән урманга
Кура җиләк җыярга.
Җыйсын әле күп итеп.
Какка җитәрлек итеп.
Җиләк җыям, как коям
Әбиемә бүләккә дип.
Әби тәмләп чәй эчәр,
«Улым җыйган җиләк», – дип.

3 нче бала Эшләп ашый

Чөгендер җире бирелгән
Авылда әбисенә,
Марс та кайтып булышты
Әбинең бу эшенә.
Бергәләп өйде, утады,
Эшләде ничә көннәр!
Самавыр зурлыгы булып
Үстеләр чөгендерләр.
Ә бүген аларны җыеп
Өемнәргә ташый ул.
Табында быел шикәрне
Тартынмыйча ашый ул.

4 нче бала Әниемнең кызы юк бит…

Әниемнең кызы юк бит,
Мин әнигә бер генә.
Кызы да юк, эш тә бик күп
Әнинең берүзенә.
Әниемнең кызы юк шул,
Мин булышам әнигә.
Идән юам, җыештырам,
Кер юышам әнигә.
Кибеттән сөт алып кайтам,
Ипигә дә йөгерәм.
Әниемнең кызы юк та,
Малае бар бер дигән.

5 нче бала Авылга кайткач

Абзарларны карап кергәч,
Марс әйтте тиз генә:
– Әни! Казның бәрәне күп,
Сарыкныкы бер генә.

***Алып баручы.*** Клара Булатованың шигырьләре хис-тойгыларга бай, алардан моң агыла. Шуңа күрә шагыйрә бик матур җырлар авторы буларакта танылды (**слайд *9)***

*«Солдатлар» К.Булатова сүз, М.Минһаҗев көе*

***Алып баручы.*** Афәрин, балалар, сез – чын солдатлар сыман. Ә беләсезме, Клара Булатова укыган мәктәптә сугыштан кайткан фронтовиклар да укыта. Шуларның берсе – аның әтисе, ә икенчесе – татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әзһәр Габиди. Алар да шигъриятькә гашыйк булганнар һәм укучы Кларанның беренче остазлары булганнар (**слайд *10)***

Шагыйрь Әзһәр Габиди 1926 елның 25 сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында өченче бала булып туа. Ул кечкенәдән үк шигырьләр яратып үсә һәм аларны иҗат итәргә омтыла. Ләкин 10 нчы сыйныфны тәмамларга да өлгерми, Бөек Ватан сугышы башлана. Бик яшьли Әзһәр фронтка китә.

Сугыштан кайткач, ул шигырьләр яза башлый. Ә ул искиткеч матур урында урнашкан туган ягы турында, урмандагы гүзәллек, авыл чишмәләренең саф сулары, ипигә ягып ашарлык саф һавасы хакында ничек матурдан-матур шигырьләр язмыйсың, ди. (***Слайд 11)***

Шулай ук Әзһәр абый тормышын татар теленә һәм әдәбиятына мәхәббәт тәрбияләүгә һәм балаларны укытуга багышлый. Әсәрләрендә ул һәрвакыт яхшылыкка өйрәтте, балада туган җиргә, туган авылга, туган йортка мәхәббәт хисләре тәрбияләүгә омтылды. (***Слайд 12)***

Шагыйрьнең балалар өчен язылган шигырьләре бик күп: «Таң догасы», «Тыңлаусыз чүкеч», «Югалган кояш» һәм башкалар. Балалар аларны аеруча яратып укыйлар. Ул балалар өчен «Без – яз дуслары», «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Таң сәгате», «Калган эшкә кар ява» дигән шигырьләр җыентыклары авторы.

6 нчы бала. Яз сөңгеләре.

Март иртәсендә абыем
Тыштан шатланып керде.
Ул, көлә-көлә, әнигә:
– Безгә яз килгән! – диде.
– Каян беләсең? – дип, аңа
Әнием сорау бирде.
Абый аңа: – Яз кыекка
Сөңгеләр элгән! – диде.

7 нче бала. Бакчада.

– Нәрсәдән син шулай тәмле,
Әйт әле, җир җиләге?
Мин югында, әллә әни
Сиңа шикәр сибәме?

Матур бул, дип, әллә абый
Сине алга манамы?
Хуш исле бул, дип, апа да
Хушбуйларын ягамы?

8 нче бала

– Син яраткан тәмле балны
Мин, дустым, җирдән алам,
Ә, битемне, алсулатып,
Кояш нурына манам.

9 нчы бала Бал кортлары

Карабодайлар
Чәчәк аткан.
Гүя басуга
Тәңкә кар яткан.
Бал исе бөрки
Талгын җәй җиле,
Походка чыгар
Эшчән корт иле.
Алар очарлар
Белми ал-ялны,
Умарталарга
Җыярга балны.
Һәм аны безгә
Бүләк итәрләр,
Баллы табынлы
Булыр иртәләр.

**Алып баручы**. Әзһәр абыйның табышмак шигырьләре дә күп. Әйдәгез әле, балалар, табышмак чишеп карыйк.

1. Янымда минем беркайчан
   Булмаса да сәгатем,
   Бар кайсы вакыт икәнне
   Әйтә торган гадәтем. *(Әтәч)*
2. Асрамаса да умарта,
   Балны бик тә ярата.
   Кышын сөя йокыны,
   Язгача тормый ята. *(Аю)*
3. Мөгеземнән тоталар да
   Аяк белән йөртәләр.
   Миңа утырып, кешеләр
   Юлны җитез үтәләр. *(Велосипед)*
4. Пыр-пыр килеп китәр кош,
   Күккә менеп җитәр кош.
   Ширбәт түгел, су да түгел,
   Девон маен эчәр кош. *(Самолет)*
5. Мыегын ул үстермәс,
   Ләкин сакалсыз йөрмәс.
   Бакчада булыр үзе,
   Урлашмый туймас үзе. *(Кәҗә)*

**Алып баручы.**Афәрин, балалар. Булдырдыгыз. Әзһәр Габидиның шигырьләре күп композиторларга илһам чыганагы булды. Илгиз Закиров, Зөфәр Сәхәбиев, Равил Курамшин, Мәгъфүр Юзлибаев аның дистәләрчә шигырьләренә музыка яздылар. Алар арасында композитор Гөлнара Рәис кызы Якупова да бар. Ул бүгенге көндә Сарман авылында яши һәм иҗат итә. Бүген без аның шагыйрь Әзһәр Габиди сүзләренә язган «Яратам сине, кояш!» дигән җырын тыңлап үтәбез.

*«Яратам сине, кояш!» А.Габиди сүзләре, Г.Якупова көе*

**Алып баручы.** Балалар, композитор Гөлнара Якупова күбрәк балалар өчен иҗат итә. Күп җырларының Сарман ягында яшәп иҗат итүче шагыйрьләр Дамир Гарифуллин, Вәсимә Хәйруллина, Әхнәф Гатауллин, Әзһәр Габиди сүзләренә булуы аның туган җиренә мәхәббәте, якташлары белән горурлана белүе хакында сөйли. Әйдәгез аларның да берничә шигырен искә алып үтик. (***Слайд 13, 14)***

10 нчы бала «Җәйге яңгыр» Вәсимә Хәйруллина

Болытларны сыеклап,
Кыйгач-кыйгач кыеклап,
Сукмак буйлап, шаян уйнап,
Сыңар аяк, яланаяк
Яңгыр чаба миңа таба.
Көмеш җебе як-ягымда
Чәбәләнә аягымда.
Балтырыма бәрә-бәрә,
Безнең өйгә таба бара.
Кереп киттем, яңгыр калды.
Тәрәзәмә көмеш җебен сузып салды.

11 нче бала «Карлыгач» Вәсимә Хәйруллина

Карлыгач кара булгач,
Исеме дә карлыгач.
Диңгез-таулар артыннан
Кайтып төшә яз булгач. (***Слайд 15, 16)***

12 нче бала «Кар бабай ясадык» Дамир Гарифуллин

Җыелып җепшек кардан
Кар бабай ясап куйдык.
Матурлап аның күзләрен,
Авызын хәтта уйдык.
Нинди эш кушыйк аңа, дип,
Кичен уйлап тордык та
Каравылга дип калдырдык
Бер таяк тоттырдык та.

**Алып баручы.** Ә хәзер мин сезне бер суалчанны бүлә алмаган ике чеби белән таныштырам. (***Слайд 17).****Музыкаль инсценировка «Ике чеби» (Д.Гарифуллин)*

Бер суалчан тапканнар да,
Баш-башыннан капканнар да
Тартышалар ике чеби:
– Сиңа түгел, миңа ди, ди,
Тартышалар уңга таба.
Тартышалар сулга таба.
Тартышалар алга-артка,
Тартышалар төрле якка...
Әй, сугышып китә болар,
Хәлдән таеп бетә болар.
Моннан исә чыпчык ота –
Суалчанны кабып йота.
Ә тегеләр авыз ачып
Калды шунда читтә басып.

**Алып баручы**. Без туган ягыбыз белән, аның талантлы шагыйрьләре, композиторлары, рәссамнәре белән горурланабыз. Без талантлы, иҗади кешеләр турындагы истәлекне сакларга һәм киләчәк буыннарга тапшырырга тиеш.

Бүгенге кичәне Вәсимә Хәйруллинаның «Үз иле» дигән шигыре белән тәмамлыйсы килә.

Үзенең урманына
Карый бүре баласы.
Бөҗәккә кирәк чәчәк,
Ә бөркеткә – һавасы.
Сандугач талын мактый,
Балык мактый елгасын.
Кеше мактый үз илен,
Нинди генә булмасын.

## Туган туфракның тугры улы

(Хәниф Гыйздулла улы Хәйруллин иҗатын өйрәнү буенча
иҗади проект эше)

Нәҗметдинова Чулпан Мөнир кызы, Шәйхразиева Гүзәл Ринат кызы,
Сарман аграр көллияте, Сарман районы

Сандугачлар сайрый, кайда сайрый,
Сарман буйларында тирәктә шул,
Сарман буйларында тирәктә...
*(Д. Х. Гарифуллин)*

Әйе, җырларда җырлана торган, шигырьләргә кергән, риваятьләрдә йөргән сандугачлы Сарман яклары... Шушы гүзәл табигатьле Сарманыбызның сандугачлары дип кемнәрне атыйбыз соң без?! Әлбәттә, бөтен татар дөньясына мәгълүм булган мәшһүр җырчыларын, олпат язучыларын, данлы артистларын, уңган игенчеләрен. Шулар арасында иң тыйнак, шул ук вакытта халык күңеленә керә белгән, Сарманыбызда туып шунда яшәгән һәм бик тәрбияви, мавыктыргыч әсәрләр авторы, язучы-журналист – Хәниф ага Хәйруллин зур урын алып тора. Якташ язучыбызның тууына быел 90 ел тула. Аның иҗатын өйрәнү укыту программасына кертелмәсә дә, әлеге бөек шәхес турында укучыларга җиткерү, аның иҗаты белән таныштырудан читтә кала алмыйбыз.

Аграр көллиятебездә күпчелек студентлар – булачак ир-егетләр белем ала. Укыту-тәрбия эшләрен алып барганда үрнәк итеп алырдай геройларны күрсәтәсе килә. Хәниф ага Хәйруллин кебек, туры сүзле, әйткән сүзеңә, эшләгән эшеңә тугры кала белү сыйфатларын киләчәк буында булдырырга чакыру. Нинди генә сынаулар алдында калганда да чын ир булып калырга кирәклеген онытмаска, югалып калмаска кирәклеген аңларга кирәк. Шуны истә тотып әлеге иҗади проектны төзү һәм чынга ашыру планнаштырыла. Студентларны мөстәкыйль эш йөртүгә һәм активлыкка чакыру өчен, яхшылык эшләүче, күңелләрендә изгелек йөртүче кешеләрнең күбрәк икәнен, өлкән буын белән яшь буын арасын якынайту максатыннан чыгып төзелгән иҗади проект үзенең эшен аклар дип ышанабыз.

Проект эшен ике юнәлешкә бүлеп башкарырга булдык: беренчесе, язчуыбызның әсәрләре буенча, әдәби әсәрләрдән эзләнүләр булса, икенчесе, язучының тормыш юлы белән, чынбарлыктан, тормыштан алынган вакыйгалар белән бәйле булырга тиеш. Беренче юнәлешне «Канатлар талмасын», икенчесен «Безнең генерал» дип исемләдек. Беренче юнәлештә Хәниф Хәйруллин әсәрләренең эчтәлеге, төп геройларга характеристика ясау, уңай һәм тискәре геройларны чагыштыру, географик киңлекләргә басым ясау максаты куелды. Аграр көллият студентлары тумышы белән Сарман һәм Сарманга якын авыллардан, шуңа күрә дә бу эш аларга бик кызыклы булып тоелды. Ә «Безнең генерал» юнәлешендә төп эзләнү объекты булып – язучы-журналистның тормыш юлыннан алынган кызыклы вакыйгалар, балачагыннан истәлекләр, аның турында сабакташлары, дус-туганнары, хезмәттәшләре язган мәкаләләр тора. Тормыш юлыннан башлап бүгенге көн истәлекләренә кадәр вакытны колачлаучы әлеге юнәлеш – аның исемен мәңгеләштерүче урыннарны, районнан беренче язучы-журналист булуын, район газетасы тарихында калдырган эзләре турындагы фикерләрне дә үз эченә ала. Бер дәрес эчендә әлеге проект турында сүз кузгатуга, һәр студентның Хәниф Хәйруллин исеме белән бәйле фикер әйтүләре тагын да

канатландырып җибәрде. Көллиятебезнең төп бинасына куелган мемориаль такта, Сарманыбызда аның исемендәге урам барлыгын белүчеләр – киләчәк буынның битараф булмавын аңларга мөмкинлек бирде. Проект эше бары уңай нәтиҗәләр генә бирер дигән нияттә түбәндәге планны төзедек.

| Проект эше | **«Туган туфракның тугры улы»** |
|---|---|
| Проектның җитәкчесе | Татар теле һәм әдәбияты укытучылары<br>Нәҗметдинова Чулпан Мөнир кызы,<br>Шәйхразиева Гүзәл Ринат кызы. |
| Катнашучылар | «Сарман аграр көллияте»нең 1 курс студентлары |
| Проектның максаты | Җәмгыять ничек кенә үзгәрмәсен, кеше яхшы белән начарны, ак белән караны, бөеклек белән түбәнлекне аерырга, ата-анага булган хөрмәт-мәхәббәтне аңлап үсәргә тиеш. Чөнки бәхетле тормышны безгә үзебезгә төзергә туры киләчәк. Нинди генә сынаулар алдында калганда да чын ир булып калырга кирәклеген онытмаска, югалып калмаска кирәклеген аңларга. Студентларны мөстәкыйль эш йөртүгә һәм активлыкка чакыру, өлкән буын белән яшь буын арасын якынайту. |
| Проектның актуальлеге | Соңгы елларда мәгариф системасында проектлар методы киң таралыш алды. Ул үз алдына, укучыларның төрле предмет буенча алган белемнәрен файдаланып, укыганда мөстәкыйль эшләргә өйрәтү максатын куя. Әлеге методны педагогик технология мәгънәсендә аңлаганда, ул үзендә эзләнү-тикшеренү һәм проблемалы методларның бердәмлеген хәтерләтә. Укытучы проектны планлаштыручы, эшне җайга салучы эксперт яки консультант буларак катнаша. Шунысын да әйтергә кирәк: теоретик белемнәрне гамәлдә куллана белү аерым проблемаларны чишү юлларын да билгеләргә ярдәм итә; укыту эшен аерым шәхескә, бу очракта укучыга адреслы итеп алып барырга булыша, мөстәкыйль фикерләргә – теманы сайларга, кирәкле мәгълүматны эзләп табарга, аңлатырга һәм күрсәтергә өйрәтә. Укучылар бу вакытта сөйләмнең эчтәлегенә күбрәк игътибар итәләр. Әлеге метод предметара бәйләнешләрне тормышка ашырып, укучыларның белемнәрен интеграцияли, танып белү эшчәнлеген арттыра, аларның иҗади һәм тикшеренү күнекмәләрен үстерә. |
| Проектның бурычлары | укучыларда татар әдәбиятына, халык авыз иҗатына карата мәхәббәт тәрбияләү, аларның тәрбияви кыйммәтенең зурлыгын аңларга ярдәм итү;<br>аерым төркемнәрдә эшләү күнекмәләрен булдыру;<br>эзләнү-тикшерү эшләре алып барырга өйрәнү;<br>кешелек сыйфатларын барлау;<br>яшь буынны үткәнебез белән кызыксындыру;<br>туган җир мәсьәләсе, аның кеше тормышында зур урын алуын аңлату;<br>ата-ана хакын аңлау;<br>изге гамәлләрнең җирдә ятмаганын исбатлау;<br>халкыбызның гореф-гадәтләре турында күзаллау булдыру. |
| Проекттан көтелгән нәтиҗәләр | студентларның активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл эшчәнлегенә һәм рухи эшчәнлеккә өйрәнүләре<br>төркемнәрдә эшләүнең уңай һәм тискәре якларын ачыклаулары |

| | |
|---|---|
| | һәр төркемгә бирелгән эшләрнең төгәл башкарылуы<br>әзерләп килгән материалларны дөрес итеп куллану<br>үз фикерләреңне мөстәкыйль дәлилли белүләре<br>барлык материалларны кулланып иҗади конференция оештыру<br>куелган максат һәм бурычларга уңышлы ирешү |
| Көтелгән нәтиҗәләрне чынга ашыру шартлары | - Студентларның актив булулары<br>- Төркемнәрне дөрес итеп оештыру<br>- Аерым төркемнәргә бурычларны куя белү<br>- Өлкән буын кешеләре белән якынаю<br>- Авыл һәм районыбыз китапханәчеләренең ярдәме<br>- Дамир Хайрулла улы Гарифуллин белән очрашуны штыру<br>- Техник җайланмалар белән тәэмин ителү |
| Проектны чынга ашыру сроклары | 2020/2021 нче уку елының икенче яртысы<br>**I этап - әзерлек этабы**<br>(гыйнвар – март)<br>*Укытучы эшчәнлеге:*<br>Әлеге проектны чынга ашыру планы<br>Укучыларны дөрес итеп төркемнәргә бүлү, иҗади биремнәр бирү<br>Кулланылачак әдәбият исемлеген төзү һәм укучыларны таныштыру<br>Китапханә хезмәткәрләре белән сөйләшү<br>Д. Х. Гарифуллин белән очрашуны оештыру<br>«Бөек Ватан сугышы һәм Туган якны өйрәнү» музеена алып бару<br>«Сарман» газетасы редакциясенә экскурсия оештыру<br>*Студентлар эшчәнлеге:*<br>Төркемнәрдә эшләү<br>Иҗади-тикшеренү эше<br>Фәнни-тикшеренү эше<br>**II этап – төп этап** (апрель)<br>- җыелган материалларны дөрес итеп төркемнәргә бүлү, тикшерү<br>- Хәниф ага Хайруллин әсәрләрен уку, алар буенча фикер алышу<br>- һәр төркемгә бирелгән эшләрнең төгәл башкарылуын тикшерү, ачыклау<br>- язмаларны уку, иң уңышлыларын ачыклау<br>- иҗади кичә үткәрү<br>**III этап – йомгаклау** (май)<br>- Эшләнгән эшләрне йомгаклап конференция үткәрү<br>- Проектны чынга ашыруда зур өлеш кертүчеләргә рәхмәт хатлары җиткерү<br>- Җиңүчеләрне һәм актив студентларны диплом һәм грамоталар белән бүләкләү |

## Клара Булатова ижатында балалар дөньясы

Латыпова Дания Фатыйх кызы, Тимербаева Зөлфия Зөлфәт кызы,
Җәлил бистәсенең 6 нчы балалар бакчасы тәрбиячеләре, Сарман районы

Клара Булатова иҗаты барлык яшьтәге кешеләргә: әби-бабайлар, әти-әниләр, яшьләр, үсмерләр өчен дә аңлаешлы. Аның кечкенә балалар өчен язган «Марс китабы», «Әллә кайсын тыңласы», «Курка димәгез әле», «Камилә – тәти кыз», «Камилә дигән матур кыз» дигән китаплары чыкты. Бай сурәтләү чаралары аша бу китаплар балаларны яхшылыкка өнди, дөньяны ныграк танып белергә өйрәтә.

Мәктәпне бетергәч, ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Аннан ул башы-аягы белән мәктәпкә чума һәм үзенә яңа бер дөнья ача – балалар дөньясы. Балалар күңеле аның җанына яктылык биреп, шигырьләренә нур өсти. Балалар өчен матур-матур китаплар чыгара. Бик күп шигырьләрендә ул мәктәпкә, балаларга булган олы мәхәббәтен сурәтли:

Миңа сорау бирсәләр,
– Шатлыгың ни? – дисәләр,
Шушы мәктәп сукмаклары
Шатлыгыма илтәләр.

К. Булатова шигриятенең төп темасы – мәктәп, балалар язмышы. Тумыштан ук шагыйрә булган кебек, тумыштан ук укытучы да. Мәктәптә изелгән, мәктәптә басылган һәм мәктәптә әвәләнгән бер җан иясе ул. Бик якын кешесенә ул болай җавап биргән:

…Тотасың да миңа «ташла» дисең,
Шулмы булды дуслар әйткән сүз?
Минсез дә ул мәктәп мәктәп инде,
Мин кем булыр идем мәктәпсез?

Яңа көнгә яңа хуҗа булып яңа буын килә, дип куана шагыйрә. Оныгы Марат тугач, инде әби булгач балалар өчен яңа җыр текстлары языла башлый. Үз оныгы өчен генә түгел, күпләрнең оныклары өчен изге дога булырдай юллар бар аларда.

Күкләргә кара, улым,
Йолдызлар сана, улым,
Йолдызларны таныган бала
Үз юлын таба, улым.

Җыр – шигырьнең соңгы юлларында:

…Йолдызың күрсәткән юлдан
Тайпылмасана, улым, –

дип меңләгән әниләрнең, әбиләрнең гозер-теләкләрен җиткерә.

Клара Булатова диюгә безнең күз алдына атна саен көтеп ала торган «Җомга апабыз» килеп баса. Әлмәттә бу тапшыруны карамаган бер генә гаилә дә юктыр. Клара апа бу тапшыруны шундый оста итеп алып бара иде. Бу тапшырулар балалар иҗатына, алар белән булган төрле чараларга, очрашуларга багышланган.

Клара Булатова иҗаты татар әдәбиятында үзенең лаеклы урынын алды. Шундый якташыбыз белән горурланабыз без.

## Клара Булатова иҗатында табигатькә мәхәббәт

Гарипова Эльвина Фәнис кызы, Латыпова Дания Фатыйх кызы,
Җәлил бистәсенең 6 нчы балалар бакчасы тәрбиячеләре, Сарман районы

Клара ханымның шигырьләре туган якка, газиз туфрагына тирән мәхббәт белән сугарылган. Данлыклы Әлмәт табигатенең гүзәл табигатенә, иксез-чиксез хәзинә байлыкларына, тырыш, хезмәт сөючән, батыр, фидакарь халкына мәдхия кебек аның әсәрләре.

Шагыйрә үзе җырларга кергән Сарманякларында туып үссә дә, иҗаты Әлмәтнең уңдырышлы туфрагында чәчәк аткан. Биредә аның тынгысыз, якты хыялларга бай яшьлеге, иң җегәрле, көч-куәт ташып торган еллары узган. Әлмәт – шагыйрәнең рухи туган җире.

Безнең яшьлекне үзенә
Фундамент иткән шәһәр –
Улларыбызга мирас ул,

Кызларыбызга мәһәр, – дип яза ул үзенең «Күларты посёлогы» шигырендә.

Шагыйрә Әлмәт төбәгенең зәңгәр язларын, чәчәкле җәйләрен, моңсу көзләрен, ак мамыклы кышларын, көмеш нурга коенган урамнарын, сихри айлы төннәрен үзенә генә хас поэтик бизәкләргә, иҗат фантазиясенә төреп бирә һәм сиздермичә генә фәлсәфи фикер дөньясына алып керә.

Могҗиза тудыра, энҗе бөртекләре коела шагыйрә каләмннән. Аның шигырьләрендә таллар җырлый, өянкеләр елый, каеннар бии. Чыннан да, шагыйрәнең поэтик тукымасында метафора, чагыштыру, эпитетларга киң урын бирелгән. «Безнең як» шигырен генә алыйк:

Ипигә ягып ашарлык
Кара җир безнең якта.
Шәл итеп иңгә ябарлык
Яшеллек безнең якта.
Алтынга алыштыргысыз
Хәзинә безнең якта.

Ел фасылларын тасвирлаган шигырьләре гүзәллек дөньясына алып керә, күз алдыбызга жанлы картиналар китереп бастыра. Менә аның «Дөньяларның бигрәк матур чагы» шигыреннән өзекләр:

Зәй буйларын кем куллары чиккән,
Исле гөлләр белән бизәлгән?
Урманнарда җиләк уйдыклары
Мәтрүшкәләр бөрки хуш исен.
Дөньяларның бигрәк матур чагы,
Кырда иген килә өлгереп.

Шушы җырлы урманнарда, иген тулы кырларда бала чакка, үсмер чакка кайтып яланаяк йөгереп йөрисе, болын-кырларны яңгыратып җырлыйсы килә.

Җыеп кына әйткәндә, шагыйрә табигатьтән бөтен матурлыкны җыя да матур чәчәк бәйләме итеп халыкның үзенә кайтарып бирә.

## Кем булса да – кеше булыгыз!

(Тәрбиячеләр арасында Клара Булатова тормышы һәм иҗатына багышланган КВН)

Хәлиуллина Рузилә Рубирт кызы, Җәлил бистәсенең 6 нчы номерлы балалар бакчасы өлкән тәрбиячесе, Сарман районы

**Максатлар:** Клара Булатова тормышы һәм иҗаты буенча белемнәрне ныгыту, язучының әсәрләренә кызыксыну уяту. Якташ язучылар иҗатын өйрәнүне дәвам итү. Туган ягыбызга карата горурлык хисе тәрбияләү, аны ярату, туган җиребезгә мәхәббәт тәрбияләү.
**Кирәкле җиһазлар:** Клара Булатова портреты, китаплар күргәзмәсе.
**Алдан эшләнгән эш:** Клара Булатова тормышы, иҗаты һәм әсәрләре белән танышу, педагоглар өчен «Клара Булатова тормышы һәм иҗаты» дигән консультация әзерләү, китаплар күргәзмәсе оештыру.

**Уен барышы:**

**1 нче алып баручы:** Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Китә калсак үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр елап озата...

Туган җир.. Туган авыл... Йөрәккә нинди якын һәм кадерле бу сүзләр. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, нигезебез урнашкан кадерле туган авылы бар. Һәр авылның үзенә генә хас кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Сокланып туймаслык тугайлар, челтерәп ага торган йөгерек чишмә буйлары, туган ягыбызның кырлары, басулары, шаулап торган урманнары күңелләргә рәхәтлек биреп, туган туфракка мәхәббәт тәрбияли.

**2 нче алып баручы:** Сарман районы үзенең мәшһүр җырчылары, бию осталары, язучылары, шагыйрьләре, театрда уйнаучы артистлары белән данлыклы. Ә шушы җирлектә туып-үскән, гомерләрен иҗат эшенә багышлаган якташларыбыз булуы күңелдә горурлык

хисе уята. Шуларның берсе – шагыйрә Клара Булатова. «Сезнең кайчан да булса тезелешеп очкан кошларны күзәткәнегез, алар биеклегенә күтәрелергә тырышканыгыз юкмы? Әгәр булса, сез – шигъри җанлы кеше. Зәңгәр күктән тезелешеп очкан кошлар каурыйлары белән һавада шигырь язып калдыралар. Ә инде кошлар телен аңлый белүче илаһи затлар шул шигырьләрне эләктереп алалар да дәфтәр битләренә төшерәләр. Аларны шагыйрьләр дип атыйлар». (*Фәнис Яруллиннан*)

**2 нче алып баручы:** Язучы каләме, заман тормышының төрле өлкәләренә мөрәҗәгать итеп, әсәр каһарманнарының рухи дөньясын бөтен тирәнлеге, каршылыклары белән яктыртырга, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең катлаулы нечкәлекләрен, нокталарын ачарга омтыла, яшәешнең төп мәгънәсе һәм максаты турында укучы белән җитди әңгәмә алып бара.

**1 нче алып баручы:** Хөрмәтле тәрбиячеләр, килгән кунаклар, без сезнең белән шушы мәшһүр шагыйрәбез турында белемнәрне тагын да тулыландырырга – КВН үткәрергә җыелдык.

**2 нче алып баручы:** Бүген була КВН
Бу бик күңелле уен.
Бу бит бик зур тамаша!
Тәрбиячеләр көч сынаша,

**1 нче алып баручы:** Бу уенда үзебезнең тәрбиячеләребез көч сынаячаклар. Әйдәгез әле, алкышлар белән уенчыларыбызны бирегә чакырыйк. «Тәнәкә» һәм «Умырзая» командалары бирегә рәхим итегез. (Һәр командада 3әр тәрбияче катнаша).

**2 нче алып баручы:** Безнең командаларны бәяләп баручы жюриларыбыз да бар. (Жюри составы белән таныштырыла)

**1 нче алып баручы:** Уеныбызны өй эше тикшерүдән башлап җибәрәбез. (Өй эше итеп Клара Булатованың бер шигырен яттан сәнгатьле итеп сөйләргә бирелә ).

**2 нче алып баручы:** Булдырдыгыз, афәрин! Жюри 1нче турга үзенең бәясен куяр. Без 2 нче турга күчәбез. 2 нче тур – «Сорау – бездән, җавап – сездән» дип атала. Сезгә Клара Булатова тормышы һәм иҗаты буенча сораулар бирелә. Сез шул сорауларга җавап бирергә тиеш буласыз (һәр командага 4 әр сорау бирелә).

«Тәнәкә» командасына сораулар:

1.Клара булатова кайчан һәм кайда туа?( Клара Гариф кызы Булатова 1936 елның 18 мартында Сарман районы Татар Карамалысы авылында туа.).

2.Шагыйрә нинди гаиләдә дөньяга килә? (Шагыйрә укытучы гаиләсендә туа).

3.Клара Булатова ничә яшьтә үзенең беренче шигырен язган? Белсәгез, сөйләп китегез әле.
(Клара Булатова беренче шигырен 7 яшендә язган.
Ак балчык белән агарткан
Безнең өй стенасы.
Паек та кайтмый ичмасам,
Кичкә әллә ни ашасы?)

4. Клара Булатованың тормыш иптәше кем? (Клара Булатованың тормыш иптәше – Нәфис).

«Умырзая» командасына сораулар:

1. Клара Булатова ничә ел укытучы булып эшли? (Ул 52 ел укыта).
2. Шагыйрәнең улының исеме ничек?( Шагыйрәнең улы – Марс исемле).
3. Клара Булатова турында кем роман язган? Романның исеме ничек? (Фәрит Яхин шагыйрә турында «Умырзая» дигән роман язган).
4. Хәсән Туфан Клара Булатовага ничә хат язган? (Хәсән Туфан шагыйрәгә 76 хат язган).

**1 нче алып баручы:** Безнең уенчыларыбыз бик күп беләләр. Афәрин, Афәрин! Уеныбызның 3 нче туры «Бер-бер артлы сана» дип атала. Командалар бер-бер артлы шагыйрәбезнең җыентык исемнәрен әйтешәләр, чират кемдә кала – шул команда җиңелә. Уеныбызны «Тәнәкә» командасы башлап җибәрсен әле.(«Миләш кагы», «Әрнү», «Якты сагыш», «Үзем турында үзем», «Үзеннән үзе туа җыр» һ.б.)

**2 нче алып баручы:** Безнең хөрмәтле жюри әгъзалары бу ярыш өчен үзләренең бәяләрен куяр.

**1 нче алып баручы:** 4 нче турга күчәбез. Хөрмәтде педагогларыбыз, бу тур «Дөрес әйт» дип атала. Сезнең бурычыгыз – укылган шигырь юлларының кайсы әсәрдән икәнен билгеләү.

Чигәләрдә чал чәчләр дә,
Күз төбендә - күләгәләр...
Сиңа кайтам, гомеремне
Кыл урталай бүлсәм әгәр...(«Сина кайтам» шигыреннән)
1 нче алып баручы:
Абажурлы зәңгәр лампасыннан
Өстәлеңә якты сибелгән.
Дәфтәрләр дә инде тикшерелгән,
Планнар да күптән төзелгән.
Ә ул әле һаман йокламаган,
Төн йокысын нәрсә алган соң?
Сәбәбе син, Азат, син дә бүген
Язма эштә «5»ле алгансың. («Укытучы апаң йокламаган..» шигыреннән)

**2 нче алып баручы:** Уен турлары тәмам. Нәтиҗәне чыгарыр өчен сүз жюрига бирелә.

**1 нче алып баручы:** Клара Булатова турында яшьтәшләре, каләмдәшләре горурланып язалар. Атлас Гафиятов менә нәрсә дип яза: «Безнең Балачак, Яшьлек иленә мәңге тугрылык саклап калган кешеләребез бар. К. Булатова-Ана, Педагог һәм Шагыйрә. Балалар күңеленә мәрхәмәтлелек, туган телгә карата мәхәббәт орлыкларын кечкенәдән үк салып куйган ул Клара апабыз».

**2 нче алып баручы:** Хөрмәтле педагогларыбыз, килгән кунаклар, якташ язучыларыбызны онытмыйк, аларның иҗаты белән танышып торыйк. Якташ язучыларыбыз белән горурланыйк!

## Сүнә белми торган ялкын

(Клара Булатова белән очрашу кичәсе)

Гыйльфанова Фәнүсә Мәгъсүмҗан кызы, Кызрачева Нурзия Мәрвәр кызы,
Адлер Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш мәктәбе, Сарман районы

Максат: Якташ язучыбыз Клара Булатова иҗаты һәм аның балалар өчен язган шигырьләре белән танышу.

Көтелгән нәтиҗә: якташ язучыларны таный һәм хөрмәтли белү; аларның хезмәтләре белән кызыксынып танышу теләге уяну; иптәшләреңне тыңлый, ишетә, үз фикереңне ачык итеп әйтү; шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйли белү.

Кичә барышы

Алып баручы: Сарман ягы халкы чыннан да бәхетле... Ул тырыш як, моң чишмәләре уянган як. Сарман үзе дә,авыллары да табигатьнең матур җиренә урнашкан. Халкы ачык, киң күңелле, талантлы, җырга-моңга бай, ярдәмчел һәм хезмәт сөючән.

Төбәгебездәге авылларыбызның, алар янындагы су-чишмәләрнең матурлыгы шагыйрьләребезне шигырь язарга һәм композиторларыбызны көй язарга этәрә.

Җырларда җырланган Сарман ягы, Сарман төбәге. Бу якның никадәр гүзәл икәнен аңлау, ярату өчен җәй көннәрендә аның урманнарыннан җиләк авыз итәргә, челтерәп аккан чишмәләреннән көмештәй саф суын татып карарга, кыш көннәрендә киртләч тауларыннан чаңгы шуарга, көзге урманнарында йөрергә, җыр-моңнарын тыңларга кирәк.

Монда һәр тау итәге, һәр агач, болындагы һәр чәчәк, кыскасы, һәбернәрсә иҗатка, моңга, шигъриятькә рухландыра. Никадәр талантлы кешеләр чыккан Сарманнан: Аяз Гыйләҗев, Мәдинә Маликова, Клара Булатова, Әзһәр Габиди, Вәсимә Хәйруллина, Рәфкать Кәрами, Адлер Тимергалин, Дамир Гарифуллин, Гөлшат Зәйнәшева, Фәрит Яхин, Хәниф Хәйруллин, Илһам Шакиров, Зөһрә Сәхәбиева, Зөһрә Шарифуллина, Гөлдания Хәйруллина, Фәридә Сафина, Илтөзәр Мөхәммәтгалиев, Гәфифә Гаффарова!

Шушы талантлы кешеләребезнең берсе – СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан-ның атказанган мәдәният хезмәткәре, Г.Тукай, Рафаэль Төхвәтуллин исемендәге әдәби пре-мияләр лауреаты шагыйрә Клара Булатова бездә кунакта.

Клара апа Булатова, сәхнәгә рәхим итегез!

**Алып баручы.** Клара Булатова кебек гаҗәеп сәләткә ия тагын берәр талант иясе бармы икән? Ул үзе риваять булырлык искиткеч зат. Авыр елларда – сугыш чорларында –1943 елда беренче шигырьләре туа. Бу вакытта шагыйрәгә 7 яшь була. 1951 елдан бирле газета, журналларда басылып яши, 1970 елдан – Язучылар союзы члены. 40ка якын китап бастырып чыгарды: Ходай аңа соклангыч аһәң биргән, аны тыңлап сихерләнәсең, рухи ләззәт аласың. Шагыйрьлеге тумыштан, зиһене шаккатырлык, сәгатьләр буе шигырь сөйләп, теләсә кемне авызына каратып тора ала. Клара Булатованың исә аның белән күрешеп сөйләшкән һәр кешене гаҗәпләндерә торган сыйфаты да бар. Ул шигырь белән уйлый, шигырь белән бәхәсләшә. Аның телендә, сөйләмендә – сүз тантанасы.

**Алып баручы.** Хәзер сүзне Клара ханымның үзенә бирәбез. Рәхим итегез, Клара апа, сүз сезгә.

**Клара Булатова сөйли**

**Алып баручы**. Халык күңелен яулап алган шагыйрьләр дә табигатьнең гүзәл, сирәк бүләкләре бит. Якты, саф чишмә кебек бәреп чыккан талант иясе ул – Клара Булатова. Заман үзгәрсә дә үзгәрми торган күңел кылларын тибрәтерлек шигырьләр язучы, үз тавышы булган шагыйрә бит ул. Сезнең игътибарга аның «Үкенмим» шигырен укытучыбыз Фәнүсә Мәгъсүмҗан кызы башкаруында тәкъдим итәбез.

**Алып баручы.** Клара Булатова туган ягы, Сарман ягын якын итеп, үз итеп, аның хуш исле гөлләренә гашыйк булып, үзенең иң ягымлы шигырьләрен иҗат итә. Ә шигырьләре, шигырьләре җырлап тора. «Кеше җанын, кеше рухын яктыртырдай җыр тудырган мәңгелеккә бәхетледер». Клара Булатова сүзләренә Ифрат Хисамов көй язган «Якын дустың барын онытма» җырын 9 нчы класс укучысы Шакурова Эльвина башкаруында тыңлап китәрсез.

**Алып баручы.** Шагыйрәнең күпләр яратып тыңлый, укыганда күздән яшьләр китерә торган «Сиңа кайтам» дигән шигыре бар. Клара апа тәүге мәхәббәтнең, беренче хисләрнең матурлыгын уңышлы табылган чагыштырулар аша укучыга күрсәтеп бирә. Ул аны шулхәтле эчкерсез, шулкадәр самими итеп сөйли ки, шигырьне укыганда син үзең дә геройның хәленә керәсең. Ә бүген исә без бу әсәрне укытучыбыз Кызрачева Нурзия Мәрвәр кызы башкаруында ишетербез

**Алып баручы.** Клара Булатова шигырьләре хис-кичерешләргә бик бай, алардан моң агыла. Шуның өчен дә шагыйрә матур-матур җырлар авторы буларак танылды. 2002 елда «Раннур» китап нәшрияты тарафыннан иҗат ителгән «Үзеннән-үзе туа җыр» китабында Клара Булатованың 75 җыры тупланган. Җырларда туган як, мәхәббәт темасы үзәк урынны алып тора. Шагыйрәнең яшьлек елларында язылган «Кыңгыраулар» җырын укытучыбыз Габдрхманова Гөлназ Расит кызы башкаруында тыңлап китәрсез.

**Алып баручы.** Күңелеңдә рухи төшенкелек вакытында К.Булатованың шигырьләр җыентыгын кулыңа алсаң, бу шигырьләр уйландыра, моңландыра, сөендерә торган җылы хисләр уята. Аның шигырьләре туган якка, иң газиз кешеләр-ата-анага мәхәббәт белән сугарылган. Шундый шигырьләренең берсе – «Татарстан – бәхет җырым син!» Аны безгә укытучыбыз Кәлимуллина Әлфия Нәҗип кызы укып китәр.

**Алып баручы.** Клара Булатова – җор, йөгерек телле балалар шагыйре ул. Аның шигырьләре балалар күңеленә бик җиңел үтеп керә. Юморга бай кызыклы шигырьләрен балалар бик теләп ятлыйлар. Шуларның кайберләрен укучыларыбыздан сөйләтәсе килә: Хөснетдинова Алсу «Әни – егет», Ситдиков Эмиль «Әниемнең кызы юк бит», Шайхлисламов Илмир «Әллә кайсын тыңласы», Кәлимуллина Эльвина «Иптәш», Сафиуллин Булат «Зоопаркта» шигырьләрен сөйлиләр.

**Алып баручы.** Ата-анага булган чиксез хөрмәт, мәхәббәт, аларны ярату хисе шагыйрә иҗатында бигрәк тә ачык чагыла. Шундый шигырьләрнең берсен 3 нче сыйныф укучысы Хасанова Илзинә башкаруында тыңлап китәрбез. «Рәхәт чак».

**Алып баручы.** Укытучылык хезмәте – Клара Булатова иҗатының буеннан-буена сузылган үзәк темаларның берсе. Шагыйрә дөньяга укытучы күзләре белән бага, әйләнә-тирәне укытучы бизмәне белән бәяли, хуплый. Аның гади генә сүзләрдән тезеп язылган юлларында мөгаллимә шәхесенең күңел тирәнлеге, үз хезмәтенә мөкиббәнлеге, иманы ярылып ята. Укый укытучыбыз – Илһамова Эльвира Әзһәр кызы. «Алтынчы класстагылар»

**Алып баручы.** Җырсыз йөрми, моңсыз йөрми
Җаным, йөрәгем.
Гомер буе моңы яши
Миндә берәүнең, – дип яза шагыйрә халкыбызның классик шагыйре Хәсән Туфан турында. Хәсән Туфан – Клара Булатованы талантлы шагыйрә буларак кабул иткән, аңа хәер-фатихасын, киңәшләрен биргән, үзе дә шагыйрәгә байтак шигырьләрен багышлаган атаклы шәхес. «Хәсән абый шигъриятемдә, иҗатымда гомерлек юлдашыма әверелде», – дип яза Клара апа. Х.Туфан шигыренә язылган «Әйткән идең...» дигән җырны лаеклы ялдагы укытучыбыз Әлфия апа Мөхәммәтҗанова башкаруында тыңлап китик.

**Алып баручы.** Туган җир... Туган туфрак... – һәркайсыбыз өчен иң изге төшенчәләрнең берседер... Филология фәннәре кандидаты Рәфкать Шәһиев: «Төбәгебезнең асылын ачкан «Шушы яктан, шушы туфрактан без» дигән җыры өчен генә дә Клара Булатованы җырчы-шагыйрә дип атап булыр иде. Ә аның җырга салынган шигырьләре санап бетергесез», – ди.

Безнең халык гомер буйларына
Юлдаш иткән җырны үзенә.
Колак салган аның моңнарына,
Мәгънә салган һәрбер сүзенә.
Һәр күңелдә, телдә җыр туадыр,
Телдән телгә күчеп яшәргә
Хакы булган моңлы, чын олы җыр
Мирас булып кала яшьләргә.

Сезнең игътибарга бу җырны укытучылар коллективы башкаруында тәкъдим итәбез.

**Алып баручы.** Хөрмәтле китап сөюче дусларыбыз! Шушындый матур әдәби чарабызның кунагы Клара апа Булатовага бирергә теләгән сорауларыгыз бардыр. Рәхим итегез, форсаттан файдаланып, үзебезне кызыксындырган сорауларны бирик әле Клара апага.

**Алып баручы.** К.Булатованың 1967 елда басылган «Язлар алда» дигән тәүге китабының тәүге битендәге «Гел кояшка карап» дигән шигырендә шундый юллар бар:

Күз ачарга төнен теләмәгән
Яшь бөреләр иртән барсы да
Гел кояшка карап, гел кояшка карап,
Гел кояшка карап ачыла.
Ах, минем дә килә киң юлларның
Иң яктысын сайлап аласым.
Гел кояшка карап, гел кояшка карап,
Гел кояшка карап барасым.

Клара апа, шушы тәүге шигырегезнең максатына тугры калып, тормыш юлыгызның иң яктысын сайлап, яшь мөгаллимнәргә, яшь шагыйрьләргә үрнәк булып, матур, игелекле гомер юлын үттегез, үтәсез. Киләчәктә дә олыгаю авырлыкларына бирешмичә, яшәү, иҗат итү дәртен сүрелдермичә, сау-сәламәт булып яшәргә, иҗат итәргә язсын!

Очрашу кичәбез инде ахырына да якынлашты. Сезгә бетмәс-төкәнмәс иҗат дәрте, ныклы сәламәтлек, искәрмәс сөенечләр телибез. Киләчәктә дә безне бәрәкәтле иҗатыгыз белән куандырып яшәгез, исән-имин булыгыз!

Очрашуга килгән барлык китап сөючеләргә, шагыйрәнең иҗат җимешләрен халыкка җиткергән башкаручыларыбызга чын күңелдән рәхмәтебезне әйтәбез, барыгызга да саулык-сәламәтлек, иҗади уңышлар теләп саубуллашабыз, сезнең белән яңадан-яңа очрашулар насыйп булсын!

## Күңелегезгә керәм янган ут булып!

(Клара Булатова иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Газизова Рәмзия Асфан кызы, Бәдертдинова Илсияр Изаил кызы,
беренче санлы Җәлил урта мәктәбе, Сарман районы

**Алып баручы:** Кышкы салкыннардан соң,җир уянып, әллә кайдан, кайсыдыр илаһи тарафлардан өмет һәм яшәү сулышы бөркелгәндә дөньяга шагыйрә туган. Әти-әнисе бу кызларына Клара дип исем кушканнар, туган илен, җирен яратсын, кешеләргә итагатьле булсын, дип теләк теләгәннәр. Аларның теләкләре кабул булган. Чирек гасырдан артык бу кыз балаларга белем биргән, аларны туган илләрен яратырга өйрәткән, бөтен гомерен иленкөнен, халкын яратуы турында шигырьләр һәм җырлар язуга багышлаган.

**1 укучы: «**Еллар, сулар ага» шигыре

**2 укучы:** Шагыйрә Клара Гариф кызы Булатова 1936 елның 18 мартында Татарстанның Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туган. Әти-әнисе укытучылар булганлыктан, Кларага бала чактан ук әти-әниләре белән бер төбәктән икенче төбәккә күчер йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче сыйныфка укырга керә, өченче сыйныфта Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, ә урта белемне 1954 елда Сарман урта мәктәбендә алып чыга. Шул ук елның көзендә К.Булатова хезмәт юлын башлый: Түбән Ләшәү авылы мәктәбенең башлангыч сыйныфларында балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли. 1962-1965 елларда Әлмәт районының Колшәрип авылы балаларына тел-әдәбият, тарих фәннәре укыта.

Клара Булатованың шигъри иҗаты да нәкъ шул дәвердә тернәкләнеп китә. Әле мәктәптә укыган елларында ук аерым шигырьләре матбугатта күренгән яшь каләм бик актив рәвештә Әлмәттәге әдәби түгәрәккә йөри.

**3 укучы:** «Бала чакта» шигыре.

**4 укучы:** 1965-1969 елларда Клара Булатова Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам иттерә. 1967 елда студент кызның «Язлар алда» исемле лирик шигырьләре тупланган беренче китабы дөнья күрә. Университетны тәмамлаганнан соң, К. Булатова Әлмәт районының Яңа Кәшер урта мәктәбендә тел укытучысы булып эшкә китә. Гомумән, гомеренең 40 елдан артыгын ул балалар укытуга багышлый.

**5 укучы: «**Укытучы бәхете» шигыре.

**Алып баручы:** Бөек Ватан сугышы елларының авырлыгы Клара апаның да тормышын читләтеп үтми. («Сугыш чорындагы балачактан» шигыре).

**1 укучы:** Әнидән башланды... Сугыш елларында без яшәгән авылда куыклы лампа дигән нәрсә ике-өч кенә өйдә, аннан соң инде сирәк-мирәк кенә безнең өйдә дә була торган иде. Әни инде эшләми, сәламәтлеге какшады. Укытудан туктады. Безне исән-сау асрау өчен ул төне буе җөй тегә. Мин гел аның янында, ярдәмче тегүче... Әни тегәргә бәйләргә, чигәргә һәм үзе сөйләгән бик күп шигъри һәм чәчмә әсәрләрне тыңларга өйрәтте мине. Баксаң, аңардан бар ишеткәнне мин гомерлеккә күңелемә бикләп-ятлап барганмын икән, – дип искә ала Клара апа үзенең балачагы турында.

**2 укучы**:«Әниемә» шигыре.

**3 укучы:** Клара Булатова – дистәдән артык шигъри китап авторы. Аның нигездә традицион татар шигыре калыбында иҗат ителгән лирикасында тормышта кайгы-хәсрәтен дә, сөенечшатлыкларын да күп күргән хатын-кыз шәхеснең хис-тойгылары, мәхәббәт кичерешләре, гомер турында, туган җир, заман, кеше язмышы, мәңгелек турында фәлсәфи уйланулары, сагыш-әрнүләре сурәтле чагылыш таба. Аның шигъри теле халыкчан гыйбарәтләргә, отышлы чагыштыру-метафораларга бай булуы, фикер-хисләрнең ихласлыгы белән үзенә тарта. Шагыйрәнең күп кенә лирик шигырьләренә Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафларыннан музыка язылган.

**Җыр «Шушы яктан шушы туфрактан без»**

Балалар өчен язган шигырьләрен башлангыч сыйныф укучылары яттан сөйли: «Әниемнең кызы юк бит», «Зоопаркта», «Урамда», «Солдатлар», «Тел белмәү», «Әллә кайсын тыңлыйсы».

**Җыр «Туган көн»**

**4 укучы:** Клара Булатова үзен иң беренче чиратта дөньяның, галәмнең матурлыгын һәм иркенлеген, «тауларның биеклеген», «юлларның яктылыгын», күреп шатланучы, туган

илебезне, «бәхет тулы» туган җиребезне бөтен рәхәте-газаплары, шатлык-кайгылары белән тормышны яратучы, җир, кеше, ил язмышы, кешенең тормыштагы урыны, яшәү мәгънәсе турында уйланучы һәм борчылучы лирик шагыйрә итеп танытты, – дип яза әдәбият тәнкыйтьчесе Равил Лотфуллин.
**5 укучы: «**Бишек җыры никтер ишетелми» шигыре.
**6 укучы:** Шагыйрәнең шигъри тойгылары бик заманча, кешелекле, күңелгә хуш килә торган, теле бик ачык, авылча, саф татарча. Аның иҗаты бик халыкчан. «Можно научиться писать гладкие стихи, а поэтом родиться нужно»,– дигән В.Г.Белинский. Клара Булатова – шагыйрь булып туган кеше, шигырь җанлы, шигырь җенле, фанатик шагыйрә, талантлы, бик популяр шагыйрә ул, – дип яза Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзал.

**Ансамбль башкаруында «Туган җирем» җыры**

**Алып баручы**: Без үзебезнең туган телебез, шул телдә иҗат итүче шәхесләребез белән горурланабыз!

## «Тамчы – шоу» уены

Тәслимә Флер кызы Фәрхетдинова, Алсу Хөсәен кызы Хәмидуллина, икенче санлы Җәлил мәктәбе укытучылары, Сарман районы

**Максат: у**кучыларда якташ язучыларыбыз иҗатына кызыксыну уяту, аларга карата ихтирам, хөрмәт, горурлык, мәхәббәт хисләре тәрбияләү; укучыларның сөйләм телен, дөньяны танып-белү, күзаллауларын арттыру, баету; эзләнергә, мөстәкыйль эшләргә өйрәтү.
**Планлаштырылган нәтиҗәләр.**
*Метапредмет:* якташларыбыз турында мәгълүмат алу.
*Регулятив универсаль уку гамәлләре:* чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру.
*Танып белү универсаль уку гамәлләре:* тиешле мәгълүматны табу, объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү.
*Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:* фикерне төгәл итеп җиткерү; әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү; мәгълүматны туплау өчен кумәк эш башкару.
*Предмет:* үз халкыңның рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләү.
*Шәхескә кагылышлы:* дискуссияләрдә катнашу, үз фикереңне әйтү.
**Җиһазлау:** якташ язучыларыбыз китапларыннан күргәзмә, сораулар язылган карточкалар, компьютер, төрле рәсем слайдлары, Клара Булатова, Әзһәр Габиди, Фәрит Яхин, Хәниф Хәйруллин портретлары, презентация.

Уенда 2 команда катнаша. Өй эшенә визитка әзерләү, исем, девиз сайлау, якташ язучыларның биографияләрен, әсәрләрен өйрәнү һәм командирларга татар халык мәкальләре бәйгесенә әзерләнүләр кирә. Командалар исемнәренә туры китереп төрле костюмнар да әзерли ала.

**Уен барышы**

**Алып баручы:** Хәерле көн, хөрмәтле укытучылар, укучылар! «Тамчы-шоу» уенын башлап җибәрәбез. Безнең бүгенге уеныбыз якташ язучыларга багышлана. Бәйгедә 3, 4 сыйныф укучылары катнаша.

Бәйге булгач, бәйге инде. Уенчыларыбызны бәяләү өчен безгә жюри сайларга кирәк. Хәзер үзләре белән таныштыру өчен сүзне командаларга бирәбез. Сүз беренче командага бирелә.
**Безнең исем:** Тапкырлар!
**Безнең девиз:**
Тапкыр җиңәр, оттырмас,
Сезгә куып тоттырмас.
1.Мин – Кадрия, бик күп укыйм
Быел бик тә тырышам.
Отличник укучылардан

Бераз гына калышам.
2. Рамазан булам, Җәлилдән,
Мин дүртенче сыйныфта.
Бик яратам җырларга,
Тырышам шәп укырга.
3.Ә мин, Риназ, шук малай,
Өлгер малай, ут малай.
Кайчак мине кисәтәләр
Аңламыймын, ник алай.
4. Өченче сыйныфта укыйм
Рузил булам, дусларым,
Биим дә мин, җырлыйм да мин
Спортны да яратам.
<u>Барысы бергә:</u>
Барыбыз да дус һәм тату
Командада дүрт бала.
Сер бирмәскә тырышырбыз –
**«Тапкырлар»** сезнең алда.
**Безнең исем:** Зирәкләр!
**Безнең девиз:**
Зирәк һәр җирдә кирәк,
Тик зирәк ул бик сирәк.
**1.**Мин – Муса, беркайчан да
Девизымны онытмыйм.
Чиста, пөхтә, тиз язам
Өлгер белән дуслашам.
2. Мин, Илназ, бик тырышам,
Һәр көн саен алга барам.
Иптәшләрне дә калдырмыйм,
Үзем белән бергә алам.
3.Исәнмесез, барыгыз да!
Минем исемем Ләйсән.
Туган илемне яратам,
Күгебез булсын аяз.
4. Минем исемем Румиль,
Үзем һәр яктан камил.
Куамын көнчелекне,
Яратам дөреслекне.
<u>Барысы бергә:</u>
Без дә бик тырыш балалар
Командада дүрт кенә.
Көч сынашырга әзер без
Дүрт булсак та төш кенә.
**I тур. Батыр – берне, белемле – меңне егар.**
- Мин сезгә мәкальләрнең беренче өлешен әйтәм, ә сез икенче өлешен әйтеп бетерергә тиеш буласыз.
1 нче команда җавап бирә.
Кем эшләми –.... (шул ашамый)
Дөрес сүзгә –.... (җавап юк)
Иле барның –.... (теле бар)
2 нче команда җавап бирә.
Агач җимеше белән мактана –... (кеше эше белән)
Әйткән сүз –... (аткан ук)
Калган эшкә – ..... (кар явар)

**II тур. Язучыны таны.**

- Менә без икенче турга да аяк бастык. Конвертта язучыларның биографияләреннән өзек бирелгән. Өзекне укып, экраннан шул язучыны табып әйтергә.

... 1936 елның 18 мартында Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туган. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була. Ул башлангыч классларда балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәттәге көнкүреш комбинатында кассир, «Төзүчеләр» клубында оештыручы була. 1962-1965 елларда ул яңадан мәктәптә – Әлмәт районының Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта. Шигырьләре «Гел кояшка карап» исемле күләмле китабында урын алган. (Клара Булатова)

... – Бөек Ватан сугышында катнаша, 17 яшьтә ул армия сафларына алына. 1945 елда япон сугышында бик каты яралана, бер ел дәвамында госпитальдә дәвалана. 1946 елда үз туган авылына кайта. Ул 20дән артык китаплар авторы, шигырьләрнең тематикасы күбрәк аның туган авылы табигатенә багышлана. Балалар шагыйре булып танылса да, аның олылар өчен язылган китаплары да бар (мәсәлән, «Урман читендәге имәннәр без» дип исемләнгән китабы). (Әзһәр Габиди)

... Ул авылда булган барлык үзгәрешләрне җаны-тәне белән тоеп, нәтиҗәдә «Канатлар талмасын», «Картлык – кемгә шатлык» исемле повестьларын язган. «Канатлар талмасын» повесте 1971 елда язылып, башта «Казан утлары»нда (1973 ел, 1, 2 саннар), соңыннан аерым китап булып чыккан. Бу әсәрне укучылар язучының җитди уңышы итеп кабул иткәннәр. (Хәниф Хайруллин)

... Шагыйрь, язучы-прозаик, әдәбият галиме 1961 елның 2 гыйнварында Татарстанның Сарман районы Дүсем авылында туа. 1999 елның августыннан Татар дәүләт гуманитар институтының әдәбият белеме кафедрасы мөдире хезмәтендә. Ул шигырьләр, хикәяләр яза, «Сарман таңнары» иҗат берләшмәсенең актив әгъзасы була. (Фәрит Яхин)

*I , II турлар буенча йомгак ясау өчен сүз жюрига бирелә.*

**III тур. Игътибарлылык ярышы.**

- Экранда сез рәсемнәр күрерсез. Шул рәсемнәрне игътибар белән карап, мөмкин кадәр истә калдырырга тырышыгыз.

Сораулар:

1 командага – Әлеге рәсемнәрдә сез ничә малай күрдегез. (Өч)

2 командага – Әлеге рәсемнәрдә сез ничә песи күрдегез. (Алты)

**IV тур. Видеосорау**

- Игътибар белән тыңлагыз, әлеге шигырьнең авторын әйтегез.

**Күкләргә кара, улым**

(Әби җыры)

Күкләргә кара, улым,
Йолдызлар сана, улым...
Йолдызлар таныган бала
Якты юл таба, улым.
Йолдызың якты булсын,
Юлларың яхшы булсын;
Сүзләрең затлы булсын,
Телләрең татлы булсын (К.Булатова)

**Яз сөңгеләре**

Март иртәсендә абыем
Тыштан шатланып керде.
Ул, көлә-көлә, әнигә:
- Безгә яз килгән! – диде
- Каян беләсең? – дип аңа
Әнием сорау бирде.
Абый аңа: – Яз кыекка
Сөңгеләр элгән! – диде. (Әзһәр Габиди)

**V тур. Капитаннар ярышы.**

- Сорауларга «Әйе» яки «Юк» дип җавап бирергә

**«Зирәкләр» командасы капитанына сораулар:**
1. Әзһәр Габиди Сарман районында туган. (Әйе)
2. Фәрит Яхин Дүсем авылы егете. (Әйе)
3. Без Азнакай районында яшибез. (Юк)
4. Әзһәр Габиди иҗатының зур өлешен өлкәннәргә багышлаган. (Юк)
5. Әзһәр Габиди балалр өчен табышмаклар язган. (Әйе)
6. Клара Булатова урта белемне Азнакай урта мәктәбендә алып чыга. (Юк)
7. Мәктәбебез М.Җәлил урамында урнашкан. (Юк)
**«Тапкырлар» командасы капитанына сораулар:**
1.Клара Булатованың әти-әнисе укытучылар була. (Әйе)
2. Әзһәр Габиди 1950 елда Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый. (Әйе)
3. Якшәмбе – ял көне. (Әйе)
4. Ф.Яхин Казандагы М.Җәлил музееның директоры була. (Юк)
5. К. Булатова 40 елдан артык укытучы булып эшли. (Әйе)
6. Хәниф Хәйруллин тумышы белән Мөслим районыннан. (Юк)
7. Без Әлмәт районында яшибез. (Юк)
**VI тур. Әзһәр Габиди шарадалары, табышмаклары.**
Сүз табышмагының җавабын табыгыз. Игътибар экранга.
«Тапкырлар» командасына:
1. Минем өч хәреф
Ява җәй көне
Чәчәк гөлләргә
Һәм азык була
Нечкә билләргә.
Соңгы икесен
Йөртә бер елга,
Җәен-кышын да
Яшим мин шунда. (Балык)
2. Янымда минем беркайчан
Булмасада сәгатем,
Бар кайсы вакыт икәнне
Әйтә торган гадәтем. (Әтәч)
«Зирәкләр» командасына:
1. Тәүге иҗегем
Бай минем суга,
Соңгы иҗегем
Үсә басуда.
Минем үземне
Һәр кеше сөя,
Шуңа, яратып,
Өстенә кия. (Күлмәк.)
2. Кызыл бантик йөртә үзе
Гомер буе башында.
Үзе кызыл төсне күрсә
Кабарына, ярсына. (Күркә)
**- Ә хәзер сүзне жюрига бирәбез. Рәхим итегез!**
- Бүгенге «Тамчы–шоу» уен備ыз ахырына якынлашты. Татар телен яратыгыз, якташ язучыларыбызны белегез, туган телдә аралашыгыз, бер-берегез белән дус яшәгез.
Җирне саклап кала алмабыз,
Дуслашмаган килеш без.
Шуңа күрә барыбыз да,
Дус булырга тиеш без.
Үскәч тә без дошман булмыйк
Беребез дә.

**Шушы яктан, шушы туфрактан без**
(Әдәби кунакханә)

Мияссәрова Л.К., Шәңгәрәева Н.Н., икенче санлы Җәлил урта мәктәбе, Сарман районы

Максат: Клара Булатованың туган як табигате, туган ил турындагы шигырьләре белән танышу аша татар шигъриятенә карата уңай караш тәрбияләү өстендә эш алып бару.
*Регулятив универсаль уку гамәлләре*: укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү; укудагы уңышларга, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү; уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү.
*Танып белү универсаль уку гамәлләре:* сөйләм берәмлекләрен логик тәртипкә салу; тиешле мәгълүматны сайлап алу; төп мәгълүматны аеру; укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.
*Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:* күмәк эшне планлаштыру; әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый белү.
*Планлаштырылган нәтиҗә:* укучыларның эзлекле фикерләү сәләтен үстерү.

Алып баручылар һәм укучылар чәчәкләр белән бизәлгән өстәлләр артында утыралар. Аерым өстәл артында (анда кәгазь битләре, китаплар, каләм, Клара Булатова китаплары һәм аның портреты). Зал «Туган ягым – гүзәл як» исемле рәсемнәр күргәзмәсе белән бизәлгән. Кичә барышында салмак кына «Гармун моңы» яңгырый. (https://lightaudio.ru/mp3/татар%20 көйләре)

Очрашу «Шушы яктан, шушы туфрактан без» жыры белән башлана (Рәис Нәгыймов көе, Клара Булатова сүзләре). Сәхнәдә кызлар төркеме башкара.

*Бөтендөнья шигърият көненә багышланган видеоролик карау.*

**Алып баручы** Бүген шигърият көне алдыннан ( 21 мартта билгеләп үтелә) «Шушы яктан, шушы туфрактан без» исемле әдәби кунакханәгә чакырабыз. Бүгенге очрашуыбыз якташыбыз Клара апа Булатовага багышлана.

Китапханә дәресләрендә без сезнең белән Клара апа Булатова шигырьләре белән танышкан идек. Аларны укып, без кече Ватанның нәрсә икәнен аңладык. Бу хакта балалар менә нәрсә сөйли. Кызларыбызның фикерләрен тыңлап китик әле: «Минем кече Ватаным – ул минем бистә, минем урам, минем йортым, туганнарым. Ул – һәрвакыт мәхәббәт, бәхет һәм аңлау хөкем сөргән урын. Хәтта әгәр син икенче шәһәргә китсәң дә, син туган як турыда һәрвакыт истә тотачаксың». (Мәрьям). «Кече Ватан – син туган һәм беркайчан да үзгәрмәгән урын ул». (Адилә)

**Алып баручы** Тумыштан, беренче бишек җырларыннан башлап, кеше кайда гына яшәсә дә, үзен үз халкының, үз җиренең бер кисәкчеге итеп тоя башлый. Туган якка, табигатькә, якын кешегә булган мәхәббәтләрен барыннан да бигрәк шигырьләр аша белдерәләр.

Миңа калса, шигырьләр язу – кош кебек оча белү дигән сүз. Моңа өйрәнеп булмыйдыр, ә менә шигырьне аңларга һәркем өйрәнә ала. Бүгенге кичәнең чын хуҗасы – шигърият, ә көтеп алынган кунаклар – шигырьләр булачак.

**Укучы**
Кадерле бу көндә булганың,
Кадерле миңача узганың.
Халкымның бүгене,
Киләчәк гомере,
Син, илем,
Үз җирем,
Үз ягым – Татарстаным!

**Алып баручы** Шундый шагыйрәләрнең берсе – якты, саф чишмә кебек бәреп чыккан талант иясе, халык күңелен яулап алган – Клара Булатова.

**Укучы**

Исәнмесез, минем газизләрем!
Бүз егетләр, сылу кызларым.
Сез барында әле яктыртырбыз
Шигъриятнең нурлы юлларын, – дип керә Клара Булатова укучылар алдына.
Шагыйрә Клара Булатова озак еллар буена укытучы булып эшли.
**Укучы**
Үсеп килгән галәм хуҗалары!
Килер көнгә шулар барасы.
Ә бүгенгә менә минем алда
Орбиталар – парта арасы.
Сорау тулы күзләр сиңа карый:
Бер сораумы, йөзме, меңәүме?
«Белмим» сүзен, куй, юк, әйтә күрмә!
Кичермиләр алар белмәүне.
Син белергә тиеш, укытучы,
Ни сорыйлар – шуны белергә.
Укытучы булу – бу шундый эш –
Белгәнеңне кирәк бирергә.
**Алып баручы** Клара апа балаларны акыллы, тәртипле, шәфкатьле, миһербанлы, инсафлы булып үсәргә өнди. Туган җирне яратырга чакыра. Әти-әниләрне олылауны, хөрмәт итүне таләп итә. Клара Булатова яраткан хезмәтенә бәхетенең югары бер чагылышы итеп карый.
**Укучы**
Сөенечем – таңнан торып,
Эшкә килгән иртәләр.
Шагыйрә бәхет төшенчәсен дә үз һөнәрендә, укытучы хезмәтендә күрә:
Бәхет – шушы укучылар
Кеше булып үссәләр.
Могҗиза тудыра, энҗе бөртекләре коела шагыйрә каләменнән. Аның шигырьләрендә таллар җырлый, өянкеләр елый, каеннар бии. «Безнең як» шигырен укучы сөйли:
**Укучы**
Ипигә ягып ашарлык
Кара җир безнең якта.
Шәл итеп иңгә ябарлык
Яшеллек безнең якта.
Алтынга алыштыргысыз
Хәзинә безнең якта.
**Алып баручы** Клара Булатова даими мәшәкатьләрнең асылында да туган җирнең матурлыгына, күбебез өчен гадәти һәм сизелми дә калганын күрүдән туктамый. Күз алдыбызга жанлы картиналар китереп бастыра, ел фасылларын тасвирлаган шигырьләре гүзәллек дөньясына алып керә.
**Укучы**
Августның да урталары җитә,
Фани дөнья һаман үзгәрештә.
Бал кортлары әле һаман эштә,
Алары да соңгы тибрәлештә.
**Алып баручы** Дөресен генә әйткәндә, шагыйрә табигатьтән бөтен матурлыкны җыя да матур чәчәк бәйләме итеп кешеләрнең үзенә кайтарып бирә.
**Укучы**
Күрми дә калдык бит әле,
Кай арада киттек килеп?
Җыйды җәй яшел итәген,
Көз килә сары сибеп.
Кыр-басу төсен үзгәртә,
Яланнар – ала-тилә.

Ниндидер борчу йөрәктә...
Бу сагыш кайдан килә?
**Алып баручы** «Ак булсын» шигырендә кыш хөкем сөрә. Бар җиһанны аклык-сафлык төсе биләп ала.
**Укучы**
Кар ява, ява урамда
Ак төстә бөтенесе.
Ак булсын!
Аклык – Яңа ел,
Яңа юл. Бәхет төсе.
**Алып баручы** Клара Булатова моңсу көзләрен, ак мамыклы кышларын, көмеш нурга коенган урамнарын, сихри айлы төннәрен үзенә генә хас поэтик бизәкләргә, иҗат фантазиясенә төреп бирә һәм сиздермичә генә могҗиза дөньясына алып керә.
**Укучы**
Урманнарда җиләк уйдыклары,
Мәтрүшкәләр бөрки хуш исен,
Юк, син кара:
Җәйнең бөтен яме
Шул аланга тулган диярсең.
Җырлы урман, иген тулы кырлар
Һәр ягында илнең күп күбен.
Юк, син кара:
Минем өчен болар
Бигрәк якын, бигрәк үз бүген.
**Алып баручы** Әлмәт районының Колшәрип авылында Клара исемендәге чишмә ачылган. Һәр язны март аенда авыл халкы Клара Булатова иҗатына багышланган очрашулар уздыра. Авыл халкы горурлана, чөнки Колшәрип сүзе аның шигырьләрендә еш яңгырый.
**Укучы**
Авылларны күпме күргәнем бар,
Охшаш кебек берсе-берсенә.
Охшаш кебек,
Ләкин алар менә
Колшәрипкә җитми берсе дә.
Урманымы, Дөмәй буйларымы,
Шау чәчәкле урман артымы.
Күз иңләмәс иркен кырларымы, –
Ни-нәрсәсе шулай тарта икән?
Нигә күңелем, еллар узган саен,
Җырлар эзләп шунда кайта икән?
Кай җирләрдә күпме йөргәнем бар,
Гизгәнем бар дөнья иркендә.
Авылларны күпме күргәнем бар –
Колшәрипкә җитми берсе дә.
**Алып баручы** Клара Булатованың иҗаты күпкырлы. Без аны бер генә әдәби кичә кыйсаларында гына өйрәнеп бетерә алмыйбыз. Аның иҗаты буыннан-буынга күчеп укырлык, киң планда өйрәнерлек тирән иҗат. Һәм бүгенге кичәбезне Клара апаның «Иртәгә дә кояш чыгар әле» шигыре белән тәмамлыйсым килә.
**Укучы**
Иртәгә дә кояш чыгар әле
Нурлар сибеп Нәдер өстенә.
Болытларны җилләр куар әле,
Күкләр кайтыр зәңгәр төсенә.
Иртәгә дә кошлар очар әле,
Очар әле таулар өстендә.

Иртәгә дә яшәү дәвам итәр
Бәлки әле безнең өчен дә.
Дәвам итәр яшәү, озак яшәү,
Бергә яшәү шатлык хисендә.
Икеләтә бәхет кичеп яшәү
Шул бер сыңар гомер эчендә.
Иртәгә дә кояш чыгар әле,
Кояш чыгар безнең өчен дә.

Менә шундый очрашулардан яңадан яңа аһәңнәр алып, чылтырап агып торсын! Ә иң мөһиме, Клара апага саулык, сәламәтлек телибез. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт. Киләсе очрашуларга кадәр, сау булыгыз.

**Татарстан – бәхет җырым син!**

(Клара Булатова иҗатына багышланган әдәби кичә)

Нигматуллина Флүзә Әсгать кызы, Яңа Кәшер санатор-интернат мәктәбе, Әлмәт районы

Максат: балаларны Клара Булатова иҗаты белән таныштыру, якташ мөгаллимә-шагыйрә иҗатына кызыксынучанлык тәрбияләү, иҗади сәләтне үстерү өчен этәргеч бирү.
Җиһазлау: Клара Булатованың шигырь җыентыкларына күргәзмә, презентация.

**Кичә барышы:**

Алып баручы:

Исәнмесез, диеп башлыйк әле,
Очрашулар шулай башлана.
Сезнең белән бүген очрашуга
Күңелебез шундый шатлана.

Хәерле көн кадерле укучылар, хөрмәтле кунаклар! Бүген бездә зур бәйрәм, Шигърият бәйрәме. Ә шигърият шәхестән башлана. Ул шәхеснең иҗат җимеше. Иҗат – хыял, үз хыялыңны үзең куып җитәргә омтылу. Ә шагыйрәләр күңеле бигрәк тә хыялга, хискә бай була. Әлмәт ягы җырга, моңга, югары һөнәри дәрәҗәдәге шагыйрьләргә, җырчы-композиторларга бай төбәк.

Әйдәгез, шагыйрә Клара Булатова иҗатына багышланган «Татарстан – бәхет җырым син!» дигән кичәсен башлап җибәрик. **(** Клара Булатова иҗаты буенча слайд**)**

Күкрәгеңнән кара алтын аккан,
Илгә җырлар биргән урын син.
Беркая да китмим туган яктан,
Татарстан – бәхет җырым син!

Клара Булатова

1 нче укучы. Шагыйрә 1936 елнын 18 мартында Татарстанның Сарман районы Татар Карамалы авылында укытучылар гаиләсендә туа.Ул вакытта әтисе Карамалыда мәктәп директоры булып эшли.Шуңа мин Сарман районы Карамалы авылы кызы булып язылганмын, – ди шагыйрә.

…1965-1969 елларда Клара Булатова В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам иттерә: 1965 елда аның шигъри бәйләме «Дуслык» исемле күмәк җыентыкта басылып чыга. Шагыйрәнең исеме тәнкыйтьтә җылы сүз белән телгә алына башлый. 1967 елда «Язлар алда» исемле мөстәкыйль китабы – лирик шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

2 нче укучы. Аның иҗатында туган телгә, илгә, халкына булган мәхәббәткә таң калырлык.

3 нче укучы.

...Кояшта пешеп, тып-тыгыз
Башаклар тулган чакта.
Алтынга алыштыргысыз
Хәзинә безнең якта. («Безнең як» шигыре)

4 нче укучы.

...Синдә кердем шигырь дөньясына,
Шигърияттә яшим яшь көйләй;
И Әлмәтем, мин бит гашыйк сиңа,
Вакытлыча түгел, бөтенләй. («И Әлмәтем!» шигыре)

Алып баручы: Һәр күзәнәгенә шагыйрьлек рухы сеңгән Клара апа очрашулар вакытында сорауларга бик теләп җавап бирә. Әдибә авызыннан чыккан тирән мәгънәле һәр сүзне укучылар рәхәтләнеп тыңлыйлар. Аның сөйләмендә, үз-үзен тотышында балаларны чын күңеленнән ярату канлыгы күренеп тора. Шуңа шигырьләре дә җиңел языладыр. Күп кенә шигырьләрендә ул Ана булып та, бала булып та уйлый.

5 нче укучы.

...Күмелми үткән яшьлек эзләре,
Күңел түрендә сөю сүзләре...
Сез һаман шулай хуш исле микән,
Дөмәй буеның зәңгәр гөлләре? («Яшьлекне сагыну» шигыре)

6 нчы укучы.

...Әниемә ул чак бик тә авыр
Икәнлеген күрә идек без.
Бала күңеле барын белмәсә дә,
Тоя идек, сизә идек без. ( «Бала чакта» шигыре)

7 нче укучы.

Кырларда буран икән.
Юлларга салган микән?
Инде туган авылымда
Бөтенләй калмам микән? («Кырларда буран икән» шигыре)

8 нче укучы.

Ник көенәм дигәндә,
Ник борчылам дигәндә-
Чирләп-нитеп китмәгәе:
Улым йөри идәндә. («Ана шатлыгы» шигыре)

9 нчы укучы.

Бәхетемдер, бөртегем,
Кашым, күзем, керфегем,
Ай-кояшым, йолдызым,
Үз тамырым, үз улым. («Бергенәм» шигыре)

10 нчы укучы.

Күп кенә шигырьләре туган якны сагыну, горурлану хисләре белән сугарылган:

Ә туган як – ул диңгезсез иде,
Кыр-басулар диңгездәй киң иде,
Кайда гына йөрмик, шул якларда
Сагынуыбыз диңгезгә тиң иде.
Диңгездә гөжли акчарлаклар,
Бездә гөрли әнә күгәрченнәр.
Акчарлаклар күчкән җирдәгеләр
Безнең яктан әле көнләшерләр. «Безнең яктан әле көнләшерләр» шигыре

Алып баручы: Клара апа Булатова «Сиңа кайтам…» шигырендә үткән белән хәзерге тормышны бик матур итеп тасвирлый.

...Шунда кайтам, гомеремне,
Бер бөтенгә җыйсам әгәр!
Зәңгәр кигән зәңгәр җәйләр,
Әйтерсең лә, кичә генә. ..
Зат киемнәр, күр, никадәр,
Туфлилар дә ничә менә!
Агы да бар, күге дә бар,

Карасы да, кызылы да.
Тик танцыга аны киеп
Йөри күрше кызы гына…
Ә мин, кайтып шул җәйләргә,
Шул чүәктән йөрер идем…
Чәчләремне, тасма тагып,
Толымнарга үрер идем.
Иңнәремә көянтә асып,
Чишмәләргә төшәр идем…
Әкрен атлап, вак-вак басып,
Сезнең турыдан үтәр идем.
Чүәктән дә танцыларга
Йөрер идем, киеп зәңгәр…
Сиңа кайтам…
Кайтыр идем, гомеремне
Кыл урталай бүлсәм әгәр.

Алып баручы: Безнең бүгенге бәйрәмебез йөзек кашы булган шагыйрәбез – Клара Гариф кызы Булатовага багышланды.

Клара апа Булатова – чын мәгънәсендә милләтебезнең күренекле шәхесе, атаклы укытучы. Әлмәт җирлегендә яшәп, шунда иҗат итеп, безне искиткеч шигъри әсәрләре белән сөендерә алуы – безнең өчен чиксез горурлык!.

Кичәне йомгаклап «Шушы яктан, шушы туфрактан без» җыры башкарыла.

## Умножение натуральных чисел и его свойства

(интегрированный урок в 5 классе на тему:
с применением биографии поэтессы, заслуженного работника культуры Татарстана Булатовой Клары Гарифовны)

Афзалова Луиза Акрамовна, Салимгараева Альфия Мидхатовна, учителя
МБОУ «Джалильская СОШ №2», Сармановский район

***Тип учебного занятия:*** закрепление и обобщение темы «Умножение натуральных чисел»
***Цели учебного занятия:***
***Образовательные:*** Обобщить и закрепить знания учащихся по теме «Умножение натуральных чисел» с использованием биографии Клары Булатовой.
***Развивающие:*** создать условия для развития у учащихся умения структурировать информацию; развитие познавательной деятельности; содействовать развитию у школьников интереса к изучению жизни и деятельности писателей родного края.
***Воспитательные:*** содействовать развитию дружеского отношения друг к другу; создать условия для развития у школьников стремления к познанию; воспитывать усидчивость и трудолюбие; нравственные качества на личном примере К.Булатовой.
***Оборудование***: портрет Клары Булатовой, мультимедиа-проектор, индивидуальные карточки.

### ***Ход урока***

**1. Организационный момент.**

Учитель математики: Здравствуйте, ребята. Сегодня у нас необычный урок. Мы с вами не только будем вычислять, но и познакомимся с творчеством поэтессы, заслуженного работника культуры республики Татарстан, лауреат премии имени Р.Тухватуллина, которая родилась в Сармановском районе. Выполнив вычисления и сопоставив к полученным ответам буквы, мы узнаем её имя и фамилию.

Выполните действия:

| | |
|---|---|
| 12*51 | 336 Л |

| | |
|---|---|
| 14*24 | 986 Р |
| 32*60 | 1925 А |
| 986*1 | 612 К |
| 385*5 | 1920 А |
| 122*4 | 195 Л |
| 20*404 | 488 Б |
| 15*13 | 222 Т |
| 47*12 | 8080 У |
| 111*2 | 564 А |
| 24*10 | 0 В |
| 123*0 | 240 О |
| 25*4 | 100 А |

Ответ ученика: Клара Булатова

Учитель истории: Клара Булатова родилась 18 марта в деревне Татарские Карамалы Сармановского района ТАССР в семье учителя. Чтоб узнать ещё некоторые факты из её жизни перейдем к следующему пункту.

**2. Актуализация знаний**

Учитель математики: вычислите, выбрав удобный порядок действий

1) 50*(2*19) + 36 ответ (50*2)*19+36=1936
2) (125*2)*8 -59 ответ (125*8)*2-59=1941
3) 2*(4*125) +956 ответ (2*125)*4+956=1956
4) 25*(37*4)-3600-90 ответ (25*4)*37-3600-90=10

Учитель истории: вычислив эти примеры, вы ответите на вопросы:
1. В каком году родилась Клара Булатова? (1936)
2. В каком году Клара Булатова поступает в первый класс? (1941)
3. В каком году переезжает в г. Альметьевск? (1956)
4. Сколько лет Клара Булатова проработает в телерадиокомпании «Нур»? (10 лет)

Учитель математики: какими свойствами вы пользовались при решении данных примеров? Правильно, сочетательное свойство умножения.

**3. Решение задачи (работа в парах)**

Задача. Бочка вмещает воды в 9 раз больше, чем 4 ведра. Сколько литров воды вмещает бочка, если в одно ведро входит 8 л воды?

Решение:
1) 8*4=32(л) вмещают 4 ведра
2)32*9=288(л) вмещает бочка.
Ответ: Бочка вмещает в себя 288 литров воды

Учитель истории: А теперь послушайте интересную историю из жизни Клары Булатовой про бочку.

Это было в сентябре, пишет Клара Булатова. Я училась в 6 классе. В том году осень, как ни странно, была очень теплой. Даже в сентябре мы купались в пруду недалеко от Петровского завода. Однажды наш одноклассник (довольно-таки хулиган) на запряжен-ной быками телеге вёз с Петровского водочного завода в сторону деревни Ляки бочку с бардой. (Барда – это такая жидкость, очень полезная для скотины, образуется из остатков зерна или картошки). Когда он переехал через мост, телега его накренилась, и бочка упала на землю. Мальчик один не может положить бочку в телегу. Мы, девочки, в это время находились в воде и конечно, никак не можем ему помочь. Со стороны деревни Ляки в сторону завода по дороге шагает один русский мужик Метери (Дмитрий). Мальчик увидел его и закричал: «Уйди сюда! Уйди сюда!» Бедный мужик, услышав слово «уйди», уходит. Это повторяется несколько раз! В конце концов он всё-таки помог мальчику положить бочку.

На следующей день в школьной стенгазете вышло в свет мое стихотворение. Содержание примерно было таково:

Не надо быть таким слабым, надо уметь управлять быками так, чтобы бочка не упала; Зовешь «Уйди сюда!» – а как поймет этот русский? Или «иди сюда», или «уйди отсюда»?


Учитель: Послушаем подготовленные сообщения о фактах из биографии Клары Булатовой.
Ученик1: В 1941 году поступает учиться в первый класс Верхнее-Чыршылинской школы.
В 1954 году заканчивает Сармановскую школу. После чего начинает работать учителем начальных классов в Нижнее-Лешевской школе Сармановского района.
В 1965-1969 гг. обучалась в Казанском государственном университете.
С 1969 года, после окончания университета, начинает преподавать татарский язык и литературу в Ново-Кашировской средней школе Альметьевского района.
10 лет преподает в Альметьевской татарской гимназии.
Более 8 лет ведёт уроки татарской литературы в Альметьевском муниципальном институте.
Ученик 2*:* 10 лет работает в телерадиокомпании «Нур» в городе Альметьевске (с 1991 года).
В 1967 году выходит в свет самостоятельная книга под названием «Вёсны впереди» (сборник лирических стихов).
В 1972 году издается книга «Когда наступит лето».
В 1986 году в связи с 50 летним юбилеем в Татарском книжном издательстве издается книга «Сенокос».
В 1989 году издается сборник под названием «Окна памяти».
Издается сборник прозаических произведений «Зеленое перо» в издательстве «Рухият» («Духовные ценности»).

**4. Творческая работа**

Пугало

В огороде пугало
Дедушка поставил.
Но рукой размахивать
Грозно не заставил.
Птицы все слетаются,
Ягоды клюют.
Жить спокойно дедушке
Снова не дают.
Он ворчит на пугало:
-Головой поник...
Даже не шевелишься.
Как седой старик!
Взялся Марс из сада
Выдворить всех птиц.
На сарай кормушку
Вынес для синиц.
Вдоволь им насыпал
Семечек, пшена.
Не летает в ягодник
Птичка не одна.
Все теперь довольны:
Сытный есть обед.
И в саду гуляет
Без ворчанья дед.

Учитель математики: мы послушали стихотворение, а теперь давайте разукрасим пугало. На ваших столах рисунок пугало, нужно вычислив примеры, разукрасить соответсвующими цветами.



| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 470 | 515 | 144 | 1010 | 1000 |
| красный | зеленый | желтый | синий | черный |

**5. Физкультминутка**

**Пляши, сынок!**

Выйди в круг, сыночек! (дети встают из за парт)
Топни-ка ногой!
Засветись цветочком, (поднимают, разводят в стороны руки)
Запылай зарей. (выполняют наклоны влево-вправо)
Мне порадуй душу, (наклоны вперед)
Людям покажи,
Как плясать умеешь (любые плясовые движения)
Без кривляний, лжи.

**6. Рефлексия**

Синквейн.

1. Клара Булатова.
2. Талантливая, интересная.
3. Творит, раскрывает, учит.
4. Герои ее произведения – дети, жители села, пугало, птицы и животные…
5. Автор книг, поэтесса, заслуженный работник культуры, наша землячка.

А теперь, ребята поднимите сигнальные карточки с вашим настроением.
У нас тоже нисколько оно не изменилось. Урок закончен, друзья, до скорого свидания!

**7. Подведение итогов**

Окончен урок, и выполнен план.
Спасибо, ребята, огромное вам
За то, что упорно и дружно трудились,
И знания точно уж вам пригодились.

А теперь, внимание, домашнее задание: Придумать и творчески представить задачу по теме «Мой край родной».

## Земляки юбиляры

(классный час для обучающихся начальных классов)

Шайхелисламова Л.Ф., Бариева Ф.Ф., учителя начальных классов

Цель: познакомить с земляками юбилярами 2021 года: Азгаром Габиди, Кларой Булатовой, Рустамом Яхиным, Ханифом Хайруллиным. Развивать интерес к изучению произвдений и работ известных земляков.
Оборудование: ноутбук, проектор, экран, выставка из газет и книг, портреты.

- Конференция, которая будет проходить в нашей школе в этом году, будет посвященна сразу четырём нашим землякам. А именно: 95-летию со дня рождения поэта, заслуженного работника культуры ТАССР Азгара Габиди, 90-летию со дня рождения писателя, журналиста, заслуженного деятеля культуры ТАССР Ханифа Хайруллина, 85-летию поэтессы, лауреата премии имени Г.Тукая Клары Булатовой, 60-летию поэта, прозаика, доктора филологических наук, заслуженного работника культуры Татарстана и России Фарита Яхина.

На сегодняшнем классном часу мы познакомимся с ними, их деятельностью и творчеством.

**Азгар Габиди (портрет).** Азгар Габиди (Азгар Самигуллович Габидуллин) родился 25 сентября 1926 года в селе Чукмарлы Сармановского района Татарстана. Учился в Сармановской средней школе, в 1943 году ушел на фронт. Вернувшись с поля боя после ранения, в 1950 году окончил Мензелинское педагогическое училище. В течение тридцати лет преподавал татарский язык и литературу в средней школе.

С 1942 года А. Габиди занимается литературным творчеством. Большая часть его творчества посвящена детям. Его книги сыграли большую роль в воспитании подрастающего поколения добросовестным и порядочным, старательным и трудолюбивым. Поэт пишет стихи и для взрослых. А. Габиди награжден орденами Отечественной войны I и II степени, медалью «За отвагу». Ему были присвоены почетные звания «Отличник народного образования», «Заслуженный работник культуры Республики Татарстан». Он умер 22 августа 2001 года.

- Послушаем стихотворение Азгара Габиди «Люблю тебя, солнышко».

**Ханиф Хайруллин** (портрет) Родился 12 сентября 1931 года в селе Сарманово. Окончил Сармановскую среднюю школу (1950). После окончания средней школы год преподавал в школе села Азалаково Сармановского района. Желая получить высшее образование, отправился в Казань, поступил в Казанский государственный ветеринарный институт. Это учебное заведение не понравилось будущему писателю, и он перешел на отделение татарского языка и литературы Казанского государственного университета. В 1956-1993 годах работал в Сармановской районной газете (сначала «за высокие урожаи», затем «Ленинчы» (ныне «Сарман»).
До последних дней жизни жил и творил в Сарманово. Умер в 1998 году.

Писатель, заслуженный работник культуры ТАССР (1981г.). В центре его творчества – романы, повести, очерки о переменах, происходящих в деревне, о прошлом родного края. Новеллы «Высота» («Канатлар талмасын», 1974г.), «Старость - не радость» («Картлык - кемгә шатлык...», 1976г.), сборник «Повести» («Повестьлар», 1981г.).

**Клара Булатова (портрет)** Родилась 18 марта в деревне Татарские Карамалы Сармановского района ТАССР в семье учителя. Окончила Казанский государственный университет имени В.И.Ульянова Ленина. Живет в Альметьевске. Работала на строительных площадках, художественным руководителем в клубе «Строитель» рабочего поселка, в сельских библиотеках. Более тридцати лет активно участвует в художественной самодеятельности. Клара Гарифовна – поэтесса, заслуженный работник культуры Татарстана, лауреат премии им. Р.Тухватуллина, С.Сулеймановой, Г.Тукая. Она посвятила всю свою творческую деятельность воспеванию красоты альметьевской земли, труды нефтяников, тружеников сельчан. (Чтение наизусть стихов К.Булатовой)

**Фарит Яхин (портрет)** Родился 2 января 1961 года в деревне Дусюмово Сармановского района Татарстана. Закончил среднюю школу в родной деревне в 1978 году и поступил на историко-филологический факультет Казанского университета. В июле 2000 года защитил диссертацию на тему «Мистика и мифология в татарской литературе» на соискание доктора

филологических наук. В январе 1993 года назначен директором Литературного музея Г.Тукая (г.Казань). В 2004 году получил звание профессора. В 2005 году профессор кафедры татарской литературы КФУ.

Основные направления научных исследований: журналистика, теория литературы, средневековая литература тюркских народов, история татарской литературы, исламоведение, рукописные книги и источники.

- Ребята, мы сегодня с вами познакомились с нашими земляками, юбилярами 2021 года. Что вам больше всего запомнилось из сегодняшней классного часа? Какие чувства вы испытали слушая стихи?

## Клара Булатованың «Март башында» шигыре белән танышу

Кәримова Зөлфирә Равил кызы, Юлтимер балалар бакчасы тәрбиячесе,
Сарман районы

Бурычлар: Клара Булатованың тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру; Клара Булатова әсәренә кызыксыну уяту, язучы шигыре аша балаларда язгы табигатьтәге үзгәрешләр турында күзаллауларын киңәйтү; балаларның фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү.

Җиһазлар: К.Булатова портреты, ноутбук, проектор, презентация

**Эшчәнлек барышы**

1. Клара Булатованың портретын карау. Язучының тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат бирү.( слайдлар ярдәмендә)
2. К.Булатованың «Март башында» шигырен уку

Кара карга төшкән карга,
ак сызыктан –
Кыш ягыннан яз ягына
сикереп чыккан.
Чыбыкларда чыпчыклар да
сикерешәләр,
Яз килде дип чыркылдаша,
сөенешәләр.
Күгәрченнәр гөрелдәшә
гөлдер-гөлдер!
Март башланды, карлар эрер,
карлар эрер.
Ә урманда бар да яңа
кызык тапкан:
Өнендәге аю сыңар
күзен ачкан,
Бер ботактан бер ботакка
күчә-күчә
Тиен бии, тукран җырлап
кайры тишә.
Куяннар да бәйрәм ясап
алмакчылар,
Кышын кигән ак туннарын
салмакчылар.
Март башланды. Җир уяна,
көн яңара,
Кыш ягыннан яз ягына
очып бара!

Балалар, шигырьдә кайсы ел фасылы турында сүз бара? (Яз.)

- Яз көне иң беренче булып нинди кошлар кайткан?

- Кышлаучы кошлар яз килүгә ничек сөенәләр?
- Җәнлекләр ничек шатлана?
- Яз килгәндә табигатьтә тагын нинди үзгәрешләр була? (кояш, һава торышы, көн озынлыгы турында сораулар бирү)
- Сез язны ни өчен яратасыз?

3. Балалар, яз – ул кышкы озын йокыдан уяну, яктыга, җылыга, кояшка омтылу вакыты. Табигатьуяну белән өйләргә Нәүрүз бәйрәме килә. Нәүрүз – кышны озату, язны каршылау бәйрәме. Безнең бабаларыбыз элек Нәүрүз бәйрәмен үткәргәннәр. Балалар, яшьләр, йорттан-йортка кереп, Нәүрүз әйтеп йөргәннәр. Хуҗаларга бәхет, уңыш теләгәннәр. Нәүрүз бәйрәме шулай ук «Карга туе» дип йөртелгән һәм бу көнне «карга боткасы» пешергәннәр. Бала-чага, такмаклар әйтешә-әйтешә, барлык кешеләрдән ярма, тоз, май, йомырка җыйган. Аннары бөтенесе инеш буенда, зур казан асып, иң оста хуҗабикәдән ботка пешерттергәннәр.

4. Хәзер бергәләп тел көрмәкләндергеч өйрәник.

Карга килер – казан асар,
Торна килер – тоз салыр,
Саескан килер – салма салыр,
Песнәк килер – пешерер,
Чыпчык килер – төшерер.
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Кечкенә түти туймый калыр,
Кетер, кетер, кетер,
Казан төбен кимер...

Йомгаклау. Тәрбияче шөгыльгә йомгак ясый.

**Туган ягым әле онытмас…**

(фронтовик-шагыйрь Әзһәр Габиди иҗатына әдәби кичә эшкәртмәсе)

Ганиуллина Римма Ясир кызы, Сарман гимназиясе педагог-китапханәчесе,
Сарман районы

Максат: Туган якка мәхәббәт хисләре тәрбияләү; укучыларда туган җир, аның кешеләре белән горурлану хисе тәрбияләү; Әзһәр Габидинең тормышы һәм иҗаты белән таныштыру.

Җиһазлау: Ә. Габидинең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган «Янсын гомер учагы» күргәзмәсе.

Цитата: Күзләр булса да кыраулы.
Алтын аның кочагы,
Сүнмәсен әле, сүнмәсен
Янсын гомер учагы.

мультимедия проекторы, презентация, аудио һәм видеоязмалар.

1 бүлек: «Мин зәңгәр тау улы».
2 бүлек: «Шигъри дөнья тылсымчысы».
3 бүлек: « Гомер көзем».

**Кичә барышы:**

Язмада Илһам Шакиров башкаруында татар халык җыры «Сарман» яңгырый

Китапханәче: (1слайд) Туган як... Һәркемгә якын, изге төшенчә. Беренче тапкыр җиргә аяк басудан башлап гомернең соңгы көннәренә кадәр ул безгә көч, таяныч бирә, онытылмас моң булып озатып йөри.

Тропикта да,
Салкын котыпта да
Булганым бар-таныш бөтен як.
Ләкин, Сарман, һич кенә булмады
Сине уйламый торган чак,

– дип яза үзенең «Бер сүзем бар, дуслар» шигырендә үзебезнең якташ шагыйребез Әзһәр ага Габиди. Әйе, җырларда җырланган зәңгәр таулы Сарманнан булуыбыз белән бик

горурланабыз без. Челтерәп аккан чишмәләре, киң кырлары, халкының күңел байлыгы, туган телгә мәхәббәте күпме җырчыларга, шагыйрьләргә, язучыларга илһам биргән. Кичә башында яңгыраган «Сарман» җырын да кем башкарды? Әлбәттә, безнен легендар җырчыбыз, якташыбыз ИлҺам ага Шакиров. Тагын Сарман районында туган нинди жырчылар, язучылар, шагыйрьләр һәм күренекле кешеләрне беләсез?

**Балалар:** Диләрә Зөбәерова, Мәдинә Маликова, Дамир Гарифуллин, Хәниф Хәйруллин, Адлер Тимергалин, Рәфкать Кәрами, Морад Рәмзи, Гөлдания Хәйруллина, Зөһрә Сәхәбиева, Аяз Гыйләҗев, Зиннәт Хәсәнов, Изаил Зарипов, Вәсимә Хәйруллина, Соббух Рафыйков, Нияз Акмал, Фәрит Яхин, Клара Булатова

Сарман ягы талантларга бай. Бүгенге көнгә Сарман якларыннан 25ләп шагыйрь һәм прозаик үсеп чыкты. Бу кадәр язучының әлегә Арчадан кала республикабызның бер генә төбәге дә бирә алганы юк. Шулар арасыннан балалар һәм зурлар өчен дә матур-матур шигырьләр иҗат итүче шагыйребез Әзһәр ага Габидине дә атарга була.

Бүгенге кичәне якташыбыз Чукмарлы авылында яшәп иҗат иткән фронтовик-шагыйрь, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы Әзһәр ага Габиди иҗатына багышлыйбыз. Без аны шагыйрьнең үз сүзләре белән « Туган ягым әле онытмас…» дип атадык.

Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин 1926 елның 26 сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында урта хәлле крестьян семьясында туа. Җидееллык мәктәпне бетерә, Сарман урта мәктәбендә укып, унынчы классны тәмамлый. Беренче шигырьләре районның «Югары уңыш өчен» газетасында дөнья күрә. 1943 елда фронтка китә һәм яраланып, госпитальләрдә ята. 1945 елда «Тревога» исемле фронт газетасы типографиясендә аның «Борылмалы юллардан» исемле китабы басыла. Әзһәр ага 1947-1950 елларда «Чулпан» колхозында хисапчы ярдәмчесе, хужалык мөдире булып эшли. Минзәлә педагогия училищесын тәмамлагач, Ләке, Морбаш, Чукмарлы сигезьеллык мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Берара район газетасында да эшләп ала. 17 яшендә башланган иҗатын дәвам итә.

Әзһәр ага Габиди үзенең иҗатында милләтебезнең үткәне һәм киләчәге, бетеп бара торган авылларның үкенечле язмышы, көннән-көн коргаксый барган табигать, сөенечле һәм үкенечле мәхәббәт, сугыш чоры хатирәләре, сагындыргыч яшьлек һәм башка бик күп темаларны ачып сала. Әзһәр ага, кайсы гына темага алынмасын, фәкать үзе белгәнне һәм йөрәк аша кичергәнен яза.

Әзһәр ага Габиди башлыча балалар шигъриятенә хезмәт итте. Язучының бүгенге көнгә балалар өчен «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Калган эшкә кар ява», «Таң сәгате», «Без – яз дуслары», «Югалган кояш» китаплары дөнья күргән.

Әзһәр ага Габидинең балалар өчен язган шигырьләре туган як, андагы вакыйгалар, күренешләр турында. Аларның һәркайсына шагыйрь балалар күзлегеннән карап бәя бирә.

Ә хәзер, балалар, сезнең игътибарга Әзһәр ага Габидинең шигырьләрен үзебезнең гимназия укучылары тәкъдим итә.

**Балалар чыгышы:** (6 слайд) Аның шигырьләрендә, синең үз күңелеңдә туып та, әлегәчә сүзләргә әверелмәгән хисләр, уй-тойгыларның өермәсе белән очрашкандай буласың. Туган ягы Сарман төбәгенең кабатланмас гүзәл табигатен, аның хезмәт сөйгән халкын олылады, гашыйк булып язды, сагынып язды шагыйрь. («Сагындым» шигыре укыла).

Бу кадәрле сагынырмын диеп,
Уйламаган идем, Сарманым.
Күз алдыннан китми айлы кичең,
Истән чыкмый алсу таңнарын.
Күз йомдыммы – төшләремә керә
Чәчәкләре зәңгәр тавымның
Һич яшермим сездән: туган якның
Әременә кадәр сагындым.

Туган якка мәхәббәте, табигатькә хөрмәте аның бик күп шигырьләрен җыр итте.

Әзһәр Габиди сүзләренә Валерий Әхметшин, Илгиз Закиров, Зөфәр Сәхәбиев, Равил Курамшин һәм үзебезнең гимназиянен җыр укытучысы Гөлнара Рәис кызы Әзһәр

Габидинең «Тургай» шигыренә җыр иҗат итте. Үз жырын башкаруын Гөлнара Рәис кызыннан сорыйк әле.

**«Тургай» жыры**

Гамьсезлек, битарафлык, заманга, аның авырлыгына төкереп карау – авторга ят сыйфат булды. Аның шигырьләре биографик төсмер ала, шагыйрь гүя йөрәген укучысы каршына ачып сала.

Ялгышулар, югалтулар
Булмас, димим, булмый калмас.
Йөрәгемдә кешеләргә
Мәхәббәтем һич тә суынмас.

Әзһәр Габинең нәселен дәвам итүче 6 баласы бар. Гимназиябездә информатика укыткан, хәзерге көндә Әзһәр аганың оныкчыгын үстерүче Миләүшә Марс кызының әнисе, Әзһәр Габинең кызы Гөлнур ханым бездә кунакта. Ул Илексаз авылы мәктәбендә нәкъ әтисе кебе үк балалар укыткан. Әтисе турында сөйләүне аннан сорыйк әле.

**Гөлнур ханым чыгышы. (**Бүләк бирү)

Әзһәр ага шигърияттә дә үзенә әллә нинди олы исемнәр, бетмәс-төкәнмәс дан өмет итеп яшәми. Ул бөтен барлыгын, бөтен күңелен шигырьләренә салган һәм үзе дә шигырьләре кебек үк гади, моңлы, кайнар булды. Әзһәр ага Габиди I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнде. Аңа «Халык мәгарифе отличнигы», «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр бирелә. Әзһәр ага Габиди – 1994 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Сарман районының Чукмарлы авылында яшәп иҗат иткән ялкынлы әдип Әзһәр ага Габидинең безгә бай мирасы – ихлас хис белән язылган шигъри тәлгәшләре калды.

Галиләрдән генә тормый тормыш
Зурдан булмаса да кылганнар.
Әрләпт үгел, тик сагынып кына
Искә алсын мине Сарманнар.

Әзһәр ага Габиди иҗат сандыгындагы татлы җимешләрнең барчасын да безгә тулысынча тезеп яшәде. Һәркайсыбызга бик тә таныш, якын булган, үзенең фәлсәфи-лирик, нәфис-тәэсирле шигырьләре белән күңелләребезне яулаган мөхтәрәм Әзһәр агабыз бу якты дөньяда юк инде. Үзе булмаса да, шигырьләре яши, матурлыкка өнди, уйландыра... («Мәйдан» журналы, 2006 ел, 96 бит «Туган ягым әле онытмас»)

Бу шигъри юлларга өстәп: «Сине Сарман гына түгел, җөмһүриятебез, бөтен татар халкы беркайчан да онытмас дип кабатлыйбыз».

Һәр шагыйрь үз иҗатында үткәне, бүгенгесе, киләчәкне чагылдырырга омтыла, чын шигърият шулай гына яши ала, шуның белән генә кадерледер ул.

Тукай төсле сөйде туган җирен,
Такташ кебек тугры иҗатка.
Каһарман ул Муса Җәлил кебек,
Ул лаеклы данга-хөрмәткә.
Тыныч йокла гадел, горур шагыйрь,
Син яуладың иҗат үрләрен.
Безнең хәтерләрдә маяк булып,
Янып торыр бөркет күзләрең...

Шагыйрь китте, әмма аның шигырьләре безнең белән яши.Талантлы шагыйрьнең иҗаты мәңгелек. Әзһәр Габиди безнең күңелләрдә мәңге яшәр дигән теләктә калабыз.

## Клара Булатова поэзиясенә хас тел-стиль үзенчәлекләре

(Дәрестән тыш эшчәнлек өчен фәнни-тикшеренү эше)

Салихова Гөлнара Атлас кызы, Яңа Кәшер санатор-интернат мәктәбе, Әлмәт районы

Кереш. Һәр әсәр авторы – үзе бер шәхес. Һәр шәхескә тирә-яктагы күренешләрне, яңалыкны, вакыйганы үзенчә кабул итү хас. Мәсәлән, бер язучы, алсуланып таң атып килүен бер төрле күрсә, башка язучы шушы ук күренешнең нәкъ бүтән ягын, теге язучы күреп бетерә алмаган икенче матур ягын күрергә мөмкин. Язучы, теге яки бу күренешне тасвирлаганда, шәхси якын килә, үзенә хас стиль үзенчәлекләреннән файдалана.

Фәнни эшебезнең максаты: якташыбыз шагыйрә Клара Булатова кулланган тел-стиль үзенчәлекләренең кулланылышын тирәнрәк өйрәнеп, киң катлау укучыга тарату, популярлаштыру. Бу максаттан чыгып, авторның «Якты сагыш», «Каурый канат – Җил Атым» җыентыгындагы төрле темаларга иҗат ителгән шигырьләре файдаланылды.

Бүгенге көндә бай әдәби мирасы булган шагыйрә Клара Булатова исемен телгә алу белән, изге күңелле, тыйнак, эшчән, юмарт, рухи бай гап-гади кешеләре, үз заманының ашкынулы уй-кичерешләрен, оптимистик күтәренке рухын чагылдырган Яшьлек, Мәхәббәт, Туган як җырчылары, Сәвәләй тау итәкләре, Дөмәй буеның зәңгәр гөлләре, «чалгы пычак белән кыра-кыра ике сайгак идән юган ике нәни кызчык»лары һ.б. бер-бер артлы күз алдыннан уза. Шигырьләрен укыган саен шагыйрәнең сурәтләү осталыгына таң каласың, шуңадыр да алар ялыктырмый, туйдырмый. Ә бу үз чиратында шигырьләренең аһәңлелеге, сүзләрнең күңелгә ятышлы булуы белән дә аңлатыла. Ә шигырьләрендә -сагыну да, сөеп-сөелү дә, мәхәббәттән янып-көю дә, үгет-нәсыйхәт тә, шатлану-боегу да, бөтен авырлыкларны, кайгыларны җиңеп чыгуга ышаныч та бар.

Төп өлеш. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, кеше күңеленә әхлакый тәрбияви орлыклар салу, уй-фикер һәм кичерешләргә үз мөнәсәбәтен белдерү өчен Клара Булатова барлык тел-сурәтләү чараларына да мөрәҗәгать итә. Хәзер шуларның берничәсенә тукталыйк.

Шигырьләрендәге үзенчәлекле яңгыраш кабатлаулар исәбенә дә барлыкка килгән. «Кабатлау – сүз ясый, кабатлау – эмоциональ бизәк була, кабатлау – мәгънәви басымны арттыра, кабатлау – үзенчәлекле яңгыраш барлыкка китерә». [Сафиуллина Ф.З. 1993:185].

Кабатлау алымнарын шагыйрә яратып куллана. Шигырьләрендә сүз кабатлауларының нәфис үрнәкләреннән алып, сүзтезмә, җөмлә кабатлауларының да искиткеч матур чагылышларын табарга була. Ләкин ул аны әсәрен бизәү өчен генә түгел, ә мәгънәне көчәйтү, укучының игътибарын әйтергә теләгән фикергә юнәлтү өчен куллана.

Таң салкынын әмма көн алуга,
Эреп бетә кырау тиз генә.
*Кар түгел шул әле, кырау гына,*
*Кыш түгел бит әле, көз генә.*
Чигәләрдә чаллар күренгәндә,
Юатабыз үзебезне дә:
- *Бу кар түгел әле, кырау гына;*
- *Бу кыш түгел әле, көз генә.* [Якты сагыш 1995: 3]

Кәефемне күпме бозды болар,
Үзәгемә күпме үттеләр!..
Тик һаман да жанга якын шулар,
*Минекеләр, үземнекеләр.*
*Минекеләр, үземнекеләр* шул,
*«Үземнекеләр» дип* үстерәм.
*«Үземнекеләр»* дип гаеплим дә
*«Үземнекеләр»* дип кичерәм. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 23]

Сәнгатьчә сурәтләү алымы буларак, Клара Булатова чагыштыруларның төрле формаларын оста куллана. Бу алым ярдәмендә тирә-юньгә, җәмгыятьтәге күренешләргә, яшәешкә, ялкынлы мәхәббәткә үзенең мөнәсәбәтен белдерә.

Таңга чыга алмас *төн кебек.*
*Кара кайгы* килде ишелеп.
Урап алды уңнан, сулымнан,
Каләмемне алды кулымнан. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 210]
Сезнең *гомер-тирән, олы диңгез*,
Берегездән калмый берегез.

Рәхәтен дә күреп бу гомернең
Озаграк яши күрегез! [Якты сагыш 1995:77]
Мин – шагыйрә. Мин шигырьләр язам.
Минем *бакчам-шигъри түтәлләр.* [Каурый канат – Җил Атым 2006: 39]

Строфаның бер сүз яки сүзләр белән башлануы яки бетүе эпистрофа дип атала. Шагыйрь Х.Туфан яратып куллана торган бу алым К.Булатовада да кулланылган.

Апрельнең сынган *уртасы,*
*Уртасында* язның ноктасы. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 210]
Киткәндә караңгы иде,
*Көн яктырып җитмәде,*
*Көн дә яктырып җитмәде,*
Күренмәгәч көткәне. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 221]

Сынландыру – метафорик күчерүгә нигезләнгән тропларның бер төре. Сынландыру табигать күренешләрен, тере булмаган әйберләрне җанлы әйберләргә хас сыйфатлар белән сурәтләүдән гыйбарәт. Мондый сурәтләү әсәр теленең тәэсир көчен арттыра. [Әдәбият белеме сүзлеге 1990: 172.] Клара Булатова иҗат иткән шигырьләрдән сынландыруга түбәндәге мисаларны китерергә була:

Безнең якта шулай:
Күзләр кергәч,
Китеп барган торна төркеменә
*Кызыл яулык болгап кала миләш.* [Каурый канат – Җил Атым 2006: 38]
Бу хәсрәттән су агудан туктар,
Авырлыктан *таулар иелер*.[Каурый канат – Җил Атым 2006: 43]
*Ай йөри* каплап урамны
Йокылы көмеш белән. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 55]

Укучының игътибарын төп фикергә юнәлтү максатында, шагыйрә халыкта киң таралган мәкаль-әйтемнәрне файдалана: мәкаль яки әйтемне структур яктан да үзгәртә (мәкаль яки әйтемнең ахыргы өлеше баштагы өлешеннән алда килә), ягъни шигырьнең эчтәлегенә яраклаштырып үзгәртеп бирә.

«Халык әйтә: «Сулар
Баштан болгана»,– дип.
«Баштан чери балык» дигән сүзе бар. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 76]
«Яшь тә бара, китә саулык та.
Беркемгә дә картлык шатлык түгел», –
дигән сүз дә бар бит халыкта. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 80]
Өйдән чыкмый байтак яткан идем,
Яткан таш бит, диләр күгәрә. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 90]
Күзләреннән нур сирпелә,
Телләреннән гөл тама. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 101]
«Тик бәладән генә башаяк» дип
Посып яши мәхлук өнендә. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 118]
– Үз картлыгың әйбәт булсын дисәң,
Оныкларны бездән биздермә.
Нәрсә чәчсәң, шуны урырсың, дип,
Хак сүз сөйли бит олылар. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 173]
«Китап – белем чишмәсе» дип яттан
Өйрәнелгән сүзләр бик хаклы. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 123]
Халык телендә «Тапкан түгел,
Бакканы Ана» дигән сүз кергән. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 130]

Шагыйрә иҗатында мәгънә ягыннан бер-берсенә якын торган сүзләр – синонимнар, капма-каршы мәгънәдәге сүзләр – антонимнар сөйләмне дөрес төзүгә, форма белән эчтәлекнең бәйләнешен булдыруга, баетуга ярдәм итәләр. Синонимнар, әдибәнең әйтергә теләгән фикерен ныгыту, тулыландыру өченхезмәт итсәләр, антонимнар кеше күңелендәге

яки тормыштагы каршылыкларны сурәтләү өчен кулланыла. Моңа түбәндәге мисалларны күрсәтергә була:
Антонимнар.

Канатларны җил тузгытты
*Акларын да, карасын да*.[Каурый канат – Җил Атым 2006: 159]
Әкияттән аерылсаң,
Син яшәүдән тукта гел,
*Әкияттән курыкма* син –
*Чынбарлыктан курка* бел. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 163]
Ник сиңа дөньяның гел тигез булмавы?
*Аста да өстә дә* болганып торганы? [Каурый канат – Җил Атым 2006: 170]

Синонимнар.

Кичләрен дә бик *ямансу*,
Үтә *моңсу* иртәсе.
Әллә инде тотасы да
Кайтып кына китәсе? [Каурый канат – Җил Атым 2006: 191]
Адәм баласына *усаллык* хас.
Исемемә яман бәя таксаң –
Юк, иплелек мин дә сакламам.
*Әшәкелек* өчен тугызлата
Мин *явызлык* белән кайтарам. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 206]

Шагыйрә Клара Булатова иҗатына хас тагын бер үзенчәлеккә игътибар итик. Ул, татар телендә күптәннән килә торган парлы сүзләр ясалу кагыйдәсен нигез итеп алып, яңа сыйфатлар ясый.

Их, йөрисе иде урамнарда!
*Карлы-назлы* февраль иртәсе.
Әллә инде, ияреп шул карларга,
Авылга ук кайтып китәсе! [Каурый канат – Җил Атым 2006: 187]
*Тап-тамгасыз* аяз зәңгәрлектә
Балкып торган июнь кояшы
Шундый чиста, якты, әйтерсең лә
Әниләрнең хәер-догасы.[Каурый канат – Җил Атым 2006: 31]

Метафоралар телнең матурлыгын, эмоциональлеген һәм тәэсир итү көчен арттыралар, фикерне тирәнрәк аңлауга, зур һәм катлаулы күренешләрне җыйнак кына бер сүз белән әйтеп бирергә ярдәм итәләр. Клара Булатова шигырьләрендә метафоралар куллануга да зур игътибар иткән.

Сарытауның сары итәкләре
Далаларга барып кушылган;
Ил ирееген саклар *бөркетләре*
Сугышларга киткән шушыннан.[ Хәтер көзгесе 1995: 48]

«Сарытау көе» шигырендә “бөркетләре” сүзе батыр кешеләр мәгънәсендә белдерелгән.

Алмашынмас *ике бөҗрам* минем,
Әткәм-әнкәм минем-карт, карчык.
Хәтта ярны ярлар алмаштыра,
Сезне булмый, булмый алмашып.

«Булмый алмашып» шигырендә “ике бөҗра” сүзе әти белән әни төшенчәсен аңлата.
3. Ихата да ак күбәләк -
Инәйнең җаны бугай. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 216].

Шагыйрәнең иҗатында метафорик троплардан метонимия («исем алмаштыру») күренеше белән башланып киткән шигырьләр дә бар. Фикер үстерелеше шушы алым ярдәмендә бирелә, һәм шигъри юллар бер-берсенә чылбыр кебек үрелеп барып, матур мәгънәви бәйләнеш тудыра.

Бөек Алла колы!
Синең белән даим авырдым. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 6]

Бөек шагыйрь Тукайның исемен «Алла колы» мәгънәсендә бирә.

Күкчәчәгем, җитен чәчемне,
Бик сагындым бәләкәчемне,
Сагындым ла шул бәләкәйне-
Күбәләккәй Камиләкәйне. [Каурый канат – Җил Атым 2006:11]

Әлеге строфаның беренче юлында затны атамыйча, ягъни кызчыкка үз исеме белән түгел, ә аның белән тыгыз бәйләнештә торган билгесе (күкчәчәк, җитен чәч) аша мөрәҗәгать итә.

Шагыйрә Клара Булатова шигырьләренең тел үзенчәлекләренә игътибар итсәң, керешмәләрнең дә шактый актив булуы күзгә ташлана.

... Син «Миләшем!» дидең,
Каршы килмим.
(Җан ни дисә – шуны тел сөйли) [Каурый канат – Җил Атым 2006:35]
Санап кына кулланмасаң
(Анысы нык агулы),
Зарары да тиюе бар,
Табигатьнең даруы. [Каурый канат – Җил Атым 2006: 24]

Һәр милләтнең борын-борыннан килгән йола-гадәтләре, бәйрәмнәре була. Бу аның яшәү рәвешен үзенчәлекле итә. Шулар белән ул башкалардан аерылып тора. Шагыйрәнең «Бәйрәмнәрне барлыйм» дигән шигыре моңа мисал. Әлеге шигырендә ул керәшен халкының «Авыз ачу», «Кач ману», «Май чабу», «Олы көн», «Энҗел», «Питрау» бәйрәмнәрендәге йола-гадәтләрне тасвирлаган.

«Чана ташлау» бәйрәме

Кышны куадыр инде.
Пауал дәдәй арбаны
Көйләп куйгандыр инде.[Якты сагыш 1995: 199]

Йомгаклау. Шигырьләреннән күренгәнчә, шагыйрә Клара Булатова тел сурәтләү чараларына җан кертеп, кеше күңеле, аларның кичерешләре белән бәйле хәл-вакыйгаларны сурәтләргә, гади генә шул хәл-вакыйгаларга олы мәгънә салырга ярата. Әйтергә теләгәнен кирәк җирдә сүз-сурәтләр аша, кирәк җирдә гади генә, тынак кына, ләкин сүз-тойгыларын, кичерешләрен тәэсирле, үтемле итеп әйтеп бирә белә. Клара апа кебек көчле шагыйрь-шагыйрәләребез, әдип-әдибәләребез булганда без әле бәхетле халык. Ләкин киләчәктә алар кебек әдәбиятның өлгесе булырлык шәхесләр булырмы? Монысы – вакыт, заман эше, монысын без киләчәккә тапшырыйк.

Бүгенгесе көндә Клара апа Булатова – зур игътибарга һәм хөрмәткә лаек кеше. Мин ышанам, тарихта ул үз урынын алыр.

## К. Булатова шигырьләре

(2 нче сыйныфта әдәби уку дәресе)

Кашапова Гөлназ Марс кызы, Зиннәт Хәсәнов исемендәге Иске Кәшер мәктәбе, Сарман районы

**Максат:** Клара Булатова шигырьләре белән таныштыру, җир йөзендә иң матур сүз – әни икәнен аңлату, әниләргә ярдәм итәргә кирәклеге, өйдәге эш-йомышларны теләп үтәү омтылышы тәрбияләү. Мәгънә барлыкка китерү (Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар? соравын кую), логик фикер йөртү осталыгы, тәҗрибә куллану аша нәтиҗә чыгару, алдагы дәресләрдә үзләштергән белемнәргә таянып, дәреслектән яңа мәгълүматны таба белергә күнектерү.
**Бурычлар:** көйсезләнмәскә, ялкауланмаска, өлкәннәргә һәрвакыт булышырга, яхшы укырга дигән төшенчәләрне әдәби әсәрләр укып, кирәклене эзләп табып, чагыштырып тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, нәтиҗә ясарга өйрәтү. Әнине, яратырга кирәклекне төшендерү; образлы, ихтирамлы сөйләм тәрбияләү, иҗат фантазиясен үстерү.
**Материал:** дәреслекнең 1 нче кисәгендә 34-35 нче битләрендәге материал.
**Җиһазлау:** слайдлар: Клара Булатова портреты, китаплары.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**
Метапредмет:
танып белү УУГ: аңлап уку һәм сөйләм күнекмәләрен камилләштерү, тексттан кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
коммуникатив УУГ: үз фикереңне җиткерә белү, күршең белән хезмәттәшлек итү;
регулятив УУГ: мөстәкыйль рәвештә дәреснең темасын, максатын формалаш-тыра белү, төп нәтиҗәне чыгару эшчәнлегендә катнашу өчен тырышу, үз эшеңә
бәя бирә белү.
**Предмет буенча:** К. Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача белешмә алу, шигырьләренә кызыксыну уяту.
**Дәреснең тибы:** яңа белемнәрне формалаштыру.
**Төп төшенчәләр:** әнием чәчләре, әнием күзләре, әнием җырлавы, иң матур сүз.
**Предметара бәйләнеш:** сәнгать, татар теле.
**Эшне оештыру:** фронталь, парларда, индивидуаль.
**Чыганаклар:** картиналар, портрет, проектор, экран, нетбук.

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|
| **I. Оештыру. Мотивлаштыру**<br>*Максат:* укытучыга игътибар итү; дәрестә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре формалаштыру | -Исәнмесез, укучылар!<br>-Хәерле иртәләр сезгә!<br>-Зиһен һәм тел ачкычлары<br>Телимен һәммәгезгә!<br>Имин үтсен көнегез!<br>Кәефләрегез ничек соң?<br><br>Яхшы, ә хәзер гәүдәләрне төз тотабыз да берничә сөйләм күнегүе эшләп алабыз.<br>– Кулларыбызда хуш исле чәчәкләр, аларны иснибез, ә иснәгәндә, тирән итеп сулыш алабыз да һаваны кире чыгарабыз.<br>– «Кайтаваз» уенын уйныйбыз.<br><br>– Тактада язылганны укыйбыз. *(Тавышны күтәреп, тавышны төшереп* | Исәнмесез!<br>Хәерле иртәләр!<br><br>-Рәхмәт!<br><br>- Кояшлы иртә кебек,<br>Тукай телен, анам телен<br>Өйрәнергә дип килдек.<br><br>сулыйлар...<br><br>– кайтавазны чакыралар:<br>– иртә – тә-тә, урман – ман-ман, һава-ва-ва, килми-ми-ми...<br>– Сиңа бирелгән ике колак,<br>бер тел: ике тыңла, бер сөйлә, калганын үзең бел. *(Әйтем)* | – укытучыга һәм хезмәттәшләр еңә<br>хөрмәт хисе тудыру;<br>– классташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;<br>– эш урынын оештыру; |
| **2. Белемнәрне актуальләштерү**<br>*Максат:* алдагы дәрестә алган | Безнең кәефебез тагын да яхшырсын өчен, әлбәттә,<br>өй эшен бик әйбәт итеп сөйләп бирергә кирәк. Үзбәя | Үзбәя | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| белемнәрне искә төшерү | карточкаларын әзерлибез.<br>– Өйгә бирелгән эшне әйтеп китегез әле?<br>– Ә өй эшен мин бүген уен формасында тикшереп алам. Ул уен «Ышанасызмы сез?» дип атала. Җавапны дәлилләп тә бирергә кирәк була. Тыңлыйбыз. (Р.Миңнуллинның «Әни кирәк» шигыре буенча)<br>Җил-давылдан саклар өчен әни кирәклегенә ышанасызмы?<br>– Авторның усаллардан саклар өчен әни кирәк дигәненә ышанасызмы, исбатлагыз;<br>– Дөньяда иң кирәк кеше – әни икәненә ышанасызмы, исбатлагыз;<br>– Ә мин, үз чиратымда, сезнең өй эшләрен эшләп килүегезгә ышанам, чөнки сез дөрес җаваплар бирдегез | карточкаларын әзерлиләр.<br>– Р. Миңнуллин «Әни кирәк» шигырен укырга һәм сорауларга җаваплар табарга.<br><br>Әйе, мин ышанам.<br>*(Тексттан өзек табып укый.)*<br>– Әйе, мин ышанам.<br>– Әйе, мин ышанам | |
| **3.Яңа материалны үзләштерүгә ихтыяҗ тудыру**<br>Максат: элек үзләштергән белемнәрне мөстәкыйль рәвештә искә төшерү мөмкинлеге булдыру | -Укучылар, карагыз әле безгә монда бер тартма калдырып киткәннәр. Әгәр табышмакның җавабын тапсагыз, тартмада нәрсә булуын белерсез.<br>Агач түгел – яфраклы,<br>Тун түгел тегелгән.<br>Ак җир, кара тап,<br>Нәрсә булыр? Уйлап тап.<br>Дөрес, укучылар, бу – китап. Тик ул гади китап түгел:анда районыбызның күренекле кешеләре турын-да язылган. Әйдәгез бу китап белән танышып алыйк. Күренекле дип кемнәргә әйтәләр?<br>Ә сез күренекле кешеләрдән кемнәрне беләсез? | – Укытучыны тыңлыйлар.<br><br>-Китап.<br><br>- Танылган, бөек, талантлы кешеләргә.<br>- Г.Тукай, М.Җәлил, А.Алиш һ.б. | -үзмаксат кую, табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтә белү;<br>– укытучы һәм укучы белән хезмәттәшлек, тыңлый белү, үз фикер-ләреңне әйтә белү;<br>– дәреснең максатын формалашты-ру, үзбәя |
| **4. Яңа материалны аңлату**<br>*Максат:* таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен истә калдыру | (1 нче слайд – язучы портреты) (К.Булатова турында кыскача мәгълүмат бирү)<br>-К.Булатова 1936 елның 18 мартында Сарман районы Татар Карамалысы авылында туа.Белемне Ләке,Югары Чыршылы, Сарман урта | – Укытучыны тыңлыйлар. | -тыңланган һәм укылган тексттан кирәкле мәгълү-матны кабул итү;<br>– башкалар-ның сөйләмен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | мәктәбендә ала. Аннан соң Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Аны бетергәч тел-әдәбият укытучысы булып китә. | | тыңлау,аңлау;<br>– хикәянең эчтәлеген аңлау, белү;<br>– лексиканы кабул итү; |
| **Ял итү** | Электрон тактада рәсемле уен *(Слайд)* | Ял итү күнегүләрен эшлиләр. | Эмоциональ чи-шелеш |
| **5. Яңа белемнәрне беренчел үзләштерү, Ныгыту.**<br>*Максат:* ишетеп, күреп тану күнекмәләрен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү | - Без сезнең узган дәрестә Р.Вәлиевның «Кояш кебек» шигырен укыдык. Әниләр өйгә каткач, чыннан да өйләр яктыра. Ә әниләребез һәрвакыт елмаеп торсын өчен барсын да эшлибезме?<br>К.Булатованың «Әләкләргә ярамый» шигырен уку.<br>- Бу малайны тәртипсез дип әйтеп буламы?<br>- Әнисе кайтуына нинди тәртипсезлекләр эшлиләр? Өйдә алны-артны карамыйча чабарга ярыймы?<br>- Малайның әләкләргә ярамый дигән фикере беләнкилешәсезме? | -Үз фикерләрен әйтәләр.<br><br>Балалар үз фикерләрен әйтәләр. | – тексттан кирәкле мәгълүматны таба белү, сөйли белү, синтезлау;<br>– үз фикереңне әйтә белү, парларда эшли белү, тыңлый белү, монолог төзү;<br>– вакытны контрольдә тоту; |
| **6. Өйрәнгәннәрне ныгыту күнегүләре.**<br>*Максат:*алган белем һәм күнекмәләрне ныгыту һәм гомумиләштерү. | «Әниемнең кызы юк бит» шигырен уку.<br>- Өйдәге бөтен эш кем җилкәсенә төшә?<br>- Өйдә эшне кызлар эше, малайлар эше дип бүлешергә кирәкме, юкмы?<br>- Малай нинди эшләр эшли? Аз-маз булса да кызлар эшен белү малайларга кайчан кирәк була?<br>- Күрәсезме, укучылар, Клара апа безнең өчен нинди матур, эчтәлекле шигырьләр язган.<br>- Ә бу шигырьләре белән Клара апа безгә нәрсә әйтергә теләгән? | Балалар үз фикерләрен әйтәләр.<br><br>Тексттан шул өзекне табып укыйлар<br><br>Үзбәя. | – мөстәкыйль эшли белү, кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;<br>– хаталарны табып төзәтә белү, үзбәя;<br>– табигатьтәге җан ияләренә мәрхәмәтле-лек хисе тәрбияләү, һәр баланың шәхси нәтиҗәгә ирешүе; |
| **7. Мөстәкыйль эш.**<br>*Максат:* укучыларның игътибарлыгын тикшерү,хаталарны төзәтү | 1. Дәфтәрдә язма эш<br>2. Сораулар буенча әңгәмә:<br>– Безнең иң яраткан кешеләребез – әниләр, сез аларга нинди ягымлы сүзләр әйтәсез?<br>– Иртән сезне кем һәм ничек уята?<br>3. Проект эше эшләтү. | 1. Дәфтәргә 34 нче биттә бирелгән әйтемнәрне күчереп язалар.<br>2. Тексттан өзекләр кулланып җаваплар | -үз фикереңне әйтә белү, сорауларга җавап бирә белү, тыңлый белү;<br>– хаталарны табу, төзәтү; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | – Мин сезгә әниләрегезнең фотосурәтләрен алып килергә әйткән идем. Сезгә үз әниләрегез турында сөйләп бирергә кирәк | төзиләр<br>3. Проект төзиләр. Сөйләргә әзерләнәләр. Үзбәя. | – иптәшеңнең иҗатын күзәтә |
| **7. Рефлексия.**<br>*Максат:* дәрестә эшләнгән эшләргә нәтиҗә ясау | - Без якташыбыз – Клара Булатованың 2 шигыре белән таныштык. Алга таба да без аның иҗаты белән танышуны дәвам итәрбез. Тикмәгә К.Блатова:<br>*«Мин – шагыйрә, Мин шигырьләр язам. Минем бакчам – шигъри түтәлләр, Мин орлыклар гына чәчә алам, Җыючылар булыр бүтәннәр»*<br>– дип шигырь язмаган. Ул чәчкән орлыкларны җыеп, әниләребез бер генә һәм аларны һәрвакыт кадерләргә, ярдәм итәргә кирәк дип үзебезгә нәтиҗә ясыйк.<br>– Без бүген кем турында сөйләштек?<br>– Сез дәрестән үзегезгә нинди яңалык алдыгыз?<br>– Сезнең смайликларда – яз кояшы, кәефегезгә карап, аның йөзен ясагыз. Ни өчен шулай? Аңлатыгыз.<br>– Алган белемнәрегезне сигнал карточкалары белән күрсәтегез. | Үз фикерләрен әйтәләр, сораулар бирәләр. Үзбәя | – үзбәя, үз эшеңә объектив бәя бирә белү һәм тәнкыйть күзлеген-нән карау;<br>– коллектив һәм индивидуаль эшне дөрес бәяләү;<br>– укытучыны тыңлау, сораулар бирү, әңгәмәдә катнашу |
| **8. Өй эше** | Өй эше.<br>1. «Мин әниемнең кызы (улы)» исемле кечкенә хикәя язарга.<br>– Укучылар, дәрес тәмам. Дәрестә яхшы эшләвегез өчен рәхмәт. | Өй эшен язып алалар, сораулар бирәләр | –үз мөмкинлегең нән чыгып, өй эше алу |

**Татар әдәбияты дәресе**

5 нче сыйныф ( татар төркеме)

Мингалеева Рәмзия Әхмәтзакир кызы, Масловка мәктәбе,
Балык Бистәсе районы

| | |
|---|---|
| Тема | «Бәхетле булу серләре» темасы буенча бәйләнешле сөйләм үстерү дәресе |
| Дәреснең максатлары | 1.Һәркемнең бәхете аның үз кулында икәнлегенә төшендерү һәм бәхетле булырга омтылыш уяту. 2.Ветераннарга хөрмәт |

| | |
|---|---|
| | тәрбияләү. Тынычлыкның иң кадерле нәрсә булуын аңлату.<br>3. Дәрестә предметара бәйләнеш булдыру һәм рус әдәбияты, тарих, музыка, рәсем сәнгате белән бәйләү. |
| Дәреснең бурычлары | Белем бирү максаты: хикәянең төп фикерен укучы аңына җиткерү өчен шартлар тудыру.<br>Фикерләү сәләтен үстерү максаты: анализлау, чагыштыру, гомумиләштереп, нәтиҗә ясау күнекмәләрен үстерүне дәвам итү.<br>Тәрбия бирү максаты: бәхетле булу кешенең үзеннән тора икәнлегенә ышандыру. |
| Планлаштырылган нәтиҗәләр | Предмет нәтиҗәләре: хикәянең темасын аңлау һәм формалаштыру, идеясен күрсәтү.<br>Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр: герой кылган гамәлләр аша яхшыны начардан аерырга өйрәнү.<br>Метапредмет нәтиҗәләр:<br>- регулятив: үзеңнең һәм башкаларның фикерен дөрес бәяләү, төп нәтиҗәне чыгару эшчәнлегендә катнашу өчен тырышу.<br>- танып-белү: булган белемнәргә таянып, “бәхет” төшенчәсенә кагылышлы мәгълүматны табу һәм анализлау аша аны бәяләү, гомуми нәтиҗәне чыгару.<br>- коммуникатив: бәхет турында төп фикергә килгәнче, төрле җавапларны тыңлау; төркемнәрдә эшләгәндә, төрле мисаллар белән үз фикереңне дәлилләү, әсәрнең төп фикерен табу һәм формалаштыру. |
| Предметара бәйләнешләр | Рәсем сәнгате, тарих, музыка, рус әдәбияты. |
| Ресурслар:<br>- төп<br>- өстәмә | Төп: Татар әдәбияты. 5 нче сыйныф<br>Өстәмә: слайдлар күрсәтү өчен проектор, экран, ноутбук. |
| Эшне оештыру | Төркемнәрдә һәм индивидуаль эшләү. |
| Төп төшенчәләр | Тема, идея, бәхет проблемасы, анализлау, чагыштыру, гомуми нәтиҗә |
| Педагогие технология (педагогические технологии) | Өлешчә тикшеренүгә корылган әңгәмә |
| Дәреснең төре (тип урока) | Яңа белемнәр үзләштерү |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Белем бирү һәм фикерләү сәләтен үстерү (дәреслек, предмет материалы) | Универсаль уку гамәлләре (УУГ) | Эшкә этәргеч бирүче сораулар һәм тәкъ-димнәр |
|---|---|---|---|---|---|
| <u>Мотивлаштыру</u><br>2 мин.<br>Максат: уңай психологик халәт тудыру. | Укучыларны уку эшчәнлегенә тарту. | Дәрестә төркемнәрдә эшләү кагыйдәләрен искә төшерәләр: башкаларны тыңла, үз фикереңне ачык әйт, игътибарлы бул. | Шәхси эшчәнлек: дәреслек һәм эш дәфтәрләрендәге язмаларны барлау. | **Шәхси:** әдәп-әхлак кагыйдәләрен искә төшерү, бер-берсенә уңышлар теләү. | Дәресебез уңышлы булсын өчен нишлибез? |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Актуальләштерү<br>6 мин.<br><br>Максат: яңа белем алуга әзерлекне тикшерү, аның темасын формалаштыру. | Белем алуга эчке ихтыяҗ булдыру өчен, шартлар тудыру.<br>Искәрмә: шигырь өйдә кабат укыла, шуңа таянып, яңа белем алуга әзерлек эше алып барыла. | Узган дәрестә Нәби Дәүлинең “Бәхет кайда була?”шигыре һәм “Кар нинди җылы”әсәрләре белән таныштык. | Ул дәреслектәге өзек буенча чорга автор исеменнән бәя бирү. | **Шәхси**: уку эшчәнлегендә бер-берсе һәм укытучы белән хезмәттәшлек оештыру.<br>**Регулятив**: һәр төркемнең бәясен тыңлап, нәтиҗә чыгару, алдагы адымнарны фаразлау.<br>**Коммуникатив:** геройның эшгамәлләренә бәя биргәндә, ике төркем хезмәттәшлегенә ирешү.<br>Һәр слайдтагы рәсем турында сөйләнә торган вакыйганы тормыш белән бәйләп, нәтиҗә чыгаруны оештыру. | Узган дәрестә нинди хикәя укыдыгыз? Төп герой кем?<br>Башка геройлар белән мөнәсәбәтен, бәйләнешен ачыклагыз. |
| | **Слайд №1. *БӘХЕТ* – тулы канәгатьләнү халәте һәм хисе.** | «Аңлатмалы сүзлектән» табу | Фикереңне кыска һәм матур итеп әйтү, дәреслектән мисаллар китерү. | | |
| | **Слайд №2. *Слайдта*** *бәхетле гаилә күрсәтелгән рәсем* ***урнаштырыла.***<br>(укучыларның үз гаиләләрен сурәтләгән рәсемнәрен дә куярга була) | Гаиләдәге бәхет турында әңгәмә. | Булган белемнәрдән чыгып, яңа фикерне формалаштыру. | **Шәхси:** Бәхет турында үз фикереңне әйтә белү.<br>**Коммуникатив:** төркемнәрнең фикерләренә мөнәсәбәтеңне белдерү. | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **Слайд №3.** ***Слайдта*** *авыру кешеләр рәсеме* ***урнаштырыла.*** | Тулы бәхет өчен саулыкның кирәклеге ачыклана. | Фикерләрне үз мисалларыңа таянып раслау. | **Танып-белү:** һәр төркем үз фикерен белдерә, аларның җаваплары тыңлана, чагыштырып, уртак нәтиҗә чыгарыла. **Регулятив:** тиешле нәтиҗәгә килүдә эзлеклелекне саклау. | |
| | **Слайд №4.** ***Слайдта*** *төрле табигать, төзелеш, матур киемнәр һ.б. рәсемнәр* ***урнаштырыла.*** | Матурлыкны тудыруда төрле һөнәр ияләре хезмәт куюын аңлату. | | **Шәхси:** һәр укучы дәреснең темасын мөстәкыйль формалаштыра. **Коммуникатив:** уртак фикергә килү. | |
| | **Слайд №5.** ***Слайдта*** *төрле һөнәр ияләрен чагылдырган рәсемнәр* ***урнаштырыла.*** | «Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз» дип әйтмәгәннәр. Чөнки кеше үзе яраткан һөнәрен табарга һәм шул хезмәте белән тирә – юньдәгеләргә файдалы кеше булып яшәргә омтыла. Ә моның өчен белемле дә булырга кирәк. Димәк, эшле һәм белемле булу да зур бәхет икән. | Фикерләрне үз мисалларыңа таянып раслау. | **Танып-белү:** һәр төркем үз фикерен белдерә, аларның җаваплары тыңлана, чагыштырып, уртак нәтиҗә чыгарыла. **Регулятив:** тиешле нәтиҗәгә килүдә эзлеклелекне саклау. | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Физминутка. Максат: укучыларны ял иттерү. | Физминутка үткәрүгә җаваплы укучының эшен оештыру. | Күнегүләр ясыйлар. | | **Шәхси:** төрле ял итү күнегүләре ясау. **Регулятив:** күнегүләрне дөрес эшләүне контрольдә тоту. | |
| | **Слайд №6.** *Шунда белде ике дус – Галимҗан белән Илдус: Бабай бик дөрес әйтә – Бәхет була хезмәттә.* | Нәби Дәүлинең тагын «Бәхет кайда була?» шигырен искә төшерик. *(укучылар Илдус белән Галимҗанның бәхетне эзләүләре турында фикер алышалар.)* | Дәреслекнең тиешле өзекләреннән мисаллар уку. | **Шәхси:** герой халәтен тоеп, үз кичерешләрең не чагылдыру. **Танып-белү:** әйтелгәннәргә нигезләнеп, чираттагы нәтиҗәне чыгару. | Тормышта кешенең бәхетле минутлары күп буламы? Бу кайсы өлештә күренде? |
| | **Слайд №7** ***Слайдта*** *төрле ризыкларны, матур киемнәрне, матур йортны, машинаны һ.б. чагылдырган рәсемнәр* ***урнаштырыла.*** | Үзенең эше белән кеше җәмгыятькә үз өлешен кертә. Шулай итеп, ул үзен матди яктан да тәэмин итә, байлык туплый. Муллыкта яшәгәндә үзен бәхетле сизә, аның күңеле дә тыныч була. Ә сез муллыкта яшәүне ничек аңлатыр идегез? (*укучыларның җавабы)* Димәк, бәхет б**айлыкта һәм муллыкта** да була. | Фикерләрне үз мисалларыңа таянып раслау. | **Танып-белү:** һәр төркем үз фикерен белдерә, аларның җаваплары тыңлана, чагыштырып, уртак нәтиҗә чыгарыла. **Регулятив:** тиешле нәтиҗәгә килүдә эзлеклелекне саклау. | |
| <u>Рефлексия</u> 2 мин. Максат: үз эшчәнлегеңә кире кайтып бәя бирү. | Үз эшеңне бәяләүгә юнәлтелгән сораулар куела. | Һәр төркемнең үз җавабы. | | **Регулятив:** аңлашылмаган якны ачыклау, бергәләп эшләгәндә, бердәм карар кабул итә белүнең әһәмиятен аңларга булышу. | Укучылар, сез бүген нәрсә турында өйрәндегез |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **Слайд № 8.** ТУГАН ИЛДӘ ЯШӘҮ слайды куела. | Безнең татарлар дөньяның төрле почмакларына чәчелеп яшиләр. Сез моны зәңгәр экраннардан "Татарлар" тапшыруын карап белә аласыз. Кайда гына яшәсәләр дә татарлар үзләренең хезмәт сөючәнлекләре, чисталыклары, гореф-гадәтләрен һәм телләрен онытмаулары арка-сында югалмыйлар. Ләкин гомерләре буена алар Туган илләрен сагынып яшиләр. Чөнки кеше үзенең туган җирендә генә үзен чын бәхетле тоя | Барлык эш процессын күздән кичереп, төп нәтиҗәне чыгару. *Музыка фәне белән бәйләү* | **Шәхси:** һәр баланың шәхси нәтиҗәгә ирешүе. **Коммуника-тив:** әңгәмәдә актив катнашу. | Нинди нәтиҗә ясадыгыз? |
| | **Слайд № 9 Слайдта** төрле ак яулыклы әбиләр, парлы картлар һ.б. чагылдырган рәсемнәр урнаштыры-ла. | Кеше гомере буена бәхетле булырга омтылып яши. Менә шушылай яшәгәндә генә кеше күңел тынычлыгын таба, үзенең бәхетле картлы-гын каршылый. Димәк, укучы-лар, БӘХЕТЛЕ КАРТЛЫК та була икән. | Барлык эш процессын күздән кичереп, төп нәтиҗәне чыгару. | **Шәхси:** һәр баланың шәхси нәтиҗәгә ирешүе. **Коммуника-тив:** әңгәмәдә актив катнашу. | |
| | **Слайд № 10.** ***Слайдта*** *сугыш, шартлау, елаган балалар* ***урнаштыры-ла.*** | Илгә дошман басып кергән. Сугыш кайгысы һәркемнең йөзенә сарган. Бу бала нәрсә турында хыяллана икән соң?(*экрандагы бала рәсеменә игътибар ителә* | *Тарих фәне белән бәйләү* | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | ) Укучылар, безнең май аенда нинди зур бәйрәмебез була соң?*(укучылар җавабы)* Әйе, Җиңү бәйрәме. Бу Җиңү миллионлаган корбаннар бәрабәренә яулап алынды. Шуңа күрә дә без аның кадерен белергә, ветераннарыбызга хөрмәт белән карарга тиешбез. Димәк, кешенең бәхетле булуы өчен **ТЫНЫЧЛЫК**та кирәк икән. | | | |
| | **Слайд № 11.** *Барлык слайд исемнәре бер слайдта була.* | ГАИЛӘ БӘХЕТЕ БӘХЕТ САУЛЫКТА МАТУРЛЫККА ОМТЫЛУДА ЭШЛЕ һәм БЕЛЕМЛЕ БАЙЛЫКТА һәм МУЛЛЫКТА ТУГАН ИЛДӘ ЯШӘҮ БӘХЕТЛЕ КАРТЛЫК ТЫНЫЧЛЫК – БӘХЕТ | Барлык эш процессын күздән кичереп, төп нәтиҗәне чыгару. | **Шәхси:** һәр баланың шәхси нәтиҗәгә ирешүе. **Коммуникатив:** әңгәмәдә актив катнашу. | Шулай итеп, бәхетле булу өчен безгә нәрсәләр кирәк булды инде? |
| <u>Ныгыту</u> | Ә рус әдәбиятыннан бәхет турында нинди әсәрләр беләсез? *( укучыларның җавабы)* Бик дөрес. Чыннан да, сез Валентин Катаевның «Цветик-семицветик» дигән экиятен барыгыз да беләсез. | Укучылар таҗларга,төркем-ләп, теләкләрен язалар һәм ахырда чәчәк барлыкка килә. | *Рәсем сәнгате һәм рус әдәбияты белән бәйләү* | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Татарча инде без аны «Җиде таҗлы чәчәк» дип йөртәбез. | | | | |
| <u>Дәресне йомгаклау.</u><br><u>2 мин.</u><br><u>Максат: бер-береңнең эшен бәяләү, билгеләр кую.</u> | Укытучы укучылар белән берлектә эшкә йомгак ясый. | Һәр төркемнең эшенә һәм индивидуаль чыгышларга, үз эшләренә укучылар бәя бирәләр, билге куялар. | Укучылар бер-берсенә рәхмәт белдерәләр. | **Шәхси:** үз эшеңә объектив бәя бирә белү һәм тәнкыйть күзлегеннән карау. | Укучылар, үзбәяләрегезне карагыз һәм билгеләрегезне куегыз. |
| Өй эше бирү һәм теләкләр.<br>2 мин. | «Нәрсә ул бәхет?» темасына үз фикереңне яз. Көндәлекләргә билге куела. | | | **Шәхси:** үз мөмкинлегеңнән чыгып, өй эше алу. | Укучылар, дәрес тәмам. Дәрестә яхшы эшләвегез өчен рәхмәт. |


**Фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше. Контроль күчереп язу**
**(Туган (татар ) тел дәресе, 3 нче сыйныф)**

Сорокина Резидә Фәрит кызы, Сарман гимназиясе,
Сарман районы

Максатлар: белем бирү максаты: укучыларның фигыль темасы буенча алдагы дәресләрдә өйрәнгән белемнәрен тикшерү, якташ язучыбыз К.Булатова иҗатына мәхәббәт тәрбияләү; фикер сәләтен үстерү максаты: укучыларның логик фикерләү сәләтен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын һәм танып-белүләрен үстерүгә ярдәм итү; тәрбияви максат: аралашу һәм коллективта хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру.
Җиһазлау. контроль күчереп язу тексты язылган карточкалар, кластер төзү өчен чиста А4 битләре, компьютер, проектор, экран.

Дәрес барышы

I.Оештыру өлеше. Мотивлаштыру
Исәнмесез, балалар, кәефләрегез ничек? Кәефләрегезнең яхшы булуын теләп, дәресебезне башлыйбыз.
II.Белемнәрне актуальләштерү
-Хикәя фигыль темасы буенча нәрсәләр беләбез?
(Төркемнәрдә эш- кластер төзү)



| Заман белән төрләнә | Зат-сан белән төрләнә | Барлыкта-юклыкта килә |
|---|---|---|

III.Дәреснең темасын,максатын билгеләү.
- Димәк бүгенге дәресебез фигыль сүз төркеменә багышлана. Текстны күчереп язабыз, текстта булган хикәя фигыльлләрнең зат-санын билгелибез. Әйтегез әле, безнең алдыбызда нинди максат тора? (Җавапларны тыңлау)
- дөрес итеп утыру; текстны чиста, матур, дөрес итеп күчереп язу; хикәя фигыльләрнең зат-санын билгеләү.
IV. Контроль күчереп язуга әзерлек. Дәфтәрләргә число языла. (Алдан әзерләнгән картокалар өләшенә)
Текст белән танышу.

Клара Булатова иҗаты барлык яшьтәге кешеләргә дә аңлаешлы. Аның китаплары балаларны яхшылыкка өнди, дөньяны ныграк танып белергә өйрәтә.

Казанда югары уку йортын тәмамлый. Аннан ул башы-аягы белән мәктәпкә чума.Үзенә яңа бер дөнья – балалар дөньясы ача. Балалар күңеле аның җанына яктылык биреп, шигырьләренә нур өсти. Балалар өчен матур-матур китаплар чыгара. (52 сүз)

Бирем: Текстта булган хикәя фигыльләрнең зат-санын билгеләргә.
V. Балаларның мөстәкыйль эше. Контроль күчереп язу. Биремне эшләү.
VI.Эшләрне тапшыру.
VII.Биремне тикшерү:
Өнди – 3 зат,берлек сан
Өйрәтә – 3 зат, берлек сан
Тәмамлый – 3 зат, берлек сан
Чума – 3 зат, берлек сан
Ача – 3 зат, берлек сан
Өсти – 3 зат, берлек сан
Чыгара – 3 зат, берлек сан
VIII. Рефлексия.
- Куйган максатларга ирештекме? Кайсы бирем сездә авырлык тудырды? Үзегезнең эшчәнлегегезне ничек бәялисез? ( Туры килгән смайлик күрсәтәләр
Мин барысын да аңладым, дөрес эшләдем.
Минем хаталарым булды, миңа тагын да игътибарлырак булырга кирәк.
IX. Дәрескә йомгак.
Шушының белән дәресебез тәмам. Рәхмәт!

## Шушы яктан, шушы туфрактан без

(әдәби-музыкаль кичә)

Гайфуллина Зөлфия Нуриман кызы, Тихонова Резедә Рәфәт кызы,
Җәлил беренче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Максат:** Шагыйрә Клара Булатова иҗатына күзәтү ясау. Укучыларда Клара Булатова иҗаты белән кызыксынучанлык, китап укырга омтылыш тәрбияләү

**Җиhазлау:** Клара Булатова китапларыннан күргәзмә, Клара Булатова турында презентация, җыр язмалары.

Зал бәйрәмчә бизәлгән. Китап күргәзмәсе оештырыла.

**«Шушы яктан, шушы туфрактан без» җыры яңгырый (Рәис Нәгыймов көе)**

**Укытучы:**

Шушы яктан, шушы туфрактан без...

Безнең туган ягыбыз – Сарман ягы – җырларда җырланган сандугач сайрар ягыбыз. Бик тә күренекле, исемнәре еракларга билгеле каләм ияләрен үстергән Сарман ягы. Халыкның тирән хөрмәтенә ия булган язучыларыбыз Аяз Гыйләҗев, Сөббух Рафиков, Мәдинә Маликова, бертуган Изаил һәм Марсель Зариповлар, Диләрә Зөбәерова, Рәфкать

Кәрами, Адлер Тимергалин, Хәниф Хәйруллин, Әзһәр Габиди, Дамир Гарифуллин, Гөлшат Зәйнәшевалар олы әдәбиятка юлны Сарманнан башлаганнар. Бүгенге кичә дә халыкның тирән хөрмәтенә лаек булган, якташыбыз Клара Булатовага багышланган. Тыңлап үткән җыр да К.Булатова сүзләренә язылган..

Үзе туып үскән төбәккә багышлап бик күп шигырьләр язды, шуларның берсе «Сарманым».

**«Сарманым» шигырен сөйли**

**Укытучы:** Тормыш юлына күзәтү ясыйк.

Клара Гариф кызы Булатова 1936 елның 18 мартында Татарстан АССРның Сарман районы Татар Карамалысы авылында туган. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа күрә Кларага бала чактан ук әти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күченеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә. Өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, Ләке мәктәбен ул «бик яхшы» билгеләренә генә тәмамлый. Чыгарылыш җыелышында мәктәпнең яңа директоры Митрофанов абый: «Отличниклар өчәр метр күлмәклекләр белән бүләкләнә», – дип сөендерә. Ләкин «әллә акчасы булмый, әллә оныта...». Клара апа ул вакыйганы болай дип искә ала: «Сарманга килеп, 8 нче класста укый башлагач, мин тоттым да аңа шигъри калыпта ачык хат яздым: ...Биргән вәгъдә үтәлергә тиеш! Без әле дә өмет итәбез. Июль, август, сентябрь үтте – Октябрьдә бүләк көтәбез! Шуннан бирле мине «Безнең шагыйрәбез» дип атадылар һәм шуннан бирле мин шигырьләр язам».

Урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыга. Шул ук елның көзеннән Клара Булатова үзе дә эшли башлый: Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч сыйныфларда балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәттәге көнкүреш комбинатында кассир, «Төзүчеләр» клубында оештыручы була.

**Укучы:** Клара Булатова шул елларда даими яза башлый. Әле мәктәп елларында ук аерым шигырьләре матбугатта күренгән яшь шагыйрә Әлмәттәге әдәби түгәрәккә йөри, һәм 1956 елдан башлап «Татарстан яшьләре», «Совет Татарстаны» («Социалистик Татарстан») газеталарында, «Пионер» («Ялкын»), «Азат хатын», «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналларында аның күп кенә шигырьләре дөнья күрә.

**«Клара Булатова – кабатланмас мөгаллимә – укытучы шагыйрә»**

Клара Булатованың укытучы гаиләсендә тәрбияләнеп, ата-ана һөнәренә тугры булып, гомерен шуңа багышлавы, иҗатында укытучы шәхесен олылавы бер дә гаҗәп түгел. Укытучылык аңа кан белән бирелгән, ана сөте белән күчкән, гаилә тәрбиясе белән сеңгән.

1965-1969 елларда Клара Булатова Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам иттерә: 1965 елда аның шигъри бәйләме «Дуслык» исемле күмәк җыентыкта басылып чыга. 1967 елда «Язлар алда» исемле мөстәкыйль китабы дөнья күрә.

Университетны тәмамлаганнан соң Клара Булатова Әлмәт районының Яна Кәшер урта мәктәбенә тел әдәбият укытучысы булып килә. 10 ел татар гимназиясендә укыта. 8 елдан артык Әлмәт муниципаль институтында булачак татар теле һәм әдәбияты укытучыларына әдәбият дәресләре бирә. Олуг шагыйрәбезгә хөрмәт йөзеннән, бу уку йорты тарафыннан Клара Булатова исемендәге премия булдырылды.

Тәҗрибәле укытучы буларак, 1978 елда аңа РСФСР Мәгариф министрлыгы тарафыннан «Укытучы-методист» дигән мактаулы исем бирелә. Татар җанлы, тынгы белмәс Клара апабыз 10 еллап «Нур» телерадиокомпанисендә журналист булып эшли. Аның алып барган «Җомга» тапшыруын татар яшьләре зур кызыксыну белән көтеп алалар.

**«Җомга» тапшыруын карап үтү.**

Җитмешенче елларда шагыйрә тагын берничә шигырь җыентыгы чыгарды. Аның бер бәйләм шигырьләре русчага тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә «Детская литература» нәшриятында чыккан «Песня, мечта и любовь» («Җыр, хыял һәм мәхәббәт») исемле күмәк җыентыкка да кертелгән. К. Булатова – 1970 елдан СССР Язучылар союзы члены. Рафаэль Төхфәтуллин исемендәге премия лауреаты. Әлмәт шәһәренең почетлы гражданины.

**Укытучы:** Укытучылык хезмәте – Клара ханымның иҗатының буеннан-буена сузылган үзәк темаларның берсе. Яшьлек оптимизмы, тормышны ихлас ярату, аның киләчәгенә тирән

ышану, самими кичерешләр... авторның шушы үз профессиясе-белгечлеге үзенчәлекләрен тасвирлаган шигъри юлларыннан да ташып-ургылып тора. Шагыйрә бу яраткан хезмәтенә бәхетенең югары бер чагылышы итеп карый, бәхет төшенчәсен дә үз һөнәрендә, укытучы хезмәтендә күрә.

**«Укытучы бәхете» шигыре укыла**

Хәтта укытучының йокы калдырып, үз дәресенә төннәр буе әзерләнеп утыруы да аның өчен олы бер бәхет.

**«Укытучы апаң йокламаган» шигыре укыла.**

Нишләтәсең, укытучының көндәлек тормышы һәм еллык эш режимы да турыдан-туры шушы мәктәп – балалар дөньясы белән бәйле. Мәктәпнең үз чәчү вакыты һәм үз "урак өсте" бар. Мәктәп үз әхлакый кысалары, үз фәлсәфи үлчәмнәре белән яши.

**Укытучы:** Укытучылык хезмәте – Клара Булатова иҗатының буеннан-буена сузылган үзәк темаларның берсе. Ул 40 елдан артык балаларга белем бирә, укучыларында матурлыкны, туган телебезгә мәхәббәт тәрбияли. Ә шигырьләрендә яшьлек оптимизмы, тормышны ихлас ярату, аның киләчәгенә ышану, самими кичерешләр. Шагыйрә балаларны акыллы, тәртипле, шәфкатьле, миһербанлы, инсафлы булып үсәргә өнди. Туган җирне яратырга чакыра. Әти-әниләрне олылауны, хөрмәт итүне таләп итә.

Сүзне нәниләргә бирәбез **(К.Булатованың балалар өчен язган: «Иң кызыклы дөнья», «Курка димәгез әле», «Әләкләргә ярамый», «Беткәнмени», «Әниемнең кызы юк бит», «Әни егет», «Әллә кайсын тыңлыйсы» шигырьләре укыла.**

**4 нче сыйныф укучылары «Туган көн» җырын башкара**

**Укытучы:** Клара Булатова дәресләре – үзе бер дөнья. Аның дәресләрендә тормыш белән поэзия үзара үрелеп бара. Шуңа күрә дә балалар укытучы апаларын тын да алмый тыңлыйлар. Клара апаның шигырьләренә генә хас бер үзенчәлек бар: хатын-кызның эчке дөньясын (ир хатыны да, шагыйрә дә, Укытучы да, Ана да буларак) һәрьяклап ачу, бары тик хатын-кызга гына хас сизгерлек белән тормышның ир-ат язучылар күреп бетерә алмаган мизгелләрен тоя алу сәләте. Үз фикерен шигырь юллары белән тезмәләп сөйли ала торган шагыйрьләребез юк дәрәҗәсендә. Ир-ат шагыйрьләрдән Хәсән ага Туфан булса, шагыйрәләребез арасында Клара апа Булатова булыр.

**«Су буенда кыяк үлән» җыры яңгырый.**

**Укытучы:** Клара Булатованың иҗаты күпкырлы. Аның балалар өчен дә кызыклы әсәрләре бар, ул өлкәннәр өчен дә язган. Шигырьләре хис-кичерешләргә бик бай, алардан моң агыла. Шуның өчен дә шагыйрә матур-матур җырлар авторы буларак танылды. Җырларда туган як, мәхәббәт темасы үзәк урынны алып тора. Шагыйрәнең күп кенә лирик шигырьләренә Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан музыка язылган, җырлары да аерым җыентык булып чыкты.

Иң беренчеләрдән булып Клара апаның шигырьләренә Рәис Нагыймов көй яза. Аларның уртак жимеше «Шушы яктан, шушы туфрактан без» җыры. Кичәбезне без шул җырдан башладык.

«Эй, Ирекле, Ирекле», «Шушындый тыныч төннәрдә», «Тамчы җыры», «Төштә курдем», «Татлы инеш», «Ай яктылары микән?» җырлары да – аларның уртак җимешләре.

**«Кырга чыктым, юлга чыктым» җырын тыңлау.**

**Укытучы:** 2015 елда Клара Булатовага Габдулла Тукай исемендәге премия тапшырылды. Рафаэль Төхфәтуллин, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр иясе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (һәм атказанган мәгариф хезмәткәре дисәк тә дөрес була), Әлмәт шәһәренең почётлы гражданины Клара Гариф кызы Булатова иҗатын балалар да, яшьләр дә, олылар да яратып укый, яттан өйрәнә, шигырьләренә көйләр яза. Һәм үзләре дә иҗатка тартыла. Клара апаның хәзер зур горурлыгы – оныгы Гайшәнең шигырьләре дөнья күрә. «Дәвамчым бар», – дип сөенә ул...

Нинди генә заманнар, нинди генә шартлар туса да, шагыйрь булып кала. Клара апа моны үз язмышында, үз иҗатында кире каккысыз итеп раслый килә. Клара апаның иҗат чишмәсе саекмасын, яңадан-яңа җыентыклары дөнья күрсен теләктә калабыз.

**К.Булатова – безнең яраткан шагыйребез**
(Күңел ачу кичәсе)

Талибуллина Динара Халит кызы,
Җәлил бистәсенең 6 нчы балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

**Максат:** Балаларда К.Булатованың күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту, ихтирам хисләре тәрбияләү. Шигырьнең эчтәлеге буенча үз фикерләрен әйтә белү, фикерләү, хәтер сәләтен үстерү. К.Булатова шигырьләре аша балаларда матур әдәбият белән кызыксыну, аларда укырга теләк тәрбияләү.
**Материал:** К.Булатова портреты, китаплар күргәзмәсе, аудиоязмалар, «Әлли бәлли бәү», «Март башында» җырлары.

Зал бәйрәм чарасына туры китереп бизәлгән. Салмак кына көй яңгырый. Көй астына залга балалар керәләр.

Т: Хәерле көн, кадерле балалар! Исәнмесез, кәефләрегез ничек? Күрәм, кәефләрегез яхшы, күңелләрегез шат. Балалар, тәрәзәгә карагыз әле, бүген көн нинди? (Балаларның җаваплары).
Т:– Ә хәзер елның нинди фасылы? (Балаларның җаваплары).
– Сез, яз дип нинди күренешләрдән чыгып әйтәсез? (Балаларның җаваплары).
– Балалар, әйтегез әле, яз нинди истәлекләргә бай ул? (Балаларның җаваплары).
Т: Бик дөрес, балалар, яз аенда күренекле шагыйрь К.Булатова туган.
**1 слайд:** Клара Булатова 1936 елның 18 мартында Татарстан АССРның Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туган.
**2 слайд:** Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа күрә Кларага бала чактан ук әти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күчеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә.
**3 слайд:** 1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә, өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, ә урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыга.
**4 слайд:** Шул ук елның көзеннән К. Булатова хезмәт юлын башлый: Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч классларда балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәттәге көнкүреш комбинатында кассир, «Төзүчеләр» клубында оештыручы була. 1962-1965 елларда ул яңадан мәктәптә – Әлмәт районының Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта.
**5 слайд:** Клара Булатова 1960 еллардан башлап сез нәни дусларга шигырьләр яза башлый. Дистәдән артык шигырь китапларын бастырып чыгара. Аның сүзләренә күп кенә җырлар да язылган.
**6 слайд:** Ә хәзер сүзне зурлар төркеменә йөрүче нәни дусларыбызга: .............. бирәбез. (*Балалар К.Булатова шигырьләрен сөйлиләр*)
Т: Афәрин, балалар, менә безнең арабызда нинди сәнгатьле итеп шигырь сөйләүчеләр үсеп килә икән бит.
**7 слайд:** К.Булатова кечкенәдән табигатьне, җан ияләрен яраткан, аларга карата миһербанлы, шәфкатьле булырга өндәгән. Әйдәгез, хәзер Алия һәм Нияз башкаруында «Урманда», «Март башында» шигырен тыңлап үтик.
Т: Балалар, сез К.Булатованың бик күп шигырьләрен беләсез. Хәзер сезнең белән бер уен уйнап алырбыз. Бу уенның исеме «Рәсем кайсы шигырьдән?» дип атала. Мин сезгә рәсемнәр күрсәтәм, ә сез бу рәсемнең нинди шигырьгә туры килә икәнен әйтерсез:
**Уен: «Кайсы шигырь кирәк-яраклары»**
- Сәгать, карга, җиләк, солдат, ат.
Т: Балалар, сез бик күп шигырьләр беләсез. Әйдәгез, хәзер ял итеп алыйк.
**Ял минуты «Унга кадәр» уены.**

Марсның бармаклары –
Санагыч таяклары.
Бер турайта, бер бөгә,
Унга кадәр сан белә.
Әти белән әни, ди,
Бабай белән әби, ди,
Үзем, абый һәм апа,
Боларга кушкан чакта
Бозау белән песи, ди,
Алай да җитешми, ди,
Этемне дә син куш, ди,
Унынчысы – Актүш, ди.
Әминә «Рәхәт чак» дигән шигырь сөйли. Шигырь сөйләү барышында, акрын гына моңлы көй уйнатыла.
**9 слайд:** Шигырь: «Рәхәт чак»
Т: Балалар, җиһанда – яз. Димәк, эшнең тагын да кызу вакыты җитте дигән сүз. Кулларыбызны эшкә күнектереп алыйк әле.
**10 слайд:Уен «Булышу»:**
Тышка чыктык,
Кулга пычкы тоттык.
Утын кистек:
Зиң-зиң, зиң-зиң.
Ике кулга балта тоттык,
Утын ярдык:
Ддак-ддак, дддак-дддак.
Өйгә кайттык.
Т: Балалар, бәйрәмебез ахырына якынлашты. Хәзер бергәләшеп К.Булатованың «Сөенеч» шигыренә күмәк рәсем ясап алыйк.

**Үзеннән-үзе туа җыр**
(Әдәби-музыкаль кичә)

Галимҗанова Галия Равил кызы, Азалак төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

Залда К.Булатованың китап күргәзмәсе. Кичә барган вакытта презентация күрсәтелә. Кичә «Туган як» җыры белән башланып китә.

**А.б.** Бездә кунакта шушы җырның авторы, яраткан шагыйрәбез Клара Булатова. Ул безгә ерактан, Әлмәт шәһәреннән үк үз итеп, яратып, табигатьнең нинди булуына карамастан, яңгырлы, салкын көннәр торса да безгә җылылык, яктылык алып килде. Без аңа зур рәхмәт белдерәбез.

Клара апа Булатова ул безнең якташ язучыбыз, чөнки тумышы белән җырларда көйләнгән, бик күп мәшһүр затларны, шул исәптән әдәбият һәм сәнгать әһелләре биргән атаклы халык моңының табигый төбәге Сарман ягы Татар Карамалы авылыннан, укытучылар гаиләсеннән. Әтисе – математик һәм мәктәп директоры, әнисе – тел-әдәбият укытучысы булган. Клара апалар гаиләдә биш бала үскән. Башлангыч белемне ул Югары Чыршылы авылында ала (1944 елда). Ә 1946-1951 уку елын Ләке мәктәбендә дәвам итә. Аннан соң инде Сарман урта мәктәбе. Сарман урта мәктәбендә укыганда, Клара апаның байтак кына шигырьләре район газеталарында гына түгел, үзәк матбугатта, «Чаян» журналында да басылып чыга. Аның күпчелек шигырьләре табигатькә, туган якка багышланган.

Ә хәзер без «**Табигать дусты»** дигән шигырен тыңлап үтәрбез.

**А.б.** Шулай итеп Клара апа 1954 елда Сарман мәктәбен тәмамлый. Шул ук елның көзендә хезмәт юлын Түбән Ләшәү башлангыч мәктәбендә балалар укытудан башлый. Аннан соң

төзелештә эшли. 1962-1965 елларда ул яңадан мәктәптә әдәбият, тарих укыта. Аның шигъри иҗаты да нәкъ шул чорда тернәкләнеп китә. Алай гына түгел аның байтак шигырьләренә композиторлар көй яза. «Су буе» дигән шигыренә Роберт Андреев көй язган, менә шул җырны тыңлап үтик.

**А.б.** Әле мәктәп елларында ук аерым шигырьләре мәтбугатта күренгән яшь шагыйрә актив рәвештә Әлмәттәге әдәби түгәрәккә йөри һәм 1956 елдан башлап аның шигырьләре, хикәяләре «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан» газеталарында, «Идел» альманахында, «Азат хатын» («Сөембикә»), «Совет әдәбияты» журналларында да басыла. (Шигырь укыла).

**А.б.** 1965-1969 елларда Клара Булатова В.И.Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле, әдәбияты бүлегендә укый. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам итә. 1965 елда аның шигъри бәйләме «Дуслык» исемле күмәк җыентык та басылып чыга. 1967 елда «Язлар алда» исемле мөстәкыйль китабы – лирик шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Шушы җынтыкка кергән берничә шигырь, җырларны тыңлап үтик әле.

Рәис Нәгыймов музыкасы, Клара Булатова сүзләре «Шушы яктан, шушы туфрактан без»

**А.б.** Чынлап та, Клара Булатова – шагыйрь булып туган кеше, шигырь җанлы, талантлы, тормышны чын дәрәҗәсендә аңлап, туган ягына, табигатенә мәхәббәтен эчке кичерешләре, уй-фикерләре аша чагылдыручы бик популяр шагыйрә. Исеме җисеменә туры килгән, авторның холык-фигылен ачып бирүче шигырь җыентыклары да шуны раслый. Ул яшәгән төбәкнең басулары киң, тугайлары иркен, урманнары төрле нигъмәт-сыйга юмарттыр. Көмештәй саф сулы чишмәләре, салкын инешләре, зәңгәр офыклары, сайрар кошлары үтә дә моңлыдыр. Шигъри җанлы хатын-кызлары туу өчен бөтен шартлары булган як ул. (Шигырь)

**А.б.** Клара апа – баш-аягы белән авыл шагыйрәсе. Аның шигырьләрендә авыл табигате: җырлы, кәккүкле урманнар, дулкынланып, гөҗләп утырган арыш, өч буын сикерткән бодай, тал-тирәкле елга-инеш буйлары, мул итеп керендереп яуган яңгырлар татар авыл теле белән җырлап торалар. (Җыр)

**А.б.** Яшьләр, мәхәббәт һәм яз. Аның шигырьләре дә, җырлары да, хыял-омтылышлары да бар нәрсәдән бигрәк мәңгелек яшьлек, мәңгелек мәхәббәт, мәңгелек яз турында. Язгы сулар кебек ярсып ташкан хисләрне, яшьлек ашкынуын шагыйрәнә әйтеп биргән юлларның авторын халык ничек үз итмәсен дә, шагыйрем дип аның шигырьләрен көйгә салып нигә җырламасын? (Җыр)

**А.б.** Клара Булатованың матурлыкка, рухи гүзәллеккә дан җырлаган әсәрләре күңелләрне иркәләп торган шигъри аһәң музыкаль агышы белән композиторларны һәм халыкны үзенә тартып, чакырып тора. «Бәлки син үзедер», «Кырга чыктым, юлга чыктым», «Су буенда кыяк үлән», «Кыңгырау чәчәкләре», «Якын дустың барын онытма», «Фазилә», «Зөлфия җыры», «Арада тау киртә түгел», «Карлыгандай кара күзләрең», «Синең белән» – болар шагыйрә Клара Булатованың сүзләренә язылган җырларның бер өлеше генә. Ул җырлар бүген күпләрнең яшьлек хатирәләрен искә төшереп яңгыраса, кем өчендер әле дә дөрләп торган хис учагы, күңел һәм җан юлдашы булып калалар. Димәк, җыр картаймый, җыр дәвам итә. (Җыр).

**А.б.** Клара апа әле ул җанына газиз һәм кадерле авыл хатын-кыз образлары, шул арны яратып, сокланып язучы шагыйрә дә. Анда ак күлмәк, ак яулык бәйләгән апалар, ак алъяпкычларын җилфердәтеп эшләп өйргән уңган киленнәр, фермаларда хезмәт куйган бик чибәр, бик шаян, вәгъдәләренә тугрылыклы булып, ятларга карамый торган яшь кызлар – барысы да бик бәхетле кешеләр. Ә хәзер аның шигырьләрен яратып укучы килгән кунакларыбызга сүз бирәбез.

**А.б.** Әйе, Клара Булатова – лирик шагыйрә. Лирик шигырьләрендә ул үзенең замандашларының күңел тирбәнешләрен табигать күренешләренә бик оста итеп бирә белә. Аның шигырьләрендә ак төсләр, көзге урманнар, саргая башлаган яфраклар, урак көткән басукырлар, кеше гомеренең бер моңсу мизгеле булып кабул ителә. (Шигырь).

**А.б.** Клара апа университетны тәмамлаганнан соң 25 елын шәһәрдән авылга йөреп Әлмәт районының Яңа Кәшер, Колшәрип, Түбән Мактама мәктәпләрендә укытып үткәрә. 1978 елда Клара Булатовага РСФСРның Мәгариф министрлыгы тарафыннан «Укытучы-методист» дигән мактаулы исем бирелә. Аннан соң ун ел Әлмәт татар гимназиясе. 1991 елдан Әлмәттә

барлыкка килгән «Нур» телерадиокомпаниясендә һәм 2001 елдан Әлмәт муниципаль институтында әдәбият укытучысы була. Гомер буе юлда йөреп эшли, шуның өстенә 35 елдан артык язучылар берлеге әгъзасы булып та сыңар көн дә «Мин – профессиональ язучы» дип каләм башы суырып, иҗат итеп утыра торган шәхес түгел. Клара апага иҗаттагы уңышлары өчен Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә. Шулай ук ул – Рафаил Төхфәтуллин исемендәге әдәби бүләк иясе дә. Г.Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясенә лауреаты булган шәхес тә. Шуның өчен дә аңа безнең белән яшәве һәм иҗаты өчен рәхмәт әйтәсе килә. Сезнең иҗатыгыз турында сөйләү өчен әллә никадәр вакыт кирәк булыр иде. Киләчәктә дә, Клара апа, Сез безне яңа шигырьләрегез белән шатландырсагыз иде. Яраткан шагыйрәбез турында без әйтеп бетерә алмаган сүзләрне сезнең шигырьләрегез-җырларыгыз сөйләп куандырсын иде дип өмет итеп калабыз.

Кичәбезне дәвам итеп, Клара апаның сүзләренә иҗат ителгән «Кыр» исемле җырын тыңларбыз. Ә хәзер сүзне Клара апаның үзенә бирәбез, рәхим итегез.

## Сүз төркемнәрен гомумиләштереп кабатлау темасы буенча якташ шагыйрәбез Клара Булатова шигырьләрен файдаланып эшләнгән контроль эш

Якупова Гүзәлия Фаиз кызы, икенче санлы Җәлил мәктәбе,
Сарман районы

Укучыларыбызда чыгышы белән туган төбәгебездән булган күренекле шагыйрьләрнең шигырьләре белән кызыксыну уяту йөзеннән, аларның әсәрләреннән алынган текстларны файдалану бик отышлы. Бу әдәби текстлар (өзекләр) үзендә кешелеклелек сыйфатлары булдырырга ярдәм итә, матурлыкка, әдәплелеккә өнди.

**Аңлатма язуы**

Контроль эш рус мәктәбенең татар төркемендә укучы 4 нче сыйныф укучыларының «Сүз төркемнәрен гомумиләштереп кабатлау» темасы буенча алган белемнәрен тикшерү максатыннан төзелде. Контроль эш 3 өлештән тора. Беренче өлештә (1-10 нчы биремнәр) – тестлар, икенче өлештә (11-15 нчы биремнәр) – үтелгән темалар буенча төрле биремнәр, 16 нчы биремдә иҗади эш тәкъдим ителә. Белемнәрне тикшерү эшенең күләме программа таләпләреннән чыгып билгеләнде. Ул 45 минутка исәпләнгән.

**1 нче вариант**

**1 нче өлеш**

1. Калынлык билгесе (ъ) төшеп калган рәтне күрсәтегез.
   1) Сәнгат..., сәгат...
   2) Мөстәкыйл..., ям...ле
   3) Дән...я, дәр...я
   4) Кул...язма, мәг...нә
2. Хаталы сүзләр рәтен күрсәтегез.
   1) Каләм, ямь
   2) Кәгазь, ихтирам
   3) Тәкдим, яш
   4) Тирә-юнь, әһәмият
3. Болар нинди сыйфатлар?
   ***Көчле-көчсез биек-тәбәнәк***
   1) Омоним сыйфатлар
   2) Синоним сыйфатлар
   3) Антоним сыйфатлар
   4) Монда сыйфатлар юк
4. Фигыльгә ялгана торган юклык кушымчасын табыгыз.
   1) –сыз, -сез
   2) –да, -дә
   3) –ма, -мә
   4) –нар, -нәр

5. Бирелгән сүз төркеме нәрсәне белдерә?
   ***Сыйфат***
   1) Предметның эшен
   2) Предметның билгесен
   3) Предметның исәбен, санын
   4) Предметны
6. Киләчәк заман хикәя фигыльне табыгыз.
   1) Бара
   2) Барачак
   3) Барды
   4) барган
7. Ясагыч кушымчалы сүзләр төркемен табыгыз.
   1) Балчык, алачык
   2) Китап, балалар
   3) Озынборын, ап-ак
   4) Белемле, камышлык
8. Парлы сүзне табыгыз.
   1) Бал(корты)
   2) Мүк(җиләге)
   3) Кечкенә(абый)
   4) Бала(чага)
9. Сүзтезмәне күрсәтегез.
   1) Көн матур
   2) Матур көн
   3) Көн бик матур
   4) Көн
10. Туры килгән билгеләмәне күрсәтегез.
   ***Җыйнак җөмлә***
   1) Баш һәм иярчен кисәкләре булган җөмлә
   2) Тойгылы интонация белән әйтелгән җөмлә
   3) Тыныч интонация белән әйтелгән җөмлә
   4) Баш кисәкләрдән генә торган җөмлә

**2 нче өлеш**

(1) Тәрәзәдән өйгә көн кергән,
Бүләк итеп кояш китергән.
(2) Бөтен кеше эштә чакта, ди,
(3) Тор, тор, Марс! Йоклап ятма! – ди.
(4) Бәрәңгеләр үсеп җиткән, ди,
(5) Помидорлар пешкән күптән, ди,
(6) Бакчага чык, тизрәк җыеш, ди,
(7) Әбиеңә, әйдә, булыш, ди.
(8) Сикереп торды Марс, киенде
Һәм бакчага чыгып йөгерде.
(9) Бүген безгә шундый көн килгән, –
Кояш белән Хезмәт китергән.
(Клара Булатова)

11. **Кояш** сүзендә ничә аваз бар? Сан белән языгыз.
12. 1 нче җөмләдән юнәлеш килешендәге исемне табып языгыз.
13. **Бакчага** сүзенең ясалышын языгыз.
14. 6 нчы җөмләдәге **чык** сүзенең антонимын языгыз.
15. 5 нче җөмләнең иясе белән хәбәрен табып языгыз.

**3 нче өлеш**

16. «Мин әбигә булышам» темасына 8-10 җөмләдән торган хикәя языгыз.

**2 нче вариант**

**1 нче өлеш**

1. Нечкәлек билгесе (ь) төшеп калган рәтне күрсәтегез.
   1) Тәк...дим, ар...як
   2) Мөстәкыйл..., ям...ле
   3) Вәг...дә, иг...тибар
   4) Кул...язма, мәг...нә
2. Хаталы сүзләр рәтен күрсәтегез.
   1) Каләм, ямь
   2) Кәгазь, ихтирам
   3) Төньяк, шагыйрь
   4) Тирә-юн, әхәмият
3. Болар нинди сыйфатлар?
   ***Җылы, кайнар, эссе***
   1) Омоним сыйфатлар
   2) Синоним сыйфатлар
   3) Антоним сыйфатлар
   4) Монда сыйфатлар юк
4. Фигыльгә ялгана торган юклык кушымчасын табыгыз.
   1) –сыз, -сез
   2) –ды, -де
   3) –мый, -ми
   4) –нар, -нәр
5. Бирелгән сүз төркеме нәрсәне белдерә?
   ***Сан***
   1) Предметның эшен
   2) Предметның билгесен
   3) Предметның исәбен, санын
   4) Предметны
6. Киләчәк заман хикәя фигыльне табыгыз.
   1) Бара
   2) Барыр
   3) Барды
   4) барган
7. Ясагыч кушымчалы сүзләр төркемен табыгыз.
   1) сыерчык, ашъяулык
   2) батырлык, авылдаш
   3) озынборын, ап-ак
   4) унбиш, җир җиләге
8. Парлы сүзне табыгыз.
   1) Сабан(туй)
   2) кура(җиләге)
   3) Көн(чыгыш)
   4) Савыт(саба)
9. Сүзтезмәне күрсәтегез.
   1) Җир җиләге
   2) Тәмле җиләк
   3) Кура җиләге
   4) Мүк җиләге
10. Туры килгән билгеләмәне күрсәтегез.
    ***Җәенке җөмлә***
    1) Баш һәм иярчен кисәкләре булган җөмлә
    2) Тойгылы интонация белән әйтелгән җөмлә
    3) Тыныч интонация белән әйтелгән җөмлә
    4) Баш кисәкләрдән генә торган җөмлә

**2 нче өлеш**

(1) Әниемнең кызы юк бит,
Мин әнигә бер генә.
(2) Кызы да юк, эше дә күп
Әнинең берүзенә.
(3) Әниемнең кызы юк шул,
Мин булышам әнигә.
(4) Аш пешерәм, җыештырам,
Кер юышам әнигә.
(5) Магазиннан сөт апкайтам,
Ипигә дә йөгерәм.
(6) Әниемнең кызы юк та –
Малае бар бер дигән.
(Клара Булатова)

11. **Юышам** сүзендә ничә аваз бар? Сан белән языгыз.
12. 1 нче җөмләдән алмашлыкны табып языгыз.
13. **Ипигә** сүзенең килешен билгеләгез.
14. 3 нче җөмләдәге **булышам** сүзенең синонимын языгыз.
15. 4 нче җөмләдән тиңдәш кисәкләрне табып языгыз.

**3 нче өлеш**

16. «Мин әбигә булышам»   темасына 8-10 җөмләдән торган хикәя языгыз.

## Таяну ноктасы кайда?

(Ф.Яхинның «Ак әбиләр догасы» әсәре буенча сыйныфтан тыш эшчәнлек дәресе)

Шәйдуллина Л.К., Шәйдуллина Ч.К., икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары,
Сарман районы

Максат. Укучыларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү. Башкаларны тыңлау, тормыш тәҗрибәсенә, укылган әсәргә таянып, үз фикереренеңне дәлилләп әйтә белүне, фикерләү сәләтен үстерү. Әти-әниләре алдында гомер буе бурычлы икәнне, төрле шартларда кеше булып калырга кирәклекне аңлап калуларына ирешү.
Чарага өлкән буын вәкилләре, дин әһелләре, өлкән сыйныф укучылары чакырыла.

**Чара барышы**

Талгын гына музыка яңгырый. Укучы шигырь укый.

Әниләрне фәрештәләр, диләр,
Фәрештәләр була канатлы.
Ә минемчә, газиз әнкәйләрнең
Балаларыдыр ул канаты.
Канатларны Раббым каермасын,
Сау-сәламәт булсын балалар!
Җан җимеше таза булса гына
Тыныч яшәр җирдә аналар.

Бала бит ул – җаның кебек газиз,
Алар өчен йөрәк өзелә.
Бала хәсрәтләре күрми генә,
Җитсәк иде гомер көзенә!

Гөлара Шәрипова

**Укытучы.** Исәнмесез, укучылар, укытучылар, әти-әниләр. Сезне түгәрәк өстәлебез артында күрүебезгә шатбыз. Бүген кеше яшәешендә таяну ноктасының кайда булырга тиешлеге хакында сөйләшүгә чакырасыбыз килә. Чакыруны кабул иткәнегезгә рәхмәт. Очрашуыбыз истәлекле, файдалы булсын иде.

Язның иң матур, беренче бәйрәме якынлаша. Элина укыган шигъри юлларны кабатлыйсы да кабатлыйсы килә:

Әниләрне фәрештәләр, диләр,
Фәрештәләр була канатлы.

Мин бәхетле. Минем ике канатым – әтием һәм әнием бар. Алар булгач, миңа рәхәт, тыныч. Алар – минем таянычым, яклаучым, саклаучым. Гомер узган саен, кеше туган нигезнең, ата-ананың кадерен ныграк аңлый, тоя башлый. Бу хис күңелне никадәр иртәрәк биләп ала, кеше шулкадәр игелекле булыр иде кебек. Татар халкының «Оҗмах аналарның аяк астында» гыйбәрәсе шул хакта искәртә бит. Кеше кайда гына йөрмәсен, аны әнисенең изге догасы озата.

«Әнкәйнең догалары» җыры яңгырый.

**Укытучы**. Сөйләшүебезне, укучылар, сездән башлыйк әле. Нәрсә ул дога? Дога сүзен сез ничек аңлыйсыз? Ул сезнең тормышыгызда урын алганмы? (Укучыларның җавапларын тыңлау)

Укучы Вил Казыйхановның «Әбием догалар укый» шигырен укый.

**Укытучы.** Инде сорауны өлкәнрәк буын кешеләренә – эти-әниләргә бирик. Нәрсә ул дога? Ул сезнең тормышыгызда бармы? (Әти-әниләрнең җавапларын тыңлау)

**Укытучы.** Шушы ук сорауны минем дин әһелләренә юллыйсым килә. (Дин әһелләре җавабын тыңлау)

**Укытучы.** Укучылар, без сезнең белән якташыбыз Ф.Яхинның «Ак әбиләр догасы» дигән хикәясен укыдык, анализладык. Хикәя балачак, туган як, авыл тормышы, дин белән бәйле, дидек. Аның үзәгендә – ак әбиләр образы.

Соравым өлкән буын кешеләренә: әби белән ак әби арасында аерма бармы? Булса нинди? (Өлкәннәрнең җавапларын тыңлау)

**Укытучы.** Балалар, ак әби дәрәҗәсенә күтәрелү өчен ничек яшәргә кирәк икәнен, әйдәгез, дин әһелләреннән сорыйк әле. (Дин әһелләрен тыңлау)

Экраннар аша чишмә агышын күрсәткән презентация күрсәтелә.

**Укытучы.** Хикәядә Әүлияләр чишмәсе турында сүз бара. Нинди чишмә соң ул? Ник шулай атала? Игътибар – экраннарга.

Иске Минзәләбаш авылының Әүлия чишмәсе турында ролик күрсәтелә.

**Укытучы.** Укучылар, безнең халкыбыз элек-электән суга, чишмәләргә сак караш белән яшәгән. Аларның пычрануына юл куймаган. Алар хәзерге кебек затлы итеп төзекләндерелмәгәннәр, тик халык аның янын һәрчак чиста тоткан, бүгенге кебек чүп өемнәре булмаган анда. Бүген чишмәләр янында ниләр генә күрмисең.

Экран аша бистә яны чишмә яннарындагы чүп өемнәре күрсәтелә.

**Укытучы.** Ә бит кешеләр элек-электән чишмә суы белән юынып, шуны эчеп дәваланганнар, аның көченә ышанганнар. Без укыган Р.Мөхәммәдиевнең «Беренче умырзаялар» әсәре – моның ачык мисалы. Чишмә суы дәвалый аламы? Әйдәгез белгечләрне тыңлый. (Килгән кунакка сүз бирелә, я видеоролик күрсәтелә)

«Җидегән чишмә» җыры яңгырый.

**Укытучы.** Кире укылган әсәргә кайтыйк әле, укучылар. Аның соңгы абзацын укыйбыз. Автор безгә нәрсә әйтергә теләгән? (Әсәрнең идеясен ачу. Укучыларның фикерләрен тыңлау)

**Укытучы.** Әсәр ни өчен шулай аталган дип уйлыйсыз? (Фикерләрне тыңлау)

**Укытучы.** Без – бик бәхетле кешеләр. Әсәрнең авторы Фәрит абый Яхин – безнең якташыбыз. Язучы, шагыйрь һәм мөгаллим Ф.Яхин 1961 елда Сарман районы Дүсем авылында туган. Казан дәүләт университетында белем алган. Фәнни эшчәнлеген Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында башлый. Ул Г.Тукай музее директоры да була. Күренекле әдәбият белгече, филология фәннәре докторы. Сарман менә шундый күренекле кешеләре белән горурланып яши.

Безне уйланырга мәҗбүр итә, түгәрәк өстәл артына җыя алырлык әсәрләр әдәбиятыбызда мулдан безнең. Бары кызыксынырга, укырга, үз фикереңне әйтергә курыккмаска һәм ак әби, ак бабайлар кебек күпләргә үрнәк булып яшәргә, туган җирне, телне, әни-әниләрне кадерләп яшәргә, кеше булырга омтылырга кирәк. Барыгыз да бу

фикерләр белән килешерсез дип уйлыйбыз һәм яшәешебездә таяну ноктасы шушы булырга тиеш дип сезнең белән саубуллашабыз. Ә сезнең игътибарыгызга якташыбыз Ф.Яхинның тагын бер бик мәгънәле шигырен тәкъдим итәбез.

Укытучы Ф.Яхинның шигырен яттан сөйли.

**Рәхмәт сезгә, әнкәйләр!**

(«Әниләр кадере» темасына Әзһәр Габиди иҗатыннан файдаланып язылган әдәби- музыкаль чара)

Нәбиуллина Фәридә Әнвәр кызы, Зиннәт Хәсәнов исемендәге Иске Кәшер урта мәктәбе, Сарман районы

Гамьсез балачакны кемнәр генә искә алмый икән. Шул истәлекләрне барлаганда каршыбызга әниләребезнең мөлаем күз карашы килеп баса. Егылганда, абынганда, елаганда сабыйларга иң беренче әни кирәк.

(Биләүсәдә бәби ята. Әни кеше биләүсәне тирбәтә. Бишек җыры ишетелә.

Куанычларым, шатлыгым булып,
Балам-багалмам, үсәрсеңме син?
Сагынып җырлар җырыма минем,
Күземнең нуры, кучәрсеңме син?

Шатлыгыннан каң-каң килә
Болында бер йорт казы,
Як-ягында бөтерелә
Сап-сары йомгаклары.
Күз алдымнан йөгереп үтә
Балачагымның язы.
Искә төшә, сагындыра
Әнкәйнең җылы назы.
Тәүге тапкыр тәпи баскан көннән
Йөртмәсәң дә мине кулыңда,
Гел торгансың күз һәм колак булып,
Абындырмый мине юлымда.
«Талбишек» җыры яңгырый

Беренче тапкыр үз телебезнең матурлыгын, байлыгын күрсәтүче кеше дә ул – әни. Чөнки һәрбер сабыйның тәүге сүзе әти-әни. Димәк милләтебезнең язмышын билгеләүче кеше дә ул – әни.

Теле, иле барлар яши ала,
Тел, ил барда әле без – кеше.
Теле, иле барның җыры була,
Җыры барның матур һәр эше.

«Туган телем» җыры

Үсеп буйга җитеп, җиде юл чатында үз язмышыңны сайлар вакыт житкәч тә, без әниләргә мөрәҗәгать итәбез. Чөнки әни кеше генә сине чын- чынлап аңлый, белә. Әниләрнең киңәшләре генә чын мәгънәсендә сиңа кирәкле.

Юлыксам бәла-җәфага,
Үзеңне, дип, җәфалама,
Әнкәй миңа киңәш итә,
Ә үзе борчыла бик тә,
Ә үзе борчыла бик тә.
Начар дустымнан арынсам,
Абынганда торып бассам,
Ул миннән дә нык шатлана,

Шушы сүз мең кабатлана:
Ялгышыңны кабатлама,
Ялгышыңны кабатлама...
– Горурлардан, улым, горур бул,
Батырлардан, улым, батыр бул,
Кыюлардан, улым, кыю бул,
Матурлардан, улым, матур бул.
Ялган белән берүк мавыкма,
Буш сүз белән кеше каралтма.
Гел изгелек ит син кешеләргә
Яманатың җирдә таратма.
Рәхмәт,  әнкәй, киңәшләрең өчен,
Чыкмас алар минем уемнан,
Синең әйткән һәрбер асыл сүзең
Йөрәгемә тирән уелган.

Тормыш аклы да була кара да. Тормышның үз законнары. Бу тормышның җил-давылларында сыгылмас өчен ныклы терәк ул – әни. Нәрсә генә булса да, нинди генә авырлыклар килсә дә ана кеше үз баласын саклый, яклый торган бердәнбер зат. Беркемгә дә сөйләнмәгән тирән серләр дә бары аңа гына сөйләнә.

Барган юлым сикелтәле булып,
Бәла-казаларга юлыксам,
Киңәш- табыш сорап,
Ярдәм көтеп,
Әнкәй, синең янга юл тотам.
Үз хәсрәтең баштан ашканда да,
Безнең өчен янып-көясең.
Барлык кайгыларың читкә куеп,
Безнең белән бергә көләсең.

Җыр: «Иң якын кешем син»

Дөнья шулай корылган, бернәрсә дә мәңгелек түгел. Кеше җиргә туа, яши һәм беркөнне мәңгелеккә китеп бара. Әниләр дә мәңгелек түгел. Әмма аларның баласына булган мәхәббәте, кайгыртуы беркайчан да үлмәячәк. Еллар дәвамында балаларны  тормышның җил-давылларыннан саклаучы – әниләрнең догасы.  Ак канатлы фәрештәләр кебек, алар безне гомер буе саклап барачак.

Миндә шундый гадәт инде:
Булса юлга чыгасым,
Үзем белән бергә алам
Әткәм- әнкәм догасын.
Беләм бит мин ул доганың
Маяк булып янасын,
Кыйбламны бутамаска
Юлымны яктыртасын.

Бар әле минем, бар әле
Бик күп юллар урасы:
Исән-имин әйдәп барыр
Әткәм- әнкәм догасы

«Әнкәмнең догалары» җыры

**Марс – уңган егет ул**

(Клара Булатованың тууына 85 ел тулуга багышланган башлангыч сыйныф укучылары өчен әдәби-музыкаль кичә)

Сәмигуллина Гөлсем Малик кызы, Урманай авылы гомуми урта белем бирү мәктәбе, Азнакай районы

**Катнашалар:**
*Алып баручы*
*Кыз*
*Малай*
*Марс*
*Әни кеше*
*Башлангыч сыйныф укучылары*

**Кичәнең максаты:** Төбәгебездә яшәп иҗат итүче шагыйрәбез К.Булатованың иҗаты белән таныштыру, кызыксыну уяту. Сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру, шигырьләрне аңларга һәм яратырга өйрәтү.

**Җиһазлау**: К.Булатова китапларыннан күргәзмә, презентация, «Шушы яктан, шушы туфрактан без» дип исемләнгән фоторәсемнәр стенды, «Шушы яктан, шушы туфрактан без» җыры язмасы.

**Кичәнең барышы.**

*Йөгереп алга кечкенә генә бер малай чыга.*

**Малай**. Мин зур инде, дусларым,
Санарга да өйрәндем.
Бармакларны турайтам, аннан бөгәм
Унга кадәр сан беләм.

**Алып баручы**.Яле, яле, сана әле,
Ялгышмассыңмы әле*?!(Көлә*)

**Малай**. Әти белән әни,
Бабай белән әби,
Абый, үзем һәм апа,
Авылга кайткан чакта
Бәрән белән песи,

**Алып баручы**. Алай да җитешми,

**Малай**. Этемне дә син куш,
Унынчысы – Черныш,
Черныш-Черно-Ушкаем,
Кара колак дускаем.

**Алып баручы**.Туктале, үскәнем, син миңа кемнедер хәтерләтәсең ич*?(Уйлана*)
Син бит, син бит....
Әйе шул, шикәр алырга, диеп
Кибеткә киткән малай.
Онытып ник килгәнен
Бер басасын биш атлап
Аю кайттың кочаклап.*(Көлә)*

**Малай**.Әллә, апа, син мине беләсеңъ? Сезгә дә ишетелдеме инде ул маҗарам минем?

**Алып баручы**.Ничек танымаска инде сине, Марс? Балалар да таныды. Шулай бит, балалар?

**Кыз**. Әйе, Марс, син бит безнең бик яраткан героебыз.

**Малай**. Сине безгә Клара апабыз Булатова бүләк итте.

**Марс**. Бик дөрес, Клара апабызның иҗатын, димәк, сез дә яратасыз? Беләсегез килсә, бу ел 18 мартта Клара Гариф кызы Булатовага 85 яшь тула.

**Малай**. Анысын да беләбез. Ничек яратмый, ди, Марс, яратабыз.

**Алып баручы**.Кадерле балалар, без бүген Клара апабыз Булатованың иҗаты буенча сәяхәт итәргә булдык. Марс, бәлки син дә безгә кушылырсың?

**Марс**.Бик кызык булырга ошап тора. Мин риза. Киттек.

*Клара Булатованың «Әниемнең кызы юк бит» шигыре сәхнәләштереп күрсәтелә.*
**Алып баручы**. Балалар, ә шагыйрә турында без ниләр беләбез икән?

(*Презентация буенча шагыйрә турында кыскача белешмә бирелә.*)

**Укучы**. Клара Гариф кызы Булатова 1936 елның 18 мартында Сарман районы Татар Карамалысы авылында укытучы гаиләсендә туган. Клара апага бала чактан ук әти-әниләре белән бергә бер төбәктән бер төбәккә йөрергә,төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. Урта белемне 1954 елда Сарман урта мәктәбендә алып чыга. Мәктәпне тәмамлау белән Түбән Ләшәү авылында башлангыч сыйныфларда балалар укыта, аннан төзелештә эшли. Аннан тагы укытучы һөнәрен дәвам итә. «Беренче китабым «Язлар алда» дип атала, 1967 елда чыкты», – ди ул. Әсәрләре бик күп газета-журналларда басылып чыга. Казан дәүләт университетын тәмамлый. «Без бит укучылар өчен «Апа» идек. Авыл мәктәпләрендә укыган кызлар-егетләр Әлмәтне, Түбән Каманы, Лениногорскины үстерделәр.

«Мин укучыларыма дәреслекне өйдә укырсыз, дәрестә мине тыңлагыз, мин сезгә китапта булмаганны сөйлим, дип әйтә идем. 72 яшькә кадәр укыттым», – дип сөйли үзе турында Клара апа.

*Римма Сәгъдиева көенә «Беренчеләр» җыры яңгырый*.

**Марс**. Балалар, ә минем турыда ниләр беләсез?
**Алып баручы**.Ягез әле, дусларым, Марска сөйләп бирик әле үзе турында.

*«Курка димәгез әле» шигыре яңгырый.*

**Марс.** Әйе шул, кешеләрне хөрмәтлә! – дип,
Әни һаман өйрәтә...
Үземнең бер яхшы ягымны сезгә сөйләп күрсәтим әле, дусларым.

*«Әләкләргә ярамый» шигырен Марс үзе сөйли.*

**Алып баручы**. Балалар, Клара апа Булатова табигатьне бик ярата. Аның күренешләрен кызык итеп сезгә җиткерүче бик оста шагыйрә ул. Әйдәгез тынлап карыйк әле.
**Марс**. Әйе, дуслар, үземә
Сөңге башлы боз тиде.
Мин бит бозның су икәнен
Авыргач кына белдем.

*«Сәбәпләрен белмиләр» шигыре укыла.*

**Марс**. Буран ул нинди була?
Тышта буран котырса,
Урамда торып кара!

*«Әти белми» шигыре укыла.*

**Алып баручы.** Балалар, Клара апа Булатованың шигырьләрен укуы шундый рәхәт! Шулай бит?!
**Кыз**. Клара апа безгә әле кызыклы әкиятләр дә яза. Шуларның берсе – «Пицунда әкияте». Әйдәгез аны Марска күрсәтеп алабыз.
**Алып баручы**. Әйе, Марс, бу әкиятне балалар күләгә театры ярдәмендә сина күрсәтеп китәрләр.

*«Пицунда әкияте» күләгә театры күрсәтелә.*

**Ашыгып Әни кеше керә.**

**Әни кеше**. Шушында гына уйнап
Карале калган иде.
Юкка чыкты кай ара?!
Болай да арган идем.
**Алып баручы**. Сез кемне эзлисез икән?
**Әни кеше**. Күренмәдеме Марс атлы бер шук малай?
**Марс**. Мин монда,әни. Балалар белән бик кызыклы очрашу булды безнең. Алар мине таныдылар, чөнки Клара апа Булатованың иҗатын бик яраталар икән.
**Әни кеше**. Рәхмәт, балалар. Әйе, Клара Булатованың иҗат җимеше ул – Марс. Аның турындагы шигырьләр «Курка димәгез әле» дип аталган китабында язылган. Менә ул китап. *(Китапны балаларга курсәтә*)

**Алып баручы**. Кадерле балалар, безнең сәяхәтебез ахырына якынлашты. Клара Гариф кызы Булатованың иҗатын өйрәнүне без дәвам итәрбез. Клара апаны юбилее белән котлыйбыз. Аңа сәламәтлек, иҗатында зур уңышлар телибез. Хәзер сәяхәтебез ахырында Рәис Нәгыймов көенә «Шушы яктан, шушы туфрактан без» җырын тыңларбыз, үзебез дә кушылып җырларбыз. Ә Марска без рәхмәтләребезне җиткерәбез.

**Хезмәтем – мәңге картаймас шатлыгым чыганагы**
(яраткан шагыйрәбез Клара Булатованың иҗатына багышлана)

Шакирова Дилбәр Сәгыйть кызы, Тау Иле мәктәбе,
Мамадыш районы

Кичә буласы зал бәйрәмчә бизәлгән.
Җиһазлар: шагыйрә К.Булатованың портреты, китаплары, мультимедия технологиясе, плакат.

**1 нче алып баручы**: Шагыйрә Клара Гариф кызы Булатова тумышы белән Татарстанның Сарман районы Татар Карамалысы авылыннан булса да, бөтен тормыш юлын, иҗатын Әлмәт төбәге белән бәйли. Гомеренең кырык елдан артыгын ул балалар укытуга багышлый. Тәҗрибәле укытучы буларак, аңа РСФСР Мәгариф министрлыгының «Укытучы-методист» (1978) һәм «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» (1986) дигән мактаулы исемнәр бирелә, 1996 елда Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Шагыйрәнең әти-әнисе дә үз гомерләрен балалар укытуга багышлыйлар. Шунлыктан Клара Булатова иҗатында укытучы образына зур урын бирелгән.
**2 нче алып баручы**: Бөтен гомерен балалар тәрбияләүгә һәм иҗат эшенә багышлаган укытучы-шагыйрә Клара Булатова укучыларга «Язлар алда», «Җәйләр җитсә», «Гел кояшка карап», «Шушы яктан, шушы туфрактан без» һ.б. китаплары белән таныш.
**1 нче алып баручы**: Клара Булатова үзенең «Әнием» шигырендә әнисенә үзенең беренче укытучысы – хәреф танырга, язарга өйрәтүче буларак мөрәҗәгать итә. Укытучы-әни образына югары бәя бирә.
**Укучы:** Син башлап хәреф өйрәттең,
Әлифен, яңалифен.
Тукайлы, җырлы, шигырьле
Дөньяга әйдәп керттең.
**2 нче алып баручы**: Менә шушы шигыре белән шагыйрә үзенең тормыш юлында әнисе өйрәткән әсәрләр аша туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләвен, әнисе-остаз үрнәгендә үзе дә татар теле һәм әдәбияты укытучысы һөнәрен сайлавын ассызыклый.
**Укучы:**
Тукайлы, җырлы дәрескә
Кергәндә иртән килеп,
Һәрвакыт әни-остазым
Ияреп керә кебек.
**1 нче алып баручы:** «Беренче укытучыма» дигән шигырендә дә Клара Гариф кызы Укытучы образын, аның мактаулы һәм авыр хезмәтен сурәтли.
**Укучы:**
Беренче укытучым
Минем исемдә:
Җитәкләшеп бергә килдек
Белем көнендә.
Мин сезнең бер укучыгыз,
Тәүге сыйныфта.
Сез – беренче укытучым,
Минем тормышта.

2 нче алып баручы: «Остаз дияр идем мин...» шигырендә дә укытучыларның һәм остазларның гүзәл образы яктыртыла. Клара Булатова балаларга белем бирүче, ягъни мәгърифәтле итүчеләрне кояш белән тиңли. Кояш бар дөньяны яктыртып, җылытып, кешелеккә тормыш бирсә, укытучы кояштай балаларның күңелен җылытып, аң-белем биреп яктырта, ди. Андый кешеләргә минем хөрмәтем бик зур, җанымны да фида итәргә әзер, дип Укытучы образын югары күтәрә.
**Укучы:**
Остаз дияр идем мин,
Юлдаш дияр идем
Мәгърифәтле кешеләрне
Кояш дияр идем мин.
Күзләреннән нур сирпелә,
Телләреннән гөл тама.
Кеше җанын якты ут
Алардан тыш кем таба?
1 нче алып баручы: Клара Булатованың «Гел кояшка карап» дигән китабында «Укытучы көндәлеге» дип аталган аерым бүлек бар. Бу бүлеккә кергән шигырьләр авторның үз хезмәт тәҗрибәсеннән чыгып язылган. «Тагын башлана уку еллары», «Беренче сентябрь», «Төшләреңдә күреп», «Котлау сүзе», «Алтынчы класстагылар» һ.б. шундый шигырьләре укытучы һәм укучы мөнәсәбәтләренә, укытучының уй-хисләренә, үз хезмәтләрен чын күңелдән сөюләренә багышланган.
**Укучы:** Бу сүзләр күптән әйтелде,
Кимендә ун ел элек.
Колакка яңгырый үзе
Бүген ишеткән кебек.
**2 нче алып баручы:** «Котлау сүзе», «Төшләреңдә күреп...» шигырьләрендә дә әлеге фикер дәвам ителә. Шагыйрә, укытучылар өчен укучыларның ихтирамы, хөрмәте, хәтта бер ягымлы сүзе дә җитә, ди. Әнә шул бер генә сүз, Укытучыларны гомер буе сихерләп, үз эшләрен яратып башкарырга, укучы балаларның барын да бердәй тигез күреп, яратып, мәгърифәт юлында хезмәт итәргә этәрүенә басым ясый. Клара Булатова, укытучыга иң кадерле, иң зур бәя – ул укучысы бәясе – аның яшәү кыйбласы икәнен әйтеп бирә:
Балалар бәясеннән дә
Олырак хак бармы тагы?!
Хезмәтем – мәңге картаймас
Шатлыгым чыганагы.
**1 нче алып баручы:** Клара Булатова шигырьләре хис-кичерешләргә бик бай, алардан моң агыла. Шуның өчен дә шагыйрә матур-матур җырлар авторы буларак та танылды. Җырларында туган як, мәхәббәт темасы үзәк урынны алып тора.
**2 нче алып баручы:** Яраткан шагыйрәбез Клара апа Булатова – нәниләр өчен чын күңелен биреп иҗат итүчеләрнең берсе. Аның поэзиясе үзенең тема төрлелеге, үзенчәлекле стиле, оригиналь юмор хисе белән аерылып тора. Бәләкәчләр өчен яза алу сәләте дә бик сирәкләр өлешенә төшкән бәхет. Сабыйның теле ачылганда ук синең сүзләреңне тәтелди, балалар бакчасында, мәктәптә синең сүзләреңне сөйли икән – шуннан да зуррак куаныч бармыни? Алар үзләре белән сине дә киләчәккә алып барачак, ләбаса! Гадилектә – бөеклек, диләр.
**Укучы:** «Мин зур үскәч...», – дибез бала чакта
Үзе генә шушы сүз безгә.
Әллә ниләр инде вәгъдә итә,
Әллә ниләр килер көнебездә.
**Укучы:**
«Мин зур үскәч», – дибез, шушы сүзгә
Хыялларны теркәп сөйлибез.
Сәгать, көнне, айны, елны куып,
Зур үсүне көтеп йөрибез.
**Укучы:**

Ә зур үскәч, тик бер кайтыр өчен
Гамьсез үткән якты көннәргә,
Бу зурлыкның барын бирер идек,
Бирер идек әллә ниләр дә.

**1 нче алып баручы**: Балалар өчен язылган әсәрләрендә Клара апаның осталыгы, таланты аеруча ярылып ята. Яраткан шагыйрәбезнең күп кенә шигырьләре тәрбияви әһәмияткә ия булуы да безнең өчен бик мөһим. Шагыйрә балаларны акыллы, тәртипле, шәфкатьле, миһербанлы, инсафлы булып үсәргә өнди. Туган җирне яратырга чакыра. Әти-әниләрне олылауны, хөрмәт итүне таләп итә.

**2 нче алып баручы**: Шушының белән Клара Булатова иҗатына багышланган кичәбез тәмам. Кичәдә катнашкан барлык укучыларга да рәхмәт.

## Яңа китап – яңа дус

(Әзһәр Габидинең «Күлдәвектә кояш көлә» китабын тәкъдир итү)

Адлер Эльвира Демьян кызы, Заһитова Ләйлә Әзһәр кызы, «Мәлбагыш урта гомуми белем бирү мәктәбе» филиалы «Әлкәй төп белем бирү мәктәбе», Азнакай районы

Максат. ТАССРның атказанган мәдәният эшлеклесе, Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия иясе, Халык мәгариф отличнигы Әзһәр Габидинең «Күлдәвектә кояш көлә» китабы белән укучыларны таныштыру, укучыларда Әзһәр Габиди иҗаты аша шигырьләренә һәм китапларына мәхәббәт тәрбияләү.
Материал. Әзһәр Габиди портреты, Әзһәр Габиди китапларыннан күргәзмә

Сарман ягы талантларга бай. Бүгенге көндә Сарман якларыннан 25ләп шагыйрь һәм прозаик үсеп чыкты. Бу кадәр язучыны әлегә Арчадан кала республикабызның бер генә төбәге дә бирә алганы юк. Шулар арасыннан балалар һәм зурлар өчен дә матур-матур шигырьләр иҗат иткән язучыбыз Әзһәр абый Габидине атарга була. Бүгенге дәресне Әзһәр абый Габиди иҗатына багышлыйбыз

Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин 1926 елның 25 сентябрендә Сарман районының Чукмарлы авылында туа. Гаиләдә өченче бала булганга күрә, ул авыл тормышының бөтен авырлыкларын үз җилкәсендә татый. Әзһәр Габиди Бөек Ватан сугышында катнаша, 17 яшьтә ул армия сафларына алына. 1945 елда Япон сугышында бик каты яралана, бер ел дәвамында госпитальдә дәвалана. 1946 елда үз туган авылына кайта. 1950 елда Минзәлә педагогика көллиятендә белем ала, соңыннан Сарман район мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Шул вакытта аның «Без – яз дуслары» исемле беренче шигырь җыентыгы дөнья күрә һәм аны алга таба иҗат эше белән шөгыльләнергә илһамландыра.

Әзһәр Габиди – балалар әдәбиятының танылган шагыйре. Ул инде кечкенә дусларыбыз өчен берничә меңләгән әсәрләр иҗат иткән, аларны уннарча китапларга туплап бастырып чыгарган һәм укучыларыбыз кулына ирештергән. Шунысы куанычлы, аның китаплары кибет шүрлекләрендә тузан җыеп ятмыйча, барысы да берничә ай эчендә сатылып беткән.

Әзһәр Габидинең «Күлдәвектә кояш көлә» китабы 2020 елда Казан «Рухият» нәшриятында басылып чыга. Булат Гыйльфанов ясаган кызыклы рәсемнәр китапны тулыландырып торалар. Китап 8 бүлектән тора. «Яз шатлыгы» бүлегендә шау-шулы яз тамашаларын күз алдыннан үткәрәбез. Яз килүнең беренче билгесе – ләйсән яңгыр. Шагыйрьнең ләйсән яңгыры энҗеләр сибелгән сыман, тамчылары да: «Сине сагындык!» дигән кебек җирне үбәләр.

Никадәр матур чагыштырулар, гүзәл сынландырулар! Мондый якны яратмаган җирдән яратырсың, мондый җирләрне сөймәс җиреңнән сөярсең. Авыл баласы кечкенәдән үк җиргә гашыйк, җирне сөя, аның хикмәтләрен белә.

«Җәй көннәре күңелле» бүлегенә кергән «Тәүлекбикә гүзәлләре» дә табигатьнең матурлыгын чагылдыручы үзенчәлекле шигырь. Биредә автор шигырьне чын әсәр итүче матур бизәкләр табып эш иткән.

Таңсылу кияр ал күлмәк,
Ал шәлен иңгә ябар,
Киемнәренә пар итеп
Битенә иннек ягар.
Көнсылу да һич калышмас
Апасы Таңсылудан,
Күлмәк, яулыгын тегәр ул.
Зәңгәр атлас ситсадан.

Бу шагыйрьнең үзенчә генә күзәтүләрен, уйлануларын чагылдыра торган строфалар. Тәүлекнең уртанчысы Кичсылу да, Төнсылуның да шигъри детальләре әнә шулар кебек матур итеп язылганнар. Шуңа күрә әлеге әсәр бер укуда ук истә кала, укучылар күңелендә соклану тудыра.

Әзһәр абый туган ягыннан бер көн генә аерылып тормаган. Ул чишмәләрнең тәмен, ахат төсле офыкларын, эт өрүен, әтәч кычкырганын сагынган. Әзһәр ага Габиди шигырьләрендә башкаларны да үз артыннан ияртергә омтылып иҗат иткән. Әнә шуңа күрә дә Әзһәр абый Габиди шигырьләре үзләренең гадилеге, эчкерсезлеге белән күңелне җәлеп иткән. «Күзләр аша кышка таба» бүлегенә кергән «Кар бабайга ни булган?» шигырен тыңлап үтик әле.

Әзһәр Габиди әсәрләре тормышчан булулары белән күңелне җәлеп итәләр. Ул кырык еллар чамасы гомерен балалар укытуга багышлаган, яшь буынга белем биргән, аларда халкыбызга, туган җиребезгә, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләгән. Бу аның өчен дә, безнең өчен дә зур сөенеч, әлбәттә. Шунысын да әйтергә кирәк, шагыйрь әнә шуңа күрә дә балалар табигатен, аларның уй-фикерләрен аңлап иҗат иткән, аларча уйлый да, фикерли дә белгән. Моны ачыклау өчен аның «Укыйбыз, белем алабыз» бүлегендәге шигырьләренә генә игътибар итик. «Афәрин, Илдус!», «Космонавт булырмын» шигырьләрен укыганда без аның Әзһәр абый язганлыгын онытып та җибәрәбез, үзебез дә балаларча хискә бирeләбез.

«Чәчәкләрдә кунакта» дигән җыелмасындагы шигырьләр табигатьнең гүзәл күренешләрен – чәчәкләрне аңлау дәрәҗәсен арттыра, фикерләү, сиземләү сәләтен үстерүгә йогынты ясый. Кече яшьтәге дусларыбыз өчен бу бик кирәкле нәрсә. Тузганак, ландыш, төнбоек, канәфер, миләүшә, күкчәчәк тукранбаш чәчәкләре турында укыйсы килеп кенә тора. Чәчәк исемнәреннән класс белән бергәләп кроссворд төзербез.

«Әкиятләр сөйләп алыйк» бүлегенә «Калган эшкә кар ява», «Зәңгәр офык» ике шигъри әкият кергән. Аларда да укучылар күңелен җәлеп итәрлек үткен фикерләр, яхшылыкны олылау хисләре нигез итеп салынган. Шуңа күрә дә ул әсәрләр яратып укылалар һәм күңелгә сеңеп калалар. Мин әкиятне укый башлыйм. Әкиятне укып бетергәч, ни өчен «Калган эшкә кар ява» дип аталганын белерсез.

Балаларның зиһенен баетуда, уйлау-фикерләү сәләтен үстерүдә дә Әзһәр аганың күп кенә табышмаклары игътибарга лаек. Әйдәгез әле, без дә зиһеннәребезне тикшереп, «Булсаң зирәк – әйт тизрәк!» дип аталган табышмак әйтү уенын уйнап карыйк.

Күлмәк, балык, сыерчык, алабуга, парта сүзләренә ясаган шарадаларын чишеп алабыз.

Әзһәр Габиди – бәхетле шагыйрь. Ул безгә дистәдән артык китап калдырып китте. Кызганычка каршы, Әзһәр Габиди безнең арада хәзер юк инде. Ул барлык шигырьләрен, күңел җылысын безгә калдырып, бакый дөньяга китеп барган.

ТАССРның атказанган мәдәният эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия иясе, Халык мәгариф отличнигы Әзһәр абый Габидинең тууына 95 ел тулуга багышланган балалар иртәсендә без «Күлдәвектә кояш көлә» китабын тәкъдир иттек.

## Мәктәпкә әзерлек төркемендә балаларны Хәниф Хәйруллин иҗаты белән таныштыру

Ә. Ә. Харисова, «Кояшкай» №1 балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

Бурычлар: Балаларны Хәниф Хәйруллин иҗаты белән таныштыру, балаларның фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен, сүзлек запасын үстерү; Хәниф Хәйруллин әсәрләренә

кызыксыну уяту; балаларда патриотизм хисе, туган авыл һәм аның геройлары белән горурлану, мәхәббәт хисләре тәрбияләү.

Сүзлек: музей, Бакыр базы.

Җиһазлау: Хәниф Хәйруллин портреты, язучының китаплары, Хәниф Хәйруллинның кыскача тормыш юлы һәм аның иҗаты буенча эшләнгән презентация.

**Эшчәнлек барышы:**

Балалар, без бүген сезнең белән язучы, журналист Хәниф Хәйруллин иҗаты турында сөйләшербез. Кем соң ул?(Портреты куела).

Хәниф Гыйздулла улы Хәйруллин 1931 елның 12 сентябрендә безнең Сарман авылында туган. Әгәр дә исән булса, аңа 90 яшь тулган булыр иде. Хәниф Хәйруллин – КПСС әгъзасы, Журналистлар, язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан АССРның атказанган мәдәният хезмәткәре булган. Мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Бик күп җаваплы урыннарда хезмәт куя. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Сарманда яши һәм иҗат итә. Аның әсәрләре авыл тормышы, авыл кешеләре турында. «Канатлар талмасын», «Картлык – кемгә шатлык», «Кайда сез, улларым?» исемле повестьлары белән киң танылa. Унлап китабы басылып чыккан. Балалар өчен ул «Тылсымлы таяк табышы», «Бакыр базының серләре» исемле әсәр яза. Ул әсәр «Ялкын» журналында басылып чыга.

Балалар, кемнәр Бакыр базы турында белә? Ул кайда урнашкан? Ни өчен Бакыр базы дип аталган? Текәй тавы кайда? Кемнәрнең барганы бар? (Фикер алышулар).

Ә хәзер ял итеп алыйк.

**Физминутка.**

Матур сүзләр уйладык
Ял итәргә туктадык.
Җилкәләрне турайттык,
Тирән итеп суладык,
Башны як-якка бордык,
Чүгәләдек һәм тордык,
Бер урында йөгердек,
Аннары соң сикердек.
Сузылдык-киерелдек.
Югарыга үрелдек.
Соңыннан тынычланып
Шөгыльне дәвам итик.

Хәзер без Хәниф Хәйруллинның иҗаты турында презентация карап китик.(Презентация).

Балалар, безнең Сарман гимназиясендә Хәниф Хәйруллин иҗатына багышланган музей эшли. Без дә сезнең белән анда барырбыз әле. Шулай ук Хәниф Хәйруллин исемендәге премия булдырылган. Аның иганәчесе – улы Ленар Хәйруллин. Премияне Сарман гәҗите битләрендә даими бастырылып килә торган һәм иң кызыклы дип табылган язмалар авторларына тапшыралар.

Балалар, туган ил, туган җир дип нинди җирне атыйлар? (Балалар җаваплары). Без сезнең белән хәзер туган ил турында мәкальләр әйтеп китәрбез.

1.Туган ил ул була бер генә,
Туган илнең кадерен бел генә.
2.Үз илем – үземә кадерле.
3.Туган илем – туган өем.
4.Туган-үскән җирдән дә матур җир булмас.
5.Туган җирдәй җир булмас,
Туган илдәй ил булмас.

Бик күп беләсез, балалар, афәрин! Без бүген эшчәнлек барышында Хәниф Хәйруллин иҗаты турында бик күп мәгълүмат белдек. Сезгә кызыклы булгандыр дип уйлыйм. Эшчәнлегебезнең азагында бер кызыклы уен уйнап алырбыз. (Сарманда урнашкан истәлекле урыннарның исемнәрен әйтеп, «Ике урамлы» уйнау.

Агыйделнең суларында
Ак чиләгем күмелде.
Әйдә, дустым, безнең якка,
Безнең яклар күңелле.
Зәңгәр чәчәк җыя җыя,
Зәңгәрләттем кулымны.
Бергә-бергә уйныйк әле,
Бир, дускаем, кулыңны.

### «Ак каен» исемендәге җәйге ял аланында әдәби уку көне
### «Шушы яктан, шушы туфрактан»
### (Сарман язучыларына багышланган телдән журнал)

Абдуллина Флюра Мөхәмәтханиф кызы,
Мусабай-Завод гомуми белем урта мәктәбе китапханәчесе, Тукай районы

**Максат**: балаларда татар теленә – ана теленә мәхәббәт тәрбияләү һәм сүзнең, татар сүзенең, егәрен арттыру өстендә системалы эшчәнлекне дәвам итү; Сарман якларында туып үскән язучыларыбыз: Клара Булатова, Әзһәр Габиди, Хәниф Хәйруллин, Фәрит Яхинның тормышы һәм иҗат эшчәнлеге белән таныштыру; туган якка, туып-үскән авылыңа мәхәббәт тәрбияләү һәм горурлану хисен үстерү; әйләнә-тирә табигать белән кызыксыну һәм аны саклау мәсьәләләренә игътибарны юнәлтү; экологик культура формалаштыру; ватанпарвәрлек, үз халкыңның тарихы белән кызыксыну һәм горурлану хисләре тәрбияләүнең яңа, кызыклы алымнарын эзләү; коллективта үзара аралашу әдәбе, бер-береңә ярдәмләшү, дуслык һәм туганлык хисләре формалаштыруны дәвам итү; шигырь сөйләү осталыгын камилләштерү, иҗади сәләтләрен үстерү.

**Чараны** «Ак каен» исемендәге җәйге ял аланына йөрүче 1-8 нче сыйныф укучылары белән үткәрергә мөмкин.

**Чарага әзерлек эшләре**

1. Чараны үткәрү өчен уңайлы алан һәм кабинет сайлап алу;
2. Клара Булатова, Әзһәр Габиди, Хәниф Хәйруллин, Фәрит Яхин әсәрләре басылып чыккан китаплар; алар иҗатына багышланган массакүләм матбугат чараларында басылып чыккан газета һәм журнал материалларыннан күргәзмәсе оештыру; язучыларның портретлары, мультимедияле проектор, ноотбук, презентация.
3. Ике отрядны бәйрәмгә әзерләү, звеноларга бүлү: исем сайлау, әйдәман билгеләү, төркемнәрнең девизларын сайлау (Имәннәр һәм Умырзая төркемнәре яки башка исемнәр).
4. Хөкемдарлар (жюри) составын билгеләү.
5. Чара көн буе үткәрелә, шуңа күрә төшке аш һәм төштән соңгы аш өчен махсус вакыт бүлеп бирелә.

**План**

I. Кар астында умырзая (Клара Булатова)
II.Урман кырындаге имәннәр без...(Әзһәр Габиди)
III. Яран гөл (Хәниф Хәйруллин)
IV. Куш каен аланы (Фәрит Яхин)
V.Күргәзмә – башваткыч «Сандугачлы Сарман ягын беләсезме?»
VI. «Акбурлы ботаника»
VII. Йомгаклау

**Чараның барышы**

Без ул кадәр олы шәхес түгел,
Тукайныкы кадәр эз калмас;
Ләкин Сарман үзен җырга салган
Ихлас җанлы улын онытмас...
(Әзһәр Габиди)

**Кереш өлеше**

**Бүген бездә кунак бар...**

**Алып баручы**: Балалар, бүген җәйге ял аланына кунак итеп укытучыларны да чакырдык. Аларны кайберләре, билгеле, сезнең тәрбиячеләр дә әле. Шулай да бүген алар – кунак та булып торалар. Ни өчен дисезме?! (Проблемалы сорау куела). Менә алар: Лилия Равил кызы, Флюра Хәниф кызы, Марина Назыйф кызы (Чәчкә апагыз), Нурсинә Җәмил кызы һәм Фәргать Фалих улы. Бу укытучыларны нәрсә берләштерә? Ни өчен мин менә шуларны чакырдым? (Укучыларның җаваплары тыңлана, гомуми нәтиҗәгә киләләр).

Флюра апагыз үзенең Сарман районыннан икәнен гел искәртеп тора, Ул – Юлтимер кызы. Ләкин 40 елга якын гомерен Мусабай-Заводта үткәргән. Аны биология һәм химия укытучысы итеп җибәргән Казан, менә шуннан биредә калган. Әле җитмәсә, хәзер китапханәче дә булып эшли. Чәчкә апагыз – Зур Нөркәй авылы кызы, Мусабай килене. Лилия апагыз – мәктәбебезнең директоры, Кәүҗияк авылы килене. Нурсинә апагыз –Чураш авылы килене һәм, ниһаять, Фәргать абыегыз – Кәүҗияк авылы егете. Үз бәхетен Мусабайда тапкан, бер дигән 3 кызы үсеп килә, Җәмиләнең әтисе дә. Алар үзләренең истәлекләре белән дә уртаклашырлар әле, бәлки?! Димәк, бүген көне буе сүз Сарман районы һәм аның билгеле шәхесләренә – язучыларына багышлана. Әйдәгез, бер видеоклип карап китик.

(Экранда Алинә Кәримова катнашында видеоклип күрсәтелә, Миргасыйм Гаскәров сүзләре, Рафис Уразаев көе «Сарманым» җыры башкарыла.)

**Флюра Хәниф кызы**: Мин Азалак урта мәктәбендә урта белем алдым. Миргасыйм абый безнең мәктәптә тарих һәм җәмгыять белеме укытты, Юлтимернеке. Ул Мусабай мәктәбендә озак еллар директор булып эшләгән Аринат Гариф улы Илматовның курсташы да әле. Хәзерге көндә Сарманда яши, 81яшьтә. Ә Рафис абый – музыка мәктәбе директоры булып эшләгән иде, 1947нче елгы. Сарманда яши.

**Алып баручы**: «Кем дә һәр адымы саен эз калдырып бара. Әмма яуган яңгырлар, искән җилләр белән бергә еллар агышы аларны юдыралар, җуйдыралар һәм бетерәләр кебек. Ә кеше күңелендә калган эзең һаман да хатирәләрендә саклана, хәтта төнге йокыларында сыкрата торганнары да бар. Адәм баласының табигате шундый инде, нишләтәсең...» – дип язган Фәрит Яхин «Күңел чиге» дигән хикәясендә. Без дә сезнең белән бүген күңел чикләребезне киңәйтеп, укытучылар, бигрәк тә Сарман районы белән бәйле булганнары, хатирәләрен яңартып, белемнәребезне арттыра алсак максатыбызга ирештек, дип санарбыз, минемчә.

**Беренче бит. Кар астында умырзая**

**Беренче укучы:** Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Китә калсак үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр елап озатыр.
Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Читтә йөрсәк, шуңа күрәдер,
Чишмә чыңлап, өянкеләр елап,
Таллар җырлап төшкә керәдер.
Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Шушы җиргә дәшеп кайтырга,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр зурлап чакыра.
Шушы якта безнең хезмәт калсын,
Мирас булып килер яшьләргә.
Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Шушы туфракта язсын яшәргә!

Алып баручы: «Шушы яктан, шушы туфрактан без», – дип язган Клара Булатова «Шушы яктан, шушы туфрактан без» дигән шигырендә. Рәис Нәгыймов бу шигырьне көйгә салган.

**Икенче укучы:** Клара Булатова 1936 елның 18 мартында Татарстан АССРның Сарман районы Татар Карамалысы авылында укытучылар гаиләсендә туган. Әтисе – математик (һәм мәктәп директоры), әнисе тел-әдәбият укытучысы булган. Укырга 1944 елда Сарман районы Югары Чыршылы җидееллык мәктәбенә керә. 1951 елда, әтисен Ләке мәктәбенә күчерү

нәтиҗәсендә, укуын Ләке мәктәбендә дәвам итә. Урта белемне Сарман мәктәбендә ала. Шул вакытта инде аның шигырьләре район газетасында гына басылып калмыйча, «Чаян» журналында да дөнья күрә. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Әлмәт шәһәренә китә. Шагыйрәнең үз сүзләре белән әйтсәк: «...1965 – 1969 елларда Казанда университетта укыган вакытны искә алмаганда, минем бөтен гомерем Әлмәттә үтте... Тагын шул: мин ярты гасыр буе Әлмәттә яшәгән гомеремнең кыл яртысын, ягъни 25 елын була инде, шәһәрдән авылга йөреп укытып үткәрдем. Колшәрип, Яңа Кәшер, Түбән Мактама мәктәпләре. Аннан соң инде гасырдан гасырга күчү чорында үзгәрешләр вакытында, минем бәхеткә дияргә дә ярыйдыр, ниһаять, тарихта беренче тапкыр Әлмәттә, нәкъ менә шәкертләрем белән бергә тудырган «Гимназия җыры»нда яңгыраганча:

Тарихта беренче тапкыр
Әлмәт җирендә.
Гимназия эшләп килә
Татар телендә, – дип туган Әлмәт татар гимназиясендә ун еллап, 1991елда Әлмәттә барлыкка килгән «Луч» («Нур») телерадиокомпаниясендә шулай ук ун ел эшләгәннең өстенә инде сигегезенче ел Әлмәт муниципаль институтында әдәбият дәресләрен, киресендә үзем килен булып төшкән Нәдер авылыннан йөреп алып барам... Иҗаттагы уңышларым өчен миңа Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирделәр. Мин шулай ук Рафаил Төхфәтуллин исемендәге әдәби бүләк иясе дә». 2016 елны Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Клара Булатова – 1970 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

**Алып баручы**. Без 2020 елны Бөек Җиңүнең 75 еллыгын билгеләп үттек. Клара Булатовага сугыш башлаганда 5 кенә яшь булса да, ул шул чорларны искә алып болай диеп язган: «1943 елның ачлыктан шешенеп-интегеп утырган кышында инде хәреф танысам да, кулыма каләм алып язмый идем әле, әмма әллә күпме такмак туглаган телем инде «чын шигырь» диярлек:

Мәрхәбәне урыныннан
Алып кына ташласы:
Паек та кайтмый, ичмасам –
Кич әллә нәрсә ашасы?! – дигән сугыш чоры балалары өчен бик тә актуаль теманы күтәргән әйберне чыгаруга, әни мәрхүмә миңа шагыйрьлек язмышын юрап куйды...»

**Өченче укучы**:

Каеннар яшь иде, алар да яшь иде.
Авылдан хушлашып киткәндә.
Кайтмаслар икәнне белделәр микәнни?
Каеннар сыкранды үткәндә...
Озата бардылар, кул болгап калдылар:
“Онытма!” “Исән кайт!” “Җиңеп кайт!”
Җилләрдә җилфердәп тибрәнде каеннар.
Кызларның теләген кабатлап.
Каеннар яшь иде, алар да яшь иде...
Каеннар картайган, саргайган...
Ап-ак бәс түгел лә, сыкылар күренә,
Чигәләр изелеп агарган.
Яз арты яз үтә,
Яз арты яз үтә.
Җәй җитә, җәй җитә аннары...
Бу күңел ни көтә?
Бу күңел ни көтә?!
Кайтмаска киткән бит ярлары.
Каеннар саргайган, чигәләр агарган.
Күңелләр, әйтерсең, япь-яшьләр.
Һаман да сөяләр, һаман да көтәләр
Ярлары кайтмаган кәләшләр. (Каеннар яшь иде)

**Тарих укытучысыннан белешмә**: Бөек Ватан сугышына безнең җирлектән 335 асыл ир- ат

чыгып киткән. Шуларның 175 кешесе – Мусабай авылыннан. Сугыш кырларында 120се ятып калган.
**Алып баручы**: Клара Булатова бөтен гомерен туган ягында, туган Татарстанында үткәрә. Читкә киткәннәргә, авылын сагынып кайтырга вакыт таба алмаганнарга, шәһәрдә ятып авыл турында шигырь язып ятучыларга да әйтер сүзе бар шагыйрәнең. Үзенең шигырьләрендә һәрвакыт кендек каны тамган, балачак һәм яшьлек еллары үткән авылларны онытмый. Әсәрләрендә яңгырата.
**Марина Назыйф кызы**: Минем Зур Нөркәй авылы кызы икәнлегемне әйтеп уздылар инде, мин дә бер шигырь укып китәм әле, рөхсәт итсәгез.

Туган якка кайтып чыккан саен,
Бер нечкәреп ала күңелкәй.
Туган авылым түгел, әмма башлап
Тәпи баскан җирем бу – Нөркәй.
Әти мәрхүм, монда дәрес биргән,
Әнием дә шунда укыткан.
Дөрес, аңа байтак еллар үткән,
Кем хәтерли, кемдер оныткан.
Ә мин менә Зариф бабайларның
Ике катлы өен һаман да
Истә тотам, тәүге такмагымны
Иҗат иткән идем мин анда.
Дүрт яшь иде миңа. Шигыремнең
Хәтерләмим инде азагын,
«Әхмәтзыя, Әхмәтзыя,
Йөгерә-йөгерә ни җыя?» – дип
Үрти идем күрше малаен.
Аннан соң без Чыршылыга күчтек.
Ә шулай да әле күп бәйдә
Килеп йөри идек кунак булып
Фатыйма апаларга – Нөркәйгә.
Фатыйма апа – Елена Кухарук
Гомер итте шушы авылда.
Нөркәйлеләр арасында, бәлки,
Якыннары бардыр аның да.
Үзе инде вафат булган икән,
Чирек гасыр элек Нөркәйгә
Мин килгәндә, әле исән иде,
Без күрешкән идек ул җәйдә.
Кемдер китә җирдән, кемдер үсә,
Шулай үтә икән гомеркәй.
Туган авылым түгел түгелен дә,
Телем ачкан җирем бу – Нөркәй.
Кайтам дигән теләк-омтылышлар
Гел үтәлми калып ятмастыр.
Өлкән агам итеп атап кайтсам,
Хәмәт абый кире какмастыр.
Бер күрешү – үзе бер гомер шул,
Нөркәйләр бит миңа ят түгел,
Туган якларыңда күрешүдән
Яңа җырлар алып кайт, күңел!       (Туган якка кайткан саен)

Элек укытучыларны бик еш авылдан-авылларга күчерә торган булганнар. Шагыйрәнең ата-анасы да Сарман районының берничә авылында яшәп, шунда укытканнар.
**Алып баручы**: Гомере буе балаларга ана телен укыткан шагыйрәнең, билгеле, мәктәпкә, укытучыларга багышланган шигырьләре күп. Шуларның берсен безнең мәктәпнең татар теле

укытучысы Лилия Равил кызы укып китәр, рәхим итегез.
**Ана теле укытучысы**:
Миңа сорау бирсәләр:
– Сөенечең ни? – дисәләр,
Сөенечем – таңнан торып,
Эшкә килгән иртәләр.
Миңа сорау бирсәләр:
– Шатлыгың ни? – дисәләр,
Шушы мәктәп сукмаклары
Шатлыгыма илтәләр.
Миңа сорау бирсәләр:
– Бәхет ни ул? – дисәләр,
Бәхет – шушы укучылар
Кеше булып үссәләр. (Укытучы бәхете)
**Алып баручы**: Икенче юбилярыбыз Әзһәр Габиди шулай ук бөтен гомерен балаларга ана теленнән белем бирүгә багышлаган. Әйдәгез, журналыбызның икенче битен ачыйк.
**Икенче бит. Урман кырындагы имәннәр без...**
**Дүртенче укучы**: Әзһәр Габиди (Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин) 1926 елның 26 сентябрендә Сарман районының Чукмарлы авылында Сәмигулла абый белән Гайнелҗиһан апаның өченче улы булып дөньяга килә, авыл тормышының барлык якларын күреп, татып үсә. Чабата үрә, печән чаба, атлар карый, урман кисә... Үсмер чагыннан ук милләтенең, Рәсәй дәүләте кысаларында үтә дә кыерсытылган ана теленең хокуксызлыгын, милли гадәт-йолаларыбызның санга сугылмавын күреп үсә. «Җиңелмәскә!» – дип төпле фикергә килә һәм шул кыйбласына тугры калып, укытучы- мөгаллим, ана теле укытучысы һөнәрен үз итә.

1943 елның ноябрь аенда 17 яше генә тулып киткән Әзһәрне хәрби хезмәткә алалар. Хәрби хезмәтенең икенче елында, 1945 елның көзендә японнарга каршы сугышта ул авыр яралана. Шуннан соң бер елга якын хәрби госпитальләрдә дәваланып, 1946 елда гына Чукмарлыга әйләнеп кайта.

Мортышбаш сигезьеллык мәктәбенә укытучы итеп эшкә алына. Шул елларда шигырь яза башлый. Балалар өчен «Без – яз дуслары» дигән беренче шигырьләр җыентыгын чыгара.
**Алып баручы**: Беренче китап аны яңа иҗат үрләренә дәртләндерә. Бүгенге көндә инде аның ике дистәләп китабы дөнья күргән. Табигый, аларның күпчелеге балаларга багышланган.

Өлкәннәрне уйландыра торганнары да бар. «Урман кырындагы имәннәр без» өч бүлектән торган шигырьләр җыентыгы, миңа калса, иң отышлысы.
**Бишенче укучы:**
Бик какшаган булып күренсәк тә,
Барны күтәргән без – чыдамнар.
Урман кырындагы имәннәр без,
Урман кырындагы чаганнар.
Безнең өскә күпме давыл килде
Һәм котырды күпме бураннар.
Күкрәк киереп каршы тормадыкмы,
Сау булсын дип, дуслар-туганнар.
Яныбызга баскач, яшь агачлар
Үсеп килә таза, нык булып.
Безнең белән бергә шаулый-шаулый
Киләчәккә бара томрылып.
Яшь агачлар җырын тыңлаганда
Чалынып китсә безнең чалымнар,
Урман кырындагы имәннәр без,
Урман кырындагы чаганнар. (Урман кырындагы имәннәр без)
**Алып баручы:** Әзһәр Габиди – төп хезмәте буенча укытучы-мөгаллим булса да, бер үк вакытта газета хәбәрчесе дә, тәнкыйтьче дә, шагыйрь дә. Әмма ул бу хезмәтләре белән беркайчан да масаймаган, барлык шөгыльләрен тигез күреп, үзенең иҗат кыйбласы иткән.

«Ул һичкайчан зур биеклекләргә омтылмады, әрсезлеген күрсәтмәде. Иҗат итте бары. Шигырьләр язды. Сабыйлар өчен язды. Туган ягы Сарман төбәгенең гүзәл табигатен, аның хезмәт сөйгән халкын олылады. Гашыйк булып язды. Сокланып язды. Сокландырырга тырышып, башкаларны артыннан ияртергә омтылып иҗат итте. Гомере буе авыл балаларына, башта Мортышбаш, аннан соң Ләке, Чукмарлы балаларына ана телебезнең гүзәллеген, серләрен өйрәтте», – дип язалар аның турында.

**Алтынчы укучы**

Алма ботагына кунып,
Сандугач җырлый,
Ә бакчада урындыкта
Гөлгенә җылый.
– Икеле алдым, дисеңме?
Сәбәбе нидән?
Әйтче, әйтче яшермичә,
Дустым – Гөлгенәм.
– Учымдагы язуларым
Беткән юылып,
Такта алдына чыккач та
Калдым хур булып.
Укытучымны алдавым
Эх, харап итте...
...Сандугач тыңлап тормады,
Очты да китте. (Сандугач белән Гөлгенә)

**Алып баручы**: Авыр хезмәт юлы һәм сугыш яраларыннан сәламәтлеге какшаган булса да, Әзһәр абый Габиди һаман эзләнде, язды, иҗат итте. Әзһәр Габиди – 1994 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Кызганычка каршы, үзенең 75 яшьлек юбилей көненә кадәр яши алмыйча, 2001 елда вафат булды. (26.09.1936 – 22.08.2001)

**Җиденче укучы**:

Без ул кадәр олы шәхес түгел,
Тукайныкы кадәр эз калмас.
Ләкин Сарман үзен җырга салган
Ихлас җанлы улын онытмас...
Зәңгәр тауның алсу чәчәкләрен
Таптатмаска яуда йөрдек без.
Корыч, тимерләрне эретердәй
Ут эченә анда кердек без...
...Үз кайгыбыз булса, сер бирмәдек,
Кеше кайгысына кердек без.
Аның өчен чын күңелдән янып,
Авырлыгын бергә бүлдек без.
Шатлык булса, аны уртак иттек,
Нур балкыттык, йөздә, юлларда.
Гел атлыктык алгы сызыкларга
Ямь өстәргә елдам елларга.
Җыр яраткан,
Батыр, хезмәт сөйгән,
Улын якын итәр Сарманым;
Ал-ялны беми,
Мәшәкатьләре белән
Янып үтте бик күп таңнарым.
Эш дигәндә – эшне эш иттек без,
Уен дисәк – көлдек, шаярдык;
Болай тыныч кына күренсәк тә,
Ун кешелек булды шаянлык.

Без ул кадәр олы шәхес түгел,
Тукайныкы кебек эз калмас;
Ләкин Сарман үзен җырга салган
Ихлас җанлы улын онытмас.
Алып баручы: Онытмый Сарман үз балаларын, искә алып тора.

**Өченче бит. Яран гөл**

**Алып баручы**: Журналыбызның өченче бите язучы Хәниф Хәйруллинга багышлана.

**Сигезенче укучы**: Хәниф Гыйздулла улы Хәйруллин 1931елның 12 сентябрендә җырларда җырланган җирдә – Сарманда туган. Шул авылда урта мәктәпне тәмамлаган. 1951-1956 елларда Казан дәүләт университетында укыган. Университеттан соң кире туган ягына әйләнеп кайткан һәм Сарманда чыгып килә торган район газетасы «Ленинчы» (хәзерге көндә район газетасы «Сарман» исеме астында чыга) редакциясендә эшли.

Әгәр каләмдәш замандашлары университетта укыганда ук иҗат эше белән шөгыльләнә башласалар, Хәнифтә язучы булу теләге шактый соң туа. Мөстәкыйль тормыш юлына басып, байтак вакытлар узгач, зур гына тормыш тәҗрибәсе туплагач һәм, аның үз сүзләре белән әйткәндә, “бүтән язмыйча түзә алмаганын аңлагач кына” каләмгә тотына. Баштарак үзен төрле жанрларда сынап карый. Очерклар да яза, балалар өчен «Тылсымлы таяк серләре» дигән мажаралы повесть та иҗат итә.

Хәниф Хәйруллинны язучы итеп таныткан әсәр – ул, әлбәттә, «Канатлар талмасын» повесте. Хәниф Хәйруллин – 1974 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

**Флюра Хәниф кызы**: Мин бу повестьны урта мәктәптә укыган вакыттамы, әллә бераз соңракмы укыган идем. Һәрхәлдә, бу китап 1981 елны басылып чыккан, Ә ул ел минем – Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлап, кулыма биология һәм химия укытучысы дигән диплом алган елым.

Әсәрдә сүз «Беренче Май» колхозы, аның ул вакыттагы председателе, колхозчылары һәм башка кешеләре турында бара. Хәзерге мәктәп балалары колхозны да күрмәделәр, алар – яңа чор кешеләре. Ләкин минем өчен бу әсәр балачак һәм яшьлек елларымның кайтавазы булып тора. Миңа әсәрне укыганда геройлары шулкадәр якын, чөнки мин аларның прототипларын күреп, ишетеп беләм. Повестьтагы колхоз председателе – Рамай Вилданов, ә тормышта ул – Вилдан Рамазанов. Парторг – Яхъя Курмашев, тормышта – мәктәп директоры – Язкар Курмашев. Бу икәү – заманасында билгеле кешеләр иде. Безнең Юлтимердә бригадир булып эшләгән кеше – Бөек Ватан сугышында бер кулын калдырып кайткан Әхмәдия абый (Әхмәй диеп йөртә иделәр авылда), ә әсәрдә ул – Әхмәтзыя диеп бирелгән. Вилдан абый армиягә киткән җиреннән сугышка алына. Менә кечкенә генә бер өзек укып китәм. «...Икенче көнне Сәкинә Рамайны район үзәгенә хәтле озата барды. Ленин бакчасы янында аңа кульяулык бүләк итте. Рамай Бөгелмәдән үк көн саен диярлек хат яза башлады. “Исән – имин кайтсам, икәүләшеп укырга китәрбез. Мин берәр техникумга керермен, син укытучылыкка укырсың”, – дип язды. Рамайның кайтырына санаулы көннәр калганда, ил өстенә афәт килде – сугыш чыкты.

Сәкинә күңеле белән Рамайны сугышка ничек озаткандыр, анысын әйтә алмый. Шулай ук Сәкинә дә ул көннәрдә Рамайның Буг елгасы буенда ил чигендә үлем белән күзгә-күз очрашуын һәм икенче тәүлек авызына кабым ризык, йотым су алмыйча ут-давыл эчендә кайнавын, өермәле сугыш юллары аша чолганыштан чыгып килүен белми иде...

Сәкинәнең бәхете, саф, керсез мәхәббәте өчен исән калгандыр инде Рамай... Авылдан сиксән дүрт ир яу кырларында ятып калды..»

**Алып баручы**: Хәниф Хәйруллин язган очерклар арасында «Канлы еллар, авыр юллар» дигәне минем кулдагы китапта урын алган.

**Фәргать Фалих улы**: Бу очеркта сүз минем туган авылым Кәүҗияк турында бара. Авыллар тарихында илебез тарихы чагыла. Бу әсәрне укып Татарстан тарихы, татар тарихы белән дә танышырга мөмкин. Бер өзек тыңлап китик: «...Авыл, караңгы юрганын бөркәнеп, йокларга җыена. Тычкан уты елтыраган тәрәзәләр саны бер-бер артлы кими. Типтәр, Казан ягы урамында ул инде бөтенләй күренми. Тик Башкорт ягындагы байлар яши торган йортларның тәрәзәләрендә генә унлы лампа яктысы балкый... Башкорт ягына (авылның бу урамында башлыча бик күп җир биләүчеләр), башкорт ягыннан күчеп килгән кешеләр яши...»

**Марина Назыйф кызы**: Безнең Зур Нөркәй авылында да типтәр, казан татарлары яши. Безнең нәсел – типтәрләрдән.

**Флюра Хәниф кызы**: Безнең Юлтимер ерганак белән ике өлешкә бүленгән. Бер якта – типтәрләр (Нөркәй очы), ә икенче ярда – казан татарлары яшәгән. 1917 елгы революциягә кадәр «Типтәрдән кыз алмаганнар, типтәргә кыз бирмәгәннәр». Хәзер мондый бүленеш турында өлкән яшьтәгеләр генә искә ала. Ләкин авылда ике зират бар, мәетләрне ир ягы буенча гореф-гадәтләрне саклап җирлиләр. Безнең нәсел – казан татарларына карый.

**Алып баручы**: Язучы туган төбәгенең үткәнен, Гражданнар сугышы һәм колхозлашу чорында анда барган социаль үзгәрешләрне, катлаулы вакыйгаларны җентекләп өйрәнә. Шул конкрет тормыш материалы нигезендә Хәниф Хәйруллин алтмышынчы еллар дәвамында документаль повесть характерындагы «Бакыр базының серләре», «Алмаз ихтыяр», «Канлы еллар, авыр юллар», «Хуҗида үскән батыр» кебек очеркларын һәм балалар өчен «Тылсымлы таяк табышы» исемле маҗаралы повестен иҗат итә.

**Фәргать Фалих улы:** Әсәрдә вакыйга 1917 елгы революциядән соңгы чорда бара. Илдә Гражданнар сугышы котыра, власть шәһәрдә генә түгел, ә авылларда да алышынып кына тора. Бер көнне – кызыллар, икенче көнне – аклар. Авыл халкына нишләргә кала? Зур кыенлыклар белән совет властен урнаштыралар.

**Алып баручы**: Журналыбызның дүртенче битен ачар вакыт җитте. Бу бите Фәрит Яхинга багышлана.

**Тугызынчы укучы**: Язучы, шагыйрь һәм галим, мөгаллим Фәрит Яхин 1961 елның 1 гыйнварында Сарман районы Дүсем авылында дөньяга килә. Ләшәү Тамак урта мәктәбендә белем алганнан соң, Казан дәүләт университетын һәм аспирантураны тәмамлый. Шуннан соң Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни эшчәнлек алып бара. Соңрак Г. Тукай музее директоры булып эшли. Бүгенге көндә Татар дәүләт гуманитар институтында укыта, филология фәннәре докторы**.**

**Нурсинә Җәмил кызы:** Туксанынчы еллар башында исә беренчеләрдән булып дини мәсьәләләрне яктырткан әдәби һәм фәнни хезмәтләрен язу эшенә керешә. «Пәйгамбәрләр тарихы» (1992), «Иман» (1993) дип аталган беренче китаплары белән киң җәмәгатьчелек таныла. Аннары 1994-1998 еллар арасында, аның аерым-аерым өч китап рәвешендә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә багышланган трилогиясе иҗат ителә һәм басылып чыга. 1999 елда «Раннур» нәшрияты, трилогиянең өч китабын бергә туплап, «Пәйгамбәребез Мөхәммәд» исеме белән хезмәтне яңадан бастырып чыгара.

**Унынчы укучы**: Фәрит Яхин – лирик тезмәләре тупланган өч шигъри җыентык ( «Гүргә кадәр саклаган сөю», «Таңга кайту», «Хис керфегемдә күз яшең») һәм балалар өчен «Могҗизалы ел фасыллары» дигән әкият-поэма (1994) авторы. Шигърияттә ул үзен катлаулы идея-тематик эчтәлеккә ия булган интеллектуаль поэзия тарафдары итеп саный. Аның «Мөхәммәдьяр» исемле драматик поэмасы 1997 елда Татар Дәүләт академия театры сәхнәсендә спектакль итеп куела. Ул проза жанрында да актив иҗат итә, укучыларга көндәлек матбугатта басылып чыккан дистәләрчә хикәя, повестьлары һәм ике кисәктән торган «Август ае» дигән романы белән билгеле. Фәрит Яхин – 1994 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Унберенче укучы**: «Юксыну» дигән нәсердән кыска гына өзек укып китәм. «... Кешеләр бер-берләренә карата мәхәббәт хисләрендә генә түгел, бәлки дуслык вә хөрмәт мәртәбәсе белән кадерлеләр. Хәер, моны ваклап аңлатып торасы түгел, һәркем белә булыр!

Шәхсән мин тормыш шактый туздырды, бәгыремә үтеп аптыратты, ахрысы? Белмим, кешеләр ничек һәм ни-нәрсәдән көч таба торганнардыр, ә мин исә сине уйлап, и газиз җирем, гаҗизләнеп кенә калмыйча, бәлки яшәү көче белән җанымны да ныгыта идем. Дөньям шулай корылырга тиеш булгандыр инде? Сине уйлау, гүяки шифалы яңгыр сыман, җанымның чәчәкле бакчаларын сугара иде...

– Юксыну! Сине йөрәгемнең түренә оялаган кош итеп күрдем. Яну-көюләремнең нәрсә икәнлеген белдем. Көннәрнең берендә балаларың канат чыгарыр да, шулар белән бергә очып китәрсең дип көттем, сабыр иттем. Һәм шулай булды да: син, юксыну хисе, каядыр юкка чыктың, очтың да киттең. Ә күңелем буш калды. Бушлыктан шыксызрак халәт юк икән ул. Буш җаннар бу дөньяда ничек яшиләр икән?

– Инде аңладым: кеше җаны хисләрдән, тойгылардан, зиһеннән һәм өметләрдән төзелә! Аны без нокта итеп тә, аклык итеп тә, сафлык сыман да күз алдына китерергә тырышабыз. Кайчакта граммлап үлчисебез килә. Ә аны күтәреп торырлык бизмәннәр бармы соң? Аңа тонналар гына аз... Һәм кеше гомере буе, шуларны күтәреп, үзенә бикләнеп яши.

– Юксыну – син минем җанымның яшәешененнән бер сыйфаты гына икән шул!»

**Уникенче укучы**:

Елларны моңга сарып,
Тибрәткән халык җыры!
Сизми дә калам,
Ишелеп ярдан чыгасың тагы.
Каян килә сиңа бу дәрт,
Кайдан ага сагышың?
Йөрәгемне мең кат телеп,
Мең кат сыгып аласың.
Иделләрең, далаларының, кырларың, тугайларың –
Барысы җырлый, тик менә
Тулып ишелә зарың.
Нинди моңнар, нинди сагыш
Йокы кисеп уята?
Идел белән Урал уртасында –
Җырларыңда-моңнарыңда
Халкым күңеле ята. (Халык җыры)

**Алып баручы**: Кичәбезнең бу өлешен йомгаклар вакыт җитте. Хәзер тагын бер видеоклип карап китәрбез. Рөстәм Сәрвәров башкаруында татар халык җыры «Сарман» (Юлия Гарифуллина, Алинә Кәримова башкаруында да яңгырый бу җыр).

**Флюра Хәниф кызы**: Минем Клара Булатованың «Безнең як» шигырен сөйләп китәсем килә.

Сабаннар үткән актарып,
Басулар җәйрап ята.
Ипигә ягып ашарлык
Кара җир безнең якта.
Язлардан җылы пар алып
Уҗымнар үскән чакта,
Шәл итеп иңгә ябарлык
Яшеллек безнең якта.
Кояшта пешеп, тып-тыгыз
Башаклар тулган чакта
Алтынга алыштыргысыз
Хәзинә безнең якта.
Әҗерен генә бирик тә.
Кадерен генә белик.
Кадерләп, сөеп үз җирен.
Кем яши эше белән –
Безнең як куйган көчеңне
Кайтара бише белән.

Алып баручы: Кичәбездә катнашкан барлык укытучыларга һәм укучыларга зур рәхмәт. Ә хәзер ял итеп алырбыз. Аннан соң башваткыч чишеп алырбыз.

**V. Күргәзмә-башваткыч «Сандугачлы Сарман ягын беләсезме?» (Күргәзмә-кроссворд)**

Башваткычка җавапларны табу өчен күргәзмә материалларын кулланырга кирәк булачак. Язучылар турында мәгълүматлар чара барышында да яңгырадылар. Башваткычлар 4 вариантта бирелә, кәгазь вариантларда. *(Кушымта №1, Кушымта №2, Кушымта №3)*

**Алып баручы**. Нинди сүз килеп чыкты? Ни өчен сандугач атамасы кулланылган? (Җаваплар тыңлана, нәтиҗә чыгарыла.) Хөкемдарлар башваткычларны тикшереп тиешле билгеләрне куя торырлар, ә без мәктәп ихатасына сәяхәткә чыгарбыз. Сезгә биремнәр алдан ук бирелгән

иде. Юбиляр язучыларның әсәрләрен укып чыгарга һәм аларда очраган үсемлек атамаларын язып алырга.

**VI. Акбурлы ботаника**

**Алып баручы**. Хәзер без сезнең белән мәктәп ихатасы буйлап кечкенә генә сәяхәткә чыгып керербез. Бәйрәмнең бу өлеше – «*Акбурлы ботаника»* дип атала. Акбурның нәрсә икәнен барыгыз да беләсез. Ә ботаника нәрсә өйрәнә? (Җаваплар тыңлана). Ботаника – үсемлекләрне өйрәнүче фән. Ә бу термин кайдан һәм ничек барлыкка килде икән? Бераз тарихына күз салыйк. «Якты юл» газетасында басылып чыккан мәкаләдән бер өзек белән таныштырып китим әле үзегезне.

«Европада «акбурлы ботаника» дигән хәрәкәт популярлаша. Табигать сөючеләр асфальтка үсемлекләрнең атамаларын язып куя. «Үсемләрне тану табигатьне сакларга ярдәм итә», дигән фикердә тора алар. «Акбурлы ботаника»ны 2019 нчы елда Франциянең Тулуза шәһәре музее ботанигы Борис Прессек башлап җибәргән. «Мин табигатьтә "чүп" үләннәре барлыгын аңлатырга, аларны хөрмәт итүләрен теләдем», – дип сөйләгән ул журналистларга.

Берникадәр вакыттан соң Бөекбританиядә ботаник Софи Легуил «Чүп үләне генә түгел» дип аталган экологик хәрәкәт башлап җибәрә. Кыргый үсемлекләрне саклау оешмасы вәкиле Тревор Динес, бу хәрәкәтнең кирәклеген дәлилләп, саннар китерә. Мәсәлән, Бөекбританиядә 16 яшьтән 24 яшькә кадәргеләрнең алты проценты гына миләүшә чәчәген таный икән. Шул ук вакытта, сораштырган яшьләрнең 70 проценты үсемлекләрнең атамаларын белергә теләүләрен әйткән.

**Биология укытучысы**. Мәктәп ихатасында асфальт бары керә торган юлда гына. Без бераз гына үзгәрешләр кертербез. Мин сезгә төшке ашка кадәр язучыларның китапларын өләштем. Сезгә әсәрләрдә очраган үсемлекләрнең исемлеген төзергә дигән бирем бирелгән иде. Хәзер мәктәп ихатасыннан шул үсемлекләрн эзләп табарга кирәк, бүлмә гөлләрен дә онытмагыз, танышып килегез. Бу исемлектәге үсемлекләрне табыгыз, авылча атамалары да ярый. Исемлектә культуралы үсемлекләр дә бар. Иң беренче эш итеп, бары тик кыргый үсемлекләрне генә сайлап алыгыз, бергәләп тикшереп чыгарбыз. Икенче көнне су үтмәслек этикеткалар ясарбыз, татарча һәм русча атамаларын табып, язып куярбыз. 1)Ничек итеп су үтмәслек этикеткалар ясарга мөмкин? 2) Этикеткаларны җәй буе ничек сакларга?

Шуны да онытмагыз, ихатадагы үлән чабылып тора! Авыл җирендә чабылган үлән – печән икәнен аңлыйсыз. Менә бер сан гына китерим әле. Кислород бүленеп чыксын өчен шәһәр территориясенең 40-60% яшеллек тәшкил итүе, шуларның яртысы «кыргый» урыннар булуы мөһим. Казан мисалында бу күрсәткеч 15% кына. Үләне чабылган парклар, мәсәлән, су буендагы куаклыкларга караганда, кислородны 12-15% ка азрак җитештерә. Кеше кислородсыз яши алмый.Табигатьтән читләшеп, асфальт-бетон арасында гомер иткән кеше депрессиягә бирелә башлый.

**Йомгаклау**

**Алып баручы**: Хөкемдарлар гомуми нәтиҗә ясыйлар, ә мин чарабызны йомгаклау үзебезнең укытучыбыз (мәрхүмә) Рәйсә апагызның шигыре белән тәмамлыйсым килә.

«Бәхетләрнең төсе нинди?» – димә,
Бәхет һәрчак кояш төсендә.
Кара икмәк, үскән газиз җире,
Имин дөнья кирәк кешегә.
«Бәхетләрнең төсе нинди?» – димә,
Яшел чирәм, рәшә төсләре,
Мөлдерәмә бодай басулары
Баш әйләнгеч арыш исләре.
Бәхет төсе безнең туган якта
Һәммәбезгә өлеш җитәрлек.
Кояш нуры белән җанга иңгән
Йөрәкләрдә яши ул бәхет.

(«Бәхетләрнең төсе нинди?» – димә» Р. Вәлитова)

**Әзһәр Габиди – Сарманның йөзек кашы**
(Эшлекле уен)

Хәсәншина Фирая Зәкәрия кызы, 2 нче санлы «Лилия» балалар бакчасының өлкән тәрбиячесе, Сарман районы

Максат: педагогларның Сарман төбәгенең күренекле шәхесе Әзһәр Габидинең тормыш юлы һәм иҗатына турында белемнәрен ачыклау һәм киңәйтү, һөнәри осталыгын арттыру.

Уен барышы

Сарман ягы талантларга бик бай. Монда танылган язучылар, күренекле шагыйрьләр, атказанган артистлар туып-үскән. Алар үзләренең иҗатлары белән татар сәнгать дөньясын баеталар һәм туган ягыбыз данын еракларга тараталар. Гомумән, һәр төбәкнең горурланыр шәхесләре бар. Ә Сарман җиренең горурлыгы – язучы, шагыйрь, мөгаллим Әзһәр Габиди. Сарманның йөзек кашы ул. Аңа, һичшиксез, Сарман төбәге чишмәләренең шифалы суы, сандугачларының моңлы сайравы, яшел урманнарының сихри һавасы, зәңгәр тауларының гүзәллеге илһам биреп, олы иҗат юлына алып чыккандыр.

Безнең эшлекле уеныбыз Әзһәр Габидинең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган. Балалар бакчасында Әзһәр Габидинең бик күп шигырьләрен укыйбыз, яттан сөйлибез, ә аның үзе турында ниләр беләсез икән, үзегезне сынап карагыз әле, хөрмәтле педагоглар.

Педагоглар ике командага бүленеп ярыша. Ярыш дәвамында иң күп балл җыйган команда, әлбәттә, җиңү яулаячак.

(Кайсы команда беренче җавап бирә, шул командага балл куела).

<u>1.Сорау-җавап</u>

1) Әзһәр Габиди кайчан һәм кайда туган ? (1926 елның 25 сентябрендә Татарстан АССРның Сарман районы Чукмарлы авылында туган)

2) Кайда һөнәри белем алган? (Минзәлә педагогика училищесында белем алган)

3) Әзһәр Габиди нинди һөнәр иясе? (Татар теле һәм әдәбияты укытучысы)

4) Әзһәр Габидине алга таба иҗат эше белән шөгыльләнергә илһамландыручы беренче шигырь җыентыгының исеме? (Беренче шигырь җыентыгы «Без – яз дуслары» исемле була)

5) Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Әзһәр Габиди әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге казанышлары өчен нинди премия белән бүләкләнә? (1997 елда Рафаил Төхфәтуллин премиясе бирелә)

7) Әзһәр Габиди шигырьләренең тематикасы нинди? (Туган авылы табигатенә багышлана)

8) Әзһәр Габиди мәктәптә әдәби түгәрәк җитәкләгән, ул нинди исем йөрткән? («Яшь бөре» әдәби түгәрәге)

<u>2. Ребус чишү.</u> Ребуска мәкаль һәм Әзһәр Габидинең китап исеме яшерелгән. Кайсы команда беренче чишеп бетерә, шул командага балл куела.

1)





3. Кроссворд.

(Кайсы команда беренче чишеп бетерә, шул командага балл куела).

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1) | | | | | | | |
| | 2) | | | | | | |
| | | 3) | | | | | |
| | 4) | | | | | | |
| | | 5) | | | | | |
| 6) | | | | | | | |

1. Дөньядагы бөтен һөнәрләрнең
   иң сәере, иң-иң көмешсезе,
   иң-иң өлешсезе тиде миңа...
   Минем «һөнәр» – шигырь язучы...(авторның һөнәре (Шагыйрь)?
2. Кәгазь өстен карайта,
   Дөнья йөзен агарта. (Китап)
3. Бер байлык бар – янмый,
   Карак та урлый алмый,
   Төшеп тә югалмый. (Белем)
4. Нәрсә beләсең килсә дә,
   Син җавапны аннан тап.
   Телгә оста, белеме күп,
   Аның исеме... (Китап).
5. Өстәлгә дә мин куям.
   Куенга да кыстырам,
   Шунда мин язып барам. (Дәфтәр)
6. Укырга да өйрәтә,
   Язарга да өйрәтә.
   Балага бирә белем, ул буладыр... (Мөгаллим)

4. Серле тартма.

Бу тартма эчендә язучы белән турыдан-туры бәйләнгән предмет яшерелгән. Сезгә аны тасвирлап күрсәтәм, ә сез аңларга тырышыгыз һәм нәрсә икәнен языгыз.

Күп еллар дәвамында бу предмет язучыларның, философларның һәм журналистларның эш коралы булып санала. Ә бу предметның тарихы 1714 елда башлана. Аны Англиядә Генри Милл исемле су үткәрүче уйлап таба. 1808 елда, йөз ел вакыт үткәннән соң, аны Пеллегрино Тури таныш графинясы өчен уйлап тапкан. Графиня сукыр була, ә бу предмет ярдәмендә ул туганнары белән аралаша ала.




Бу предмет  ясалучы тагын бер урын Россия була. Аны ясаучы кешенең исеме Михаил Иванович Алисов. Ләкин бу предметны ясау бик кыйммәткә төшә һәм ул күпләп ясалмый. Ә менә  бу предметны  күпләп ясау эше Америкада 1874 елда башлана. Аны   Кристофер Лэтхэм Шолес – язучы, журналист һәм, әлбәттә, уйлап табучы башлап җибәрә.



Алга таба  бу предмет бөтен дөньяда популярлык казана. Аны җитештерүче заводлар эшли. Аны елдан-ел үзгәртәләр, камилләштерәләр.

Һиндстанда булган бу предметны  җитештерү буенча соңгы завод 2011 елның апрелендә ябылган. Димәк, бу язучы коралының чоры рәсми төстә тәмамланды. Һәм алар сувенирлар кебек  кенә кулланыла. Серле тартма эчендә нәрсә?

<u>5. Кроссенс  «Әзһәр Габиди».</u>   Командаларга бирем –  кроссенс төзү.

| | | |
|---|---|---|
|  | |  |
|  |  |  |
|  | |  |

<u>6. «Нинди син, Сарман?»</u>

Безнең уенның исеме «Әзһәр Габиди – Сарманның йөзек кашы» дип атала. Татарстанга күренекле җырчылар, язучылар, шагыйрьләр, сәнгать, мәдәният, дәүләт эшлеклеләре, хезмәт алдынгылары биргән  Сарман ягы. Нинди ул? Алдагы бирем  «Нинди син, Сарман?» дип атала.

САРМАН сүзенең һәр хәрефенә сыйфатлар уйлап әйтергә кирәк.

(Ике комндага да балл куела)
С - сандугачлы, сабыр
А - акыллы, аһәңле
Р - рәхимле, риясыз
М - матур, моңлы
А - абруйлы, ачык йөзле
Н - нәзәкатьле, намуслы
7. Йомгаклау. (Нәтиҗә чыгырыла һәм җиңүче команда билгеләнә)
Уеныбызны Әзһәр Габидинең шигырь юллары белән тәмалыйсым килә:
Без ул кадәр олы шәхес түгел,
Тукайныкы кадәр эз калмас.
Ләкин Сарман үзен җырга салган.
Ихлас җанлы улын онытмас, – дип язган ул.

Шагыйрьләрнең язмышлары үзгә – безнең арабыздан китсәләр дә, онытылмас истәлек булып тарихта аларның шигъри юллары кала, еллар үткән саен алар безгә якынрак һәм кыйммәтлерәк. Әзһәр Габидинең иҗаты да нәкъ менә шундый язмышка ия. Еллар үтә тора, ә ул шигырьләр укыган саен безгә моңа кадәр күрелмәгән гүзәллеген ачалар.

Катнашуыгыз өчен рәхмәт. Уен кызыклы һәм файдалы булгандыр дип ышанып калам. Барыгызга да уңышлар телим. Сау булыгыз!

**Укытучы – шагыйрь – фронтовик**
(Сыйныфтан тыш чара эшкәртмәсе)

Фатыйхова Гөлия Фоат кызы, Хаҗиева Равия Рафаил кызы, Сарман гимназиясенең башлангыч сыйныф укытучылары, Сарман районы

Максат: Әзһәр Габиди иҗатына кызыксыну, мәхәббәт, олуг шәхеснең якташыбыз булуы белән горурлану хисләре уяту.
Җиһазлау: Әзһәр ага Габидинең портреты, «Сарман үзен җырга салган, Ихлас җанлы улын онытмас» дип исемләнгән китап күргәзмәсе, презентация, аудиоязма.
Җырлар: «Минем гөлем» Ә. Габиди сүзләре, Ф. Хатыйпов көе, «Чыршы» Ә. Габиди сүзләре
Чарада катнашалар: алып баручылар, башлангыч сыйныф укучылары
1 нче алып баручы: Безнең Сарман ягы талантларга бай. Әзһәр ага Габиди – шундый талант ияләренең берсе. Өлкәннәр һәм балалар өчен матур шигырьләр иҗат иткән шагыйрь ул. Дәһшәтле Бөек Ватан сугышының утларын кичкән фронтовик. Сугыш кырыннан исән-сау кайтып, 30 ел гомерен балаларга белем биргән укытучы.
2 нче алып баручы: (Экранда шагыйрьнең биографиясе) Слайд 1

Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин 1926 елның 26 сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында урта хәлле крестьян семьясында туа. Авылда җидееллык мәктәпне бетереп, Сарман урта мәктәбендә укып, унынчы классны тәмамлап,17 яшендә фронтка китә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ә. Габиди 1 һәм 2 дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә.
Слайд 2. 1945 елда Совет – япон сугышында бик каты яралана, бер ел госпитальдә ята. 1946 елда туган авылына кайта. 1950 елда Минзәлә педагогия көллиятендә белем ала, соңыннан Сарман районы Чукмарлы мәктәбендә 30 ел татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.
Слайд 3. Шул вакытта «Без – яз дуслары» исемле балалар өчен язылган беренче шигырь җыентыгы дөнья күрә. Ә. Габиди – 20дән артык китаплар авторы, башлыча балалар шигъриятенә хезмәт итте. Ә.Габиди – 1994 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. 1997 елда Рафаил Төхватуллин исемендәге премия белән бүләкләнә. 2001 елның 22 августында вафат була.

1 нче алып баручы: Слайд 4. Ә.Габиди – балалар әдәбиятының танылган өлкән шагыйре. Язучының бүгенге көнгә балалар өчен «Тапкырҗан табышмаклары», «Таң сәгате», «Без – яз дуслары», «Югалган кояш», «Кошчыгым», «Калган эшкә кар ява» китаплары дөнья күргән.
2 нче алып баручы: Әзһәр ага Габидинең шигырьләре туган як, андагы гадәти вакыйгалар, күренешләр турында. Туган җирнең, туган туфракның кадерен белергә, кыю булырга өнди ул.
1 нче бала: «Нарат» шигыре
Җилләр чыкса нараткайны
Сыгалар төрле табан.
Буйсынырга теләми ул,
Турайта башын һаман.
Ялгыз гына яшәсә дә,
Курыкмый ул җилләрдән.
Чөнки бит ул тамырларын
Җиргә тирән җибәргән.
2 нче алып баручы: Әзһәр аганың: «Туган туфракта үскән җиләк кенә тәмле була», – диясе килә.
2 нче бала: «Бакчада» шигыре
Нәрсәдән син болай тәмле,
Әйт әле, җир җиләге?
Мин югында әллә әни
Сиңа шикәр бирәме?
Матур бул дип, әллә абый
Сине алга манамы?
Хуш исле бул дип, апа да
Хушбуйларын ягамы?
Син яраткан тәмле балны
Мин, дустым, җирдән алам,
Ә битемне, алсулатып,
Кояш нурына манам.
2 нче алып баручы: Әзһәр Габиди шигырьләрендә әхлак темасы да шактый урын алган. Шагыйрь балаларга тискәре сыйфатларга ия булуны начар икәнлеген аңлата. Бу турыда шагыйрь турыдан-туры әйтми, үпкәләтмәслек итеп, читләтеп әйтә, нәни укучыга нәтиҗә ясарлык итеп сөйли.
3 нче бала: «Һавалы чеби» шигыре
Һаваланып йөргән булды
Чуар тавык чебие,
Аны тотып алып киткән
Күршебезнең песие.
Песи тырнагына эләккәч
Үкенгәндер, бичара.
Мондый чакта ялгыз чеби
Кыла ала ни чара?!
Төркемеңнән аерылу –
Һәлакәт башы икән,
Аерылганны аю түгел
Песи дә ашый икән.
1 нче алып баручы. Алдагы шигырендә Ә. Габиди кеше әйберен рөхсәтсез алу начар икәнен күрсәтә.
4 нче бала: «Карак песи» шигыре
Песи кергән келәткә,
Хуҗасы күреп алган –
Песие куркып качкан.
Эзен яшерер өчен,

Кереп поскан почмакка.
Әгәр шушы хәлне күрсә,
Көләр иде тычкан да.

1 нче алып баручы. Ә Габидинең күп кенә шигырьләре көйгә дә салынган, җырга әйләнгән.

**«Минем гөлем» Ә. Габиди сүзләре, Ф. Хатыйпов көе (Катнашучы балалар башкара)**

2 нче алып баручы. Балаларның зиһенен баетуда, уйлау-фикерләү сәләтен үстерүдә дә Әзһәр аганың «Тапкырҗан табышмаклары» исемле китабы игътибарга лаек. «Булсаң зирәк – әйт тизрәк!» дигән табышмак әйтү уенын уйнап алыйк.

1. Җир астында – алмасы
Сабагында – йөземе.
Шул алманы бөтен халык
Җыеп ала көз көне. (Бәрәңге)
2. Мөгезеннән тоталар да
Баскалап үкертәләр,
Аннан биленә атланып,
Юл буйлап җилдертәләр. (Мотоцикл)
3. Юк энәсе, юк күзе
Челтәр бәйли ул үзе,
Күпме челтәр бәйләсә дә,
Юктыр бер генә җөе. (Үрмәкүч)

2 нче алып баручы. Шагыйрь балаларны, табигатьне яратырга, аны сакларга, күзәтүчән булырга чакыра

5 нче бала: «Синоптик» шигыре
Булмаса да үрмәкүчнең
Сөйләргә радиосы,
Ул яшь натуралистларның
Иң ышанычлы дусты.
«Ничек дус була, – дисезме, –
Үрмәкүч кеше белән?»
Һава торышын белдерә
Ул кылган эше белән.
Әгәр челтәр бәйләсә ул,
Чалт аяз була һава.
Әгәр күләгәгә качса,
Ул көнне яңгыр ява.

«Чыршы» җырын күмәк башкару

1 нче алып баручы. Һәркайсыбызга таныш, якын, матур-матур шигырьләре белән күңелләребезне яулаган мөхтәрәм якташыбыз, шагыйрь Әзһәр ага Габиди безнең арабызда юк инде. Үзе булмаса да, шигырьләре яши, ихласлыкка, матурлыкка өнди. Әле тагын күп-күп балалар киләчәктә Әзһәр Габидинең шигъри тәлгәшләрен «авыз итәрләр»!

## Сарман ягы талантлары
## (4 нче сыйныфта туган (татар) телдә әдәби уку дәресе)

Һадиуллина Гөлнара Әкмәлетдин кызы, Сарман гимназиясенең башлангыч сыйныфлар укытучысы, Сарман районы

**Максат:** Ә.Габиди, К.Булатова, Х.Хәйруллин, Ф.Яхин иҗатлары, тормыш юллары белән танышу.

**Бурычлар**: укучыларның сорау куя, нәтиҗә ясый белү кебек фикерләү сәләтләрен үстерү; туган якка, әниләргә хөрмәт хисләре тәрбияләү.

**Планлаштырыла торган нәтиҗә:**

- предмет нәтиҗәләре: шагыйрьләрнең тормышлары һәм иҗатларының туган як тормышыннан аерылгысыз булуына төшенү;

- шәхесне үстерә торган нәтиҗәләр: Ә. Габиди, К. Булатова, Х.Хәйруллин, Ф.Яхин шәхесләре белән кызыксыну уяту,

- метапредмет нәтиҗәләре: төрле мәгълүмат чаралары белән эшләү тәҗрибәсен ныгыту.

**Универсаль уку гамәлләре:**

- танып белү УУГ: укучыларның сорау куя белү, нәтиҗә ясый белү кебек фикерләү сәләтләрен үстерү, үз фикерләрен дөрес һәм матур итеп әйтүләренә ирешү;

– регулятив УУГ: эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү; ихтияр көче, максатчанлык, активлык кебек сыйфатларга ия булуга ирешү;

– коммуникатив УУГ: төркемдә эшли белү; мәгълүматны туплау өчен күмәк эшчәнлектә катнашу.

**Дәреснең тибы**: Яңа белемнәр үздәштерү дәресе.

**Предметара бәйләнеш:** тарих, сәнгать.

**Алымнар**: мәгълүмат бирү, эзләнү, модельләштерү, монолог.

**Эш формалары:** фронталь, төркемнәрдә, индивидуаль.

**Җиһазлау**: проектор, презентация, китаплар күргәзмәсе, шагыйрьләрнең портретлары, төсле итеп чыгартылган китап тышлыклары, төркемнәрдә эшләү өчен карточкалар, шагыйрьләрнең кыскача тормыш юлы язылган карточкалар, конверт

Дәрес барышы

**I. Оештыру өлеше, мотивация.**

- Исәнмесез, укучылар! (Укытучының кесә телефоны шалтырый) **(Слайд 1)**
Гафу итегез, зинһар, балалар, тиз генә сөйләшеп алыйм инде. Кем микән? Алло, әйе, тыңлыйм...
(Инглизчә акцент (бозыбрак әйтү) белән тавыш ишетелә) ( **Слайд 2**):
- Исәнмесез, Сарман гимназиясенең 3 нче б сыйныфы укучылары! Без – Американың Калифорния штаты Лос-Анджелес шәһәреннән сезнең яшьтәшләрегез булабыз. Зинһар өчен, үтенечебезне кире какмагыз. Безгә сезнең ярдәм кирәк. Бөтендөнья әдәбият форумында катнашу өчен чыгыш әзерлибез. Һәр илдән, һәр төбәктән танылган язучылар, шагыйрьләрне барлыйбыз. Сарман районы турында гына мәгълүмат таба алмадык. Бар өмет – сездә. Әдәбият өлкәсендә нинди күренекле кешеләрегез бар, зинһар өчен, безгә язып җибәрегез әле. Адрес һәм конверт җибәрдек. Алдан ук бик зур рәхмәт.
- Балалар, нишлибез, булышабызмы? (Җаваплар) Ничек инде булышмыйк ди, океанның теге ягыннан безгә шалтыратып ярдәм сорыйлар. Безнең өчен авыр эш түгел бит бу, балалар, шулаймы? **(Слайд 3)**

**II. Дәреснең темасын билгеләү, максат кую**

- Димәк, бүгенге дәресебезнең темасы нинди булыр? Кемнәр турында сөйләшербез? (Сарман районының күренекле язучылары, шагыйрьләре. **(Слайд 4)**
- Бик дөрес. Алар турында Америкада яшәүче дусларыбызга мәгълүмат җибәрү өчен безгә нәрсәләр эшләргә кирәк? (Балаларның җаваплары: исем, фамилияләрен искә төшерергә; портретларын табарга; әсәрләре белән танышырга; тормыш юлларын өйрәнергә кирәк. **(Слайд 5)**
- Балалар, безнең Сарман төбәге талантларга бик бай. Күренекле фән эшлекләләре дә, табиблар да, җырчылар да, артистлар да җитәрлек бездә. Ә бүген без берничә якташ әдип хакында сөйләшербез. Дәресебез ахырында, менә шушы конвертка салып, Америкага хат җибәрербез. (Алдан әзерләнгән зур конверт күрсәтелә, тактага элеп куела)

**III. Белемнәрне актуальләштерү. Төркемнәрдә эш.**

(Күренекле кешеләрнең исем, фамилиясе язылган карточкалар әзерләнә. Шулар арасыннан Сарман төбәге кешеләрен сайлап алырга кирәк.)
1 нче төркемгә – Шарль Перро, **Әзһәр Габиди**, Радик Фәизов, Сибгат Хәким
2 нче төркемгә – Габдулла Тукай, Николай Гоголь, **Клара Булатова**, Муса Җәлил

3 нче төркемгә – Александр Пушкин, **Хәниф Хәйруллин**, Ризаэтдин Фәхреддин, Абдулла Алиш

4 нче төркемгә – Иван Крылов, **Фәрит Яхин**, Шиһабетдин Мәрҗани, Ганс Христиан Андерсен (һәр төркем Сарман язучылары күрсәтелгән карточкаларны тактага чыгарып беркетә) **( Слайд 6, 7 )**

**IV. Дәрес темасы өстендә эш. Яңа белемнәр алу.**


- Бүгенге дәрестә туган төбәгебезнең менә шушы дүрт атаклы кешесе турында тирәнрәк, күбрәк белербез.

**1.Әзһәр Габиди. (Слайд 8)**

- Әзһәр Габиди турында нәрсәләр беләсез? Аның нинди шигырьләрен укыганыгыз, ятлаганыгыз бар? (Җаваплар тыңлана)
- Портретын күрсәтү
- Ә. Габиди китаплары күргәзмәсе белән танышу







- Тормыш юлы белән танышу:

1926 елның 26 сентябрендә Чукмарлы авылында туа. Сарман урта мәктәбен тәмамлый. 17 яшендә фронтка китә. Яралана, госпитальдә ята. 1946 елда туган авылына кайта. 30 ел буена татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. 20 дән артык китап чыгара. 2001 елнын 22 августында вафат була.

**Шигырьләре белән танышу.**

«Котырма, буран» шигырен башта эчтән укыйлар, аннан берничә бала кычкырып укый.

- Шигырьдә кайсы ел фасылы турында сүз бара?
- Ни өчен автор кышны яратмый?
- Аның күңеленә кайсы ел фасылы якынрак?
- Америка балаларына, бәлки, бу шигырь сәеррәк тоелыр, аларда бездәге кебек салкын, буранлы кышлар юк. Ә. Габиди безнең үзебезнең искиткеч матур табигатебез турында язган.

«Асыл килсен фасыллар» шигыре белән танышу. (Башта эчтән, аннан кычкырып укыйлар. Сүзлек эше: Җиһан – дөнья).

- Ә бу шигырендә автор кайсы ел фасылын мактый?
- Шагыйрьнең төп әйтәсе килгән фикере кайсы юлларда бирелгән?

-Үзе сугышта катнашкан кеше буларак, Ә. Габиди тыныч, имин тормышның кадерен белә. Балаларга да шуны аңлатырга тели.

**Нәтиҗә**: Чит илдәге дусларыбызга Ә. Габиди турында нинди мәгълүматлар җибәрербез? Без аның турында нәрсәләр белдек? (Балаларның җаваплары тыңлана)

Конвертка Ә. Габидинең портретын, кыскача тормыш юлы язылган карточканы, чыгартылган китап тышлыкларын, укыган ике шигырь текстын салына.

**2. Клара Булатова (Слайд 9)**

- Җырлы Сарманыбызның тагын бер танылган, талантлы кешесе – шагыйрә Клара Булатова турында сөйләшербез.




- Клара Булатова турында нәрсәләр беләсез? (Җаваплар тыңлана)
- Портретын күрсәтү
- Китап күргәзмәсен карау
- Тормыш юлы белән танышу

1936 елның 18 мартында Татар Карамалысы авылында туа. Сарман урта мәктәбен, Казан дәүләт университетын тәмамлый. Түбән Ләшәү, Яңа Кәшер мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Дистәдән артык китап авторы. Бик күп шигырьләренә җырлар язылган. Хәзерге көндә Әлмәт районында яши.

**«Әниемнең кызы юк бит»** шигыре белән танышу. (Башта эчтән, аннан кычкырып укыйлар)
- Әниләргә ни өчен булышырга кирәк? Сез әниләрегезгә булышасызмы? Ничек ярдәм итәсез?
- К.Булатованың әлеге герое сезгә ошадымы? Ни өчен?

**«Әни – егет»** шигыре белән танышу (Эчтән укып танышалар, сәнгатьле уку өстендә эш)
- Ни өчен автор әнине егет дип атый?
- Сезнең гаиләдә моный хәл күзәтелмиме?

Клара апа Булатованың әниләр, әниләргә хөрмәт, аларга булышу турында ике шигыре белән таныштык. Ул үзе дә әни, Марс исемле малай үстергән. Чынлап та, дөньяда иң кадерле кешеләр – әниләр. Алар исән-сау, сәламәт, озын гомерле булсыннар.

**Нәтиҗә:** Чит илдәге дусларыбызга К.Булатова турында нинди мәгълүматлар җибәрербез? Без аның турында нәрсәләр белдек? (Балаларның җаваплары тыңлана)

Конвертка К.Булатованың портретын, кыскача тормыш юлы язылган карточканы, чыгартылган китап тышлыкларын, укыган ике шигырь текстын салына.

**V. Ял минуты.** С.Фәтхетдинов башкаруында К.Булатова сүзләренә, Р. Тимербаев иҗат иткән «Гармун» җырына берничә бала чиратлап татар бию хәрәкәтләре күрсәтә, калганнар кабатлый. **(Слайд 10)**

**VI. Яңа белемнәр үзләштерүне дәвам итү.**

**3. Фәрит Яхин. (Слайд 11)** Фәрит Яхин – шагыйрь, язучы, әдәбият галиме.




- Портретын күрсәтү
- Китап күргәзмәсе белән танышу
- Тормыш юлы белән танышу

1961 елның 2 гыйнварында Дүсем авылында туа. Ләшәү Тамак урта мәктәбен, Казан дәүләт университетын тәмамлый. Тел, әдәбият һәм тарих институтында, Г.Тукай музеенда эшли. Бик күп фәнни хезмәтләр бастыра. Казанда яши.

- Туган-туфрак, туган ил кадере турындагы «**Читтә калу**» исемле шигырь белән танышып китәрбез. (Укытучы укый)

**- Сүзлек эше:** Тәкъдир – язмыш

- Лирик герой ни өчен читтә кала?

- Читтә яшәү авырлыклары язылган урыннарны тап.

Әйе, туган җир – аңлатып бетерә алмаслык кадерле урын ул. Читтә яшәгән кешеләр моны бик нык аңлыйлар. Ф.Яхин да үзенең Дүсемен бик сагынып яшидер. Шушы ук темага язылган «**Чыктым да мин авыл башына»** исемле шигыре белән танышырбыз. (Шигырьне уку).

- Авторның туган ягын сагынып яшәве кайсы юлларда күренә?

- Балалар, үзебезнең Сарманыбызның кадерен белегез. Укып чыгып, зур кешеләр булып, туган ягыбызны үстерү өстендә эшләгез. Читтә бәхет эзләмәгез, бәхет – үзеңнең туган төбәгеңдә, әти-әниләр янында, минемчә.


**Нәтиҗә:** Америкадагы дусларыбызга Ф.Яхин турында нинди мәгълүматлар җибәрербез? Без аның турында нәрсәләр белдек? (Балаларның җаваплары тыңлана)

Конвертка Ф.Яхинның портретын, кыскача тормыш юлы язылган карточканы, чыгартылган китап тышлыкларын, танышкан ике шигырен салына.

4. Районыбызның тагын бер күренекле кешесе – язучы, журналист **Хәниф Хәйруллин. (Слайд 12)**

- Портретын күрсәтү

- Китапларыннан төзелгән күргәзмә белән танышу




- Тормыш юлы белән танышу

1931 елның 12 сентябрендә Сарман авылында туа. Сарман урта мәктәбен, Казан дәүләт университетын тәмамлый. Азалак мәктәбендә 1 ел укытучы булып эшли. Сарман район газетасында озак еллар хезмәт куя. Буа районы газетасында да эшли. 1998 елның 18 июнендә вафат була. Безнең гимназиябездә Х.Хәйруллин исемендәге музей эшләп килә. Хәтта Х.Хәйруллин исемендәге премия дә бирелә. Аның өчен яхшы укырга, конкурс, ярышларда катнашырга, урыннар алырга кирәк.

Х.Хәйруллинның балалар өчен язылган «Бакыр базының серләре» әсәре бар. Бакыр базында нинди серләр яшерелүе турында үзегез мөстәкыйль укырсыз. Бик кызыклы, мавыктыргыч әсәр. Икенче дәрестә шул турыда сөйләшербез.

**Нәтиҗә:** Чит илдәге яшьтәшләребезгә Х.Хәйруллин турында нинди мәгълүматлар җибәрербез? Без аның турында нәрсәләр белдек?

Конвертка Х.Хәйруллинның портретын, кыскача тормыш юлы язылган карточканы, чыгартылган китап тышлыкларын, «Бакыр базы серләре» әсәрен салына.

**VII. Алган белемнәрне ныгыту. Модельләштерү. (Слайд 13)**

| | |
|---|---|
| Шагыйрь, укытучы, фронтовик | Клара Булатова |
| Бүгенге көндә Казанда яши, шагыйрь, галим | Әзһәр Габиди |
| «Марс китабы» авторы | Хәниф Хәйруллин |
| Гимназиябез музее аның исемен йөртә | Фәрит Яхин |

**VIII. Дәрескә йомгак. Рефлексия.**

- Балалар, үзебезнең туган төбәгебездән чыккан берничә атаклы шәхес белән таныштык. Америкадагы яшьтәшәребезгә дигән хатыбыз әзер. Шактый гына мәгълүмат тупладык. Аларга файдалы булыр дип уйлыйм. Хәзер инде конвертка үзебезнең адресны язып, почтага илтеп саласы гына калды. Сезгә бик зур рәхмәтемне әйтәсем килә. Кешенең үтенечен кире какмадыгыз, тиз арада җавап та яздыгыз.

Дәрес башында куелган максатларны искә төшерик әле. Без аларга ирештекме?

- Кайсы язучы, шагыйь сезгә ныграк ошады? Ни өчен?

Сарман ягы талантлы кешеләргә бай, дидек. Чынлап та, алар бик күп. Алдагы дәресләрдә без алар белән танышуны дәвам итәрбез. Үзебезнең Сарманыбыз белән горурланып яшәргә язсын!( Слайд 14)

Дәресебез шушының белән тәмам. (Шигырьләрне кычкырып укучы балаларга билгеләр кую)

**IX. Өй эше.** Х.Хәйруллинның «Бакыр базының серләре» әсәре белән танышырга.

## Җир кешеләр белән матур

(Әзһәр Габидинең иҗатына багышланган шигырь кичәсе)

Габдрахманова Гөлназ Рәсит кызы, А.Тимергалин ис. Иске Минзәләбаш төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Сарман районы

Максат: укучыларга Әзһәр Габидинең тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат бирү, аның әдәбиятта тоткан урыны белән таныштыру; балаларның сүзлек запасын баету, сөйләм телен, иҗади фикерләү сәләтен үстерү, аларны эзләнү-тикшерену эшенә тарту; шагыйрь иҗаты белән кызыксыну уяту; туган җирне, туган якны ярату хисе тәрбияләү.

А.Б.: Исәнмесез, хәерле көн, кадерле укучылар, хөрмәтле укытучылар! Сарман – тарихлы, җырлы-моңлы, талантларга бай төбәк. Без бүген шундый талантларыбызның берсе, гомере буе Сарман районының Чукмарлы авылында яшәп иҗат иткән, ялкынлы әдип Әзһәр ага Габидинең ижатына багышланган шигырь кичәсенә җыелдык.

А.б. Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин 1926 елның 26 сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Җидееллык мәктәпне бетерә, Сарман урта мәктәбендә унынчы классны тәмамлый, 1943 елда фронтка китә. 1945 елда япон сугышында каты яралана, бер ел дәвамында госпитальдә дәвалана. 1945 елда «Тревога» исемле фронт газетасы типографиясендә аның «Борылмалы юллардан» исемле китабы басыла. 1946 елда үз туган авылына әйләнеп кайта.

А.б. Әзһәр Габиди 1947-1950 елларда «Чулпан» колхозында хисапчы ярдәмчесе, хуҗалык мөдире булып эшли.

А.б. 1950 елда Минзәлә педагогия училищесында белем ала. Училищены тәмамлагач, Ләке, Морбаш, Чукмарлы сигезьеллык мәктәпләрендә укыта, соңыннан Сарман район мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Шул вакытта аның «Без – яз дуслары» исемле беренче шигырь җыентыгы дөнья күрә һәм аны алга таба иҗат эше белән шөгыльләнергә илһамландыра.

1 укучы: «Дәрес бирәм» шигыре

Дәрес бирәм,
Бар дөньямны онытып.
Бөтен класс тыңлый йотлыгып.
Үзем уйлыйм: сүзем керсен иде
Бала йөрәгенә нур булып.
Бала күңеле – күтәрәсе чирәм,
Ни чәчсәң дә анда үсәчәк.
Нинди авыр булыр: гөл урынына
Үсеп чыкса шыксыз тигәнәк.
Тырышканда әле йолкып була,
Утап була кырдан чүп-чарны.
Ләкин
Бала күңеленә үскән чүпне
Бик-бик кыен була утавы.
Дәрес бирәм,
Бар дөньямны онытып.
Бөтен класс тыңлый йотлыгып.
Сүз-орлыгым бала күңелендә

Шытып чыга гүя гөл булып.

А.б. Әзһәр ага Габиди 1942 елдан бирле әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Иҗатының зур өлеше балаларга багышланган. Аның төрле елларда дөнья күргән «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Калган эшкә кар ява», «Таң сәгате», «Без – яз дуслары», «Югалган кояш», «Өч киңәшче» китаплары балаларны намуслы һәм тәртипле, тырыш һәм хезмәт сөючән итеп тәрбияләүдә зур роль уйный.

2 нче укучы: «Әхияр белән кыяр» шигыре

Күреп бакчада кыяр,
Кергән шунда Әхияр.
Килеп чыккан бакчачы,
Ничек кенә качасы?
Әллә ары китәргә,
Әллә бире китәргә,
Инде нихәл итәргә?
Сикереп менгән читәнгә.
Күлмәк эләгеп калган,
Бакчачы тотып алган.
Кычыткан белән чаккан,
Әхияр елап чапкан...
Инде хәзер Әхияр
Үзе үстерә кыяр.

А.б. Шагыйрьнең балалар өчен язган шигырьләре туган як, андагы вакыйгалар, күренешләр турында. Төрле образлар аша ул туган як җиренең уңдырышлылыгы, муллыгы турында сөйли.

3 нче укучы: «Нарат» шигыре

Җилләр чыкса, нараткайны
Сыгалар төрле табан.
Буйсынырга теләми ул,
Турайта башын һаман.
Ялгыз гына яшәсә дә,
Курыкмый ул җилләрдән.
Чөнки бит ул тамырларын
Җиргә тирән җибәргән.

А.б.«Синоптик» дигән шигырь балаларда яшәеш күренешләрен аңлау дәрәҗәсен арттыра, фикерләү, сиземләү сәләтен үстерүгә йогынты ясый. Кече яшьтәге дусларыбыз өчен бу бик кирәкле нәрсә.

5 нче укучы:

Булмаса да үрмәкүчнең
Сөйләргә радиосы,
Ул яшь натуралистларның
Иң ышанычлы дусты.
Ничек дус була дисезме
Үрмәкүч кеше белән? –
Һава торышын белдерә
Ул кылган эше белән.
Әгәр челтәр бәйләсә ул,
Чалт аяз була һава.
Әгәр күләгәгә качса,
Ул көнне яңгыр ява.

А.б. Әзһәр ага Габидинең балаларның зиһенен баетуга, уйлау-фикерләү сәләтен үстерүгә тәэсир итүче табышмак-шигырьләре дә күп. Укучыларыбыз аларны укып үзләренә ләззәт алалар, шәхси фикерләү куәтләрен үстерәләр.

А.б. Әйдәгез әле, зиһеннәребезне тикшереп, «Булсаң зирәк – әйт тизрәк!» дигән табышмак әйтү уенын уйнап алыйк. (Табышмаклар чишү)

А.б. Шагыйрьнең шигырьләре хезмәткә, батырлыкка, кыюлыкка чакыра, төрле профессия кешеләренә хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияли. «Бал кортлары», «Кораб», «Җайдаклар», «Җырлы урамнар», «Шофер» шигырьләре шундыйлардан.

6 нчы укучы: «Җырлы урамнар» шигыре

Баганага рәт-рәт булып
Сузылганнар чыбыклар,
Нота билгеләре сыман
Кунган аңа чыпчыклар.
Шаян җилләр ул нотаны
Гүя көйгә салганнар,
Шул җыр белән көне буе
Чыңлап тора урамнар.
Туктау белми чыңласыннар
Урамнарда шат җырлар,
Ул җырларны иҗат иткән
Тынгы белмәс монтерлар.

А.б. Ә.Габидинең шактый шигырьләре юмор белән сугарылганнар. Аларда ялкаулыктан, эш сөймәүчелектән, масаючанлыктан көлү нигез итеп алынган. Андый шигырьләр рәтенә «Булышчы», «Шук билге», «Ялкау теләге», «Юкмы сездә мондыйлар?», «Мыеклы машина», «Илдус – кунак белән дус», «Мин Марста булдым бүген», «Дәресләрдә» дигән һәм башка шигырьләрне кертергә була.

7 нче укучы: «Һавалы чеби» шигыре

Һаваланып йөргән булды
Чуар тавык чебие,
Аны тотып алып киткән
Күршебезнең песие.
Песи тырнагына эләккәч,
Үкенгәндер, бичара,
Мондый чакта ялгыз чеби
Кыла ала ни чара?
Төркемеңнән аерылу –
Һәлакәт башы икән,
Аерылганны аю түгел
Песи дә ашый икән.

А.б. Әзһәр ага Габидинең мәсәлләре дә яшь буынны тәрбияләүдә зур роль уйный.

8 нче укучы: «Черки» мәсәле

Умарта янына черки
Килгән очып,
Андагы бал кортына ул
Әйткән посып:
– Һәр икебез дә йөртәбез
Бер ат – Бөҗәк,
Шулай булгач, син дә, мин дә
Бер зат, димәк.
Шул сүзләрне әйткән дә ул
Китеп барган.
Ат белән түгел, эш белән
Тот син мәйдан.

А.б. Җыр, хезмәт – алар бертуган,

Җыр – хезмәтнең дәвамы, – ди ул бер шигырендә. Шуңа күрәдер, аның күңеленнән хисләр җыр булып та ташып чыккандыр.

А.б. Башлангыч класс укучылары башкаруында «Мыеклы малай» җыры.

А.б. Шагыйрь зурлар өчен дә тирән лирика, дөнья гаме, заман сулышы белән сугарылган эчкерсез шигырьләр иҗат итә. Аның төрле нәшриятларда басылып чыккан «Таң

догасы», «Урман читендәге имәннәр без…», «Көзге барлау», «Гомер учагы» исемле шигырь китаплары тиз арада үз укучысын таба.

А.б. Әзһәр ага Габиди үзенең иҗатында милләтебезнең үткәне һәм киләчәге, бетеп бара торган авылларның үкенечле язмышы, көннән-көн коргаксый барган табигать, сугыш чоры хатирәләре, сагындыргыч яшьлек һәм башка бик күп темаларны ачып сала. Әзһәр ага, кайсы гына темага алынмасын, фәкать үзе белгәнне һәм йөрәк аша кичергәнен яза.

А.б. Укытучылар ансамбле башкаруында «Кайтса әгәр яшь чагым» җыры яңгырый. (Рамил Курамшин көе, Әзһәр Габиди сүзләре)

А.б. Туган ягы Сарман төбәгенең кабатланмас гүзәл табигатен, аның хезмәт сөйгән халкын олылап, гашыйк булып, сагынып «Сагындым» шигырен язды.

9 нчы укучы:

Бу кадәрле сагынырмын диеп,
Уйламаган идем, Сарманым.
Күз алдыннан китми айлы кичең,
Истән чыкмый алсу таңнарың.
Күз йомдыммы – төшләремә керә
Чәчәкләре зәңгәр тавымның.
Һич яшермим сездән: туган якның
Әременә кадәр сагындым.

А.б. 8,9 нчы сыйныф укучылары башкаруында «Җәлил» җырын тыңлыйк әле. (Мәгафур Йөзлебаев көе, Әзһәр Габиди сүзләре).

1.Җырлы Сарман күкрәгендә
Калыкты яңа кала.
«Кара алтын»ы белән ул
Бөтен җирдә мактала.
Кушымта:
Эх, Җәлил каласы,
Асфальт юллар арасы.
Бертугандай яши анда
Утыз милләт баласы.
2.Кичен вышка утларыннан
Зәңгәр күге аллана.
Гүзәллеге белән Җәлил
Шат җырларда данлана.
3.Җәлил, Казан, Чаллы кебек
Булмаса да зур кала;
Анда гомер сөрүчеләр
Үзенә бәхет таба.

А.б. Әзһәр Габидинең иҗаты хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнде. Сугышчан орден-медальләре янына төрле газета-журналларның Мактау грамоталары өстәлде. 1986 нчы елда Әзһәр Габидигә «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

А.б. Әзһәр ага – ачлыкны, туклыкны, ялангачлыкны үз җилкәсендә татыган шагыйрь. «Урыны булсын табында» шигыре – моның ачык мисалы.

А.б. Әзһәр ага бөтен барлыгын, бөтен күңелен шигырьләренә салган һәм үзе дә шигырьләре кебек үк гади, моңлы, кайнар. Ул I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнде. Аңа «Халык мәгарифе отличнигы», «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр бирелә. Әзһәр ага Габиди – 1994 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

А.б. Гомере буе Сарман районы Чукмарлы авылында яшәп иҗат иткән ялкынлы әдип Әзһәр ага Габидинең безгә бай мирасы – ихлас хис белән язылган шигъри тәлгәшләре калды.

Галиләрдән генә тормый тормыш
Зурдан булмаса да кылганнар.
Әрләп түгел, тик сагынып кына

Искә алсын мине Сарманнар.

Һәркайсыбызга бик тә таныш, якын булган, үзенең фәлсәфи-лирик, нәфис тәэсирле шигырьләре белән күңелләребезне яулаган мөхтәрәм Әзһәр агабыз бу якты дөньяда юк инде. Ул 2001 елның 22 августында вафат була.Үзе булмаса да, шигырьләре яши, матурлыкка өнди, уйландыра...

Үзенең бер шигырендә мөхтәрәм шагыйрь:

Без ул кадәр
Олы шәхес түгел,
Тукайныкы кадәр эз калмас.
Ләкин Сарман үзен җырга салган.
Ихлас җанлы улын онытмас, – дип язган.

А.б. Бу шигъри юлларга өстәп: «Сине Сарман гына түгел, җөмһүриятебез, бөтен татар халкы беркайчан да онытмас», – дип кабатлыйбыз.

## «Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау» темасы буенча якташ язучыбыз Фәрит Яхин әсәрләрен файдаланып эшләнгән карточкалар

Җиһангирова Гөлшат Таһир кызы, А.Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш мәктәбе, Сарман районы

### Аңлатма язуы

Туган тел дәресләрендә мөстәкыйль рәвештә язма күнегүләр эшләү эзлекле белем алуны тормышка ашыра, укучыларның белемнәрен ныгыта, телне гамәли куллану культурасын булдыра, грамоталылыкка ирешүдә ярдәм итә. Менә шуларны күздә тотып, укучыларыбызда чыгышы белән туган төбәгебездән булган күренекле язучыларның әсәрләре белән кызыксыну уяту йөзеннән, аларның әсәрләреннән алынган текстларны файдаланып карточкалар төзелде. Бу әдәби текстлар (өзекләр) үзендә кешелеклелек сыйфатлары булдырырга ярдәм итә, халкыбызның гореф-гадәтләре белән таныштыра, матурлыкка, әдәплелеккә өнди. Әлеге карточкалар татар мәктәбендә укучы 9 нчы сыйныф укучыларының «Исем», «Алмашлык», «Фигыль», «Эндәш сүзләр» темалары буенча алган белемнәрен тикшерү максатыннан төзелде.

### I. Исем

**1. Җөмләләрне күчереп язарга. Исемнәрне табып, килешләрен билгеләргә.**

**1 нче карточка**

Ә без могҗиза көтеп кала бирдек. Шулай аптырап утырганда урам буйлап җен туен йөгертә-йөгертә җил үтеп китте. Ул тузына, кәгазь вә чүпләрне биеккә-биеккә бөтереп күтәрә, әле еландай нечкәреп югарыга ашкына, әле түбәнәеп, юанаеп китә.

**2 нче карточка**

Без бүрәнәләргә ябыштык. Җен туе безнең янга якын да килмәде, югары очка таба менеп китте. Әмма ул үзе артыннан яңгыр исе, дымлы һәм җиңел һава калдырды. Безнең сулышлар иркенәеп китте, авызлар ерылды.

**3 нче карточка**

Игеннәргә корылыктан шактый зыян килгән икән, шулай да аларга да яңгырның файдасы тиде, тәмам корып-янып бетүдән сакланып калдылар. Әмма дә бәрәңгегә шәп булды инде. Күкрәп үстеләр. Маллар да көтүдән тук кайта башладылар.

**4 нче карточка**

Могҗизаны минем күрәсем бик килә иде. Чәйдән соң ишек төбенә, болдырга чыгып утырдым. Яңгыр җиле исеп куйды. Еракта гөрелдәгән тавыш ишетелде һәм дөнья тынып калды. Минем күңелгә курку йөгерде. Өйгә кереп, урынга тәгәрәдем.

**5 нче карточка**

Ил өстенә ачлык куркынычы төшеп, көннәрнең яме бозылды, маллар да җәйләүдә кипкән үлән эзләнеп, арыкланганнан-арыклана бардылар. Корылык һәм ачлык бәласеннән

котылу мөмкин түгел кебек иде инде. Коткарса, бары тик могҗиза гына коткара ала. Ул да булса – яңгыр, атна буе явып торган яңгыр гына...

**2. Тартым белән төрләнгән һәм төрләнмәгән исемнәрне язып алырга, килешләрен билгеләргә.**

**1 нче карточка**

Басу-кырда бәрәңге вә чөгендер мәшәкатьләре бетте. Аң-белемгә тәмам сусап, дәртләнеп укуга керештек. Мәктәптә җылы һәм рәхәт. Яңа директорыбыз Нәкыйп Әмирович килүгә, барыбыз да үзгәрдек, хәтта мәктәп бинасына да ниндидер бер мәһабәт рух өстәлде. Өлкән сыйныф укучыларында җитдилек артты. Тәнәфес вакытларында тәртип, дәресләрдә таләпчәнлек үсте. Авыл мәктәпләрендә генә була торган серле, әмма шул ук вакытта табигый самимилек урнашты.

**2 нче карточка**

Бүген ял көне. Көзге пычрак эшләрдән соң һәр авыл өендә балаларга туйганчы йокларга ирек бирәләр. Иркәләнеп, киерелеп, бер күрә башлаган төшеңне кат-кат кабатлап, йомшак-җылы түшәктә сигезләр-тугызлар тулганчы рәхәтләндереп изрисең дә изрисең инде менә. Аһ, чукынчык, күрше Нәсимне әйтәм инде. Кояш тәрәзәдән күз салырга өлгермәгән, кереп тә җиткән бит. Сабакташ диген инде аны! Йокысын симертәсе урынга, тапкан уйнар вакыт, йөри кешене борчып.

**3 нче карточка**

Укытучыбыз – ягымлы һәм йомшак тавышлы Халидә апа Сөләймановна, һәммәбезгә дә яттан белгән, яки үзлегеңнән чыгарып, берәр шигырь язарга кушты. Дәфтәрләребезне ачып, эшкә керештек. Мин, тәрәзәгә карап, озак кына уйланып утырдым. Иҗади эш булганлыктан, тәрәзәгә күз салу рөхсәт ителә иде... Авылымны яратканым, аның матур бер урында, табигатьнең җәннәт почмагында урнашканлыгын уйлап, хыял диңгезенә чумдым, күңелгә талгын гына агылып шигъри юллар килә башлады.

**4 нче карточка**

Шунда ишек ачыла һәм Асия Мифтаховна артыннан ияреп имтихан комиссиясе керә. Дөнья бер мәлгә тигезләнеп калган үлчәү тәлинкәләре хәленә килә. Директорның таләпчән кырыс карашы укучыларны утыртып куя. Сынау башлана. Мин үземне тәүге имтихан бирүче бала хәлендә сизәм. Шулай да сынатасым килми. Ышанам, ышанам укучыларыма. Күз белән һәрберсен тынычландырырга тырышам.

**5 нче карточка**

Югары очтан кемнеңдер трактор үкертеп төшүе авылны тәмам уятып, хәрәкәтне башлап җибәрде. Көннең эссе булачагына чалт аяз күк, җилсезлек, кошларның инде хәзердән агач күләгәсендә мәш килүләре хәбәр вә дәлил иде. Габдулла абзый әйткән печәнлекнең кайда икәнлеген төгәл генә белмәсәм дә, калкулыктан калкулыкка күчеп сузылган юлның очына төбәлдем. Ул урманга кереп югала иде.

**3. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне табарга, язылыш үзенчәлекләрен аңлатырга.**

**1 нче карточка**

Яңа директорыбыз Нәкыйп Әмирович килүгә, барыбыз да үзгәрдек, хәтта мәктәп бинасына да ниндидер бер мәһабәт рух өстәлде. Өлкән сыйныф укучыларында җитдилек артты. Тәнәфес вакытларында тәртип, дәресләрдә таләпчәнлек үсте.

**2 нче карточка**

Бүген ял көне. Көзге пычрак эшләрдән соң һәр авыл өендә балаларга туйганчы йокларга ирек бирәләр. Иркәләнеп, киерелеп, йомшак-җылы түшәктә сигезләр-тугызлар тулганчы рәхәтләндереп изрисең дә изрисең инде менә. Аһ, чукынчык, күрше Нәсимне әйтәм инде. Кояш тәрәзәдән күз салырга өлгермәгән, кереп тә җиткән бит.

**3 нче карточка**

Укытучыбыз – ягымлы һәм йомшак тавышлы Халидә апа Сөләймановна, һәммәбезгә дә яттан белгән, яки үзлегеңнән чыгарып, берәр шигырь язарга кушты. Дәфтәрләребезне ачып, эшкә керештек. Мин, тәрәзәгә карап, озак кына уйланып утырдым. Иҗади эш булганлыктан, тәрәзәгә күз салу рөхсәт ителә иде...

**4 нче карточка**

Шунда ишек ачыла һәм Асия Мифтаховна артыннан ияреп имтихан комиссиясе керә. Сынау башлана. Мин үземне тәүге имтихан бирүче бала хәлендә сизәм. Шулай да сынатасым килми. Ышанам, ышанам укучыларыма. Күз белән һәрберсен тынычландырырга тырышам.

**5 нче карточка**

Көннең эссе булачагына чалт аяз күк, җилсезлек, кошларның инде хәзердән агач күләгәсендә мәш килүләре хәбәр вә дәлил иде. Габдулла абзый әйткән печәнлекнең кайда икәнлеген төгәл генә белмәсәм дә, калкулыктан калкулыкка күчеп сузылган юлның очына төбәлдем. Ул урманга кереп югала иде.

## II. Алмашлык

**1. Алмашлыкларны табарга, төркемчәләрен билгеләргә.**

**1 нче карточка**

Басу-кырда бәрәңге вә чөгендер мәшәкатьләре бетте. Аң-белемгә тәмам сусап, дәртләнеп укуга керештек. Мәктәптә җылы һәм рәхәт. Яңа директорыбыз Нәкыйп Әмирович килүгә, барыбыз да үзгәрдек, хәтта мәктәп бинасына да ниндидер бер мәһабәт рух өстәлде. Өлкән сыйныф укучыларында җитдилек артты. Тәнәфес вакытларында тәртип, дәресләрдә таләпчәнлек үсте. Авыл мәктәпләрендә генә була торган серле, әмма шул ук вакытта табигый самимилек урнашты.

**2 нче карточка**

Бүген ял көне. Көзге пычрак эшләрдән соң һәр авыл өендә балаларга туйганчы йокларга ирек бирәләр. Иркәләнеп, киерелеп, бер күрә башлаган төшеңне кат-кат кабатлап, йомшак-җылы түшәктә сигезләр-тугызлар тулганчы рәхәтләндереп изрисең дә изрисең инде менә. Аһ, чукынчык, күрше Нәсимне әйтәм инде. Кояш тәрәзәдән күз салырга өлгермәгән, кереп тә җиткән бит. Сабакташ диген инде аны! Йокысын симертәсе урынга, тапкан уйнар вакыт, йөри кешене борчып.

**3 нче карточка**

Укытучыбыз – ягымлы һәм йомшак тавышлы Халидә апа Сөләймановна, һәммәбезгә дә яттан белгән, яки үзлегеңнән чыгарып, берәр шигырь язарга кушты. Дәфтәрләребезне ачып, эшкә керештек. Мин, тәрәзәгә карап, озак кына уйланып утырдым. Иҗади эш булганлыктан, тәрәзәгә күз салу рөхсәт ителә иде... Авылымны яратканым, аның матур бер урында, табигатьнең җәннәт почмагында урнашканлыгын уйлап, хыял диңгезенә чумдым, күңелгә талгын гына агылып шигъри юллар килә башлады.

**4 нче карточка**

Шунда ишек ачыла һәм Асия Мифтаховна артыннан ияреп имтихан комиссиясе керә. Дөнья бер мәлгә тигезләнеп калган үлчәү тәлинкәләре хәленә килә. Директорның таләпчән кырыс карашы укучыларны утыртып куя. Сынау башлана. Мин үземне тәүге имтихан бирүче бала хәлендә сизәм. Шулай да сынатасым килми. Ышанам, ышанам укучыларыма. Күз белән һәрберсен тынычландырырга тырышам.

**5 нче карточка**

Югары очтан кемнеңдер трактор үкертеп төшүе авылны тәмам уятып, хәрәкәтне башлап җибәрде. Көннең эссе булачагына чалт аяз күк, җилсезлек, кошларның инде хәзердән агач күләгәсендә мәш килүләре хәбәр вә дәлил иде. Габдулла абзый әйткән печәнлекнең кайда икәнлеген төгәл генә белмәсәм дә, калкулыктан калкулыкка күчеп сузылган юлның очына төбәлдем. Ул урманга кереп югала иде.

## III. Фигыль

**1. Фигыльләрне табып язарга, төркемчәләрен күрсәтергә.**

**1 нче карточка**

Ә без могҗиза көтеп кала бирдек. Шулай аптырап утырганда урам буйлап җен туен йөгертә-йөгертә җил үтеп китте. Ул тузына, кәгазь вә чүпләрне биеккә-биеккә бөтереп күтәрә, әле еландай нечкәреп югарыга ашкына, әле түбәнәеп, юанаеп китә.

**2 нче карточка**

Без бүрәнәләргә ябыштык. Җен туе безнең янга якын да килмәде, югары очка таба менеп китте. Әмма ул үзе артыннан яңгыр исе, дымлы һәм җиңел һава калдырды. Безнең сулышлар иркенәеп китте, авызлар ерылды.

**3 нче карточка**

Игеннәргә корылыктан шактый зыян килгән икән, шулай да аларга да яңгырның файдасы тиде, тәмам корып-янып бетүдән сакланып калдылар. Әмма дә бәрәңгегә шәп булды инде. Күкрәп үстеләр. Маллар да көтүдән тук кайта башладылар.

**4 нче карточка**

Могҗизаны минем күрәсем бик килә иде. Чәйдән соң ишек төбенә, болдырга чыгып утырдым. Яңгыр җиле исеп куйды. Ерактан гөрелдәгән тавыш ишетелде һәм дөнья тынып калды. Минем күңелгә курку йөгерде. Өйгә кереп, урынга тәгәрәдем.

**5 нче карточка**

Ил өстенә ачлык куркынычы төшеп, көннәрнең яме бозылды, маллар да җәйләүдә кипкән үлән эзләнеп, арыкланганнан-арыклана бардылар. Корылык һәм ачлык бәласеннән котылу мөмкин түгел кебек иде инде. Коткарса, бары тик могҗиза гына коткара ала. Ул да булса – яңгыр, атна буе явып торган яңгыр гына...

**IV. Эндәш сүзләр**

**1. Эндәш сүзләр янында тыныш билгеләренең куелышын аңлатырга. Эндәш сүзләр нинди сүз төркеме белән белдерелгән?**

**1 нче карточка**

- Алмаз, болар барсы да синеке! Кармаклар алып кайтканың өчен бездән рәхмәт билгесе булсын!

**2 нче карточка**

- Ни сорыйсың син, улым? – әбием аптырап карады, аның ак йөзенә борчылу йөгерде, яшел күзләре төссезләнеп калгандай тоелды.

**3 нче карточка**

- Әбием, ә ул Зәмзәм коесы кайсы төштә? Моннан ерак түгелме? Безнең Зәмзәм коебыз бармыни?

**4 нче карточка**

- Әбкәм, әбекәем, алып бар мине урманга! Җиләк ашыйсым килә... Әби, дим, әбекәем...

**5 нче карточка**

- Улым Алмаз, дәү әниеңне тыңла! Эшләрендә булыш, көне буе уйнап кына йөрмә, – дип, әнкәй үгет-нәсыйхәтен тапшырса да, аларның машинасы юл тузанына күмелүе булды, урамга чыгып шылдым.

## Синдә – яшьлек язларым, синдә – башлап язганым

(Клара Булатова белән очрашу кичәсе)

Хәмәтҗанова Фәнүзә Сәгыйрь кызы, Сабирова Чулпан Рамил кызы, Сарман урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы

***Җиһазлау***: К.Булатова китапларыннан күргәзмә, проектор, әдипнең әсәрләренә ясалган иллюстрацияләр.

***Кичәнең максаты:*** укучыларны якташыбыз Клара Булатова иҗаты белән таныштыру, кызыксыну уяту; сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру, шигырьләрне аңларга һәм яратырга өйрәтү; әсәрләре аша укучыларда туган илгә, туган җиргә, туган авылларына карата горурлык, мәхәббәт, хөрмәт хисе тәрбияләү.

**1 нче алып баручы:**

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Китә калсак үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр елап озата.
Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Читтә йөрсәк — шуңа күрәдер,
Чишмә чыңлап, өянкеләр елап,
Таллар җырлап төшкә керәдер.

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Шушы җиргә дәшеп кайтырга,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр зурлап чакыра.

Хәерле көн, кадерле укучылар, хөрмәтле укытучылар!

**2 нче алып баручы:** Үзенең гүзәл табигате, борма-борма юллары, бөдрә таллары, зәңгәр таулары белән җырларда җырлана торган, татар дөньясына күренекле шагыйрь Нияз Акмал, Гөлшат Зәйнашева, әдәбият белгече Фәрит Яхин, Аяз Гыйләҗев, Сөббух Рафиков, Ямаш Игәнәй, Мәдинә Маликова, Дамир Гарифуллин, Хәниф Хәйруллин, Рәфкать Кәрами, Рафис Гыйззәтуллин, Вәсимә Хәйруллина кебек күренекле шагыйрь һәм әдипләрне, күп талантларны биргән төбәктән ул бүгенге кичәбезнең сәбәпчесе. Әйе, шушы яктан, шушы төбәктән ул. Бүген бездә кунакта Татарстанның атказанган укытучысы, Г.Тукай, Рафаил Төхфәтуллин, Саҗидә Сөләйманова исемендәге бүләк иясе, тынгы белмәс шагыйрәбез – Клара апа Булатова. Әйдәгез, алкышлап аны сәхнәгә чакырыйк әле.

*«Чыгарсыңмы каршы алырга?» көе астында сәхнәгә чыга.*

Клара апа, рәхим итеп, Сезнең сәхнә түреннән урын алуыгызны сорыйбыз.

**1 нче алып баручы:** *(Талгын гына татар көе уйный)* Буыннан-буынга асыл хәзинә итеп тапшырыла торган, замана җилләре дә ала алмый, гасырлар үтсә дә югалмый торган, кешелек тарихы өчен бик кадерле булган кыйммәтләр бар. Юк, болар асылташлар түгел. Бәясен бернәрсә белән дә үлчәп булмый торган, еллар үткәч тә әһәмиятен югалтмаган бу кыйммәтле хәзинәләр – китаплар. Менә бүген безнең алдыбызда – шушы рухи байлыкны безгә бүләк итүче, татар әдәбиятының йөзек кашы булган, шигърияттә якты йолдыз булып балкыган, үзенең киң кырлы иҗаты белән меңнәрчә китап сөючеләрнең күңелен яулаган, ике дистәләп шигырь китаплары чыгарган яраткан шагыйрәбез – Клара апа Булатова!

**2 нче алып баручы:** Хөрмәтле Клара апа! Сезнең бик тиздән 85 яшьлек юбилеегыз! Сезнең өчен әлеге көннәр гаять шатлыклы да һәм бераз гына, бәлки, сагышлы да. 85 яшь әле ул нибары 85 кыш, 85 көз, 85 җәй, һәм 85 яз гына. Йөзләрегездә нур уйнап торганда, Сезнең өчен ул гомерегезнең бер җәе генә. Әле аның көзе дә, кышы да, кабат язы да булыр. Шушы изге минутларда яшәү дәфтәрегезгә озын, тыныч гомер язылсын, бүгенге ихлас теләкләр барсы да кабул булсыннар. Котлау өчен сүз мәктәп директоры ... бирелә. *(Мәктәп директоры котлавы. Соңыннан җыр «Шушы яктан, шушы туфрактан без»)*

**1 нче алып баручы: Клара Гариф кызы Булатова** 1936 елның 18 мартында Татарстан АССРның Сарман районы Татар Карамалысы авылында туган. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа күрә Кларага бала чактан ук әти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күченеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә, өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, ә урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыга. Әйе, нәкъ менә безнең Сарман урта мәктәбен тәмамлаган Клара апабыз.

**2 нче алып баручы:** Шул ук елның көзеннән Клара Булатова үзе дә эшли башлый: Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч классларда балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәттәге көнкүреш комбинатында кассир, «Төзүчеләр» клубында оештыручы була. 1962-1965 елларда ул яңадан мәктәптә — Әлмәт районының Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта.

**1 нче алып баручы:** 1965-1969 елларда К. Булатова В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам иттерә. Шагыйрәнең исеме тәнкыйтьтә җылы сүз белән телгә алына башлый. 1967 елда «Язлар алда» исемле мөстәкыйль китабы — лирик шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

**2 нче алып баручы:** Университетны тәмамлаганнан соң К. Булатова Әлмәт районының Яна Кәшер урта мәктәбенә тел әдәбият укытучысы булып килә. 10 ел татар гимназиясендә укыта. 8 елдан артык Әлмәт муниципаль институтында булачак татар теле һәм әдәбияты укытучыларына әдәбият дәресләре бирә. Олуг шагыйрәбезгә хөрмәт йөзеннән, бу уку йорты тарафыннан Клара Булатова исемендәге премия булдырылды. Тәҗрибәле укытучы буларак, 1978 елда аңа РСФСР Мәгариф министрлыгы тарафыннан «Укытучы-методист» дигән

мактаулы исем бирелә. Татар җанлы, тынгы белмәс Клара апабыз 10 еллап «Нур» телерадиокомпанисендә журналист булып эшли. Ул алып барган «Җомга» тапшыруын татар яшьләре зур кызыксыну белән көтеп алалар.

*(Укучылар башкаруында татар халык биюе)*

**1 нче алып баручы:** Кеше таныла кешегә
Кирәкле эше белән.
Чын кеше илгә әҗерен
Кайтара бише белән, – дип яза авылдашыбыз Дамир абый.

Әйе, кайда гына хезмәт куймасын, Клара Булатова ата-ана һөнәренә тугры кала, гомерен укытучы эшенә багышлый, иҗатында укытучы шәхесен олылый. Укытучылык аңа кан белән бирелгән, ана сөте белән күчкән, гаилә тәрбиясе белән сеңгән.

*(«Укытучы бәхете», «Укытучы апаң йокламаган» исемле шигырьләрен уку)*

**1 нче алып баручы:** Клара Булатова иҗаты барлык яшьтәге кешеләргә: әби-бабайлар, әти-әниләр, яшьләр, үсмерләр өчен дә анлаешлы. Менә аның кечкенә балалар өчен язган «Марс китабы», «Әллә кайсын тыңласы», «Курка димәгез әле», «Камилә – тәти кыз» дигән китаплары чыкты. Бай сурәтләү чаралары аша бу китаплар балаларны яхшылыкка өнди, дөньяны ныграк танып белергә өйрәтә. Шушы китапларда басылган шигырьләрен сезгә тәкъдим итәбез.

Авылда туып үскәнгәме, аның шигырьләренең күбесе авыл табигатен, аның хезмәт сөючән халкын, шаян нәниләрне чагылдыра. Ә хәзер укучыларыбыз башкаруында К.Булатованың шигырьләрен тыңлап үтәрбез. *(К.Булатованың балалар өчен язылган шигырьләрен тыңлау)*

**2 нче алып баручы:** Лиана, әйдә, сүзне озын-озакка сузмыйча, аның үзенә бирик әле, безне кызыксындырган сорауларга җавапны шагыйрәнең үзеннән ишетик. Рәхим итегез, Клара апа! Бәлки безгә үзегезнең шигырьләрегезне укырсыз яисә әйтәсе киңәшләрегез бардыр. Рәхим итегез, Клара апа!

*(Сүз Клара апага бирелә. Клара апа сөйли, сорауларга җаваплар бирә)*

**1 нче алып баручы:** Килер еллар озын гомер бүләк итсен,
Безнең өчен бик якын һәм кадерле сез!
һәр яңа көн сезне кабат сөендерсен,
Уңышларның яңаларын алып килсен

Тиздән Клара апа үзенең олуг юбилеен каршы алачак. Без дә аңа изге теләкләр теләп, үзебезнең кечкенә истәлекле бүләгебезне тапшырабыз.

*( Бүләк тапшыру, җыр)*

**2 нче алып баручы:** Клара апа, сезгә бүләк итеп мәктәбебезнең 8 а сыйныфы укучысы үзе иҗат иткән шигырен укый.

**Могыйнова Ләйлә:**

Туры сүзле, гадел, сизгер дә сез,
Кирәк чакта усал була беләсез.
Өлкәннәрнең генә түгел, яшьләрнең дә
Күңеленә якын киләсез.
Шагыйрьләрчә сизгер, нечкә күңелле сез,
Балаларны яратучы – педагог.
Укучыларыгыз сезне хөрмәт итә
Моннан зуррак инде бәя юк.
Укытучы гаиләсеннән булгангадыр,
Акыллы Сез, сабыр холыклы.
Табып булмас, күпме эзләсәк тә
Җир йөзендә сездәй кебекне.
Безнең яктан, безнең туфрактансез,
Түбән Ләшәү, Ләке, Чыршылы...
Сармандагы һәрбер үлән, чәчәк

Онытмыйлар сездәй җырчыны.
Тормыш учагыгыз гөрләп торсын.
Кайгы-хәсрәт мәңге күрмәгез.
Иҗатыгыз сезнең, Клара апа,
Мәңге үссен, мәңге сүнмәсен!

**1 нче алып баручы:** Бик зур рәхмәт сезгә. Киләчәктә дә тормыштан ямь табып, матур әсәрләр иҗат итеп, яңалыкка, алга омтылып яшәгез. Иҗат ялкыннарыгыз сүрелмәсен. Илһамыгыз кимемәсен. Сезгә озын гомер юллары, ныклы сәламәтлек, иминлек телибез. Сезнең белән тагын очрашулар көтеп калабыз. *(Җыр)*

## Әзһәр Габиди иҗатына багышланган «Йолдыз сәгате» уены
*(4 сыйныф)*

Шаһгалиева Гөлназ Нәҗип кызы, Актүбә 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Азнакай районы

Әлеге уенга башлангыч сыйныфтан алты укучы алына. Алар үзләренә шул ук сыйныфлардан алты ярдәмче сайлый. Уен үткәреләсе залга башта тамашачылар кереп урнаша. Алып баручы «Йолдыз сәгате» уенында катнашучыларны һәм ярдәмчеләрне чакыра. Кайсы йолдызлыкта туулары, аларга хас үзенчәлекләр турында сөйли. Катнашучы укучыларның өстәлләренә 1, 2, 3, 4 саннары куела. Сорауларга икесе дә дөрес җавап бирсә, уенга катнашкан укучының өстәленә йолдыз беркетелә һәм ул өстәле белән бер адым алга күчә. Ярдәмчесенең генә җавабы дөрес булса, йолдыз да беркетелми, өстәл дә күчми. Төп уйнаучы укучы гына дөрес җавап бирсә, өстәл бер адым алга күчә, йолдыз бирелми.

**Уен барышы.**

**I тур.**

**1. Алып баручы:** Магнит тактасына еллар язылган, сез дөрес җавапны табып сайлап алырга тиеш.

2019 1943 1994 1942

**Сорау.**

1. Ә.Габиди кайчан фронтка китә? (1943)
2. Кайчан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы була? (1994)
3. «Җир кешеләр белән матур» исемле җыентыгы кайчан дөнья күрә? (2019)

**Музыкаль тәнәфес.**

**2. Алып баручы:** Дөрес җавапны сайлап алыгыз.

Кыш Яз Җәй Көз

**Сорау.** Әлеге юлларда кайсы ел фасылы турында сүз бара?

Ак юрганын җыеп алган
Болыннар һәм тугайлар.
Дәртле җырларын сузарга
Килгән җырчы тургайлар. (яз)

1. Миләш-сылуга гашыйклар –
Алтын алкалар таккан,
Аның белән серләшергә
Болынга учак яккан. (көз)

3. Карабодайлар
Ак чәчәк аткан.
Гүя басуга
Тәңкә кар яткан. (Җәй)

**Музыкаль тәнәфес.**

**3. Алып баручы:** Дөрес җавапны сайлап алыгыз.

Минзәлә Сарман Яр Чаллы Казан

**Сорау.**

1. Габиди кайда училище тәмамлый? (Минзәлә)

2. Ул туган район? (Сарман)

**Музыкаль тәнәфес.**

**4. Алып баручы:** Җавапны табыгыз.

Сорау.

Шушы бүләкләрнең кайсы Әзһәр Габидигә бирелмәгән? (Г.Тукай премиясе лауреаты)

**Музыкаль тәнәфес.**

**I тур буенча нәтиҗә.**

**II тур.**

**1. Алып баручы:** 3 минут эчендә Ә.Габиди шигырьләрендә искә алынган кошларны табып язарга.

П, Ы, Е, Р, Т, С, Ч, Н, А, Ү, О, Ә, Г, К

(песнәк, сыерчык, торналар, күке, чыпчык, карга.)

**Музыкаль тәнәфес.**

**2. Алып баручы:** Дөрес җавапны сайла.

Үсәсе килә   Бакчада   Ишек төбендә   Көтү кайтты

1. Кайсы шигырьдә хуш исле, тәмле, әни шикәр сипкән сыман баллы җир җиләге турында сүз бара? («Бакчада»)

2. Кайсы шигырьдә бала, иптәшләреннән зур булу өчен, яңгырда йөри, ипи майлап ашый, шикәрне күп салып чәй эчә? («Үсәсе килә»)

3. Кайсы шигырь Әзһәр Габидинеке түгел? («Ишек төбендә»)

**Музыкаль тәнәфес.**

**3. Алып баручы:** Шигырь юлларында нинди сурәтләү чарасы бар?


Сынландыру   Чагыштыру   Пейзаж

Кояш белән көннәр матур,
Кояш белән көн якты,
Әнине яраткан кебек
Яратам мин кояшны.  (Чагыштыру)

**Музыкаль тәнәфес.**

**III тур. Финал.**

**Кроссворд чишү.**




1)Түтәлдә яткан чагымда
Тулып торам ай кебек.
Табынга ярып куйганда,
Эчем сары бал кебек
2)Нинди рәссам буяусыз
Битләргә иннек яга?
Пыялага да каләмсез

Рәсемнәр ясый ала?

1) Күлләре бар – суы юк,
Чүлләре бар – комы юк,
Таулары бар – кар ятмый,
Аны белгән адашмый.

4)Күлмәгем алтын төсендә,
Тәнем минем бүз кебек.
Торалар минем күлмәкне
Салдырганда яшь түгеп.

5) Энәсенең күзе юк,
Тегәр өчен җебе юк.
Яшерсә башын, аягын,
Ул нәни генә бер туп.

**Алып баручы:** Ничә сүзне дөрес язган, шулкадәрле йолдыз бирелә.

**IV тур. Бирелгән хәрефләрдән сүз төзергә. Кем беренче төзи, йолдыз бирелә.**

А, Р, Т, С, Т, А, Т, Н, А

*ТАТАРСТАН* сүзендәге хәрефләрдән сүзләр төзергә. Бер минут вакыт эчендә кем күпме сүз төзи ала? Җиңүче билгеле була. Җиңүче һәм җиңелүчегә, аларның ярдәмчеләренә бүләкләр бирелә. Җиңүче укучы теләкләрен әйтә.

**Музыкаль тәнәфес.**

## Туган авылым шагыйрәсе Клара Булатова иҗаты

(Клара Булатова иҗаты буенча 1 нче һәм 2 нче сыйныфта проектлар яклау дәресе)

Әхмәдуллина Айгөл Гомәр кызы, Яңа Нәдер урта мәктәбе,
Әлмәт районы

**Максат:** үткәннәрне кабатлау,туган як шагыйрәсе Клара Булатованың балалар өчен язылган әсәрләрен искә төшерү, укучыларны якташ язучыларның туган як белән бәйләнешле иҗатлары белән таныштыру, шигырьләрен уку; якташ язучы Клара Булатова иҗатына багышланган проектлар аша укучыларда логик фикерләүне үстерү, алган белемнәрен гамәлдә файдалану, үзеңне төрле эштә сынап карау һәм бәйләнешле сөйләм эшен дәвам итү; туган төбәк, аның әдәбиятына, халкына мәхәббәт, соклану һәм горурлык хисе тәрбияләү.

Җиһазлау: ноутбук, мультимедиапроектор, магнитофон, Клара Булатовага багышланган презентация, «Солдатлар», «Шушы яктан, шушы туфрактан без», «Кыңгыраулар», «Якын дустың барын онытма» җырларының аудиоязмасы, автор китаплары күрәзмәсе, «Көмеш кыңгырау» газетасы, 3 февраль, 2018 ел.

**Дәрес төре**: бәйләнешле сөйләм үстерү, проектлар яклау дәресе.

**Дәрес алымнары**: укытучы сүзе, өстәмә материаллар кулланып, фикер алышу, сорау-җавап, укучылар чыгышы.

**Яңа педагогик технологияләр**: үстерешле укыту һәм укытуда проектлар куллану.

**Предметара бәйләнеш**: сынлы сәнгать, музыка.

### Дәрес барышы.

**I Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

**1 укытучы**: Туган як ул – туган йортыбыз, туган авылыбыз. Ватаныбыз... Ул гомер-гомергә кешеләр өчен илһам чыганагы, яшәүгә көч һәм дәрт бирүче, күңел терәге булды. Безнең Әлмәт районының бай һәм гүзәл табигате үз халкы күңеленә затлы орлыклар, илаһи рухи байлык сала. Шуңа да районда андый затлар, күренекле шәхесләр күп. Шулар арасыннан – якташ язучыларыбыз.


Без Татарстанның нефтьчеләр башкаласы Әлмәт районында яшәвебез белән горурланабыз. Чөнки безнең яктан иң күренекле шагыйрьләр, композиторлар, галимнәр чыккан

**II.Уку максатын чишү.**

**2 укытучы**: Хәзер мин сезгә үзебезнең авылыбызга багышланган шигырьне укып китәм. Ул кайсы әдипнеке икән? Һәм ни өчен бу әдип аны безнең авылга багышлап язды икән?
Нәдер авылы егетләре җыры
Сәвәләй тау итәгендә
Кистем талның яшелен,
Исләремдә, төшләремдә
Шунда үткән яшьлегем.
Сәвәләй тау итәгендә
Гөлләр үсә язларда,
Туган яклар, классташлар
Күңелемдә һаман да.
Сәвәләй тау итәгендә
Гөлләр үсә хәзер дә,
Бер күрешик әле, дуслар,
Кайтыйк әле Нәдергә, –
ди ул үз шигырендә. Менә шушы шигырьдә Нәдер авылы искә алына. Каян белде икән бу язучы безнең авылыбыз турында, анда Сәвәләй тавы барлыгын каян белгән? Авылдагы тауларның, елгаларның исемнәрен шул авылда яшәүчеләр генә белә бит, югыйсә. Димәк, бу шигырь юлларын иҗат итүче кеше безнең авылыбызда яши булып чыга түгелме соң? Кем икән соң ул балалар? Әйе, ул безнең авылыбызның гына түгел, хәтта Әлмәтнең генә дә түгел, ә бөтен Татарстанның танылган шагыйрәсе – Клара апа Булатова. Ул бүген бездә куната. Балалар, димәк, без бүген дәрестә нинди темага сөйләшәчәкбез?
Укучылар: Бүгенге дәресебезнең максаты – авылыбызның йөзек кашы булган шагыйрәбез иҗатын өйрәнүне дәвам итү.
 - Әйе, бүген без сезнең белән аның иҗатын кызыксынып өйрәнүне дәвам итәрбез.
**Укытучы**: - Укучылар, инде без дәресебезнең төп өлешенә күчәбез. «Әгәр дә язучыны аңларга теләсәң, аның туган ягында бул», – ди Гете. Дөрестән дә, әгәр дә язучының язган әсәрен аңларга теләсәң, беренче чиратта, аның туып-үскән төбәге, табигате һәм тормыш юлы белән танышырга кирәк. Чөнки барлык язучыларның да иҗаты туган яклары, көнкүреше белән бәйле. Менә без, 1 һәм 2 нче сыйныф укучылары, туган авылыбызда яшәп иҗат итүче шагыйрәбезнең иҗатын өйрәнүне аның балаларга багышлап язылган шигырьләреннән башлап киттек. Алда әйтелгәнчә, язучы иҗаты аның торган җире, көнкүреше белән бәйле, дидек. Укылган, тикшерелгән әсәрләребез берсе дә әллә каян алып язылмаган, ә Клара апаның бердәнбер улы Марс турында язылган булып чыкты. Тулы бер җыентык балачак хатирәләрен туплаган. Без бергәләшеп кызыксынып укыдык. Һәм шушы эшебезне, үзебезнең аңлаганлыгыбызны, кызыксынганлыгыбызны күрсәтү өчен проект эше итеп тә башкардык. Хәзер укучылар сезгә шушы эшләрен тәкъдим итәрләр. Рәхим итегез, укучылар.
**II. Уку максатын ныгыту.**
**I төркем чыгышы.** Авылыбызда шундый тарихи шәхес, танылган кеше яшәгәнен белгәч, якташ шагыйрәбез Клара Булатова турында сыйныф сәгатендә ишеткәч, аның шигырьләре белән тагын да танышасыбыз килде. Өлкәннәр өчен булган шигырьләрен уку әле безнең өчен бераз авыррак булгач, без аның балалар өчен язылган шигырьләре юкмы икән дип сорадык укытучыбыздан. Ул безгә Клара апаның «Әллә кайсын тыңлыйсы» дигән 1996 елда ук басылган иске генә китабын табып бирде. Менә без шуннан соң уйлаштык та бу китапны яңартырга булдык. Үзебезнең алдыбызга шигырьләрне уку, аларга иллюстрацияләр ясау һәм шушы шигырьләрне ятлау максатын куйдык.


Укучылар чыгышы. Һәрбер укучы ясаган китап бите экранда күрсәтелеп барыла.






















«Солдатлар» шигыренә иҗат ителгән җырны малайлар җырлый.

**Укытучы:** Менә укучылар, тыңлап киттек, Клара апаның шигырьләре әле җырлар булып та яңгырый икән. Әйе, аның моңга бай, көйләп язылган шигырьләренә бик күп композиторлар кызыга шул, чыннан да. Көйгә салынган шигырьләре дә бик күп аның. Әйдәгез, хәзер берничәсен тыңлап та китик әле.

«Шушы яктан, шушы туфрактан без», «Кыңгыраулар», «Якын дустың барын онытма» җырларының берәр куплеты яңгырый.

**<u>Физминутка.</u> Укытучы**: Инде утырып ардык, бераз ял итеп алыйк әле. Бу физминутканың сүзләрен дә мин Клара ападан отып алган идем, чөнки моннан 20 еллар элек аның укучысы булдым мин. Әйдәгез, бергәләп шул күнегүләрне эшләп алыйк әле.

Кабатлыйбыз: Менә минем уң кулым
Менә минем сул кулым,
Менә минем уң аягым,
Менә минем сул аягым,
Менә идән, менә түшәм,

Менә шулай зур үсәм.

**II төркем чыгышы.** Без, 2 сыйныф укучылары, шулай ук Клара апа Булатова иҗатын тирәнтен өйрәнү максатыннан, үзебезнең проект эшен башкардык. Без аның балалар өчен булган әсәрләрен укып, иллюстрацияләр ясадык һәм бу эшләребезне зур газета итеп бергә җыйдык. Безнең бу эшебез башка кешеләргә дә җиңел һәм тиз арада шагыйрәнең балалар турындагы шигырьләре белән танышып чыгарга мөмкинлек бирә. (Балалар газетаны ике почмагыннан тоталар, һәрберсе үзе ясаган һәм ятлаган шигырен сөйли)

Мәрьям: Ә мин тагын бер яңалыкка тап булдым бит әле. Клара апабызның оныгы да шигырьләр яза икән бит. Мин Гайшә Булатованың кечкенә генә матур китабыннан шигырь өйрәндем.

**III төркем чыгышы. Укытучы:** Бу төркем укучылары үзләренең исемнәрен «Шагыйрьгә ияреп...» дип атадылар. Чөнки бу төркем укучылары үзләре шигырь язганнар. Алар инде бу шигырьләрен туплап, газетага да җибәргәннәр. «Көмеш кыңгырау» газетасының быелгы 3 февраль санында шигырьләре басылып та чыкты. Хәзер сүзне аларга бирәбез.

**IV Рефлексия.**

**Укытучы**: Укучылар, барыгызга да рәхмәт. Без бик шатбыз, чөнки сез якташ шагыйрәбез иҗаты турында шактый гына мәгълүматлар туплагансыз. Йомгаклап шуны әйтәсем килә: сез укыган балалар шигырьләре ул әле айсбергның башы гына. Чөнки менә бу күргәзмәгә игътибар итсәгез, күрә аласыз –Клара апабызның никадәр хезмәте әле безнең тарафтан тотынылмаган да... Безнең тарафтан әле тотынылмаса да (чөнки без әле кечкенә), Клара апабызның хезмәте дәүләтебез тарафыннан югары бәяләнде. Аңа 2016 елда ук инде Г.Тукай премиясе бирелде. Ә без үсәбез, ныгыйбыз, күп нәрсәләрне аңлый башлыйбыз. Шулай булгач, алга таба да без аның иҗаты белән танышуны дәвам итәрбезме? Аның соклангыч иҗатына, туган ягыбыз табигатенә карата янәдән горурлану, соклану хисе тудыра торга әсәрләрен өйрәнүне киләчәккә максат итеп куябызмы? Сез дәрестән нинди тәэсирләр алдыгыз? Үзегездә дә шигырьләр иҗат итү теләге тумадымы?

**Укытучы**: Клара апабыз шагыйрә генә түгел, ул әле бик яхшы укытучы да. Ул озак еллар буе әдәбият фәнен укытты. Туган тел, татар мәдәнияты, татар әдәбияты дип янып йөргән шәхесләребезнең берсе ул – Клара апабыз. Шуңа күрә дә, әйдәгез, дәресебезне татар халкының гимнына әверелгән «Туган тел» шигыре белән тәмамлыйк әле. Бу аның укытучылык хезмәтенә мәдхия булып яңгырасын.

«Туган тел» шигыре яңгырый.

**Бергә-бергә күңелле**

(мәктәпкәчә әзерлек төркемендә балаларының сөйләм телен үстерү буенча ачык интеграль шөгыль конспекты)

Нуриева Миләүшә Вәгыйз кызы,
Җәлил бистәсенең 5 нче балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

Максат: балаларның сөйләм телләрен баету: чыршы, урман, уенчык, җырлар, бәйрәм итә, кунак һ.б. Аларны башка сүзләр белән куллануны ныгыту: зур, матур, яшел, күп һ.б.; кошлар турында төшенчәләр бирү, аларга кыш көне авыр икәнен аңлату; бәйләнешле сөйләмне үстерү һәм матур әдәбияткә мәхәббәт үстерү; кошларга сак караш тәрбияләү.

**Җиһазлар:** чыршы, бизәлгән чыршы, уенчыклар, кош рәсемнәре, җимлекләр, Ә.Габиди портреты.

**Шөгыль барышы**

**Тәрбияче.** Исәнмесез, балалар. Минем бүген дәресебезне бер матур рәсем күрсәтеп башлыйсым килә. (Урман аланында үскән чыршы агачы күрсәтелә). Рәсемдә ни күрүегезне әйтегез әле.

Балалар рәсем буенча җөмләләр төзеп әйтәләр.

**Тәрбияче**. Булдырдыгыз, балалар. Хәзер тагын бер рәсемне карагыз әле. (Зал уртасындагы бизәлгән чыршы рәсеме күрсәтелә). Бу рәсем турында нәрсә әйтерсез микән?

Балалар рәсем буенча җөмләләр төзеп әйтәләр.

**Тәрбияче.** Балалар, ә мондый чыршы булган бәйрәм кайчан була?

**Балалар.** Кыш көне була.

**Тәрбияче.** Нинди бәйрәм соң ул?

**Балалар.** Яңа ел.

**Тәрбияче.** Дөрес, балалар. Әйдәгез хәзер шул матур бәйрәмне искә төшереп, уен уйнап алабыз. (Бәйрәмгә әзерләнгән уенны уйнарга, җырны кабатларга мөмкин).

**Тәрбияче.** Безнең кайсы чыршыбызга рәхәтрәк микән, балалар? Ник алай уйлыйсыз?

(Балалар үз фикерләрен белдерәләр).

**Тәрбияче.** Мин дә урмандагы чыршыга рәхәтрәк дип уйлыйм. Ул үсә, матурая. Ә бүлмәдәгесен без бәйрәмнән соң чүплеккә ташлыйбыз шул, балалар. Шуңа күрә хәзер күпләр ясалма чыршылар куялар, я урмандагы агачларны кисмичә, питомникта үскәнен сатып алалар.

Уенчыклы чыршы ошадымы соң сезгә? Әйдәгез хәзер без бу чыршыны да бизәп куябыз. Моның өчен безгә төрле уенчыкларны кисәргә һәм чыршыга ябыштырырга кирәк. Сезнең алдыгызда уенчыклар. Кисәбез дә чыршы ботагына эләбез. (Үрнәкне кисәләр, клей белән чыршы рәсеменә алып килеп ябыштыралар).

**Тәрбияче.** Менә ничек матурланды безнең чыршыбыз. Әйдәгез бергәләп чыршы турындагы җырны җырлап алабыз. (Җыр җырлана).

**Тәрбияче.** Минем сезгә тагын бер күчтәнәчем бар. Сез тыңларга әзерме? Мин сезгә шигырь укыйм.

**Чыршы**

Яңа елны бакчабызга
Чыршы куеп көтәм мин.
Чөнки аны кошлар белән
Бергә бәйрәм итәм мин.

Уенчык та юк чыршымда,
Йолдыз да тормый көлеп.
Уйнап йөрми балалар да,
Аның янына килеп.

Ләкин, дускайлар, ул чыршы
Һич гади чыршы түгел,
Күгәрчен, песнәк, чыпчыклар
Ачалар анда күңел.

Нигә дисәгез, чыршыга
Ашханә куям элеп.
Мин салган җимнәрне алар
Ашыйлар шуннан килеп.

Әзһәр Габиди

**Тәрбияче.** Балалар, шигырьне аңладыгызмы? Менә аның эчтәлеген шушы рәсем белән бәйләп аңлатып карыйк әле. (Кластер алымы)

1. Шигырь нәрсә турында? (Чыршы рәсеме күрсәтелә)
2. Аны малай кайда куя? (Бакча рәсеме күрсәтелә һәм алар тактага урнаштырыла).
3. Чыршыда уенчыклар бармы? (Бизәлгән чыршы күрсәтелә).
4. Малай кемнәрне чакырган бәйрәмгә? (Кош рәсемнәре күрсәтелә).
5. Сез бу кошларны беләсезме? (Чыпчык, песнәк, күгәрчен рәсемнәре күрсәтелә)
6. Малай аларны ничек кунак итә? (Җимлек рәсеме күрсәтелә)
7. Балалар, малай дөрес эшлиме? Ни өчен кошларга кыш көне ярдәм итәргә кирәк?

**Тәрбияче.** Бу шигырьне безнең якташыбыз Әзһәр Габиди язган. (Рәсеме күрсәтелә). Балалар, ул безгә ни әйтергә теләде икән?

**Тәрбияче.** Менә хәзер булачак хезмәт шөгыленда без дә шигырьдәге малай кебек кошларга ярдәм итәрбез. Ә хәзергә ял итәбез. Шөгылебез тәмам.

## Бәхет кенә телик кешегә

(Ә.Габиди иҗаты буенча китапханә дәресе)

Харисова Илзирә Алмас кызы, Зиннәт Хәсәнов исемендәге Иске Кәшер мәктәбе,
Сарман районы

Максат: Укучыларда якташ язучылар иҗатына кызыксыну уяту, хөрмәт, ихтирам тәрбияләү. Сугышка каршы нәфрәт хисе уяту. Батырлык турында уйландыру, батырлыкка өндәү.

Китапханәдә китап күргәзмәсе оештырыла, әдипнең рәсеме урнаштырыла. Алдан укучыларгга шигырь ятлау, чыгыш ясау биреме бирелә, һәр партага Татарстан картасы таратыла, «Әзһәр Габиди – якташ шагыйребез» презентациясе, сугыш чорын күрсәткән рәсемнәр, фронтовик әдипләрнең портретлары әзерләнә..

**Дәрес барышы.**

1 укучы Ә.Габидинең «Бәхет кенә телик кешегә» шигырен укый.

Сугыш сүзе бомбалардан авыр,
Елан утларыдай зәһәрле;
Үзе түгел, хәтта төшенчәсе
Үзенә җыйган күпме каһәрне.
Бернәрсәне аяп тормый сугыш,
Нәрсә булса, шуны җимерә,
Кеше иҗат иткән гүзәллекне
Әйләндергә кара күмергә.
Җирне балкытучы гөлләрне дә
Зәһәр ялкынында яндыра.
Янсалар да гөлләр исәннәргә
Хуш исләрен сибеп калдыра.
Җир безгә, гөлләр дусты – кеше,
Нәфрәтен төяп сугышка,
Сүндерергә ачы ялкыннарны
Атылып килеп керә сугышка.
Сүнә ялкын,
Ләкин күп гомерләр
Коелып кала шул ут эчендә;
Чәчәк бирик,
Бәхет кенә телик
Яшәгәндә җирдә кешегә.

**Укытучы.** Укучылар, бу шигырьнең авторы – Сарман районында яшәп, иҗат иткән шагыйрь Әзһәр Габиди. Әйдәгез хәзер аның турында мәгълүмат белән танышыйк.

(Презентация аша Ә.Габидинең биографиясе белән таныштыру).

**Практик бирем.** Инде, укучылар, Татарстан Республикасы картасыннан ул туып-үскән, хезмәт куйган Чукмарлы авылын эзләп табыйк. (Карта белән эшләү)

Алдан әзерләнеп килгән укучының Чукмарлы авылы, аның мәктәбе турындагы чыгышын тыңлау.

**Укытучы.** Әзһәр Габиди – фронтовик шагыйрь. Фронтовик әдипләрдән кемнәрне беләсез? Искә төшерәбез. (Презентациядә М.Җәлил, А.Алиш, Ф.Кәрим, Г.Кутуй рәсемнәре күрсәтелә) Сугышны үз күзләре белән күргән әдип үзе кичергән хәлләр турында тетрәнеп яза, укучылар.

1 укучы Әзһәр Габидинең «Ветераннар» шигырен укый.

Кояш баткан, Җиргә эңгер яткан,
Аксакаллар капка төбендә
Бүрәнәгә тезелеп утырган да
Сөйләшәләр дуслык телендә.
Берсе сөйли колхоз төзегәнен,
Икенчесе яуда күргәнен,
Өченчесе укчы батальоны
Атакага алып кергәнен.
Дүртенчесе авыр яраланып
Фашистларга әсир калганын,

Бу тәмугтан көч-хәл белән генә
Ничек итеп чыгып тайганын.
Мең куркынып, мең могҗиза белән
Отрядны эзләп тапканын,
Дүрт ел буе партизаннар белән
Җиңү учаклары якканын.
Тоташ үлем, тоташ ачлык аша
Үткән алар авыр сугышны,
Пуляларга күкрәкләрен куеп
Саклаганнар җирдә тормышны.
Илгә җиңеп кайтсалар да, алар
Тыныч йокы бик тиз күрмәгән,
Сугыш җимергәнне ямый-ямый,
Күпме көн-төннәрен үткәргән.

Сугыш чоры тасвирланган рәсемнәр күрсәтелә.

**Укытучы.** Укучылар, безгә менә бу рәсемнәр аша халкыбызның тарихын барларга кирәк. Нинди данлы сәхифәләре тасвирланган бу рәсемнәрдә? (Мәскәү янындагы сугыш, Ленинград блокадасы, Сталинград сугышы, Берлинны алу)

Бүгенге көн рәсемнәре күрсәтелә.

**Укытучы.** Бүген дә дөнья тыныч түгел. Әле монда, әле тегендә сугыш уты кабынып тора.
1 укучы Ә.Габидинең «Сугыш тынмаган» шигырен укый.

Сугыш инде күптән-күптән тынды,
Таңнарыбыз туа тынычта,
Җанны кыйнар өчен тетрәндереп
Баш очында тормый кылычта.
Дары исе түгел, иген исе
Алып килә искән җилләр дә,
Танк изгән болын, тугайлар да
Төренделәр күптән гөлләргә.
Окопларда түгел, җылы өйдә
Тыныч кына гомер итәбез,
Илдә муллык һәм иминлек өчен
Багышлана һәрбер иртәбез.
Сугыш дигән канлы афәт белән
Ераклашсалар дааралар,
Безнең өчен сугыш тынмаган ул –
Сызлый әле һаман яралар.
Ә сез – грузин, әрмән, таҗик дуслар,
Нигә сугышасыз һаман да?
Яшик әле, яшик бертугандай
Атыш, талашларсыз заманда!

Укытучы. Халык үзенең геройларын онытмый, укучылар. Безнең мәктәп Зиннәт Хәсәнов исемен йөртә. Аның турында без күп сөйләшәбез. Мәктәп янында аның һәйкәле бар. Җиңү безгә әнә шундый каһарманнарыбызның фидакарьлеге аша килде. Безнең аларны онытырга хакыбыз юк.

Кылган эше белән үлемсезлек
Яулап ала батыр кешеләр,
Гасырлардан гасырларга күчеп,
Күңелләрдә үлми яшиләр.
Батырларның үлгән көне булмый,
Була бары туган көннәре.
Көчле ташкыннар да юа алмыйлар
Алар басып үткән эзләрне.

Каберләре дә бит җиргә түгел,
Йөрәк түрләренә уелган,
Һәйкәлләре дә бит таштан түгел,
Күңел җылысыннан куелган.
Пуля тиеп үлми геройлар,
Мәңге тере, мәңге сау алар.

**Рефлексия.** Укытучы. Укучылар, бүгенге дәресебезне йомгаклыйбыз. Сарман районы язучыларга бай булуын беләсез.

1.Бүген кем иҗаты турында сөйләштек?
2.Ни өчен сугыш темасы турында сүз барды?
3.Сугыш чоры белән бәйле батыр якташыбыз кем?
4.Ни өчен боларны истә тотарга кирәк?
5.Бурыч сүзен ничек аңлыйсыз?

Безнең бурыч, балалар, сугышларны булдырмау, ә булган сугышларның каһарманнарын хөрмәтләп искә алу. Дәресебез тәмам. Сау булыгыз.

## Минем бакчам – шигъри түтәлләр

(сыйныфтан тыш эшчәнлек кысаларында шагыйрә Клара Булатова белән очрашу кичәсе)

Н.З. Кашипова, Р.М.Махиянова, Әлмәт шәһәре 17 нче автономияле урта гомуми белем бирү мәктәбе

Кичә узачак зал Клара Булатованың китапларыннан күргәзмә, иҗатына багышланган стена газеталары, шигырь һәм әсәрләренә нигезләнеп ясалган рәсемнәр белән бизәлә.

Магнитофон язмасында азан тавышы яңгырый. 11нче сыйныф укучылары башкаруында сәхнәләштерелгән, балага исем кушу йоласы күрсәтелә.

Сәхнәләштерелгән күренеш тәмамлануга, Фәридә-Алсу дуэтының «Әнкәем теләкләре» җыры яңгырый. Музыка астында алып баручы укытучы чыга. Ул Клара Булатованың «Өйдә туды кыз бала» шигырен укый.

Алып баручы: Әйе, нәкъ моннан 85 ел элек, шигырьдәгечә, дөньяга нур, гаиләгә бәхет-куанычлар өстәп, чегән кызларыдай кап-кара чәчле, якты чырайлы, кочакка сыеп бетәрлек кечкенә генә кыз бала дөньяга килә. Әти-әнисе бик яратып, киләчәгенә зур өметләр баглап, нәни кызчыкка Клара дип исем бирәләр. Ләкин кызның әти-әнисе дә, исем кушкан хәзрәт тә, туган-тумачалар да, еллар үтеп, бу баланың үз авылында гына түгел, нефтьчеләр башкаласы Әлмәт шәһәрендә, хәтта бөтен татар дөньясында танылган шагыйрә булып китәчәген күз алдына да китерә алмыйлар.

Укучылар, бүген сезнең арада кунакта яраткан шагыйрәбез, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Рафаил Төхфәтуллин, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләкләре иясе, олы йөрәкле мөгаллимә – Клара апа Булатова!

Хөрмәтле, Клара Гарифовна! Без сезнең иҗатыгыз, шигырь тәлгәшләрегез, үгет-нәсихәтләрегез белән һәрдаим танышып торабыз. Ләкин сезнең үзегезне күреп, сөйләшеп, киңәш һәм теләкләрегезне тыңлыйсыбыз килде. Рәхәтләнеп, үз кешеләрчә гәпләшеп утыруга сез дә каршы түгелдер дип уйлыйбыз. Ә сезнең белән сөйләшүгә укучылар менә болайрак әзерләнделәр.

**Бер укучы «Сабый чагым» шигырен укый.**

(Ф. Вәлиәхмәтов башкаруында «Мәшәкать» җырының 1 куплеты яңгырый).

**Икенче укучы «Булмый алмашып» шигырен укый.**

Алып баручы: Клара апа! Әти-әни – һәммәбезнең күңелендә иң якты кояш, тормышта иң ышанычлы терәк. Алдагы сораулар да әти-әниләргә кагылышлы сораулар.

(Укучылар әти-әни, кечкенә вакытлары турында сорау бирәләр).

Укытучылар һәм укучылар башкаруында «Хәтерлим мин әле бүгенгедәй» җыры яңгырый.

**Укучылар «Үсмер чагым», «Яшьлек чагым», «Шәкертләремә» шигырьләрен укыйлар.**

3 сыйныф укучылары башкаруында «Өйрәтәләр мәктәпләрдә» җыры яңгырый.

**Укучылар «Әби сүзе», «Өйрәтегез яратырга» шигырьләрен укыйлар.**

Алып баручы: Клара апа, барыбыз да белгәнебезчә, сез шагыйрә генә түгел, олы җанлы мөгаллимә дә. Бүген укылган шигырьләребез сезгә бүләк булып барып ирешсен, балалардан яуган сорауларның чыңы колакларыгызда озак вакытлар яңгырап торсын. Укучыларның сезгә сораулары бар.

(Укучылар мәктәп еллары, укытучы һөнәре, студент вакытлары турында сораулар бирәләр).

В. Исламова башкаруында «Яшьлекне сагыну» җыры яңгырый.

**Укучылар «Юләр яшьлек», «Ни булды сиңа авыл?» шигырьләрен укый.**

Алып баручы: Әйе, сез яшь чактагы матур гореф-гадәт, йола һәм бәйрәмнәрнең юкка чыгуына борчыласыз, йөрәгегез ачынып тибә. Әйдәгез, йөрәк ярсуларын бастырып, яшьлеккә кайтып килик әле.

(Кызлар һәм егетләр башкаруында «Кичке уен» күренеше тасвирлана. Бию көйләре һәм «Кырга чыктым, юлга чыктым» җыры кулланыла).

Л. Хәмитова башкаруында «Күз тимәсен балама» җыры яңгырый.

**Бер укучы: «Әлли-бәлли бәүкәем!» шигырен укый.**

Алып баручы: Клара апа, Ходай Тәгалә сезгә күпме сөенеч, шатлык бүләк иткән. Сез – танылган шагыйрә, атаклы мөгаллимә, Нәфис абыйның кадерле кешесе. Иң мөһиме сез – Ана. Шагыйрь Һади Такташ сүзләре белән мөрәҗәгать итәбез: Аналар бәхете нәрсәдә?

(Клара Булатова сорауга җавап бирә).

В. Исламова башкаруында «Татлы инеш» җыры яңгырый.

Алып баручы: Клара апа! «Татлы инеш гел элекке кебек, элеккечә түгел без генә» дияргә ашыккансыз түгелме? Чөнки сез һаман хәрәкәттә. Янып иҗат итәсез, дәүләтебездә барган кимчелекләрне күреп борчыласыз, дәрт-дәрманыгыз, күз тимәсен, ташып тора. Менә шундый Ак килен, Ак әби булганыгыз өчен хөрмәтлибез без сезне. Бүгенге очрашудан да ак хисләр белән китсен дип, бүләккә сезгә ап-ак шәл әзерләдек. Ак шәлегез иңнәрегезне бизәп, 17 нче мәктәптәге очрашу турында һәрвакыт исегезгә төшереп торсын.

Клара Булатованың иңенә ак шәл салалар.

(Язмада «Шушы яктан, шушы туфрактан без» җыры ишетелә. Алып баручы шигырьне укый).

**Бер укучы «Ләкеләрдә чакта» шигырен укый.**

Алып баручы: Клара апа, туган җир, туган туфрак, туган авыл – һәр кеше йөрәге өчен изге сүзләр. Һәркемгә үз туган җире гүзәлрәк тә, кунакчылрак та тоела. Әмма сездә ул алай түгел. Сезнең өчен Колшәрип тә, Нәдере һәм Ләкесе дә, Әлмәте дә бердәй якын. Моның сере нәрсәдә, ничек итеп сез аяк баскан һәр төбәк сезне үз баласыдай кабул итә?

(Клара Булатова укучыларның сорауларына җавап бирә).

Язмада «Ирекле» җыры яңгырый).

**Укучылар «Районга 75 яшь», «Һай, авыр! Авыр, авырта!» шигырьләрен укыйлар.**

Алып баручы: Клара апа! Үз сүзен курыкмыйча турыдан ярып әйтә торган чичән шагыйрә буларак, бүгенге көндә татар телен өйрәнергә теләмәгән укучыларыбызга, телебезне, гореф-гадәтләрне юкка чыгаруга юл куйган әти-әниләрбезгә, әби-бабаларыбызга, хөкүмәт җитәкчеләренә нинди сүзләр, нинди киңәшләр әйтер идегез? (К.Булатованың җаваплары тыңланыла).

Клара апа, укучыларыбыз арасында үзләре дә шигырьләр иҗат итеп, алар белән төрле конкурсларда катнашып, дәрәҗәле урын алган укучыларыбыз бар. Шулар арасыннан Н. Кашиповның сезнең иҗатыгызны данлап язылган бер-ике шигырен ишеттерәсебез килә.

**Укучылар Н.Кашиповның «Булатова бары бер генә», «Милләтемнең гүзәл Ханбикәсе» шигырьләрен укыйлар.**

Алып баручы: Менә шушындый югары нотада укучылар сезнең белән очрашуга багышлап әзерләгән чыгышларын тәмамлыйлар. Очрашуга килүегез, сорауларыбызга җавап бирүегез, үгет-нәсихәт һәм шигырьләрегез өчен зур рәхмәтебезне белдерәбез. Очрашу соңгысы булмас дип ышанып каласыбыз килә. Ходай сезгә ныклы исәнлек, күңел тынычлыгы насыйп итсен, иҗат чишмәләрегез саекмасын, картлыгыгыз сөенечтә узсын дигән теләктә калабыз.

Очрашу Клара Булатованың аерым чыгышы белән тәмамлана.

**Клара Булатова иҗатына багышланган «Тамчы шоу» уены**

Солтанова Айсылу Мансур кызы, Яңа Чечкаб урта мәктәбе укытучысы, Балтач районы

Максат: татар шагыйрәсе Клара Булатованың тормышы һәм иҗаты белән таныштыру, шагыйрә иҗаты үрнәкләре ярдәмендә балаларда Ватанга мәхәббәт һәм милли үзаң тәрбияләү.

*Залда К.Булатов сүзләренә иҗат ителгән «Шуны яктан, шушы туфрактан без» җыры яңгырый. Бүлмәдә шагыйрәнең китапларыннан күргәзмә оештырылган. Уенчылар үз урыннарын алалар.*

**АБ**. Хәерле көн, исәнмесез укучылар!

Кыш үтеп, яз җиткәч, ягъни 18 март көнне халкыбызның танылган шагыйрәсе Клара Гариф кызы Булатованың туган көне. Ә быел Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы, күп кенә җырлар авторы, шагыйрә Клара Булатованың 85 еллык юбилеен билгеләп үтәбез. Бүген без сезнең белән аның тормыш һәм иҗат юлы буенча сәяхәт итәрбез. Юбиляр шагыйрә Клара Булатова иҗатына багышланган «Тамчы – шоу» уены үткәрербез.

Уенда ике команда катнаша. Беренче команда – «Кыю малайлар», ә икенче команданың исеме «Тапкыр кызлар». Ике команда арасыннан иң тапкырларын, зирәкләрен, булганнарын сайлап алырбыз. Аларның чыгышларын жюри бәяләп барыр. «Тамчы-шоу» түбәндәге турлардан тора.

1.«Батыр берне егар, белемле меңне егар» дип атала. К.Булатова тормыш юлы һәм иҗаты буенча сорауларга җаваплар бирү.

2. Яшь рәссамчылар.

3.Капитаннар бәйгесе.

4. Өй эше.

5. «Куып җит» туры – кем күбрәк сүз төзи?

Әйдәгез, командалар белән якыннанрак танышыйк. Сезнең алда 6 нчы сыйныфның «Кыю малайлар» һәм «Тапкыр кызлар» командалары.

Әйдәгез, үзләренә сүз бирик. *(Укучылар үзләре белән таныштыралар.)*

***1 нче команда.*** Безнең исем**: «Кыю малайлар»**

Безнең девиз: «Бердәмлектә бит көч, кыю малайлар җиңелмәсләр һич»

Әби-бабай гадәтләре белән
Хәерле дип башлыйк эшләрне.
Хәерле иртә, хәерле көн телик,
Хәерле дип башлыйк бәйгене.
*(һәрберсе исемнәрен әйтә)*
Жюрига сезгә телибез
Гадел хөкем итәргә.
Катнашкан команданың
Кәефен төшермәскә.

***2 нче команда.*** Безнең исем: **«Тапкыр кызлар»**

Безнең девиз: «Тапкырлар җиңәр отырмас, сезгә куып тотырмас».

Бүген бәйге менә без дә –
Килдек көч сынашырга.
Кызармас өчен йөзебез,
Кирәк бик тырышырга.
*(һәрберсе исемнәрен әйтә)*
Хөрмәтле жюриебызга,
Бар бездән теләк.
Очколарны бутамагыз,
Тапкырлык белән бергә –
Гадел булу бик кирәк.

**АБ**. Командалар үзләре белән якыннан таныштырып киттеләр. Рәхмәт аларга! Афәрин! Шулай итеп, уенның беренче туры. Командаларга шагыйрә Клара Булатова иҗаты буенча 10 сорау биреләчәк. Сораулар укылган саен һәр команданың җавабы тыңлана. Һәр дөрес җавап өчен 1әр очко бирелә.

К. Булатова тормышы һәм иҗаты буенча белемнәрне тикшерү бәйгесен башлыйбыз.

1. К. Булатованың туган елы. (**1936)**
2. К. Булатованың әти-әнисе нинди һөнәр ияләре була? **(Укытучылар)**
3. К. Булатованың туган авыл. (**Татар Карамалысы)**
4. Клара Булатованың сүзләренә иҗат ителгән «Шушы яктан, шушы туфрактан без» җыры көенең авторы кем? **(Рәис Нәгыймов)**
5. Яшь шагыйрәнең беренче шигырьләре басылган балалар һәм яшүсмерләр өчен журнал исеме ничек аталган? **(«Пионер» («Ялкын»)**
6. Шагыйрьнең 2009 елда балалар өчен язылган шигырьләр җыентыгы нинди кыз исеменә багышлана? **(Камилә. «Камилә дигән матур кыз»)**
7. «Аш пешерәм, җыештырам,
   Кер юышам әнигә.
   Магазиннан сөт апкайтам,
   Ипигә дә йөгерәм». Бу өзек кайсы шигырьдән ? («**Әниемнең кызы юк бит»)**
8. Клара Булатова белгечлеге буенча кем? **(Укытучы)**
9. К.Булатова сүзләренә, Ифрат Хисамов көенә иҗат ителгән «Якын дустың барын онытма» җырын кем башкара? **(Булат Нигъмәтуллин).**
10. К. Булатова 6 нчы сыйныф укучыларына багышлап язылган шигыре ничек атала? **(«Алтынчы класстагылар»)**

**2 нче тур. «Яшь рәссамчылар».**

**АБ.** Әйдәгез, икенче турга күчәбез. Игътибар белән экранга карагыз. Экранда язучы танылган татар язучысын сурәтләнгән. 1994 е елда шагыйрә Клара Булатовага әлеге язучы исемендәге премия бирелгән. Бу язучы әсәрләрендә сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыл тормышын сурәтли. Әлмәткә күчеп килгәч, нефтьчеләр, төзүчеләр турында яза. 34 китап язып бастыра. «Авылдашым Нәби», «Йолдызым» кебек әсәрләрнең авторы. Экранда язучы фотосурәтенең 1\4 өлеше сурәтләнгән. Кем ул? **(Рафаэль Төхфәтуллин).**

Экранда икенче фотосурәтенең 1\4 өлеше. Ул – иң мәшһүр татар шагыйрьләренең берсе. Клара Булатова әлеге шагыйрьгә багышлап «Искәндәр кыйссасы» дигән китабын яза. «Гөлләр инде яфрак яралар», «Кайсыгызның кулы җылы?», «Иртәләрем-кичләрем» кебек шигырьләр авторы. Кем соң ул? (**Хәсән Туфан)**

***Җаваплар бәяләнә.***

***3 нче тур. «Капитаннар ярышы»*** дип атала. Һәр команданың капитанына 8әр сорау яңгырар. Сез аларга «Әйе», я «Юк» дип кенә җавап бирергә тиеш. Һәр дөрес җавапка шулай ук 1әр очко биреләчәк.

Иң беренче бәйгене **«Кыю малайлар»** командасының капитаны сездән башлыйбыз.

1. Шагыйрәнең әтисенең исеме Гариф. (**Әйе )**
2. К. Булатова мәктәпне 1954 нче елда тәмамлый. **(Әйе)**
3. К. Булатова В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының математика һәм информатика бүлегендә укый. **(Юк)**
4. «Вәхшәт» шигырен Клара Булатова язган. **(Юк**)
5. Клара Булатовага Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия бирелгән. (**Әйе)**
6. Шагыйрә 1970 нче елдан башлап Язучылар берлеге әгъзасы. **(Әйе)**
7. Шагыйрәнең «Марс китабы» шигырьләр җыенгы балалар өчен. **(Әйе)**
8. Клара Булатова хәзерге вакытта Казан шәһәрендә яши. **(Юк)**

Ә хәзер сүз «**Тапкыр кызлар»** командасының капитанына бирелә.

1. К. Булатова 1946 нчы елда тумаган. **( Әйе.)**
2. Татар Карамалысы, Ләке, Югары Чыршылы авыллары Татарстанның Буа районына керә. **(Юк, Сарман)**
3. «Камилә - матур кыз» шигырен К.Булатова язган. (**Әйе)**
4. К. Булатова белгечлеге буенча табиб. **(Юк)**

5. К. Булатова шигырьләренә җырлар иҗат ителгән. **(Әйе)**
6. К. Булатова романнар, повестьлар яза. **(Юк)**
7. Клара апа Булатова – Тукай премиясе лауреаты. **(Әйе)**
8. К. Булатовага быел 84 яшь тула**. (Юк)**

**Җавапларны бәяләү.**

**4 нче тур «Өй эше».** Бу биремгә иң югары балл – 5 балл куела. **(***Клара Булатова иҗатыннан я шигырь яттан сөйләү, я җыр җырлау.)*

**Җавапларны бәяләү.**

Иң соңгы тур **«Куып җит»** дип атала. Хәзер сез бер озын сүздән кыска сүзләр төзерсез. Сүзләрнең хәрефләр саны булган хәрефләрдән артмаска, татар телендә булуы сорала. *(«**БЕРДӘМЛЕК»** сүзеннән кыска сүзләр төзелә).*

**Җавапларны бәяләү. Уенга нәтиҗә ясала.**

## Гомер учагында еллар яна...

(мәктәпкә әзерлек төркемендә шагыйрә Клара Булатова белән очрашу )

Афзалова Алия Мөнәвир кызы, Җәлил бистәсенең 1 нче «Каенкай» балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

**Максат:** Клара Булатова иҗатының төрлелегән шигырьләре аша балаларга җиткерү; балаларның сәнгатьле сөйләмен үстерү; балаларда якташыбыз иҗаты аша татар поэзиясенә карата кызыксыну тудыру, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт-итәгать тәрбияләү.

**Җиһазлау:** шагыйрә иҗатына багышланган китаплар стенды, проектор, музыка үзәге, стенгазеталар, аның шигырьләренә язылган җырлар .

**Очрашу барышы:**

Очрашу балалар башкаруында **«Туган көн»** җыры белән башланып китә.(К.Булатова сүзләре, М.Гарифуллина көе)

**Тәрбияче:** Тәрәзәдән өйгә көн кергән,
Бүләк итеп кояш китергән...
Бүген безгә шундый көн килгән
Кояш белән Клара апа килгән.

- Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар, кадерле балалар! Кайнар сәлам – күңелләрне язгы кояштай яктыртучы, барыбыз өчен дә якын, балачактан үзенчәлекле шигырьләре белән йөрәкләребезгә кереп калган якташыбыз Клара апа Булатовага!

Мөгаллимә-шагыйрәбезнең кечкенә хикәяне хәтерләткән һәр шигыре уңай һәм тискәре күренешләрне күрә, шәфкатьлелек, кешелеклелек, ярдәмчеллек кебек күркәм сыйфатларны бәяли белергә өйрәтә. Яшь буынны әхлаклы, иманлы, чын татар баласы итеп тәрбияләүдә Клара апа Булатова шигырьләре төп ярдәмчебез булып тора. Хәзер сүзне балаларга бирик.

**Унга кадәр**

Марсның бармаклары –
Санагыч таяклары.
Бер турайта, бер бөгә,
Унга кадәр сан белә.
Әти белән әни, ди,
Бабай белән әби, ди,
Үзем, абый һәм апа,
Боларга кушкан чакта
Бозау белән песи, ди,
Алай да җитешми, ди,
Этемне дә син куш, ди,
Унынчысы – Актүш, ди.

«Камилә» җыры башкарыла (К.Булатова сүзләре, Н.Сабирҗанова көе)
**Тәрбияче:** Клара Булатова балалар өчен бик күп шигырьләр иҗат итеп кенә калмый, аларны менә шушындый матур китаплар итеп тә бастырып чыгара. «Марс китабы», «Әллә кайсын тыңлыйсы», «Курка димәгез әле», «Камилә – тәти кыз» китаплары безне яхшылыкка өнди, дөньяны танып-белергә өйрәтә. (Китап күргәзмәсе белән танышу)

**«Әләкләргә ярамый»** шигырен сәхнәләштерү.

Әни:
- Сез үзегез тәртипсез,
Песиегез дә тәртипсез.
Туздыргансыз өйне,
Аударгансыз гөлне,
Монда ята чүлмәк,
Тегендә ауный күлмәк,
Азынасыз бигрәк!
1 бала:
Бүлмә үзе тузгандыр,
Без аны гел күрмәдек.
2 бала:
Чүлмәк үзе аугандыр,
Без аңа да тимәдек.
3 бала:
Һич тәртипсез түгел без,
Без бит бары уйныйбыз,
1 бала:
Песи наян,без шаян
Шуңа өйгә сыймыйбыз.
2 бала:
Песи чапты, мин кудым,
Алны-артны карамый.
3 бала:
Кайсыбыз гөл аударганны
Ул да әйтми, мин дә әйтмим,
3се бергә:
- Әләкләргә ярамый.
**Тәрбияче:** Шагыйрә апабыз иҗатында мәктәп темасына багышланган шигырьләр аерым урын алып тора,чөнки ул – тумыштан ук укытучы апа! Бик күп шигырьләрендә ул мәктәпкә, балаларга булган олы мәхәббәтен сурәтли:
Миңа сорау бирсәләр,
Шатлыгың ни? – дисәләр,
Шушы мәктәп сукмаклары
Шатлыгыма илтәләр.

**«Кайчан гына үскән диген»** шигыре башкарыла.

Җидегә җиткән диген:
Камилә дигән матур кыз
Укырга китә бүген.
Гимназиягә бара бит,
Олы Белем иленә.
Акыллы һәм тырыш булса,
Укыр «бишле»гә генә.
**Тәрбияче:** Яңа көнгә яңа хуҗа булып, яңа буын килә, – дип куана шагыйрә. Инде яраткан оныгына яңа җырлар, яңа шигырьләр иҗат итә ул. Үз оныгы өчен генә түгел, күпләрнең оныклары өчен изге дога булырдай юллар бар аларда.
Күкләргә кара, улым,
Йолдызлар сана, улым,

Йолдызларны таныган бала,

Үз юлын таба, улым, – дип меңләгән әниләрнең, әбиләрнең гозер-теләкләрен җиткерә. Клара апа, хәзер сүзне сезгә бирәбез. Яшь буынга җиткерәсе теләкләрегез, әйтәсе сүзләрегез бардыр, рәхим итегез!

**Клара Булатова чыгышы.**

- Хөрмәтле Клара апа! Балалар һәм халкыбыз күңеленә якты өмет чаткылары салып, яңадан-яңа рухи байлыклар бүләк итеп, сәламәтлек белән яшәргә язсын Сезгә!

Очрашу тәрбияче һәм балалар башкаруында **«Кырга чыктым, юлга чыктым»** җыры белән тәмамлана (К.Булатова сүзләре, Ә.Шиһапов көе).

**Еллар кайтавазы – китап битләрендә**

(класстан тыш чара эшкәртмәсе. Язучы Хәниф Хәйруллинның «Канлы еллар, авыр еллар» очеркына күзәтү, геройларны барлау)

Хәбибуллина Асия Алин кызы, Сарман аграр көллияте укытучысы
Мөхтәров Ислам Рунис улы, студент

**Максат**: студентларны, укучыларны Хәниф Хәйруллин иҗаты белән таныштыру, әдәби әсәрләр укуга омтылыш уяту; Туган як, Ватанга карата мәхәббәт хисләре тәрбияләү; тарихи әсәрләр укуга кызыксыну уяту.

**Материал, җиһазлау**: Хәниф Хәйруллин әсәрләреннән күргәзмә, «Канлы еллар, авыр юллар» тарихи очеркы, әсәрдән өзекләр, аудиоязма «Көзге ачы җилләрдә», Дамир Гарифуллин «Кәүҗияк авылы җыры», проектор, Сарман районы картасы.

Безнең авыл арасы ла,
Олы юл баганасы шул,
–Йөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам
Көзге ачы җилләрдә лә
Туган-үскән илләргә.
Куандырды туган җирне
Хөррият заманасы шул...

(Әсәрдә Хаҗи Ишморатов авылны чыкканда башлап җырлый, ул 1918 елда Уфа губернасы, Минзәлә өязе Советының 1 съездында делегат булып катнаша)

**Укытучы (**Хәбибуллина Асия Алин кызы): Хәниф Хәйруллин мөстәкыйль тормыш юлына басып байтак вакытлар узгач, зур гына тормыш тәҗрибәсе туплангач һәм, анын үз сүзләре белен әйткәндә, «бүтән язмыйча түзә алмаганым аңлагач кына» каләмгә алына. Баштарак үзен төрле жанрларда сынап карый. Очерклар яза. Озак еллар Сарман районы газетасы «Ленинчы» («Сарман») редакциясенда эшли, еш кына хәбәрче буларак авылларда йөри, халык белән таныша, тынгысыз җаны тарихи чоңгыллар, куркыныч еллар вакыйгалары, аларның җанлы шаһитлары җанын тынгысызлый. Очерк язарга этәрә.

**Укучы.** Кыскача Кәүҗияк авылы тарихын (үткәнен, хәзергесен) сөйли.

**Укытучы.** Районның Кәүжияк дигән авылында 19 гасырның 20 елларында булган, халыкны икегә аерган, бер-берсе белән дошманлаштырган шомлы вакыйгалары җурналистның тынгысыз куңелен битараф калдырмый. Авылга кат-кат барып шул елларның шаһитларын күреп мәгълүмат туплый, тәфсилләп сораша, архив документлары белән танышып тарихи очерк иҗат итә.

Әсәр 40 битле китапчык булып 1972 елда аз тираж белән басылып чыга. (Эшкәртмә язу өчен шактый эзләп тә бу китапчыкны табып булмады, әсәрне «Повестьлар» җыентыгыннан алып укыдык. 1981 елда, Казанда Татарстан китап нәшриятында чыккан. Бу экземпляр авторның шәхси китапханәсеннән вакытлыча укып танышу өчен алынды)

**Хәбибуллина (**Камалетдинова) **Асия (**истәлекләр) Бу китап басылып чыгу авылда янә кабатланган инкыйлаби вакыйгага тиң булгандыр. Олысы-кечесе, урамда, чишмә юлында, терлекчеләр йортында, басуда, МТПда сүз әсәр хакында булды. Персонажлар (реаль авыл

кешеләре) танылды, әти-бабайлар кайсысы акланды, кайсы нәфрәт алды. Халыкның күңеле сизгер, риясыз, туры. Аның үз хөкеме, үз җәзасы.

Китапханәче Кәримә апа Әхтәмова чират дәфтәре (элек китапханәчеләрдә шундый дәфтәр бар иде) язып әсәрне чиратлап гаиләләргә укырга биреп тора. Ниһаять, китап – безнең гаиләдә. Кичен без ике гаилә җыелып (әнкәйнең сеңлесе Хәния апа ире, ике баласы белән өч йорт аша яши иде) очеркны чиратлап укый башладык. Әти, апа, мин укыйбыз. Кире кайтып, кат-кат. Миңа күбрәк укырга туры килде (йөгерек, сәнгатьле, кычкырып укыйм). Аеруча газиз бабабыз, Казан ягының мәхәллә мулласы, указлы (дипломлы), белемле, зыялы, гадел Садыршәһит турындагы эпизодларны елый-елый укыдык. Әсәрдә ул беренче мәртәбә авыл бае, явыз, кешелексез Сәлимгәрәй йортына чакырулы, аклар ягына кушылудан, аларны яклаудан баш тарта: «...Мәхәлләгә ни йөзем белән күреним мин», – дип аңлата үзенең фикерен. «Ярлы-йонтагай бөтен мөлкәтеңне тартып алса» дию дә куркытмый аны. (Тартып алалар. Анысы соңрак була. Яңа туган баласын яткырырга колак мендәре дә калдырмыйлар. Төрмәгә озаталар...). Гадел, төпле фикерле итеп тасвирлый аны автор (тормышта да нәкъ шундый булган дип сөйлиләр аны белүчеләр). Соңгы бүлектә «Садыршәһит имамлыктан китеп игенчелек белән шөгыльләнә башлый», – дип яза автор. «Теге “изге” бәндәләр Хаҗиның да башына җиткәч, җаным бизде», – дип җавап кайтара кызыксынучыларга. Күңеле белән бизмәгән. Иман күңелдә ул. Җавабы – болганчык елларга ишарә…

Ул чорда авыл заманасы өчен зур: башта биш, аннары өч мәхәлләгә әйләнгән. Геройлар да һәркемгә авылда таныш – Типтәр мәхәлләсе мулласы Лотфулла Мансуров та, укытучы-мөгаллим Нигъмәтулла Хәмидуллин, абыйсы – кызылармеец, сыйнфый көрәштә үз-үзен аямаган Сәмигулла Хәмидуллин, Мансуров Бадыйкшан, аклар тарафыннан капка баганасына асылган Шәрифҗан да... Онытырлыкмыни аларны? Алар кичергән авыр вакыйгаларны?

Очерк йөгерек тел белән, фикри тыгызлык, тормышчанлыгы белән вакыйгаларга бөтереп алып кереп китә укучыны:

**Укучы (**аудио, яки яттан уку**)** «Язгы төн. Җил ястык калынлыгы бозларны, тау итәкләренә салган өй биеклеге карларны үчләнеп-үчләнеп ашый. Авыл, караңгы юрганын бөркәнеп, йокларга җыена. Тычкан уты елтыраган тәрәзәләр саны бер-бер артлы кими. Типтәр, казан ягы урамында ул инде бөтенләй күренми. Тик башкорт ягындагы байлар яши торган йортларның тәрәзәләрендә генә унлы лампа яктысы балкый. Габдулла мулла, Сәлимгәрәй бай ихаталарында топольлар (шул урында хәзер дә тупыллар күкрәп үсәләр), көчле җил белән кочаклашып, нидер серләшәләр, аның шәрә ботакларына кургашындай авыр болытлар эләгеп-эләгеп китәләр.

Башкорт ягына (авылнын бу урамында башлыча бик күп җир биләүчеләр, башкорт ягыннан күчеп килгән кешеләр яши) күрше рус авылы тарафыннан бер җайдак килеп керде... Урам уртасында басып торган каравылчыны күргәч, җайдак аттан сикереп төште. Аның өстендә күн тужурка, киң каешына револьвер асылган, аягында хром итекләр. Бер кулы белән кобурага тотынган бу кеше хәтәр күренә, күзләре төнлә дә үтәли күрә кебек. Алар әнә ничек каравылчыны – Сәлимгәрәй бай ялчысын бораулыйлар.

- Абый кеше, әйт әле, авылга кем хуҗа?
- Кем, дип, ни, үзебез…
- Байлармы, ярлылармы?
- Ә, алай! Хәзергә беркем дә! Габдулла мулла белән минем бай Сәлимгәрәй Колчакны көтәләр, Хаҗилар, Лотфулла хәзрәтләр кызылларны көтә…»

**Укучы**.Уфадан килгән кызылгвардеец Шаммасов авылның иң кыю 30 ир-егетеннән отряд туплый, алар 1917 елны ВКП(б) члены Минлегәрәй Әхметшин җитәкчелегендә Минзәлә өязеннән акчехларны, акгвардиячеларне кууда һәрвакыт алгы сафта булалар, аларның байтагы Азин дивизиясенә килеп кушыла. Биредә дә сынатмыйлар алар. Сугышларның берсендә Хаҗи Ишморатов һәм Камали Гайфиевлар (әтием Алинның әтисе – минем бабай), яраланып бер авылда калалар, терелгәч, Яшьләр союзы төзү турында күрсәтмә алалар...

Әсәр зур булмаган, ләкин мөстәкыйль 13 (шомлы сан) бүлекне үз эченә ала. Исемнәре үк укучы куңеленә шом сала: «Төнге юлчы», «Барыбыз да китәбез», «Аны капка баганасына астылар», «Авыл өстендә болытлар куера», «Шомлы төн», «Каракның бүреге яна»,

«Качыгыз, оланнар!..», «Уналты штык арасында», «Аның телен кискәннәр бит», «Сәмигулла белән Бадыйкшанның һәлакәте», «Эткә – эт үлеме», «Дошманның яңа мәкере».

**Укытучы.** 1919 елның 9 апреле. Сәлимгәрәй бай, аның куштаны Габдуллалар доносы белән кулга алынган кызылармеецларны акларның вакытлы штабы булган Метрәй (Мөслим районы) авылына китерәләр, коточкыч кыйнау-җәзалаулар, шәрә бозга яткырып тал чыбыгы белән суктыру, Нигъмәтне гариплэгәнче газаплау («Аның телен кискәннәр бит», Сәмигулла белән Бәдыйкшанны Карамалы (Мөслим) авылы янында атып үтерү... Дошман фәтвәсенә бирелеп, Хаҗыймөхәммәт, Габдулла байлар коткысы белән Нуретдин үзенең улы – авылның каһарманы, беренче комсомолы – Хаҗи Ишморатовны үз куллары белән корбан итү, үзен дә сыйнфый дошманнар үтереп елгага агызу... Барысы – канлы елларның  гаепсез корбаннары, аяусыз көрәш, мәгънәсез сугыш нәтиҗәсе.

Бу 1921 елның 21 апреле була. Дошманнар, әлбәттә, үз җәзасын ала: «Эткә – эт үлеме». Никадәр кан кою, вәхшилек... Әсәр-тарих укучыны сюжетка бәйләп тора, аны уйландыра, елата, сыкрата.

**Укучы**-тарихчы. 1918-1921 елгы вакыйгалар турында сөйли.

**Укучы:** Тарихка күз салсак, Гражданнар сугышы узенең миһербансыз, канкойгыч вакыйгалары белән аерыла. Бер ил, бер Ватан, бер авыл, бер ата-ана балалары, сәяси аң булмау сәбәпле, бер-берсен вәхшиләрчә үтерәләр. Шушындый язмышка авылның йөзек кашы булырдай, җир сөреп, икмәк үстерәсе, тигез гаиләдә балалар багасы ир-егетләре дучар була. Якты киләчәк хакына.

Еллар үтә, тыныч тормыш авыр юллар, канлы елларны әкренләп оныттыра. Октябрь каһарманнары, революцияне үз куллары белән яулаган ветераннар туган авылларына кулдан килгән кадәр ярдәм итәләр, аларның эшләрен бала-оныклары дәвам итә. Лотфулла – герой: «...Ә дөнья ничек матур булачак!.. Нигъмәт, улым, син аны күрерсең... Кәүҗияклеләр минем ни өчен шаһит китүемне дөрес аңласыннар иде... Безнең каннар тикмәгә акмасын...» – ди.

Канлы еллар, авыр юллар артта калды. Куркыныч вакыйгалар да тарихның ерак битләрендә калды кебек. Кәүҗияк авылының да йөзе бик үзгәрде. Хәзер авыл кешеләре мул тормышта, яна, биек, якты, җылы йортларда яшиләр, газы-суы кергән, балалар үстерәләр, бәйрәмнәрдә бергә җыелып туганлыкны барлыйлар. Авылда элекке хезмәтче Хафиз, күп балалы, нужа шулпасын туйганчы эчкән Нигъмәтҗановлар  («аталары 22 ел солдат хезмәтен үтәп исән, ләкин хаста булып кайткан») Харрасов Фатыйх,  комсомол Хажи Ишморатовлар, Марданшин Бадыйкжан, Мөхәммәтҗанов Шәрифҗан, Якупов Хаҗи, Харрасов, Фәрраховлар, Гәрәевлар, Ихсановлар, Хаҗиевларны, аларның нәсел-нисбәтен, бала-оланнарын, яки үзләрен, беләләр, хәтерлиләрдер авылдашлар. Хәзер  аларның оныклары авылга, районга, илгә хезмәт итәләр, бабалары рухына тугры булып матур яшиләр.

Һичшиксез, өлкәннәр дә, яшь буын да бүгенге бәхетле тормыш өчен кан койган авылдашларын тирән ихтирам белән искә алалардыр. Хәтер шулай куша. Онытырга хакыбыз юк.

**«Кәүҗияк авылы җыры» (Дамир Гарифуллин сүзләре) яңгырый, яки башкарыла.**

Тау җиләге тәмле була
Кызарып пешкән чакта.
Язмыш кайларга ташласын
Белмәдек үскән чакта.
– Җәмәлҗән тау итәгеннән
Күтәрелә җил-давыл.
Кәүҗиягем, синнән читтә
Яшәүләре бик авыр.
Кыр казлары күлгә төшми,
Җырлап уза һавадан.
Насып булса, туган якка
Бер кайтырбыз яңадан...

Җыр авыл турында, сандугачлы иртә, XVIII гасыр истәлеге – Емельян Пугачев явы шаһиты – Җәмәлҗән тау турында, аерылу-кавышу, яшьлек турында. Җырлар да башка шул хәзер.

Кулланылган әдәбият.
Х.Г.Хәйруллин. Повестьлар, Казан, Татарстан китап нәшрияте, 1981 ел
Кушымта:
1.Дамир Харифуллин төзегән шәҗәрә (кайбер очерк геройлары кергән)
2.Мулла Ихсанов Садыршәһит, Хәмидә абыстайларның фотолары.1946 ел
3.Мулла Ихсанов Садыршәһит, Хәмидә абыстайларның шәхси китапханәсеннән китаплар (фотосүрәтләр кучермәсе)

**Укытучы – мактаулы һөнәр**
(Клара Булатованың 85 еллык юбилеен каршылап)

Закирова Гөлназ Илдус кызы, Әгерҗе шәһәре 1нче гимназиясенең
туган тел укытучысы

**Максат**: укучыларга һөнәр сайлау эшендә Клара Булатова иҗаты аша ярдәм итү; К.Булатова шигырьләре аша укытучы хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.

**1 нче алып баручы**. Дөньяда бик күп һөнәрләр бар. Шулар арасында укытучы һөнәре авыр, җаваплы, ләкин иң дәрәҗәле һөнәрләрнең берсе булып тора. Җир йөзендә яшәгән һәр кешенең язмышы укытучыга бәйле. Укытучы хезмәте авыр да, җаваплы да, кызыклы да. Ул зур сабырлык, түземлек, күпкырлы белем, зыялылык, балаларга карата олы мәхәббәт һәм сайлаган һөнәргә чиксез бирелгәнлек таләп итә. Кешелекнең киләчәге – укытучылар кулында. Алар балалар күңеленә нинди орлык сала алса, хезмәтләренең дә җимешләре шундый булачак.
**2 нче алып баручы** Бүген без гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган укытучы-шагыйрә, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Клара Булатованың мәктәп, укытучылар турында язылган шигырьләре презентациясенә җыелдык.
**1 нче алып баручы** Шагыйрә Клара Булатова 1936 елда Сарман районында укытучылар гаиләсендә дөньяга килә. Математикадан белем биргән әтисе дә, татар теле һәм әдәбияты укыткан әнисе дә кызларында кечкенәдән үк белемгә омтылыш, тирә-юньгә мәрхәмәтлелек тәрбиялиләр.
**2 нче алып баручы** Икесе дә шигърияткә гашыйк әти-әнисе шигырьләр аша кызларын сүз тәмен тоярга өйрәтәләр, поэзиягә мәхәббәт тәрбиялиләр.
<u>**Алсу**</u>
Син башлап хәреф өйрәттең,
Әлифен, яңалифен.
Тукайлы, җырлы, шигырьле
Дөньяга әйдәп керттең.
Ул чакны телевизор да,
Кино да – телең булды.
Телеңнән күчкән бар нәрсә
Гомерлек белем булды. («Әнием»)
**1 нче алып баручы** Туган телгә әнисеннән күчкән тирән мәхәббәт Кларага һөнәр сайлаганда икеләнеп торырга урын калдырмый. Ул укытучы булачак! «Алтыда мәктәпкә килгән идем, алтмышта да балалар янында мәш киләм», дип сөенеп искә ала ул үзенең 40 елга сузылган педагогик хезмәт юлын.
**2 нче алып баручы** Һәр көне, һәр дәресе ак кәгазь битедәй чиста күңелгә бәрәкәтле белем орлыклары чәчүгә багышланган игелекле хезмәткә багышлый ул үзен. Укучыларының белем илендәге җиңүләренә алардан да ныграк сөенеп, уңышсызлыкларына борчылып, һәр укучысына ярдәм итәргә омтылып башкарылган яраткан хезмәте ул аның.
<u>**Илдар**</u>
Ә ул әле һаман йокламаган,
Төн йокысын нәрсә алган соң?

Сәбәбе син, Азат,
Син дә бүген
Язма эштә «5»ле алгансың.
Табельдәге синең «3»леләрне
Алыштырсын өчен шул билге...
Ничә төне ялсыз үтте аның,
Йөрәк көче күпме түгелде.
Күзләрендә бүген борчу түгел,
Шатлык яна синең җиңүдән.
Алда ята дәрес планнары,
Дәфтәрләре янда өелгән...
Син йоклыйсың, татлы төшләр күреп,
Әнкәң җәйгән җылы урыныңда.
Укытучы апаң, керфек какмый,
һаман уйлый синең турында. («Укытучы апаң йокламаган...»)

**1 нче алып баручы** Укытучы өметләнә. Һәр укучы, һичшиксез, тормышта үз юлын табарга тиеш.

**Миләүшә**

Сорау тулы күзләр сиңа карый:
Бер сораумы, йөзме, меңәүме?
«Белмим» сүзен, куй, юк, әйтә күрмә!
Кичермиләр алар белмәүне.
Бу яшь буын юллар юнәлешен
Синнән ала кая барырга?!
Алар гомере, заман килере өчен
Җаваплы син тормыш алдында.
Унөч-ундүрт яшьтә...
Алтынчылар...
Тик башлана гына юлыгыз.
Киләчәктә сездән кемнәр чыгар?..
Кем булса да –
Кеше булыгыз! («Алтынчы класстагылар»)

**2 нче алып баручы** Яшь буынны кешелекле, миһербанлы итеп тәрбияләү эшендә мөгаллимә-шагыйрәнең төп кыйбласы –туган теле, чөнки максаты – укучыларында әдәби китаплар укырга омтылыш булдыру. Китаплардан тормыш итү өчен уңай якларны алып, тискәре күренешләргә карата үз фикерләрен әйтә алучы, катлаулы тормышта үз юлларын таба белүче яшьләр тәрбияләү.

**Марат**

И Туган тел! Син бит минем
Эштә нигез коралым.
Бишек җыры гына түгел –
Кыйбла татар иманым.
И Туган тел! Синдә күпме
Мин дәресләр үткәрдем,
Синең белән күпер салдым
Иҗатына күпләрнең.
Алар күпме шигырь язды,
Күпме китап чыгарды.
Син булдың бит төп коралым,
Үстергәндә шуларны... («Туган тел»)

**1 нче алып баручы** Укытучы шуны анык белә: бары тик туган телдә генә балаңа йөрәк авазын ишеттерергә мөмкин, туган телдә теләнгән теләкләр генә кабул була.

**Лиана**

Йолдызың якты булсын,
Юлларың яхшы булсын;
Сүзләрең затлы булсын,
Телләрең татлы булсын.
Каты тел катма, улым,
Тәмсез сүз әйтмә, улым;
Олыны да, кечене дә
Яманнан якла, улым.
Күкләргә кара, улым,
Йолдызлар сана, улым...
Йолдызың ачкан юлыңнан
Тайпылмасана, улым! («Күкләргә кара, улым»)

**1 нче алып баручы** Быел 85 яшен тутыручы Клара Булатова – үз бәхетен мәктәптә тапкан укытучы, шигъряттә тапкан шагыйрә, Кеше тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш керткән Шәхес. Ул бүген дә укытучы.

**Илдан**

Миңа сорау бирсәләр:
– Сөенечең ни? – дисәләр,
Сөенечем – таңнан торып
Эшкә килгән иртәләр.
Миңа сорау бирсәләр:
– Сөенечең ни? – дисәләр,
Шушы мәктәп сукмаклары
Шатлыгыма илтәләр.
Миңа сорау бирсәләр:
– Бәхетең ни? – дисәләр,
Бәхет – шушы укучылар
Кеше булып үссәләр. («Укытучы бәхете»)

**2 нче алып баручы** Мәктәп, укытучылар турындагы тирән мәгънәле шигырьләре белән безне – татар милләтенең киләчәген – булачак укытучыларны тәрбияләүче укытучы-шагыйрә Клара Булатовага Әлмәттән еракта яшәүче Әгерҗе укучылары исеменнән озын иҗади гомер телибез.

## Знакомство с жизнью и творчеством Клары Булатовой

(Развлечение для детей подготовительной к школе группы)

Денисова Эльмира Нилевна, Джалильский детский сад № 5 «Сказка»,
Сармановский район

**Цель:** познакомить детей с жизнью и творчеством татарской поэтессы Кларой Булатовой. Расширять представления о татарской детской литературе, вызвать интерес к поэзии. Учить выразительно читать стихотворения.

**Предварительная работа:** чтение стихотворений Клары Булатовой.

*Дети входят в зал под музыку. Стулья полукругом, экран для показа слайдов*

**Воспитатель:** Еврей и тувинец, бурят и урдмурт.
Русский, татарин, башкир и якут.
Разных народов большая семья
И этим гордиться дожны мы друзья.

Много народов живёт на нашей планете, много национальностей. Мы с вами живем в Татарстане. В Татарстане тоже живут много народов разных национальностей. В каждой нации есть свои герои, известные люди. Сегодня я хочу вас познакомить с татарской писательницей Кларой Булатовой. (Слайд 2)

Клара Булатова родилась в нашем районе. Родилась 18 марта 1936 года в деревне Татарские Карамалы Сармановского района в семье служащего. Может и ваши бабушки, дедушки живут в этой деревне.

Когда началась война в1941 году поступает учиться в первый класс Верхнее – Чыршылинской школы. В 3-7 классах учится в Лякинской школы Сармановского района, потом учится и заканчивает Сармановскую среднюю школу. Работает учительницей начальных классов Нижнее-Лешевской школе Сармановского района.

В 1956 году приезжает в город Альметьевск. Учится в отделении татарского языка и литературы. Казанского государственного университета.

С 1969 года, после окончания университета, начинает преподавать татарский язык и литературу в Ново-Кашировской средней школе Альметьевского района. 10 лет преподает в Альметьевской татарской гимназии. Более 8 лет ведёт уроки татарской литературы в Альметьевском муниципальном институте.

10 лет работает в телерадиокомпании «Нур» в городе Альметьевске (с 1991 года).

В 1967 году выходит в свет самостоятельная книга под названием « Вёсны впереди » (сборник лирических стихов. Клара Булатова пишет стихи для детей и для взрослых.(слайд 3)

Воспитатель: Наши ребята, выучили стихи Клары Булатовой.

*3-4 ребёнка читают стихи.* «Беренче адымнар», «Әниемнең кызы юк бит», «Зоопарк», «Әни сүзе», «Абыем дәрес хәзерли»

Поэтесса стала известной и как автор очень красивых песен. В этих песнях центральное место занимает тема любви, тема родного края. (слайд 4)

*Слушание песни «Шушы яктан, шушы туфрактан без»*

Клара Булатова более 35 лет является членом Союза писателей. За творческие успехи ей присвоено почетное звание “Заслуженный деятель культуры Республики Татарстан». Клара Булатова является лауреатом литературной премии имени Рафаила Тухватуллина.

Воспитатель: А сейчас ребята, мы с вами нарисуем иллюстрации к стихотворениям Клары Булатовой. И оформим её как книжку.

*В конце рисуют рисунки к произведению Клары Булатовой.*

Воспитатель: Сегодня мы с Вами познакомились с творчеством нашей землячки Клары Булатовой. И мы очень гордимся, что среди нас вырастают такие известные, знаменитые люди. Родившийся в простой семье можно достичь больших жизненных успехов, главное стараться, идти к своей цели, нужно всегда оставаться хорошим человеком.

## Сценарий КВН, посвященный жизни и творчеству Клары Булатовой, с применением биографии поэтессы

Харисова Ильсеяр Музагитовна, Талипова Ляйсан Равилевна, учителя Джалильской СОШ №2, Сармановский район

Цели и задачи КВН: КВН включает в себя разные виды заданий, их выполнение требует не только знания произведений, но и воображения, фантазии, способности смоделировать ситуацию по заданным параметрам. В ходе КВН проверяются навыки и умения учащихся: умение общаться, владение ораторскими приемами, четкость и громкость речи, эмоциональность, оригинальность.

Подведение итогов**.**

Подведение итогов производит компетентное жюри, в которое входят специалисты –учителя татарского языка и ученики. Каждый член жюри самостоятельно и обосновано выставляет оценки по заданной системе. Победители конкурса награждаются памятными призами и дипломами.

Ход мероприятия

1. Вступительное слово учителя:

Сегодня в форме КВН у нас пройдёт мероприятие, посвященное жизни и творчеству Клары Булатовой. Клара Булатова – поэтесса, всем свои существом пронизанная духом поэзии и сохраняющая верность своему перу. Она – член Союза писателей СССР, заслуженный работник культуры Татарстана, лауреат премии имени Габдуллы Тукая, Рафаэля Тухватуллина.

В этом году поэтессе исполняется 85 лет.И мы сегодня вспомним основные события ее жизни, особенности творчества, главных героев ее произведений. Итак, пришло время участникам представиться.

Команды, участвующие в КВНе (задание было дано заранее) представляют себя: название, эмблему, девиз. Наибольшее количество баллов 3 балла.

2. Учитель: И у нас первый конкурс — «Разминка».

В своей критической статье о книге «Окна памяти» Мансур Валиев пишет: «Вот уже сколько лет поэтесса Клара Булатова добросовестно исполняет эту святую …. Это разве не подвиг?! Эх, остальные поэты тоже слились бы сегодня в этот … по охране и … юного поколения».

Вставьте пропущенные в высказывании слова. (Учащиеся должны вставить слова-обязанность, поток, защита). За каждый правильный ответ 1 балл. Всего за «Разминку» каждая команда может набрать 3 балла.

3.Следующее задание посвящено биографии и творчеству писательницы:

1. В каком районе Татарстана родилась писательница? (Сармановском)
2. В каком году и где родилась поэтесса? (поэтесса К.Булатова родилась в 1936 году в Сармановском районе, в д. Татарское Карамалы в семье педагогов).
3. Где получила высшее образование? (в Казанском государственном университете).
4. С чего началась студенческая деятельность писательницы? (с организатора литературного кружка).
5. Какой деятельности Клара Булатова отдала около сорока лет? (преподавательской)
6. Когда начала печататься и в каких журналах вышли первые произведения? («Ялкын, «Азат хатын», «Казан утлары», «Чаян»).
7. Кому был посвящен первый сборник лирических стихов «Впереди весна»? (нефтяникам, строителям, труженикам села).
8. Назовите в каких стихотворениях проявляется любовь к жизни и смене времен года? «Безнең як» («Наш край»), «Туган җирем» («Родная земля») «Укытучы бәхете» («Счастье учителя»). За каждое название команда получает 1 балл.

Подводятся итоги данного конкурса.

4. Учитель: Пришло время показать домашнее задание: инсценировку эпизода из любого стихотворения Клары Булатовой. За это задание максимальный балл 5. (Команды представляют свои домашние заготовки: учитывается оригинальность постановки, точность воспроизведения текста, актёрское мастерство)

5. Учитель: Следующее задание такое – данные вам строчки стихотворения «Когда на сердце…» надо расположить так, чтобы получился связный текст. (Каждой команде выдаётся набор из предложений этого стихотворения, учитываются быстрота и правильность выполнения). Максимальное количество баллов 5.

Образец задания.

Когда на сердце... смутно и тревожно,
Но только сердцу, сердцу каково!
Или уйди в работу, чувства пряча,
Забыв себя – обиды, неудачи,
Все огорченья, все до одного...
Иди к друзьям –там посмеяться можно
И скрыть следы волненья своего...
Твой нежный друг перестаёт быть другом,
Наверно, можно и простить его...
Но только сердцу, сердцу каково!

Правильный текст: Когда на сердце смутно и тревожно,

Но только сердцу, сердцу каково!
Когда твой друг, доверившись разлукам
Когда на сердце смутно и тревожно,
Иди к друзьям – там посмеяться можно
И скрыть следы волненья своего...
Но только сердцу, сердцу каково!
Или уйди в работу, чувства пряча,
Забыв себя – обиды, неудачи,
Все огорченья, все до одного...
Но только сердцу, сердцу каково!
Когда твой друг, доверившись разлукам,
Твой нежный друг перестаёт быть другом,
Наверно, можно и простить его...
Но только сердцу, сердцу каково!
Подводят итоги конкурса, объявляют результаты.
7. Учитель. Заключительное задание может определить победителя, а состоит оно в следующем: напишите эссе о месте Клары Булатовой в татарской литературе. Максимальный балл 10.
8. Определяют команду-победительницу.
9. Учитель: Вот и подошёл наш КВН к концу. Давайте поделимся впечатлениями от данного мероприятия. (Рефлексия.)

**Әзһәр Габиди иҗатында – сугыш**

Салихова Айгөл Роберт кызы, Нуртдинова Гөлнар Салихҗан кызы, Гатин Рафис Исмәгыйль улы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы

Максат: укучыларның Бөек Ватан сугышы турыдагы белемнәрен тирәнәйтү, гражданлык һәм патриотик хисләр, туган җиренә, халкына карата горурлык хисе тәрбияләү.

Кичәнең барышы

**1укучы:** Ир-егетләр илгә яу килгәндә
Ничек тыныч ятсын илендә?
Кулга ала сыйнфый винтовкасын,
Соры шинель сала иңенә

**Беренче алып баручы.** 1941 елның 22 июнь таңы. Бу иртә башка иртәләрдән бер нәрсәсе белән дә аерылып тормый иде. Шул ук сандугач сайрады, кошлар җырлады. Иртән авыл халкы көндәгечә көтүен куды. Менә шундый тыныч иртәдә илебезнең чигенә дошман бәреп керә. Бөек Ватан сугышы башлана.

**Икенче алып баручы.** Бөтен ил халкы бер булып, дошманга каршы күтәрелде. Авыл башына чыгып, хатыннар ирләрен, ваемсыз сабыйлар әтиләрен, яшь кызлар сөйгәннәрен фронтка озата. Берни аңламаган сабый сугышның нинди куркыныч икәнлеген белмиләр шул әле. Тиздән, бик тиздән үзләренең ятим каласыннарын да, балачаклары буразна арасында үтәсеннәрен дә аңламый алар. Сугыш рәхимсез. «Әткәй, китмә!» – диеп елаган балалар инәлүен дә ишетми ул сугыш.

**2 укучы:**
Нинди генә көннәр булмагандыр,
Барысы да истә калмаган.
Ләкин яуда йөргән чакны вакыт
Хәтеремнән юа алмаган.
Яраландык.
Ләкин җиңелмәдек –
Ил тарихын яздык кан белән.

Рейхстагка кадап байракларны
Илгә кайттык җиңеп дан белән.
**3 укучы:** Явыз дошман килә ябырылып.
Кыл өстендә тора илебез.
Иң өстенә салдык соры шинель.
Онытмагыз,
Безне көтегез
**4 укучы:** Явыз дошман Мәскәү капкасында
Кыл өстендә торган чагыбыз.
Дошманнарга барыбер җиңдермәбез,
Сагынабыз,
Хатлар языгыз.
**Беренче алып баручы.** Сугыш авылдагы һәрбер йортны тетрәтте. Авылда тормыш карт-коры, хатын-кыз, бала-чага кулына күчте. Чәчелгән икмәкне җыеп алырга кирәк иде. Мондагы тормыш икенче фронтка әйләнде.
**Икенче алып баручы.** Җир ябыккан,
Кырлар хәлсезләнгән,
Аларга да сугыш кагылган.
Киң басулар утлы яуга киткән,
Батыр хуҗаларын сагынган.
**1 укучы:** Сезгә, кырлар, тиздән юл алырбыз
Сездә, сездә безнең уебыз;
Гитлер чаба канлы Берлинына,
Якынлаша җиңү туебыз.
**2 укучы:** Канга буялса да тапланмады
Ватан алдындагы антыбыз.
Салют бирә горур тупларыбыз,
Без кайтабыз –
Каршы алыгыз!
**Беренче алып баручы.** Лачын кебек баһадирларыбыз, сугышка киткән хатын-кызларыбыз бер-бер артлы шәһәрләребезне азат иттеләр, Европа илләрен фашистлардан азат итә-итә, Берлингача данлы сугыш юлы үттеләр. Бик күпләре тиңдәшсез батырлыклар күрсәтеп ятып калдылар.
**Икенче алып баручы.** Җиңү көне якынлаша! Бу көнне кешелек дөньясы түземсезлек белән көтте. Һәм ул көн килде. 1945 елның май ае. Бу көнне безнең күзләрдә шатлыклы күз яшьләре.
**3 укучы:** Туплар тынды.Чик буйлары тыныч.
Тик хәтердә туплар тынмыйлар.
Каберләрдә үскән кыңгыраулар
Күңелләрдә бүген чыңлыйлар.
**4 укучы:**
Кылдан нечкә һәм кылычтан үткен
Сират күперен кичкән буын сез.
Үзе үлсә дә, илне исән килеш
Безгә бүләк иткән буын сез.
Безгә сезнең буынның
Һәр бөртеге – бер дөнья.
Илебезнең тарихының
Данлы бите сез монда.
Йомгаклау. Әйе, совет халкының үз-үзен аямыйча көрәшүе нәтиҗәсендә генә бу коточкыч сугышта безнең илебез җиңү яулады. Бик күп корбаннар аша гына җиңү таңы туды. Бик көттереп туды ул 9 май – Җиңү таңы. Боларны онытырга безнең хакыбыз юк. Хакыбыз юк! Батырлар даны мәңгелек!

## Клара Булатова – бәхетен туган ягында тапкан шагыйрә

(шагыйрә белән очрашу кичәсе)

Җиһангиров Айдар Фаиз улы, Җиһангирова Гөлшат Таһир кызы,
А. Тимергалин исемендәге Иске Минзәләбаш мәктәбе, Сарман районы

Күргәзмәгә Клара Булатованың портреты, китаплары, гәҗит-журнал битләреннән аның иҗатына багышланган мәкаләләр куела. Тормыш юлын һәм иҗатын чагылдырган презентация.

**Максат:** Клара Булатованың төрле рухта язылган шигырьләрен укучыларга җиткерү; укучыларда сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү; укучыларда якташыбыз иҗаты аша татар поэзиясенә карата кызыксыну тудыру.

**К. Булатова сүзләре, Р. Нәгыймов көенә язылган «Шушы яктан, шушы туфрактан без» җыры яңгырый.**

Укытучы: Исәнмесез, кадерле укучылар, хөрмәтле укытучылар, хөрмәтле Клара апа, килгән кунаклар! Һәр милләтнең дә үзе горурланырлык шәхесләре бар. Без әле генә татар әдәбиятының йөзек кашы булган, шигърияттә якты йолдыз булып балкыган, үзенең киң кырлы иҗаты белән меңнәрчә китап сөючеләрнең күңелен яулаган якташыбыз Клара Гариф кызы Булатованың «Шушы яктан, шушы туфрактан без» шигыренә язылган җырны тыңлап үттек. Клара Булатова үзенең укучысын үзенчәлекле тавышы, матур сүз осталыгы көчле булуы белән әсир итә. Тирәндә яткан күренешләрне җиңел итеп, гади итеп әйтә белүе – бу әдибәнең табигый халәте. Шигырь юллары аның, ташны ярып чыккан чишмә кебек, үзләреннән-үзләре туалар. Клара апа үзе дә: «Минем тормыш һәм иҗат юлым икесе бергә башлангандыр, дип беләм: шигырьләрне үзем белә башлаганнан бирле чыгарам, нәкъ шулай “чыгарам”, ә “язам” түгел», – дип аңлата.

Бүген без күпкырлы талант иясе Укытучылар гаиләсендә тәрбия алып, гомерен шушы һөнәргә багышлап, бүгенге көнгәчә мөгаллимәлегенә тугры булып калучы чичән-шагыйрә Клара Булатовага багышланган очрашу кичәсенә җыелдык. Аның тормыш һәм иҗат юлы белән якыннанрак танышып китик.

**1 нче алып баручы:** 1936 елның 18 мартында Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туган. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа күрә Кларага бала чактан ук әти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күчеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. Ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә, өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый.

**2 нче алып баручы:** Ләке мәктәбен ул «бик яхшы» билгеләренә генә тәмамлый. Чыгарылыш җыелышында мәктәпнең яңа директоры Митрофанов абый: «Отличниклар өчәр метр күлмәклекләр белән бүләкләнә», – дип сөендерә. Ләкин «әллә акчасы булмый, әллә оныта...». Клара апа ул вакыйганы болай дип искә ала: «Сарманга килеп, 8 нче класста укый башлагач, мин тоттым да аңа шигъри калыпта ачык хат яздым:

...Биргән вәгъдә үтәлергә тиеш!
Без әле дә өмет итәбез.
Июль, август, сентябрь үтте –
Октябрьдә бүләк көтәбез!

Сентябрь аенда ул шигырь район газетасында басылып та чыкты. Бусы белән мин бер атуда ике генә түгел, төп-төгәл өч куян алдым: бердән, шушы шигырь чыккан газета кайтуга, директор абый, култык астына күлмәклек салынган төргәк кыстырып, безгә кунакка килде. Икенчедән, миңа ул шигырь өчен редакциядән 4 сум 20 тиен гонорар түләделәр. Мин ул акчага үземә бер чүәк, сеңлем Альбинага бер ташкурчак, калганына 200 гр карамель алдым. Өченчедән, шуннан бирле мине «безнең шагыйрә» дип атадылар һәм шуннан бирле мин шигырьләр язам».

**1 нче алып баручы:** Урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыга. Шул ук елның көзеннән К. Булатова хезмәт юлын башлый.

**2 нче алып баручы:** Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч классларда балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәттәге көнкүреш комбинатында кассир, «Төзүчеләр» клубында

оештыручы була. 1962-1965 елларда ул яңадан мәктәптә – Әлмәт районының Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта.

**1 нче алып баручы:**- Клара Булатованың шигъри иҗаты да нәкъ шул чорда тернәкләнеп китә. Әле мәктәп елларында ук аерым шигырьләре матбугатта күренгән яшь шагыйрә актив рәвештә Әлмәттәге әдәби түгәрәккә йөри, һәм 1956 елдан башлап «Татарстан яшьләре», «Совет Татарстаны» газеталарында «Пионер», «Азат хатын», «Совет әдәбияты» журналларында аның күп кенә шигырьләре дөнья күрә. Бераздан аерым шигъри цикллары «Үсү юлы», «Идел» альманахы, «Яшь үрентеләр» кебек күмәк җыентыкларда басыла.

**2 нче алып баручы:** 1965-1969 елларда К. Булатова В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам иттерә. Шагыйрәнең исеме тәнкыйтьтә җылы сүз белән телгә алына башлый. 1967 елда «Язлар алда» исемле мөстәкыйль китабы – лирик шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

**1 нче алып баручы:** Клара Булатованың укытучы гаиләсендә тәрбияләнеп, ата-ана һөнәренә тугры булып, гомерен шуңа багышлавы, иҗатында укытучы шәхесен олылавы бер дә гаҗәп түгел. Укытучылык аңа кан белән бирелгән, ана сөте белән күчкән, гаилә тәрбиясе белән сеңгән.

Мин синнән дәрес алмадым,
Аз гына соңга калдым.
Шулай да тормыш сабагын
Мин башлап синнән алдым.
Син башлап хәреф өйрәттең,
Әлифен, яңалифен.
Тукайлы, җырлы, шигырьле
Дөньяга әйдәп керттең, –

дип яза шагыйрә әнисе – остазы турында.

**2 нче алып баручы:** Көзге кыңгырауны көткән август аенда үзе сорап сугышка киткән һәм анда дүрт ел көрәшеп җиңү алып кайтып, укытучылык эшен дәвам иткән әтисе истәлегенә менә мондый юллар бар:

Үзең әле байтак дәресләргә шинель киеп йөрдең,
Мин, нарасый, синнән күзләремне ала алмый идем.
Укытучы-солдат! Үз постыңда үтте һәрбер көнең...
Мин сайладым, әти, синең юлны һәм үкенмим.

**1 нче алып баручы:** Университетны тәмамлаганнан соң К. Булатова Әлмәт районының Яңа Кәшер урта мәктәбенә тел әдәбият укытучысы булып килә. 10 ел татар гимназиясендә укыта. 8 елдан артык Әлмәт муниципаль институтында булачак татар теле һәм әдәбияты укытучыларына әдәбият дәресләре бирә. Тәҗрибәле укытучы буларак, 1978 елда аңа РСФСР Мәгариф министрлыгы тарафыннан «Укытучы–методист» дигән мактаулы исем бирелә. Татар җанлы, тынгы белмәс Клара апа 10 еллап «Нур» телерадиокомпаниясендә журналист булып эшли. Аның алып барган «Җомга» тапшыруын татар яшьләре зур кызыксыну белән көтеп алалар.

**2 нче алыпбаручы:** Җитмешенче елларда шагыйрә тагын берничә шигырь җыентыгы чыгарды. Аның бер бәйләм шигырьләре русчага тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә «Детская литература» нәшриятында чыккан «Песня, мечта и любовь» («Җыр, хыял һәм мәхәббәт») исемле күмәк җыентыкка да кертелгән.

**1 нче алып баручы:** Шагыйрәнең 20 елдан артык иҗат эшчәнлеген чагылдырган шигырьләре 1981 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Гел кояшка карап» исемле китабында урын алган. 1993 елда Клара Булатованың «Миләш кагы» исемле чираттагы шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

**2 нче алып баручы:** Шагыйрәнең шигырьләре төрле рухта язылган. Ул шигырьләрендә канатлы, хыялый яшьлегенә мөрәҗәгать итә, мавыктыргыч мәктәп атмосферасын безгә аеруча якын романтик кысаларда гәүдәләндереп бирә.

**1 нче алып баручы:** Шагыйрә дөньяга укытучы күзләре белән бага, әйләнә-тирәне укытучы бизмәне белән бәяли, хуплый, кире кага. Аның гади генә сүзләрдән тезеп язылган юлларында мөгаллимә шәхесенең күңел тирәнлеге, үз хезмәтенә мөкиббәнлеге, иманы ярылып ята.

**«Укытучы бәхете»** шигыре укыла.

**2 нче алып баручы:** Ягымлылык, һәр укучыны үз баласыдай якын күрү һәм нечкә шагыйранә юллар белән шушы тойгыны укучы күңеленә җиткерү – Клара Булатованың иҗат үзенчәлеге, шигъри почеркы.

**«Укытучы апаң йокламаган», «Алтынчы класстагылар», «Ә тормыш, тормыш матур ул»** шигырьләре укыла.

**1 нче алып баручы:** К. Булатова – 1970 елдан СССР Язучылар союзы члены. Рафаэль Төхвәтуллин, Саҗидә Сөләйманова, Габдулла Тукай исемендәге премияләр лауреаты.

**2 нче алып баручы:** Ләкин шигырьләренең зур күпчелеге туган якка мәхәббәт белән өретелгәннәр. Шигъри табигатьле Сарман яклары, илһамлы, дәртле Әлмәт туфрагы шагыйрә иҗатына үзенчәлекле бер әдәби җирлек булып килеп кергән.

Туган ягым, кыр ягым,
Игеннәр уңар ягым.
Синдәгедәй нурлы таңнар,
Кай җирләрдә бар тагын, Сарманым?

**1 нче алып баручы:** Шагыйрәне нинди генә уйлар борчымасын, иң башта ул рухи этәрелешне туган як табигатеннән ала. Хыялларга канат биргән туган як тойгысы аның шигырьләренең буеннан-буена килә. «Сарманым», «Татарстан, бәхет җырым син», «Шушы яктан, шушы туфрактан без», «Туган җиремә», «Дөньяларның бигрәк матур чагы», «Печән өсте», «Безнең як шигырьләре» – нәкъ әнә шундый шигырьләрдән. Сөенечләрнең башы туган туфракта булган кебек, борчу-сагышлары да аның нәкъ шушы җирдә.

**«Татарстан, бәхет җырым син»** шигыре укыла.

**2 нче алып баручы:** Әлеге шигъри юллар шагыйрәнең актив тормыш позициясен бар тулылыгында чагылдыралар. Иң көчле җырлар бары туган якта гына туа ала. Туган ягыннан аерылган кеше – канатсыз кош ул. Монда аның таяныр ноктасы, ышанычлы терәге.

**Укытучы:** Ярты гасырдан артык гомерен балалар тәрбияләүгә багышлаган Клара апаның иҗаты кеше күңелен җырлата да, елата да торган, иң мөһиме, уйландыра, җанны-рухны чистарта, өмет яктылыгын сакларга өйрәтә торган итагатьле тойгылар тупланган китаплары белән бай.

**Клара апа, иҗатыгызда чагылмаган юнәлеш, әйтергә теләп тә, каләм очына эләгә алмыйча калган темаларыгыз бармы?** (Шагыйрәгә сүз бирелә)

**Укучыларның сораулары.**

**1 нче алып баручы:**

Үзе бәхет – янып яши алу,
Янып эшләү, эштән куану.
Үзең өчен, илең өчен кирәк,
Кешеләр өчен кирәк бу яну.

Хөрмәтле Клара апа! Менә шушы юлларда язганча, бу изге гамәлегездән туктамыйча, янып эшләргә, янып яшәргә язсын Сезгә! Иҗат чишмәгез сулмасын, саекмасын, әле озак еллар кешеләргә наз өләшүегезне телибез, сезнең яңа тылсымлы иҗат җимешләрегезне көтеп калабыз.

## К.Булатова. «Шушы яктан, шушы туфрактан без»

Чернова Ирина Григорьевна, Сарсаз-Баграж төп гомуми белем мәктәбенең
татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Зәй районы

| **Тема** | К.Булатова «Шушы яктан, шушы туфрактан без» |
|---|---|
| **Максат** | 1. Шигырьнең эчтәлеген анализ нәтиҗәсендә ачыклау;<br>2. Укучыларның шигырьнең эчтәлеген хәтерләп, эзлекле һәм мисаллар белән дәлилләп сөйләү күнекмәләрен үстерү. |

| | |
|---|---|
| | 3. Укучыларны тиз һәм йөгерек укырга гадәтләндерү. Укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклау, дөрес тавыш төсмерләре (тавыш көче, темпы) белән укырга өйрәтү.<br>4. Туган якка карата мәхәббәт, кешелеклелек, шәфкатьлелек кебек сыйфатлар тәрбияләү. |
| **Бурыч** | Укучыларның фикерләү активлыгын, сөйләм телен үстерү.<br>Укучыларда УУГ (танып белү, регулятив, коммуникатив, шәхескә кагылышлы) формалаштыру. |
| **УУЭ** | *Шәхескә кагылышлы УУГ:*<br>- укучының башкарган эшенә җаваплылык хисен арттыру.<br>*Регулятив УУГ:*<br>- хәл ителгән һәм хәл ителергә тиешлене чагыштырып, уку бурычларын кую;<br>- максатны гамәлгә ашыру чараларын сайлап алу һәм аларны куллану;<br>-бәяләү.<br>*Танып белү УУГ:*<br>- тиешле мәгълүматны табу һәм аерып алу ;<br>-төрле рәвештә бирелгән мәгълүматны кабул итү һәм укыганны анализлау.<br>*Коммуникатив УУГ:*<br>- башкаларның сөйләмен ишетү һәм тыңлау;<br>- үз фикерләреңә ышандыра белү;<br>- иптәшеңне тыңлап, фикереңне тулы һәм аңлаешлы итеп әйтеп бирә белү. |
| **Төп төшенчәләр** | Сюжет, жанр үзенчәлеге, төп герой, әсәр эчтәлеге. |
| **Предметара бәйләнеш** | Татар теле, әхлак тәрбиясе |
| **Төп ресурслар**<br><br>**Өстәмә ресурслар** | Г.М. Сафиуллина, Ф.Ф. Хәсәнова, Ә.Г. Мөхәммәтҗанова, Әдәби уку. 4 нче сыйныф: Туган телдә (татар телендә) башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек.<br>*Техник чаралар:*<br>Компьютер, экран, проектор, презентация. |
| **Эшчәнлекне оештыру формасы** | Фронталь, индивидуаль, парлап, төркемнәрдә эш. |

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Көтелгән нәтиҗә** |
|---|---|---|---|
| **1 этап. Оештыру өлеше.**<br>***Максат: дәрестә укучылар белән уңай психологик халәт тудыру*** | Хәерле көн, укучылар! Әйдәгез күңелдән, йөрәгебездән чыккан иң изге теләкләребезне бер-беребезгә телик. «Йөрәктән чыккан йөрәккә барып җитә», – диелә татар халык әйтемендә. Бер-беребезгә карап, елмайыйк, бүлмәбез шатлык хисе белән тулсын.<br>Укучылар, әйтегез әле, бер-берегезгә нинди теләкләр теләдегез?<br>Мин сезгә уңышлар | *Укучылар кулларны-кулга тотынышалар, күңелдән генә бер-берсенә изге теләкләр телиләр. Бер-берсенә карап елмаялар.*<br><br>*Берничә укучы теләкләрне кычкырып әйтәләр.* | Коммуникатив. Иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү гамәле. Укучылар бер-берсенә теләкләр теләп уңай атмосфера тудыралар.<br>Шәхси. Яхшы укучы сыйфатын аңлау. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | телим. Дәрестә игътибарлы булыгыз, сыйныфташыгызга ярдәм итегез, актив катнашыгыз.<br>Дәрестә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре *(1.Укытучы сөйләвен игътибар белән тыңла. 2. Иптәшеңне бүлдермә, тыңлап бетер! 3.Урыннан кычкырма, кулыңны күтәреп кенә җавап бир! 4.Җавабың төгәл һәм аңлаешлы булсын!)*искә төшерелә, аларның ни өчен кирәклеге кабатлана. | | |
| ***2 этап. Белемнәрне актуальләштерү. Максат**: алдагы дәрестә алган белемнәрне искә төшерү.* | Укучылар, үткән дәрестә без ниләр эшләдек? | Фронталь эш оештыру. Л.Ихсанованың «Шомырт чәчәкләре ак кына» әсәренең эчтәлеген сөйләү | Регулятив (укучылар тарафыннан белгән күнекмәләрне үзара бәйләү). |
| **3 этап. Мотивация (эшкә кызыксыну) тудыру.**<br>***Максат:*** Туган якка карата мәхәббәт, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлек, гаделлек, игътибарлы мөнәсәбәт кебек сыйфатлар тәрбияләү. | Туган як турында, шәфкатьлелек, мәрхәмәтлек, гаделлек, игътибарлы мөнәсәбәт кебек сыйфатлар турында сөйләшү. | *Тормыш ситуацияләреннән мисаллар белән нигезләнгән укучыларның җаваплары тыңлана* | *Коммуникатив:*<br>- башкаларның сөйләвен тыңлау һәм аңлау;<br>- үз фикерләренә ышандыра белү. |
| **4 этап. Уку мәсьәләсе кую.**<br>**Максат:** ***Дәрескә максат кую***(белгәннәр нигезендә ачыклап бу дәрестә үзләштерелергә тиешле уку мәсьәләсе кую).<br><br>Максат: музыканы күзаллау, фикерләреңне әйтә алу | Биремнең үтәлешенә контроль булдыру. | Рәис Нәгыймовның Клара Булатова шигыренә язган «Шушы яктан, шушы туфрактан без» җырының музыкасын тыңлау.<br>- Балалар, сезнең күз алдыгызга ниләр килде? Укучыларның фикерләрен тыңлау. | *Метапредмет УУГ регулятив:*<br>- дәреснең максатын билгеләү, аңа формулировка ясау;<br>- укытучы ярдәмендә дәрестә үз эшчәнлегеңне планлаштыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | **Физминутка.** | |
| **5 этап. Яңа материалны аңлату.**<br>**Максат:** Укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклау, дөрес тавыш төсмерләре (тавыш көче, темпы) белән укырга өйрәтү | К.Булатованың «Шушы яктан, шушы туфрактан без» әсәре белән таныштыру.<br><br>Шигырьнең эчтәлеген укучыларга дөрес дикция, аһәң белән җиткерү. | Кычкырып уку. Абзацлап кычкырып уку | *Шәхси УУГ:*<br>- укучының башкарган эшенә җаваплылык хисен арттыру;<br>-парларда һәм төркемнәрдә эшли белү.<br>*Регулятив УУГ:*<br>- уку бурычларын кую;<br>- максатны гамәлгә ашыру чараларын сайлап алу һәм аларны куллану.<br>*Танып белү УУГ:*<br>- тиешле мәгълүматны табу һәм аерып алу;<br>-төрле рәвештә бирелгән мәгълүматны кабул итү һәм укыганны анализлау.<br>*Коммуникатив УУГ:*<br>- башкаларның сөйләмен ишетеп һәм тыңлап, фикереңне тулы һәм аңлаешлы итеп әйтеп бирә белү;<br>- үз фикерләреңә ышандыра белү. |
| **6 этап. Уку мәсьәләсен чишү.**<br>***Максат:*** шигырьнең эчтәлеген анализ нәтиҗәсендә табу; шигырьне аңлау өчен шартлар тудыру. | Укучыларны активлаштыру.<br><br>- Укучылар, җирле шагыйрьләрне искә төшерик әле. Нинди шагыйрьләребез, язучыларыбыз бар әле безнең?<br>- Укучылар, җирле шагыйрьләребез, язучылар арасында туган якка багышлап язган нинди шигырьләрне беләсез? | Сорау-җавап бирүдә катнашу.<br><br>- Мөдәррис Әгъләмов, Рабит Батулла, Гурий Тавлин, Никифор Тукмачев, Александр Кузьмин, Иван Глухов.<br>- Александр Кузьминның туган ягыбызга багышланган «Туган авылым – Багражым», Иван Глуховның «Туган як», Никифор | Танып-белү эшчәнлекне формалаштыру<br><br><br><br>Коммуникатив эшчәнлек. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Тукмачевның «Гомерем Питраулары» шигырьләре бар | |
| **7 этап. Рефлексия.**<br>***Максаты: Дәрестә эшләгән эшләргә нәтиҗә ясау.*** | Без бүген дәрестә Клара Булатованың «Шушы яктан, шушы туфрактан без» шигырен өйрәндек. Биремнәрне үтәү.<br>- Автор бу шигырендә нәрсәләрне күңеленә якын итә ?<br>-Туган җирен яратуын нинди сүзләр аша тыңлаучыга җиткерә? | Шәхси фикерен формалаштыра, аны дәлилли Шигырьнең эчтәлеген ачыкладык.<br>Автор фикерен таптык. Туган якны яратырга, кайда гына булсак та, туган якны онытмаска кирәклегенә төшендек.<br>Җирле шагыйрьләрнең дә туган ягыбызга багышланган шигырьләрен укыдык.<br>Әсәрне өйрәнеп шундый нәтиҗә ясадык: Туган якны бервакытта да онытмаска кирәк, чөнки һәркемнең дә туган ягы берәү генә. | *коммуникатив:*<br>- бүтәннәрнең сөйләмен тыңлау һәм аңлау;<br>-үз фикерләреңне тулы,<br>төгәл, ачык һәм аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау. |
| **8 этап.**<br>**Дәрескә гомуми бәя.** | Укучылар, бүгенге дәрес темасын үзләштерүегез буенча билгеләр куюыгызны сорыйм.<br>Билгеләр саны ачыклана.<br>Укучылар белән килешенгән (укытучы һәм укучы килешкән) билгеләр көндәлекләргә һәм журналга куела. | Укучылар гомуми билге куялар.<br><br>Үзбәя. Үзбәя өчен критерийлар:<br>а) дәрестә нинди УМ чиштек? Ничек эшләдек?<br>Ниләр белдек? сорауларына үз фикерен тулы, төгәл, аңлаешлы итеп әйтеп бирә алса – «5»;<br>б) куелган сорауларга | *Метапредмет УУГ регулятив:*<br>- дөрес һәм ялгыш эшләнгән эшне аера белү.<br>- үзара контроль булдыру.<br>-үз эшчәнлекләрен бәяләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | җавап тулы булмаса – «4»;<br>в) дәрестә нинди УМ чиштек? Ничек эшләдек?<br>Ниләр белдек? дигән сорауларга укытучы яисә иптәше ярдәме белән генә сөйләп бирсә – «3»;<br>г) укытучы яисә иптәше ярдәме белән дә сөйләп бирә алмаса – «2». | |
| **9 этап. Өй эше бирү** | Өй эшен сайлау мөмкинлеге бар.<br>Шигырьне сәнгатьле итеп укырга.<br>Җирле шагыйрьләрнең шигырьләрен укырга һәм алып килергә. | | *Метапредмет(УУГ) регулятив:*<br>-үз эшчәнлегең белән идарә итү, өй эшен сайлаганда дөрес карар кабул итү белү. |

**Кем булсаң да – кеше булып кал**
(шагыйрә Клара Булатованың 85 яшьлек юбилеена багышланган
әдәби-музыкаль кичә)

Латыйпова Алсу Рафаил кызы, Симакова Гөлнур Илдус кызы, Исәнбай урта гомуми
белем бирү мәктәбе укытучылары, Әгерҗе районы

**Максатлар: «**Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы» уңаеннан Республикабызда яшәп иҗат итүче талантлы шәхесләребезне барлау; Тукай премиясе лауреаты Клара Булатованың тормыш юлы, иҗаты белән таныштыру; укучыларда сәнгатьле сөйләм, сәхнәдә үз-үзеңне тоту күнекмәләрен үстерү, әдәбиятка, шигъриятка мәхәббәт тәрбияләү.
**Җиһазлар**: Клара Булатованың тормыш юлын, иҗатын сурәтләүче слайдлар, китапларыннан күргәзмә, Әлфирә Низамованың шәхси архивыннан К.Булатова белән очрашу мизгелләрен чагылдырган фотоколлаж.

**Кичә барышы**

**«Мин – шагыйрә» шигыре** (бер укучы, шагыйрә образында өстәл артына утырып, шәм яктысында, сөйли. Салмак кына көй уйнап тора. Өстәлдә шагыйрәнең куен дәфтәре, каләм..)
Мин – шагыйрә,
Мин шигырьләр язам.
Минем бакчам – шигъри түтәлләр,
Мин орлыклар гына чәчә алам,
Җыючылар булыр бүтәннәр.
Мин орлыклар гына чәчәм әле,
Чи җирлеккә, кәсле җирлектә.

Җимешен дә килер җыяр мәле,
Ирешә алса халкым ireккә.
Мин кулыма утлы корал алмам,
Мылтык тотмам, тотмам кылыч та.
Мин – шагыйрә, мин тик җырлар язам,
Җир яшәсен өчен тынычта.
Тыныч илгә хас тигезлек белән
Яшәүләре мәңге көткәннәр.
Мин шул өмет орлыкларын сибәм,
Өлгерешен җыяр бүтәннәр.

1 алып баручы. Мин – шагыйрә... Әнә шулай дия-дия, үзенә генә хас шигъри аһәңе булган, күңелләрне җырлата да, елата да, уйландыра, җанны-рухны чистарта, өмет яктылыгын сакларга өйрәтә торган, итәгатьле тойгылар тупланган әсәрләре белән шигърият күгендә мәңге балкучы йолдыз ул...

**2 алып баручы.** Әйе, сүзебез шагыйрә, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе, Рафаэль Төхвәтуллин, Сажидә Сөләйманова исемендәге премияләр лауреаты Клара Булатова турында.

**Татар эстрадасы җырчыларының Клара Булатова сүзләренә язылган җырларыннан торган видеоязма карау**

**1 алып баручы.** Күкрәгеңнән кара алтын аккан,
Илгә җырлар биргән урын син.
Беркая да китмим туган яктан,
Татарстан – бәхет җырым син!

**2 алып баручы**. Татарстан АССРның Сарман районы Татар Карамалысы авылында туып-үскән Клара Гариф кызы Булатова бәхетне үз илендә, үз туган ягында тапкан шагыйрә. Халкымның чая, батыр кызы шигырьләрендә Татарстаныбызга, туган ягына дан җырлый.

Укучылар «Туган җирем», 258 бит, «Туган як», 259 бит шигырьләрен сөйлиләр.

**Җыр «Су буенда кыяк үлән», Р. Андреев муз.**

**1 алып баручы.** Ул гади генә шагыйрә түгел. Ул – мөгаллимә-шагыйрә. 25 ел шәһәрдән авылга, 35 елдан артык авылдан шәһәргә йөреп укыткан Клара ханым. Шуңа да укытучылык хезмәте – Клара Булатова иҗатының буеннан-буена сузылган үзәк темаларның берсе.

**2 алып баручы**. Шагыйрә бу яраткан хезмәтенә бәхетенең югары бер чагылышы итеп карый:

Бәхет – шушы укучылар
Кеше булып үссәләр, – дип яза ул үзенең «Укытучы бәхете» шигырендә.

**1 алып баручы.** Балалар өчен төн йокламый дәрескә әзерләнеп утыру да – аның өчен зур бәхет:

Алда ята дәрес планнары,
Дәфтәрләре янда өелгән...
Бу юллар «Укытучы апаң йокламаган...» шигыреннән.

**2 алып баручы.** Киләчәктә сездән кемнәр чыгар?..

Кем булса да – Кеше булыгыз! – дип үз укучыларына нәсихәтен бирергә дә онытмый олы йөрәкле укытучы-шагыйрә.

Укучылар «Укытучы бәхете», «Әниемә», «Мәктәптә «урак өсте» шигырьләрен сөйлиләр.

**Җыр: «Кырга чыктым, юлга чыктым», Р. Нәгыймов муз.**

**1 алып баручы.** Сугыш чоры баласы, ир хатыны, әни... Алда әйтелгән һөнәрләре янына әлеге рольләрдә дә үзен лаеклы тота белгән шәхес бит ул Клара Булатова! Әни кеше буларак танылган шагыйрә үз улына багышлап шигырь язмый каламы соң? Клара ханым да кадерләп үстергән улы Марсның кечкенә чактагы шуклыгын да, шаянлыгын да, кызыксынучанлыгын да....шигъри юлларга сала һәм аларны нәниләр өчен «Марс китабы» җыентыгына туплап чыгара.

Укучылар «Әниемнең кызы юк бит», «Кызык инде бу бабай», «Бакчада», «Марс – уңган егет ул» «Тел белмәү» «Әни – егет» шигырьләрен сөйлиләр.

**Җыр «Солдатлар». М. Минһаҗев муз.**

**1 алып баручы.** Клара апа Булатованың һәр шигырендә якты омтылыш, кайнар хис ташкыны, ихласлылык күзгә ташлана. Аның иҗат җимешләре төрле. Кайберләрендә язгы яшь бөреләр сыман тыелгысыз эчке бер дәрт белән, беркатлы самими ышаныч белән көн-кояшка, тормыш-яшәешкә, киләчәккә-бәхеткә омтылучанлык сизелә, икенче бер шигырьләре алдында без, укучылар, мәхәббәтнең һәм, гомумән, яшьлекнең чайкалып-тирбәлеп торган шигъри –символик сурәте каршында калгандай булабыз.
**2 алып баручы.** Туган телгә, туган илгә, кешеләргә булган мәхәббәт, сөйгәненә, хезмәтенә тугрылык, намус белән яшәү, кешеләргә ярдәмчел булу һәм игелеклелек эшләү, туры сүзлелек. Бу сыйфатлар шагыйрәнең геройларына гына түгел, үзенә дә хас. Әйткән сүзендә тору, килешкәнчә һәм һәр эшне үз вакытында эшләү, киләчәк буын алдында җаваплылык тоеп яшәү – аның тормыш принцибы. Укучыларын да шуңа өнди, өндәп кенә дә калмый, аларны тәрбияли, үстерә.
**12 укучы.**
«Ул телсез, моңсыз», димәсләр
Тукайны ишеткәннәр,
«Эшсез, булдыксыз», димәсләр
Уңганны иш иткәннәр.
«Кунакчыл»,«Матур», диярләр
Илемне күргәннәре.
«Үлемсез», «Батыр» диярләр
Җәлилне белгәннәре.
Тарихны өйрән, дөнья гиз,
Юлда йөр, ничек тә син!
Юк, минем халкым турында
Начар сүз ишетмәссең! («Тарихны өйрән!» шигыре)
**1 алып баручы.** Әдипләребезнең асыл талантларын билгели торган бер үлчәү бар. Ул – аларның өлкәннәр өчен дә, нәниләр өчен дә бердәй талантлы әсәр иҗат итә алулары. Клара Булатова шундый шагыйрәләрнең берсе булуы- татар халкы өчен зур горурлык. Якташлары, укучылары, аны белгән, аның белән таныш булган һәммә кеше, яратып, зурлап, «безнең Клара апа» дип йөртәләр шагыйрәне.
**2 алып баручы.** Шундый кешеләрнең берсе – авылдашыбыз, Татарстанның һәм Удмуртиянең язучылар берлеге әгъзасы, бик күп премияләр иясе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, үзе дә 5 китап авторы булган Әлфирә апа Низамова – бүген бәйрәмебез кунагы. Клара Булатованы якыннан белгән, аның белән аралашып, дус булып яшәгән Әлфирә апабызның шагыйрә турында безгә әйтер сүзләре, аның белән очрашу мизгелләреннән алынган истәлекләре бар.
**1 алып баручы.** Сүз сезгә, Әлфирә ханым.
**Әлфирә Низамова сөйли**

**Җыр: «Кыңгырау чәчәкләре», М. Макаров муз.**

**2 алып баручы**. 50дән артык китап авторы, халкым тормышын яктырткан иҗат җимешләре: шигырьләр, поэмалар һәм проза әсәрләре язган шагыйрә Клара Булатова – чын мәгънәсендә халык шагыйре.
**1 алып баручы**. Нинди генә милләт вәкиле булмасын, бар да аны якын итә, иҗатына хөрмәт белән баш ия.
**2 алып баручы.** Шагыйрәбезнең зур юбилее Республикабызда «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы»на туры килүе дә очраклы гына түгелдер, нәкъ менә аның тел, милләт сакчысы булуына ишарәдер, мөгаен.
… Ялгышмыйм, хезмәт юлымда
Туган тел терәк дисәм:
Тел яшәсә – милләт исән,
Милләт сауда – тел исән!

**Җыр: «Шушы яктан шушы туфрактан без», Р. Нәгыймов муз.**

**Чишмәләр җыры тынмасын**

(Катнаш төркемдә сөйләм телен үстерү һәм рәсем буенча интеграль шөгыль)

Шәйдуллина Гөлнара Индүс кызы, Ләшәү Тамак мәктәбенең балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

Алдан эшчәнлек:
– авыл чишмәсе янына сәяхәт кылу;
– «Чишмә яны» макеты ясау,
– «Чишмә» шигырен уку, автор турында сөйләшү;
– Чишмә тавышы язылган язма әзерләү.
– «Кем тизрәк» хәрәкәтле уенын уйнау.

Максат. Балаларның сүз байлыгын арттыру, гади сорауларга җавап бирү теләге уяту, кабул итү сәләтен, игътибарын, хәтерен, тәрбияче күрсәтмәләрен үтәү осталыгын үстерү; логик һәм мөстәкыйль фикерләү сәләтен, чагыштыру күнекмәләрен үстерү; туган якның күренекле шәхесләре белән таныштыру аша горурлану хисе тәрбияләү; рәсемнәрне буярга, үрнәк буенча кисәргә өйрәтү.

**Эшчәнлек барышы:**

Кереш өлеш.

– Балалар, тәрәзәгә карагыз әле, кояш ничек итеп безгә елмая. Әйдәгез, без дә кояшка елмаеп күрсәтик. (Балалар кояшка карап елмаялар). Бер-беребезгә карап елмаеп алыйк. Рәхмәт, балалар, утырыгыз.

Төп өлеш.

– Балалар, без сезнең белән кичә чишмә янына барган идек. Мин сезне фотога төшердем. Әйдәгез бергәләп шул сүрәтләрне карыйбыз. Түгәрәк ясап утырыйк әле. (Түгәрәк ясап утыралар)

Чишмә янында нәрсәләр турында сөйләшкән идек әле? (Чишмә янында үзеңне тоту кагыйдәләрен кабатлыйлар)

Хәзер минем сезгәбер шигырь тыңлатасым килә:

Тау астыннан чишмә ага
Чылтыр да чылтыр.
Аның җырыннан да җирдә
Матур җыр юктыр.
Ярга тулып акмаса да
Чиста, саф сулы:
Эсседә дә, салкында да
Баса сусауны.
Янындагы үләннәр дә
Аннан дым ала,
Эше һәм җыры белән ул
Шулай данлана.

Бу шигырьгә рәссам абыегыз менә мондый рәсем ясап куйган. Матур бит, балалар? Нәкъ безнең авыл чишмәсе кебек. Димәк, чишмәләр бер-берсенә бик охшаганнар икән. Кайда гына булсак та, без аларны бердәй сакларга, пычратмаска тиеш.

Ә бу шигырь, балалар менә бу китапта язылган (Ә.Габинең шигырь җыентыгы белән таныштыру, автор турында мәгълүмат бирү).

- Балалар, менә мин чишмәбезне шушындый макет рәвешендә күрсәтергә уйлаган идем. Тик ул нишләптер бик төссез, күңелсез килеп чыкты. Безнең бурыч – чишмәбезне матурлау, аның янын тәртипкә китерү.

Проект эшләнә. Макет элементлары буяла, ташлар киселә.

**Ял моменты**.

Командалы уен оештырыла. Чишмә янындагы чүпләрне җыю. Конфет кәгазен бер команда, пластик савтыларны икенче команда чиләкләргә җыя.

Проект эшләүне дәвам итү.Чәчәк рәсемнәре ясала.

Йомгаклау.

- Балалар. Чишмә янын тәртиптә тоту җиңел эшме? Чишмә кайчан безне тәмле субелән сыйлаячак?

Ул тәртиптә булсын өчен һәрвакыт үз артыңнан җыештырырга кирәк. Ул вакыт ул һәрвакыт менә шулай җырлап торачак.

Чишмә аккан тавышлы язма ишетелә.

Шөгыль тәмам.

## Тапкырлар һәм зирәкләр ярышы

(Ф.Яхин тормышы һәм иҗаты буенча уен-ярыш)

Бәдриева Фәридә Рәис кызы, икенче санлы Җәлил мәктәбе,
Сарман районы

Максат: укучыларның Ф. Яхин тормышы, иҗаты турында күбрәк белүенә ирешү, укучыларның сорауларга тулы, дөрес җавап бирүләрен һәм уйлау, фикерләү сәләтләрен үстерү өстендә эшләү, туган якка, районның күренекле шәхесләренә карата кызыксыну уяту һәм хөрмәт тәрбияләү.

Дәрес формасы: ярыш.

Җиһазлау: мәкальләр язылган плакатлар: «Күп укыган, күп белер», «Ике тапкыр уйла, бер кат сөйлә!», «Бәхетле очрак»; шарлар, чәчәкләр, ком сәгате, визиткалар, санлы карточкалар, бүләкләр.

Метод һәм алымнар: сөйләү, уку, сорау-җавап, әңгәмә.

Ярыш барышы:

I. Оештыру.

- Исәнмесез, кадерле кунаклар, укытучылар һәм укучылар!

- Без, бүген сезнең белән «Тапкырлар һәм зирәкләр» ярышына җыелдык. Бу ярышта 3 нче сыйныфы укучылары катнаша. Алар үзләренең белемнәрен шушы ярышта сынаячаклар.

II. Актуальләштерү.

- Хәзер, һәр команда үзләре белән таныштырачаклар. «Тапкырлар» командасына сүз бирелә. (Команда девиз әйтә һәм һәр укучы үзе белән кыскача гына таныштыра.) Тапкырлар. Девиз: Тапкыр җиңәр, оттырмас, Сезгә куып тоттырмас!

- «Зирәкләр» командасына сүз бирелә.

Зирәкләр. Девиз:
Зирәк һәр җирдә кирәк,
Тик чын зирәк бик сирәк.

III. Төп өлеш.

- Менә һәр команда белән таныштык.

Ярышыбызның I турын ачып җибәрәбез. I тур «Тел чарлау» дип атала. Һәр командага сораулар бирелә. Дөрес җавап өчен 1 очко куелып барыла.

I тур «Тел чарлау».

1 нче команда өчен сораулар:

1. Ф. Яхин кайда туган? ( Дүсем авылында туган)
2. Казанда кайда укыган? (Казан дәүләт университетында)
3. Ф.Яхин нинди жанр иясе? (Шигырь, хикәяләр)
4. Әтисенең исеме? (Зәкиҗан.)
5. Ничәнче елда туган? (1961)

2 нче команда өчен сораулар:

1. Ф.Яхин кайсы районда туган (Сарман районында.)
2. Нинди фән тикшеренүләре белән шөгыльләнгән? (Тарих.)
3. Ф.Яхинның 1994 елда язган әкият-поэмасы? («Могҗизалы ел фасыллары»)
4. Ничә шигъри җыентыгы бар? (3)
5. Кайда яши? (Казан.)

- Һәр команданың җыелган очколар саны әйтелә.

II тур. «Кисмәктәге хикмәтләр».
- II тур «Кисмәктәге хикмәтләр» дип атала. Капитаннар чиратлашып кисмәктән фишка ала – бу сорауның номеры. Җавапны команда әгъзалары әзерли, 1 кеше җавап бирә. Уйларга бераз вакыт бирелә. Кисмәктәге бер сорау призлы.

Очколар саны әйтелә.

III тур «Мин – сиңа, син – миңа».
- III тур Мин – сиңа, син – миңа» дип атала. Һәр команда өйләрендә «Ф.Яхин – балаларга» темасына шигырьләр ятлап килергә тиеш иде. Бер команда икенче командага шигырь сөйлиләр.
IV тур.- Һәр команда шигырьне укый, ә икенче команда сүзсез генә аңлата, күрсәтә.
V тур «Капитаннар алга!»
- Бу тур «Капитаннар алга!» дип атала. Капитаннарга Ф. Яхин иҗаты буенча сораулар бирелә.
VI тур «Алга, алга, алга!»
- VI тур «Алга, алга, алга!» дип атала. Сораулар җиңүче командага бирүдән башлана.
Кем? Нәрсә?
IV. Йомгаклау өлеше.
- Һәр команданың очко саны әйтелә. Җиңүче команда билгеләнә. Бүләкләр тапшырыла.
- Шуның белән безнең ярышыбыз тәмам. Сау булыгыз.

**Урман читендәге имәннәр без...**

(Әзһәр Габиди иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә)

Ихсанова Халидә Мөнәвир кызы, Хөснетдинова Илмира Наил кызы, Җәлил гимназиясе укытучылары, Сарман районы

**Максат:** Ә.Габидиның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру, аның шигырьләренең бөеклеген дәлилләү; туган илгә, аның табигатенә мәхәббәт тәрбияләү;
**Сәхнә бизәлеше.** Әзһәр Габиди портреты. Аның астына эре хәрефләр белән «Урман читендәге имәннәр без... » дигән язу эленә. Ә.Габиди китапларыннан күргәзмә.
**Стенада**
«Без ул кадәр олы шәхес түгел,
Тукайныкы кадәр эз калмас;
Ләкин Сарман үзен җырга салган
Ихлас җанлы улын онытмас...» (Ә.Габиди) дип язылган плакат эленгән.

*(Салмак кына «Сарман» көе яңгырый)*

- Хәерле көн, дуслар! Бүген без якташыбыз, герой-шагыйрь Әзһәр Габиди иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичәгә җыелдык, җайлап утырыгыз. Кичәбезне башлыйбыз.
**Алып баручы.** Әзһәр Самигулла улы Габидуллин Сарман районы Чукмарлы авылында 1926 елның 25 сентябрендә туа. Сарман урта мәктәбендә белем ала. 1943 елда фронтка китә. Яраланып яу кырыннан кайткач, 1950 елда Минзәлә педагогия училищесын тәмамлый. Утыз ел буе мәктәптә балаларга татар теле һәм әдәбияты укыта. Шагыйрьнең беренче шигырьләре үк туган якка, аның табигатенең матурлыгына сокланып язылган әсәрләр.

***Алдан әзерләнгән укучы Әзһәр Габидинең«Зәңгәр тау» шигырен сөйли.***

Бормалы зәңгәр хәтфә тау
Сарман буенда бит ул.
Анда күрештек тәүге кат,
Шуңа уемда бит ул.
Бормалы зәңгәр тау буе
Чәчәк кенә, гөл генә.
Матурлыгы белән бит ул
Тирә якта бер генә.
Кайда булсам да, зәңгәр тау,

Сагынып кайтам сине.
Шат елмаеп каршы ала
Шаулы Сарманым минем...

Алып баручы. Иҗатының зур өлеше балаларга багышланган. Аның төрле елларда дөнья күргән «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Калган эшкә кар ява», «Таң сәгате», «Без – яз дуслары», «Күлдәвектә кояш көлә» китаплары яшь буынны намуслы һәм тәртипле, тырыш һәм хезмәтчән итеп тәрбияләүдә зур роль уйный.

***Алдан әзерләнгән укучы Әзһәр Габидинең «Күрәсегез килсә» шигырен сөйли.***

Җирем белән,
Туган халкым белән
Бергә тибә минем йөрәгем.
Кылган эшем белән җирне бизәү,
Янып яшәү – бөтен теләгем.
Сабан сөрсәм, ярган буразнага
Йөрәгемнең салдым җылысын,
Туфрагым үстерсен дип
Башакларның зурын-олысын.
Язын-көзен тынгы белмәдем мин,
Маңгай тирләремне тамыздым,
Шул башаклар кеше-туганымның
Түгәрәкләсен дип табынын.
Моннан соң да аның бәхете өчен
Багышланыр минем бар көчем,
Кулларымда уйнар ай урагым,
Сандалымда биер чүкечем...

Алып баручы. Әзһәр ага Габиди – күпкырлы талант иясе ул. Яшь буын, язучының әкиятләрен дә теләп укый. «Калган эшкә кар ява» әкиятенең төп герое булган Өлгер аркылы балаларда яхшы сыйфатлар тәрбияләнә. Язучы Салмакҗан үрнәгендә ялкаулыкны хурлый, кимсетә.

**«Калган эшкә кар ява» әкитен сәхнәләштерү**

**Алып баручы.**Әзһәр Сәмигулла улының иллеләп шигыренә көй язылган. Алар арасында безнең бистәбезгә багышланганын да ишетергә мөмкин:

Җырлы Сарман күкрәгендә
Калыкты яңа кала.
«Кара» алтыны белән ул
Бөтен җирдә мактала.
Эх, Җәлил каласы,
Асфальт юллар арасы.
Бертугандай яши анда
Утыз милләт баласы...

Укучылар башкаруында җыр «Җәлил», Әзһәр Габиди сүзләре, Мәгафур Йөзлебаев көе

**Алып баручы.** Ә.Габиди I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. Иҗатында батырлыкка дан җырлый торган шигырьләр бик күп.

***Алдан әзерләнгән укучы.***

Кылган эше белән үлемсезлек
Яулап алган батыр кешеләр,
Гасырлардан гасырларга күчеп,
Күңелләрдә үлми яшиләр.
Каберләре дә бит җирдә түгел,
Йөрәк түрләренә уелган,
Һәйкәлләре дә бит таштан түгел,
Күңел җылысыннан куелган.
Пуля тиеп үлми геройлар,
Мәңге тере, мәңге сау алар.

**Алып баручы**. Язучының балаларга карата мәхәббәте чиксез. «Күлдәвектә кояш көлә» дип аталган китабында аның бары тик нәниләргә атап язылган шигырьләре тупланган. Шигырьләр генә түгел, табышмаклар, шарадалар җыелган монда. Әйдәгез әле берничә шараданы чишеп алыйк.

***Алдан әзерләнгән укучы***

- Тәүге иҗегем
Бай минем суга,
Соңгы иҗегем
Үсә басуда.
Минем үземне
Һәр кеше сөя,
Шуңа, яратып,
Өстенә кия. (Күлмәк)
- Минем өч хәреф
Ява җәй көне
Чәчәк, гөлләргә
Һәм азык була
Нечкә билләргә.
Соңгы икесен
Йөртә бер елга,
Җәен-кышын да
Яшим мин шунда. (Балык)
- Нәни генә кош
Булсам да үзем,
Атым (Исемем) эчендә
Бар ике исем.
Аның тәүгесе
Сөт-каймак бирә,
Ә икенчесе
Җәй көннәрендә
Төшә чирәмгә.
Үземне бик тә
Сөя балалар.
Ясап оялар,
Каршы алалар.(Сыерчык)
- Үзем торам мин
Елга буенда,
Ә исемем йөзә
аның суында.
Мине син дөрес
Уйласаң әгәр,
Исемемне минем
Йөртер бер шәһәр.(Алабуга)

**Алып баручы**. Әзһәр ага, урын өстенә калганчы, каләмне штыкка тиңләп язды да язды. Ул 2001 елның 22 августында вафат булды. Ләкин ул халыкның, милләтнең, Сарманның газиз баласы булып калды. Моңа инану өчен шагыйрьнең менә шушы юлларын искә алу да җитәдер:

Без ул кадәр олы шәхес түгел,
Тукайныкы кадәр эз калмас;
Ләкин Сарман үзен җырга салган
Ихлас җанлы улын онытмас...
(Ә.Габиди)

Бүгенге кичәбез тәмам. Сезгә Әзһәр Габидинеке кебек көчле рух телибез. Аның китапларын укыгыз, шигырьләрен ятлагыз. Аның үрнәгендә иҗат итеп карагыз. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт, сау булыгыз!

## Вариант устного собеседования для учащихся 9-х классов (методические рекомендации с использованием материала по родной (татарской) литературе)

Садыкова Ильмира Зуфаровна, Фасхутдинова Раиля Ильдаровна,
учителя русского языка и литературы МБОУ «Джалильская СОШ№2»

Русский язык является основной дисциплиной для учащихся в средних общеобразовательных учреждениях Российской Федерации. С момента введения новой формы экзамена по русскому языку тема подготовки к устному экзамену, как допуску к ОГЭ, стала одной из самых актуальных. Обучение чтению как одному из видов речевой деятельности – важнейшая учебная задача, которую должен решать не только учитель русского языка, но и учителя других учебных дисциплин.

Наиболее существенными чертами зрелого (хорошего) чтения являются следующие: высокая скорость чтения (про себя), что обусловлено автоматизмом обработки воспринимаемого печатного материала; гибкость чтения, т.е. умение читать с разной скоростью в зависимости от речевой ситуации.

Высокая скорость и гибкость чтения являются базой (основой) формирования многих других умений, необходимых для осуществления процесса чтения. Это такие умения, как умение сосредоточить внимание на определенных вопросах содержания; предвидеть в процессе чтения то, что будет сказано дальше; определять ключевые места текста; вычленять основную мысль высказывания; отличать существенное от несущественного в воспринимаемой информации; устанавливать (и игнорировать, если это необходимо) избыточные детали информации; ставить вопросы в процессе восприятия текста; определять логику, структуру высказывания; делать выводы и формулировать их своими словами; критически оценивать полученную информацию, реагировать на нее и использовать ее в соответствующих жизненных ситуациях.

Следовательно, при обучении чтению учитель должен четко осознавать ту коммуникативную задачу, которая будет определять характер восприятия текста школьниками.

Перед учителями стоит задача – реализация работы с текстовой информацией на уроках своей предметной области. Учителям-предметникам необходимо корректировать календарно-тематического планирования с учетом обязательного введения в учебный процесс работы с текстовой информацией, разрабатывать дидактические материалы содержащего тексты для работы на уроках.

Из своего опыта хотим предложить вариант задания для подготовки к устному собеседованию по русскому языку с использованием материалов по родной литературе.

**Задание 1. Чтение текста.**

Выразительно прочитайте текст «Поэзия Клары Булатовой».

У Вас есть 2 минуты на подготовку

Поэзия – это цельное явление. Но в жизни существует понятие женская душа, мир женщины, женская логика… Поэтому в мире лирики выделяют «женскую поэзию». Интерес к этому «пласту» литературы заключен в том, что в настоящем активируется приход в литературные круги поэтов-женщин. Поэтесса Клара Булатова вошла в поэзию в конце 60-х годов прошлого века и до сегодняшнего дня является одной из своеобразных поэтесс своего времени.

Поэтесса К.Булатова родилась в 1936 году в Сармановском районе, в д. Татарское Карамалы в семье педагогов. Это сыграло большую роль в духовном развитии будущей поэтессы. Мать К.Булатовой была учительницей татарской литературы, отец же преподавал математику. Оба были влюблены в поэзию, сами занимались сочинением стихов. Таким

образом любовь к преподавательской работе, литературе и поэзии закладывается девочки еще в раннем детстве.

Веяние времени делает свое: семья переезжает из деревни в деревню. Булатовы живут в нескольких деревнях Сармановского района Татарской АССР. Таким образом, Кларе приходится обучаться в различных школах в силу частых переездов.

Скоро К.Булатова поступает учиться в Казанский государственный университет и становиться живой легендой студенческой среды. Примечательно, что в это время она является главным организатором литературного кружка.

Будучи творческой личностью, поэтессой, К.Булатова в течении сорока лет равностно отдает себя преподавательской деятельности. Она глубже чувствует все тонкости и прелести языка, его своеобразие, богатство и ценность.

В то же время К.Булатова поднимает и такие проблемы, которые одинаково касаются как мира взрослых, так и мира детей. Зачастую центральной в этом случае выступает проблема воспитания и обучения подрастающего поколения. Автор не навязывает свои взгляды, мысли и переживания, а делится ими через описания специально придуманных веселых ситуаций.

**Задание 2. Пересказ текста.**

Перескажите прочитанный Вами текст, включив в пересказ слова, взятые из той же статьи:

*К.Булатова, досканально знающая школьную жизнь и секреты преподавательской деятельности, довольно своеобразным образом поднимает актуальные проблемы своего времени. Ее поэзия богата не только образами, но и философскими размышлениями.*

Подумайте, где лучше использовать данные слова в пересказе. Вы можете использовать любые способы цитирования.

У Вас есть 1 минута на подготовку.

Внимание!

Задания 3 и 4 не связаны с заданиями 1 и 2.

Для выполнения заданий 3 и 4 Вам необходимо выбрать одну из предложенных тем беседы.

**Задание 3. Монологическое высказывание.**

**Выберите одну из предложенных тем беседы.**

Тема 1. Увлечение (на основе описания фотографии)

Тема 2. Книга, которая запомнилась мне больше всего (повествование на основе жизненного опыта)

Тема 3. Как привить любовь к родному языку? (рассуждение по поставленному вопросу)

У Вас есть 1 минута на подготовку.

Ваше высказывание должно занимать не более 3 минут.

Карточки участника собеседования

**Тема 1. Увлечение**

**Опишите фотографию**



Не забудьте рассказать:
- какими могут быть увлечения в зависимости от их тематической направленности;
· что дает человеку его увлечение;
· в чем преимущество интеллектуальных увлечений;
· опишите героев этого фотоснимка и их настроение.
**Тема 2. Книга, которая запомнилась мне больше всего**
**Расскажите о том, какая книга вам запомнилась больше всего.**
Не забудьте рассказать:
· давно ли Вы читаете;
· какова основная цель путешествия для Вас и для Вашей семьи;
· какое из произведений Вам запомнилось больше всего и почему;
· что изменилось в Вашей жизни благодаря чтению.
**Тема 3. Как привить любовь к родному языку?**
Не забудьте дать ответы на вопросы:
· Какова роль родного языка и в чем, по-вашему, заключено его богатство?
· Почему меняется отношение к родному языку?
· Что значит беречь родной язык?
**Задание 4. Диалог.**
**Во время беседы Вам будут заданы вопросы по выбранной Вами теме. Пожалуйста, дайте полные ответы на вопросы, заданные собеседником-экзаменатором.**

Карточка собеседника-экзаменатора

**Тема 1. Увлечение**
Опишите фотографию.
1) Есть ли у Вас какое-либо увлечение и в чем его привлекательность?
2) Какие необычные увлечения есть у Ваших друзей и знакомых?
3) Может ли увлечение повлиять на выбор профессии?
Карточка собеседника-экзаменатора
**Тема 2. Любимая книга**
Расскажите о вашей любимой книге.
1) Какие книги вы любите читать?
2) Есть ли книги, которые Вы бы хотели перечитать?
3) Что бы Вы порекомендовали тем, кто не любит читать книги?
Карточка собеседника-экзаменатора
**Тема 3. Как привить любовь к родному языку?**
Нужно ли бережно относиться к родному языку?
1) Как Вы понимаете выражение «бережное отношение к родному языку»?
2) Что может рассказать о человеке его язык и словарный состав?
3) Как Вы относитесь к привычке употреблять в речи слова иностранного произношения?

## Татар теле – туган телем, безгә газиз анам теле (телдән журнал)

Шәймарданова Венера Миналис кызы, Морат Рәмзи исемендәге Иске Әлмәт урта мәктәбе, Сарман районы

Максат: укучыларда туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләү, үз туган ягыңның язучы һәм шагыйрьләрен белү, иҗатлары белән танышу, нәсел шәҗәрәңне өйрәнү.

Кәримә: «Әгәр дә милләтне көчле итеп,бөек итеп күрәсең килә икән, иң элек аның көчен таны, шул милләтнең баласы булуың белән горурлан». (Туфан Миңнуллин)
Газинур: Әссәламәгаләйкем, хөрмәтле кунаклар, туган телебез сагында торучы фидакарь укытучыларыбыз! «Татар теле – туган телем, безгә газиз анам теле» исемле телдән журналыбызны тәкъдим итәбез! Аның беренче бите – «Тел дигән дәрья бар» дип атала

Беренче укучы: Туган тел ул – Ватан, туган җир, ата-ана сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә торучы бөек, изге, кадерле сүз. Аны тугач та ишетә һәм өйрәнә башлыйсың, шуңа күрә аны туган тел дип атыйлар. Ул телгә баланы башлап аның әнисе өйрәтә, шул телдә аңа бишек җырлары җырлый, иркәли, юата. Шуңа күрә халык аны ана теле дип йөртә. Әйе, кечкенәдән өйрәнелгән туган тел безнең күңелләрдә милли горурлык хисләре уята, ата-бабаларыбыз теленә мәхәббәт тәрбияли.

Икенче укучы: 21 февраль – Халыкара туган тел көне. Һәр милләт, һәр төбәк өчен бәйрәм көн бу. 1952 елның шушы көнендә Пакыстанда үзләренең бангл теленә дәүләт статусы бирүне таләп иткән 5 студент үтерелә. Шушы вакыйгадан соң, 47 ел үткәч, 1999 елда ЮНЕСКО тарафыннан 21 февраль – Халыкара туган тел көне дип игълан ителә.

Өченче укучы: «Халыкның зур байлыгы, иң кадерле рухи хәзинәсе, һичшиксез, аның теле. Халык үзенең телен, оста бакчачы кебек, яман җилләрдән, рәхимсез салкыннар куырудан саклап, мең еллар буена үстереп килгән, өзлексез баетып, матурлап, иң тирән фикерләрен, иң нечкә хисләрен дә аңлатып бирер дәрәҗәгә китергән», – диде бөек язучыбыз Гомәр ага Бәширов.

Дүртенче укучы: Татар теле! Тугач та иң кадереле кешең – әниеңнән ишетә башлаган, күп гасырлык тарихы булган, Кол Гали, Тукайлар нигез салган дөньядагы иң дәрәҗәле 14 тел исәбенә кергән тел ул! Кемнәр генә сокланмаган һәм мактау җырламаган синңа!

Үз телемдә шигырь укыйм<br>Үз телемдә сөйли алам.<br>Туган җирем,туган илем,<br>Мин бит синнән илһам алам.

Бер укучы яттан Н.Акмалның «Туган тел» шигырен сөйли.

Кәримә: Әйдәгез, икенче битебезне ачыйк.

Газинур: Журналыбызның бу бите: «Үз телемдә иҗат итәм» дип атала.

Бишенче укучы: Һәр халык өчен туган тел – иң кадерле, иң моңлы, иң назлы тел. Безне хыялланырга, җор телле һәм тапкыр булырга өйрәткән. Табышмак, мәкаль, әйтемнәребезне, моңлы җырларыбызны без туган телебез аша ишетәбез. Ә телебезгә булган мәхәббәтне без үз иҗатыбызда белдерәбез. Безнең мәктәп укучылары да каләм тибрәтергә ярата. Сүз Тимербаева Ләйсәнгә бирелә. (Шигырен укый).

Алтынчы укучы. «Нәсел-нәсәбегезне белегез, кардәшләрегезгә барыгыз, чөнки бергә яшәсәгез дә, өзелгән туганлыкта якынлык юк, еракта торсагыз да, йөрешкән туганлыкта ераклык юк» (Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисе)

Нинди хак сүзләр! Безнең мәктәпнең 5 класс укучы Садиков Муслим үз нәсел җебен төзегән, хәзер шуны тәкъдим итәр. (Садиков М. шәҗәрәсен аңлата)

Кәримә: Журналыбызның өченче битенә күчәбез. Без аны «Минем якташ язучыларым» дип атадык.

Кеше кайда гына тумасын, аның изге туган җире бар. Ул нинди югары үрләргә ирешсә дә, туган җиреннән, газиз туфрагыннан бөек була алмый. Безнең Сарман халкы, Аллаһыга шөкер, талантларга бай. Әзһәр Габиди, Дамир Гарифуллин, Мәдинә Маликова, Клара Булатова. Әле болар берничәсе генә.

(К.Булатованың «Күкләргә кара, улым» шигыре укыла).

Кәримә: Нинди матур, төпле сүзләр! Клара апа бу шигырендә бөтен балаларга үзенең алтын киңәшләрен бирә. Минем фикеремчә, шагыйрә иң мөһимне – туган телен, ана телен онытмаска куша. Ана телен яраткан, хөрмәт иткән бала анасына, туганнарына, барлык кешелеккә мәрхәмәтле булачак. Ул начарлык эшли алмаячак. Якташ шагыйрәнең барлык әсәрләре дә туган теленә, туган ягына чиксез ярату хисләре белән сугарылган. Хөрмәтле шагыйрәбезгә 18 мартта 85 яшь тула. Без Клара апаның тагын озак еллар сәламәт булып, матур шигырьләр язуын теләп калабыз.

Әгәр исән булса, күрше Каташ–Каран авылында туып-үскән Нияз Акмалга 14 февральдә 67 яшь тулыр иде.

Нияз Акмал – табигать кочагында туып-үскән шагыйрь. Ул кеше белән табигатьне, тормышны бербөтен итеп кабул итә. Бик яшьли шигырь тыңларга, язарга ярата. Ул кешелеккә гашыйк! Һәрбер шигырендә аның ихласлылыгы, эчкерсезлеге! Хәер, аны шагыйрь

дип кенә атау дөрес булмас иде. Ул – прозада да, сатирик жанрда да каләм чарлаган шәхес. Акмалның һәр язган сүзендә тормышның үзе, яшәүгә омтылыш, күңел матурлыгы күренә. Тормыштан бик иртә китсә дә, ул һаман арабызда (Н.Акмал «Туган тел турында»).
Кәримә: Зур хөрмәткә лаек, олпат якташ шагыйребез Әзһәр Габиди турында әйтмичә калырга ярамый. Авыр сугыш юлларын үткән, гомерен балалар тәрбияләүгә биргән әдипкә быел тууына 95 ел. Аның шигырьләре һәрберсе бер дәрес кебек.

(Әзһәр Габиди. «Язасы иде»)

Халкым өчен матур бер җыр
Килә язасы.
Ул җырны әле язганчы
Бар күп янасы.
Халкыбызның гимны булып
Шауласын ул җыр
Анда тулылыгы белән
Гәүдәләнсен чор.
Минем ул җыр вәхшилектән
Йолсын дөньяны.
Тазарынсын,чистарынсын
Кешелек җаны.

Изгелеккә генә булсын
Аның уйлары.
Мылтык түгел, урак тотсын,
Көчле куллары.
Ил-көн өчен багышласын
Эш-гамәлләрен.
Дус, туганлыкка күтәрсен
Ул әләмнәрен.
Эремәсен, югалтмасын,
Татарым йөзен.
Һәр урында курыкмыйча,
Нык әйтсен сүзен.

Бәлки, бу җырны язганчы
Яшәп тә булмас.
Ләкин ул җырны язмыйча
Ашкын җан тынмас.

Кәримә: «Халыкның тормыш тәҗрибәсен, фәлсәфәсен, гореф-гадәтен, шигъриятен, фәнен, тарихын, ниһаять, һәрбер халыкның булучанлыгын мең еллар буена саклап килүче бетмәс-төкәнмәс бер байлыгы бар. Ул – аның теле. Телнең шундый сокландгыч сыйфатлары, шундый гаҗәеп хасиятләре һәм куәте бар ки, уйлыйсың да хәйран каласың».

Олпат язучыбыз Гомәр ага Бәшировның сүзләре белән журналыбызның соңгы битләрен ябабыз.

## Дога яшәтә безне

(IX сыйныфта туган (татар) әдәбияты дәресе)

Хәлиуллина Г.Г., Сарман урта мәктәбенең Каташ-Каран филиалы укытучысы,
Сарман районы

Максат. Ф.Яхинның иҗат үзенчәлеге белән таныштыру; хикәянең идея-эчтәлеген ачу күнекмәләрен ныгыту; укучыларда өлкәннәргә карата кече күңеллелек, шәфкатьлелек сыйфатлары тәрбияләү.
Җиһазлау. Ф.Яхин. «Ак әбиләр догасы» әсәре.
Метод. Әңгәмә.

Дәрес барышы.

1. Компьютерда бирелгән сорауларга җавап бирү. (Казан ханлыгы чоры әдәбиятын кабатлауга компьютердан тест биремнәре үтәү)
2. Дөньяда һәркем өчен дә кадерле, изге булган кешеләр бар. Ул кадерле затлар – әти һәм әни. Алар турында без бик күп җырлар, шигырьләр сөйлибез. Ә менә аларның да әниләре булган, аларга тормыш биргән, тәрбияләп үстергән әбиләр турында алай еш уйламыйбыз. «Әбием», «Әбекәй». Нинди матур сүз! Әби – гаиләдә кадерле, хөрмәткә лаек кеше. Әбисе булган кеше тагын да бәхетлерәк. Күпне күргән, күпне кичергән әбиләр газиз ирләрен, улларын яуга озатканнар. Гомере буе аларны көтеп яшәгәннәр. Ятып калганнар рухына да, исән калганнарның иминлегенә дә дога укыганнар.
3. *В.Казыйхановның «Әбием догалар укый» шигырен бер укучы укый.*
4. <u>*Дога*</u> сүзенең эчтәлеген ачу. (Аллаһы Тәгаләдән кирәк хаҗәтеңне сорау)

5. Әнә шундый ак яулыклы, изге күңелле әбиләребез турында Фәрит Яхин «Ак әбиләр догасы» дигән хикәя язган. Сез хикәянең эчтәлеген беләсез инде.

6. *Ф.Яхинның тормышы һәм иҗат үзенчәлеген бер укучы сөйләп чыга.*

Язучы, шагыйрь һәм мөгаллим Ф.Яхин 1961 нче елда Сарман районы Дүсем авылында туган. КДУны тәмамлагач, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни эшчәнлек алып бара. Соңрак Г.Тукай музее директоры булып эшли. Бүгенге көндә Татар дәүләт гуманитар институтында укыта, филология фәннәре докторы.

Ул – әдәбият фәне, рухи мирас, әдәбият белеме өлкәләренә караган күп кенә хезмәтләр авторы да. «Пәйгамбәрләр тарихы», «Олуг пәйгамбәр», «Иман», «Ак әбиләр догасы» һәм башка хезмәтләре бар.

Хикәяләрендә балаларга үз итеп, тормыш, кичерешләр, тәэсирләр турында сөйләшергә омтыла. Геройлары көчле, кызыксынучан. Авыл тормышы, балачак, табигать, дин – төп темалары.

7. Хикәянең эчтәлеген искә төшерү.

8. - Әсәрнең жанры нинди?

- Нинди әсәрне хикәя дип атыйлар?

- Кечкенә күләмле әсәрдә ак әбиләрнең барлык сыйфатлары да ачыла. Алар нинди сыйфатлар?

- Түземлелек, сабырлык, ышану, доганың көчен күрсәтү, халык турында кайгырту.

9. Әүлия зираты, әүлия чишмәсе, зекер әйтү сүзләренең мәгънәсен ачу.

- әүлия – изге кеше, иң яхшы, гадел, кешелекле кеше; зекер – искә алу, искә төшереп әйтү, әйтеп үтү, аллаһны зурлап һәм мактап укыла торган доганың бер төре.

10. Соңгы кызыл юлны уку, идеясен ачу. Укучыларның фикерләрен тыңлау. Әсәр ни өчен шулай аталган?

11. Укучыларның әбиләре хакында язган миниатюр сочинениеләре белән танышу. (теләк буенча 2-3 укучының иҗат эшен тыңлау)

12. Өлкәннәр ункөнлеге, Хәйрия акцияләре турында искә төшерү.

13. Йомгаклау. Магнитофон язмасында «Әнкәмнең догалары» җырын тыңлау.

14. Өй эше. Киләсе класстан тыш уку дәресенә Ф.Садриевның «Таң җиле» романын укырга.

## Шушы яктан, шушы туфрактан без

(шагыйрә Клара Булатова белән очрашу кичәсе)

Салихова Рәмзия Равил кызы, Петровка завод урта гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Максат:** шагыйрә Клара Булатова белән очрашу үткәрү; аның иҗатына күзәтү ясау; укучыларда Клара Булатова иҗаты белән кызыксынучанлык, китап укырга омтылыш тәрбияләү

**Җиһазлау:** Клара Булатова китапларыннан күргәзмә, Клара Булатова турында презентация, җыр язмалары.

### Кичә барышы

**1. Алып баручы**.

Читтә йөргән чакта, сагындырып,
Керер өчен төнлә төшенә.
Алсу таңлы, биек зәңгәр күкле
Туган ягы кирәк кешегә.
Зур уңышлар яулап заманалар
Матур бәя бирсә эшенә,
Шатлыкларын уртаклашыр өчен
Туган ягы кирәк кешегә.

Әйе, безнең туган ягыбыз – Сарман ягы, җырларда җырланган сандугач сайрар ягыбыз. Сарман ягы талантларга искиткеч бай. Безнең як Илһамнары, Зөһрәләре белән мактана ала. Безнең якта туып-үсеп, канат чыгарган Аяз Гыйләҗев, Сөббух Рафиков, Әзһәр Габиди, Клара Булатова, Мәдинә Маликова, Хәниф Хәйруллиннар күренекле язучы, шагыйрьләр булдылар. Алардан алган эстафетаны Дамир Гарифуллин, Вәсимә Хәйруллина, Гөлнара Якуповалар үз кулларына алдылар. Кыскасы, Сарманда әдәбият-сәнгать дөньясы туктаусыз гөрләп тора. Әледән-әле төрле иҗади конкурслар үткәрелә, ә аларда призлы урыннар алган сәләтле яшьләребез артканнан-арта бара.

**2.** Бүген безнең мәктәптә истәлекле вакыйга. Әлмәт шәһәреннән Р.Төхфәтуллин, С.Сәләйманова, Г.Тукай премияләре лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, яраткан шагыйрәбез, якташыбыз Клара Булатова килде. Кунагыбызны түргә чакырыйк һәм тәбриклик әле.

Музыка уйный һәм алкышлар астында шагыйрә түргә уза.

Ә хәзер укучыларны К.Булатова белән якынрак таныштыру өчен сүзне китапханәчебезгә бирәбез.

Китапханәче К. Булатова белән таныштырганда презентация дә күрсәтелә.

Клара Булатова исеме шигърият яратучыларга күптәннән таныш. Үз гомерендә 20дән артык китап чыгырган, 50дән артык шигыре көйгә салынган шагыйрә ул бүген. Укучылар игътибарына К.Булатова чыгарган җыентыкларга карагыз.

Ә хәзер шагыйрәбезнең шигырьләрен тыңлап алыйк.«Туган җиремә» шигыре укыла.

Клара Булатова шигърияткә илленче елларның азагы – 60 нчы елларның башында, үз заманының ашкынулы уй-кичерешләрен, оптимистик күтәренке рухын чагылдырган яшьлек, Мәхәббәт җырчысы буларак килеп керә. Шигырьләрендәге якты омтылыш, кайнар хис ташкыны, ихласлылык – киләчәккә шагыйрә иҗатының төп поэтик эзләнү кыйбласына әверелә:

Күз ачарга төнен теләмәгән
Яшь бүреләр иртән барсы да
Гел кояшка карап,
Гел кояшка карап,
Гел кояшка карап ачыла.

Әлеге юллар «Гел кояшка карап ...» шигыреннән...

Шагыйрәнең беренче иҗат чорында язган әсәрләрен шартлы төстә «Яз шигырьләре» дип атау урынлы булыр кебек. 1967 елда чыккан бер мөстәкыйль китабының исеме дә «Язлар алда» дип исемләнгән. Ул шигырьләрдә автор язгы яшь бөреләр сыман тыелгысыз экче бер дәрт белән, беркатлы самими ышаныч белән көн-кояшка, тормыш-яшәешкә, киләчәк бәхеткә омтыла:

Комсызланып сулыйм таң һавасын,
Комсызланып, йотылып җыр тыңлыйм ...

(«Комсызлык» шигыре)

Клара Булатова үзе туып үскән төбәккә багышлап бик күп күп шигырьләр язды: «Сарманым», «Туган җиремә», «Шушы яктан, шушы туфрактан без». Бу шигырьләрдә канатлы яшьлек ашкынуы һәм изге туган җир туфрагы бербөтенгә әверелеп яши: туган якның агымсулары кебек лирик героебызның йөрәге ярсу, туган як таңнары кебек аның йөзе алсу, күкләрнең зәңгәрлеге – күзләрендә, кырларның иркенлеге – күңелендә ...

**Җыр: «Шушы яктан, шушы туфрактан без»** (К.Булатова сүзләре, Фәрит Хатыйпов музыкасы)

Шагыйрәнең 2 нче китабы «Һәрвакыт янымда» дип атала. Ул аны 1968 елда 112 битлек булып 4000 данә чыгара.

1972 елда чыккан 3 нче китабын К.Булатова «Җәйләр җитсә» исеме белән бастыра. Бу чор иҗатына караган шигырьләрендә без лирик героинябызның чын-чынлап экче өлгерүен: хис-кичерешләрнең тагын да кайнарлана баруын күрәбез.

Шагыйрәнең туган төбәгенә, әти-әнисенә, үзенең ана булу тойгыларын үзәккә куеп язган шигырьләре дә игътибарга лаек. Хәзер без сезгә К.Булатованың «Ана шатлыгы» дигән шигырен тәкъдим итәбез. **(«Ана шатлыгы» шигыре укыла)**

**Сорау.** Атлас Гафиятов: «Бездә Балачак, Яшьлек иленә гомерләре буе тугры калган кешеләр бар. К.Булатова – Шагыйрә дә, Укытучы да, Ана да», – дип яза. Хөрмәтле, Клара ханым, гаиләгез белән таныштырып китсәгез иде. (Сүз Клара Булатовага бирелә.)

Клара Булатова – укытучы шагыйрә. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар булганнар. Клара апаны Түбән Ләшәү һәм Ләке авылы укучылары, Әлмәт районының Колшәрип, Яңа Кәшер урта мәктәпләрендә белем алучылар, Әлмәт каласы мәктәпләре һәм югары уку йортлары бүген дә сагынып һәм сокланып искә ала.

**«Укытучы бәхете» шигыре укыла.**

Укытучылык хезмәте – Клара Булатова иҗатының буеннан-буена сузылган үзәк темаларның берсе. Ул 40 елдан артык балаларга белем бирә, укучыларында матурлыкны, туган телебезгә мәхәббәт тәрбияли. Ә шигырьләрендә яшьлек оптимизмы, тормышны ихлас ярату, аның киләчәгенә ышану, самими кичерешләр.

Укытучы күңеле һәрчак балачакта. Шагыйрәнең шигырьләре – моның ачык мисалы. Нәниләрне тыңлагач, моның шулай булуын үзегез дә тоярсыз. Сүзне нәниләргә бирәбез.

К.Булатованың балалар өчен язган шигырьләре сөйләнә.

**Җыр: «Су буенда кыяк үлән»**

Клара Булатова шигырьләре хис-кичерешләргә бик бай, алардан моң агыла. Шуның өчен дә шагыйрә матур-матур җырлар авторы буларак танылды. Җырларда туган як, мәхәббәт темасы үзәк урынны алып тора. Филология фәннәре кандидаты Рәфкать Шаһиев: «Төбәгебезнең асылын ачкан «Шушы яктан, шушы туфрактан без» дигән әсәр өчен генә дә аны җырчы-шагыйрә атап булыр иде. ә аның андый әсәрләре санап бетергесез», – ди.

Ә хәзер «Шушы яктан, шушы туфрактан без» шигыренә салынган 2 нче көй варианты тыңларбыз.

**«Шушы яктан, шушы туфрактан без» җыры яңгырый. Рәис Нәгыймов көе**

Нефтьчеләр башкаласында яшәүчеләр өчен Клара ханым Булатова – дистә еллар дәвамында милләтебезгә генә хас иң яхшы сыйфатларны эченә сыйдырган күркәм, тыйнак, тирән эчтәлекле «Җомга» тапшыруының сценарий авторы да.

**Сорау.** Әйтегез әле, бу тапшыруны эшләү идеясе кайчан һәм ни сәбәпле барлыкка килде?

**Сорау.** Хәсән Туфан 1959 елда Геннадий Паушкинның берничә шигырен тәрҗемә итәргә кушкач, Сез берничә шигырен татарчага тәрҗемә итәсез. Аны К.Табул дип куясыз. К.Табул псевдонимы нәрсәне аңлата? Шул еллардан соң тагын тәрҗемә белән шөгыльләнергә туры килдеме?

**Сорау.** Клара ханым, үз гомерегездә сез бик күп эшләр башкаргансыз. Әйтегез әле, эшләп карамаган нинди эшләр калды? Яңадан яши башласагыз, мин башкача эшләр идем, дигән уй бармы?

**Сорау.** Клара ханым, сезнең иҗатны шартлы рәвештә 2 чорга бүлеп карасак, 1 нчесендә сезнең лирик герой романтик, тормышны ярата, соңгысында лирик шәхеснең илдә барган үзгәрешләргә, укытучы горурлыгын таптаган сәясәткә, кичәге укучыларның бүгенге әхлаксызлыгына карата җан әрнүен күрәсең.

Укытучы исемен гомере буе горур йөрткән лирик шәхес хәзер:

Горурлана алмыйм Укытучы
Дигән атым белән…
Горурлана алмыйм үз теленнән
Бизгән халкым белән, – ди. Мондый рухтагы шигырьләрегез «Әрнү» дигән җыентыгыгызда урын алган. Укытучыларга һәм алар укыткан укучыларга сез нинди теләкләр әйтер идегез?

**Сораулар:**

1. Х.Туфан белән 1 нче мәртәбә кайчан һәм ничек очраштыгыз? (1957 елның декабрендә Казанда яшь язучылар семинарында)
2. «Син – Искәндәр, мин Тәнәкә идем» шигырен Х.Туфанга багышлап язгансыз. Ни өчен Х.Туфан сезгә Тәнәкә дип эндәшә иде?
3. Х.Туфан белән икегез арасында язылган хатлар арасында Х.Туфанның мондый юллары бар:

Якын да син миңа,

Ерак та, сөеклем.
Тәнәкәм, Тәнәкәм!
Ак чәчәк шикеллем!

Бу шигырьдә остаз белән шәкерт арасында була торган ихтирам хисе түгел, ә чын мәхәббәт, сөю хисе ярылып ята. Ни өчен Сез бергә була алмадыгыз? (1959 елның көзеннән соң аерылышалар)

Әлмәт шәһәрендә яшәп иҗат итүче Р.Төхфәтуллин, С.Сөләйманова, Г.Тукай исемендәге премияләр лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, яраткан шагыйрәбез, якташыбыз Клара Булатова белән очрашу кичәбез ахырына якынлашып килә. Без аңа ныклы сәламәтлек, озын гомер телибез.

Моңа кадәр янып-көеп яшәде, калган гомере дә шигърият, туган тел, милләт, табигате өчен янып-көеп үтсен! Безне, укучыларны, әледән-әле матур шигырьләр белән, җырлар белән сөендерергә язсын! Бик зур рәхмәт Сезгә!

Клара Булатовага чәчәк бәйләмнәре бүләк итү белән кичә тәмамлана.

## Always remember (Не забыть никогда…) из произведений К.Булатовой (технологическая карта урока)

Мусина Гузель Фаритовна, Юнусова Резеда Фадитовна, учителя английского языка
МБОУ «Джалильская СОШ №2», Сармановский район

**Тема: Always remember (Не забыть никогда…) из произведений К.Булатовой**
**Класс: 9**
**Цели деятельности учителя:**
Организовать деятельность учащихся по поиску и обработке информации; обобщению способов действия; постановке цели урока, расширить знания учеников за счет включения новых определений и описаний.
**Тип урока:** урок открытия новых знаний
**Планируемые образовательные результаты:**
*Предметные:*
**Ученик научится:**
- работать с адаптированным текстом литературного произведения;
- использовать языковые средства текста в устной монологической и диалогической речи;
- группировать полученные сведения по изученному тексту.

**Ученик получит возможность научиться**: делать литературный перевод на основе прочитанного.

*Личностные:* умение вести диалог на основе взаимного уважения и принятия другой стороны; умение осмыслить ошибки и устранить ошибки, объяснять самостоятельно - изученные грамматические правила и подбирать конкретные примеры.

*Метапредметные:*

-*Регулятивные УУД:* Определение и прогнозирование трудностей при работе с текстовой информацией, способность осуществлять самокоррекцию и самопроверку устного сообщения; **умение продуктивно общаться и взаимодействовать** в процессе совместной деятельности, учитывать позиции других участников деятельности, эффективно разрешать конфликты, адекватно самостоятельно оценивать правильность выполнения действия и вносить необходимые коррективы.

-*Коммуникативные УУД*: умение читать и понимать адаптированный текст; читать с пониманием основной идеи и с извлечением специальной информации; логично строить развернутое высказывание; подбирать синонимы, заменять слова; умение соблюдать формат устного высказывания; умение осознанно строить речевое высказывание в устной форме в соответствии со стилем общения и нормами языка; умение слушать собеседника и проявлять уважительное отношение к нему, работать в сотрудничестве, уметь литературно переводить текст.

-*Познавательные УУД:* умениестроить логическое рассуждение (учебно-познавательная компетенция); умение работать с печатным текстом; умение выделять необходимую информацию; использовать приобретенные знания в практической деятельности;

**Используемые методы и технологии обучения:**

Технологии уровневой дифференциации, здоровьесберегающие технологии, игровые технологии, технология развития критического мышления

**Наглядно-демонстрационный материал:**

Интерактивная доска, портрет К. Булатовой

**Основные понятия, с которыми идет работа на уроке:**

Синквейн, литературный перевод, «мозговой штурм»

| Этап урока | Действия учителя | Действия учеников |
|---|---|---|
| 1) Организационный момент | Приветствие. | Приветствие. |
| 2) Постановка цели и задач урока. Мотивация учебной деятельности учащихся. | Прием «мозговой штурм»:<br>На доске написано слово *war* (война)<br>- Учитель просит учащихся назвать как можно больше слов по данной тематике и записывает примеры на доске (схема).<br>- На экран выводится фото Клары Булатовой и небольшая информация о ее биографии.<br>Задаетсявопрос:<br>*What is the theme of the lesson?*<br>*The theme of our lesson is Klara Bulatova and her works about war.*<br><br>Учитель подводит учащихся к постановке целей урока применяя вопросно-ответную работу. *What do you expect to learn at this lesson?* | Предлагаютсвоиварианты: *death, enemy, victory, kill, cry, sadness.*<br><br>Изучают информацию о поэте.<br><br>Определяют тему урока<br><br>*I want to know whom did she write about in her works.*<br>*I would like to get more information about her family.* |
| 3) Открытие новых знаний. | Работа над стихотворением Булатовой К.Г.<br>Снятие лексических трудностей (на экране фразы с переводом)<br>*At dawn – нарассвете*<br>*Long-awaited – when you wait for a long time*<br>Учитель читает текст стихотворения на английском (прил.2).<br><br>Настраивает учащихся на работу с текстом задавая вопрос и побуждая к высказыванию своего мнения:<br>*What do you think the author felt when she wrote this poem?*<br><br>Учитель просит 1 ученика прочитать оригинал стихотворения на русском языке (прил. 2).<br>Учитель дает задание на поиск в произведении слов-синонимов.<br>*Match the words in bold to their meanings. Use each one in a sentence of your own.* | Хором отрабатывают фразы.<br><br>Ученики слушают прочтение учителем стихотворения<br><br>Отвечают на вопрос учителя и предлагают свои варианты:<br>*I think she was proud of her country.*<br>*I suppose she wanted to show her joy and happiness for Soviet people.*<br><br>Находят в тексте слова синонимы и составляют письменно свои предложения с ними |

| | | |
|---|---|---|
| | 1. *Declared (announced)*<br>2. *All of a sudden (suddenly)*<br>3. *Important (significant)*<br>4. *Running (racing)*<br>5. *Motherland (homeland)*<br>6. *Terrible (hateful)* | |
| 4) Первичная проверка понимания и первичное закрепление. | Организуется беседа по уточнению и конкретизации первичных знаний.<br>*Work in groups. Translate the extract into English, give a literary translation.* | Высказывают свои предположения в группах и делают литературный перевод выделенного отрывка с русского на английский |
| 5) Закрепление изученных способов действия | Выдвигает проблему и напоминает обучающимся о необходимости применения изученных лексических единиц, контролирует выполнение работы.<br>Учитель раздает половинки пословиц о мире, родной земле и войне, напечатанных на отдельных листочках. Затем просит учеников найти вторую часть пословицы и сесть рядом с вторым учеником (данное упражнение направлено на формирование пар и зарядки для тела).<br>*Find the pair from the next row and read out the proverb.*<br>*Express your opinion about the connection of the proverb and the content of the poem.* | Ученики находят себе пару и вслух зачитывают получившиеся пословицы. Работают в парах и обсуждают связь пословицы с содержанием стихотворения. Обаученикавысказываютсвоим ысли:<br>*1. Ask not what your country can do for you, ask what you can do for your country.(This proverb is about our contribution to the victory in the war)* |
| 6) Рефлексия (подведение итогов занятия) | Подводит обучающихся к выводу о главной идее стихотворения.<br>*What is the main idea of the poem "Never forget" by K.Bulatova?*<br><br>Учитель организует работу учащихся с целью контроля и выявления степени усвоения учебного материала (метод синквейна)<br>-Существительное<br>-2 прилагательных<br>-3 глагола<br>-Фраза из 4 слов<br>-Синоним<br>Учитель проводит рефлексию деятельности на уроке (прием «Продолжи фразу»):<br>*It was interesting for me ….*<br>*Today we have discussed …* | Высказываютсвоемнение<br>*I think she wanted to underline the idea that people should always remember the importance of victory.*<br>*I suppose she wants other people be proud of Soviet soldiers.*<br>Излагают содержание учебного материала на тему изученного отрывка<br>*Victory*<br>*Great, long-awaited*<br>*Win, happen, announce*<br>*We are proud of it*<br>*Winners*<br>Формулируют свое отношение к результатам урока<br>*It was interesting for me to make a literary translation/ to learn Bulatova`s biography…*<br>*Today we have discussed the moral of the poem and the author`s feelings …* |

| | | |
|---|---|---|
| | *I have understood that…*<br>*It was difficult for me …* | *I have understood that nature is very fragile and we should take care of it…* |
| 7) Объяснение домашнего задания | Объясняетдифференцированноедомашнее задание:<br>*Your hometask is to make your own translation of the poem.*<br>*If you want to get "5" you should translate 12 lines words.*<br>*"4" – 8 lines*<br>*"3" – 4 lines.* | Задают вопросы, если есть непонятные моменты |

Приложение 1

Биография Булатовой К.Г. (The biography of Bulatova K.G.)

She was born on March 18 in the village of Tatar Karamaly in the Sarmanovsky district of the TASSR in the family of a teacher. Graduated from Kazan State University named after V. I. Ulyanov Lenin.

Lives in Almetyevsk from the first days of its foundation. She worked on construction sites, as an artistic director in the club "Builder" of the working settlement, in rural libraries. For more than thirty years, she has been actively involved in amateur art.

Klara Garifovna-poet, Honored Worker of Culture of Tatarstan, winner of the R. Tukhvatullin Prize.

She devoted all her creative activity to the glorification of the beauty of the Almetyevsk land, the works of oil workers, and the workers of the villagers. She also wrote poems about war.

Приложение 2

| Не забыть никогда! | Never Forget! |
|---|---|
| Этот день сорок пятого года<br>Позабыть разве можно когда!..<br>Долгожданное слово «победа»<br>На заре принесли провода. | This day of 1945<br>How can we ever forget ! …<br>The long- awaited word «victory»<br>Was announced at dawn on the radio. |
| В час, когда выгоняется стадо,<br>В час, когда даль туманно-светла,<br>Из райцентра в деревню нашу<br>Вдруг о празднике весть пришла. | At the time when the herd is driven out,<br>At the time when the distance is foggy-light,<br>From the regional centre to our village<br>News about the holiday came suddenly. |
| Крики, плач, поздравленья друг друга…<br>И сегодня сквозь времени тень<br>Вижу я дорогую деревню<br>В этот радостный, светлый день. | Shouts, crying, congratulations ...<br>And today after a long time<br>I see my favourite village<br>On this joyful, bright day. |
| С красной вестью от дома к дому<br>Что есть мочи летит детвора…<br>Старый-малый, смеясь и рыдая,<br>Выбегает вослед со двора. | With significant message from house to house<br>The kids are racing with all their might ...<br>The old and the young, laughing and crying,<br>Are running out after them of the yard. |
| Никогда, верно, радости большей<br>Не бывало в родной стороне!<br>Что быть может прекраснее вести:<br>«Смерть-конец ненавистной войне!» | Never such a greater joy<br>Happened i-n the home land!<br>What could be more wonderful than the news:<br>"The Death and the end of the hateful war!" |
| В час, когда выгоняется стадо, | At the time when the herd is driven out, |

| | |
|---|---|
| В час, когда даль туманно-светла,<br>Из райцентра в деревню нашу<br>Вдруг о празднике весть пришла.<br><br>Долгожданное слово «победа»<br>На заре принесли провода.<br>Этот день сорок пятого года<br>Не забыть никогда, никогда!<br>Перевод Л. Воздвиженского | At the time when the distance is foggy-light,<br>From the regional center to our village<br>News about the holiday came suddenly.<br><br>The long- awaited word «victory»<br>At dawn was announced on the radio.<br>This day of 1945<br>We will never, never forget! |

Приложение 3

1. Ask not what your country can do for you, ask what you can do for your country.
2. As long as you are ready to die for humanity, the life of your country is immortal.
3. A man without a Motherland is like a nightingale without a song.
4. To live is to serve the Motherland.

**Рәнҗемәслек булсын оныклар**

(гомере буе Сарман районының Чукмарлы авылында яшәп иҗат итүче фронтовик-шагыйрь Әзһәр ага Габидинең табигатькә багышланган шигырьләре нигезендә укучыларга экологик тәрбия бирү максатыннан төзелгән кичә эшкәртмәсе)

Г.М.Нәбиуллина, Илексаз төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Кичәнең максаты:** Әзһәр Габиди иҗаты аша табигатькә карата мәхәббәт һәм сакчыл караш тәрбияләү, шигырьләренә һәм китапларына кызыксыну уяту.

**Залның бизәлеше:** Стенада «Әзһәр Габиди» портреты, класста китап күргәзмәсе, укучылар тарафыннан ясалган рәсемнәр куела.

**1 а.б. :** Сарман ягы талантларга бай. Бүгенге көндә Шулар арасыннан балалар һәм зурлар өчен дә матур-матур шигырьләр иҗат итүче язучыбыз Әзһәр ага Габидине дә атарга була. Бүгенге дәресне якташыбыз Әзһәр ага Габиди иҗатына багышлыйбыз.

**2 а.б.** Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин 1926 елның 26 сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында урта хәлле крестьян семьясында туа. Җидееллык мәктәпне бетереп, Сарман урта мәктәбендә укып, унынчы классны тәмамлап, фронтка китә һәм, яраланып, госпитальләрдә ята. 1945 елда «Тревога» исемле фронт газетасы типографиясендә аның «Борылмалы юллардан» исемле китабы басыла.

**1 а.б.** Әзһәр ага Габиди башлыча балалар шигъриятенә хезмәт итте. Язучының бүгенге көнгә балалар өчен «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Калган эшкә кар ява», «Таң сәгате», «Без – яз дуслары», «Югалган кояш» китаплары дөнья күргән.

**2 а.б.** Әзһәр ага Габидинең шигырьләре туган як, андагы вакыйгалар, күренешләр турында. Аларның һәркайсына шагыйрь балалар күзлегеннән карап бәя бирә Ул әдәби әсәрдә табигать күренешләрен тасвирлау аша үзенең геройларының табигатькә мөнәсәбәтен, туган илгә мәхәббәтен, аның матурлыгына сокгануын тасвирлый.

**1 а.б.** Табигатьне саклау турында язылган шигырьләре укучыларда туган якка мәхәббәт, сакчыл караш тәрбияли. Кеше тормышы һәрвакыт табигать белән бәйле. Ул – кешенең сәламәтлек, туклану, гомумән, яшәеш чыганагы. Табигать дигәч, иң беренче чиратта, калын яшел урманнар, саф сулы чишмәләр, бай тарихлы елгалар, күлләр, иксез-чиксез җәелеп яткан далалар күз алдына килә. Табигать безгә азык, кием, торыр урын бирә. Кеше тормыш өчен кирәкле бар нәрсәне табигатьтән ала. Шуңа күрә табигатьне сакларга кирәк.

**2 а.б.** Табигатьне саклау – һәр кешенең изге бурычы. Язучыларыбыз, беренчеләрдән булып, табигатьне саклау турында чаң сукты. Әйләнә-тирә дөньяны, кеше сәламәтлеген, аның рухын, телен саклау аларны иң борчыган һәм дулкынландырган проблемага әйләнде.

**1 а.б.** Ә.Габидиның табигатьне саклау темасына язылган әсәрләр исемлеге бай һәм төрле. Ул үзенең шигырьләрендә җәнлекләргә, кошларга, бөҗәкләргә карата мәрхәмәтле булырга өнди, үзенең шигъри бизәкләре белән табигатьнең гүзәллеген ача. Табигатьне саклау –

милләтебезне, туган телебезне, гореф-гадәтләрне, тарихи байлыкларны саклау белән тыгыз бәйләнгән. Чөнки әдәби һәм тарихи мирас туган җиребездә барлыкка килгән. Шуңа күрә балаларны татар халкының рухи тамырлары, ерак бабаларыбызның яшәү рәвеше, һөнәрләре белән таныштыру, аларда милли горурлык тәрбияләү мөһим. Табигатьнең матурлыгын, серлелеген язучы үзенең җаны, саф күңеле, йөрәк җылысы салынган шигъри юллары белән укучы җанына, аның күңеленә салучы, ныгытучы, мәңгеләштерүче.

**2 а.б** Язучы табигать темасын үзенчә күрә, тасвирлый, укучыга төрле тел бизәкләре, сурәтләү чаралары, әдәби алымнар аша ачып бирә. Шагыйрьнең пейзажы туган туфрактан, балачагы үткән Чукмарлы авылыннан аерылгысыз. Пейзаж күп очракта сабыйлык хатирәләре аша үтеп тасвирлана. Аның туган як табигатенә балаларча мәхәббәте сизелеп тора. Туган төбәгенең гүзәллеге, зәңгәр күге, офык алсулыгы, балкып чыккан салават күпере, кояшлы яңгыры, чирәменә кунган чыгы, елгаларның көмеш сулары, җылы җилләре, хуш исле йомшак үләннәренә чиксез мәхәббәте «Туган як», «Туган җиремә», «Туган авыл», «Җәйге таң хатирәсе», «Кояшлы як» шигырьләрендә ачык чагыла.

**1 а.б.** Шагыйрьнең «Нарат», «Тополь» исемле шигырьләрендә үсеп утырган төрле-төрле агачларны күрәбез. Агачлар җырлашалар да, дусларча хәбәрләшәләр дә икән – аларны тыңлый гына, аңлый гына бел! Ә иң мөһиме – менә шул чыршы, нарат, усак, каен кебек агачлар безнең һаваны сафландыралар. Юкка гына бит урманны – табигатьнең үпкәсе, дип әйтмиләр.

**2а.б.** Ә. Габидинең шигырьләрендә кеше белән табигать нык берләшкән. «Таң гөле» шигырен тыңлап үтик.

**1 нче укучы «Таң гөле» шигырен укый.**

Тау буенда без утырткан
Гөл үсә.
Сыйпап аның ал керфеген
Җил исә.
Кеше генә гашыйк түгел
Ул гөлгә,
Гашыйк әле хәтта аңа
Шук җил дә.
Килеп аңа былбыллар да
Куналар.
Иртә-кичен дәртле җырлар
Сузалар.
Зәңгәр күктән ак болытлар
Агалар,
Алар аңа яңгыр булып
Тамалар.
Алсу булып үссен ул гөл,
Сулмасын.
Шат күңелләр хуш исләрен
Суласын.
Үзебез дә җир-әнкәнең
Гөле без.
Гөлләрдән дә матур безнең
Көнебез.

**1 а.б.** Тау буенда кешеләр утырткан гөл үсә. Җил аның ал керфеген сыйпый, былбыллар аңа кунып сайрый, ак болытлар яңгыр булып тама. Гөл үзе дә җавапсыз калмый, күңелләргә хуш исләрен бүләк итә. Бактың исә, без үзебез дә җир-әнкәйнең гөле икән бит, шуңа күрә безгә туган якта рәхәт, иркен, күңелле.

**2а.б.** Кошлар – безнең дсларыбыз. Кошларны танып-белү, аларның әһәмиятен аңлату, кышлаучы кошларны кыш көне туендыру турындагы шигырьләр зур тәрбияви әһәмияткә ия. Шагыйрьнең нәни геройлары гел яхшылык эшләүдә. «Таң сәгате» китабында язылган «Елка» шигырендә кыш көне ашханә ясап кошларны кунак итүе турында яза.

**2 нче укучы «Елка» шигырен укый**

Яңа елны бакчабызга
Елка корып көтәм мин,
Чөнки аны кошлар белән
Бергә бәйрәм итәм мин.
Уенчык та юк елкамда,
Йолдыз да тормый көлеп,
Уйнап йөрми балалар да
Аның янына килеп.
Ләкин, дускайлар, ул елка
Һич гади елка түгел.
Күгәрчен,песнәк, чыпчыклар
Ачалар анда күңел.
Нигә дисәгез, елкага
Ашханә куям элеп.
Мин салган җимнәрне алар
Ашыйлар шуннан килеп.
Яңа елны бакчабызга
Елка корып көтәм мин,
Канатлы дускайларымны
Шунда кунак итәм мин.

**1 а.б.** Балаларның зиһенен баетуда, уйлау-фикерләү сәләтен үстерүдә дә Әзһәр аганың табигатькә багышланган күп кенә табышмаклары игътибарга лаек. Әйдәгез әле, без дә зиһеннәребезне тикшереп, «Булсаң зирәк – әйт тизрәк!» дигән табышмак әйтү уенын уйнап алыйк.

**Табышмаклар**

1.Кеше дисәң, кеше түгел,
Сумка булыр түшендә.
Китап түгел, дәфтәр түгел,
Бала йөртер эчендә. (Көнгерә)
2.Җир астында алмасы,
Сабагында йөземе,
Шул алманы бөтен халык
Җыеп ала көз көне. (Бәрәңге)
3.Юк энәсе, юк җебе,
Челтәр бәйли ул үзе,
Күпме челтәр бәйләсә дә,
Юктыр бер генә җөе. (Үрмәкүч)
4.Черек-черек итәр кош,
Тырык-тырык итәр кош,
Бер урыннан бер урынга
Сикереп кенә китәр кош.
Бу ни була? Исем куш. (Чикерткә)
5.Аллы-гөлле җилпә кош,
Җил иркенә очар кош,
Таңда очса, кич белән
Җирдә сулып ятар кош. (Күбәләк)
6.Морҗа башында бүре,
Ләкин күренми үзе,
Күренмәсә дә үзе,
Яңгырап тора өне. (Җил)
7.Ак аляпкыч билендә,
Чулпылары иңендә.
Шул чулпылар, зың-зың килеп,

Эндәшә бер-берсенә.(Каен)
8.Үзе ул көмеш билбау –
Беркем бумас биленә.
Тигезсә аны тигезер
Сусаганда иренгә. (Елга)
9.Күлләре бар – суы юк,
Чүлләре бар – комы юк.
Таулары бар – кар ятмый,
Аны белгән адашмый. (Карта)

**1а.б.** Ә.Габиди иҗатында күп кулланылучы табигать образларының берсе – җил. «Җиңелгән җил» шигырендә укучылрга тәртипсезләнеп җил куып йөрмәскә, эш эшләргә кирәклекне кисәтә.

**3 нче укучы «Җиңелгән җил» шигырен укый.**

Көндез дими, кичен дими,
Җил бушка исеп йөри,
Юлларда тузан туздыра –
Тәртип дигәнне белми.
Тәрәзәләр ачык булса,
Өйгә дә килеп керә,
Өстәлдәге кәгазьләрне
Өреп кенә төшерә.
– Бик шаярып йөрмә! – диеп,
Эшкә җиктем үзен дә:
Җил тегермәне ясадым
Бакчабызның түренә.

**2 а.б.** Язучының кайбер шигырьләре хезмәткә, батырлыкка чакыра, төрле һөнәр кешеләренә хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияли. «Бал кортлары», «Җайдаклар», «Кораб» шигырьләре бала күңеленә барып җитәрлек итеп гади телдә язылган.

**4 нче укучы«Бал кортлары» шигырен укый.**

Карабодайлар
Ак чәчәк аткан –
Гүя, басуга
Тәңкә кар яткан.
Бал исе бөрки
Талгын җәй җиле.
Походка чыгар
Эшчән корт иле.
Алар очарлар
Белми ал-ялны,
Умарталарга
Җыярга балны.
Һәм аны безгә
Бүләк итәрләр,
Баллы табынлы
Булыр иртәләр.

**1 а.б.** Җир – гаҗәеп матур келәм. Аның бизәкләре – чәчәкләр. Ниндиләре генә юк аларның. Табигать чәчәкләрне җирне матурлау өчен үстерә. Кешеләр табигать матурлыгын бозмаска, сакларга тиешләр. Урман-кыр чәчәкләре дә саклауга мохтаҗ. «Чәчәкләрдә кунакта» дип аталган шигырләр җыентыгында ландыш, миләүшә, канәфер чәчәкләренең матурлыгына соклана.

**5 нче укучы «Тузганак» шигырен укый.**

Артык сылу булмаса да,
И көяз дә тузганак,
Аның кигән башлыклары

Әле сары, әле ак.
Җитмәсә, ул бик җилбәзәк,
Җил белән шаяручан,
Шул шуклыгы аркасында
Мамыкларын коючан

**6 нчы укучы «Ландыш» шигырен укый.**

Вакытыңны әрәм итеп
Аланнан эзләмә дә,
Тәмле хуш исләрен сибеп,
Үсә ул күләгәдә.
Көмеш кыңгырауычыклары
Җилләрдә чең-чең килә,
Игътибар белән тыңласаң,
Ишетерсең, чын, менә.
Әгәр дә син аның белән
Буласың килсә таныш,
Исемен дә әйтим инде,
Ул чәчәк булыр – ландыш.

**2а.б.** Халкыбыз гомер-гомергә дару үләннәре белән дәваланган, аның серләрен буыннан-буынга әйтеп калдырган. Язучы аларның файдасын исә төрле китаплардан, сүзлекләрдән укып өйрәнә. «Болын табибы» шигыре аша безнең сәламәтлек турында да кайгырта.

**7 нче укучы «Болын табибы» шигырен укый.**

Әгәр синең яраланса
Кул, йә аягың,
Онытма аңа ябарга
Бака яфрагын.
Чабыруга һәм ярага
Ул бик шифалы.
Шуңа болын табибы дип
Йөртәләр аны.

**1 а.б.** Әзһәр Габиди – һичкайчан зур бөеклекләргә омтылмыйча, әрсезлек күрсәтмичә иҗат иткән шагыйрь. Туган ягы Сарман төбәгенең кабатланмас гүзәл табигатен, аның хезмәт сөйгән халкын олылады, гашыйк булып язды, сагынып язды.

**8 нче укучы «Сагындым» шигырен укый.**

Бу кадәрле сагынырмын диеп,
Уйламаган идем, Сарманым.
Күз алдыннан китми айлы кичең,
Истән чыкмый алсу таңнарын.
Күз йомдыммы – төшләремә керә
Чәчәкләре зәңгәр тавымның.
Һич яшермим сездән: туган якның
Әременә кадәр сагындым.

**2 а.б.** Әзһәр ага туган яктан, төбәктән бер көн генә дә аерылып китә алмый. Ул чишмәләрнең тәмен, эт өрүен, әтәч кычкырганын сагына.

Ташлап китсәм, әрәмәдә үскән
Бөдрә каен миңа үпкәләр,
Килеп чистартмасак кибеп бетәр
Без су эчкән көмеш чишмәләр.
Очар кошлар төсле күчеп йөрү
Минем табигатькә ярамый,
Туфрагыннан куптарылган тамыр
Чит җирләрдә бик тиз яңармый,
– дип яза туган җирләрен ташлап китүчеләр турында.

**1 а.б.** Чишмә – җир астыннан бәреп чыга торган су. Чишмә элек-электән тылсым көченә ия

булган. Кеше дә гомер башын чишмә белән тиңләгән. Чыннан да, чишмә чыга да акрын гына чылтырап ага. Чишмә тавышын ишетү әллә никадәр куаныч бирә, аларның үз җыры бар. Туган авыл, әти-әни дә чишмә суларыннан башлана. Бүгенге көннең иң актуаль проблемаларының берсе – чишмәләрнең кирәклеге «Чишмә» шигырендә ачык чагыла.

**9 нчы укучы «Чишмә» шигырен укый.**

Тау астыннан чишмә ага
Чылтыр да чылтыр.
Аның җырыннан да җирдә
Матур җыр юктыр.
Ярга тулып акмаса да
Чиста,саф сулы:
Эсседә дә, салкында да
Баса сусауны.
Янындагы үләннәр дә
Аннан дым ала,
Эше һәм җыры белән ул
Шулай данлана.

**2 а.б.** Әзһәр ага Габиди үзенең иҗатында милләтебезнең үткәне һәм киләчәге, бетеп бара торган авылларның үкенечле язмышы, көннән-көн коргаксый барган табигать, сөенечле һәм үкенечле мәхәббәт, сугыш чоры хатирәләре, сагындыргыч яшьлек һәм башка бик күп темаларны ачып сала. «Сакласын иде кеше» шигыре – көннән-көн коргаксый барган табигатьне саклау турында.

**10 нчы укучы «Сакласын иде кеше» шигырен укый.**

Җанга бер рәхәт моң белән
Шаулыйлар урманнарым.
Әгәр эчләрендә йөрсәм,
Югала арганнарым.
Көмеш көзгедәй җемелди
Елгаларым, күлләрем.
Кояшка карап елмая
Чәчәкләрем, гөлләрем.
Тәмле хуш исен аңкыта
Җиләкле аланнарым.
Алсу гәрәбәдәй балкый
Миләшем, баланнарым.
Алтын дулкында чайкала
Басуларым, кырларым.
Алтын көшелләре белән
Тулыдыр ындырларым.
Болар – табигать-ананың
Соклангыч күркәм эше.
Аны шул гүзәллек белән
Сакласын иде кеше.

**1 а.б.** «Нәрсә әйтер килер буыннар?!» шигырендә шагыйрьне яшь буынның киләчәге борчый.

Авыл очы әрәмәлек иде –
Үсә иде балан, миләшләр.
Кич уенга,тальян гармун тартып,
Төшә иде шунда шат яшьләр.
Ташлы елга буйлап офыккача
Җәйрәп ята иде тугайлар.
Урман буе зәңгәр күллек иде,
Үсә иде ярда камышлар.

Җылы яктан бала чыгарырга
Килә иде язын аккошлар.
Әрәмә дә беткән,
Күл дә кипкән,
Ергычланган хәтфә болыннар;
Моның өчен ләгънәт укымасмы
Безгә алмаш килгән буыннар?!

**2 а.б**. Сарман районының Чукмарлы авылында яшәп иҗат иткән ялкынлы әдип Әзһәр ага Габиди без – укучыларга ихлас хис белән язылган бай мирас калдырды. Һәркайсыбызга таныш, якын булган, үзенең лирик, нәфис шигырьләре белән күңелләребезне яулаган мөхтәрәм Әзһәр агабыз бу якты дөньяда юк инде. Үзе булмаса да, шигырьләре яши, матурлыкка өнди, уйландыра..

**1 а б.** Фронтовик шагыйрь Сарман җирендә туып, татар халкына булган мәхәббәтен түкми-чәчми үз укучысына җиткерү бәхете белән рухланып яшәде. Язучы туган ягының табигатенә битараф калмый. «Рәнҗемәслек булсын оныклар» шигырендә:

Без табигать улы – җир баласы,
Без бит шунда гомер итәсе;
Ае көлсен, йолдызлары янсын;
Гүзәл булып тусын иртәсе.
Яшьлек туен көткән сылулардай
Ак күлмәген кисен шомыртлар,
Борыннарны иркәләсен әле
Шул куаклар чәчкән хуш исләр.
Кырларда да яшел дулкын чапсын,
Болыннарда көтү утласын.
Ә кичләрен зәңгәр күгебездә
Аҗаганнар камчы уйнатсын.
Ертмыйк әле озон катлауларын,
Агуламыйк сулар һаваны,
Саклыйк әле күз карасы кебек
Табигатьне – изге ананы, – дип яза.

**1 а.б.** Туган ягыбыз, сулар һавабыз, эчәр суыбыз кешеләрнең битарафлыгыннан сыкрап утыра.Табигатебез, баласын назлап караган анадай, үзенең байлыклары белән кешегә хезмәт итә. Шуңа күрә Әзһәр ага Габиди дә табигатьне әни белән тиңли: Җир-әнкә, Табигать-Ана. Ә без – кешеләр аның балалары.Үзебезнең дөрес гамәлләребез белән генә табигатьне саклап калырга мөмкин.

**11нче укучы «Җир бизәге» шигырен укый.**

Күк бизәге – йолдыз,
Җир бизәге – кеше,
Җирнең өстен ямьли
Аның гүзәл эше.
Идел күрке – киңлек,
Мәйдан күрке – батыр,
Җир-әнкә дә безнең
Кеше белән матур.
Бизәк булып мин дә
Килдем туган җиргә,
Эшем белән аны
Төрсәм иде гөлгә.

## Әгәр дә син гөлләр булсаң, ак чәчәк атар идең...

(Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты буенча квест-уен)

А.С. Ширеева, Г.Р. Сәлахова Азнакай шәһәре 4нче лицее укытучылары,

**Аңлатма язуы.**

Федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә төп белем бирү программасы уку планы һәм дәрестән тыш эшчәнлек аша гамәлгә ашырылырга тиеш. Дәрестән тыш эшчәнлек ул – укучыларның ял итү ихтыяҗларын канәгатьләндерү, аларның үзидарәгә һәм иҗтимагый һәм файдалы эшчәнлеккә катнашуы өчен дәрестән тыш вакытта оештырыла торган эшчәнлек. Яңа белем бирү стандартлары педагоглардан эшчәнлекле юнәлеш куллануны таләп итә, чөнки эшчәнлек барышында балалар материалны яхшырак үзләштерә. Кагыйдә буларак, укучылар, дәрестән тыш эшчәнлекне мәҗбүр итү дип санап, мондый төр мөстәкыйль эшкә битараф карыйлар. Квест оештырганда исә, тискәре кәеф тулысынча юкка чыга. Укучыларга командада үзара бәйләнештә торырга туры килә, ә бу – коммуникатив күнекмәләрне үстерү дә, уйнаучыларны бергә туплауның яхшы ысулы да.

**Квестны үткәрү планы.**

**Максат:** Клара Булатова турында алган белемнәр нигезендә укучыларның иҗади, интеллектуаль сәләтләрен үстерү өчен шартлар тудыру.

**Бурычлар:**

- командада эшли белү күнекмәсен формалаштыру;
- үзара ярдәмләшү, берләшү атмосферасын булдыру;
- гомуми эш өчен җаваплылык тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

- куелган бурычларны хәл итүнең стандарт булмаган ысулларын кулланып, практикада белемнәрне куллану тәҗрибәсен булдыру;
- аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган ысулларын куллану;
- тирә-юньдәгеләр белән продуктив хезмәттәшлек төзи белү;
- эшчәнлекнең нәтиҗәләрен дөрес бәяләү;
- үзара ярдәмләшү, толерантлык, эшне үтәүгә шәхси җаваплылык, яшьтәшләре белән уртак тел табып аралашу осталыгын үстерү.

Үткәрү урыны: уку кабинетлары

Үткәрү вакыты – 45 мин

Катнашучылар: 7 сыйныф укучылары

**Әзерлек эше:**

1. Сценарийны эшләргә.
2. Һәр этап өчен биремнәр булган тарату материалы булдырырга.
3. Кирәкле реквизит (биремнәр салынган конвертлар) әзерләргә.
4. Модераторларны билгеләргә һәм бурычлары белән таныштырырга.

Уен чылбыр буенча төзелгән: бер биремне чишеп, катнашучылар алдагысын алалар һәм маршрут тәмамланганчы шулай эшлиләр.

Квестның максаты – Клара Булатова турында 7 кызыклы факт җыю. Моны беренче булып эшләгән команда җиңүче була. Һәр этапның исеме халык мәкале белән аталган һәм ул бирем эчтәлеге белән туры килә. Уен үтә торган кабинетлар тематика буенча әзерләнә.

Һәр этапта биремнәрнең үтәлешен күзәтеп торучы һәм катнашучыларга аларны дөрес үтәгән өчен 1 фактны бирүче модераторлар бар. Команда дөрес җавап бирмәсә, башка этапларны үткәннән соң әлеге биремгә кире кайтырга мөмкинлек бирелә.

**Уен барышы.**

**Алып баручы:** Хәерле көн, уенда катнашучылар. Бүген без туган телебезне, мәдәниятебезне саклап калуда, аны үстерүдә армый-талмый хезмәт итүче күренекле шәхесләребезнең берсе – Клара Булатовага багышланган квест-уенга җыелдык. Шагыйрә безне үзенчәлекле тавышы, матур сүз осталыгы белән әсир итә. Тирәндә яткан күренешләрне җиңел итеп, гади итеп әйтә белүе – бу әдибәнең табигый халәте. Аның шигъриятен фирүзә сулы тирән диңгез белән чагыштыралар. Аңа чумган саен чумасы, киңрәк колачлыйсы килә. Без дә бүген шушы диңгез төбеннән энҗе-мәрҗәннәр эзләрбез, алар – Клара Булатова турында 7 кызыклы факт булачак. Шуларны беренче булып җыйган команда җиңүче булып санала.

Уенны башлыйбыз. Маршрут буенча төгәл баруыгыз сорала.

**1 нче этап.«Күп укысаң, күп белерсең»**

*Клара Булатованың «Яшел каләм» хикәясеннән геройларны тану.*

а) Кызыкмагыз күлмәгенә,
Герман күлмәге бит ул.
Күлмәген салып ташласа,
Катык чүлмәге бит ул.
Бу сүзләр кем турында?

ә) «Борчылма, әнисе. Син баларның барысын да исән алып чыккансың. Дәрес эшкәртмәләре язылыр ул, сатылган портфельләр дә, йорт әйберләре дә яңадан алыныр, кием дә табылыр. Иң мөһиме – исән булу! Илнең җиңеп чыгуы, сугышның бетүе!» Бу сүзләрне кем әйтә?

б) Әтисенә яшел каләм алып кайтырга кушкан герой исеме.

в) Сугышка нәкъ сабан туе көнне китеп, сугыштан соң да нәкъ сабан туе көнендә кайткан солдат.

г) Гадәттә балаларына ияреп кергән кыз-малайларны да төксерәк каршылый, күбрәк сөйләшергә ярата торган хатыннарны да тизрәк озата торган апа да бүген гел башка, бөтенесенә дә – ай да кояш, бөтенесен өстәл янына чакыра, кыстый-кыстый коймак ашата. Бу җөмлә кем турында?

**2 нче этап. «Белемле кеше югалмас»**

*Тормыш юлы һәм иҗаты буенча сорауларга җавап бирү.*

а) Клара Булатова кайда һәм кайчан туган?

ә) Мәктәпне тәмамлагач кайда укый?

б)Хезмәт юлын кайда башлый?

в)1962-1965 елларда ул кайсы мәктәптә, нинди фәннәр укыта?

г) Кечкенә балалар өчен язган китап исемнәре.

д) Клара Булатова шигъриятенең төп темасы.

е) Иҗатына нинди халык фольклорының йогынтысы зур булган?


ж) Нинди бүләкләре, мактаулы исемнәре бар?

з) Шагыйрәнең лирик шигырьләрен туплаган беренче китабының исеме, басылып чыккан елы?

и) Нинди күренекле шагыйрьнең хатларын үзендә кадерләп саклый?

**3 нче этап. «Сөйләп күрсәткәнче, эшләп күрсәт»**

*Ребусны дөрес чишсәгез, Клара Булатованың бер шигыреннән өзек укырсыз.*






**4 нче этап**. **«Эзләгән табар, ташка кадак кагар»**

*Хәрефләр җыелмасыннан шагыйрәнең «Әләкләргә ярамый!» шигыреннән бер өзекне эзләп табу.*

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| п | у | к | е | н | к | п | у | е | ч | к | е | п | ю | ч | ю | ч | е | ю | п |
| у | п | е | с | и | е | н | а | я | н | п | м | и | н | н | ш | а | я | н | к |
| е | п | у | н | д | п | ю | к | ю | у | к | у | к | ю | ч | н | к | ю | н | н |
| к | п | к | ю | к | е | ю | ч | п | ю | п | ч | н | ч | п | ч | п | ю | д | е |
| ш | у | ң | а | у | ө | й | г | ә | ч | н | с | ы | й | м | ы | й | б | ы | з |
| п | е | с | и | к | ч | а | п | т | ы | к | м | и | н | и | к | у | д | ы | м |
| к | н | е | ю | к | е | ю | ч | б | н | п | е | у | ю | к | б | ю | ч | б | п |
| у | ю | н | к | ю | у | ч | е | н | ю | ч | б | б | п | ч | к | п | у | е | ю |
| е | к | ю | е | ч | н | п | ю | п | к | п | ю | у | е | ч | е | ю | к | ю | к |
| п | а | л | н | ы | у | а | р | т | н | ы | п | к | а | р | а | м | ы | й | у |


**4 нче этап.«Әйткән сүз – аткан ук»**

*«Әйе», «юк» дип җавап бирегез.*

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Клара Булатова март аенда туган | |
| 2. | Әтисе колхоз рәисе, әнисе укытучы булган | |
| 3. | Аңа төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килгән | |
| 4. | Сарман районы Ләке авылында беренче сыйныфны тәмамлый | |
| 5. | Түбән Ләшәү мәктәбендә югары классларда балалар укыта | |
| 6. | Ул бары тик укытучы гына булып хезмәт иткән | |
| 7. | Шагыйрәнең күп кенә лирик шигырьләренә Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан музыка язылган. | |
| 8. | Ул Казан дәүләт университетының рус теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый | |
| 9. | Диплом эшен шигырь белән язган. Сибгат Хәкимнең поэмаларына багышланган ул. | |
| 10. | Керәшен татарлары фольклорын яхшы белә | |
| 11. | 1956 елдан башлап «Татарстан яшьләре», «Совет Татарстаны» («Социалистик Татарстан») газеталарында, «Пионер» («Ялкын»), «Азат хатын» («Сөембикә»), «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналларында аның күп кенә шигырьләре дөнья күрә | |
| 12. | Клара Булатова турында Фәрит Яхин «Кыңгырау чәчәк» дигән роман язган. | |

**5 нче этап. «Бергә эшләсәң, авыр эш тә җиңел»**

*Клара Булатова шигырьләреннән өзекләрдә төшеп калган сүзләрне табып кроссворд чишү.*




| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | |
| | | 10 | 6 | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

**Өстән аска таба:**

1. ... инде.
   Җәйнең соңгы ае керде,
   Әллә нинди моңсу муллык сарган җирне.
   Бер карасаң, җан куана күреп кырны,
   Бер карасаң, ул моңлана күреп шуны.
2. « ... үтте – җәйләр бетте», – диләр
   Безнең якта халык сүзендә.
   Питраудан соң чәчәк атмый гөлләр,
   Сары йөгерә кырлар йөзенә.
3. Тау буенда яшел ...,
   Шунда кереп мин әгәр
   Бер сызгырсам, дәррәү кубып
   Чабып чыга гөмбәләр.
4. Миңа сорау бирсәләр:
   - Шатлыгың ни? – дисәләр, –
   Шушы ... сукмаклары
   Шатлыгыма илтәләр.
5. Магазиннан сөт апкайтам,
   Ипигә дә йөгерәм.
   Әниемнең кызы юк та –
   ... бар бер дигән.
6. Дүрт ... тәрәз төбендә:
   Беребез чигәр иде,
   Беребез бәйли, беребез кисә,
   Беребез тегәр иде.

**Сулдан уңга таба:**

7. Кадерле бу көндә булганың,
   Кадерле миңача узганың.
   Халкымның бүгенге, киләчәк гомере,
   Син илем, үз җирем,
   Үз ягым – ... !
8. Кайда барсам, кайда йөрсәм дә мин,
   Юлларыма маяк кабынган.
   Баш өстемдә нуры бәхетемнең,
   Тик үзеңне, ... , сагынам.
9. «Үчти-үчти» дигәндә,




   Үчтекиләп сөйгәндә.
   Күгәрченнәр көнләшерлек
   Минем ... көлгәндә.
10. Син белергә тиеш, ... ,
   Ни сорыйлар – шуны белергә.
   Укытучы булу – бу шундый эш, –
   Белгәнеңне кирәк белергә.

**7 нче этап.«Тырышкан табар, ташка кадак кагар»**

*Пазл җыегыз.*

**Алып баручы:** Командаларны уенда актив катнашулары белән котлыйм. Җиңүче команданы аерым билгеләп үтәм. Сез Клара Булатова турында 7 кызыклы факт җыйдыгыз, алар шагыйрәнең сез белмәгән якларын ача.

Якты, саф чишмә кебек бәреп чыккан талант иясе, заман үзгәрсә дә үзгәрми торган күңел кылларын тибрәтерлек шигырьләр язучы ул  Клара Булатова.  Аның кебек халык күңелен яулап алган шагыйрьләр – табигатьнең гүзәл бүләкләре. Шундый бөек  затларыбыз булганда телебез дә югалмас, мәңге яшәр.

Кушымта

**Кызыклы фактлар**

1. К.Булатова беркайчан да караламага язмый.
2.1958 елдан башлап  бер генә көн дә көндәлек язмый калганы юк.
3. Оныгы Гайшә шигырьләр иҗат итә, димәк, дәвамчысы бар.
4. Үзе яшәгән өйнең бер бүлмәсендә музей ача.
5. Укыганда  студентлар арасында китап чыгарган бердәнбер кеше булган.
6. Шигырьләрен язганда ук көйгә салып бара.
7. Колшәриптә Әлмәт Язучылар бүлегенең 40 еллыгы уңаеннан Клара Булатова исемендә чишмә ачканнар.

**1 нче этап. «Күп укысаң, күп белерсең»**

а) Тәвисә
 ә) Ләриянең этисе – Миргарифан.
 б) Ләрия.
в)  Сабантуй Салих.
г) Ләриянең әнисе – Хәдичә.

**2 нче этап.«Белемле кеше югалмас »**

а) Клара Булатова 1936 елның 18 мартында Татарстан АССРның Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туган.
ә) Казан Дәүләт Университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый.
б) Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч классларда балалар укыта.
в) Әлмәт районы Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта.
г) «Марс китабы», «Әллә кайсын тыңласы», «Курка димәгез әле», «Камилә дигән матур кыз».
д) Мәктәп, балалар язмышы.
е) Керәшен фольклоры.
ж) Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре; Татарстанның халык язучысы (2019); Рафаил Төхфәтуллин (1994), Саҗидә Сөләйманова (2007) һәм Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премияләре (2015) лауреаты
з)  Беренче китабы «Язлар алда» дип атала, 1967 елда басылып чыккан.
и) Хәсән Туфан хатларын саклый.

**3 нче этап**. **«Эзләгән табар, ташка кадак кагар»**

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| п | у | к | е | н | к | п | у | е | ч | к | е | п | ю | ч | ю | ч | е | ю | п |
| у | **п** | **е** | **с** | **и** | е | **н** | **а** | **я** | **н** | п | **м** | **и** | **н** | н | **ш** | **а** | **я** | **н** | к |
| е | п | у | н | д | п | ю | к | ю | у | к | у | к | ю | ч | н | к | ю | н | н |
| к | п | к | ю | к | е | ю | ч | п | ю | п | ч | н | ч | п | ч | п | ю | д | е |
| **ш** | **у** | **ң** | **а** | у | **ө** | **й** | **г** | **ә** | ч | н | **с** | **ы** | **й** | **м** | **ы** | **й** | **б** | **ы** | **з** |
| **п** | **е** | **с** | **и** | к | **ч** | **а** | **п** | **т** | **ы** | к | **м** | **и** | **н** | и | **к** | **у** | **д** | **ы** | **м** |
| к | н | е | ю | к | е | ю | ч | б | н | п | е | у | ю | к | б | ю | ч | б | п |
| у | ю | н | к | ю | у | ч | е | н | ю | ч | б | б | п | ч | к | п | у | е | ю |
| е | к | ю | е | ч | н | п | ю | п | к | п | ю | у | е | ч | е | ю | к | ю | к |
| п | **а** | **л** | **н** | **ы** | у | **а** | **р** | **т** | **н** | **ы** | п | **к** | **а** | **р** | **а** | **м** | **ы** | **й** | у |

**К.Булатова «Әләкләргә ярамый!»**

Песи наян, мин шаян,
Шуңа өйгә сыймыйбыз.
Песи чапты, мин кудым,
Алны-артны карамый.

**4 нче этап.«Әйткән сүз – аткан ук»**

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Клара Булатова март аенда туган | әйе |

| | | |
|---|---|---|
| 2 | Әтисе колхоз рәисе, әнисе укытучы булган | юк |
| 3 | Аңа төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килгән | әйе |
| 4 | Сарман районы Ләке авылында беренче сыйныфны тәмамлый | юк |
| 5 | Түбән Ләшәү мәктәбендә югары классларда балалар укыта | юк |
| 6 | Ул бары тик укытучы гына булып хезмәт иткән | юк |
| 7 | Шагыйрәнең күп кенә лирик шигырьләренә Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан музыка язылган. | әйе |
| 8 | Ул Казан дәүләт университетының рус теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый | юк |
| 9 | Диплом эшен шигырь белән язган. Сибгат Хәкимнең поэмаларына багышланган ул. | әйе |
| 10 | Керәшен татарлары фольклорын яхшы белә | әйе |
| 11 | 1956 елдан башлап «Татарстан яшьләре», «Совет Татарстаны» («Социалистик Татарстан») газеталарында, «Пионер» («Ялкын»), «Азат хатын» («Сөембикә»), «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналларында аның күп кенә шигырьләре дөнья күрә | әйе |
| 12 | Клара Булатова турында Фәрит Яхин «Кыңгырау чәчәк» дигән роман язган. | юк |

**5 нче этап. «Бергә эшләсәң, авыр эш тә җиңел»**

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| [1] а | | | | | [3] у | | | | | | | |
| в | | [2] п | | | р | | | | | [5] м | | |
| г | | и | | | м | | | | | а | | |
| у | | т | | | а | | | | [9] у | л | ы | м |
| [7] с | а | р | м | а | н | ы | [4] м | | | а | | |
| т | | а | | | | | [8] ә | н | и | е | м | |
| | | у | | | | | к | | | | | |
| | | | | [10] у | [6] к | ы | т | у | ч | ы | | |
| | | | | | ы | | ә | | | | | |
| | | | | | з | | п | | | | | |

**6 нчы этап «Сөйләп күрсәткәнче, эшләп күрсәт»**

«Камилә барган җиләккә» шигыре
Чиләктәге җиләкләре
Тәмле булган бигрәк тә.
Җирдән җыймый башлаган,
Утырган да ашаган.

**7 нче этап. «Тырышкан табар, ташка кадак кагар»**

## К.Булатованың «Әниемнең кызы юк бит» шигырен уку

(мәктәпкә хәзерлек төркемендә интеграль шөгыль эшкәртмәсе)

Вәлиева Л.Җ., Сарман 4 нче «Сандугач » балалар бакчасы тәрбиячесе,
Сарман районы

**Максат:** балаларга текстны тыңларга һәм эчтәлеген аңларга өйрәтү.

**Бурычлар:** якташ язучыбыз иҗаты турында күзаллау булдыру; балаларның кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, сөйләмдә ирекле аралашуларын, башкаларга аңлаешлы итеп җавап бирү осталыкларын, фантазияне (әвәләү өлешендә) үстерү; әниләргә карата хөрмәт, ярату, ярдәм итәсе килү хисләре тәрбияләү.

**Белем бирү өлкәләре**: сөйләм үсеше(төп), физик үсеш, иҗтимагый-аралашу үсеше, нәфис-нәфасәти үсеш.

**Җиһазлар:** аудиоязма «Рәхмәт, әнием», К.Булатованың шигырь җыентыгы, К.Булатова портреты, слайд-шоу, тозлы камыр,

**Эшчәнлек барышы:**

**Оештыру өлеше.**

Тәрбияче: Хәерле иртә, балалар, әйдәгез кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басыйк та бер-беребезгә карап ягымлы сүзләр әйтик (уңай психологик халәт тудыру):

Хәерле иртә, малайлар,
Хәерле иртә, кызлар!
Күңелле шөгыльләр
Теләсен безгә йолдызлар!

**Төп өлеш.**

- Балалар, карагыз әле минем электрон почтама ниндидер хат килгән икән. Ул хатта: «БАЛАЛАР БЕЛӘН БЕРГӘ ТЫҢЛАРГА», – дигән язу һәм ниндидер бер таныш түгел файл бар. Тыңлап карыйкбызмы? (Әйе).

*Җыр тыңлау: «Рәхмәт, әнием!»*

Әңгәмә:

- Балалар, сез җырның сүзләренә игътибар иттегезме? Кем турында ул? (Әни турында)
- Әниләргә нәрсә әйтә? (Рәхмәт, әнием, сиңа мең рәхмәт)
- Балалар, без әниләргә үзебезнең рәхмәтләрне ничек итеп белдерә алабыз? (җыр аша, тәртипле булып, әниләргә булышып, уенчыкларны җыештырып куеп, шигырьләр сөйләп)

Кайсыларыгыз өйләрендә әниләргә булыша?

**Физминутка.**

Тәрбияче идәнгә уенчыклар тарата. Балаларга уенчык тартмаларын бирә. Кемдә нинди тартма, шулл уенчыкны җыярга тиеш була. Тизлеккә эшләнә.

- Ә хәзер минем сезгә үзебезнең якташ язучыбыз Клара апа Булатованың «Әниемнең кызы юк шул» шигырен укып китәсем килә. Игътибар белән тыңлагыз әле. (Китаптан уку. Язучының портретын күрсәтеп, аның Сарман районында яшәп иҗат итүче язучы икәнен ассызыклап үтү).

Шигырь эчтәлеге буенча әңгәмә:

- Әнинең кызы булганмы? (Юк, аның улы гына булган)
- Әнинең ничә улы булган? (Бер)
- Әнинең нәрсәсе күп булган? (эше) (*Слайдта әниләрнең көнкүреш эшләрен тасвирлаучы рәсемнәр)*
- Малай әнисенә булышамы? Ул аңа ниләр эшләшә?(Аш пешерешә, җыештыра, кер юыша, магазинга йөри)
- Ничек уйлыйсыз: малай әнисен яратамы? (Әйе)
- Ни өчен шулай дип уйлыйсыз? (Чөнки ул әнисенә ярдәм итә. Малай булса да, кызлар эшли торган эшләрне дә эшли)
- Ул үзе турында нәрсә ди? (Бер дигән малай).
- Малайны мактанчык дип әйтеп буламы соң? (Юк, ул ярдәмчел – шул турыда гына әйтә)
- Ә сез әниләрегезгә ничек итеп булышасыз? (Әйе) (*Һәр әйтәсе килгән баланың җавабын тыңлау).*
- Балалар, әйдәгез әниләрегез килүгә, аларга «күчтәнәчләр» пешерәбез. Аның өчен, һәрберегез өстәл янына килсен әле. Анда тозлы камырлар куелган. Шулардан без төрле тәмле ризыклар “пешерик”.

Камырдан ниләр пешереп була? (бәлеш, өчпочмак, бөккән, кыстыбый, дурчмак, вак бәлеш, өлеш һ.б.) (*Слайдта милли ризык рәсемнәре*).

**Йомгаклау.**

Камырдан милли ризыклар әвәләү барышында балаларга сораулар бирү:

- Балалар, кайткач, әниләрегезгә ниләр турында сөйләрсез? (Җыр тыңладык, шигырь укыдык, камырдан әниләргә күчтәнәчләр ясадык)
- Шигырьне кем язган? (Сарманда яшәүче язучы Клара апа Булатова). Эшләрне тәмамлау, урыннарны җыештыру, әвәләгән әйберләрне киштәгә урнаштыру.

## Туган телем – алтын бишек

(Әзһәр Габидинең «Күлдәвектә кояш көлә» исемле яна китабын тәкъдим итү)

Абдуллина Кадрия Галимҗан кызы, Марданшина Алсу Тимерхан кызы, Күтәмәле төп гомуми белем бирү мәктәбе, Сарман районы

**Дәрес төре:** тәрбия дәресе.
**Максатлар:**
1. **Фәнни:** тел турында мәгълүмат бирү.
2. **Коммуникатив:** коллективта эшләргә өйрәтү.
3. **Тәрбияви:** туган телгә карата хөрмәт ояту. Туган ягыбыз шагыйрьләре һәм язучылары иҗатына кызыксыну уяту.

**Бурычлар:** туган телебез турында белемнәрне үстерү, Әзһәр Габидинең яна шигырьләр җыентыгы белән таныштыру, биремнәрне үтәгәндә барлык укучыларны катнаштырырга тырышу.
**Ысуллар:** репродуктив; өлешчә эзләнү; иҗади уку.
**Алымнар:** сорау-җавап; әңгәмә; укытучы сөйләме.
**Җиһазлау:** артына сорау-биремнәр яшерелгән баскыч, «Белем кояшы», презентация, проектр, экран.
**Файдаланылган әдәбият:**
Әзһәр Габидинең «Күлдәвектә кояш көлә» исемле яна китабы.
Татар халык иҗаты. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1977. – 271 б.
Габдулла Тукай. Сайланма әсәрләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1996. – 191 б.

### Дәрес планы

**I. Оештыру** (1 мин.)
**II. Актуальләштерү** (5 мин.)
а) 2021нче ел – Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы;
б) тел турында мәгълүмат бирү.
**III. Белем һәм күнекмәләр формалаштыру этабы** (34 мин.)
а) укучыларны «Белем кояшы»на илтә торган баскыч белән таныштыру;
б) бирелгән хәрефләргә башланган сүзләрдән торган текст төзү;
в) мәкальләрнең ахырларын язып бетерү;
г) яңгыраган шигырьләрнең исемнәрен атау;
д) табышмакларга җавап табу;
е) Әзһәр Габидинең «Күлдәвектә кояш көлә» исемле яна китабы белән таныштыру;
ж) «Белем кояшы»на менеп җитү;
**IV. Йомгаклау** (5 мин.)
а) нәтиҗә чыгару;
б) «Туган тел» җырын тыңлату;

### Дәрес барышы

**I.** *Укытучы:* Исәнмесез, укучылар, утырышыгыз. Кәефләрегез ничек?
*Укучылар:* Әйбәт.
*Укытучы:* Укучылар, тәрбия дәресебез нинди темага багышланганын белер өчен, әйдәгез, ике ребус чишик.

Булдырдыгыз, димәк, тәрбия дәресебез туган телебез һәм Әзһәр Габидинең «Күлдәвектә кояш көлә» исемле яна китабы белән танышуга багышлана.

**II.** *Укытучы:* Быел Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов Татарстан Республикасында 2021 елны Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итте. «Телебез – рухи яктан берләштерүче зур көч», – диде Президент. (Укучыларны эмблема белән таныштыру)
Укучылар, ә сез февраль аенда нинди бәйрәм якынлашып килүен беләсезме?
*Укучылар:* Әйе, әйе, Туган тел бәйрәме, 21 февраль – Туган тел бәйрәме!

*Укытучы:* Әйе, афәрин, укучылар. Тиздән безнең туган тел бәйрәме җитәчәк, һәм безнең бүгенге класс сәгатебез туган телгә багышланачак. Балалар, ә сез беләсезме соң, ни өчен бу көн Халыкара туган тел көне итеп игълан ителгән?
*Укучылар:* Юк, белмибез.
*Укытучы:* Халыкара туган тел көне 2000 елның 21 февраленнән ЮНЕСКО тарафыннан игълан ителгән. Бүгенге көндә дөньяда көн саен 50ләп тел юкка чыга бара. Бу көнне Туган тел көне дип игълан итүнең максаты – юкка чыга баручы телләрне саклап калу. ЮНЕСКОның күзәтүләреннән күренгәнчә, дөньядагы 6 мең телнең яртысы якын арада үзенең тел йөртүчеләрен югалтырга мөмкин. 2009 елда ЮНЕСКО Россия территориясендәге 136 телнең юкка чыгу алдында торуы турында игълан итте.

«И туган тел, и матур тел, Әткәм-әнкәмнең теле...» – дигән бөек Тукаебыз һәм ул мең тапкыр хаклы. Ни өчен? Чөнки кечкенәдән өйрәнелгән туган тел халык йөрәген шигърият белән сугарып кына калмый, аның күңелендә милли горурлык хисләре дә уята, ата-бабаларыбыз теленнән рухи ләззәт алу мөмкинлеге бирә.

Кешенең бөтен тормышы тел белән бәйле. Туганнан алып, соңгы сулышына кадәр, тел һәм сүз – кешенең аерылгысыз юлдашы. Телнең төп материалы – сүз. Ачык, дөрес итеп сөйли белмәсәң, иң ялкынлы хисләр дә кешеләргә барып җитә алмый.

Татар теле – безнең милли телебез. Без шушы телдә сөйләшеп аңлашабыз, белем һәм тәҗрибә туплыйбыз. Шуңа күрә без туган телебезне яратабыз,аны бик яхшы белергә, әдәби телдә сөйләшергә тырышабыз. Сүз байлыгы чикле булса, теләгән фикереңне аңлатып бирүе бик авыр. Шуңа күрә гомуми әдәби телне үзләштерергә – күп укырга, хәтердә калдыра барырга кирәк. Җиләкләрне берәмтекләп сала-сала, савытың тулган кебек, сүз байлыгы да шулай әкренләп туплана.

Тел – халыкның, милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү – мәдәниятны, зыялы һәр кешенең изге бурычы.
*Укытучы:* Укучылар, бүген безнең максат «Белем кояшына» менеп җитү. Әйдәгез, юлга!
**III.** *Укытучы:* Укучылар, игътибарыгызны тактага юнәлтегез әле. Биредә сез «Белем баскычы» күрәсез. Ул сезне әкренләп «Белем кояшы»на илтәчәк. Әйдәгез, беренче баскычны атлыйк. *(Баскычка яшерелгән сорау-бирем ачыла).*

Сез беренче баскычта бирелгән хәрефләргә башланган сүзләрдән торган текст төзергә тиеш буласыз. Ә кемгә нинди хәреф эләккәнен хәзер беләчәкбез. Тәкъдим ителгән кәгазьләрне тартып чыгарыгыз. Әйдәгез әле, кемгә нинди хәреф эләкте икән? *(Стикерлар артына яшерелгән хәрефләр әйтелә, укучыларга текст төзер өчен биш минут вакыт бирелә).*

Афәрин, укучылар, әлеге биремне бик уңышлы башкардыгыз, әйдәгез икенче баскычка аяк басабыз. Күрәсезме, укучылар, без сезнең белән әкренләп «Белем кояшы»на якынаябыз. *(Икенче баскычтагы бирем укыла, анда тәкъдим ителгән мәкальләрнең ахырларын язып бетерергә кушыла).* Укучылар, хәзер сезгә мәкальләр бирәм, сез аларның ахырларын дөрес итеп язарга тиеш. *(Бирем эшләнә һәм укыла).*

1. Теле барның ... ... . (иле бар).
2. Теле татлының ... ... . (дусы күп).
3. Сөйли белсәң, ... ... . (тыңлый бел).
4. Үз илем – ... ... . (алтын бишек).
5. Ата-ананы тыңлаган – адәм булган. Тыңламаган ... ... .(әрәм булган).
6. Уйнавын уйна ... ... . (эшеңне дә уйла).
7. Белмәү гаеп түгел, ... ... ... . (белергә теләмәү гаеп).
8. Эше барның, ... ... . (ашы бар).
9. Яхшы тел яз кебек, яман тел – ... ... . (көз кебек).
10. Телең озын булса – гомерең ... ... . (кыска булыр).

Афәрин, укучылар, хәзер өченче баскычка атлыйбыз. Без сезгә Г. Тукайның шигырьләрен укыйбыз, сез әлеге шигырьләрнең исемнәрен атарга тиеш буласыз. Игътибар белән тыңлагыз. *(Шигырьләр укыла, исемнәре атала).*

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр;

Җырлаганда көй өчен “тавыклары җырлай” диләр.
Гәрчә анда тугмасам да, мин бераз торган идем;
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем. («Шүрәле»)
Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.
Кич иде. Шатлык белән нурлар чәчеп ай ялтырый;
Искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый. («Пар ат»)
Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным, тәнем белән. («Туган авыл»)
Барлык күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!
Бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен: бәйрәм бүген! («Бәйрәм бүген»)
Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә,
Аһ! оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.
Булса калдырмак берәү ошбу җиһанда изге ат,
Тир белән тапсын ашарын, итсен әлбәт иҗтиһад. («Эшкә өндәү»)
Кырга ак кардан
Юрган ябылган;
Җир язга чаклы
Уйкуга талган.
Ул тормас, йоклар,
Кышлар үтмичә, –
Кыйбладан кошлар
Кайтып җитмичә. («Җир йокысы»)

Афәрин, укучылар, хәзер дүртенче баскычка аяк басабыз. Биредә табышмакларга җавап табарга кирәк була. Без табышмакларны укыйбыз, урыннан кычкырып түгел, ә кул күтәреп җавап бирелгән очракта гына кабул ителә. *(Табышмаклар укыла, җаваплар бирелә).*

Кулдан-кулга йөри ул,
Бөтен телдә сөйли ул,
Белмәгәне юк аның,
Көзгесе ул дөньяның. (Китап)
Бик күп телләрне белсә дә,
Сөйләшми бер телдә дә.
Өйрәним дисәң Өйрәтә,
Карышмый бер кемгә дә. (Сүзлек)
Ачыдан ачырак, татлыдан татлырак,
Усалдан усалрак, дөрестән дөресрәк. (Тел)
Аягы юк – китәр,
Җибәргән җиргә җитәр,
Кушкан йомышны үтәр. (Хат)
Күңелсезгә – юаныч,
Күңеллегә – куаныч. (Җыр)
Җир өстендә күп кешеләр,
Кар өстендә кара-соры чәчәкләр. (Язу)

Бик яхшы, укучылар, хәзер «Белем кояшы»на иң якын баскычка менеп җиттек, укучылар, әйдәгез, бишенче баскычны ачыйк әле.

Татар теленең матурлыгына игътибар иткәнегез бар микән? Искиткеч нәфислек! Татар әсәрләренең һәрберсен җыр белән тиңләп була.

Китаплар укып без тормышны өйрәнәбез, чөнки аларда бик күп акыл хәзинәсе тупланган. Ул хәзинәне бернинди компьютор да, телевизор да алыштыра алмый. Китап укып, без белем алабыз, уйланабыз. Китап геройларыннан үрнәк алабыз һәм кайберләренә

охшамаска тырышабыз. «Китап – бакча, андагы язулар – шул бакчаның гөлләре», – дип язган бит Каюм Насыйри да. (Презентация)

Ә хәзер Әзһәр Габидинең яна китабы белән танышырбыз. Шагыйрь турында бераз әйтеп үтәм. Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин Сарман районы Чукмарлы авылында яшәп иҗат иткән шагыйрь. Балалар өчен бик күп шигырьләр язган. Безгә аның «Без – яз дуслары», «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Таң сәгате», «Калган эшкә кар ява» исемле китаплары инде таныш. Конкурста катнашыр өчен без шагыйрьнең «Мыеклы малай», «Әхияр белән кыяр», «Хәйләкәр төлке, алдатмас керпе», «Бакчада», «Һавалы чеби», «Җигелгән җил» исемле шигыйрьләрен ятладык, шулаймы?

(*Укучылар шигырьләр сөйли*).

Укучылар, әйдәгез, яна китап белән танышыйк.

Китап тышыннан ук үзенә тартып тора, якты, матур төсле рәсемнәре белән җәлеп итә. Ә китап эче – җанлы хәзинә! Һәрбер бит шигырьләр эчтәлегенә туры китерелеп, искиткеч матур, төсле рәсемнәр белән баетылган.

Шагыйрь шигырьләрен мавыктыргыч әкиятләр, башваткычлар, табышмаклар һәм тапкырлык таләп иткән шарадалар рәвешендә бирә. Алар зиһенне арттыра һәм эзлекле фикер йөртергә, чынбарлыкны дөрес аңларга өйрәтә.

Эчтәлеге 8 бүлектән тора: «Яз шатлыгы», «Җәй көннәре күңелле», «Көзләр аша – кышка таба», «Укыйбыз, белем алабыз», «Чәчәкләрдә кунакта», «Әкиятләр сөйләп алыйк әле», «Тапкырларга – табышмак», «Шарадалар». Соныннан Әзһәр Габидинең биографиясе бирелгән.

Укучылар, әйдәгез, хәзер шигырьләр белән дә танышып үтик *(Шигырьләрне уку, анализлау, фикерләрне әйтү).*

Афәрин, укучылар! Сез бүген дәрестә бик актив булдыгыз, үзегезне төрле яктан күрсәттегез. Менә шулай әкрен генә биремнәрне үтәп, «Белем кояшы»на да барып җиттек. «Белем кояшы» ул – сезнең мәктәптә алган белемнәрегез, кызыксынучанлыгыгыз, белемгә омтылышыгыз. Мин сезнең нинди актив булуыгызны күрдем, белемгә омтылуыгызны, телгә хөрмәт хисегезне күрдем. Сез аны беркайчан да югалтмагыз, укучылар.

**IV.** *Укытучы:* Ә хәзер, укучылар, барыбыз да басып, «Туган тел» җырын җырлап, тәрбия дәресебезне йомгаклыйбыз.

## Шушы яктан, шушы туфрактан без…

(Сыйныф сәгате)

Гыймадеева Римма Зөфәр кызы, Гыйлфанова Ильмира Альберт кызы Сарман гимназиясе укытучылары, Сарман районы

**Максат:** Вәсимә Хәйруллина, Әзһәр Габиди, Дамир Гарифуллин иҗаты белән танышу, туган якка багышланган шигырьләрне уку.

Укучыларда туган якка, туган җиргә, аның халкына мәхәббәт, горурлык, соклану хисләре тәрбияләү; сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру; укучыларның эстетик зәвыкларын үстерү.

**Материал:** якташ язучылар китаплары, компьютер

**Барышы:**

Магнитофоннан «**Шушы яктан, шушы туфрактан без»** дигән җыр яңгырый. Рәис. Нәгыймов көе, Клара Булатова сүзләре

Читтә йөргән чакта, сагындырып,
Керер өчен төнлә төшеңә.
Алсу таңлы, биек зәңгәр күкле
Туган ягы кирәк кешегә.
Зур уңышлар яулап заманалар
Матур бәя бирсә эшенә,
Шатлыкларын уртаклашыр өчен
Туган ягы кирәк кешегә.

Ф.Яруллин

- Әйе, безнең туган ягыбыз – Сарман ягы, җырларда җырланган сандугач сайрар ягыбыз. Сарман ягы талантларга искиткеч бай. Безнең як Илһамнары, Зөһрәләре белән мактана ала. Безнең якта туып-үсеп, канат чыгарган Аяз Гыйләҗев, Сөббух Рафиков, Әзһәр Габиди, Клара Булатова, Мәдинә Маликова, Хәниф Хәйруллиннар күренекле язучы, шагыйрьләр булдылар. Алардан алган эстафетаны Дамир Гарифуллин, Вәсимә Хәйруллина, Гөлнара Якуповалар үз кулларына алдылар. Кыскасы, Сарманда әдәбият-сәнгать дөньясы туктаусыз гөрләп тора.

Саумы, кояш! Саумы, елга!
Саумысез, урманнарым!
Саумысез, кошлар, чишмәләр,
Авылым урамнары.

1. Исәнмесез, таулар, кырлар,
Күлләрем, камышларым!
Саумысез, җәнлек, бөҗәкләр,
Дусларым, танышларым!
2. Хәерле көн, туган авылым!
Яңа көнем, бул изге!
Алып кил җиргә бәрәкәт
Куандыр әле безне.
3. Исән булыйк һәркайсыбыз,
Таң туды сәламләшик.
Табигатьнең җаны бит без,
Бер бөтен булып яшик.

«Хәерле көн». В.Хәйруллина сүзләре.

- Шигырь нәрсә турында? *( Туган авыл)*
- Туган авылны икенче төрле ничек әйтеп була? ( *Туган җир, туып үскән җир)*
- Димәк, бүген сүз нәрсә турында барачак? (*Туган авыл, туган җир*)

**Магнитлы тактага «Туган авыл», «Туган җир» дигән сүзләр куела.**

- Димәк, бүген сыйныф сәгатендә без нәрсә турында сөйләшәчәкбез? (....)
- Әйе, без бүгенге сыйныф сәгатендә үзебезнең туган ягыбыз, туган ягыбызда иҗат иткән язучыларыбыз турында сөйләшәчәкбез, аларның шигырьләрен тыңлаячакбыз. Ләкин безнең дәрес үзенчәлеклерәк булыр, без рәсем дә ясарбыз, шигырьләр дә укырбыз, кроссворд та чишәрбез, үзебезне шагыйрь итеп тә сынап карарбыз.

**1нче тукталыш –(слайдта Сарман гербы) рәссам тукталышы.**

Безгә сары, яшел, кара карандашлар кирәк була.Сезнен алдыгызда – Сарман районы гербы, *Татарстан Республикасының Сарман муниципаль районы гербы*. «Караңгы кызыл җирлектә – җырлаучы сандугач; аскы ягында щитның ике почмагы да яшел төс белән, түгәрәкләп һәм аска чыгып китә торган ике фигура белән аерымланган: уңнан – алтын башак, сулдан – кара ташкын белән».

Герб символикасын нигезләү.

Кошлар кешеләрдә һәрвакыт гадәти булмаган хисләр тудыра. Җирдән өскә күтәрелеп оча алуларыннан чыгып, алар бик күп төрле, бигрәк тә рухи үсеш һәм иҗат белән бәйле сыйфатларга ия, дип исәпләнгәннәр. Символ буларак, кошлар күп нәрсәне аңлаткан. Сарман районы гербында сандугач күтәренкелек, иҗат итү һәм алга омтылыш символы булып тора. Җырлаучы сандугач җирле халыкның мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге уңышларын күрсәтә. Кызыл төс сандугач символикасын тулыландыра, шулай ук Сарман табигатенең матурлыгын һәм халыкның хезмәт сөючәнлек, ныклык, оптимизм кебек сыйфатларын чагылдыра.

Районның икътисади үсешен, аның хуҗалык итү нигезен тәшкил иткән авыл хуҗалыгы алтын башак һәм табигать, сәламәтлек, уңдырышлылык, тормыш үсеше символы булган яшел төс белән чагылдырылган. Алтын – байлык, тотрыклылык, ихтирам һәм акыл символы. Район икътисадының икенче өлеше – нефть тармагы – кара ташкыннар белән күрсәтелгән. Кара төс – тыйнаклык, акыллылык, яшәешнең мәңгелеге символы.
Шулай итеп, герб символлар теле белән һәм аллегорияләр аша районның мәдәни, табигый һәм икътисади үзенчәлекләрен чагылдыра.

Авторлар төркеме: *герб составында Рамил Хәйретдинов (Казан), Радик Салихов (Казан), Илнур Миңнуллин (Казан), Константин Моченов (Химки), Кирилл Переходенко (Конаково), Оксана Афанасьева (Мәскәү), Раил Ямашев (Җәлил бистәсе), Эльмира Аскарова (Сарман) булган Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Геральдика советы һәм Россия Геральдачылары союзы тарафыннан эшләнде.*

(Парларда эш: гербны слайдта күрсәтелгәнчә буяу)

**2 нче тукталыш.** Туган ягым шагыйрьләре (Слайд)

Сарман ягы талантларга бай. Бүгенге көндә Сарман якларыннан 25ләп шагыйрь һәм прозаик үсеп чыкты. Бу кадәр язучының әлегә Арчадан кала республикабызның бер генә төбәге дә бирә алганы юк. Шулар арасында балалар һәм зурлар өчен дә матур-матур шигырьләр иҗат итүче язучыбыз – Әзһәр ага Габиди.

Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин 1926 елның 26 сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында урта хәлле крестьян семьясында туа. Җидееллык мәктәпне бетереп, Сарман урта мәктәбендә укып, унынчы классны тәмамлап, фронтка китә һәм, яраланып, госпитальләрдә ята. 1945 елда «Тревога» исемле фронт газетасы типографиясендә аның «Борылмалы юллардан» исемле китабы басыла.

Язучының бүгенге көнгә балалар өчен «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Калган эшкә кар ява», «Таң сәгате», «Без – яз дуслары», «Югалган кояш», «Күлдәвектә кояш көлә» китаплары дөнья күргән.

Әзһәр ага Габидинең балалар өчен язган шигырьләре туган як, андагы вакыйгалар, күренешләр турында. Аларның һәркайсына шагыйрь балалар күзлегеннән карап бәя бирә.

Туган ил, туган җир темасы Ә. Габидинең балалар өчен язган шигырьләрендә кызыл җеп булып сузылган. Төрле образлар аша ул туган як җиренең уңдырышлылыгы, муллыгы турында сөйли. Мәсәлән, «Нарат» шигыре. (1 укучы сөйли)

Ә. Габиди балалар психологиясенә хас булган тискәре сыйфатлардан көлә, уңай сыйфатларга, киресенчә, дан җырлый, бу сыйфатларны яшь укучыда күрергә тели. Бу турыда шагыйрь ачыктан-ачык әйтми, ә бәлки киная белән яшь укучыга нәтиҗәләр ясарлык итеп сөйли. «Һавалы чеби» шигырендәге чуар тавык чебие кебек һаваланып йөрсәң, песи тырнагына эләгерсең, «аерылганны аю түгел, песи дә ашый». (1 укучы сөйли).

Слайд. Клара Булатова Клара Тариф кызы Булатова 1936 елның 18 мартында Татарстан АССРның Сарман районы Татар Карамалысы авылында туган. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа күрә Кларага бала чактан ук әти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күченеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә, өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, ә урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыга. Шул ук елның көзеннән Клара Булатова үзе дә эшли башлый: Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч классларда балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәттәге көнкүреш комбинатында кассир, «Төзүчеләр» клубында оештыручы була. 1962-1965 елларда ул яңадан мәктәптә – Әлмәт районының Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта. Клара Булатова шул елларда даими яза башлый. Әле мәктәп елларында ук аерым шигырьләре матбугатта күренгән яшь шагыйрә Әлмәттәге әдәби түгәрәккә йөри, һәм 1956 елдан башлап «Татарстан яшьләре», «Совет Татарстаны» («Социалистик Татарстан») газеталарында, «Пионер» («Ялкын»), «Азат хатын», «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналларында аның күп кенә шигырьләре дөнья күрә. 1965-1969 елларда Клара Булатова Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам иттерә: 1965 елда аның шигъри бәйләме «Дуслык» исемле күмәк җыентыкта басылып чыга. 1967 елда «Язлар алда» исемле мөстәкыйль китабы дөнья күрә. Университетны тәмамлаганнан соң, Клара Булатова Әлмәт районының Яңа Кәшер урта мәктәбенә тел-әдәбият укытучысы булып китә. Шуннан соң ул бөтен гомерен балалар укытуга һәм иҗатка багышлый. Хәзерге көндә ул – дистәләгән шигырь китаплары һәм күпсанлы җырлар авторы.

**Укучылар шигырьләрен сөйли: «Эшләп ашый», «Авыл урамыннан гармун үтә», «Онытма», «Шушы яктан шушы туфрактан без…»**

**3 нче тукталыш.   Кроссворд чиш  тукталышы** (Әзһәр Габиди табышмакларыннан төзелгән)(сыйныф 3 төркемгә бүленеп чишә)

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1)к | а | р | **т** | а | | |
| | | | 2)с | **у** | г | а | н |
| 3) к | ү | л | ә | **г** | ә | | |
| | | | | **4)а** | ю | | |
| 5)к | а | в | ы | **н** | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | **я** | | | |
| | | | | **6)к** | ы | ш | |

1) Күлләре бар – суы юк,
   Чүлләре бар – комы юк,
   Таулары бар – кар ятмый,
   Аны белгән адашмый. (Карта)
2) Күлмәгем алтын төсендә,
   Тәнем минем бүз кебек.
   Торалар минем күлмәкне
   Салдырганда яшь түгеп. (Суган)
3) Болыт булса, эзләмә дә,
   Ул чакта мин күренмим.
   Кояш чыкса, ай калыкса,
   Гел синнән калмый йөрим. (Күләгә)
4) Асрамаса да умарта,
   Балны  бик тә ярата.
   Кышын сөя йокыны,
   Язгача тормый ята. (Аю)
5) Түтәлдә яткан чагымда
   Тулып торам вй кебек.
   Табынга ярып куйганда,
   Эчем сары бал кебек. (Кавын)
6) Балта остасы да түгел,
   Елгага күпер сала.
   Язларын аны сүтә дә
   Төньякка китеп бара. (Кыш)

**4 нче тукталыш** Яшь шагыйрьләр  Синквейн алымы белән шигырь төзү
Тема: Туган авыл
Туган авыл
Кадерле, якын
Яратам, горурланм, сөенәм
Туган авылымны яратам, горурланам
Жылылык

Ә хәзер **Фәнис Яруллинның «Туган ягы кирәк кешегә»** шигырен тыңлап китик.

Һәр кеше өчен туган як газиз булган кебек, һәр мәртәбәле, данлыклы шәхес туган төбәкнең бизәге булып тора. Бүген без районыбызның йөзек кашы булырдай кешеләре белән таныштык, шигырьләрен укыдык. Туган якның горурлыгы булган шагыйрьләре белән таныштык. Туган як белән горурлану хисе тагын да артты.

**Нәтиҗә ясату.**

Без үзебезнең авыл, аның уңган, күренекле кешеләре белән горурланырга тиешбез.  Шушы якта, шушы җирдә туып үскән балалар буларак, без аларның йөзенә, эти-әниләргә, әбиләргә, бабайларга кызыллык китермәскә тиешбез.

**Йомгаклау. «Туган ягым» проекты ясап килергә (Төркемнәрдә эш.)**

## Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты буенча ачык дәрес

Галиәхмәтова Г.И., Бариева-Саетгараева Г.Ф., икенче Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы

**Максат:** Якташыбыз иҗатына кызыксыну уяту. Өйрәнелгән материал буенча балаларны сөйләмгә чыгару. К.Булатованың тормыш юлын, иҗатын өйрәнү һәм аның иҗаты буенча газета ясау.

**Җиһазлау:** проектор, презентация, К. Булатова иҗатына багышланган аерым битләрдә өстәмә мәгълүмат, карточкалар, фотосүрәтләр, төсле каләмнәр, А3 форматындагы кәгазь битләре һ.б.

**Дәрес барышы.**

I. Дәресне башлау, уңай психологик халәт тудыру.

Арткы фонда салмак кына көй уйный. Укучылар ике төркемгә бүленеп утыралар. Дәрес барышында һәр төркем К.Булатованың иҗатына багышланган газета ясап барырга тиеш. Газетаны ясау өчен һәр төркемгә әзер рәсемнәр, мәгълүмат язылган битләр һәм А3 форматында булган бит укучылар өстәленә әзерләнгән. Дәрестә кулланыр өчен өстәмә ярдәмлекләр таратылган. Дәрес ахырында һәр төркемгә ясалган газеталарын якларга кирәк булачак.

Укытучы «Шушы яктан, шушы туфрактан без» шигыренең 1 куплетын укып ачык дәресне башлап җибәрә.

**Укытучы:** Хәерле көн, хөрмәтле укучылар! Килгән кунаклар! Дәресне башлыйбыз.

II. Уку мәсьәләсен кую һәм чишү.

**Укытучы:** Укучылар, сез «Шушы яктан, шушы туфрактан» шигыреннән өзек тыңлап үттегез. Ничек уйлыйсыз, бу шигырьне кем язган икән? (Укытучы К.Булатованың фотосүрәтен курсәтә). Сезгә бу шәхес танышмы?

**Укучылар:** Клара Булатова.

**Укытучы:** Җавап бирегез әле миңа, ничек уйлыйсыз, бүген дәрестә без кемнең иҗаты белән танышабыз?

**Укучылар:** Якташ язучы Клара Булатова иҗаты белән.

**Укытучы:** Клара Булатова хакында нинди мәгълүматлар билгеле сезгә?

**Укучы:** Минем туганнарым Әлмәт районы Нәдер авылында яши. Клара Булатованы шунда кургәнем бар, хәтта ул минем апамнарга кунакка да кергән иде.

**Укытучы:** Димәк, укучылар К.Булатова Әлмәт районының Нәдер авылыннан икәне ачыкланды.

Дәреснең темасы укыла.

**Укытучы:** Шулай итеп, бүгенге дәресебезнең темасы: «К.Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты». Бу тема юкка гына алынмады, чөнки, билгеле булганча, 2021 елда К. Булатованың 85 яшьлек юбилее билгеләнеп үтәчәк.

**Укытучы:** Укучылар, бүгенге дәресебезгә нинди максат куярбыз икән?

Дәреснең максаты укыла.

**Укытучы:** Әйе, укучылар без бүген дәресебездә К.Булатованың тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнербез һәм аның нинди мактаулы исемнәргә лаек булуын ачыкларбыз.

К.Булатованың тормыш юлы турында махсус әзерләнгән өч укучы кыскача сөйләп китә. Проекторда әзерләгән презентация ачыла. Төркемгә бүленгән укучылар шулвакытта мөһим фактларны презентация аша газетага билгеләп баралар.

**1 нче укучы:** Шагыйрә Клара Гариф кызы Булатова 1936 елның 18 мартында Татарстанның Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Әти-әнисе укытучылар булганлыктан, Кларага бала чактан ук әти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күчеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче сыйныфка укырга керә, өченче сыйныфтан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, ә урта белемне 1954 елда Сарман урта мәктәбендә алып чыга. Шул ук елның көзеннән К.Булатова хезмәт юлын башлый: Түбән

Ләшәү авылы мәктәбенең башлангыч сыйныфларында балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәт шәһәрендә көнкүреш комбинатында кассир. Төзүчеләр сараенда оештыручы вазифаларын башкара. 1962–1965 елларда ул янәдән мәктәптә – Әлмәт районының Колшәриф авылы балаларына тел-әдәбият, тарих фәннәре укыта. 1965-1969 елларда Клара Булатова Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында белем ала. Университетны тәмамлаганнан соң К. Булатова Әлмәт районының Яна Кәшер урта мәктәбенә тел әдәбият укытучысы булып китә. 1970 елдан башлап К.Булатова – Язучылар союзы әгъзасы.

**Укытучы:** Хәзер һәр төркемгә 5 минут вакыт эчендә К.Булатова тормыш юлы картасын ясарга кирәк була.

**2 нче укучы:** Аның бер бәйләм шигырьләре рус теленә тәрҗемә ителә. Бүгенге аның кырыктан артык китабы дөнья күрде. Ул укытучы буларак бик күп шигырьләрен балаларга багышланган. «Үзеннән үзе туа җыр» җыентыгында аның шигырьләренә язылган көйләре дә ноталар белән күрсәтелгән. Аның шигырьләренә безнең күренекле композиторларыбыз көйләр язган. Әлбәттә аның шундый күренекле шагыйрә булып китүенә гаиләсенең дә йогынтысы булмый калмаган. Аның тормыш иптәше Нәфис абыйга, бигрәк тә яраткан улы Марска багышлап язылган шигырьләре дә бик күп. К.Булатова поэзиясенең нигезендә – тормыш һәм иҗади хезмәт шатлыгы, тугрылык, дуслык һәм мәхәббәт кебек якты хисләр ташкыны. Соңрак чордагы иҗатына нечкә лиризм, уй-кичерешләрдә табигыйлек, фәлсәфи яңгыраш хас. Аны гомер узу, рухи кыйммәтләрнең югала баруы борчый.

**3 нче укучы:** Нефтьчеләргә, төзүчеләргә, авыл хезмәтчәннәренә багышланган «Язлар алда» дип исемләнгән беренче лирик шигырьләр җыентыгы 1967 елда дөнья күрә. «Һәрвакыт янымда» (1969), «Җәйләр җитсә» (1972), «Гел кояшка карап» (1981), «Печән өсте» (1986), «Хәтер тәрәзәләре» (1989), «Миләш кагы» (1991) китапларындагы шигырьләрдә замана кешесенең уй-хисләре, тирән кичерешләре чагыла. «Хәтер көзгесе» (Уфа, 1996), «Якты сагыш» (1996), «Әрнү» (2003), «Каурый канат – Җил Атым» (2006) исемле шигъри җыентыкларында сызлану, сыкрау кебек экзистенциаль мотивлар арта бара. Балаларга атап язылган «Марс китабы» (1982), «Курка димәгез әле» (1994), «Әллә кайсын тыңлыйсы ...» (Уфа, 1995) китапларына кертелгән шигырьләре күңел җылысы, җиңелчә юмор белән аерылып тора. Хикәя-повестьлары, истәлекләре тупланган «Яшел каләм» җыентыгы (2003) – автобиографик характерда.

**Укытучы:** Һәр төркемгә карточкалар таратыла, укучылар сузтезмәләрдән шагыйрә яшәгән төбәкнең исемен табалар. (1 минут вакыт бирелә).

III. Ял минуты.

**Укытучы:** Укучылар, ял минуты үткәреп алыйк. Күзләрегезне ябыгыз, якташ язучының туган елын искә төшерегез, бу саннарны күзләрегез белән ясагыз. Киләсе күнегү, берничә шигырь исемен укып чыгам, әгәр Клара Булатованың шигыре булса, ике тапкыр кул чабасыз, әгәр бу язучының шигыре түгел икән, сез башыгызны чайкыйсыз.

IV. Яңа белемнәр үзләштерүне дәвам итү.

**Укытучы:** Укучылар, дәвам итәбез. Якташ язучыбыз – бик күп мактаулы исемнәргә лаек шәхес, аңа хезмәтләре өчен бик күп мактаулы исемнәр бирелгән, газетага мактаулы исемнәрне билгеләп, язып барыгыз.

- 1978 елда аңа РСФСР мәгариф министрлыгы тарафыннан «Укытучы–методист» дигән мактаулы исем бирелә.
- 1994 елда Рафаил Төхфәтуллин премиясе лауреаты.
- 2007 елда Саҗидә Сөләйманова премиясе лауреаты.
- 2015 елда Габдулла Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты.
- 2019 ел Татарстанның халык язучысы исеме бирелгән.

V. Дәресне йомгаклау. Рефлексия.

**Укытучы:** Укучылар, дәрес башында куелган максатларны искә төшерик әле.

Ничек уйлыйсыз, без аларга ирештекме?

Бүген без сезнең белән нинди шагыйрәнең иҗатын өйрәндек?

К.Булатова нинди темаларга иҗат иткән икән?

**Укытучы:** Дәрес ахырына якынлаша, сүзне төркемнәргә бирәбез, ясаган газеталарны безгә күрсәтеп, яклавыгыз сорала. (5 минут)

| № | Дәрестәге укучының эшчәнлеге | баллар | үз-үзеңә бәя |
|---|---|---|---|
| 1. | Газетаның дөрес эшләнеше | 2 балл | |
| 2. | Газетаны яклау | 1 балл | |
| 3. | Дәрес барышында укытучы соравына җавап бирү | 2 балл | |
| 4 | Дәрескә кызыксыну уяту | 1балл | |

Соңыннан укучыларга аерым әзерлектә үз-үзеңне бәяләп, билгеләр куеп чыгарга кирәк була.
VI. Өй эше. К.Булатованың тормыш юлы, иҗатын сөйләргә әзерләнеп килү.

## Каурый канат – Җил Атым

(2-3 нче сыйныф укучылары өчен телдән журнал)

Вахитова Люция Мансур кызы, икенче санлы Җәлил урта гомуми белем бирү мәктәбе укытучысы, Сарман районы

**Максат**: укучыларны К. Булатова иҗаты һәм тормыш юлы белән таныштыру; сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү; туган якка аның табигатенә ихтирам итү хисләре тәрбияләү;укымышлы, әдәпле кешене олылау, белем-мәгърифәтне мактау турындагы фикерләрне үстерү.
**Регулятив универсаль уку гамәлләре:** укытучы ярдәмендә чараның максатын белү, үз фикереңне дөрес итеп әйту;
**Танып белү универсаль уку гамәлләре:** кирәкле информация туплау, тормыш тәҗрибәсеннән алган информацияне файдалана белү;
**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:** үзеңнең фикереңне телдән матур итеп әйтә белү;башкаларны ишетә һәм тыңлый белү;
**Планлаштырылган нәтиҗә*:*** укучыларда шигърият белән кызыксыну уяту; иҗади мөмкинлекләрен активлаштыру, уйланырга, мөстәкыйль фикер йөртергә юнәлеш бирү.

Матур итеп бизәлгән сыйныф бүлмәсе. Клара Булатованың китапларыннан күргәзмә, иҗатына багышланган интерактив тактада презентация.

И. Шакиров башкаруында «Чыгарсынмы каршы алырга» җыры яңгырый. Музыка астында алып баручы укытучы чыга. Ул Клара Булатованың «Сарманым» шигырен укый.
***Укытучы***. Хәерле көн кадерле укучылар! Без бүген сезнең белән танылган шагыйрә Клара Булатованың тормыш юлын,җыр кебек бер укуда хәтердә кала торган шигырьләре белән танышып китәрбез.

1нче укучы.( «Җырдан башка яшәп булмый» шигырен укый.)

**Укытучы:** Ә хәзер сүзне журналыбызның баш мөхәрриренә бирәбез.
**Баш мөхәррир**. Кадерле дуслар! Хәзер журналның беренче битенә тукталып китәбез. Беренче бирем. Танылган шәхесләр арасыннан шагыйрә Клара Булатованың фотографиясен эзләп табарга.
*Вакытны ком сәгате белән билгелибез.*



**Укытучы**. Әйе, нәкъ моннан 85 ел элек, Клара Гариф кызы Булатова 1936 елның 18 мартында Татарстан АССРның Сарман районы Татар Карамалысы авылында дөньяга нур өстәп, гаиләгә бәхет-куанычлар алып, чегән кызларыдай кара чәчле, якты чырайлы кыз бала дөньяга килә. Әти-әнисе аны бик яратып, киләчәгенә зур өметләр баглап балага Клара дип

исем бирәләр. Анын этисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа күрә Кларага бала чактан ук эти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күчен йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә, өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, ә урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыга. Шул ук елның көзеннән К. Булатова хезмәт юлын башлый: Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч классларда балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәттәге көнкүреш комбинатында кассир, «Төзүчеләр» клубында оештыручы була. 1962-1965 елларда ул яңадан мәктәптә – Әлмәт районының Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта.

***2 нче укучы «Укытучы бәхете» шигырен укый.***

**Укытучы: Ә хәзер сүзне журналыбызның җаваплы мөхәрриренә бирәбез.**

**Җаваплы мөхәррир.** Хәзер журналның икенче битенә тукталып китәбез. Икенче бирем. Шагыйрәбезнең бик күп китаплары дөнья күрде. Шул китапларны пазл итеп җыярга кирәк. *(Китап тышлары төсле битләрдә эшләнә, кисәкләргә бүленә). Ком сәгате белән вакыт билгеләнә.*

***3 нче укучы «Шәкертләрем белән» шигырен укый.***

**Укытучы**: Без инде сыйныфтан тыш уку дәресләрендә Клара Булатованың күп кенә шигырьләре белән таныштык. Авторның үзе туып үскән төбәккә багышланган шигырьләрендә дә канатлы яшьлек ашкынуы һәм изге туган җир туфрагы бербөтенгә әверелеп яши: туган якның агымсулары кебек лирик героебызның йөрәге ярсу, туган як таңнары кебек үк аның йөзе алсу, күкләренең зәңгәрлеге-күзләрендә,кырларының иркенлеге-күңелендә.Шушы хисләр өермәсен туган як шигырьләренең һәр сулышында тоеп торабыз.

**4 нче укучы. «Татарстан, бәхет җырым син» шигыреннән өзек укый.**

Ак каеннар яшел яулык япкан,
Шомыртларым инде бөредә.
Беркая да китмим туган яктан,
Бәхет тулы тормыш-биредә.

**5 нче укучы «Шушы яктан, шушы туфрактан без» шигыреннән өзек укый.**

Шушы якта безнең хезмәт калсын
Мирас булып килер яшьләргә.
Шушы яктан,шушы туфрактан без,
Шул туфракта язсын яшәргә.

**6 нчы укучы «Туган җиремә» шигыреннән өзек укый.**

Аяз күкләреннең зәңгәрлеге
Күзләремә тулган.
Басу кырларынның иркенлеге
Күңелемә сыйган.

**7 нче укучы «Таныш юлда» шигыреннән өзек укый.**

Ә мин менә таныш юлда инде....
Карабашның үрен менгәндә,
Каеннарым биеп каршы килде,
Күмәкләп тә, берәм-берәм дә.

**Укытучы:** Елларны еллар, буыннарны буыннар алыштырып килә. Табигатьтә генә түгел, кеше гомерендә дә вакыт, үзенең кабатланмас билге-сыйфатларын юмартлап өләшә-өләшә, алга йөгерә, якты язларны алыштырып эссе җәйләр иңә, алтын көзләр, ап-ак кышлар алыштыра.















**Ә хәзер сүзне журналыбызның дизайн бүлегенә бирәбез.**

**Баш дизайнер.** Хәзер журналның өченче битенә тукталып китәбез. Өченче бирем.

Хәзер сезгә шагыйрәбезнең төрле шигырьләреннән өзекләр укыла. Сез шушы өзекләргә туры килгән рәсемнәрне табып үзегезнең сыйныф китапханәсенә үз кулларыгыз белән ясалган кечкенә шигырь җыентыгы эшләрсез.

**8 нче укучы «Апрельнең уналтысы» шигыреннән өзек укый.**

Апрельнең уналтысы –
Язның нәкъ кыл яртысы:
Кара җирләр ачыла,
Утырып яз атына,
Карамый да артына,
Күңел җәйгә ашыга.
Җәйгә ашыга.

**9 нчы укучы «Бер җәйге көн миңа бирегез сез!» шигыреннән өзек укый.**

Күбәләкнең тыйнак лепердәвен,
Юкәләрнең өнсез дәшүен,
Ут-сагышын сары гөлбадранның,
Гөлҗимешнең нечкә чәнчүен
Каеннарның кайнар пышылдавын
Җырларыма гына теркәрмен.

**10 нчы укучы «Сәйлән чәчәк» шигыреннән өзек укый.**

Таптамагыз меңьяфракны,
Анда саулык билгесе бар,
Сәйлән чәчәк – меңьяфракта
Мең яшәтер җир көче бар.

**11 нче укучы«Игенчегә» шигыреннән өзек укый.**

Без бөртекләр идек,синең куллар
Буразнага салган вакытта.
Хәзер кара! Күкрәп үскән бодай
Туклык исен кырга тарата.

**12 нче укучы «Ак чәчәкле болыннарга» шигыреннән өзек укый.**

Ак чәчәкле болыннарга –
Ромашкалар иленә –
Август килде....
Август килде...
Август шул инде менә.

**13 нче укучы «Миләш бит ул ашыгып өлгерми» шигыреннән өзек укый.**

Миләш бит ул ашыгып өлгерми,
Кипшенүгә каршы йөгерми.
Башка җимешләрдәй тиз-тиз пешеп,
Көз җитмәстәй җиргә түгелми.
Миләшләр бит ашыгып өлгерми,
Көз кермәстән җиргә сибелми.


**14 нче укучы «Килде буран» шигыреннән өзек укый.**

Килде буран. Җилпеп керде
Киереп ачып капканы.
Кар сибелде хәтерләтеп
Аккош канат какканны.
Китте буран. Ишегалдын
Ап-ак итеп. Ямь өреп.
Өй кыегын буяп алды,
Канат очын тигереп.









**Укытучы**: Клара Булатованың шигырьләре көйгә салынып, халкыбызның рухи чишмәсенә әверелделәр. Шигырьләрендәге лиризм, гармония, аһәң үзеннән-үзе җыр, көй сорый.

**Җыр тыңлап узарбыз. («Үз ягым» җыры куела Клара Булатова сүзләре, Разим Валиуллин көе)**

**Ә хәзер сүзне журналыбызның реклама бүлегенә бирәбез.**


**Реклама бүлеге җитәкчесе.** Кадерле укучыларыбыз! Сез бүген Клара Булатованың бик матур шигырьләре белән таныштыгыз. Аның иҗаты белән интернет челтәрләрендә, мәктәп китапханәләрендә, китап кибетләрендә даими танышып тора аласыз.


**Укытучы: Укучыларым! Мин бүгенге телдән журналыбызны шагыйрәбезнең бик матур шигыре белән тәмамлыйсым килә.**

Мин – шагыйрә. Мин шигырьләр язам.
Минем бакчам – шигъри түтәлләр.
Мин орлыклар гына чәчә алам,
Җыючылар булыр бүтәннәр.
Мин орлыклар гына чәчәм эле

Чи җирлеккә,кәсле җирлеккә.
Җимешен дә килер җыяр мәле,
Ирешә алса халкым иреккә.
Мин кулыма утлы корал алмам,
Мылтык тотмам, асмам кылыч та.
Мин шигырьләр генә яза алам,
Җир яшәсен өчен тынычта.

Сезнең үз кулларыгыз белән ясаган кечкенә шигырьләр җыентыгы безнең сыйныф бүлмәбезнең китапханәсендә урын алыр.




Ходай шагыйрәбезгә ныклы исәнлек, күңел тынычлыгы насыйп итсен, иҗат чишмәләре саекмасын, картлыгы сөенечтә узсын дигән теләктә калабыз.

Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт. Киләсе очрашуларга кадәр, сау булыгыз.

«Шушы яктан, шушы туфрактан без» җыры белән тәмамлана.

(Рәис Нәгыймов көе, Клара Булатова сүзләре).

**Икмәк – безнең горурлык**

(сыйныфтан тыш чара)

Ризатдинова Э.Х., икенче санлы Җәлил урта мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучысы, Сарман районы

Максат: Укучыларда якташ язучылар иҗаты аша игенче хезмәтенә кызыксыну уяту, хөрмәт, ихтирам тәрбияләү. Икмәк кадерен белергә өйрәтү, ипигә карата сак караш булдыру, сакларга өндәү.

Бүлмә «Икмәкне кадерләгез – Берегите хлеб» плакаты белән бизәлә. Конвертларда ике төркем өчен көзге, язгы күренеш, чәчү эшләрен, урып-җыюны, чагылдырган рәсемнәр әзерләнә. Ике төркемгә дә аскы почмагына икмәк рәсеме ясалган А3 форматлы бит куела. Почмакта төрле төр ипи продукциясен күрсәтүче күргәзмә, чигүле сөлге, ипи-тоз урнаштырыла. «Әзһәр Габиди – якташ шагыйребез», «Ленинград блокадасы» презентацияләре, китап күргәзмәсе кирәк.

**Чара барышы**

**Алып баручы.** Кулымда – яңа гына мичтән чыккан күпереп пешкән түгәрәк икмәк. Никадәр кадерле ул, мәртәбәле ул, олы ул! Әллә нинди ризыклар торса да, аннан башка табында ямь юк. Табын падишаһы ул, тормыш падишаһы! Ул тамагыбезның тук булуын, тормышыбызның мул булуын раслый. Шушы икмәккә караган саен хозурлыгым арта, горурлыгым арта. Борыныма бәреп кергән хуш исендә иркен кырлар исен, җылысында туган туфрак җылысын тоям.

Укучылар, ә сез ипинең өстәлгә ничек килгәнен беләсезме? Моның өчен без сезнең белән төркемнәрдә эшләп алабыз. Сезнең өстәлләрдә менә шундый битләр ята. Аның почмагында мин күрсәткән ипи рәсеме урын алган. Конвертта башка рәсемнәр дә бар. Сезгә шул рәсемнәрне дөрес итеп урнаштырырга кирәк. Менә шушындый икмәк пешкәнче, ипи нинди юллар аша үтә икән ул? Биремне үтәсәк, беләбез.

**Проект эше.**

**Алып баручы.** Хәзер игътибарыгызны экранга юнәлтегез. Видеороликтан икмәкнең өстәлгә ничек килүен карыйк әле. Ә сез үзегезнең эшегезне тикшереп алырсыз.

**Язгы-көзге эшләр турында сөйләүче видеоролик күрсәтелә.**

**Алып баручы.** Һәр төркем үзенең эшенә билге куя. Рәсемнәр дөрес куелса, кояш рәсеме, ялгышкан булсагыз, болыт ябыштырыгыз. (Үзбәя) Кояш ябыштыручылар, икмәк үстергәндә кояш кирәкме? Нигә кирәк? (Җаваплар тыңлана) Ә болыт кирәкме? Нигә кирәк? (Җаваплар тыңлана)

**Алып баручы**. Без ял итеп алыйк. Кич булган, ди, укучылар. (Чүгәлиләр). Әкрен генә кояш күтәрелеп килә. Менә ул бөтен җирне җылы нурлары белән коендыра. Әкрен генә җил исә. Ул көчәя. Болытлар килеп чыга. Шыбыр-шыбыр яңгыр ява башлый. Урамдагы кешеләр өйләргә кереп качалар.

**Алып баручы**. Хәзер тагын игътибарны экраннарга юнәлтик әле. Минем сезне бер шагыйрь белән таныштырасым килә. Презентацияне карый башлаганчы, берничә сорауга җавап бирик:

1. Кемгә без якташ (земляк) дибез?
2. Фронтовик шагыйрь сүзен кем аңлата ала?

**Ә. Габиди турында презентация күрсәтелә.**

**Алып баручы.** Әзһәр Габидинең шигырьләре бик күп, укучылар. Ләкин без бүген аның бер шигыре белән генә танышабыз. Ул «Горурлык» дип атала.

Сүзлек белән танышып алабыз.

игенче улы – сын хлебороба　　　патша – царь
бразна – борозда　　　горурлык – гордость

Шигырьне укытучы укый. Аннан чылбырлап уку оештырыла.

**Алып баручы.** Шигыре белән автор безгә нәрсә әйтергә тели? (Җаваплар тыңлана)

**Алып баручы**. Укучылар, минем сезне күргәзмәгә чакырасым килә. Анда оннан пешерелгән ризыклар бирелгән. Күрәсезме, күпме алар?! Бөтесе тәмле, бөтенесе үзенә чакырып тора.

Ә менә хәзер бу ризыкларның берсе дә калмаган дип уйлыйк. Хәтта күз алдына китерүе дә кыен, балалар. Ә бит андый вакытлар булган. Экранга карагыз.

**Ленинград блокадасы турында слайдлар күрсәтелә.**

**Алып баручы**. Әзһәр Габиди – фронтовик шагыйрь, дидек. Аның сугыш турында, авырлыклар турында язылган шигырьләре дә бар. Автор безне икмәкнең кадерен белергә чакыра кебек.

Икмәкнең кадерен белү ничек була ул, балалар? Әйдәгез бергәләп кагыйдәләр җыентыгы язабыз.

1. Ипине урамга, идәнгә ташламагыз.
2. Артык зур кисәкне алмагыз.
3. Өстәл артында ашагыз.
4. Пычрак кул белән ипигә тотынмагыз.
5. Ипи белән уйнамагыз.

**Алып баручы.** Кагыйдәләрне язарга гына түгел, аларны үтәргә дә кирәк, укучылар. Икмәк өстәлгә килгәнче бик зур юл үтә. Аны үстерүгә бик күп кешеләр көч куя. Димәк, без аны

кадерләсәк, бик күп кешеләрнең хезмәтен дә кадерлибез дигән сүз. Моны онытмагыз. Ә хәзер күргәзмәдән бер тәмле ризык алабыз һәм ашханәгә чәй эчәргә төшәбез.

### «Үз уеным» бәйгесе

(Клара Булатованың тормыш юлы иҗаты буенча)

Низамиева Нурфия Гарәпша кызы, 37 нче гимназия, Казан шәһәре Авиатөзелеш районы

**Максат: у**кучыларны шагыйрә Клара Булатова иҗаты белән таныштыруны дәвам итү; мөстәкыйль эзләнү эшчәнлеген булдыру; Клара Булатова иҗатына кызыксыну уяту.

**Җиһазлау.** Ноутбук, интерактив такта, К.Булатова портреты, К.Булатова сүзләренә язылган җырлар.

**Укытучы:** Исәнмесез! Хәерле көн, хөрмәтле кунаклар, укытучылар, укучылар. Бүген без «Үз уеным» исемле интеллектуаль уеныбызны башлап җибәрәбез. Әлеге чара татар әдәбиятының йөзек кашы булган шагыйрә – Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗатына багышлана.

Уеныбызда катнашучылар: бишәр укучыдан торган 2 команда.

Беренче команда – «Кояш нурлары». Икенче команда – «Замана балалары».

Хөрмәтле тамашачылар! Жюри әгъзалары белән танышып узыйк. (*Жюри әгъзалары белән таныштыру*).

«Үз уенын» дип аталган интеллектуаль уен кагыйдәләрен искә төшерәбез. Уенда шагыйрә Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты буенча сораулар куелган. Сораулар 5 бүлектән тора. Һәр бүлектәге сораулар баллар белән билгеләнә. Иң түбән балл – 50. Сораулар катлаулырак булган саен баллар да югары. Командалар сорауларны чиратлап сайлыйлар. Рәхим итеп, уенны башлыйбыз.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Тормыш юлы** | 50 | 100 | 150 | 200 | 250 |
| **Бу кызык** | 50 | 100 | 150 | 200 | 250 |
| **Кызыклы саннар** | 50 | 100 | 150 | 200 | 250 |
| **Шигырьләр** | 50 | 100 | 150 | 200 | 250 |
| **Җырлар** | 50 | 100 | 150 | 200 | 250 |

**I.Тормыш юлы:**

1. Клара Булатованың туган көне? (1936 елның 18 марты)
2. Клара Булатова нинди гаиләдә туа? (укытучылар гаиләсендә)
3. Клара Булатова нинди бала була? (үзсүзле)
4. Клара Булатова һөнәре буенча кем? (укытучы)
5. Клара Булатованың нинди мактаулы исемнәре бар? (Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Р.Төхфәтуллин исемендәге премия лауреаты, С.Сөләйманова исемендәге премия лауреаты, Г. Тукай исемендәге Татар Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы )

**II. Бу кызык:**

1. Клара Булатованың иң яраткан ризыгы (Ит)
2. 1944 елда Клара Булатова шигырь сөйләп нәрсә ала? (ике бармаклы бияләй)
3. Аңа Тәнәкә дип кем дәшә? (Хәсән Туфан)
4. Клара Булатова исемендәге премия бармы? (Бар. Ул 2011 елдан Әлмәт шәһәрендә бирелә)
5. «Минем 2 байлыгым бар. Берсе – китапларым. Икенчесе – ... .
Ул мине шагыйрә дә, язучы да итте», – ди Клара Булатова. Ул нәрсә? (Хәтер)

**III. Кызыклы саннар:**

1. Клараралар гаиләсендә ничә бала була? (5 бала: 4 кыз 1 малай)
2. Беренче гонорары ничә сум була? (4 сум 20 тиен)
3. Клара Ләке җидееллык мәктәбен нинди билгеләргә тәмамлый? (5ле)
4. Клара Булатованың ничә китабы бар? (40тан артык)
5. Клара Булатовада Хәсән Туфанның ничә хаты саклана? (76)

**IV. Шигырьләр**: «Урманда», «Әниемнең кызы юк бит», «Әниемә», «Татарстан, бәхет җырым син», «Ә мин beләм»,

**V. Җырлар: «**Килмә, йөрмә» (Клара Булатова сүзләре, Гайфулла Абзалов, Сәйдәш Чәчәнбаев көе), «Авыл урамыннан гармун үтә» (Клара Булатова сүзләре, Альфред Ширгазин көе), «Кырга чыктым, юлга чыктым» (Клара Булатова сүзләре, Рәис Нәгыймов көе), «Якын дустың барын онытма» (Клара Булатова сүзләре, Ифрат Хисамов көе), «Шушы яктан, шушы туфрактан без» (Клара Булатова сүзләре, Рәис Нәгыймов көе)

**Укытучы:** Сорауларга җавап биреп бетердек. Сүзне жюрига тапшырыйк.

*Жюри әгъзалары тулаем уен нәтиҗәләрен, ягъни кайсы команда күпме очко җыйганын саный. Командаларның очколары игълан ителә. Бүләкләү.*

**Укытучы:** Шуның белән уенибыз ахырына якынлашты. Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

## Классный час, посвященный 60-летию поэта, прозаика, доктора филологических наук, заслуженного работника культуры Татарстана и России Фарита Яхина

Халикова Л.А., Джалильская средняя общеобразовательная школа №2,
Сармановский район

Цель классного часа: ознакомление обучающихся с творческим наследием писателя Сармановского муниципального района; создание условий, стимулирующих развитие интеллектуального творчества обучающихся.

Задачи классного часа: воспитание у обучающихся толерантности, стремления к взаимопроник-новению культур и сохранению культурных и исторических ценностей; обобщение, изучение и распространение творчества писателя; создание условий для интереса к творчеству писателя;

Яхин Фарит Закизянович – заведующий отделом текстологии, доктор филологических наук, профессор.

Трудовая биография ученого-литературоведа, поэта, прозаика Фарита Яхина тесно связана с Институтом языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан. Окончив в 1983 году историко-филологический факультет Казанского государственного университета, он поступает в аспирантуру при Институте языка, литературы и истории АН СССР. Затем, продолжив работу в 1986-1992 гг. в этом же институте в качестве научного сотрудника, ведет большую научно-исследовательскую работу по изучению памятников древней татарской литературы, рукописных и печатных книг, татарской эпической поэзии начала XX века. В 1988 году защищает кандидатскую диссертацию по истории татарской литературы и журналистики, в 2000 году – докторскую диссертацию на тему «Религиозная мистика и мифология в татарской поэзии». В последующие годы Фарит Закизянович работал директором Литературного музея Г. Тукая в г. Казани (1993-1999 годы), заведующим кафедрой литературоведения Татарского государственного гуманитарного института (1999-2005 годы), профессором Татарского государственного гуманитарно-педагогического университета Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского (Приволжского) федерального университета (2005-2015 годы). В 2015 году вернулся в Институт языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан.

Сегодня вместе со своими коллегами-литературоведами Фарит Закизянович ведет большую работу по комплексному изучению истории татарской литературы, исследованию особенностей формирования и развития жанров, устранению «белых пятен» в освещении истории литературы вообще и в трактовке творчества отдельных писателей. Он автор множества монографий, научных статей, ряда поэтических и прозаических сборников. К 60-летию Ф.Яхина в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова издан сборник «Әдәби сүз хакы», куда вошли как его последние, пока еще нигде неопубликованные труды, так и статьи разных лет.

Сармановской централизованной библиотекой был объявлен интернет-конкурс «Читаем Фарита Яхина». В качестве жюри выступил сам Фарит Яхин, итоги состязания будут подведены на мероприятии, посвященном юбилею ученого.

Основные направления научных исследований: журналистика, теория литературы, средневековая литература тюркских народов, история татарской литературы, исламоведение, рукописные книги и источники.

ӘНКӘЙ

Олыгайсаң да, әнкәй, син һаман яшь,
Буй җитсәк тә бала без, бала,
Күпме гомер, үсәр чакны көтеп,
Ике күзең тала иде, тала.
Җиңел түгел иде ул чак дөнья,
Искә төшсә – көя, җан көя,
Бүген дәле бәхет урынына
Сагыш килеп өя, өскә өя.
Бу чәчләрең күптән агарса да,
Безнең өчен кара, чем-кара,
Егылсак та, чөелсәк тә, әнкәй,
Җыерчыклар сара, йөзең сара.
Әрнисеңдер безнең өчен, тиздән
Оныкларың ата һәм ана,
Олыгайсак та, әнкәй, син һаман яшь,
Кайсыбыз соң бага, сине бага?
Ялгыз калганда да үзең, безне
Ятим итмәдең шул, китмәдең,
Рәхмәт кенә яусын бу тормышка,
Әнкәбездән мәхрүм итмәдең!

ӘНКӘЙ ҖЫЛЫСЫ

Сагынасыңдыр, әнкәй, балам диеп
Көтәсеңдер бик тә зарыгып,
Алты аккош булып кайтып төшсәк,
Алты тараф китәр ачылып.
Каңгылдашып казлар канат какса,
Тетрәнепме куя күңелең?
Салкын көзне ташлап очар өчен
Канатланып кочтым күк йөзен.
Тәнгә – суык, туңам, өшим үзем,
Кыйблагамы баккан ике күз?
Хак тәгалә, бир, дип, җанга түзем,—
Тел очында туңып калды сүз.
Илдә – җылы, өйдә – кояштыр ла,
Тизрәк кайтым әнкәй янына!
Язлар булып безне каршы алыр,
Яшел яулык бөркәп башына!
«Балам!» – диеп бер сүз әйтү белән
Өшегән тән китәр савыгып...
Чиксез күкне каплап салкын болыт
Ил өстендә тора салынып.
Теле арды, туктамады,
Ирен читләре – күбек.

ХАТИРӘДӘН

Бер кайгысыз самим бала идем,
Һәм кош идем, һәм дә бер болан,
Уйнап калды күрше малайлары,

Шаулап калды яшел киң алан.
Ә мин киттем кереп яшьлегемә,
Канат кагып очтым күленә,
Болан булып чаптым тугаена,
Килеп кердем кайнар чүленә.
Адаштыммы, әллә бутадыммы
Тарафларны шушы кичемдә?
Күңелемдә – уты, яше – күздә,
Ялгыз калдым уйлар читендә.
Син гаепле түгел моңа, бәгырь,
Мин үзем дә аңлыйм хәлеңне, –
Мәхәббәтнең богавына чорнап
Кемнәр алган иде хисеңне?
Бер кайгысыз самим бала идем
Һәм кош идем, һәм дә бер болан,
Канатларым каерылган килеш
Утлы чүлдә мәңгелеккә калам!

МИН АВЫЛДАН КИТТЕМ

Мин ул көнне үзем чыгып киттем,
Калды авыл җиргә сыенып,
Юлым якын кебек иде дә шул,
Эзем барды арттан уелып.
Зар елапмы яшем тамды анда?
Яңгырлармы басты тузанны?
Куылганнар хисабыннан түгел –
Кире кайта алмыйм узганны.
Мин һаман да атлый бардым алга,
Максат арбасында җан елый!
Туган илдән киткән бәндәләрне
Чит-ят җирләр якын күралмый.
Бәхетемне эзләп бардыммы соң?
Шатлыгыммы көтте юлларда?
Башымнымы югалтырга барам –
Юлым калса әгәр елларда?
Ни чыдамлык белән түзәр җаным?
Ничек кояш чыгар, көн кичәр?
Кайтырмын дип чыгып киткән идем,
Кайталмадым,
Әнекәем нишләр?

## Клара Булатованың «Ак каен» шигыренә иллюстрация башкару

Нәбиева Сиринә Миргазиян кызы, Урманай авылы гомуми урта белем бирү мәктәбе, Азнакай районы

Максат: шагыйрә Клара Булатованың иҗаты буенча рәсем ясау, шагыйрә иҗатына, китап укуга кызыксыну уяту, шигырь аша туган як табигатенә сак караш тәрбияләү, табигать матурлыгын сурәтләргә өйрәтү; фантазияләрен, эстетик зәвыкъларын үстерү.
Укыту методлары һәм формалары: аңлату-иллюстратив, практик; шәхси, фронталь.
Җиһазлау: Клара Булатова иҗатына багышланган слайд, аерым битләрдә өстәмә мәгълүмат, кәгазь, акварель буяулар, рәссамнәрнең картина репродукцияләре.

Дәрес барышы

**1.Оештыру.** Укучыларның дәрескә әзерлекләрен барлау

**2. Яңа материал өйрәнүгә әзерләү**

- Укучылар, сез матур бизәлгән китаплар укырга, карарга яратасызмы? Бу рәсемнәрнең нәрсә турында сөйләүләрен аңларга тырышасызмы? «Диңгез төбеннән мәрҗән алалар, ә китаптан белем туплыйлар» ди халык мәкале.

- Әйе, китап белем бирә, яңа ачышлар, алга карарга өйрәтә, хәзергене аңларга, үткәннәрне искә төшерергә ярдәм итә.

Элек-электән китап бик кадерле булган, чөнки аны кулдан язганнар, рәсемнәрен ясаганнар. Китапны язу берничә еллар дәвам иткән. Шуның өчен китапның бәясе алтын авырлыгына тиң булган. Хәзер яңа технологияләр гасырында да китап үзенең әһәмиятен югалтмый. Аларның төрле эчтәлектәгеләре нәшер ителеп тора.

Өстәлдәге китапларга игътибар итегез, ниндиләре генә юк. Алар барысы да Әлмәттә яшәп иҗат итүче, шушы елда үзенең 85 еллык гомер бәйрәмен бәйрәм итәргә әзерләнүче шагыйрә Клара апа Булатованыкылар.


Клара Булатова иҗаты барлык яшьтәге кешеләргә: әби-бабайлар, әти-әниләр, яшьләр, үсмерләр өчен дә анлаешлы. Менә аның кечкенә балалар өчен язган «Марс китабы», «Әллә кайсын тыңласы», «Курка димәгез әле», «Камилә – тәти кыз» дигән китаплары чыкты. Бай сурәтләү чаралары аша бу китаплар балаларны яхшылыкка өнди, дөньяны ныграк танып белергә өйрәтә.

Клара Булатова шигриятенең төп темасы – мәктәп, балалар язмышы. Тумыштан ук шагыйрә булган кебек, тумыштан ук укытучы да. Клара ханымның шигырьләре туган якка, газиз туфрагына тирән мәхббәт белән сугарылган. Данлыклы Әлмәт төбәгенең гүзәл табигатенә, иксез-чиксез хәзинә байлыкларына, тырыш, хезмәт сөючән, батыр, фидакарь халкына мәдхия кебек аның әсәрләре.

Шагыйрә үзе җырларга кергән Сарман якларында туып үссә дә, иҗаты Әлмәтнең уңдырышлы туфрагында чәчәк аткан. Биредә аның тынгысыз, якты хыялларга бай яшьлеге, иң җегәрле, көч-куәт ташып торган еллары узган.

Шагыйрә Әлмәт төбәгенең зәңгәр язларын, чәчәкле җәйләрен, моңсу көзләрен, ак мамыклы кышларын, көмеш нурга коенган урамнарын, сихри айлы төннәрен үзенә генә хас поэтик бизәклргә, иҗат фантазиясенә төреп бирә һәм сиздермичә генә фәлсәфи фикер дөньясына алып керә.

Могҗиза тудыра, энҗе бөртекләре коела шагыйрә каләменнән. Аның шигырьләрендә таллар җырлый, өянкеләр елый, каеннар бии. Аның шигырьләрен укыган һәркем бу шигырьләрдә үз аланын, басуларын, эшчәннәрен күрә.









- Укучылар, минем кулда бер үк эчтәлектәге ике төрле китап: берсе рәсемле, икенчесе рәсемсез. Сезне кайсы китап ныграк җәлеп итә? Ни өчен? Сезнең парталарда шигырь юллары язылган кәгазь битләре тора, аларда нәрсә җитми? Әйе, алар рәсемсез, кызыксынп кулга аласы килми. Димәк бүген дәрестә нәрсә белән шөгыльләнәчәкбез? Дөрес, шигырь эчтәлегенә рәсем ясаячакбыз.

**3. Яңа белемнәр үзләштерү**

Китап бизәүнең төп асылы булып иллюстрация тора. Әдәби әсәрнең эчтәлеге һәм мөһим үзенчәлекләре белән бәйле булган сынлы сәнгать (барыннан да ешрак булган сәнгатьле графика) әсәре. Башкарылган рәсем китапның эчтәлеген баета, бизи, мавыктргыч итә. Язучы фикерен сүзләр белән җиткерсә, рәссам исә аны сызыклар аһәңе, төсләр байлыгы белән җиткерә.

- Китап бизәүне нәрсәдән башларга соң?

- Әсәрне укырга, эчтәлеген аңларга. Әгәр шигырьләр җыентыгы икән һәрбер шигырь өчен рәсем ясала.

Бүген сез үзегезне рәссам-иллюстраторлар итеп хис итәрсез һәм Клара Булатованың «Ак каен» шигыренә иллюстрация ясарбыз.

Ак каеным, назлы каенкаем,
Туган җирнең якты бизәге.
Чал шагыйрьләр җанын җырлаттырлык
Чын матурлык, сафлык үрнәге.
Иңнәреңә кичен томан ята,
Иртән аны җилләр тарата.
Ак кәүсәңдә нурлар биетүче
Кояш сине бигрәк ярата.
Күр; көндезен ничек җемелдисең,
Нурландырып төбәк-йортымны.
Ватанымдай иркен күңелле син,
Халкым кебек каты токымлы.

Каен... Каенкай..! Әйе, зифа, бөдрә ак каенны кемнәр генә туган ил, туган як, матурлык алиһәсе итеп кабул итмәгән. Төрле милләт сәнгать кешеләре аны үзенчә зурлый, хөрмәт итә. Ак төс аклык, сафлык, пакълык төсе саналган. Каен Клара апа шигырендә ныклык символы да булып тора («Халкым кебек каты токымлы»).

**Уен «Тылсымлы таякчык»** каен агачы турында белгәннәрен сөйлиләр (таяк кулдан-кулга йөри)

- Каен Россия символы;
- Каенның кәүсәсе ак;
- Каен кешеләрне дәвалый;
- Каен сок бирә;
- Каенның җимешләре бар – алкалар;
- Каен ак туз белән капланган.

Каен – юмарт һәм игелекле агач. Аның файдасын санап китик

- Каен бөресе күп чиргә дәва;
- Каен себеркесе мунчада күп чирне куа;
- Каен яфрагы төнәтмәсе йомырка кабыгын мана;
- Каен суы сәламәтлекне ныгыта;
- Каен урманы көч-куәт бирә;
- Каен тузыннан тырыслар, балаларга курчаклар, савыт-сабалар, шкатулкалар ясаганнар;
- Йортлар төзегәннәр.




**4.Физкульт минут «Каенны тасвирлыйбыз»**

Тынлыкны саклыйбыз, үзебезне каен белән янәшә ялгызыбыз итеп хис итик


1. Күзләрне йомып басабыз, без – шундый нәзек, төз каеннар.
2. Кулларны өскә күтәреп, кояшның яктысына, җылысына үреләбез.
3. Каен ботаклары әкрен генә түбән иеләләр (кулларны төшерәбез)
4. Кул чукларын селкетәбез (алар да каен ботаклары) безгә җылы, рәхәт.
5. Күзләрне ачабыз, әкрен генә утырабыз.


Каен агачы шат күңеллеме, моңсумы? Нинди төсләр белән тасвирлыйбыз?

Күп рәссамнәр каен урманнарын сурәтләгәннәр. Мәсәлән И. Э. Грабарь «Февраль зәңгәрлеге», И.И.Шишкин «Каен урманы» картиналарында күрәбез. Рәссамнәр нинди төсләрне сайлаган?







5. Мөстәкыйль эш

Хәзер каен чибәркәйнең рәсемен ясыйк. Башта агачның төзелешен искә төшерик.




- Агач нинди өлешләрдән тора? (тамыр, кәүсә, ботаклар, яфраклар)
- Башка агачлардан ничек аерыла? (сыгылмалы кара таплы кәүсә, түбәнгә иелгән ботаклар)
- Агач рәсемен ясау нәрсәдән башлана? (кәүсәнең өске өлешеннән)
- Ботаклар кәүсәгә тоташтырыла (тактада акбур белән күрсәтелә) аскы ботакларга караганда өске ботаклар кечерәк һәм кояшка таба сузылалар.



- Бүген мин сезгә Клара Булатованың каеннарын сурәтләргә тәкъдим итәм. («Ак каен» шигырен искә төшерү) Эш барышында нинди буяулар кулланырбыз? Шагыйрә нинди ел фасылын тасвирлаган? «Күр; көндезен ничек җемелдисең», – ди. Нинди ел фасылы булса да ул горур, мәһаббәт. Шигырьне кем ничек күз алдына китерә, шулай сурәтләгез.



Ахырда эшләргә күзәтү оештырыла.

6. **Йомгаклау. Рефлексия**

Бүген дәрестә сез әзләнүчеләр, тыңлаучылар, рәссамнәр булдыгыз. Дәрестә сезгә кем булу ныграк ошады? Шуны белгертеп рәсем почмагына яфрак сурәте төшерегез:

(Яшел – тыңлаучы, сары – эзләнүче, кызыл – рәссам)

7. **Өй эше**

Ясаган рәсемегезгә 4 юллык шигырь язып карагыз

## Фәрит Яхин - күпкырлы шәхес

(Ф.Яхин тормышы һәм иҗаты буенча класс сәгате эшкәртмәсе)

Вәлиева Г.Ә., китапханәче, Закирова Әлфия Ринат кызы, Нуретдинова Айгөл Гамирҗан кызы, икенче санлы Җәлил урта мәктәбенең инглиз теле укытучылары, Сарман районы

Максат: укучыларны Ф. Яхин тормышы, иҗаты һәм әсәрләре белән таныштыру, укучыларда туган якка, районның күренекле шәхесләренә карата кызыксыну уяту һәм хөрмәт тәрбияләү.
Җиһазлау: Ф. Яхинның портреты, китаплары

Эш барышы

<u>1 нче алып баручы.</u> Исәнмесез, кадерле кунаклар, укытучылар һәм укучылар! Сарман ягы – җырларда җырланган, татар тарихының җанлы сәхифәләрен буыннан-буынга язып килүче гүзәл кешеләр яшәгән, фидакарьләрчә эшләгән, күкрәп яшьнәгән илаһи да, моңлы да төбәк. Еракларга сузылган тау тезелмәләре, кояш чыкканда, ярсулы йөрәкләрнең тибешен хәтерләткән сызым-язмаларга охшап күренәдер. Мәшһүр Урал тауларының итәк очлары килеп җиткән бирегә. Борын-борыннан ук шул итәккә тулып, эреле-ваклы авыллар мәш килеп яшәп яталар. Зәңгәр таулардан һәм таллы ярлардан көмеш чишмәләр челтерәп ага, урманнарында кырыс имәннәр, нәфис каеннар, мәңге яшел нарат-чыршылар үсә, яшел аланнарда печәннәр өлгерә, алтын басуларда тук башаклы игеннәр шаулый, офыклардан-офыкларга нефть вышкалары күчә, шул хакта тирәклләрдә кошлар сайрый... Бу матурлык илһам чыганагы.

<u>2 нче алып баручы.</u> Туган ягын яратмаган, аның матурлыгына сокланмаган кеше бар микән?! Күренекле әдипләре, мактауга лаек шәхесләре булса, мондый горурлык хисе бермә-бер арта. Туган ягыбызда яшәүче никадәр күренекле шәхесләребез бар! Сарман районы – бик тә күренекле, исемнәре еракларга билгеле каләм ияләрен үстергән җир. Аяз Гыйләҗев, Хәниф Хәйруллин, Әзһәр Габиди, Нияз Акмал, Клара Булатова, Дамир Гарифуллин, Рафис Гыйззәтуллин, Гөлшат Зәйнәшева, Марсель Зарипов, Мәдинә Маликова, Сөббух Рәфыйков, Адлер Тимергалин, Ямаш Игәнәй, Фәрит Яхин һәм башка бик күпләр әдәбиятка юлны нәкъ менә Сарманнан башлыйлар. Алар үзләренең иҗат җимешләре белән туган җиребезне, аның тырыш, батыр улларын, матур кызларын зурлап, Сарманыбызны данга күмеп, бөтен дөньяга танытып яшиләр. Район халкы хаклы рәвештә үзенең мәртәбәле шәхесләре белән горурлана.

<u>3 нче алып баручы.</u> Гыйнвар аенда якташыбыз Фәрит Яхинга 60 яшь тулды. Үзенең олы юбилеена ул нинди уңышлар белән килде икән? Шул уңайдан без аның тормышы, иҗаты белән якыннан танышырга уйладык. Фәрит Яхин шушы авылда 1961 елның 2 гыйнварында туган. Аның әтисе – Зәкиҗан Әхмәтлатыйп улы, Бөек Ватан сугышы ветераны, авылда иң яхшы балта остасы булып танылган кеше була. Улын кечкенәдән балта эшенә һәм авыл тормышына өйрәтеп үстерә. Әнисе – Тутыя Нургали кызы. Гомере буе күмәк хуҗалыкта

эшли. Хәзерге вакытта алар икесе дә гүр ияләре инде. «Бәхет туфрагым бар» исемле нәсерендә ул туган ягын түбәндәгечә искә ала. «Туган авылыма кайтсам, ни яңгырлы, ни буранлы көннәрдә булсын, күңел бүлмәсенә кояш тула. Дөньялык матураеп, бөтенәеп китә. Сарман төбәгенең, мөгаен, шушы иң матур авылы Дүсем җәннәтнең үзедер кебек. Халкының чибәрлеге, сүздә ягымлылыгы, эштә тырышлыгы, табигатенең матурлыгы аны шулай итә торгандыр! Һәрхәлдә мин үзем алар хакында шулай дип уйлыйм, аларны шулай итеп күрәм, шулай тоям». 1978 елда урта мәктәпне шушы туган авылы Дүсемдә тәмамлый.
4 нче алып баручы. 1978-1983 елларда КДУның тарих-филология факультетында белем ала. 1983-1986 елларда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында, әдәбият бүлегендә, танылган галим Нил Гафурович Юзиев җитәкчелегендә аспирантура уза. Аны тәмамлагач, 1988 елда «Фикер» газетасы һәм «Әлгасрелҗәдид», «Уклар» журналларының татар әдәбияты үсешендәге роле» темасына татар әдәбияты тарихы һәм журналистика белгечлекләре буенча – кандидатлык, 2000 елда «Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология» дигән темага докторлык диссертацияләре яклый. 1986-1992 елларда Фәрит Яхин Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшли, борынгы татар әдәбияты ядкәрләрен, кульязма һәм басма китапларны, XX йөз башы татар эпик шигърияттен өйрәнү буенча күптөрле гыйльми-тарихи тикшеренүләр алып бара. 1993 елның башыннан 1999 елның августына кадәр якташыбыз Казандагы Габдулла Тукай музееның мөдире була. Монда эшләгән елларында музейны яңарту, экспозицияләрен үзгәртеп кору, яңа экспонатлар белән баету, музейда даими рәвештә «Тукай укулары»н уздыру, сынлы сәнгать күргәзмәләре, төрле кичәләр, күренекле әдәбият-сәнгать әһелләре белән очрашулар оештыру кебек мәдәни эшләр башкара. Докторлык диссертациясе әзерли. Ул монография буларак языла. Профессор дәрәҗәсе бирәләр, үз кафедрасы бар.
5 нче алып баручы. Фәрит Зәкиҗан улының аннан соңгы хезмәт биографиясе Татар дәүләт гуманитар институты белән бәйле. Шактый еллар ул Әдәбият белеме кафедрасын җитәкли.

Фәрит Зәкиҗанович – киң эрудицияле, күпкырлы шәхес. Үз аудиториясен тапкан язучы, фәненә мөкиббән галим, студентларына үрнәк остаз, полиглот. Ул – бик кызыклы шәхес.

Бүгенге көндә Фәрит Яхин Казанда яши, Татарстан фәннәр академиясендә эшли. Тормыш иптәше Зөһрә ханым белән бер кыз, бер ул үстереп, оныклар сөенече белән гомер кичерәләр. Җае чыкканда, туган якларына кайтып, туганнары, дуслары белән күрешергә дә вакыт таба ул. Бигрәк тә Сабантуйларын сагынып көтеп ала.

Язучының әдәби иҗат өлкәсендәге беренче тәҗрибәләре узган гасырның җитмешенче елларына карый. Ул шигырьләр, хикәяләр яза. «Сарман таңнары» иҗат берләшмәсенең актив әгъзасы була. Студент елларында университетның «Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсенә йөри, көндәлек матбугатта хәбәрләре, мәкаләләре белән катнаша. Сиксәненче елларда әдәби тәнкыйть эшенә тартыла. Туксанынчы еллар башыннан исә беренчеләрдән булып дини мәсьәләләрне яктырткан әдәби һәм фәнни хезмәтләрен язу эшенә керешә. «Пәйгамбәрләр тарихы» (1992), «Иман» (1993) исемендәге беренче китаплары белән киң җәмәгатьчелектә танылa. 1994-1998 еллар арасында аның өч китап рәвешендә пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәламгә багышланган трилогиясе дөнья күрә. 1999 елда «Раннур» нәшрияты, трилогиянең өч китабын да бергә туплап, «Пәйгамбәребез Мөхәммәт» исеме белән хезмәтне яңадан бастырып чыгара.
6 нчы алып баручы. Ф.Яхин – лирик тезмәләре тупланган өч шигъри җыентык («Гүргә кадәр сакланган сөю», «Таңга кайту», «Хис керфегемдә күз яшең») һәм балалар өчен «Могҗизалы ел фасыллары» дигән әкият-поэма (1994) авторы. Шигърияттә ул үзен катлаулы идея-тематик эчтәлеккә ия булган интеллектуаль поэзия тарафдары итеп саный. Аның «Мөхәммәдьяр» исемле драматик поэмасы 1997 елда Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә спектакль итеп куела. Ул проза жанрында да актив иҗат итә, укучыларга көндәлек матбугатта басылган дистәләрчә хикәя, повестьлары һәм ике кисәктән торган «Август ае», «Көзге яңгырга кадәр», «Куш каен аланлыгы», «Умырзая» дигән романнары белән билгеле. Болардан тыш галим борынгы төрки-татар әдәбияты ядкәрләрен текстологик яктан басмага әзерләү юнәлешендә дә нәтиҗәле фәнни-мөхәррирлек эшчәнлек алып бара. Соңгы елларда басмада дөнҗя күргән Әхмәд Ясәви хикмәтләре, Сәйядинең «Дастаны

Бабахан»ы, Аллаһиярның «Сөбател-гаҗизин»е («Гаҗизләргә терәк»), Мәҗлисинең «Сәйфелмөлек» кыйссасы, «Бакырган китабы» – болар барысы да Фәрит Яхинның турыдан-туры катнашы белән әзерләнгәннәр.

7 нче алып баручы. Ф.Яхин – 1994 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Шактый бай һәм күпкырлы иҗатчы Фәрит Яхинның матбугатта чыккан әсәрләреннән тыш, электрон китапханәсендәге томнары белән дә танышырга була. Биредә 6 томнан торган сайланма әсәрләре һәм 7 томнан торган шигырь һәм поэмалары, драма әсәрләре урын алган. Алар арасында төрле жанрлар: хикәя, хикәят, эссе, хикәя-манифест, хикәя-памфлет, нәсер, баллада, поэма, әкият, хикмәт, роман, повестьлар да бар. Билгеле, шулар арасында, авылдашлар хакында язылган һәм балалар өчен булган әсәрләрен аерым өйрәнергә була. Мәсәлән, «Марҗа яме» исемле кече жанр чәчмә әсәрләре. (Казан, Татарстан китап нәшрияты. 2015). Бу җыентыкка язучының узган гасырның соңгы елларында, яңа меңъеллыкның тәүге елларында иҗат ителгән хикәяләре кертелгән. Алар китап буларак бергә тупланып беренче тапкыр бастырылып чыгарылган. Җыентыкта 148 әсәр бар, шуларның җиде дистәдән артыгында Дүсем авылы кешеләре төп геройлар булып сурәтләнгән, ә үзе турында дүрт дистәдән артык әсәр тупланган. Ф.Яхинның табигать күренешләрен дә үзенең әсәрләрендә тиешле урында бик матур итеп файдаланган язучы. Бу чорда язган әдәби әсәрләрендә ул самими авыл тормышын гына түгел, авыр һәм катлаулы мөнәсәбәтләрне дә яктырта.

8 нче алып баручы. Авыл кешеләренә кагылышлы әсәрләрнең геройлары.

ОСТАЛЫК ХИКМӘТЕ (Хикәя)

(Авылда Таҗи – Таҗетдин һәм Сәлам – Сәламетдин исемле эчәргә яратучы «балта осталары» булып, колхоз эшендә йөргән кешеләр. Зәки – Зәкиҗан Фәрит Яхинның әтисе – бик яхшы балта остасы булган.)

КИЧКЕ ФАТЫЙМА (Хикәя)

(Калимуллин Котдуснең олы малае Айрат Гыйльменисаның кызы Энҗе белән матур гына йөреп өйләнешкәннәр. Аларның малайлары тугач, Айрат эчә башлый. Гаилә таркала. Малай белән хатын Чаллы шәһәрендә яшиләр. Ә Айрат төп йортта берүзе яшәп ята, эчәргә ярата, диләр аның турында авыл халкы.)

ТАТАР ЧӘЕ (Хикәя)

(Имаметдинов Зәйнетдин авылда бик дәрәҗәле кешеләр исәбеннән йөргән. Хатыны белән 5 бала үстергәннәр, алар үсеп, бишесе биш якка чыгып киткән, хатыны үлеп, ул берүзе калган. Фаттахов Фатыйхның олы улы Гүзәл, механик.)

9 нче алып баручы. ЙӨЗ БЕЛӘН ЙӨРҮ (Хикәя)

(Шаяхметов Әлфис һәм аның энесе Ленар турында сүз бара. Әлфис Әфган сугышында булып кайткан, техниканы бик яхшы белә.)

МАҖАРАЛЫ ГЫЙЛЬМЕТДИН (Хикәя)

(Хафазетдинова Хөсникамал апаның олы малае турында сүз бара. Олы малае Рузалин Хәким улы беренче ирдән туган бала. Аның Ләшәү Тамак авылында кызы Калимуллина Илсөяр яши, энесе Хафазетдинов Гайсә, аларның аталары Хәмзә. Сары чәчле мөгаллимә – тарих укытучысы Ханнанова Гандәлиф)

ЧИЛӘГЕНӘ КАПКАЧЫ (Хикәя)

(Хамидуллин Марат белән Хәлимә турында сүз бара. Алар өйләнешәләр. Ике малай тәрбияләп үстерәләр.Башта колхоз биргән өйдә яшиләр, 90 елларда Җәлил поселогына күчеп китәләр. Хәзерге көндә пенсиядә, Дүсем авылында Хәлимәләрнең төп нигезендә яшиләр.)

КИЛОЯРЫМЛЫ КУРА ҖИЛӘГЕ (Хикәя)

(Дүсем авылына хезмәт укытучысы булып, Халиков Әхәт Рәкыйп улы кайта. Ул төгәл һәм үз эшенә бирелгән, таләпчән кеше була. 1968 елларда мәктәп яны тәҗрибә участоклары оештырыла башлый. Бу балаларга хезмәт тәрбиясе бирер өчен кирәк була. Мәктәпкә 5 га мәйдандагы җир бүлеп бирелә. Аны дүрт яктан да өч рәт каен, юкә агачлары белән әйләндереп алалар. Урта өлешенә, алма, груша, карлыган, кура җиләге һ.б. төрле җиләк-җимеш агачлары утыртыла. Яшелчәлек һәм тәҗрибәләр үткәрү өчен дә участок бүлеп куела. Авыл балалары менә шунда кура җиләге ашарга керә торган булалар. Хәлиф – Әмир, Әхәт абый малае)

10 нчы алып баручы **Үз тормышыннан алынган вакыйгалар**

ӘРСЕЗЛЕК (Хикәя)

(Фәрит Яхин үзенең Кужак авылына, этисе өчен чүәк алырга барган вакытын сурәтли.)

**Балачак тәрәзәләре (хикәя)**

(Татар теле укытучысы – Сөләйманова Халидә Сөләйман кызы Каташ Каран авылыннан. Гомере буе балаларга туган теленә мәхәббәт тәрбияләде.)

ЧАЛЛЫ ЮЛЫ (Хикәя)

(Ләшәү Тамак урта мәктәбендә озак елллар тарих фәнен укыткан укытучы. Күптөрле дәрәҗәләргә ирешкән, хәтта орден-медальләргә лаек булган данлыклы укытучы.)

ИСӘНМЕ, ӘБИЕМ (Нәсер)

(Фәритнең Сәйдә әбисе алардан читтә икенче урамда малае Өлфәт белән яшәде. Фәритнең әнисе – Тутыя, аның әнисе – Сәйдә.)

БӘХЕТ ТУФРАГЫМ БАР (Нәсер)

Мин 1978 елда урта мәктәпне шушы туган авылым Дүсемдә тәмамладым. Без – беренче чыгарылыш укучылар идек. Укытучыларыбыз Нәкыйп Арсланов, Халидә Сөләйманова, Әнәс Шәрифуллин, Марс Вахитов, Фирис Хәсәншин, Дамира Гарифуллина, Фәния Корбыевалар ут йотып, бу балалардан кемнәр чыгар икән дип боегып, артларыбыздан карап калганнардыр? Ә без, кошлар кебек тезелешеп, төрле тарафларга юл алдык. Хыялларыбыз югары уку йортларына керү, зур гыйлем туплап кабат туган авылыбызга кайту, туган туфракны бәхетле итү иде. Әмма күпләребезне гомер юлы ераккарак алып китте шул.

11 нче алып баручы. Табигать турында язылган әсәрләр**.**

ӘРСЕЗЛЕК (Хикәя)

Көн матур, елга яныннан гына юл бара да бара. Яшел үлән хәтфәсенә сары, кызыл, күк чәчәкләр чигелгән. Бал кортлары тыз-быз очына,чикерткәләр дертләп-дертләп куя. Зәңгәр күк йөзендә биниһая кояш тантана итә.

ТӨНГЕ ШӘҺӘР ( Нәсер)

Урамда киребеткән кыш иде. Ак бәс юрганын ябынып йоклаган дөньяның уянырга да исәбе юк. Кояшның нурлары кар бөртекләре өстендә гүяки пыяла ватыкларында чагылып-чагылып киткәндәй уйныйлар. Суык. Колакларны өшетә. Җиңнән керә, кыскарып калган тун итәгеннән эчкә үрмәли. Сөякләр шыгырдап куя.

ТАМАША (Хикәя)

Язгы тамчылардан җыелган гөрләвекләрдә аларның чыр-чу килеп коенышканнарын күргәнем булса да, көннәрнең җылынуына һәм кояшның мулдан нур сибүенә кем генә шатланмый инде дип белдем. Ә чыпчыкларның салкын кышка шулай сөенүләре гаҗәеп бер тамаша кебек тоелды миңа.

11 нче алып баручы. ИМПЕРИАЛИСТ (Хикәя)

Җәйнең корылыгын салкынча һава алыштырды. Төньяктан искән җилләр челләдән йончыган җан ияләренә ял бирде. Печәннән кайтып, әле караңгы төшәргә иртәрәк икәнлеген чамаладым да, кармакларны җайлап, су буена киттем.

ГӨЛБАНУНЫҢ КЫЗЫЛ ЧӘЧӘКЛЕ ГӨЛЕ (*Хикәя)*

Күңел бакчасының алмагачлары гына түгел, чияләре, карлыган һәм шомыртлары да бердәй чәчәк атып, ничә кат җимешләнделәр. Урамнарның кышка кереп барышы онытылды. Әмма ничек кенә дәвамлы булмасын, бу бәхет кояшы көннәрнең берендә ят җил исүдән сүреләчәк һәм сүнәчәк иде. Һәр язның үз җәе, көзе һәм кышы барлыгын кем белми.

ДӘРВИШЛЕК ХОЗУРЫ (*Хикәя)*

... Манзараның түрендәге каенлык, биредәге юкә, өрәңге, чикләвек катыш урман алды шәһәрдән чыгучы һәм өелеп килүче машиналарның тавышын йотып калалар. Һәртөрле чәчәкләр белән бизәлгән киң һәм ерактагы сыртларга барып тоташкан җәйләү буйлап узган җылы тузанлы юл алга дәшә...

... Җәйнең рәхәт һәм тыныч һавасы, киң болын һәм якты каен урманыннан адашып чыккан төркем-төркем сылу агачлар, әле эреп югалган, әле кабат күпереп киткән болытлар – болар һәммәсе дә дөньяның гүзәллеген берьюлы күрсәтергә алынган кебек иделәр...

13 нче алып баручы. Якташыбыз, шагыйрь, язучы-прозаик, әдәбият галиме, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, филология фәннәре докторы, профессор Фәрит Яхинга «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән дәрәҗәле исем бирелде.

Кайсы гына өлкәгә күз ташлама – Ф.Яхинның эшләгән эшләре ифрат та күп. Мул сәләте аны фәндә дә, әдәбиятта да бердәй уңышка китерә. Әлбәттә, аның характерына хас булган сыйфаты – алдына куйган ниятенә ирешүдәге ныклык, тырышлык кебек сыйфатларының да талантының күпьяклы булып ачылуында әһәмиятле роль уйнавын әйтергә кирәк. Максатка омтылудагы ныклыгы, тырыш эшчәнлеге аны фән юлына алып чыга һәм чагыштырмача тиз арада фәннең югары биеклекләренә күтәрә. Бүгенге татар әдәбиятында язучы-галим Фәрит Яхинның һичкем алыштыргысыз какшамас үз урыны бар.

14 нче алып баручы. Әдәбият күгендә һәр чорның үз йолдызлары кабынып тора. Аларның кайберләре берара яналар да сүнәләр, югалалар, әмма кайберләре, халык күңелен биләп, мәңге сүнми торган нурлы йолдызга әвереләләр. Әнә шундый сунми торган йолдызларның берсе булып, Ф.Яхин да татар әдәбиятында үзенә урын алды. Ул «язучы» дигән бөек исемгә лаек булды. Ә язучы булу өчен табигать биргән зур илаһи көч, сабырлык, зирәклек һәм акыл тирәнлеге, өмет, ышаныч, ныклы иман һәм үз максатыңа тугрылык кирәк дип уйлыйм мин. Мондый сыйфатлар Фәрит абый Яхинда җитәрлек.

Һәрхәлдә мин үзем алар хакында шулай дип уйлыйм, аларны шулай күрәм, шулай тоям.

Моны һичвакыт истән чыгарырга ярамый! Шуның өчен борынгы заманнардан ук халык табигатьне һәм акыллы балаларын сакларга омтылган. Алар – аерым, бер гаиләнеке, ата-ананыкы гына түгел, бәлки халыкның, милләтнең байлыгы һәм мәртәбәсе!

Хәер, дөнья йөзендә һәр яшәп үткән кешенең дә үз төсе, сурәтенең шәүләсе кала. Вакытлар узган саен тик алар уңа, сүрелә, онытыла бара.

Ләкин Фәрит Яхин әсәрендәге авыл халкы онтылмыйча, тарихка кереп калачак. Бу үз чиратында минемчә, аларның балаларына, оныкларына киләчәктә әби-бабаларының тормышын өлешчә булса да күз алдына китерергә ярдәм итәргә булышыр.

Әйе, Ф.Яхинның әсәрләренә халыкчанлык хас. Ул тарихны да, бүгенге көнне дә белеп, ачык аңлап иҗат итә.

## Күппочмаклыклар мәйданы

(геометрия һәм татар (туган) әдәбият буенча интеграль дәрес эшкәртмәсе)

Ихсанова Р.И., Шәйдуллина Ч.К., икенче санлы
Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы

**Дәреснең тибы**: белемнәрне гомумиләштереп кабатлау.

**Дәреснең максаты:**

- ***Белем бирү:*** «Күппочмаклыклар мәйданы» темасы буенча алган белемнәрне мәсьәләләр чишү процессында кабатлау һәм ныгыту;
- ***Үстерү:*** игътибарлылыкны, күрү хәтерен, логик фикерләүне, үз хаталарыңны табу һәм төзәтә белү күнекмәләрен үстерү;
- ***Тәрбияви:*** туган якка мәхәббәт, бер-береңә хөрмәт, тәртипле булу кебек сыйфатлар тәрбияләү.

**Дәресне җиһазлау:** проектор, экран, презентация, индивидуаль биремле карточкалар.

### Дәрес барышы

Класс 2 командага бүленә.

**1. Оештыру моменты.**

*Укытучының кереш сүзе.**(слайд 1).*** Безнең бүгенге дәресебез бераз үзгә булачак, укучылар. Гадәттәгечә безмәсьәләләр чишәрбез, ләкин шул ук вакыттаматур әдәбият турында да, туган ягыбыз турында да сүз алып барачакбыз. Бу бер дә юккатүгел, чөнки 2021 нче ел – туган теллләрне саклау һәм Халыклар бердәмлеге елы буларак билгеләп үтеләчәк. Ә без чишәсе мәсьәләләр «Күппочмаклыклар», «Күппочмаклыкларның мәйданы» темаларын

үз эченә алалар. Шуңа да иң беренче итеп дәресебезне төп төшенчәләрне, формулаларны кабатлаудан башлыйбыз.

**2. Белемнәрне актуализацияләү.**


***«Разминка» өлеше*** *(һәр сорауга дөрес җавапка – 2 балл).*

*Сораулар:*

*Фразаны төгәлләгез:*

1. Бөтен почмаклары да туры булган параллелограмм … *(турыпочмаклык).*
2. Ромб – ул параллелограмм, аның … *(бөтен яклары да тигез).*
3. Ромбның диагональләре ..... *(туры почмак)*ясап кисешәләр һәм кисешү ноктасында … *(урталай бүленәләр).*
4. Турыпочмаклы өчпочмакта 30° почмакка каршы яткан катет гипатенузаның .... (*яртысына*) тигез.
5. Турыпочмаклы өчпочмаклыкта гипотенузаның квадраты … *(катетларның квадратлары суммасына)*тигез.

*Дүртпочмаклар белән мәйдан исәпләү формаласы арасындагы бәйләнешләрне билгеләгез* ***(слайд 2):***




а) $S = a \cdot h$

б) $S = a \cdot b$

в) $S = (d_1 \cdot d_2)/2$

г) $S = a^2$

**Татар әдәбияты укытучысы.**

Укучылар, туган як темасы әдәбиятыбызның барлык төрләренә үтеп кергән тема. Аны барлык әдипләребез актив куллана. Әдипләрне, әдәби жанрларны барлыйк әле.Һәр дөрес җавапка 2 балл булачак.

*Фразаны тәмамлагыз*:

1. Тезмә формадагы әсәрләр иҗат итүче .... (*шагыйрь*).
2. Бер яки берничә вакыйганы эченә алган, кеше характерының бер сыйфаты турында сөйләүче әсәр .... (*хикәя*).
3. Чәчмә әсәрләр язу остасы ..... (*язучы*).
4. Тормышта булган вакыйгаларны сәхнәдә күрсәтү өчен тудырылган әсәр...... (*драма*).
5. Сәхнә әсәрләре язучы ..... (*драматург*).

**3. 1.*«Мин – сиңа, син – миңа»*иҗади бирем, мәсьәләләр чишү этабы.**

*Командаларның һәрберсенә якташ язучыларыбызның шигырьләре бирелә. Биремнәр: шигырьләрне сәнгатьле укырга һәм шулар эчтәлеге буенча мәйдан исәпләүгә корылган мәсьәлә төзергә.****(слайд 3)***

*Һәр команда мәсьәләне төзеп бетерүгә каршы командага бирә. Бәяләгәндә түбәндәгеләрне исәпкә алырга кирәк: шигырьне сәнгатьле уку; төзегән мәсьәләнең дөреслеге һәм аңа киткән вакыт; дөрес чишелеш,чишү тизлге.*

Бирелә торган шигырьләр:

Ә.Габиди «Көт син мине,туган як!» (Габиди Ә.С. «Җир кешеләр белән матур». Шигырьләр җыентыгы. – Казан: Яз.-2019 ел)

К.Булатова «Әлмәт урамында» (Булатова К.Г. Печән өсте: шигырьләр, поэма.- Казан: Тат.кит.нәшр.,1986 ел)

**3.2.*«Кем тизрәк?»*** *уены (һәр дөрес чишелгән бирем – 4 балл)****(слайд 4)***

1. Җәлил бистәсенә кайчан нигез салына?
2. Бистәдәге иң беренче һәйкәл кемгә куелган?

3. ***Мәсьәлә (слайд 5)*** *Җәлил бистәсендәге стела күрсәтелә) Мәйданы* 0,125 $м^2$ булган, бер ягы икенчесеннән 2 тапкыр зуррак булса, с*теладагы турыпомаклы элементның яклары нинди булыр? (Җавап: 0,25 м, 0,5 м)*

4. Бер ягы 0,6 м, бер почмагы $60^{\circ}$булган ромбның мәйданын табыгыз **(слайд 5)**

**4. Динамик пауза.**


**5.Кабатлауга, ныгытуга биремнәр үтәү.**


**1.«Сез беләсезме?» уены***(һәр дөрес чишелгән бирем – 2 балл).*

*<u>Фразаны тәмамлагыз:</u>*

1. Ике ягы үзара параллель дүртпочмаклык … *(трапеция).*
2. Тигезьянлы трапеция булсын өчен, аның … *(яклары тигез булырга тиеш).*
3. Тигезьянлы трапециядә нигез яныңдагы почмаклар … *(тигез).*
4. Тигезьянлы өчпочмакның нигезенә үткәрелгән биеклек… *(биссектриса, медиана).*
5. Өчпочмакның очы белән каршы якның яртысын тоташтыручы сызык … *(медиана).*

**2. Күппочмаклыкларның төре һәм мәйдан формулалары арасындагы бәйләнешне табарга (слайд 6):**





а

1 2

а) S +b)·h

а

в) S = (a·h)/2

$S = (a^2\cdot\sqrt{3})/4$

3 а а ***Җавап: 1 – в, 2 – а, 3 – б.***

**3.Мәсьәлә чишү (слайд 7).**

Муса Җәлилгә куелган һәйкәлнең нигезендә булган тигезьянлы АВСД трапециясенең мәйданын табыгыз, АВ=0,6 м, АД=2 м, □А=60□, биеклек ВК=0,52 м. ( Җавап: 0,884 м2).

**6. Якташ язучылар иҗаты белән бәйле сорауларга җавап бирү.**

1. Фронтовик-шагыйрь, «Гомер учагы», «Урман читендәге имәннәр без» җыентыклары авторы.
2. Бу шагыйрә Г.Тукай премиясенә лаек булды.


**Китап күргәзмәсе белән таныштыру.**

**7. Дәрескә йомгак.** Биремнәр үтәлешен тикшерү. Билгеләр кую.

**8. Өй эше бирү.**

Бистәдәге Хәтер һәйкәле янында тикшеренүләрдән соң түбәндәге размерлы тигезьянлы трапеция хакында белешмә алганнар. Шушы размерлар буенчамәсьәлә төзегез һәмчишегез.

50 см



40 см

Биеклек = 34 см

Сау булыгыз,укучылар. Дәрес тәмам.

## Тел өйрәнгәндә Әзһәр Габиди иҗатын файдалану һәм фигыль турында төшенчә бирү

(4 нче сыйныфның татар төркемендә туган (татар) теле дәресе)

Шакирова Эльмира Финус кызы, Зиннәтуллина Лилия Ринат кызы,
Җәлил гимназиясе укытучылары, Сарман районы

**Максат**: тел өйрәнгәндә Әзһәр Габиди иҗатын файдалану һәм фигыль турында төшенчә бирү.

**Планлаштырылган нәтиҗә:** Ә.Габиди шигырьләреннән фигыльләрне таба, башка сүз төркемнәреннән аера һәм куллана белү .

**Танып-белү:** эзләнү, җавап бирү өчен Ә.Габиди шигырьләреннән кирәкле мәгълүматларны табу, фигыль моделен төзү, кагыйдәне чыгару.

**Коммуникатив:** укытучы белән диалогка керү, төркемнәрдә фикер алышуда катнашу, үз фикереңне әйтү.

**Регулятив:** укытучы күрсәткән ориентирны аңлау, укытучы белән берлектә яңа материалны ачу.

**Шәхси:** якташыбыз Ә.Габиди иҗатына кызыксыну белдерү, туган төбәгең өчен намуслы хезмәт итү теләге уяту, үз халкыңның рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләүгә шартлар тудыру.

**Дәрес тибы:** яңа белемне үзләштерү дәресе.

**Җиһазлау:** компьютерда слайдлар, карточкалар, тест сораулары, «Сүз төркемнәре» модельләре, Ә.Габиди портреты, китаплары, рәсемнәр, ребус.

**Дәрес барышы.**

**I.Психологик уңай халәт тудыру.** (Талгын гына музыка уйный.)

- Хәерле көн, укучылар! Мин сезнең иң тырыш, иң булган укучылар икәнегезне беләм. Ягез, моны кунакларга да күрсәтик әле. Күзләребезне йомдык. Минем арттан кабатлыйбыз һәм **куллар белән күрсәтәбез**.

- Мин гимназиядә.
- Мин күп белергә телим.
- Мин игътибарлы.
- Минем кәефем шәп! Бер-беребезгә карап, иптәшләребезгә, кунакларга елмаю бүләк итик әле.


**II.Актуальләштерү.** 1.«Тиз җавап» уены

Ла-ла-ла
Ул кармак сала.
Ла-ла-ла
Мин тырыш бала.
Та-та-та
Туган илен ярата.
Та-та-та
Сарык көтүдән кайта.
Та-та-та
Әни гәҗит тарата.
Су-су-су
Киң безнең басу.
Су-су-су
Тырыш кыз Алсу.

2.Өй эшен тикшерү. Якташыбыз Ә.Габиди иҗатыннан алмашлыклы шигырь исемнәрен язып алырга. (Укучылар укыйлар: «Рәфкать нигә оялды?», «Урман кырындагы имәннәр без», «Айны кем китеп алган?», «Кем гаепле?», «Кайда соң сез?», «Нәрсә әйтер килер буыннар?..», «Ник сеңел алып кайтмый?», «Кемнәр җырлар?», «Безгә бит азат яшәү фарыз», «Мин өшедем җылы җәйдә дә»..)

**3.** «Кем тизрәк?» уены.

- Әйдәгез, бу әйтемне бергәләп укыйк әле. **Слайд №2** Ребус чишү.



**Күк бизәге - йолдыз,**
**Җир бизәге - кеше.** (Ә. Габиди)

- Сез бу әйтемне ничек аңлыйсыз? (Күк йолдызлардан башка матур була алмый, ә җирне кеше үзенең хезмәте, эше белән бизи. Кеше тырышып эшләгәндә генә безнең тормышыбыз алга китә, җиребез ямьләнә. )


- Әйе, укучылар, без үзебезнең дәресебезне якташыбыз Ә.Габидинең «Җир бизәге» шигыреннән алынган өзек белән башлап җибәрдек. Без дә сезнең белән үзебезнең дәресебезне белемнәребез белән бизик әле.

**III. Уку мәсьәләсен кую һәм чишү**.

Картинаны җанландыр! **<u>Слайд № 3,4</u>**

- Укучылар, картинада нәрсәләр күрәсез? (Төн. Утлар. Авыл. Йолдызлар. Җил. Агачлар.)
- Ә хәзер җөмләләрне җанландырыгыз. (Төн житте. Утлар сүнде. Авыл йоклый. Йолдызлар җемелди. Җил исә. Агачлар селкенә. Тиздән таң атар.)
- Нинди сүзләр картинаны җанландырды? Алар нәрсәне белдерә? Бу сүзләр ничек атала? Фигыль турында нәрсәләр беләбез? Нинди сорауларга җавап бирә? Хикәя фигыль нәрсәләр белән төрләнә?

**( Кагыйдәне чыгару, дәреслектән уку, модельләштерү) <u>Слайд №5</u>**




2.Матур язу күнегүләре. Кк Җж Сс Уу Яя Шушы хәрефләр белән башланган предметның эшен һәм хәрәкәтен белдергән сүзләрне язарга. (Киенә, җырлый, сибә, утыра, яра.) **Үзбәя.**

3. Дәреслек белән эш. 241 нче күнегүдә бирелгән <u>Ә.Габидинең «Минем гөлем»</u> дип исемләнгән шигырен уку. Сүзләргә сорау куеп язарга, фигыльләрнең астына ике сызык сызарга.

4. Ә.Габидинең «Кем гаепле?» шигыре өстендә **парларда** эш.

Шигырьдәге ялгызлык исемнәрне атарга һәм эчтәлек буенча предметны белдергән сүзләргә эшне белдергән сүзләрне табып язарга.

**Кем гаепле?**

Акбай йоклап яткан чакта,
Тәмле генә төш күреп,
Хәмит сукты чыбык белән,
Аның йокысын бүлеп.
Көлә-көлә эт яныннан
Барганда гына китеп,
Акбай Хәмитнең ботыннан
Тешләп алды «һам» итеп.
Әй елады инде Хәмит!
Кем соң монда гаепле?
Тыныч йоклап яткан этме,
Әллә инде Хәмитме?

**<u>Слайд №6</u>**

| <u>Хәмит</u> | <u>Акбай</u> |
|---|---|
| сукты | йоклады |
| елады | тешләде |
| ... | ... |

- Шагыйрь бу шигыре белән безгә нәрсә әйтергә тели? Хәмит нинди малай?

**Ял минуты**

5. 242 нче күнегү. (1) 1 укучы тактада, башкалар урыннарда.
(2) укучылар мөстәкыйль эшлиләр, парларда тикшерәләр.

6. Карточкалар белән төркемнәрдә эш. (Сыйныфтагы укучылар тел белгечләренә, тикшерүчеләргә, корректорларга бүленә)

1. **Тел белгечләре.** Шигырьнең авторын һәм исемен әйтегез**.** Астына сызылган сүзләрнең фигыль икәнен исбатлагыз. (Нинди фигыль, заманы, зат-саны, барлыкта яки юклыкта.)

**Сагынам**

Агып китте гөрләвеккә
Корабым,
Күмелгәнче корабыма
Карадым.
Агып китте шул корабта
Балачак,
Ул хәтердә гомерлеккә
Калачак.
(Ә.Габиди)

2**. Тикшерүчеләр.** Шигырьдән фигыльләрне табып, зат-санын һәм заманнарын билгеләгез.

**Рәфкать нигә оялды?**

Мәктәптән кайтты да Рәфкать
Ашады тәмле итеп,
Эндәшми генә, табыннан
Бара ул әнә китеп.
Туктатты аны шул чата
Матур апасы Дилбәр:
-Торып тор әле, энем, -ди,-
Ашагач нәрсә диләр?
Әнисенә карады да
Оялып кына Рәфкать:
- Әй, тәмле дә булган соң аш,
Әнкәй, сиңа зур рәхмәт.

**3.Корректорлар**. Шигырьнең авторын һәм исемен әйтегез. Күп нокталар урынына тиешле фигыльләрне куегыз һәм аларның юклык формаларын әйтегез.

**Көтү ________**

Тау артында
Кояш ______ ,
Җир өстенә
Эңгер_______ ,
Авылымда
Шатлык _______–
Урам тулып
Көтү ________. (Ә.Габиди)
(Белешмә өчен сүзләр: кайтты, батты, ятты, артты, кайта.)

7. – Укучылар, без кайсы шагыйрьнең шигырьләре белән таныштык? Аның турында сез нәрсәләр беләсез? (Укучылар чыгышы)

**Укытучы.** Сарман ягы талантларга бай. Бүгенге көндә Сарман районыннан 25ләп шагыйрь һәм прозаик үсеп чыккан. Шулар арасыннан балалар һәм зурлар өчен дә матур-матур шигырьләр иҗат иткән шагыйребез Әзһәр ага Габидине атарга була.

Әзһәр Габиди 1926 елда Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында туа. Ул авыл тормышының бөтен авырлыкларын үз җилкәсендә татый. Әзһәр Габиди 17 яшендә армия сафларына алына, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947 елда үз туган авылына кайта. Авылында хисапчы ярдәмчесе, хуҗалык мөдире булып эшли. 1950 елда Минзәлә педагогия көллиятендә белем ала, соңыннан Сарман районы мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Шул вакытта аның «Без – яз дуслары»

исемле беренче шигырь җыентыгы дөнья күрә һәм аны алга таба иҗат эше белән шөгыльләнергә илһамландыра.

Әзһәр Габиди – бик күп китаплар авторы. Шигырьләре туган як, андагы кызыклы вакыйгалар турында. Ул иллегә якын җырлар авторы. Йөздән артык китапка рецензияләр яза. 1980 елдан «Сарман таңнары» әдәби берләшмәсен җитәкли. Шагыйрьгә әдәбияттагы казанышлары өчен Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премия бирелә. Ул 1992 елдан Татартан Язучылар берлеге әгъзасы. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.




2001 елның 22 августында вафат. Кабере – Чукмарлы авылы зиратында.Үзе булмаса да, шигырьләре яши, матурлыкка өнди, уйландыра...

8. Рәсемнәргә карап, Ә.Габиди турында җөмләләр төзергә. Җөмләләрдә фигыльләрне өч заманда да кулланырга. **<u>Слайд №7</u>**

9.**Дәфтәргә әйтеп яздыру.**

Әзһәр Габиди Чукмарлы авылында туган. Ул балалар өчен «Без – яз дуслары», «Өч киңәшче», «Калган эшкә кар ява», «Кошчыгым», «Тапкырҗан табышмаклары», «Таң сәгате» китапларын чыгара. Киләчәктә дә балалар Ә.Габидинең шигырьләрен яратып укырлар. (Фигыльләрнең асларына ике сызык сызарга, заманын, зат-санын билгеләргә)

**Укытучы.** Укучылар, без үзебезнең Сарман районында яшәвебез белән хаклы рәвештә горурланабыз. Ә. Габиди, Х.Хәйруллин, Ф. Яхин, Д.Гарифуллин, А. Гыйләҗев, М.Маликова, И. Шакиров, Зөһрәләр исеменә тап төшермичә тырышып укырга, тәртипле, тәрбияле булырга тиешбез.

IV. Рефлексив кабатлау.

- Без бүген фигыль турында нәрсәләр белдек? Ничек белдек? (Фигыль моделен парларда төзү) Фигыль турында без барысын да белеп бетердекме әле? (Алдагы дәрескә проблемалы сорау кую)

**Яшел** түгәрәк – дәрестә миңа күнегүләрне эшләргә җиңел булды, белгәннәремне башкаларга да аңлата алам.

**Сары** түгәрәк – мин аңладым, барлык күнегүләрне дә үзем эшләдем.

**Кызыл түгәрәк –** мин күнегүләрне иптәшләрем ярдәмендә эшләдем.

Өстәлдәге смайликларны сайлап эшегезне бәяләгез, түгәрәкләрне тактага эләбез

V. Йомгаклау. Билгеләр кую.

Өй эше: 1. Ә.Габидинең «Сандугач белән Гөлгенә» шигыреннән хикәя фигыльләрне табарга һәм юклык формасына куеп язарга, 2) теләк буенча карточкалардагы Ә.Габиди язган табышмакларны күчереп язарга, җавапларын табарга һәм биремнәрне үтәргә.

### Сарманыбызның Әзһәр Габидинең әдәби кунак бүлмәсендә очрашу

Галиәхмәтова Г.И., Бариева-Саетгараева Г.Ф. икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучылары, Сарман районы

**Максат:** Укучыларны шагыйрь, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Әзһәр Габидиның тормышы һәм иҗаты белән таныштырырга.

**Бурычлар:** Әзһәр Габидинең шәхес һәм иҗатына кызыксыну уяту; язучының гениальлеген һәм эчке көчен күрсәтергә; укуга һәм китапларга мәхәббәт тәрбияләү.

**Материаллар һәм җиһазлар:** Әзһәр Габидинең портреты һәм китаплары, башка татар язучыларының портретлары, А3 форматындагы битләр, төсле карандашлар, буяулар.

**Чараның барышы:**

**Укытучының кереш сүзе.**

- Исәнмесез, кадерле укучылар! Бүгенге класс сәгате – әдәби кунак бүлмәсендә очрашу.

Сарман ягы талантларга бай. Бүгенге көндә Сарман якларыннан 25ләп шагыйрь һәм прозаик үсеп чыкты. Безнең якташ язучылар портретларына карагыз. Аларның барысы да сезгә яхшы танышмы? Алар арасында сезнең өчен әлегә аз билгеле булганнары юкмы (укучылар язучыларны атый һәм Әзһәр Габиди портретын аерып чыгара). Әзһәр Габиди – кем ул? Ул – ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, очерклар, тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләр язучы да. Ул милләтне, телне, табигатьне сакларга чакырды, тарихны онытмаска өндәде, мәхәббәткә дан җырлады. Ул гомере буе дөньяны акларга теләде. Ә беренче чиратта ул – безнең якташыбыз!

**Язучының тормышы һәм иҗаты. (Укучылар әзерләгән презентация кулланып сөйлиләр).**

**Беренче укучы:** Шагыйрь 1926 елның 25 сентябрендә Татарстан АССРның Сарман районы Чукмарлы авылында туа. Гаиләдә өченче бала булганга күрә, ул авыл тормышының бөтен авырлыкларын үз җилкәсендә татый. Әзһәр Габиди – Бөек Ватан сугышында катнаша, 17 яшьтә ул армия сафларына алына. 1945 елда Совет-япон сугышында бик каты яралана, бер ел дәвамында госпитальдә дәвалана. 1946 елда үз туган авылына кайта. 1947-1950 елларда «Чулпан» колхозында хисапчы ярдәмчесе, хуҗалык мөдире булып эшли. 1950 елда Минзәлә педагогика училищесында белем ала, соңыннан Сарман районы Чукмарлы мәктәбендә 30 ел буена татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. Шул вакытта аның «Без – яз дуслары» исемле беренче шигырь җыентыгы дөнья күрә һәм аны алга таба иҗат эше белән шөгыльләнергә илһамландыра.

**Икенче укучы:** Ә.Габиди 1942 елдан бирле әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Иҗатының зур өлеше балаларга багышланган. Аның төрле елларда дөнья күргән «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Калган эшкә кар ява», «Таң сәгате», «Без – яз дуслары», «Өч киңәшче» һ.б. китаплары яшь буынны намуслы һәм тәртипле, тырыш һәм хезмәтчән итеп тәрбияләүдә зур роль уйный. Шагыйрь зурлар өчен дә тирән лирика, дөнья гаме, заман сулышы белән сугарылган эчкерсез шигырьләр иҗат итә. Аның соңгы елларда төрле нәшриятларда басылып чыккан «Таң догасы», «Урман читендәге имәннәр без…», «Күзге барлау», «Гомер учагы» исемле шигырь китаплары тиз арада үз укучысын таба.

**Өченче укучы:** Аның лирикасы бөтенләй үзенчәлекле. Һәр юлда шагыйрь үзенең иң яшерен кичерешләрен тапшыра. Туган илнең мәңгелек темалары һәм мотивлары шагыйрьнең бөтен лирикасына хас. Үз туган ягы Сарман төбәгенең кабатланмас гүзәл табигатен, аның хезмәт сөйгән халкын олылады, гашыйк булып язды, сагынып язды.

**«Сагындым»**

Бу кадәрле сагынырмын диеп,
Уйламаган идем, Сарманым.
Күз алдыннан китми айлы кичең,
Истән чыкмый алсу таңнарын.
Күз йомдыммы – төшләремә керә
Чәчәкләре зәңгәр тавымның.
Һич яшермим сездән: туган якның
Әременә кадәр сагындым.

Ә.Габиди I һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән. Аңа «Халык мәгарифе отличнигы», «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр бирелә. Ул 2001 елның 22 августында вафат була. Ә.Габиди – 1994 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Әзһәр Габиди китапларына күргәзмә һәм күзәтү.**

**Укытучы:** Балалар, хәзер мин кунагыбызга сүз бирергә телим – китапханәче Алинә Илдаровнага. Ул күргәзмәдә тәкъдим ителгән Әзһәр Габиди китапларына күзәтү ясаячак.

**Иҗади остаханә.**

Укучылар китапның иҗат итү процессы белән шөгыльләнәләр. Балалар өч төркемгә бүленәләр (1 – иллюстратор-рәссамнар, 2 – редакторлар, 3 – нәширләр). Төркемнәргә биремнәр: 1 төркем – Әзһәр Габиди шигырьләрендә төп геройлар образлары белән иллюстрацияләр булдыру. 2 төркем – булачак китап тышлыкларын рәсмиләштерергә. 3 төркем – китапны алга этәрү өчен реклама уйлап табу.

Эшне башкаруга 10 минут бирелә. Эш беткәч, укучылар үз проектларын яклыйлар.
**Нәтиҗәләр ясау.**
**Укытучы:** Менә безнең әдәби кунак бүлмәсендә очрашуыбыз тәмамланды. Ул кызыклы һәм нәтиҗәле булгандыр дип ышанап калам, һәм сездә Әзһәр Габиди китабын уку теләге уятты дип уйлыйм.
Рене Декартаның дип әйтүе «Яхшы китаплар уку - ул үткән заманның иң яхшы кешеләре белән сөйләшү, өстәвенә, алар безгә үзләренең иң яхшы фикерләрен генә хәбәр итә торган әңгәмә».

## Шушы яктан, шушы туфрактан без

(Фәрит Яхинның «Умырзая» китабын тәгъдим итү)

Гарифуллина А.Ф., Вәлиева Э.И., икенче санлы Җәлил урта мәктәбе укытучысы, Сарман районы

*Татар халык җыры «Умырзая» көе яңгырый.*

**1 нче укучы:** Умырзая – язгы чәчәк диләр,
Карны ерып туа дөньяга...
Тормыш упкыннарын ерта-ерта,
Мәхәббәтем туды дөньяга...
**2 нче укучы:** Өзеп алсаң язның күркәм гөлен,
Тиз коя шул нәфис таҗларын...
Сөюем дә өметсез шул минем,
Киләчәге дә юктыр бит аның...
**3 нче укучы:** Умырзая үскән жиргә бардык,
Саф чәчәкләр өзеп син суздың,
Гүя язның асыл гөлләрен түгел,
Кайнар хисләреңне тапшырдың...
**4 нче укучы:** Хисләреңне сизеп белә идем,
Тик омтылырга сиңа курыктым,
Умырзая үскән жиргә чакыргач
Назга сусаган йөрәгемне суздым...
**5 нче укучы:** Чәчәкләрең бетәр, ә сөюең???
Дөрләрме соң күңел түрендә???
Очрашулар, серле очрашулар,
Калырмы соң тормыш күгендә???
**6 нчы укучы:** Иреннәрдә татлы үбешү тәме,
Уйларымда – сорауларның йөзе,
Тик каршымда – назлы ак чәчәкләр –
Умырзая – язның беренче гөле...

*(Укучылар кереп китә. Сәхнәгә алып баручылар чыга)*

**1 нче алып баручы:** Умырзая чәчәге бер җырда кеше гомерен аңлатып килсә, икенчесендә ул тәүге мәхәббәтне тасвирлый.
**2 нче алып баручы:** Умырзая – кеше күңеленең аклыгы да, пакълыгы да.
**1 нче алып баручы:** Бүгенге очрашуыбызны Фәрит Яхин иҗатының бер җимеше «Умырзая» китабына багышларбыз.
**2 нче алып баручы:** Фәрит Яхин – бүгенге көндә мин дип кычкырып торган әдипләрнең берсе түгел.
**1 нче алып баручы:** Шагыйрь, язучы, әдәбият галиме Фәрит Яхинның иҗаты, әдәбиятка килеп керешкә, бәхетле язмышка очрады
**2 нче алып баручы:** Прозада беркемне дә кабатламый торган үз стиле, үз язу осталыгы белән Ф.Яхин – Гомәр Бәширов, Фатих Хөснидән килә торган әдәби осталыкны, Аяз Гыйләҗев һәм Мөхәммәт Мәһдиевнең ялкынлы, милли якты хисләргә үрелеп бара торган мәгънәле прозаны сәнгатьчә камиллеккә күтәрешкән, аны яңа сыйфатлар белән баеткан каләм остасы.

**1 нче алып баручы:** Ул әле бик тыйнак та. Шушы тыйнаклык артында тирән фәлсәфи эчтәлекле әсәрләре ята. Мин Фәрит Яхинның «Умырзая» романы күздә тотып әйтәм

**2 нче алып баручы:** Ул бүгенге тормыш күренешләрен тасвирлап кына карамый, тирәнгә төшеп, тормыш вакыйгаларының сәбәпләрен анализлый. Беренче урында шәхес тора. Рус әдәбиятында урын даһие, вакыт даһие дигән төшенчә бар. «Умырзая» романында да вакыт даһие бар.

**1нче алып баручы:** Татар җәмгыятендә мәдәниятне, телне тотып тора торган, аның өчен көрәшә торган зур шәхес образлары белән очрашабыз: алар ничек формалашалар. Бүгенге көндә татар җәмгыятен саклап кала торган нинди герой бар дип сорыйбыз икән, ул геройның тормыш юлы нинди булырга мөмкин? «Умырзая» әсәренә нигезләнеп, менә шундый булырга тиеш дия алабыз».

(*Сүзне мәктәп китапханәчесе ала. Ф. Яхин иҗатына багышланган китап күргәзмәсенә күзәтү ясый.)*

**Китапханәче:** ...1990 еллар башында Ф.Яхин милли реализмны этнографик һәм эзотерик детальләр белән баетылган «Ак әбиләр догасы» хикәясе, «Авыл мөгаллимнәре» повесте белән укучыны таң калдырган, соклandырган иде. «Ак әбиләр догасы»ндагы ак күлмәк кигән, ак яулык бәйләгән саф күңелле, тугры иманлы татар әбиләре, Гарсиа Маркестагыча, чынбарлык белән эзотерик элемтәгә кереп, илне корылык һәм ачлык куркынычыннан дога-гыйбадәтләре белән коткарып калалар. Юк, бу – язучы уйлап тапкан очраклы вакыйга түгел, бу – татар тормышының үзе, хәмер, куркаклык, байлык артыннан куу кебек имгәк көнкүреш вакыйгалар эчендә адашып калган рухларның саташуы түгел, ә кешенең чын асылына береккән булырга тиешле илаһи серне онытуга каршы куелган сафлык эчендәге олы мәгънәләргә ия тормышы да.

Әдәби-иҗтимагый яктан югары кимәлдә язылган «Умырзая» романын автор «метафизик роман» буларак атап, 2014-2018 елларда дөнья күргән 7 томдагы сайланма проза әсәрләренең бишенче томына урнаштырган. Ә Татарстан китап нәшриятында 2015 елда басылып чыккан вариантында бу әсәр «роман» дип кенә, иҗади юнәлеше исәпкә алынмыйча гына аталган.

**1 нче алып баручы:** Сюжет вакыйгалары әсәрнең төп геройлары Кәримә, Сабира, Газизчик, Фәхри, Хәнифә Галиевна язмышларына, аларның хис-тойгыларына, омтылышларына, тормышны аңлауларына бәйле тармакланып үсеп киләләр дә, аннары кинәт кенә көтелмәгән юнәлеш алып китә.

**2 нче алып баручы:** Ф.Яхин һәртөрле гаделсезлек, хаксызлык, кеше күңелен рәнҗетү кебек күренешләргә үтә сизгер. Ул яхшылык белән яманлыкның традицион бәрелеше һәм яңалыкның һичшиксез җиңеп чыгуы рәвешендәге артык гадиләштерелгән, примитив схемадан чыгып эш итми – тормышның катлаулылыгын күрә һәм җәмгыять үсешендә, кешеләрнең мөнәсәбәтләрендә котылгысыз очрый торган һәртөрле уңайсызлыклар, драматик мизгелләр аның игътибарыннан читтә калмый. «Умырзая» романында да бу төп иҗат нигезе булып кала.

*(Сәхнәгә югары сыйныф укучылары чыга. Алар тамашачыларны әсәрнең кыскача эчтәлеге белән таныштыра)*

**1 нче укучы:** Героиня Хәнифә Галиевна улының бәхетле булуын тели. Аның бу турыда үз карашлары бар. Ул икетуган сеңлесе Гөлшат Фаиковнага бара, аңа үзенең зарларын сөйли, фатирчы кызлары Кәримәне улы Газизчикнең яратуын, әмма араларына Сабираның керүен аңлата. Сеңлесе аңа ярдәм итәргә тиеш. Аның өе тулы уллары бар. Менә шуларның берсе Сабираны үзенә каратырга, Газизчик белән Кәримәнең бәхетле булуына булышлык итәргә алынырга тиеш.

**2 нче укучы:** Бу бурыч Гарифка йөкләнелә. Алга тагын да гаҗәбрәк хәлләр килеп чыга. Әсәрдә сурәтләнелгән вакыйгалар укучының гүяки йөрәге аша, үз хәсрәтләре һәм сагышлары рәвешен алып узалар. Гариф Сабирага өйләнә. Туйга әзерлек бара. Ә Кәримәнең югалуына айлар узган.

**2 нче укучы:** Романда геройларның язмышы тормыш дөреслеге кысаларында ачылган. Югары идеалларга ия геройлар еш кына дөньяның ачысын-төчесен татыган тәҗрибәле

кешеләр рәвешендә тәкъдим ителә. Кайвакыт алар, әсәрдә күренеп кенә узсалар да, төп геройларның характерлары формалашуына җитди йогынты ясыйлар.

**3 нче укучы:** Андыйларны автор матур, купшы фразаларга төренеп, тыштан ялтыраучыларга, дөресендә җилкуар, мәгънәсез, ялкау, ялагай, күз буяучыларга каршы куя. Персонажларның шундый ике төркемгә бүленешендә әсәрдә бөртек тә схематизм юк.

**1 нче укучы:** «Умырзая»да Кәримәнең язмышы аяныч тәмамлана. Ул – бөртек кадәр дә гөнаһы булмаган бала, татарның бөек шагыйрәсе булачак кеше. Әмма аны ил мәнфәгатен яклау күләгәсе астында үзләренең көнчелекле тойгыларына хезмәт итүләре һәлакәткә китерә.

**2 нче укучы:** Дөрес, татар дөньясының гадел кешеләре, изге җаннары аның соңгы минутларында да табыла. Соңгы минутларында, чөнки соңаралар. Алар аны имин саклап кала алмыйлар, әмма рухының сафлыгы, иманының ныклыгы өчен булсын, соңгы юлга озатканда, эти-әнисенә ярдәмгә алыналар.

**3 нче укучы:** «Умырзая»ны укыганда, аның төп геройларыннан берсе буларак Кәримә Дулатованың чын татар тормышыннан алынганлыгы сиземләнә башлый, аның прототибы буларак халык шагыйрәсе Клара Булатованың язмышы, аның эти-әниләре, яшәгән урыннарына кадәр дөрес бирелүләре белән генә түгел, хәтта авыл клубындагы «кулак Сәйфетдин көзге»се, чәч бантлары, яулыклары, чемоданнары, күлмәкләре белән дә күз алдына килеп баса.

**4 нче укучы:** Ф.Яхин яраткан шагыйрәбез язмышын тасвирлауга алынып, аны зурлады, татар хатынының XX гасырда үткән авыр юлын күз алдына китереп бастыр-ды, моның белән апаларыбызга, әниләребезгә тагын да тирән ихтирам хисләре белән баш иярגә этәрде. Клара Булатова, әдәби образыннан аермалы буларак, тормышында очраган каршылыкларны ерып чыгарга үзендә көч тапкан.

**1 нче укучы:** Дөрес, ул да башта бирешкән. Әмма аңа якыннары, гаделлек ияләре вакытында терәк була алганнар. Ә «Умырзая» романындагы Кәримә Дулатова бөтенләй ялгыз кала, хәтта иптәш кызы Сабира да аның шигырьләрен үзләштерүдән чирканмый, аңа тиешле бәхетне үзенә даулый, шагыйрәлек дәгъва кылуга ук барып җитә.

**2 нче укучы:** «Умырзая» романы – бер тында укыла торган, укыганда үзеңнең дә татар икәнлегеңне тоеп, тетрәнү дә, дулкынлану да кичерүгә этәрүче көчле әсәр. Рухи яктан бай татар тормышына бәйле ачык хакыйкатьләрне сурәтләп бирүе белән хәтта дөнья классикасы әсәрләре рәтендә укучыларга тәкъдим ителерлек роман.

*(Укучылар кереп китә)*

**1 нче алып баручы:** Фәрит Яхин иҗаты сурәтләүләрдә һәм тасвирлауларда, мантыйк төгәллегенә ирешүдә, дөреслеккә һәм хакыйкатькә хезмәт итүдә, тугры намус тойгысына корылуда күптөрле иҗатлардан аерылып тора. Әнә шул сыйфатларны ул әсәрләрендә, һаман да тирән эчтәлекле катлаулы һәм катлы-катлы агым-юнәлешләрдә бербөтен итеп алып бара, куелган мәсьәләләрне үстерә, чишелешкә кадәр җиткерә белеп яза

**2 нче алып баручы:**.Кайсы гына өлкәгә күз ташлама – Ф.Яхинның эшләгән эшләре ифрат та күп. Мул сәләте аны фәндә дә, әдәбиятта да бердәй уңышка китерә. Әлбәттә, аның характерына хас булган сыйфаты – алдына куйган ниятенә ирешүдәге ныклык, тырышлык кебек сыйфатларының да талантының күпьяклы булып ачылуында әһәмиятле роль уйнавын әйтергә кирәк. Максатка омтылудагы ныклыгы, тырыш эшчәнлеге аны фән юлына алып чыга һәм чагыштырмача тиз арада фәннең югары биеклекләренә күтәрә. Бүгенге татар әдәбиятында язучы-галим

**1 нче алып баручы:** Фәрит Яхинның һичкем алыштыргысыз какшамас үз урыны бар.

**2 нче алып баручы:** Хөрмәтле тамашычылар. Сезнең күңелләрдә Фәрит Яхинның «Умырзая» әсәрен укуга кызыксыну уятканбыздыр дигән теләктә калабыз.

**1 нче алып баручы:** Ә инде укыгач, безнең күңелләрдә матур, нәфис хисләр уяныр, без әхлакый кыйммәтләрне тагын да тирәнрәк аңларбыз, уйлана башларбыз, матурлыкка омтылырбыз. Киләсе очрашуларга кадәр.

**Татарстан, бәхет җырым син**

(якташыбыз Клара Булатованың тууына 85 ел тулуга багышланган сыйныф сәгате)

Замаева Луиза Нәзир кызы, Җәлил гимназиясе, Сарман районы

**Максат:** Якташыбыз татар шагыйрәсе Клара Булатованың тормышы һәм иҗаты үрнәгендә укучыларда Ватанга мәхәббәт һәм милли үзаң тәрбияләү.

**Бурычлар:** иҗатта үз-үзләрен күрсәтү өчен шартлар тудыру; иҗади һәм профессиональ бәйләнешләрне ныгыту; милли мәдәниятне һәм гореф-гадәтләрне торгызу һәм популярлаштыру; яшь талантларның иҗатын пропагандалау, китап укуга теләк уяту.

**Сыйныф сәгатенең барышы**

**I.** Психологик халәт тудыру.

**II.** Сыйныф сәгатенең темасы һәм максаты белән танышу.

**III.** Укытучының кереш сүзе.

**Ильвина:** Күрәсезме, бүген көн нинди матур. Ә күк йөзенә игътибар итегез, бер болыт кисәге дә күренми чалт иткән аяз күк. Кояшы да чыгып тора. Ә таң алдыннан мин бер төш күрдем. Төшемдә мин бер бик матур күренешкә тап булдым. Урамда яз. Безнең мәктәп бакчасында күп-күп алмагачлар үсеп утыра. Алар бөтен дөньяны хуш искә күмеп ап-ак чәчәк атканнар. Алмагачка сандугачлар кунып сайрыйлар. Шул агачлар арасынан бер гүзәл зат килеп чыкты. Ул шундый матур, гүзәлләрнең гүзәле, иңнәренә матур ак шәл яулыгын ябынган. Ә кулына каләм һәм дәфтәр тоткан. Уянып киттем дә бу нәрсәгә булыр икән дип уйланырга тотындым.

**Укытучы сүзе:** Син төшеңдә татар шагыйрәсе Клара Булатованы күргәнсең. Быел Клара Булатованың тууына 85 ел була. Бүген шул уңайдан сыйныф сәгатенә җыелдык. Әйдәгез, аның тормышы һәм иҗаты белән тулырак танышып үтик.

**Илһам:** Клара Гариф кызы Булатова 1936 елның 18 мартында Татарстан АССРның Сарман районы Татар Карамалысы авылында хезмәткәр гаиләсендә туган. Аның әтисе математика, ә әнисе тел-әдәбият укытучысы булган, шуңа күрә Кларага бала чактан ук әти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күчеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә, өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, ә урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыга. Шул ук елның көзеннән К. Булатова хезмәт юлын башлый: Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч классларда балалар укыта, аннан соң төзелештә эшли, Әлмәттәге көнкүреш комбинатында кассир, «Төзүчеләр» клубында оештыручы була. 1962-1965 елларда ул яңадан мәктәптә – Әлмәт районының Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта.

**Нәзилә:** К. Булатованың шигъри иҗаты да нәкъ шул чорда тернәкләнеп китә. Әле мәктәп елларында ук аерым шигырьләре матбугатта күренгән яшь шагыйрә актив рәвештә Әлмәттәге әдәби түгәрәккә йөри, һәм 1956 елдан башлап «Татарстан яшьләре», «Совет Татарстаны» («Социалистик Татарстан») газеталарында, «Пионер» («Ялкын»), «Азат хатын», «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналларында аның күп кенә шигырьләре дөнья күрә. Бераздан аерым шигъри цикллары «Идел» альманахы, «Яшь үрентеләр» кебек күмәк җыентыкларда басыла.

**Марат:** 1965-1969 елларда К. Булатова В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Уку белән бергә иҗат эшен дә дәвам иттерә: 1965 елда аның шигъри бәйләме «Дуслык» исемле күмәк җыентыкта басылып чыга. Шагыйрәнең исеме тәнкыйтьтә җылы сүз белән телгә алына башлый. 1967 елда «Язлар алда» исемле мөстәкыйль китабы – лирик шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

**Зарина:** Университетны тәмамлаганнан соң К. Булатова Әлмәт районының Яңа Кәшер урта мәктәбенә тел әдәбият укытучысы булып китә. Тәҗрибәле укытучы буларак, 1978 елда аңа РСФСР Мәгариф министрлыгы тарафыннан «Укытучы-методист» дигән мактаулы исем бирелә.

**Айнур:** Җитмешенче елларда шагыйрә тагын берничә шигырь җыентыгы чыгарды. Аның бер бәйләм шигырьләре русчага тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә «Детская литература» нәшриятында чыккан «Песня, мечта и любовь» («Җыр, хыял һәм мәхәббәт») исемле күмәк җыентыкка да кертелгән. Шагыйрәнең егерме елдан артык иҗат эшчәнлеген чагылдырган

шигырьләре 1981 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Гел кояшка карап» исемле күләмле китабында урын алган.

**Аделина:** К. Булатова – 1970 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы. Клара Булатова шагыйрә генә түгел,шулай ук ул публицист та, журналист та, юмор остасы да, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе дә.

**Дилия: «Татарстан, бәхет җырым син» шигырен укый.**

**Укытучы:** Укучылар, ә сез үзегезнең киләсәгегезне кайда күз алдына китерәсез?

**Адель:** Минем үземнең туган ягымнан беркая да китәсем килми. Туган бистәмне яратам. Әти-әниемне, туганнарымны, укытучыларымны яратам. Сез беләсезме Клара Булатова да аның әти-әнисе дә укытучы булганнар. Шуңа күрә дә ул үзенең күп кенә шигырләрен укытучыларга багышлаган. Мин сезгә К.Булатованың «**Укытучы апаң йокламаган»** сөйләп күрсәтәм.

**Укытучы:** Әйе, укытучы булу җинел хезмәт түгел. Ул барыбыз өчен дә төн йокыларын калдырып, хезмәт түккән. Клара Булатова озак еллар буена Әлмәт шәһәрендә укытучы булып эшләгән. Шуңа күрә мәктәп темасы Клара Булатованың китапларында зур урын били. Ләкин бу – иҗат өчен азык бирүче гади бер эш кенә түгел. Мәктәп – яшь буынның киләчәк язмышын хәл итү урыны, яшь буын өчен көрәш мәйданы. Моны аңлау бүген бигрәк тә мөһим. Ул көрәштә укытучы – төп фигура, үтә җаваплы вазифа башкаручы. Аның яшь кенә булса да сизгер, игътибарлы, нечкә күңелле булуы аеруча зарур, аеруча мөһим. Ә инде мәктәптә шагыйрәнең эшләве – балалар өчен бик тә зур бәхет!

**IV. Йомгаклау:** Без К. Булатованың китапларын укырга, шигырьләрен ятларга тиешбез. Чөнки шагыйрә балаларны акыллы, тәртипле, шәфкатьле, миһербанлы, инсафлы булып үсәргә өнди.Туган җирне яратырга чакыра. Әти-әниләрне олылауны, хөрмәт итүне таләп итә.

Без якташыбыз К. Булатова кебек шәхесләребез белән чиксез горурланабыз. Аларның исемнәренә тап төшермичә, тырышып эшләргә, укырга тиешбез!

## Җиңүне якынайткан җыр

(8 нче сыйныфның рус төркемендә туган (татар) әдәбияты дәресе)

Рәхмәтуллина Чулпан Хәниф кызы, 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе, Минзәлә шәһәре

Максат: К.Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыру.

Планлаштырылган нәтиҗәләр:

М е т а п р е д м е т – сугыш, аның гади халык, балалар җилкәсенә алып килгән авырлыгын аңлау.

П р е д м е т – Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты турында белешмә бирү, «Башым иям» шигырен өйрәнү.

Ш ә х е с к ә к а г ы л ы ш л ы – якыннарыңа, туганнарыңа карата ихтирам, мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләү.

Дәрес тибы: яңа белемнәрне үзләштерү

Методлар: өлешчә эзләнү, сәнгатьле уку

Эшчәнлек төрләре: сүзлек өстендә эш, әңгәмә үткәрү, сорауларга җавап бирү, техник чаралардан файдалану.

Предметара бәйләнеш: рус әдәбияты, тарих

Җиһазлау: К.Булатова портреты, мультимедиа проекторы, слайдлар, видеоязмалар, К.Булатова китаплары.

Дәреслек: Ә.Р. Мотыйгуллина, Р.Г. Ханнанов, Р.Һ.Вәлиуллина «Татар әдәбияты» 8 нче сыйныф. Казан, «Мәгариф-вакыт» нәшрияты (118—120 нче битләр).

Дәрес барышы:

I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.

1. Дәресне оештыру.
Уңай психологик халәт тудыру.
2. Белемнәрне актуальләштерү.
1) Өй эшен тикшерү: бирелгән текстларның эчтәлеге турында фикер алышу.
2) Сорауларга җавап бирү.
- Бөек Ватан сугышы ничәнче елда башланган?
- Сезнең карт бабаларыгыз сугышта катнашканмы?
- Сугыш турында укыган әсәрләрне исегезгә төшерегез.
- Сез сугышта катнашкан кайсы язучыларны беләсез?
3. Уку мәсьәләсен кую.
- Укучылар, бүгенге дәрес темасын әйтә алырсызмы? ( Сугыш темасы)
- Әйе, сугыш темасы. Һәм шагыйрә Клара Булатова иҗаты белән танышачакбыз.
II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.
1. Клара Булатова иҗаты белән таныштыру.
1) Шагыйрәнең китапларын, презентация күрсәтеп, аның тормышы һәм иҗаты турында сөйләү.

Шагыйрә Клара Булатова 1936 елның 18 мартында Сарман районы Татар Карамалысы авылында туган. Аның әтисе дә, әнисе дә укытучылар була, шуңа күрә Кларага, бала чактан ук, әти-әниләре белән бергә бер төбәктән икенче төбәккә күчеп йөрергә һәм төрле авыл мәктәпләрендә укырга туры килә. 1944 елда ул Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска керә, өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укый, урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыга. Шул ук елның көзеннән К.Булатова хезмәт юлын башлый – Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч классларда укыта, аннан соң төзелештә эшли; Әлмәттәге көнкүреш комбинатында – кассир, «Төзүчеләр» клубында оештыручы була. 1962-1965 нче елларда ул яңадан мәктәптә – Әлмәт районының Колшәрип авылында тел-әдәбият, тарих укыта. К.Булатованың шигъри иҗаты да нәкъ шул чорда тернәкләнеп китә. Әле мәктәп елларында ук аерым шигырьләре матбугатта күренгән яшь шагыйрә актив рәвештә Әлмәттәге әдәби түгәрәккә йөри һәм, 1956 елдан башлап, «Татарстан яшьләре», «Совет Татарстаны» газеталарында, «Пионер» («Ялкын»), «Азат хатын», «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналларында аның күп кенә шигырьләре дөнья күрә. Бераздан аерым шигъри цикллары «Идел» альманахы, «Яшь үрентеләр» кебек күмәк җыентыкларда басыла. Ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. Аннан ул башы-аягы белән мәктәпкә чума һәм үзенә яңа бер дөнья ача – балалар дөньясы. Балалар күңеле аның җанына яктылык биреп, шигырьләренә нур өсти.

Клара ханымның шигырьләре туган якка, газиз туфрагына тирән мәхәббәт белән сугарылган. Шагыйрә туган ягының гүзәл табигатенә, иксез-чиксез хәзинә байлыкларына, тырыш, хезмәт сөючән, батыр, фидакарь халкына мәдхия җырлый.

2) Бер укучы дәреслектән Клара Булатова турындагы белешмәне укый, аңлашылмаган сүзләр тәрҗемә ителә.
3) Сорауларга җавап бирү.
- Клара Булатова ничәнче елда туган?
- К.Булатова нинди авылда туган?
- Колшәрип авылында нинди фәннәр укыткан?
- Аның нинди китаплары басылып чыккан?
Шагыйрәнең басылып чыккан китап исемнәрен әйтегез, дәфтәрләргә язып куябыз.
2. Сүзлек белән эш.
1) Сүзләрне укыйм, укучылар кабатлыйлар. Авыр сүзләрне аерым укучылардан кабатлаттырам.
Ялангачлык – бедность, нищета
Тәпи – ножка (ребенка)
Камыл – стерня, жнивьё
Кышлау – зимовать, перезимовать
Башак – колос
Кара – чернила

Шәп-шәмәхә – посиневший
Күшегү – зябнуть
Теркәлү – записаться, зарегистрироваться
Карт-коры – старые, пожилые люди.
2) Укытучы русчасын әйтә, укучылар тәрҗемәсен укыйлар.
3) Укучылар чылбыр буенча яңа сүзләр белән сүзтезмәләр яки җөмләләр төзеп әйтәләр.
3. «Башым иям» шигыре белән таныштыру.
1) Укытучы шигырьне сәнгатьле укый.
2) Шигырьне укучылар үзлекләреннән укыйлар.
3) Берничә укучы шигырьне кычкырып укый.
4) Укучылар шигырьне тәрҗемә итәләр.
5) Сорауларга җавап бирү:
– Шигырь нәрсә һәм кемнәр турында?
– Шигырьдәге лирик герой кем? Ул кайсы вакыйгалар турында сөйли?
– Шигырь нинди хисләр белән укыла? (Сагыш – балачагы сугыш елларына туры килсә дә, автор аны сагынып искә ала, куаныч, борчылу һ.б.) Кайсы хисләр өстенлек итә? Без нинди шигырьләрне шулай укыйбыз?
– Сугыш елларында балалар мәктәпләрдә укыймы? Шигырьдә бу турында нәрсә әйтелә? (Мисалга шигырьдән өзекләр китерелә.)
–Лирик герой мәктәп тормышын ничек сурәтли? Укучылар нәрсә белән һәм нәрсәләрдә язганнар? Аларның дәфтәрләре булганмы?
– Балалар сугыштагы аталарын ничек, нәрсә белән куандырырга тырышканнар? Шул урынны табып, укып күрсәтегез.
– Баларның күңелләрен нәрсә тынычландырган, нәрсә аларның җаннарына «ул чак күпме җылы салган»? (Тукай, Такташ,Пушкин шигырьләре.)
– Түбәндәге юлларны ничек аңлыйсыз?
«Салкында да безнең җаннар туңмаганнар
Ач-ялангач өшеп үскән шул заманда»...
6) Шигырьнең соңгы ике строфасын яңадан кычкырып уку.
Фикер алышу.
– Шигырьдә сүз нинди җыр турында бара? Ул җыр нинди көчкә ия? Сугыш турындагы җырларны исегезгә төшерегез.
III. Рефлексив бәяләү.
1. Укучылар, К.Булатованың биографиясен тагын бер кат искә төшерик. Шагыйрәнең балачагы сугыш елларына туры килүен ассызыклау, «Башым иям» шигыренең эчтәлеге белән бәйләү. Бәяләү. Укучыларга билгеләр куела.
3. Өй эше: а) шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә; б) «Җиңү бәйрәме» темасына кечкенә хикәя язарга

## Әзһәр Габидинең иҗат кичәсе

(педагогик проект)

Исрафилова Фәридә Рәшит кызы, Җәлил бистәсенең «Аленушка» балалар бакчасы тәрбиячесе, Сарман районы

Кичәнең максаты: балаларга Әзһәр Габиди иҗаты аша шигырьләренә һәм китапларына кызыксыну уяту. Әзһәр аганың тормыш юлын иҗатын тирәнрәк өйрәнү.
Кичәгә әзерлек чаралары һәм җиһазлар.
Ә. Габидинең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган күргәзмә. Күргәзмәнең исеме «Янсын гомер учагы».

Күзләр булса да кыраулы.
Алтын аның кочагы,
Сүнмәсен әле, сүнмәсен

1 бүлек: «Шигъри дөнья тылсымчысы»
2 бүлек: «Мин – зәңгәр тау улы».
3 бүлек: « Гомер көзем».


1 а.б. : Сарман ягы талантларга бай. Бүгенге көндә Сарман якларыннан 25ләп шагыйрь һәм прозаик үсеп чыкты. Бу кадәр язучының әлегә Арчадан кала республикабызның бер генә төбәге дә бирә алганы юк. Шулар арасыннан балалар һәм зурлар өчен дә матур-матур шигырьләр иҗат итүче язучыбыз Әзһәр ага Габидине дә атарга була. Бүгенге кичәне якташыбыз Әзһәр ага Габиди иҗатына багышлыйбыз.

2 а.б. Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин 1926 елның 26 сентябрендә Сарман районы Чукмарлы авылында урта хәлле крестьян семьясында туа. Җидееллык мәктәпне бетереп, Сарман урта мәктәбендә укып, унынчы классны тәмамлап, фронтка китә һәм, яраланып, госпитальлләрдә ята. 1945 елда «Тревога» исемле фронт газетасы типографиясендә аның «Борылмалы юллардан» исемле китабы басыла. Әзһәр ага Габиди соңгы елларда бик актив язган, еш кына газета-журналларда шигырьләре басылып чыккан.

1.Әзһәр ага Габиди башлыча балалар шигъриятенә хезмәт итте.

Язучының бүгенге көнгә балалар өчен «Тапкырҗан табышмаклары», «Кошчыгым», «Калган эшкә кар ява», «Таң сәгате», «Без яз дуслары», «Югалган кояш» китаплары дөнья күргән.

Әзһәр ага Габидинең балалар өчен язган шигырьләре туган як, андагы вакыйгалар, күренешләр турында. Аларның һәркайсына шагыйрь балалар күзлегеннән карап бәя бирә.



Ә хәзер, балалар сезнең игътибарга Әзһәр ага Габидинең язылышлары бер үк, ләкин мәгънәләре төрле-төрле булган шигырьләрдән уен уйнап алыйк.

Һәр шигырьдән соң балалар бер үк сүзнең төрле мәгънәгә ия булуын аңлата.

Яз килүнең беренче билгесе – ләйсән яңгыр. Шагыйрьнең ләйсән яңгыры энҗеләр сибелгән сыман, тамчылары да: «Сине сагындык!» дигән күк, җирне үбәләр.

2. Никадәр матур чагыштырулар, гүзәл сынландырулар! Мондый якны яратмаган җирдән яратырсың, мондый җирләрне сөймәс җирдән сөярсең. Авыл баласы кечкенәдән үк җиргә гашыйк, җирне сөя, аның хикмәтләрен белә. Җир җиләге нигә бик тәмле? «Әллә әни аңа шикәр сибәме?».

1. Туган ил, туган җир темасы Ә. Габидинең балалар өчен язган шигырьләрендә кызыл җеп булып сузылган. Төрле образлар аша ул туган як җиренең уңдырышлылыгы, муллыгы турында сөйли. Мәсәлән, «Нарат» шигыре.

2. Шул рәвешле шагыйрь яшь укучысына: «Туган жиреңнән аерылма, аерылсаң рәхәт күрмәссең», – дип әйтә сыман.

Ә. Габидинең шигырьләрендә кеше белән табигать нык берләшкән. «Таң гөле» шигырен тыңлап үтик.

1. Тау буенда кешеләр утырткан гөл үсә. Җил аның ал керфеген сыйпый, былбыллар аңа кунып сайрый, ак болытлар яңгыр булып тама. Гөл үзе дә җавапсыз калмый шат: күңелләргә хуш исләрен бүләк итә. Бактың исә, без үзебез дә җир-әнкәйнең гөле икән бит, шуңа күрә безгә туган якта рәхәт, иркен, күңелле.

2. Ә. Габиди балалар психологиясенә хас булган тискәре сыйфатлардан көлә, уңай сыйфатларга, киресенчә, дан җырлый, бу сыйфатларны яшь укучыда күрергә тели. Бу турыда шагыйрь ачыктан-ачык әйтми, ә бәлки киная белән яшь укучыга нәтиҗәләр ясарлык итеп сөйли. «Һавалы чеби» шигырендәге чуар тавык чебие кебек һаваланып йөрсәң, песи тырнагына эләгерсең, «аерылганны аю түгел, песи дә ашый».

1 Карак мәче кебек булсаң, келәткә кереп май урлап йөрсәң, тычкан көләрлек хәлдә калырсың, – ди язучы.

Балаларның зиһенен баетуда, уйлау-фикерләү сәләтен үстерүдә дә Әзһәр аганың күп кенә табышмаклары игътибарга лаек. Әйдәгез әле, без дә зиһеннәребезне тикшереп «Булсаң зирәк – әйт тизрәк!» дигән табышмак әйтү уенын уйнап алыйк.

2. Язучының кайбер шигырьләре хезмәткә, батырлыкка, кыюлыкка чакыра, төрле профессия кешеләренә хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияли. «Бал кортлары», «Кораб», «Җайдаклар», «Җырлы урамнар», «Шофер» шигырьләре – шундыйлардан. Алар да балалар теле белән, бала күңеленә барып җитәрлек итеп язылган.
1 . Әзһәр Габиди төрле күренешләргә бала күзаллавынча бәя бирә белә. Өч яшьлек Әбүзәргә ап-ак мыек үскән. Мондый хәлнең булуы мөмкинме соң? Мөмкин икән шул: «Мыеклы малай» шигыре.
2. Кемнең генә кечкенә чакта катык-мыек үстереп караганы булмады икән? Шагыйрьнең нәни геройлары гел яхшылык эшләүдә. («Елка», «Аптырап калмаган», «Гөләндәм сәгате», «Нигә уты күренми»). Балалар тормышны үзләренчә өйрәнәләр. Мондый шигырьләрне укып үскәч, алар, һичшиксез, акны карадан, яхшыны начардан аера беләләр.

Әзһәр ага, табышмакларына җавап таптыру өчен баланың хәтер сандыгын актарып, бик тиз зиһен йөртүне таләп итә.

Әзһәр аганың балалар психологиясен аңлап, аларның белемнәрен баетуга юнәлдерелгән табышмак-шарадаларын укып үтик.

Бала :

Үз бәхетең юллап чыккан чакта
Кеше кайгысын син күрмәсәң,
Үз жаныңа уртак итеп алып
Тигез итеп аны белмәсәң.
Ялгыз шатлык шатлык буламыни –
Ялгыз шатлык бит ул гомерсез,
Кешеләргә дәрт, дәрман да бирми
Һәм ул юкка чыга бер эзсез.
Зур жаныңны күреп үз яныңа
Сыенсын дисәң син кешене –
Үзең юллап чыккан бәхетеңнән
Аларга да чыгар өлешне.

1 Әзһәр ага авыр һәм катлаулы тормыш юлын үткән. Унсигезе дә тулмас борын – фронт, аннары- төрле төзелешләр, редакция, мәктәп. «Юк китәсе килми» шигыре биографиясенә ачык мисал.
2. Әмма Әзһәр аганың күңелендә заманга да, Ватанга да һичнинди үпкәсе юк, ул һаман да сабый бала сыман эчкерсез, самими һәм садә.
1 Әзһәр ага – ачлыкны, ялангачлыкны үз җилкәсендә бик нык татыган шагыйрь. «Урыны булсын табында» – шигыре моның ачык мисалы.
2.Йомгаклап шуны әйтәсе килә.

Әзһәр Габиди – балалар әдәбиятының танылган өлкән шагыйре. Ул инде кечкенә дусларыбыз өчен әсәрләр иҗат иткән, аларны уннарча китапларга туплап бастырып чыгарган һәм укучыларыбыз кулына ирештергән. Шунысы куанычлы, аның китаплары кибет шүрлекләрендә тузан җыеп ятмый

## Укытучы көндәлегеннән

(Клара Булатова иҗаты буенча әдәби кичә)

Аглиева Гүзәл Гаптелрәшит кызы, 1 нче урта мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Минзәлә шәһәре

Чараның максаты: Татар поэзиясендә якты йолдыз булган Клара Булатова иҗатының күпкырлы, эзлекле һәм мәгънәле булуын күрсәтү. Шагыйрә иҗатында укытучы образын чагылдырган әсәрләр белән танышу.
Чараның бурычлары:Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты турындагы белемнәрне тулыландыру, ныгыту; туган телгә, укытучы образына карата хөрмәт, мәхәббәт хисләре тәрбияләү.
Җиһазлау: К.Булатованың портреты, экран, кичә фоны – салмак көй, китап җыентыклары.

Кичә барышы.

Сәхнә бәйрәм рухына туры китереп бизәлгән. Түрдә экран, талгын көй агыла. Экранда Клара Булатова портреты пәйда була. Шагыйрәнең китапларыннан күргәзмә оештырылган.

*Бәйрәм «Шушы яктан, шушы туфрактан без» җыры белән башланып китә. Җырны берничә укучы башкара.*

Сәхнәгә алып баручылар чыга.

1 нче алып баручы. Хәерле көн, кадерле кунаклар.

2 нче алып баручы. Хәерле көн, шигырь яратучы дусларыбыз. Бәйрәмгә килгән барлык кунакларыбызга кайнар сәлам.

1нче алып баручы. Шушындый күркәм залга җыелубызның максаты – Клара апа Булатова шигырьләрен искә төшерү. Быелгы ел аеруча үзенчәлекле ел. Шагыйрәнең юбилей елы. Кичәбезнең исеме «Укытучы көндәлегеннән» дип атала. Ни өчен шулай аталганын сез кичә барышында аңларсыз.

2 нче алып баручы. Клара Булатова шигърияткә илленче елларның азагы – алтмышынчы елларның башында, үз заманының ашкынулы уй-кичерешләрен, оптимистик күтәренке рухын чагылдырган Яшьлек, Мәхәббәт җырчысы буларак килеп керде.

1 нче алып баручы Клара Булатова – дистәдән артык шигъри китап авторы. Аның нигездә традицион татар шигыре калыбында иҗат ителгән лирикасында тормышта кайгы-хәсрәтен дә, сөенеч-шатлыкларын да күп күргән хатын-кыз шәхесенең хис-тойгылары, мәхәббәт кичерешләре, гомер турында, туган җир, заман, кеше язмышы, мәңгелек турында фәлсәфи уйланулары, сагыш-әрнүләре сурәтле чагылыш таба. Аның шигъри теле халыкчан гыйбарәләргә, отышлы чагыштыру-метафораларга бай булуы, фикер-хисләренең ихласлыгы белән үзенә тарта.

Клара апа Булатованың тормыш юлын искә төшереп китсәк, бик урынлы булыр дип уйлыйм.

*Сәхнә артында кыз бала биографияне «мин» исеменнән сөйли. Экранда презентация бара.*

Мин, Клара Гариф кызы Булатова тумышым белән Татарстанның Сарман районы Татар Карамалысы авылыннан булсам да, бөтен тормыш юлым, иҗатым Әлмәт төбәге белән бәйле. 1944 елда Сарман районының Югары Чыршылы авылында беренче класска кердем, өченче класстан Ләке авылы җидееллык мәктәбендә укыдым, ә урта белемне Сарман урта мәктәбендә 1954 елда алып чыктым. Шул ук елның көзеннән хезмәт юлымны башладым: Түбән Ләшәү мәктәбендә башлангыч классларда балалар укыттым.

Гомеремнең кырык елдан артыгын мин балалар укытуга багышладым. Тәҗрибәле укытучы буларак, миңа РСФСР Мәгариф министрлыгының «Укытучы методист» (1978) һәм «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» (1986) дигән мактаулы исемнәр бирелә, 1996 елда Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләндем. Әти-әнием дә үз гомерләрен балалар укытуга багышладылар. Үз иҗатымда төрле проблемаларны күтәреп, төрле темаларга иҗат иттем.

*Залга әкрен генә Әни образы килеп керә. Ул кызын җитәкләгән. Кыз бала «Әниемә» дигән шигырен укый. Әни аны иркәли, сөя, игътибар белән тыңлый.*

Әниемә.

Мин синнән дәрес алмадым,
Аз гына соңга калдым.
Шулай да тормыш сабагын
Мин башлап синнән алдым.
Син башлап хәреф өйрәттең,
Әлифне, яңалифен.
Тукайлы, җырлы, шигырьле
Дөньяга әйдәп керттең.
Ул чакны телевизор да,
Кино да – телең булды.
Телеңнән күчкән бар нәрсә,
Гомерлек белем булды.
Сөйләгән әсәрләреңне

Күңелдән әле беләм.
Мавыктым гомер буена
Мин синең фәнең белән.
Тукайлы, җырлы дәрескә
Кергәндә иртән килеп,
һәрвакыт әни остазым
Ияреп керә кебек.

2 нче алып баручы:

«Әнием» шигыре аша Клара апага беренче белемне әнисе бирүен аңлыйбыз. Әнисе өйрәткән әсәрләр аша туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләвен, әнисе үрнәгендә үзе дә татар теле һәм әдәбияты укытучысы һөнәрен сайлавын әйтә.

Укытучысыз кеше булмый,
Ул – һава кебек кирәк.
Укытучың булмаганда
Тибүдән туктый йөрәк. (Раил Гатауллин)

Бүгенге кичәдә Клара Булатованың укытучыларга багышланган шигырьләренә тукталып китәсе килә.

1нче алып баручы. «Беренче укытучыма» дигән шигырьне 9 нчы сыйныф укучысы Закирова Рания укый.

2 нче алып баручы. Бу шигырендә автор беренче укытучысына мөрәҗәгать итә, аны беркайчан да исеннән чыгармавын ассызыклый. Укытучысын якын итеп, үз итеп беренче апам дип атый.

1 нче алып баручы. Хөрмәтле тамашачыбыз. Татар халкының биюе иң бай һәм иң матур бию. Сезнең алдыгызда Тюкина Полина татар халык биюен башкара.

3 нче алып баручы: *Сәхнәгә егет чыга. Ул шагыйрәнең иҗаты турында сөйли.*

Укытучылык хезмәте – Клара Булатова иҗатының буеннан-буена сузылган үзәк темаларның берсе. Яшьлек оптимизмы, тормышны ихлас ярату, аның киләчәгенә тирән ышану, самими кичерешләр... авторның шушы үз профессиясе-белгечлеге үзенчәлекләрен тасвирлаган шигъри юлларыннан да ташып-ургылып тора.

2 нче алып баручы. Чыннан да, шагыйрә бу яраткан хезмәтенә бәхетенең югары бер чагылышы итеп карый. Моны без «Укытучы бәхете» дигән шигырьдә күрәбез.

*«Укытучы бәхете» дигән шигырь укыла.*

1 нче алып баручы. Укытучының чын бәхете – балалар өчен төн йокламый дәрескә әзерләнеп утыру.

*«Укытучы апаң йокламаган ...» шигырен 5 нче сыйныф укучылары укый. Шигырьне инсценировка формасында башкаралар.*

3 нче алып баручы.

*Сәхнәгә яңадан егет чыга. Ул сөйләвен дәвам итә.*

*«Остаз дияр идем мин...»* шигырендә дә укытучыларның һәм остазларның гүзәл образы яктыртыта. Клара Булатова балаларга белем бирүче, ягъни мәгърифәтле итүчеләрне кояш белән тиңли. Кояш бар дөньяны яктыртып, җылытып, кешелеккә тормыш бирсә, укытучы кояштай балаларның күңелен җылытып, аң-белем биреп яктырта, ди. Андый кешеләргә минем хөрмәтем бик зур, җанымны да фида итәргә әзер, дип Укытучы образын югары күтәрә.

*«Остаз дияр идем мин...» шигырен 10 нчы сыйныф укучысы Ардыханова Адилә укый.*

2 нче алып баручы. Шагыйрәнең әнисе турында әйтелде. Берничә җөмлә әтисе турындада әйтсәк, дөрес булыр дип уйлыйбыз. Әтисе 27 ел буе мәктәп директоры булып эшләгән.Фидакарь хезмәт куйган, эшенә тугъры булган. Клара апа үзенең холкы-фигыле белән әтисенә ошавын әйтә.Аңа атап язылган шигырьне тыңлап үтик.

*«Әтиемә» шигырен 9 нчы сыйныф укучысы Гәрәева Гөлназ укый.*

*«Рәхмәт сиңа, әтием» җыры башкарыла.*

1 нче алып баручы. Клара апа үзе дә әтисе юлыннан киткән, гомере буе балаларга белем биргән мөгаллимә-шагыйрь. Аның «Укытучы-монологы», «Җаваплылык күпме синең иңдә...», «Укытучы апа шигырь яза» шигырьләре – укытучы дигән бөек исемне югары

күтәрә торган әсәрләр. Мондый рухтагы шигырьләр укучыга, бүгенге заман укытучысына да бик кирәк.
2 нче алып баручы. Клара Булатова тәрбия, әхлак, намус төшенчәләре, тырышлык, гореф-гадәтләрнең сакланышы өчен көрәшә. Халыкчанлык рухы белән укучы күңеленә үтеп керә. Шагыйрә чын мәгънәсендә популяр, аның шигърияте безнең өчен үрнәк тә, үзенә күрә бер дәрес-сабак та. Ул – тере, тормышчан, тонықланмас иҗат!
3 нче алып баручы. Безнең әдәби кичәбез ахырына якынлашты. Бүгенге кичәдә яңгыраган шигырьләр сезнең күңелегездә якты хисләр уяткандыр дип уйлыйбыз. Клара Булатова иҗатын тирәнтен өйрәнүгә кызыксынуыгыз арткандыр дип ышанабыз.

**Әзһәр Габиди – шигъри дөнья тылсымчысы**

Хәйретдинова Роза Җәмилевна, сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен
9 нчы Зәй мәктәбе укытучысы

Максат: укытучы, фронтовик, шагыйрь Әзһәр Габиди турында мәгълүмат бирү; аның әсәрләре белән танышу, аларга кызыксыну уяту; шагыйрьнең шигырьләре аша туган якның матурлыгын күрә белергә өйрәтү; туган төбәккә мәхәббәт хисләре тәрбияләү.
Җиһазлау: Әзһәр Габиди һәм аның иҗаты һәм тормыш юлына багышланган китап күргәзмәсе, аның әсәрләренә балалар ясаган рәсемнәр күргәзмәсе, Дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесе «Сәламәтлеге чикләнгән балалар өчен 9нчы Зәй мәктәбе» «Шушы яктан, шушы төбәктән без» газетасы, 2 февраль, 2021 ел, № 1, презентация.
1нче алып баручы. Ерак - ерак бер шәһәрдә Өлкән рәссам яшәгән, ди, Өй түбәсендә чардакта Ул рәсемнәр ясаган, ди. Төннәр буе эшләсә дә Һич ял итәм димәгән ул? Көннәр – рәсем, ә кич белән Әкиятләр сөйләгән ул. Бүген без кичәбезне кырык ел гомерен укучыларга белем бирүгә, үзенең шигырьләре һәм әкиятләре белән туган җиребезнең матурлыгын тоярга өйрәткән әсәрләр язучы Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин иҗатына багышлыйбыз (1нче слайд ).
2нче алып баручы. Ул 1926 елның 25 сентябрендә Сарман районының Чукмарлы авылында дөньяга килгән. Әзһәр Габиди Бөек Ватан сугышында катнаша. 1945 елда япон сугышында бик каты яралана, бер ел дәвамында госпитальдә дәвалана. 1946 елда туган авылына кайта. 1950 елда Минзәлә педагогика көллиятендә белем ала. Үзенең хезмәт юлын Сарман район мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып башлый (2нче слайд). (3 нче слайдтагы рәсемгә игътибарны юнәлтү).
1нче алып баручы. Сез ничек уйлыйсыз, шагыйрь шигырьләрендә нәрсәне сурәтли? (3нче слайд)
Укучылар. Шагыйрь туган як табигатен сурәтли.
Берсе яшел келәм тукый,
Берсе сарыга мана,
Берсе ак мамыгын түши,
Ә берсе җыеп ала.
Укучылар. Ел фасыллары.
2 нче алып баручы. Нинди ел фасыллары беләсез?
Укучылар. Яз, җәй, көз, кыш.
1 нче алып баручы. Шагыйрьнең туган авылы гүзәл табигать кочагында урнашкан. Урманындагы байлык, авыл чишмәләренең саф сулары, ипигә ягып ашарлык саф һавасы хакында ничек матурдан - матур шигырьләр ничек иҗат итмисең ди. Әзһәр Габиди иҗатында табигатьнең иң матур ел фасылларын сурәтләнә.(Китап күргәзмәсенә күзәтү) Шагыйрь ел фасылларын бизәк-нәкышләргә бизәп, энҗе-мәрҗәннәргә төреп, сүзләр, җөмләләргә тезеп әйтә. Һәр айның үз төсе бар. Һәр ел фасылы үзенчә матур (4нче слайд).
1нче укучы. Кил, назлы яз!
Көлеп ятсын
Күлләвекләр,
Челтерәсен

Гөрләвекләр.
Кыр казлары
Кыйгакласын,
Күл камышы
Кыяклансын.
Яшәрсеннәр
Киң болыннар,
Кешнәсеннәр
Яшь колыннар.
Иссен җирдә
Җылы җилләр,
Көлсен көнгә
Алсу гөлләр
2 нче алып баручы. Ямьле яз җиткәч, кара каргалар килүе хөрмәтенә карга боткасы пешерәләр.
Мактана алам – эшем гел ходта,
Пешерәм ашлар, пешерәм ботка.
Укучылар: Казан. Бик дөрес, карга боткасын чуен казанда пешерәләр.
2нче укучы. Карга боткасы
Ындыр артындагы талда
Күпме карга оясы!
Туздырмыйм –
Торсыннар шунда,
Кызык аның йоласы.
Яз җиттеме безнең әби
Ясый карга боткасы,
Бөтен авыл баласы.
Аның яме! Аның тәме –
Телләреңне йотарлык!
Аның тәмен ел буена
Саклап кына тотарлык.

Күмәк уен «Торналар»

– И, торналар, кайда булдыгыз?
– Бик ерак...
– Озын булдымы юлыгыз?
– Бик озак... Ә шулай да калмадык без
Югалып,
Сезгә килдек, якын дуслар,
Яз алып.
3 нче укучы. Кораб
Зәңгәр күктән кояш көлә
Алсу нурларын сибеп,
Урамда карлар эриләр
Аның җылысын сизеп.
Юллар буйлап челтер - челтер
Йөгерә гөрләвекләр,
Кораб агызып уйнарга
Күңелле язгы көннәр.
Җилкәнле корабым өйдә
Моңсуланып ятмасын,
Җибәрәм мин аны суга
Әйдә, алга юл алсын!
Кичеп көчле штормнар
Җитсен океаннарга,

– Диңгезче батыр үсә! - дип
Сөйләсен дулкыннарга.
1нче алып баручы. Бер ел фасылы икенчесен алыштыра. Тирә-юнь чәчәккә күмелә. Табигать матурлана. Бер-бер артлы шау-шулы җәй тамашаларын күз алдыннан үткәрәбез.
2 нче алып баручы.(5нче слайд) Яшел келәм өстендә
Утлы күмерләр көйри,
Кулга алсаң пешерми,
Авызга керсә, эри.
Укучылар:  Җир җиләге. (Әзһәр Габидинең «Бакчада» шигырен сәхнәләштерү).
1нче алып баручы. Тау артында янып тора
Кич җиттеме учагы,
Ләкин юктыр бу учакның
Төтен бөркегән чагы.
Укучылар: Кояш.
2 нче алып баручы. Бик дөрес, кояш. (Әзһәр Габидинең «Чыланган кояш» шигырен сәхнәләштерү).
1нче алып баручы. Кояшны болытлар каплый.
Җир йөзенә алтын көз канатын җәя.
Көз муллык китерә.
Табигатьтә сары төсләр хакимлек итәләр.
4нче укучы. Кыр казлары
Яшел җәйнең узган инде
Яшене, күкрәүләре,
Игеннән бушаган инде
Киң басу күкрәкләре.
Тургайлар җыр сузган күктә
Болытлар гына ага,
Кыр казлары каңгылдашып
Бездән китеп тә бара.

Әзһәр Габидинең «Җир алмасы» шигырен сәхнәләштерү.

2нче алып баручы.Кара җир өстен ак мамыктай кар каплый. Кар кояш яктысында зәңгәр булып күренә. Зәңгәр иңешләр, елгалар калын боз астында тирән йокыга талганнар. Старты юк – йөгертә, Гармуны юк – биетә, Куллары юк – чеметә, Нәрсә соң ул, кем әйтә?
Укучылар: Суык.
1 нче алып баручы. Кышның салкыннарына бирешмичә, балалар яңа ел бәйрәмен көтә, кошларга ашханә бүләк итә. («Нарат» шигыре укыла)

Әзһәр Габиди сүзләре Фәрит Хатыйпов көе «Минем гөлем!» җыры башкарыла.

2 нче алып баручы. Укучылар төсле карандашлар, буяулар белән табигатьне сурәтләргә яраталар. Табигать төрле ачык төсләрне үз эченә ала. Алар шагыйрьнең әсәрләренә рәсемнәр ясадылар.(Балалар сурәтләгән рәсемнәне күрсәтү, укучыларны бүләкләү.)
1 нче алып баручы. Әзһәр ага Габиди 1 һәм 2 дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнде. Аңа «Халык мәгарифе отличнигы», «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр бирелде. 1994нче елда Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде. Рафаил Төхфәтуллин исемендәге премиягә лаек булды.
2 нче алып баручы. Ул кечкенә дусларыбыз өчен берничә меңләгән әсәрләр иҗат итте, аларны егермедән артык китапка туплап бастырып чыгарды.

Укучылар шагыйрьнең мирасы дәвамлы, аның тәрбияви шигырьләрен укыйлар, кызыклы әкиятләрен, мәсәлләрен сәхнәләштерәләр, матур җырларын җырлыйлар, мавыктыргыч табышмакларына җавап эзлиләр.

Әзһәр Габидинең «Зәңгәр офык» легендасындагы рәссам сүзләре белән шагыйрь иҗатына багышланган кичәбезне тәмамлыйбыз.
– Атсын алсуланып таңнар,
Аяз торсын киң офыклар,

Зәңгәр булсын айлы кичләр,
Яшәсен бар ачык төсләр!

## Писатели и поэты моего края

Акимова С.А., Гараева М.Р., МБОУ Джалильский детский сад № 6 «Теремок» Сармановского района

Наша малая Родина – это Сармановский район. Удивителен и загадочен край, в котором мы живем. Невозможно описать словами бескрайние поля и луга, реки, озёра, леса. Здесь мы родились, росли и делали свои первые шаги. Каждый уголок её прекрасен и щедр. Недаром многие писатели и поэты воспевают наш край в своих стихах и рассказах.
Щедра наша земля природой, разнообразен его растительный и животный мир. И всё же главное его богатство – это люди: доброжелательные, гостеприимные, умные и знаменитые, которыми мы гордимся. А некоторые из них, о которых мы хотим сегодня рассказать, воспевали эту красоту в своих стихах и рассказах.

Желание познакомиться и познакомить своих воспитанников с талантливыми мастерами художественного слова и определило актуальность данной работы.

Исходя из этого, цель нашей работы заключается в формировании чувства любви к «малой Родине» через знакомство с творчеством знаменитых поэтов писателей.

Задачи выражаются в воспитании интереса к изучению своего родного края, желании учиться, знать поэтов и писателей, стремлении к чтению, любви к книге.

Краткая аннотация проекта

В каждой строчке стихотворений Сармановских поэтов звучит огромная, искренняя любовь к родному краю, восхищение его красотой. Проект направлен на изучение их творчества. Нам предстояло узнать и обобщить сведения о жизни и творчестве поэтов. Мы посетили школьную и сельскую библиотеки нашего поселка, изучили сборники стихотворений и информацию из интернета. Выделили, какие стихотворения написаны для детей.

Этапы работы над проектом:
- выбор темы проекта
- определение целей и формирование задач проекта
- работа с ресурсами интернета
- работа по сбору информации
- оформление материалов исследования
- разработка и накопление методических материалов
- беседы с коллегами детского сада ( обсуждение целей и задач проекта; формирование интереса по созданию условий для реализации проекта, рекомендаций по приобщению детей к творчеству писателей, к творчеству родного края)
- работа с родителями:

Анкетирование родителей по изучению и чтению книг
Папка-передвижка: «Писатели и поэты моего края»
- беседы с библиотекарем поселка по подбору книг творчества наших земляков;
- проведение образовательной деятельности с воспитанниками по ознакомлению с жизнью и творчеством Клары Булатовы, Азгара Габиди
- консультация для воспитателей: «Знакомство воспитанников с жизнью и творчеством наших земляков»

Основная часть

Славится наш район именитыми поэтами и писателями. Это люди, прославившие свою родную землю далеко за её пределами. Всех их объединяет любовь к родному краю, красоте окружающего мира. Они живут и жили радостями и тревогами своего времени, своей страны. В их произведениях звучат любовь к родным местам, людям.

***Клара Гарифовна Булатова***

Родилась 18 марта в деревне Татарские Карамалы Сармановского района ТАССР в семье учителя. Окончила Казанский государственный университет имени В.И.Ульянова Ленина. Живет в Альметьевске с первых дней основания. Работала на строительных площадках художественным руководителем в клубе «Строитель» рабочего поселка, в сельских библиотеках. Более тридцати лет активно участвует в художественной самодеятельности. Клара Гарифовна – поэтесса, заслуженный работник культуры Татарстана, лауреат премии им. Р.Тухватуллина. Она посвятила всю свою творческую деятельность воспеванию красоты альметьевской земли, труды нефтяников, тружеников сельчан.

Начала печататься в 1956 г. в журнале «Ялкын», «Азат хатын», «Казан утлары», «Чаян». Первый сборник лирических стихов «Язлар алда» («Впереди весна», 1967 г.) посвященных нефтяникам, труженикам села, строителям.

В сборниках «Һәрвакыт янымда» («Всегда со мной», 1969 г.), «Җәйләр җитсә» («Летняя пора», 1972 г.), «Печәнөсте» («Сенокос», 1986 г.), «Хәтертәрәзәләре» («Окна памяти», 1989 г.), «Миләш кагы» («Рябиновая пастила», 1991г.) выражены мысли и чувства нашего современника.

В основе поэзии К.Булатовой – радость жизни и созидательного труда, светлые чувства верности, дружбы и любви. Ее стихи для детей (сборник «Курка димәгез мине» –«Я не трус», 1994 г.) отличают душевная теплота и легкий юмор.

***Азгар Самигуллович Габиди***

Родился 26 сентября 1926 г., деревня Чукмарлы, ныне Сармановского района. В 1950 г. окончил Мензелинское педагогическое училище. В 1950–1980 гг. преподавал татарский язык и литературу в средней школе. Литературным творчеством занимался с 1942 г.

Печатался в респубиканских газетах и журналах, коллективных сборниках.

Автор сборников стихов для детей «Без – яз дуслары» («Мы – друзья весны», 1965 г.), «Тапкырҗан табышмаклары» («Загадки», 1966 г.), «Кошчыгым» («Птичка», 1981 г.), «Таң сәгате» («Жнец – зарница», 1989 г.), «Калган эшкә кар ява» («Что осталось, то пропало», 1993 г.), в которых тонко раскрывается детальное восприятие мира.

Лирического героя А.С.Габиди отличают искренность, тревога за судьбу родной земли (сборник «Болыннарым» – «Мои луга», 1997 г.).

Выступал с публицистическими и литературно-критическими статьями.

Участник Великой Отечественной войны.

Нам очень хочется знать о своих земляках всё больше и больше и этим мы заинтересовали своих воспитанников. Мы стали собирать о них информацию и оформлять альбомы. Это только начало нашей работы, которую мы собираемся продолжить.

Заключение

Мы очень горды, что родились именно на этой земле, где родились такие выдающиеся люди. Народ без прошлого не имеет будущего. Он должен помнить и знать прошлое и настоящее своего края. Существует мудрое изречение: «Чтобы человек был счастливым, у него должны быть «корни и крылья».

Ожидаемые результаты: Этот проект поможет нам в дальнейшей работе, так как этот год объявлен годом родных языков и народного единства. Мы более подробно будем знакомиться с творчеством этих писателей, а эта работа может прослужить очень хорошим материалом при проведении открытых мероприятий, семинаров и конференций.

**Оглавление**

**Шушы яктан, шушы туфрактан без ... 3**
**Ә тормыш, тормыш матур ул ... 8**
**Сарман үзен җырга салган ихлас җанлы улын онытмас ... 10**
**«Бәхетле очрак» уены ... 12**
**Зоопаркка сәяхәт ... 14**
**Талантлы син, Сарман ягым ... 17**
**Туган як һәм әни бер генә, син аларның кадерен бел генә ... 22**
**Әзһәр Габиди – укытучы, фронтовик, шагыйрь ... 26**
**Клара Булатованың иҗаты ... 29**
**Клара Булатова иҗаты ... 32**
**Могҗизалар кыры ... 35**
**Шагыйрә Клара Булатова иҗатына бер караш ... 37**
**Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты ... 38**
**Укытучы, шагыйрь, фронтовик ... 40**
**Күңелле шигырьләр иртәсе ... 42**
**Мин зур үскәч ... 44**
**Шушы яктан, шушы туфрактан без ... 46**
**Шушы яктан, шушы туфрактан... ... 48**
**Шушы яктан, шушы туфрактан без ... 52**
**Калган эшкә кар ява ... 53**
**Туган як җырчысы ... 55**
**Хәниф Хәйруллин тормыш юлы һәм иҗатына күзәтү ... 57**
**Сарман сандугачы якташыбыз шагыйрә Клара Булатованың иҗатына багышланган кичә ... 60**
**Туган як җырчылары ... 64**
**Туган туфракның тугры улы ... 69**
**Клара Булатова ижатында балалар дөньясы ... 71**
**Клара Булатова ижатында табигатькә мәхәббәт ... 72**
**Кем булса да – кеше булыгыз! ... 73**
**Сүнә белми торган ялкын ... 75**
**Күңелегезгә керәм янган ут булып! ... 77**
**«Тамчы – шоу» уены ... 79**

**Шушы яктан, шушы туфрактан без ........................................................ 83**
**Татарстан – бәхет җырым син!.............................................................. 86**
**Умножение натуральных чисел и его свойства ....................................... 88**
**Земляки юбиляры ................................................................................. 91**
**Клара Булатованың «Март башында» шигыре белән танышу ................. 93**
**Туган ягым әле онытмас…........................................................................ 94**
**Клара Булатова поэзиясенә хас тел-стиль үзенчәлекләре ........................ 96**
**К. Булатова шигырьләре ......................................................................... 100**
**Татар әдәбияты дәресе............................................................................... 104**
**Фигыльләрнең зат-сан белән төрләнеше. Контроль күчереп язу ........... 111**
**Шушы яктан, шушы туфрактан без ........................................................ 112**
**К.Булатова – безнең яраткан шагыйребез ................................................ 115**
**Үзеннән-үзе туа җыр ................................................................................ 116**
**Сүз төркемнәрен гомумиләштереп кабатлау темасы буенча якташ шагыйрәбез Клара Булатова шигырьләрен файдаланып эшләнгән контроль эш ........................................................................................ 118**
**Таяну ноктасы кайда?.................................................................................. 121**
**Рәхмәт сезгә, әнкәйләр! ........................................................................... 123**
**Марс – уңган егет ул ................................................................................. 125**
**Хезмәтем – мәңге картаймас шатлыгым чыганагы ................................. 127**
**Яңа китап – яңа дус.................................................................................... 129**
**Мәктәпкә әзерлек төркемендә балаларны Хәниф Хәйруллин иҗаты белән таныштыру ......................................................................... 130**
**«Ак каен» исемендәге җәйге ял аланында әдәби уку көне ...................... 132**
**Әзһәр Габиди – Сарманның йөзек кашы ................................................... 142**
**Укытучы – шагыйрь – фронтовик ............................................................ 145**
**Сарман ягы талантлары................................................................................ 147**
**Җир кешеләр белән матур .......................................................................... 152**
**«Үткәннәрне гомумиләштереп кабатлау» темасы буенча якташ язучыбыз Фәрит Яхин әсәрләрен файдаланып эшләнгән карточкалар ............................................................................................... 156**
**Синдә – яшьлек язларым, синдә – башлап язганым ................................. 159**
**Әзһәр Габиди иҗатына багышланган «Йолдыз сәгате» уены................. 162**
**Туган авылым шагыйрәсе Клара Булатова иҗаты.................................... 164**
**Бергә-бергә күңелле .................................................................................... 167**
**Бәхет кенә телик кешегә .............................................................................. 168**
**Минем бакчам – шигъри түтәлләр .............................................................. 171**

**Клара Булатова иҗатына багышланган «Тамчы шоу» уены ................ 173**
**Гомер учагында еллар яна... ........................................................... 175**
**Еллар кайтавазы – китап битләрендә.................................................. 177**
**Укытучы – мактаулы һөнәр ............................................................... 180**
**Знакомство с жизнью и творчеством Клары Булатовой ....................... 182**
**Сценарий КВН, посвященный жизни и творчеству Клары Булатовой, с применением биографии поэтессы ...................................... 183**
**Әзһәр Габиди иҗатында – сугыш ........................................................ 185**
**Клара Булатова – бәхетен туган ягында тапкан шагыйрә...................... 187**
**К.Булатова. «Шушы яктан, шушы туфрактан без» ................................ 189**
**Кем булсаң да – кеше булып кал.......................................................... 194**
**Чишмәләр җыры тынмасын................................................................. 197**
**Тапкырлар һәм зирәкләр ярышы .......................................................... 198**
**Урман читендәге имәннәр без............................................................... 199**
**Вариант устного собеседования для учащихся 9-х классов ................... 202**
**Татар теле – туган телем, безгә газиз анам теле .................................... 204**
**Дога яшәтә безне ................................................................................ 206**
**Шушы яктан, шушы туфрактан без ...................................................... 207**
**Always remember (Не забыть никогда…) из произведений К.Булатовой (технологическая карта урока) ........................................... 210**
**Рәнҗемәслек булсын оныклар .............................................................. 214**
**Әгәр дә син гөлләр булсаң, ак чәчәк атар идең....................................... 220**
**К.Булатованың «Әниемнең кызы юк бит» шигырен уку ........................ 226**
**Туган телем – алтын бишек ................................................................. 228**
**Шушы яктан, шушы туфрактан без… .................................................... 231**
**Клара Булатованың тормыш юлы һәм иҗаты буенча .............................. 235**
**Каурый канат – Җил Атым.................................................................... 237**
**Икмәк – безнең горурлык ..................................................................... 241**
**«Үз уеным» бәйгесе ............................................................................. 243**
**Классный час, посвященный 60-летию поэта, прозаика, доктора филологических наук, заслуженного работника культуры Татарстана и России Фарита Яхина .......................................... 244**
**Клара Булатованың «Ак каен» шигыренә иллюстрация башкару ........................................................................................... 246**
**Фәрит Яхин - күпкырлы шәхес ............................................................ 250**
**Күппочмаклыклар мәйданы .................................................................. 254**

**Тел өйрәнгәндә Әзһәр Габиди ижатын файдалану һәм фигыль турында төшенчә бирү ........ 256**
**Сарманыбызның Әзһәр Габидинең әдәби кунак бүлмәсендә очрашу ........ 260**
**Шушы яктан, шушы туфрактан без ........ 262**
**Татарстан, бәхет җырым син ........ 264**
**Җиңүне якынайткан җыр ........ 266**
**Әзһәр Габидинең иҗат кичәсе ........ 268**
**Укытучы көндәлегеннән ........ 270**
**Әзһәр Габиди – шигъри дөнья тылсымчысы ........ 273**
**Писатели и поэты моего края ........ 276**